Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова
Академии наук Республики Татарстан

# МӘДӘНИЯТЛӘР ТӨРЛЕЛЕГЕ КОНТЕКСТЫНДА ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ МИРАСЫ

ХАЛЫКАРА КОНФЕРЕНЦИЯ МАТЕРИАЛЛАРЫ

2017 елның 25 апреле. Казан шәһәре

# НАСЛЕДИЕ ГАЛИМДЖАНА ИБРАГИМОВА В КОНТЕКСТЕ МНОГООБРАЗИЯ КУЛЬТУР

МАТЕРИАЛЫ МЕЖДУНАРОДНОЙ КОНФЕРЕНЦИИ

25 апреля 2017 года, город Казань

КАЗАНЬ
2017

УДК 821.512.145(082)
ББК 83.3(2Рос=Тат)я43
Н 31

*Печатается решением Ученого совета*
*Института языка, литературы и искусства*
*им. Г. Ибрагимова АН РТ*

Сборник подготовлен при финансовой поддержке
РФФИ и Правительства Республики Татарстан
в рамках научного проекта № 17-14-16502

**Составители:**

***Ф.Х. Миннуллина, А.Ф. Ганиева***

**Н 31 Наследие Галимджана Ибрагимова в контексте многообразия культур:** материалы международной конфе рен ции, посвященной 130-летию со дня рождения Г. Ибрагимова / сост. Ф.Х. Мин нуллина, А.Ф. Ганиева. – Казань: ИЯЛИ, 2017. – 368 с.
ISBN 978-5-93091-219-7

В сборнике представлены материалы международной научно-практической конференции «Наследие Галимджана Ибрагимова в контексте многообразия культур», посвященной 130-летию со дня рождения классика татарской литературы Г. Ибрагимова.

Издание объединяет порядка 90 авторов из стран ближнего и дальнего зарубежья (Казахстан, Кыргызстан, Туркменистан и др.), регионов России (Башкортостан, Чувашская Республика, Крым и др.). Авторы сделали попытку охватить самые разные направления: творчество Галимджана Ибрагимова в контексте тюрко-татарской и мировой литературы; философские аспекты художественного, публицистического и эпистолярного наследия Галимджана Ибрагимова; Галимджан Ибрагимов как общественный и государственный деятель; литературно-критическая деятельность Галимджана Ибрагимова; Галимджан Ибрагимов и вопросы языкознания и пр.

Материалы публикуются в авторской редакции. За содержание ответственны авторы публикаций.

**ISBN 978-5-93091-219-7**

© Оформление. Институт языка, литературы
и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ, 2017

**Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты Мәгъзүм Хәлимулла улы Саләховның**

# СӘЛАМЛӘҮ СҮЗЕ

# ПРИВЕТСТВИЕ

**президента Академии наук Республики Татарстан Мякзюма Халимулловича Салахова**

Татар әдәбияты классигы, күренекле галим һәм публицист, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Гыйрфан улы Ибраһимовның тормышы һәм иҗаты татар халкы тарихында һәм мәдәниятендә мөһим урын алып тора. Ул – яңа татар әдәбиятын тудыручыларның, татар әдәбиятында романтик юнәлешкә нигез салучыларның берсе. Аның әсәрләре рухи хөрлеккә омтылган һәм күңел төшенкелегенә каршы торырга сәләтле кеше табигатен зурлый, иҗтимагый гаделлек һәм халыкларның тигез хокуклылыгы идеяләрен раслый.

Галимҗан Ибраһимов татар тел һәм әдәбият белеменә нигез сала, татар телен үзгәртеп коручы буларак танылa. Татар һәм башка төрки халыкларның тарихи үткәненә, мәгариф һәм педагогика, этнография һәм культурология мәсьәләләренә багышланган хезмәтләре аны татар җәмгыятендә генә танытып калмадылар, гомумтөрки мәдәниятендә дә сизелерлек эз калдырдылар.

1920 елларның уртасы – икенче яртысында ул Республика Фәннәр академиясенә башлангыч булып торган ТАССР Халык мәгарифе комиссариаты Гыйльми үзәген җитәкли. Татарстан Фәннәр академиясе өчен Галимҗан Ибраһимов фигурасы шуның белән дә аеруча кадерле. Г. Ибраһимов күпмилләтле республикабызның рухи тормышын һәм халкының тарихын, милли-мәдәни

Жизнь и деятельность классика татарской литературы, видного ученого-гуманитария и блестящего публициста, государственного и общественного деятеля Галимджана Гирфановича Ибрагимова занимают важное место в истории и культуре татарского народа. Он стал одним из создателей новой татарской литературы, родоначальником романтического направления в татарской словесности. Его произведения воспевают свободу духа и силу человеческого характера, способного противостоять угнетению, утверждают идеи социальной справедливости и равноправия народов.

Галимджан Ибрагимов заложил основы татарского языкознания и литературоведения, выступил в роли реформатора татарского языка. Его труды, посвящённые историческому прошлому татарского и других тюркских этносов, вопросам просвещения и педагогики, этнографии и культурологии снискали ему известность не только среди татарского образованного общества, они стали заметным явлением общетюркской культуры.

Для Академии наук Татарстана фигура Галимджана Ибрагимова имеет особое значение, поскольку в середине – второй половине 1920-х годов он возглавлял Академический центр Народного комиссариата просвещения ТАССР, который явился прообразом республиканской Академии наук. Г. Ибрагимов проводил курс на объединение учёных и специалистов

үзаңнары үсешен, белем дәрәҗәләрен күтәрүгә галимнәрне һәм белгечләрне тарта, махсус курслар оештыра. Әлеге тырышлыкның нәтиҗәсе дә күренә: Академүзәктә Һ. Атласи, Ж. Вәлиди, Н. Фирсов, В. Воробьёв, С. Сингалевич, М. Худяков, Г. Шәрәф һ.б. кебек күренекле галимнәр нәтиҗәле көч куялар.

Язучы, телче һәм тарихчы буларак Г. Ибраһимовның хезмәтләрен тану, хөрмәтләү йөзеннән Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына аның исеме бирелде, безнең Академиядәге исемле премияләрнең берсе күренекле галим һәм әдәбиятчы исеме белән аталган. Республикада гуманитар белем үсеше өчен күп көч куйган Татарстан Фәннәр академиясенең беренче президенты М.Х. Хәсәновның Г. Ибраһимов иҗатын тирәнтен һәм төрле яклап өйрәнүе дә очраклы түгелдер. Г. Ибраһимовның мирасын тикшерү һәм популярлаштыру традицияләре бүген дә уңышлы үсеп килә. Моңа ачык мисал итеп Татарстан Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты коллективы көче белән әзерләнгән Г. Ибраһимов әсәрләренең 15 томлык академик басмасын китерергә мөмкин.

Галимҗан Ибраһимов тарафыннан иҗат ителгән әдәби һәм публицистик әсәрләр, бөтен тормышы, халкына җаны-тәне белән бирелгәнлек үрнәге буларак, Татарстанның иҗтимагый-мәдәни үсеше өчен бәһасез кыйммәткә ия, безнең замандашлар өчен ышанычлы рухи кыйбла булып торалар.

для всестороннего изучения духовной жизни и истории народов нашей полиэтнической республики, роста их культурно-национального самосознания, повышения образовательного уровня. Эти усилия принесли результат, в Академцентре плодотворно трудились такие видные учёные, как Х. Атласи, Дж. Валиди, Н. Фирсов, В. Воробьёв, С. Сингалевич, М. Худяков, Г. Шараф, многие другие.

В знак признания неоспоримых заслуг Г. Ибрагимова как писателя, языковеда и историка его имя присвоено Институту языка, литературы и искусства АН РТ, а одна из именных премий нашей Академии названа в честь видного татарского учёного и литератора. Не случайно первый президент Академии наук Татарстана М.Х. Хасанов, много сделавший для развития гуманитарного знания в республике, глубоко и всесторонне изучал творчество Галимджана Ибрагимова. Традиции освоения наследия Г. Ибрагимова успешно развиваются и сегодня, о чём ярко свидетельствует подготовка к изданию пятнадцатитомного академического издания произведений Г. Ибрагимова силами коллектива ИЯЛИ АН РТ.

Созданные Галимджаном Ибрагимовым художественные и публицистические произведения, вся его жизнь как пример беззаветной преданности народу представляют собой неоспоримую ценность для социально-культурного развития Татарстана, служат надёжным нравственным ориентиром для наших современников.

## Халыкара Төрки академия президенты Дархан Кыдырәлинең
## КОТЛАУ СҮЗЕ

## ПРИВЕТСТВИЕ
## президента Международной Тюркской академии Дархана Кыдырали

Татар әдәбияты классигы Галимҗан Ибраһимовның тууының 130 еллык юбилее – бөтен төрки дөнья өчен аеруча мөһим мәдәни вакыйга, бик зур бәйрәм.

Тарих дигәнебез кешеләрнең биографияләреннән гыйбарәт. Аны бөек шәхесләр үз эшләре, изге гамәлләре белән язалар. Татар милләтенең һәм, шул ук вакытта, бөтен төрки дөньяның уртак әдибе, тел галиме һәм сәясәтчесе Галимҗан Ибраһимов та, һичшиксез, шундый бөек шәхесләрнең берсе.

Гомере кыска булса да, Г. Ибраһимов үзе эшләгән һәр өлкәдә, үз халкының тарихында үлмәс эз калдырды. Бүген аның исеме урамнарга бирелеп, иҗаты кешеләрнең рухи дөньясын баетуы шуның ачык билгесе.

Татарларның үзеннән тыш, башка тугандаш халыкларның да – казакъ, үзбәк һ.б. – күп кенә зыялылары Г. Ибраһимовны үзләренә остаз дип белгән. Шуны да аеруча билгеләп үтәргә кирәк ки, аның «Казакъ кызы» дигән романы бөтен Мәркәзи Азия әдәбиятларының үсешенә шактый тәэсир иткән иде.

Россия империясендә 1917 елда урын алган инкыйлаблар – бөтен дөньяны, хосусән бөтен Евразия киңлеген селкендергән социаль-сәяси катаклизмнар булды. Быел бу гаять зур масштаблы, искиткеч һәм коточкыч вакыйгаларның 100 еллыгы. Аңа нинди бәя бирелсә дә үзенчә юбилей дип әйтергә була – котлау өчен түгел, тирәннән уйланып, үткәнебездән дәрес алыр өчен кирәк ул безгә. XX йөздә ирешкән казанышларыбызны

130-летие классика татарской литературы Галимджана Ибрагимова – значимое культурное событие и большой праздник для всего тюркского мира.

Историю делают люди, великие люди, своими не менее великими делами, всей своей жизнью. Татарский писатель, который является своим для всего тюркского мира, языковед, политик Галимджан Ибрагимов, несомненно, один из таких людей.

Несмотря на короткую жизнь, Галимджан Ибрагимов в каждой области, которой занимался, добился впечатляющих результатов, оставил неизгладимый след в истории своего народа. Его творчество продолжает одухотворять читателей и сегодня, а имя увековечено в названиях улиц и научных учреждений.

Г. Ибрагимов был учителем для многих представителей интеллигенции и не только для татар, но и для других тюркских народов, в частности казахов, узбеков. Особо следует отметить роман «Казакъ кызы» («Дочь степи»), который оказал влияние на развитие литературы всей Центральной Азии.

Российская революция 1917 года стала социально-политическим катаклизмом, повлиявшим на весь мир, перетрясшим жизнь всей Евразии. В этом году 100-летие этого масштабного, удивительного и ужасного события. Как бы мы не оценивали это событие – особенно в дни юбилея – обязаны глубоко задуматься,

югалтмыйча, ясаган хаталарны киләчәктә кабатламас өчен бик кирәк.

Мәгълүм ки, төрки милләтнең зыялылары ул инкыйлаб дәверендә икегә бүленеп, һәр ике тарафта да үзенчә самими, үз милләтенең киләчәге өчен кайгырткан күренекле кешеләр булды. Бүген безнең бурычыбыз – аларны икегә бүлмичә, барысының да тарихи гамәлләрен уртак рухи кыйммәтләр, милли мәнфәгать ноктасы ягыннан алып карау һәм объектив бәя бирү. Чөнки милли тарих, теләсә кайсы халыкның тарихи аңы – ул милли аңның үсеше өчен, бәлки, хәтта телдән дә мөһим нәрсә. Тарихка үзенчә мәгънә биреп, ул турыда яза торган галимнәр узган еллар һәм көннәрдәге вакыйгалар турында гына язмыйлар, алар милләт киләчәгенең программасын язалар.

Төрки дөньяның галимнәрен берләштереп, төрки дәүләтләр һәм республикаларның уртак һәм бердәм интеллектуаль киңлеген булдыруны үзенә максат итүче Халыкара Төрки академия шул сәбәптән тарихны, хосусан мәдәният тарихын тикшерүгә аеруча әһәмият бирә.

Безнең халыкара оешма исеменнән Галимҗан Ибраһимовның тууының 130 еллык юбилее белән кардәш татар халкын, Татарстан Республикасының галимнәре һәм бөтен зыялыларын ихлас күңелдән тәбрик итүне үзем өчен шәрәф дип беләм.

Барыбызның якты киләчәгебез өчен үз җанын фида иткән бөек ата-бабаларыбызның, узган гасырларда яшәгән галим, әдип, батырларыбызның исемнәре безнең йөрәкләргә мәңге чигелгән.

Рухлары шат булсын!

Кардәш халыкларыбыз мәңге яшәсен!

попытаться правильно понять собственное прошлое, дабы не совершать более таких ошибок и не растерять достижения XX века.

Как известно, интеллигенция тюркских народов была разделена в тот период на два лагеря и на каждой стороне были талантливые люди, по-своему заботящиеся о будущем своего народа. Наша сегодняшняя задача – рассмотреть их деяния в едином ключе, с точки зрения духовных ценностей и национальных интересов, дать объективную оценку. Национальная история, историческое сознание каждого народа – необходимый элемент для развития национального самосознания, возможно, даже более необходимый, чем язык. Ученые, которые пишут историю, трактуя, наполняя смыслом прошедшие дни и события, по сути, пишут программу будущего для этноса.

Международная тюркская академия, которая ставит своей целью объединение ученых, создание единого интеллектуального пространства тюркского мира, придает поэтому особое значение истории, в частности истории культуры.

Для меня великая честь от имени нашей международной организации поздравить родственный татарский народ, ученых и деятелей культуры Татарстана со 130-летием Галимджана Ибрагимова.

Имена наших великих предков, ученых и писателей, живших в прошлом веке и положивших жизнь ради нашего светлого будущего, навсегда в наших сердцах.

Да возрадуется их дух!

Пусть живут вечно родственные народы!

## Башкортстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты Әлфис Суфиян улы Гаязовның СӘЛАМЛӘҮ СҮЗЕ

## ПРИВЕТСТВИЕ президента Академии наук Республики Башкортостан Альфиса Суфияновича Гаязова

Мөхтәрәм хезмәттәшләр!

Сезгә – татар әдәбияты классигы, дәүләт эшлеклесе һәм галим Г. Ибраһимовның тууына 130 ел тулуга багышланган фәнни конференциясендә катнашучы барлык галимнәргә Башкортостан сәламен җиткерәм.

Әлеге конфененцияне уздыру Татарстан һәм Башкортстан Республикаларының икесе өчен дә гаять мөһим вакыйга. Галимҗан Гыйрфан улы Ибраһимов безнең якташыбыз һәм аның дөньяга карашының тәүге орлыклары нәкъ менә башкорт җирендә – Уфадагы «Галия» мәдрәсәсендә бөреләнгән. Әдипнең актив тормыш позициясе аңа әдәби иҗатын һәм төрки мәдәниятебезне өйрәнеп тикшерү өлкәсендәге гыйльми эшчәнлеген киң колачлы итеп алып барырга нигез була. Галимҗан Ибраһимов, язучы буларак, бик тиз танылу яулый. Тәүге хикәяләре үк аның әдәби иҗаты белән зур кызыксыну уята. Ә аларда ул, «Яшь йөрәкләр», «Безнең көннәр», «Тирән тамырлар» кебек, укучы күңелен биләп алачак әсәрләренең сюжетын формалаштыра башлый. Г. Ибраһимов бу хезмәтләрендә шул чордагы сыйнфый катлам вәкилләренең төрле характердагы образларын чын осталарча гәүдәләндерүгә, XX гасырның 20–30 нчы елларында барган зур күләмле вакыйгаларны тарихи биеклеккә күтәреп сурәтләүгә ирешә. Г. Ибраһимов иҗаты тагын шуның белән үзенчәлекле – ул илдәге социаль каршылыкларның сәбәпләрен тирәннән яктырта һәм яңа кардиналь

Уважаемые коллеги!

Приветствую Вас на научной конференции, посвященной 130-летию со дня рождения классика татарской литературы, государственного деятеля и ученого Г. Ибрагимова.

Данная конференции – знаменательное событие для наших республик – Татарстана и Башкортостана. Галимджан Гирфанович Ибрагимов является уроженцем нашего края и основы его мировоззрения формировались на башкирской земле в уфимском медресе «Галия». Активная жизненная позиция обусловила многогранность его деятельности как литератора и исследователя тюркской культуры. Достаточно быстро Галимджан Ибрагимов стал известным писателем. В качестве интересных литературных опытов можно отметить ранние рассказы. С первых лет творчества Г. Ибрагимов приступает к разработке сюжетов широко известных впоследствии романов: «Молодые сердца», «Наши дни», «Глубокие корни». В этих произведениях Г. Ибрагимов проявил себя как мастер психологизма, создатель масштабного исторического полотна ряда событий первой трети XX века. Следует отметить, что в творчестве Г. Ибрагимов раскрывает глубинные истоки социальных противоречий и обозначает тенденции к кардинальным переменам. Представляются широта и разнообразие характеров персонажей, философское осмысление действительности. Все это создает

үзгәрешләрнең юнәлешләрен билгели. Төрле катлау кешеләрнең характерларын бөтен киңлеге һәм нечкәлекләре белән сурәтли, чынбарлык хакында философларча фикер йөртә. Язучы тарафыннан гәүдәләндерелгән әдәби геройларның укучыны җәлеп итү сере дә менә шунда. Татар әдәбияты классигы әсәрләре төрле илләрдә күп телләргә тәрҗемә ителеп кат-кат басылып чыкты.

Г. Ибраһимов эшчәнлегенең мөһим юнәлеше – аның татар грамматикасын, әдәбият теориясен, туган телне укыту методикасын колачлаган гыйльми хезмәтләре. Галимнең тикшеренү стиле җиңел аңлаешлы һәм белем бирү процессында актуальлеген һичкайчан югалтмый.

Бүгенге форум Г. Ибраһимовның рухи мирасын төрле аспектта тормышка ашырырга омтылган белгечләрне берләштерә. Димәк, халкыбызның теле, фольклоры, әдәбияты үсешенә уңай йогынты ясарга тиешле яңа фәнни хезмәтләр әзерләү өчен шартлар тагын да киңәячәк.

Күпмилләтле һәм күпконфессияле Россия дәүләте үсешенең бүгенге этабында гомум мәдәни чыганакларны һәм туганнарча хезмәттәшлекне саклау аеруча мөһим, чөнки алар безнең халыкларны гасырлар дәвамында бәйләп торган, шуңа күрә киләчәктә дә үзара ышаныч, эчкерсезлек, бер-беребезне хөрмәт итү, диалог һәм иҗади хезмәттәшлек милләтара мөнәсәбәтләрнең нигезен тәшкил итәргә тиеш.

Конференциядә катнашучыларның һәркайсы өчен дә бу изге эшнең нәтиҗәле һәм уңышлы булуын, яңа казанышларга юл ачуын телим!

притягательность образов литературных героев. Труды классика татарской литературы были изданы на многих языках народов мира.

Важным направлением деятельности Г. Ибрагимова была научная работа, которая проявилась в подготовке ряда трудов, посвященных татарской грамматике, теории литературы, методике преподавания родного языка. Стиль его исследований отличается доступностью, что весьма актуально для применения в образовательном процессе.

Сегодняшний форум объединил гуманитариев, которые являются преемниками духовного наследия Г. Ибрагимова, что находит отражение в их исследованиях. Создаются условия для подготовки новых трудов в гуманитарной области знаний, обеспечивается содействие в изучении и сохранении языков новыми исследованиями, что должно благотворно повлиять на развитие языка, фольклора, литературы наших народов.

Считаю, что на нынешнем этапе развития многонационального и многоконфессионального Российского государства особенно важно сохранить общие истоки культуры и братское сотрудничество – все, что столетиями связывает наши народы, поэтому основой межнациональных отношений должны и впредь оставаться доверие, открытость, взаимоуважение, диалог и созидание.

Желаю всем участникам конференции плодотворной и содержательной работы, новых свершений, успехов и благополучия!

# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ИДЕАЛЛАРЫ: «МИН ХӘЯТ ЭЗЛӘДЕМ, ХӘЯТТА МӘГЪНӘ ЭЗЛӘДЕМ...»

***Заһидуллина Д.Ф.***

В статье рассматривается литературное творчество Г. Ибрагимова в разрезе его жизненной философии, общественных и эстетических установок. На основе анализа «знаковых» произведений писателя, в контексте его творческой эволюции, сделана попытка выявить идеалы, адресованные читателю. Предполагается, что в его творчестве, с одной стороны, презентован идеал борьбы за счастье народа, за национальный прогресс, напрямую связанный с идеей о необходимости постоянного самообразования, саморазвития, духовного совершенствования личности. С другой стороны, писатель воспевает образ жизни, менталитет, мировоззрение и философию, традиции и нравственно-эстетические ценности татарского народа, общетюркского мира, предупреждая о грозящей возможности утраты этого бесценного богатства.

In the article literary creativity of G. Ibragimov from the point of view of representation of his vital philosophy, the purposes, public and esthetic ideals is considered. On the example of the analysis of writer'ssign works in the context of his creative evolution the attempt of identification of the ideals addressed to the reader is made. It is supposed that in his creativity, on the one hand, the ideal of fight for happiness of the people, for the national progress directly connected with need of fixed self-education, self-development, spiritual enhancement of the personality is presented. On the other hand, the writer sings of lifestyle, mentality, outlook and philosophy, traditions and moral and esthetic values of the Tatar people, the all-Turkic world, warns about possible loss of this beauty.

Галимҗан Ибраһимов – татар мәдәниятен һәм гомумән җәмгыятен, әдәбиятны, фәнне, милли үзаңны үзгәртүгә зур өлеш керткән шәхесләрдән. Аның тормышы, иҗаты, күпкырлы сәяси, фәнни һәм мәдәни эшчәнлеге бер максатка – татар яңарышына, алгарышына, татар дөньясын яктырак, матуррак, рухлырак югарылыкка күтәрүгә хезмәт итә. Тормышының һәр баскычында ул үзенең шушы максаты һәм идеаллары турында армый-талмый сөйли, халыкны шул үзе күзаллаган яктылыкка, биеклеккә чакыра.

Бу юлда Г. Ибраһимов ялгыз түгел: татар яңарыш хәрәкәтен мәйданга чыгарган күп шәхесләрнең биографиясендә, рухи үсү-ныгуында уртак сәхифәләр, гомум иҗтимагый-тарихи сәбәпләр бар. Буыннан-буынга муллалык итеп, халыкны агартып яшәгән нәселнең дәвамчысы Галимҗанны 11 яшендә этисе Оренбург шәһәренең кадими «Вәлия» мәдрәсәсенә китерә. 1905 еллар шаукымында татар шәкертләре мәктәп-мәдрәсәләрне ташлап чыга башлагач, ул Уфадагы танылган «Галия» мәдрәсәсенә ирекле тыңлаучы булып урнаша.

Әлеге вакыйгалар тәэсирендә егетнең халыкка җиткерер мөрәҗәгате формалаша: 1907 елны әдәби эчтәлеген Фатих Әмирхан формалаштырып килгән «Әл-ислах» газетында «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» (1907) хикәясе басылып чыга. Әсәр кадим мәдрәсәләрнең эчке тәртипләрен, уку-укыту программаларын, укыту рәвешен, мондагы наданлыкны, артталыкны көлү объекты ясый, укуга сәләтле, тырыш, тыйнак, тәрбияле мәхдүм Зәкинең усал, мәнсез, каты күңелле шәкерткә әверелү юлын тергезә. Яшь язучы кадим уку йортларының милли җәмгыятьне аяныч түбәнлектә тотуын ассызыклый, халыкның милли үзаңын, җәмгыятьне үзгәртү юлын, милләтне яктылыкка чыгару мөмкинлеген җәдит уку-укыту системасы белән бәйләп карый. Башлангыч чор иҗатында кызыл җеп булып сузылган идеал – төпле белем алып, милләткә хезмәт итү аның үзен дә Казанга килеп университетка яки башка рус югары уку йортына керү уена китерә.

Г. Ибраһимовның әдәби иҗатында өйрәнчек чор тәмамланганны хәбәр иткән «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә» (1909) хикәясендә инкыйлаб һәм аннан соңгы елларда зыялы татар яшьләрендәге фикри үзгәрешләр сурәтләнә. Сюжет Сәлим исемле яшь егетнең Әстерханнан өч тапкыр Казанга килүен колачлый. Беренче килүе 1901 елда була, бу вакытта Сәлим – милләтне яратучы, бөтен барлыгын, тормышын милләт өчен корбан итәргә әзер «ялкынлы милли идеяле яшь бер адәм» [4, б. 476]. Берничә ел үткәч Казанга килгәндә, «ул, тар «милләтчелек» даирәсеннән чыгып, «инсаният даирәсенә» күчкән, милләтчелекне ташлап, инсаниятче булган, «милләтем... татарым...»ны ташлап, «ватаным – бөтен җир йөзе... милләтем – бөтен бәни бәшәр» нәзариясенә иман китергән иде» [4, б. 481]. Өченче килүендә герой бу фикерләреннән дә ваз кичкән, шәхси мәнфәгатьләрен кайгыртучы, үзенең тормышын көйләү өчен, университетка укырга керергә теләүче булып күренә. Әмма ул үзенең милләтче вакытын сагына, шул чакларын кайтарып алу хакында хыяллана. Автор аның өчен идеалның – билгеле бер идеягә, максатка хезмәт итү, яшәү мәгънәсе булуын ассызыклый.

Фикри эзләнүләр әдәби тәҗрибәләр белән янәшә бара. «Гыйшык корбаннары» (1908) хикәясе, «Татар хатыны ниләр күрми» (1909) повесте кешенең шәхси бәхеткә ирешүен һәм мәхәббәт өчен көрәшүен алгы планга чыгара. Язучы актив, җәмгыятьтә кабул ителгән тәртипләр, иске гореф-гадәтләр белән килешмичә, үз тормышын башка юлдан җибәрергә омтылган геройлар тудыра (хикәя геройлары Сәгыйд һәм Галимә – бай улы һәм ярлы кызы – мондый тигезсезлеккә карамыйча мәхәббәтләре өчен көрәшә; повесть героинясы Гөлбану туган йортыннан кача һәм ирләр кыяфәтендә ил гизеп йөри башлый). Алар бәхеткә ирешә алмасалар да, әсәрләрдәге «гыйсъянчылык чаткылары» [1, б. 187] һәр кешенең хөр рухын, бәхеткә омтылышын яшәештәге олы кыйммәт итеп күтәрә.

Әлеге әсәрләр язучының психологизм алымнарына бик теләп мөрәҗәгать итә башлавы, табигатьне тасвирлау осталыгы хакында сөйли. Бигрәк тә повестьта татар һәм башкорт халыкларының гореф-гадәтләренә, йолаларына, этнографик үзенчәлекләренә (әйтик, чәчү-игү эшләре белән бәйле өмәләргә, тула, каз өмәләренә, аулак өйләргә) киң урын бирелеп, милли яшәештәге матурлыкны барлау омтылышы ачык күренә. Бу сыйфатлар алга таба әдипнең күпсанлы хикәяләрендә дәвам итә.

«Татар хатыны ниләр күрми» повесте әдипнең һәм шәрык, һәм гареб әдәбиятлары традицияләрен бер әсәр эчендә үреп җибәрү осталыгын күр-

сәтә. Бер яктан, язучы әсәренә җирлек итеп төрки-татар халкында мәгълүм «Җиде кыз» бәетенең сюжетын ала [5, б. 302]. Балачак-үсмерчактан Гөлбану акыллы, матур, уңган кыз, әнисе Фәтхия әбинең кадерле баласы булып үсә. Аның төп хыялы – яраткан кешесенә кияүгә чыгып, матур гаилә кору, бәхетле яшәү. Эчкече һәм тупас Закир белән яшәү дә, аннан качып китеп, башкорт бае карт Солтанга хатын булу мәҗбүрияте дә, әлеге бай караклар кулыннан үлгәч, аның 11 яшьлек энесенә никахлану да Гөлбануны бәхетле итә алмый. Димәк, хатын-кыз булып яшәгәндә Гөлбануга (иске тәртипләр белән яшәгәндә – татар җәмгыятенә!) үз язмышын үзгәртергә мөмкинлек юк! Ирләр сафына басудан башка чара калмый. Язучы героинясын, чәчен кистереп, киемен алыштырып, Габдуллага әйләндерә. Символик планда бу адым татар хатын-кызларын азат итүнең бердәнбер юлы – ирләр белән тигез сафка басу, аларның яшәү рәвешен өлге итеп алу кебек аңлашыла.

Ләкин Гөлбануның холкы-психологиясе Габдулла булып яшәүдән дә бәхет таба алмый: язучы аны туган өенә юнәлтә. Мифологик «әйләнеп кайту» мотивы кеше үз табигый тормышы белән яшәргә тиешлеген ассызыклый: татар хатын кызы, хатын-кыз булып калган хәлдә, ирләр хокукларына ия булырга тиешлеккә игътибар юнәлтә.

«Татар хатыны ниләр күрми» повестендагы күп кенә мөһим форма хасиятләре: табигать сурәтләреннән оста файдалану, кеше кичерешләрен урыны белән аң агышы дәрәҗәсендә күзәтеп бару – язучының күпсанлы романтик хикәяләрендә камилләшә. «Яз башы» (1910), «Диңгездә» (1911), «Йөз ел элек» (1911), «Карак мулла» (1911), «Сөю – сәгадәт» (1911) һ.б. Әсәрдән әсәргә язучының фикерләү көче арта. Дөньяның фәлсәфи сурәте Г. Ибраһимовның «Уты сүнгән җәһәннәм» (1911) хикәясендә милли җәмгыятьтәге хәл-ситуация белән бәйләп күрсәтелә: автор татар мәдрәсәләрендәге белем дәрәҗәсенең түбән, татар яшьләренең үз максатларына ирешү юлы авыр булуны үкенеч, сызлану (экзистенциализм) фәлсәфәсенең сәбәбе ясый. Садыйк – мәдрәсә тәмамлап авылда яшәүче, мулла вазифасын башкаручы ир – өенә үзе белән бергә укыган Гыйльман Каһиров килә. Бу визит Садыйкны чарасызлыкка төшерә. Бай малайларыннан булган Садыйкка самовар куеп, гел җәберсетелеп йөргән Гыйльман, мәдрәсәдән китеп, русча укыган, зур кеше булган. Автор Садыйк-философ авызыннан кешеләрне ике төркемгә бүлә: язмышны үзгәртүчеләр һәм аңа буйсынучылар. Садыйкның максаты татар егетләренең күбесенеке төсле үк: «…үзеңне үзгәртү, мәдәниләштерү, дөнья фәннәре тәхсиль итеп, иҗтимагый эшләрнең бере артыннан йөри торган бер халык хезмәтчесе булу минем баш теләгем иде» [4, б. 128]. Ләкин егет үзе «сәҗдә кыла торган идеалына» ирешми, моны үзенең йомшак характеры белән бәйләп аңлата, мәдрәсә белеме белән канәгатьләнү, мулла булу – камилләшүдән, мәдәниләшүдән туктау дигән фикер белдерелә. Хикәядә Г. Ибраһимов белем алудан, үз өстендә эшләүдән, камилләшүдән туктамаган кеше идеалын тудыра, шул вакытта гына шәхес милләткә файдалы була дигән фикер ассызыклана.

Г. Ибраһимов иҗатында йөзек кашы булган романтик әсәр – «Яшь йөрәкләр» романы (1912) – XX йөз башында иҗат ителгән олы эпик жанр үрнәкләре арасында фәлсәфи-психологик характеры белән аерылып тора, «мәүзугының яңалыгы, мөндәриҗәсенең киңлеге, алган каһарманнары, тел-өслүбенең яңа һәм үткенлеге белән башкалардан, шөбһәсез, аерым урын тота иде» [6, б.138]. Сюжет бирелеше белән роман үз чоры тормышын

тергезә. Авылда яшәгән ике күрше гаилә, бигрәк тә Җәләш мулла, аның балалары Зыя, Сабир мисалында, язучы «аталар» һәм «балалар» каршылыгын тудыра, аталары дөрес дип тапкан яшәү рәвешенең балалар омтылышларына тәңгәл килмәве хакында сөйли. Әсәр татар прозасында яңалык булган күп хасиятләргә ия: психологизм тудыру алымнары буларак файдаланылган аң агышы, төшләргә күпләп мөрәҗәгать итү, кешенең озак вакытка сузылган чиктәш халәтен тасвирлау аны чынбарлык чикләреннән алып чыга.

Романда сурәтләнгән геройлар язмышы мохиттән азат булырга омтылыш белән бәйләнгән. Әсәрдә кешегә каршы куелган мохит – күпмедер күләмдә трансцендентальлеккә ия төшенчә. Ул кешене әйләндереп алган тирәлеккә дә, җәмгыятькә дә тәңгәл түгел. Мәгънәдәш сүз төсендә язучы «язмыш»ны файдалана. Мохит чикләреннән чыккан, аны җиңгән шәхесләр генә җәмгыятьне, милләтне үзгәртә ала дигән фәлсәфә тәкъдим ителә.

Романда яңа бер мотив – үзгә идеал: милләтне югары сәнгатьнең үзгәртә алуы алга чыга. Романтик герой Зыя музыкага гашыйк, көйне нечкә тоемлаучы итеп сурәтләнә. Үз заманында Г. Гобәйдуллин Зыя образы безнең мохиттә генә формалаша алырлык тип дип атый: «Ул 1905 елларның буранлы инкыйлаблары арасыннан чыккан адәм, ул еллар аны инкыйлабчы ясамыйча, матурлык сөюче, «музыкателист» ясаганнар. Анда матурлык коры матурлык кына түгел, гыйшык, милләт вә табигыя берлә бергә манчылган рухи бер матурлыктыр» [2, б. 194]. Бу бәядә «инкыйлабчы» һәм «матурлыкны сөюче» каршы куела; татар җәмгыятенең нечкә күңелле, рухи бай, талантлы яшьләр үстереп җиткерүе дә, аларга үз сәләтләрен милләт файдасына хезмәткә куярлык шартлар тудырылмау да ассызыклана. Алга таба Г. Ибраһимовның әдәби һәм фәнни иҗатының буеннан-буена сузылып барган сәнгатьнең роле турындагы концепция болай яңгырый: үсештән туктаган милләтләрне сәнгать уята, кузгата, алга җибәрә ала.

Г. Ибраһимовның 1913–1917 еллар иҗатында иҗтимагый-сәяси вакыйгаларны, гади халык тормышын яктырту омтылышы көчәя, әдәбият-сәнгать, аларның кешелек җәмгыятендәге урыны турында уйланулар тагын да калкулана. «Карт ялчы» (1912) хикәясе гади кеше, авыл кешесе образы тудыра, картайган һәм көчсезләнгән Шаһибәк картның авыр хезмәт белән, ач-ялангач һәм рухи түбәнсетелеп яшәвен хикәяләүче – мин ролен башкаручы яшь егет Сәфәрнең шушы хәлләргә мөнәсәбәт белдерүе рәвешендә корып, укучы игътибарын социаль каршылыкка юнәлтә. «Көтүчеләр» (1913) хикәясендә, гади кешеләрнең гадәттән тыш авыр көнитешен тасвирлау белән янәшә, әдәбият, сәнгать, фәннең кешелек җәмгыятендәге роле, иҗтимагый вазифасы турында уйланулар урын алган. Ассоциацияләр остасы булып җитешкән Ибраһимов-язучы бу әсәрдә көтелмәгән фәлсәфә формалаштыра. «Тормыш-яшәештә һәр кеше бары тик үз шәхси тормышын гына үзгәртә ала» дигән фикер XX йөз башы татар яңарышы кысаларында шулкадәр гаҗәп тоела, күрәсең, шуның өчен дә язучы аны шик астына ала, капма-каршы фәлсәфи фикерләр дә тоемланырлык әдәби структура төзи.

Кеше һәм җәмгыять тормышында сәнгать-мәдәниятнең роле хакындагы фикерләр «Мәрхүмнең дәфтәреннән» (1914) хикәясендә яңа югарылыкта тәкъдим ителә. Романтик сюжетны язучының романтик хикәяләүче герое – карт шагыйрь күңелендә барган рухи эзләнүләр барлыкка китерә. Ул фәлсәфи мәсьәлә, тормыш мәгънәсен эзләүдән туа: «Мин хәят эзләдем, хәятта мәгънә эзләдем, хәятның барлык рәхәтләрен фида кыйлдырырлык

мәртәбәдә изге була алырлык бер идеал эзләдем. Моны кем эзләмәгәндер, ләкин табучы булганмы?» [4, б. 206] – дип сөйли карт шагыйрь.

Г. Ибраһимов бу хикәядә башка әсәрләрендә белдерелгән идеяләрне бер-бер артлы кире кага. Яшәү идеалы, җир йөзендәге бәхет – матур кызларда, мәхәббәттә дип ышанган чагы да була карт шагыйрьнең. Ләкин ул аннан ваз кичә. Яшәү мәгънәсен эзләп дингә дә мөрәҗәгать итә. Ләкин «дин исеменнән түгелгән кан дәрьяларын» [4, б. 207] күреп, гайрәте чигә. Изге идеал дип милләткә хезмәтне саный. Ләкин бу юлда да төрле ихтыяҗларның бугазга-бугаз килүен аңлый. Ниһаять, игътибары фән, гыйлем һәм мәдәнияткә төбәлә. Герой әдәбият һәм сәнгать алдында «тук мещаннар һәм бай аристократлар»га [4, б. 207] хезмәт итүдән башка максатны эзли, йөрәге белән көтә, ләкин таба алмый. Нәтиҗәдә рухи газаплана, җәфа чигә. Язучы шундый авыр шөбһәләр эчендәге героен караңгы бакчада тормыш төбендә яшәүче кешеләр – сукбайлар белән очраштыра. Хикәяләүчедән аермалы буларак, болар реалистик планда, натуралистик детальләр ярдәмендә сурәтләнә. Автор карт шагыйрьгә алар авызыннан рәхмәт әйттерә, язган әсәрләренең бу кешеләргә җан азыгы булып хезмәт иткәнлеген хәбәр иттерә. Сукбайлар исеменнән шагыйрьгә әйтелгән рәхмәт «сәнгатьнең төп максаты – тормыш төбендәге кешеләргә хезмәт күрсәтү, аларны хак юлга өндәү» дигән фикерне раслый.

Язучы кешеләрне икегә бүлә: чынбарлыкта һәм хыял белән яшәүчеләр. Һәм романтикларның, идеал эзләүчеләрнең бәхетне иҗатта, сәнгатьтә таба алуын раслый, аларны тынгысыз яшәргә этәргән көчләрне билгеләп уза. Кешеләрнең икенче яртысы – «тәңренең бәхетле коллары», шуларның вәкиле булган сукбайлар өчен дә бәхет, рәхәтлек – әдәбият укуда, ул тудырган иллюзиядә кебек аңлашыла. Нәтиҗәдә, әдәбият – язучылар өчен генә түгел, укучы өчен дә тормыш мәгънәсе, яшәү шатлыгы дигән хакыйкать ассызыклана. Автор әдәбият һәм сәнгатьнең кеше тормышындагы урыны хакында уйлана. Шәхес өчен газиз кыйммәтләр: ана һәм сөйгән яр, дин, фән, гыйлем, милләт күздән кичерелеп, әдәбият аларның барыннан да югары куела, тормыштагы иң газиз нәрсә кебек шәрехләнә. Ләкин бәхетнең әдәбиятта – уйлап табылган, иҗат ителгән дөньяда – булуы кешенең иллюзия белән яшәвен дә искәртә.

Беренче рус инкыйлабы хәрәкәтләрен һәм татарларның милли сәясәт юлында эзләнүләрен тасвирлаган «Безнең көннәр» романы (1914–1920) языла башлау аның икенче юлда каләм сынауны тиеш табуы турында сөйли. Язучы татар җәмгыятендә 1905 ел инкыйлабы китереп чыгарган хәрәкәтләрне, аларның төрле катлаулардан чыккан кешеләр язмышына тәэсирен күрсәтеп, тарихны үзгәртү кешедән зур корбаннар сорый, үзен тулысынча шул көрәшкә багышлауны таләп итә дип белдерә.

1917 ел инкыйлабларын Г. Ибраһимов, үз сүзләре белән әйткәндә, «пролетариат революциясенең солдаты» булып каршылый. Мәсләк итеп большевиклар позициясен сайлаган язучы шушы көрәштә милли мәнфәгатьләрне күздә тоткан күпләр: татарның талантлы фикер ияләре, язучы-галимнәре, бергәләшеп татар яңарышының нигезләрен салган фидакарьләр – белән чын-чынлап бәрелешә, аларны буржуазлыкта гаепләү позициясенә килә. Әйтик, «Милләт мәҗлесе»ндә Г. Ибраһимов, күп кенә татар зыялылары милләтне саклауның, үстерүнең бердәнбер юлы итеп караган «культура-милли автономия» идеясенә каршы чыгып, территориаль автономия

фикерен яклый. Бүгенге көн биеклегеннән чыгып караганда, әлеге фикернең тамырдан ялгыш булганлыгын, татарларны, тарихи татар җирләрен автономия чикләреннән тышта калдыруын билгеләү авыр түгел. Шуның белән бергә, 1926 елны Г. Ибраһимов Беренче тюркология съездында латин графикасына күчүнең милли-мәдәни мирастан аерылу юлы булуын күтәреп чыга. «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?» (1927) китабындагы татар җәмгыятен Татарстан белән генә чикләп куюның дөрес түгеллегенә, милли мәдәният һәм милли бердәмлек үсешенә, киләчәгенә кагылышлы фикерләре зур тәҗрибә туплаган җәмәгать эшлеклелесенең ахыр чиктә үз халкы-милләте язмышын беренче урынга куюы турында сөйли. Г. Ибраһимовның 1917 ел инкыйлабыннан соңгы катлаулы, каршылыклы фикри эзләнүләре, күрәсең, милли җәмгыять чикләреннән чыгып, гомумән кешелек дөньясын бәхеткә ирештерү омтылышы белән дә аңлатыла. Кызганычка каршы, халкыбызның талантлы улы, шушы тормышка ашмас хыял утында янып, вакытсыз һәлак була.

Язучы иҗат эшеннән дә читтә түгел. Ләкин яңа әсәрләр мисалында аның иҗат дөньясы кай якка үзгәрә бару ачык күренә. «Яңа кешеләр» (1920) драмасы революцияләр чоры тәрбияләгән яңа кешеләр образын тудыручы беренче әсәрләрдән була. Анда канлы көрәш юлы бердәнбер дөрес юл дип билгеләнә, аның сәбәпләре итеп иҗтимагый тигезсезлек һәм милли азатлыкка ирешү өмете күрсәтелә.

Бергә уйнап үскән биш егет тормышын, дуслыгын, аларның иҗтимагый-тарихи вакыйгалар тәэсирендә төрле сукмаклардан аерылып киткән язмышын колачлаган «Кызыл чәчәкләр» (1921) повесте татар авылындагы сыйнфый катламнар: сәүдәгәрләр, муллалар, һөнәрчеләр, ярлы крестьяннар – вәкилләренең 1917 елгы вакыйгаларга мөнәсәбәтен ача. Повесть татар җәмгыяте өчен актуаль булган, милли азатлыкка ирешү юлларына кагылышлы бәхәсне үзәккә куя. Милләткә ирекне сыйнфый көрәш һәм инкыйлаб юлыннан барып яки төрле милли-дини төркемнәрнең бер идея тирәсендә берләшүе аша бирергә мөмкинме дигән сорауга җавап бер: язучы бары тик инкыйлаб һәм көрәш кенә якты киләчәккә илтәчәген ассызыклый.

Әмма 1922 елны язылган «Алмачуар» хикәясендә язучы бөтенләй башка материалга мөрәҗәгать итә: татар кешесенең атка мәхәббәтен, сабантуйлар, көрәш, ат чабыштыруларның матурлыгын күрсәтә. Авыл малае Закирның атка мәхәббәте – татар кешесенең аңында, аң төпкелендә яшәүче атка, ат чабышларына, сабантуй бәйрәмнәренә мәхәббәт белән тәңгәлләштерелә. Язучы милли менталитетны, татар кешесенә хас милли күзаллауны ачыкларга, яктыртырга омтыла, моны югала баручы матурлык дәрәҗәсенә куя.

Г. Ибраһимов «Казакъ кызы» (1923) романында сәяси-тарихи вакыйгаларның гомумән төрки халыкларга тәэсире, төрки дөньяны ничек үзгәртүе мәсьәләсе күтәрелә. Мавыктыргыч һәм фаҗигале мәхәббәт тарихы, романтик геройлар Арысланбай белән Карлыгач-Сылуның үз бәхете-мәхәббәте өчен көрәше фонында язучы казак далаларындагы көнитеш, сәяси, иҗтимагый көрәш хакында сөйли. Гасырлар дәвамында бер көйгә салынган дала тормышына инкыйлабтан соң Дәүләт Думасына сайлаулар ташкыны үтеп керә, сәяси партияләр көрәше төрки ил-йорт өчен көрәшкә әверелә. Иң йогынтылы һәм көчле ике ыруг – кара-айгыр һәм сарман башлыклары Байтүрә һәм Сарсымбай җитәкләгән ике партия ике төрле яшәү рәвешен алга куя. Күнегелгән тәртипләрне үзгәртергә ашыкмаган Сарсымбай, аның

уң кулы Биремҗан әкә – үз җиренең патриотлары. Кара-айгыр йортының җитәкчеләре, заман агышын бик тиз тоемлаучы Байтүрәләр, Азымбайлар исә – шәхси байлыкка омтылучы, үз мәнфәгатьләре өчен ил-йортны ак патшага сатарга әзер кешеләр итеп тасвирлана. Шәхси бәхет өчен көрәш сәяси көрәш белән кушылып китә һәм Карлыгачның йола бозуы, ахыр чиктә, Сарсымбайның да, Арысланбайның да илдән сөрелүенә китерә. Әсәрнең идеясе, шулай итеп, шәхси бәхет өчен көрәшүнең ил тынычлыгы, азатлыгы өчен көрәшкә комачаулавы турында сөйли.

Роман казах халкының матди һәм рухи тормышын, көнитеш рәвешен, мал карау, күчеп йөрүләрне, гадәт-йолаларны, кыз урлау, мәет күмү, мәҗлесләр, туйларны – барысын-барысын этнографик төгәллек белән сурәтләп һәм вакыйгалар агышына оста үреп бара. Бер яктан, әсәр казах тормышының этнографик энциклопедиясе дәрәҗәсендә булса, икенче яктан, төрки-татарларның да күчмә заманнары, борынгы яшәү рәвешләре белән ассоциацияләр уята. Мәҗүсилек һәм ислам йолалары гармониядә яши торган тирәлек, гаделлекнең табигатьтәгечә аңланылуы, табигать биргән нигъмәтләр белән көнкүрү рәвеше самимилеге белән үзенә җәлеп итә. Бу тормышның югала баруын автор үкенеч хисе белән ассызыклый, идеал итеп күтәрә.

Г. Ибраһимовның соңгы еллар иҗаты аның төрле сукмаклар эзләп каравы, тормышны мөмкин кадәр колачлырак, җентекләбрәк тасвирлау өчен яңа формалар сайлавы хакында сөйли. Бу чорда жанрлар ягыннан киңәю дә, тематик төрлелек тә, романтизмнан – натурализмга кадәр күчеш-сикерешләр дә язучының чор таләп иткән яңа әдәбиятның нигезләрен табарга омтылышы кебек аңлашыла. «Тирән тамырлар» (1928) романы – социалистик реализм агымында иҗат ителгән әсәре, Г. Ибраһимовның шушы агымда милли әдәби традицияләрне яңартуына бер дәлил булып тора. Әйтерсең, әдип яңа тормыш төзү барышын сурәтләүне әдәбиятка үзе куйган таләпләрдән артык читләшмичә алып барырга тели: маҗаралылык, чорга бәя бирүне тирән тамырлар символы ярдәмендә башкару, композиция өлкәсендәге тәҗрибәләр, сюжеттан тыш элементларның күпләп кулланылуы «пролетар әдәбиятына» хас схематизмнан котылырга мөмкинлек бирә. Детектив сюжет, «Хезмәт» совхозының алдынгы эшчесе Фәхринең үтерелгән гәүдәсе табылу, җинаятьчеләрне эзләү, аларны табып җәза бирү кебек классик тәртиптә үсә барып, әсәрне мавыктыргыч ясый. Бер үк вакытта, «җинаять – җәза» рамкаларын Г. Ибраһимов социалистик идеяләр белән рухланган массалар психологиясен ачу өчен файдалана, җәмгыятьтә әхлак принципларының үзгәрешен бәян итә.

Кызганычка каршы, Г. Ибраһимов шушы романыннан соң башка зур әдәби әсәр тудырырга өлгерми. Аның иҗади эзләнүләре роман белән өзелеп кала. Ул үз әсәрләрен русчага тәрҗемә итеп бастырып чыгаруга күп хезмәт сала. Гыйльми-тәнкыйди эшчәнлеге дә дәвам итә. Ләкин каты авыру аның эшләү мөмкинлекләрен нык чикли. Шулай да утызынчы елларда Г. Ибраһимовның төрле мәдәни өлкәләрдә: фән яки иҗтимагый мәсьәләләр булсын, әдәбият яки тел белеме булсын – абруе гаять зур. 1927 елның апреленнән сәламәтлеге бик нык какшау сәбәпле Ялтада яшәвенә карамастан, ул төрки-татар дөньясында иң йогынтылы шәхесләрдән булып кала.

1932 елның 11 ноябрь карары белән Г. Ибраһимовка «Хезмәт герое» дигән мактаулы исем бирелә. Ләкин шәхес культының кара күләгәсе Галимҗан Ибраһимов кояшын да каплый: ул 1937 елның 29 августында,

контрреволюцион хәрәкәткә кушылуда гаепләнеп, кулга алына. Казанга озатылган авыру әдип, үлем турындагы справкага караганда, 1938 елның 21 гыйнварында җан бирә [3, б. 79].

Г. Ибраһимов – XX гасыр башында мәйданга чыккан яңа татар әдәбиятын тудыручы, аның үсеш юлларын билгеләүче талантлы прозаик һәм фикер иясе иде. Тормышның бөтенлекле тарихи-мәдәни сурәтен ясау ягыннан аның проза әсәрләре рус һәм Европа сүз осталарының эпос традицияләрен дәвам итә. Шул ук вакытта фәлсәфи тирәнлек, өстәмә мәгънәләр бирү, күпкатламлы тормыш моделе төзү өчен ул шәрык әдәбиятларына, саф европа романтизмына хас символларга, психологизм алымнарына мөрәҗәгать итә, шулар ярдәмендә тарихи заман алып килгән тема һәм мотивларга милли яңгыраш бирә. Аның әдәби иҗатында, бер яктан, халык бәхете, милләтне үстерү өчен көрәш, шушы көрәштә файдалы булу өчен туктаусыз белем алу, хезмәт итү, рухи камилләшү идеалы алга алына. Икенче яктан, язучы татар халкының, төрки дөньяның яшәү рәвешен, менталитетын, фәлсәфәсен, йола-гадәтләрен, әхлакый-эстетик кыйммәтләрен идеал итеп күтәрә, шуларның матурлыгын җырлый, югалу мөмкинлеген искәртеп сызлана.

ӘДӘБИЯТ


1. Бәширов Ф. XX йөз башы татар прозасы. Казан: Фикер, 2002. 287 б.
2. Газиз Г. Яшь әдәбиятыбызда «Яшь йөрәкләр» // Аң. 1913. № 11. Б. 189–194.
3. Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых (авт.-сост. М.Х. Ибрагимов). Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. 336 с.
4. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. 1 т.: хикәяләр (1907–1929). 509 б.
5. Минһаҗева Р.Ә. Галимҗан Ибраһимов иҗатында руссочыл традицияләр // Галимҗан Ибраһимовның иҗат дөньясында. Казан, 2012. Б. 235–373.
6. Сәгъди Г. Татар әдәбияты тарихы // Габдрахман Сәгъди: фәнни-биографик җыентык / төз. Д.Заһидуллина, Ч. Гыйлаҗева. Казан: Җыен, 2008. Б. 52–189.


## ВОПРОСЫ НАЦИОНАЛЬНОЙ ИДЕНТИЧНОСТИ В СТАТЬЯХ Г. ИБРАГИМОВА 1910–1920-х гг.


***Ибрагимов М.И.***



В статье анализируются взгляды Г. Ибрагимова на проблему национальной идентичности в трудах 1910–1920-х гг.

Установлено, что в статьях 1910-х гг. Г. Ибрагимов выступает против последователей И. Гаспринского, сторонников идентификации татар как тюрков, и отстаивает этноним «татары» как интегрирующий татар в тюркский мир и мировое сообщество наций.

На основе анализа статей Г. Ибрагимова 1920-х гг. устанавливается позиция Г. Ибрагимова относительно отношений между тюркскими языками и литературами, определяемое ученым как «литературно-культурная федерация». В ее основе идея равноправия национальных языков и литератур, множественности идентификаций, одним из проявлений которой является различное отношение к реформе арабского алфавита.

In this article analyzes the views of G. Ibragimov on the problem of national identity in the works of 1910–1920s.

Is established: in the articles of 1910s G. Ibragimov opposed the followers of I. Gasprinsky, supporters of the turkic identification of the Tatars. G. Ibragimov

defends the ethnonym "Tatars" as an integration of the Tatars in the turkic world and the world community of nations.
Is defined the position of G. Ibragimov on the relationship between turkic languages and literatures in the writings of the 1920s. It is based on the idea of equality of national languages and literatures, and the multiplicity of identities.

В начале XX века на страницах татарской периодической печати развернулась дискуссия о национальной идентичности татар. Г. Ибрагимов пишет ряд статей, в которых выступает против последователей идей И. Гаспринского, отвергавших этноним «татары» и ратовавших за самоидентификацию татар как тюрков.

Полемизируя на страницах журнала «Шура» с Хасаном Гали, автором статьи «Без төрекмез» («Мы тюрки»), Г. Ибрагимов, в частности, размышляет по поводу этнонима «татары». Не отрицая принадлежности татар к тюркскому миру, ученый-публицист указывает на грозящую нивелированием национальной идентичности (языковой, культурной) самоидентификацию исключительно как тюрков: «Төрек нәме – славян, герман, романнар кебек – гомуми бер исем булып, соңгылар эчендә төрдле исемләр белән йөргән әллә ничә милләт булдыгы кебек, терек (төркеме) дә төрле исемләр белән йөртелгән кавемнәргә аерылган. (Димәк), хас исемебезне ташлап, «төрек» дип атала башласак, без башка төрек кабиләләре белән исемдә аерыла алмыйбыз» [5, с. 14].

Этноним «татары» выделяет, по мнению Г. Ибрагимова, татар как часть многообразного (объединяющего множество языков и культур) тюркского мира и, одновременно, интегрирует татар в сообщество наций: «Милләтләр эчендә без татар милләте аталып китеп утырабыз. Тарихның мөназәрәсе бу бер мәртәбә бирелгән һәм гомумчә танылган исемне алыштыруда – ачык яңлыш булса да – мен мәртәбә гаҗиздер» [5, с. 13]. Ученый пишет о его (этнонима) распространенности у других народов как слова, идентифицирующего татар: «Әммә аңа карап, һич бер вакыт бездән «татар» дигән сүз алына алмас. Ул яңлыш булыр, бөтен дөнья аның яңлышлыгын белер, аның зур әфәте дә булыр, шул хәлдә дә ул алышдырыла алмас. Чөнки ул мәхаль бер эш. Андый бер мәртәбә бирелгән исемләрне яңлыш булса да, әүвәлгечә дәвам иткәнлегенә әдәмләрдә, фәнни истилахларда, милләтләрнең, мәмләкәтләрнең – хәттә Америка шикелле бөтен бер кыйтгъәләрнең – исемләрендә дөнья тулы мисал» [4, с. 10].

В статьях Г. Ибрагимова 1910-х гг. проблема национальной идентичности не ограничивается вопросом о самоидентификации татар. В многочисленных трудах по вопросам языка, литературы, искусства татарский ученый размышляет о выраженности в них национального духа.

В предисловии к опубликованному в 1915 году под названием «Альбом» собранию произведений изобразительного искусства Г. Ибрагимов пишет об искусстве как единственной сфере человеческой деятельности, в которой раскрывается национальный характер, дух народа: «Әмма сәнаигы нәфисә инде бөтенләй башка. Бер милләтнең сәнаигы нәфисә генә асыл табигате ачылып җитә ала. Тик сәнаигы нәфисә генә бер кавемнең эчке йөзен, аның табигатенең маһиятен ача ала» [1, с. 191]. «Икътисад, гыйлем, һөнәр, – продолжает автор предисловия, – боларның һәркаюсы бәйнәлмиләл нәрсәләр. Русмы, татармы, французмы – моңар карап аерылмый. Ике җирдә

ике французга дә дүрт, татарга да; җир шары урыска да түгәрәк, немецка да! Болар турында икенче халыктан алырга ихтыяҗ – миллият ноктасына кагылмый. Ләкин сәнаигы нәфисә алай түгел; музыка, тәрсим, әдәбият – болар халыкның рухы, болар һәр халыкның үзенә, тик үзенә махсус... шулай һәр халыкның сәнгате – аның үзенең аерым җаны, аерым йөрәге, аның тик үзенә генә мәгълүм, тик үзенә генә аңлый ала торган серле руханиятедер» [1, с. 198–199].

Концептуальной основой в этой и других работах Г. Ибрагимова 1910-х гг. является понимание искусства как выражения национального духа («милли рух», «халык рухы», «миллият»), что было характерно для многих деятелей татарской культуры начала XX века (Г. Рахима, Д. Валиди, Г. Баттала, Г. Губайдуллина).

Среди трудов Г. Ибрагимова 1920-х гг., в которых ставятся вопросы национальной идентичности татарской культуры (языка, литературы), выделяются публикации в связи с состоявшимся в 1926 году в Баку Первым тюркологическим съездом. В опубликованных на страницах татарской периодической печати статьях ученый высказывает свою позицию относительно отношений между тюркскими языками и литературами, используя понятие «литературно-культурная федерация»: «Төрек телләренең һәрберенең аерым хасиятләре дә, һәммәгә уртак хасиятләре дә бар. Шуңа карап телләр үзләренең эчке төзелешләрендә мохтар-автоном үсәләр, әммә гомуми нигезләре буенча бер-беренә багълаy налар. Без моны «әдәби-мәдәни федерация» дип атасак, ачык булачактыр. Бу нигездә барганда, телләр җирле халыкка багъланып, массадан аерылмаячак, шунын белән бергә югары менгән-үскән саен, якынлаша барачак» [2, с. 273]. Понятие «литературно-культурная федерация» в понимании Г. Ибрагимова заключает в себя идею равноправия между национальными литературами и языками, когда каждая (каждый) из них развивается самостоятельно, обладает имманентными свойствами, сформировавшимися в процессе их исторической эволюции, участвует в межлитературном процессе как его равноправный субъект и, одновременно, благодаря языковым и литературным сходствам, выступает как часть языкового и литературного сообщества.

Идея равноправия и самостоятельности национальных языков и литератур определяет взгляды ученого и в вопросе об алфавите тюркских народов. Ученый считает, что старый арабский алфавит создает большие трудности для современной печатной техники («Гарәп әлифбасы, гарәп хәрефләре үзләренең иске рәвешләрендә сакланып барсалар, хәзерге заман техникасы өчен зур уңайсызлык тудыра...») и нуждается в замене. Указывая на два обозначившихся на Первом тюркологическом съезде подхода к этому вопросу – революционный (замена арабского алфавита латинским) и реформаторский (реформа арабского алфавита в соответствии с особенностями национального языка) – Г. Ибрагимов, разъясняя позицию всей татарской делегации, пишет о праве каждого народа на выбор алфавита: замену арабского алфавита латинским или реформу арабского алфавита.

Эта идея (она находит отражение в резолюции съезда: «Съезд считает введение нового алфавита и метод его проведения в отдельных тюрко-татарских республиках и областях делом каждой республики и каждого народа») представляется чрезвычайно плодотворной для тюркского мира: в ее основе мысль об исторически сложившемся многообразии тюркских языков

и литератур и, одновременно, о сходстве между ними, которые являются основой для межъязыкового, межлитературного, а в широком смысле, межкультурного диалога. Используемое Г. Ибрагимовым понятие «литературно-культурная федерация» не несет в себе политического смысла, это аналогия, посредством которой ученый определяет характер отношений между тюркскими языками и литературами: «Һәрбер әдәби тел тик үзенә караган эчке аерым хасиятләре, шартлары нигезендә мохтар-автоном рәвештә төзелә, ләкин башка әдәби төрки телләр белән булган уртак хасиятләр, гомуми нигезләр буенча алар белән якын бәгъланыш ясый. Әгәр сәяси атамаларны мәдәни-әдәби мәгънәләрне аңлату өчен [кулану] яраса, бу аерылу һәм бәрелешү мөнәсәбәтен әдәби-мәдәни федерация дип атарга мөмкин булыр иде. Әдәби төрки телләрнең бер-берсенә мөнәсәбәтләре, бер федерация эченә кергән мохтар-автоном бүлекләрнең бер берсенә һәи гомумгә мөнәсәбәтләренә охшаш рәвештә булыр» [3, с. 291].

Г. Ибрагимов подчеркивает, что каждый из тюркских языков и каждая литература обладают своей идентичностью, складывающейся в процессе исторического развития. Различное отношение к вопросу об алфавите ученый объясняет историей формирования и развития разных тюркских языков и литератур. Реформа арабского алфавита применительно к татарскому языку и литературе объясняется Г. Ибрагимовым многовековой историей письменности у татар, более чем столетней историей книгопечатания и начатой еще в 60-е годы XIX века К. Насыйри работой по реформированию арабского алфавита. «Хәзер, – пишет Г. Ибрагимов, – безнең типографияләребез, хәреф җыючыларыбыз, мәктәпләребез, укытучыларыбыз, язучыларыбыз, басылып тарала торган дәреслекләребез, йөз мең басыла торган әлифбабыз, көтепхәнәләребез, карангы авылллардагы уку өйләребез – һәммәсе, һәммәсе шул төзәтелгән гарәп хәрефләре нигезендә матбугат һәм әдәбиятка корылганнар. Халкыбызның 30% шул хәреф белән укырга-язарга өйрәнгәнләр. Менә бу зур мәдәни хәрәкәт машинасы туктаусыз әйләнеп эшләп тора. Латинга күчү дигән сүз – бу машинасы туктатып, яңа нигездән яңадан-яңа юлларга күчереп утырту, үсеп торган мәдәни хәрәкәтнең барышын акырынайту дигән сүздер» [3, с. 283–284].

Вместе с тем, позицию башкирских, якутских, киргизских ученых по переходу на латиницу Г. Ибрагимов мотивирует особенностями развития письменности у башкир, якутов, киргизов: «Әммә Башкортстанга, Якутстанга яки Кыргызстанга килсәк, без аларның латинны алабыз, дип бик җиңел генә карар бирүләренең сәбәбен яхшы аңлыйбыз. Башкорт әдәбиятының беренче адымлары Бабичтан башлана. Киңәеп китүенә әле ике генә ел. Шуңар күрә алар зур бер мәдәни хәрәкәтне бөтенләй яңа рельсләргә күчерү кебек мәсьүлият алдында түгелләр. Шулай ук... Кыргызстанда да ... әлифба да, матбугат та яңа туып килә, мәктәпне яңа ачалар, мөгаллимне яңа хәзерлиләр. Болар үзләре алдында туктаусыз эшләп торган машинаны сүтеп, яңа нигезгә кору мәшәкъкәтен түгел, бәлки бөтенләй буш урынга яңа бина салу, шуңа нигез сайлау кебек бер эш алдында торалар» [3, с. 284]. Иными обстоятельствами, по мнению Г. Ибрагимова, мотивирована революционная позиция по отношению к арабскому алфавиту у азербайджанских ученых: «Әммә Әзәрбайҗанның үзенә килсәк, боларда иске гарәп хәрефләре, имлясы, әдәби телләре бер дә төзәтелмәгән яки бик аз төзәтелгән. Шуңар күрә, гарәп әлифбасының аларда

сакланган хәле, рәвеше хәзерге ихтыяҗларга, техникага бик зур уңайсызлык ясый» [3, с. 284].

Таким образом, формирующаяся в процессе исторического развития идентичность тюркских языков и литератур является для Г. Ибрагимова основой для выбора алфавита и, одновременно, для культурной интеграции, понимаемой ученым не как процесс нивелирования языковых и культурных различий, а как основывающееся на диалоге различий сближение национальных культур.

Такое понимание идентичности актуально для осмысления современного межлитературного процесса. К. Султанов, рассуждая по поводу этнокультурного поворота в изучении национальных литератур, указывает на две крайности в современных исследованиях по литературам народов РФ: «транскультурации с ее «взрывными модификациями» и таким отношением к «родной» литературе, когда она аттестуется как «окаменелость», «символическое насилие» и даже «гетто идентичности», и, с другой стороны, абсолютизированной этнокультурной предзаданности, оттеснившей аксиологическую составляющую на периферию литературоведческого анализа» [6, с. 15–16]. Вторая крайность, по мнению ученого, проявилась в возобладавшей «статической модели описания национальной литературы, адаптированной преимущественно к поиску и обнаружению этнокультурных детерминаций», и в усилении центробежной тенденция, «превратившей «диалог» как якобы рецидив «дружбы народов» в спящую категорию», следствием чего стал кризис межкультурной коммуникации, в методологическом плане проявившийся «в разъединенность этнокультурного и коммуникативного дискурсов, не обнаруживающих точек соприкосновения» [6, с. 16].

Очевидно, что высказанные Г. Ибрагимовым в 1910–1920-е гг. идеи были направлены на преодоление указанных современным ученым крайностей. Татарский писатель, ученый, публицист выступал с позиций сохранения национальной идентичности и, как свидетельствуют его публикации, утверждал диалогическую природу идентичности, понимая диалог как диалог различных и (что имеет принципиальное значение) равных между собой языков и литератур.

ЛИТЕРАТУРА

1. Ибраһимов Г. Альбом мөнәсәбәте белән бер-ике сүз // Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. 5 т.: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). Б. 178–201.

2. Ибраһимов Г. Тюркология съезды нәрсә бирде? // Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 8 т.: төрки һәм татар теле белеме буенча хезмәтләр (1910–1930). Б. 271–276.

3. Ибраһимов Г. Тюркология съездында тикшерелеп үтелгән мәсьәләләр // Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 8 т.: төрки һәм татар теле белеме буенча хезмәтләр (1910–1930). Б. 281–299.

4. Ибраһимов Г. «Без кем?» бәхәсе // Ибраһимов Г. Милләт. Тел. Әдәбият: сайланма хезмәтләр. Казан: Мәгариф, 2007. С. 9–10.

5. Ибраһимов Г. Без – татармыз // Ибраһимов Г. Милләт. Тел. Әдәбият: сайланма хөзмәтләр. Казан: Мәгариф, 2007. С. 11–14.

6. Султанов К. К вопросу об «этнокультурном повороте» в изучении литератур народов России // STEPHANOS. 2015. № 2. С. 10–19.

# ТАТАРЛАРДА ФӘННИ-ТИКШЕРЕНҮ ҮЗӘКЛӘРЕ (ИНСТИТУТЛАРЫ) ОЕШТЫРУ ИДЕЯСЕ ҺӘМ ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ

***Миңнуллин К.М.***

Күп гасырлар буе татар халкының тарихи хәтерендә Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыкларының мәшһүр мәдрәсәләре, бай китапханәләре хакындагы риваятләр, гыйлемне халыкка хезмәткә кую, аны кешелек җәмгыяте үсешенең нигезенә салу, милли мәгарифне, фәнне үстерү идеясе яшәп килә. Татар тарихында халкыбызга Кол Гали, Мөхәммәдъяр, Утыз Имәни, Курсави, Мәрҗани, Тукай кебек шәхесләрне биргән, гасырлар дәвамында «югары уку йортлары» булып хезмәт иткән мәдрәсәләр системасы, Казан гимназиясендә ачылган татар классы (1769), Казан Император университеты (1804), анда ачылган Көнчыгыш разряды (1829), университет каршында оештырылган «Археология, тарих һәм этнография» җәмгыяте (1878) һ.б. күпмедер күләмдә милли тарихка һәм мәдәнияткә кагылышлы гыйльми тикшеренүләрне үстерү мәйданчыгы итеп карала.

Татар мәгърифәтчелек хәрәкәте бу хыялны татар җәмәгатьчелегенә җиткерергә мөмкинлек бирә. Сәгыйт, Исхак, Ибраһим Хәлфиннәр, Ш. Мәрҗани, К.Насыйри кебек мәгърифәтчеләр эшчәнлегенең нигезендә яткан фикерләр сүз сәнгатенә дә үтеп керә, әдәбият аларны киң халык массаларына таратуның мөһим юлы дип санала. Муса Акъегетзадәнең «Хисаметдин менла» (1886) повестенда мулла Хисаметдин, гимназист Әбүзәр Дәүләтгилдиев образлары аша халыкның киләчәге белем-мәгърифәт белән бәйләп куела [3, с. 307].

Күренекле әдәбиятчы Җ. Вәлиди «Вакыт» газетасында басылган «Әдәби хәрәкәт» (1916) язмасында мәгърифәтчелек әдәбиятында «мөселманнарны йокыдан уятмак, анларны әтрафларына каратмак, бу көнге гыйлем вә мәдәният зыясыны күрсәтмәк, вә шул вәҗһ илә ахирәткә генә иман китергән мөселманнарны дөньяга да иман китертмәк, тәрәкъкый вә тәмәдден юлына сәвекъ итмәк» [7, б.380], ягъни гыйлем һәм мәдәни үсеш юлына өндәгән әсәрләр дип Р. Фәхретдиннең «Әсма, яки Гамәл вә җәза» (1903), «Сәлимә, яки Гыйффәт» (1899) повестьларын һәм И. Гаспралының «Дар әр-рәхәт мөселманнары» (1887) повестен күрсәтә, аларга шушы яктан анализ ясый. Соңгы повесть язучының иң беренче җитди әсәре «Фрэнкистан мектюплери» («Франциядән хатлар») романының бер кисәге булып тора. Җ. Вәлиди әйтүенчә, «Тәрҗеман» газетасы 1906 елда укучыларга бүләк итеп тараткан-га күрә [7, б. 385], бу повесть татарлар арасында бик популяр була һәм татар әдәбиятына зур йогынты ясый. «Әсәр герое Мулла Габбас әкияти Дар әр-рәхәт иленә килеп эләгә, язучы аның күргәннәре аша утопик җәмгыять моделен төзи» [4, с. 48]. Бу илдә фән һәм техника нык алга киткән, мәктәп-мәдрәсәләр, сырхауханәләр, китапханәләр, хокук саклау оешмалары һ.б. гаҗәпкә калдырырлык. Мәдрәсә – югары уку йортында өч: дини-фәлсәфи, физик-техник һәм социаль-икътисадый факультетларда югары әзерлекле профессорлар укыта. Моннан тыш, югары фәнни оешма – Голәмәләр Шурасы эшләп килә, монда фәннең төрле юнәлешләре үстерелә [5]. Шул рәвешле, И. Гаспралы мәсләктәшләренә киләчәк төрки-татар дөньясының аерылгысыз бер өлеше итеп югары фәнни оешма булдыруны билгели, аның нинди булырга тиешлеген күрсәтә.

Охшаш утопик фикерләрне З. Һадиның «Яңа әсхабе кәһәф» (1908) хикәясендә, Ф. Әмирханның «Фәтхулла хәзрәт» (1909) повестенда һ.б. әсәрләрдә дә күрергә мөмкин. XX йөз башы публицистикасында да, татарларда җәдит мәктәпләр, мәдрәсәләр ачу белән бергә, югары фәнни оешмалар булдыру фикере күренә башлый. Мәсәлән, 1908 елда Йосыф Акчура «Вакыт» газетасында «Мәдрәсәләрдә тарих дәресе укыту турында» дигән мәкалә бастыра, анда болай дип яза: «Без халкыбыз тарихын булдыру бурычын үзебез үтәргә тиешле. Моңа без бурычлыбыз. Милләтебез тарихыннан сибелгән, таралган нәрсәләрне үзебез эзлик. Булдыра алган кадәрен табып-җыеп, мәйданга куйыйк. Шул юлда хезмәт итәргә сәләтле, яраклы эзләүчеләрне, алар эшен оештыручы оешмалар булдырыйк» [1, б. 39]. «Алар эшен оештыручы оешмалар» дигәндә фәнни үзәкләр, институтлар күздә тотыла.

1917 елга кадәр татар җәмгыяте бу максатны тормышка ашырырга өлгерми, ләкин мәсьәлә инде әзерләнеп җиткән була. 1918 елның маенда Казанда мөселман-укытучыларның III Бөтенроссия съезды уза. Фатих Сәйфи-Казанлы чыгышында Казанда Мәркәз мөселман Комиссариаты каршында махсус фәнни оешма – «Гыйльми һәйәт» оештыру мәсьәләсе кузгатыла.

Шунысын да әйтергә кирәк: «Галия» дә Г. Ибраһимов белән бергә укытучы булып эшләгән Ф. Сәйфи-Казанлы 1917 елдан соң аның иң якын хезмәттәшләренең берсенә, фикердәшенә әверелә. Февраль революциясе булуга, алар бергәләп «Ирек» газетасы оештыралар, аннары «Солдат теләге» газетасы белән кушылып, «Безнең юл» дигән басма әзерлиләр. Һәр икесендә дә Г. Ибраһимов – редактор, Ф. Сәйфи-Казанлы сәркятиб вазифаларын башкара. Шунысы мөһим: беренче татар гыйльми-тикшеренү үзәкләрен оештыруга өлеш керткән шәхесләр исемлегендә Ф. Сәйфи-Казанлы һәм Г. Ибраһимовның да лаеклы үз урыны бар.

Галимҗан Ибраһимовның оештыру осталыгы, мәдрәсәләрдәге уку-укыту системасының кимчелекле һәм уңай якларын укытучылык тәҗрибәсе аша яхшы тануы Татарстанда гыйльми-тикшеренү үзәкләрен оештыру, фәнни эзләнүләр системасын заман шартларына яраклаштыру эшендә зур мөмкинлекләр ача. 1918 елның октябрендә Г. Ибраһимов Мәскәүдән Казанга кайта, «Гыйльми һәйәт» оештыру мәсьәләләре белән дә шөгыльләнә башлый. 1918 ел ахырына оешма фәнни бүлек статусында эшкә керешә, аның махсус органы булган «Мәгариф» журналы чыга. Галимҗан Ибраһимов – «Мәгариф»не оештыручы, аның беренче мөхәррире. Ул әлеге оешманың фәнни концепциясен эшләүчеләрнең дә берсе була. ««Гыйльми һәйәт» үз алдына республикадагы фәнни эшчәнлекне оештыру бурычын куя, бу эш төбәкне, аның табигый байлыкларын, иҗтимагый, тарихи һәм этнографик үзенчәлекләрен өйрәнү кебек күзаллана» [2, с. 9]. Моннан тыш, оешма мәдәният, әдәбият, сәнгать, халыкны агарту мәсьәләләрен дә үз җаваплылыгына ала.

«1920 елның маенда Татар Республикасы төзелү уңаеннан тикшеренү өлкәләре күпкә киңәя, махсус фәнни-тикшеренү җәмгыятьләре һәм үзәкләре барлыкка килә. Алар арасында 1921 елда Мәгариф халык комиссариаты каршында оештырылган Академик үзәк аерым урын алып тора. Үзәкнең беренче рәисе итеп Г. Максудов (1922–1924) билгеләнә. Аннан соң бу вазыйфаны Г. Ибраһимов (1927 елга кадәр), Р. Таһиров (1927–1929 еллар), С. Атнаголов (1929–1930 еллар) башкара. Аның хезмәткәрләре арасында Е. Черны-

шев, Н. Фирсов, М. Худяков, Г. Гобәйдуллин, М. Корбангалиев, Х. Бәдигый, Г. Рәхим, Җ. Вәлиди, Г. Алпаров, М. Фазлуллин кебек атаклы галимнәр булган» [6, б. 11].

Чыннан да, 1921 елның 3 декабрендә ТССР Мәгариф Халык комиссариаты каршында Гыйльми үзәк оештыру турында карар кабул ителү татар мәгарифе, фәне өчен зур вакыйга була. 1921–1924 елларда Үзәк аякка басу баскычын уза. Г. Ибраһимов бу эшләрнең уртасында кайный. 1922 елдан ул Гыйльми Үзәкнең редакцион коллегиясе әгъзасы, «Татарларны өйрәнү җәмгыяте»нең рәис урынбасары. «Редакцион коллегиядә ул үзенең эшен әдәби һәм фәнни әсәрләрне рецензияләүдән башлый. Г. Рәхим белән Г. Гобәйдуллинның берничә кисәктән торган «Татар әдәбияты тарихы», Һ. Такташның «Җир уллары» (1923), «Давылдан соң» (1925) шигырь җыентыклары, К. Тинчуринның «Зар» (1923) драмасы Г. Ибраһимов фатихасы белән дөнья күрә. Башка байтак әсәрләр аның бәяләмәсе белән басыла» [8, б. 120–121]. Гыйльми үзәк татар телендәге «Безнең юл», «Мәгариф» журналларын, рус телендә «Вестник просвещения» журналын нәшер итүне җитәкли.

1925 елның 7 гыйнварында җитәкче булып Г. Ибраһимов килгәннән соң, «1925–1927 еллар Гыйльми Үзәкнең иң нәтиҗәле эшчәнлек чоры булып тора» [9, с. 4]. Г. Ибраһимов бер үк вакытта – Татарстан төбәкләрен өйрәнү бюросы рәисе, Бөтенроссия ҮБК һәм ТАССР ҮБК Президиумы әгъзасы да.

Гыйльми Үзәк төбәктәге барлык фәнни, фәнни-оештыру һәм мәдәни-оештыру эшен үз җаваплылыгына ала. Аның эшчәнлегендә методик (уку-укыту планнары һәм программалары эшләү, методик мәсьәләләр хәл итү), укыту (укытучылар әзерләү һәм аларның белемен күтәрү), тел белеме (татар телендә фәнни терминология булдыру, сүзлекләр төзү, тәрҗемәчеләр әзерләү), сәнгать (татар театрларының репертуарын контрольдә тоту һәм баету, татар музыкасын үстерү һәм популярлаштыру, музейлар, китапханәләр, түгәрәкләр эшчәнлеген актилаштыру, китап палатасы оештыру), фән (төбәк тарихын, монда яшәгән төрле милләтләр мәдәниятен, төбәкнең табигатен, иҗтимагый, икътисадый үсешен өйрәнү, археология, тарих, этнография, филология кебек фәннәрне үстерү), борынгы һәйкәлләрне, мәдәни мирасны саклау һәм өйрәнү юнәлешләре аерылып чыга. Үзәктә өч җәмгыять: Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте, Табигатьне яратучылар җәмгыяте һәм Татарларны өйрәнү җәмгыяте эшләп килә, аларның төзелеше һәм эшчәнлеге аерым фәнни институтлар структурасын хәтерләтә. Болардан тыш та аерым оешмалар төзелә тора. Шундыйлардан, 1925 елның 19 маенда Г. Ибраһимов җитәкчелегендә оешкан Татар төбәкне өйрәнүчеләр бюросын аерып күрсәтергә мөмкин [2, с. 29]. Төбәкне өйрәнү мәсьәләләре буенча конференцияләр уздыру, экскурсияләр уздыру эшен җайга салу, фәнни-популяр лекцияләр укуны даими нигезгә кую – бу бюро эшчәнлегенең кайбер нәтиҗәләре шулар.

Җәмгыятьләрнең эше елдан-елга киңәя бара. 1925 елдан Татарларны өйрәнү җәмгыяте республиканың аерым кантоннарына экспедицияләр (елга 10) оештыра башлый, үз журналын – «Татарларны өйрәнү җәмгыятенең хәбәрләре» («Вестник научного общества татароведения», елга 4 сан) булдыра, китаплар бастыра, конференцияләр, төрле чаралар оештыра һ.б. Мәсәлән, олы шәхесләрнең юбилейларын уздыру Гыйльми үзәк карамагына тапшырыла. Әйтик, 1925 елның 15 февралендә К. Насыйриның 100 еллык юбилее гаять масштаблы билгеләп үтелә. Фәнни җыентык,

моңарчы басылмаган хезмәтләре бер том итеп басмага әзерләнә, мәкаләләр дөнья күрә, Татар дәүләт Академия театры бинасында зур кичә була, анда Г. Ибраһимов, Г. Рәхим, М/ Корбангалиев, М. Парсин чыгыш ясый.

Гыйльми Үзәк планнары белән тәңгәл китереп, татар әдәбияты тарихын язу эше башлана. 1922–1927 еллар аралыгында Гыйльми үзәкнең әгъзалары булган Г. Рәхим һәм Г. Гобәйдуллиннар «Татар әдәбияты тарихы» томнарын, 1923 елда Җ. Вәлиди «Очерк истории образованности и литературы татар» хезмәтен бастыра. 1925 елның көзендә Г. Ибраһимов Г. Сәгъдине татар әдәбияты тарихы мәсьәләләре белән шөгыльләнү өчен махсус Казанга чакырып кайтарта. 1926 елда Г. Сәгъдинең «Татар әдәбияты тарихы», «Кешелек дөньясында тел, әдәбият, язу һәм хезмәтләре дөнья күрә.

Беренче тапкыр әдәби барышның күркәм традицияләрен популярлаштырган «Татар әдәбияты көтепханәсе» сериясе нигезләнә, 1925–1927 елларда шул сериядә М. Акъегетзадә, З. Бигиев, З. Бәшири, М. Гали, Ш. Камал, Ф. Кәрими, М. Максуд, Һ. Такташ, К. Әмири һ.б. әсәрләре басылып чыга.

Болардан тыш, Гыйльми үзәк аспирантурада белгечләр әзерләү, Мәскәү фәнни институтларында кадрларның белемен күтәрү, музейлар, күргәзмәләр оештыру, республика фәнен һәм мәдәниятен читтә пропагандалау кебек тагын бик күп мәсьәләләр белән шөгыльләнә. Фән өлкәсендә чын мәгънәсендә берничә институтны берләштергән академик үзәккә әверелә. Болар барысы да әлеге фәнни оешманың җитәкчесе Галимҗан Ибраһимов һәм аның шәхесе тирәсенә тупланган татар галимнәре эшчәнлегенең күркәм нәтиҗәсе санала.

Бу елларда Г. Ибраһимов көнне төнгә ялгап эшли: галимнәр белән аралаша, төрле чараларда катнаша, чыгышлар ясый, яңадан-яңа проектлар нигезли. Әмма 1927 елның 17 мартында, Татарстан советларының 7 съездында чакта, Г. Ибраһимовның хәле начарлана: үпкәсен кан басудан, аспирацион пневмония башлана. Аны Казандагы Иске университет клиникасына салалар. Табиблар консилиумы, үпкә туберкулезы дигән диагноз куеп, кичекмәстән җылы һавалы якларга китәргә киңәш бирә. Гыйльми үзәктәге вазифасын тапшырып, ул 21 апрельдә Кырымга кузгала. 10 ел Ялтада яшәгәннән соң, 1937 елның 29 августында кулга алына, 1938 елның 21 гыйнварында Черек күл төрмә хастаханәсендә үлә.

1930 елларга инде Гыйльми үзәкнең эше сүлпәнәя, аның вазифаларын, төрле институтлар оештырып, шуларга бүлеп бирү омтылышлары ясала. Шул исәптән гуманитар фәннәр дә төрле оешмаларга күчеп йөри [10]. 1937 елның 16 апрелендә ТАССР ҮБК Президиумы Татар тел һәм әдәбият фәнни-тикшеренү институтын оештыру турында карар кабул итә. Институт үзенең эшчәнлеген 1939 елның 7 октябрендә башлап җибәрә. Академик үзәктә эшләгән галимнәрнең күбесе фәнни эшчәнлекләрен шушы институт хезмәткәрләре буларак дәвам итәләр. 1946 елның гыйнварында СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы оештырылып, Институт аның составына кертелә һәм СССР Фәннәр академиясенең фәнни оешмасына әверелә.

Нәкъ менә шушы институт 1956 елдан башлап Г. Ибраһимовның иҗат мирасын кайтару эшен гамәлгә куя: әсәрләре басмага әзерләнә, юбилейлары уңае белән конференцияләр оештырыла, фәнни хезмәтләр башкарыла. Аерым алганда, өч томлык сайланма әсәрләрен басмага әзерләү эшен Г. Халит җитәкли. 1961 елда исә яшь галим М.Х. Хәсәнов Галимҗан Ибраһимов-

ның Октябрьгә кадәрге иҗаты буенча кандидатлык диссертациясен төгәлли [12], 1964 елда монография бастыра [13], 1971 елда докторлык диссертациясен яклый [11]. Әдипнең иҗат мирасын өйрәнү юнәлешендә Х. Госман, И. Нуруллин, А. Шамов, Ф. Әгъзәмов, С. Поварисов, Я. Абдуллин, Ф. Бәширов, М. Мәһдиев һ.б. галимнәр хезмәт куя. 1974 елда язучының сигез томлыгын (1974-1987) әзерләү турында карар кабул ителә, институт бу зур эшне дә матур башкарып чыга.

1967 елны Тел, әдәбият һәм тарих институтына Г. Ибраһимов исеме бирелә (хәзер – Татарстан Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты). Бу факт тирән символик мәгънәгә ия: татар мәдәнияте тарихында Г. Ибраһимов татар халкының махсус фәнни үзәкләр, институтлар оештырып, фәнне үстерү хыялын тормышка ашырган шәхесләрнең берсе булды. Республикадагы татар телен, әдәбиятын, сәнгатен өйрәнү белән шөгыльләнүче, зур тарихлы институтның аның исемен йөртүе бу мәсьәләдә дәвамчанлыкны күрсәтеп тора.

Г. Ибраһимовның татар фәнен оештыру өлкәсендәге эшчәнлеге озак вакытлар күләгәдә кала килде, без соңгы елларда гына аның бу юнәлештә дә милләтебез өчен бәһаләп бетергесез хезмәт башкарганын күрә, аңлый һәм бәяли башладык. Язучының әдәби һәм фәнни-публицистик мирасын яңа югарылыкта бәяләү өчен мөмкинлекләр туды: моңа кадәр билгесезлектә калып килгән әсәрләре һәм хезмәтләре укучыга җиткерелә, иҗатына, тормышына кагылышлы бик күп документлар фәнни әйләнешкә кертелә, махсус фәнни эзләнүләр алып барыла, кандидатлык диссертацияләре яклана.

Бүген Г. Ибраһимов исемен горур йөртүче Институтыбыз язучының 15 томлык академик басмасын әзерләү белән шөгыльләнә. Бу хезмәт татар мәдәниятен фәнни нигезләрдә, фәнни оешмалар төзеп өйрәнүне башлап җибәрүчеләрнең берсе булган Галимҗан Ибраһимовка Институт коллективының хөрмәте һәм рәхмәте булыр, халыкка күренекле әдип һәм дәүләт, җәмәгать эшлеклесенең хезмәтләрен тагын да тулырак җиткерергә, бу хезмәтләрнең асылына, әһәмиятенә төшенергә ярдәм итәр.

## ӘДӘБИЯТ


1. Акчура Й. Мәдрәсәләрдә тарих дәресе укыту турында // Чын мирас. 2012. № 7. Б. 38–40.
2. Валеева Г.А. Академический центр Татарии: 1920-е гг. // Академический центр Наркомпроса ТАССР: документы и материалы. Казань: ИЯЛИ, 2015. С. 7–33.
3. Гайнуллин М.Х. Татарская литература XIX века. Татар. кн. изд-во, 1975. 307 с.
4. Ганкевич В.Ю. На службе правде и просвещению. Краткий биографический очерк Исмаила Гаспринского (1851–1914). Симферополь: ДОЛЯ, 2000. 328 с.
5. Ганкевич В.Ю. О социальной значимости «Французских писем» Исмаила Гаспринского // http://www.cidct.org.ua/ru/publications/Letter/index.html – дата обращения: 11 марта 2017 г.
6. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты. Казан, 2010. 232 б.
7. Җамал Вәлиди. Әдәби һәм тарихи-документаль җыентык. Казан: Җыен, 2010. Б. 374–398.
8. Ибраһимова Ф. Г. Ибраһимов – Гыйльми Үзәктә // Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман: Тууына 115 ел тулуга багышланган фәнни конференция материаллары. Казан: Фикер, 2002. Б. 120–129.
9. Салахов М.Х. Важный этап развития академических традиций в Татарстане // Академический центр Наркомпроса ТАССР: документы и материалы. Казань: ИЯЛИ, 2015. С. 3–6.
10. Хайрутдинов Р.Р. Татарский научно-исследовательский институт культурного строительства им. М. Горького // Гасырлар авазы = Эхо веков. 2009. № 2. С. 263–265.

11. Хасанов М.Х. Эволюция творчества Галимджана Ибрагимова в послеоктябрьский период: дис. ... д-ра филол. наук / ИВ АН СССР. М., 1971. 595 с.
12. Хәсәнов М.Х. Галимҗан Ибраһимов иҗаты: (Октябрьгә кадәрге чор): филол. фән. канд. ... дис. – Казан, 1961. 343 б.
13. Хәсәнов М. Галимҗан Ибраһимов: тормыш һәм иҗат юлы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. – 331 б.

## ТӨРКИ-ТАТАР ӘДӘБИ ТЕЛ НӘЗАРИЯТЕ: ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ИҖАТЫ

***Бәширова И.Б.***

В статье ставится вопрос рассмотрения творчества татарского писателя классика, филолога и педагога, известного литературного критика и публициста, государственного и общественного деятеля Г. Ибрагимова (1887–1938), как одного из звеньев в развитии истории татарского литературного языка.

The article considers the literature legacy of the Tatar classic, famous literary critic and writer G.Ibragimov (1887–1938) as a link in the history of Tatar literary language.

**Кереш.** Классик әдип, танылган тел һәм әдәбият белеме галиме, күренекле тәнкыйтьче һәм публицист, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Г. Ибраһимовның (1887–1938), шәхес буларак тормышы да, катлаулы иҗаты да һәрьяклап җентекләп өйрәнелгән дип әйтергә мөмкин. Бу юнәлештә, 1920–1927 елларда һәм 1960 еллардан соң, күп сандагы фәнни мәкаләләр язылган, кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре якланган, монографияләр басылган. Әдипнең «Сайланма әсәрләр»е дөнья күрә тора, инде «Академик басма»сы хәзерләнә. Трилогиянең герое буларак тасвирлануы да мәгълүм [14]. Һичнинди дә яңа фикер әйтергә мөмкин түгел кебек, ләкин камиллекнең чиге юк диләр бит!

Әлеге хезмәтләрне укып, зиһенгә алып бару юнәлешендә, Г. Ибраһимов кебек кабатланмас сүз остасының төп бер үзенчәлеге җитәрлек дәрәҗәдә ачылып беткән дип әйтеп булмавы аңлашыла. Бу – Г. Ибраһимов иҗатын, **татар әдәби теле тарихының бер буыны буларак карап өйрәнүнең,** аңлы рәвештә көн тәртибенә куела алмавы. Язучы теленең әлеге ысул белән анализланырга тиешлегенә башлап, Л. Җәләй игътибар итә: «...Тукай телен өйрәнү – татар әдәби теле тарихының мәгълүм бер баскычын өйрәнү дигән сүз. Кешелек дөньясы барлыкка китергән культура байлыгын тәнкыйть үтәзеннән сөзеп алмый торып, яңаны төзеп булмый», – дип, даһи шагыйребезнең шигърият телен яңадан тикшерергә кирәклеген күтәрә [5, б. 59–60]. Г. Ибраһимов кебек классик әдип, үз вакытында татар теле һәм әдәбияты белеменең нәзарият-теориясенә нигез салучы дип санала торган галимнең әсәрләре / хезмәтләре телен, татар әдәби теле тарихының бер буыны буларак тикшергәндә, бу шәхеснең эшчәнлеген, асылда, ике нигездә карарга кирәк булуы күренә: б**еренчедән,** әдипнең тулаем иҗатын барлап, әсәрләренең тел үзенчәлеген билгеләү; и**кенчедән**, аның үзе файдаланган, үзе өйрәнгән, үз чоры әдәби теленә булган мөнәсәбәтенең нинди булуын ачыклау, бу юнәлештәге эшчәнлеген күзаллау. Бер мәкалә кысасында, әлеге мәсьәләрнең икенчесенә генә кыскача тукталырга мөмкин булуы күренә.

**1.** Академик М.Х. Хәсәнов белдергәнчә, Г. Ибраһимов бай әдәби мирас калдырган шәхес [17, б. 17]. Г. Ибраһимов, иҗат эшчәнлеге барышында, әдәби әсәрләр, халык тарихына, әдәбият, мәдәният тарихына караган хезмәтләр язуы белән бергә, төрки-татар язма әдәби теленең имля-орфография, лексика-терминология, сарыф вә нәхү, бәлягать-эстилистика, тәрҗемә теориясе һ.б. тармакларын, автор үзе әйткәнчә, фәнни нәзарият-теория югарылыгына күтәрү дәрәҗәсендә яктыртып, күп санлы мәкаләләрендә, дәреслекләрендә, гамәли-практик яктан эшкәртеп, киң даирә укучыларына тәкъдим итә. Ф.С. Фасеев болай дип искәртә: «...Бу уңай белән монда Г. Ибраһимовның иҗат эшчәнлегенә хас бер үзенчәлекне исәпкә алмый мөмкин түгел: ул да булса – аның хезмәтләрендәге эзлекле тарихылык, актуальлек, зәвекълелек һәм интеллектуальлек, гуманизм һәм халыкчанлык» [9, б. 6]. Димәк, аерым бер авторның иҗаты, шундый югарылыкка күтәрелүе өчен, үз вакытындагы әдәби телнең барлык мөмкинлеге булган һәм язучы аны оста файдаланган дигән нәтиҗә көтелә.

Тарихи яссылыкта караганда, татар әдәби теленең, язмачылык тарихы гомумтөрки гаиләдә угыз-уйгур-кыпчак кабилә телләренә нигезләнеп килә торган X–XI йөзләрдә башланып, XII–XIII гасырдан язма истәлегенең язылу датасы мәгълүм булган иске язулы (старописьменные) телләрнең берсе буларак [19, б. 358], татар халкының классик әдипләре булып танылачак шәхесләре, шул исәптән Г. Ибраһимов, иҗат итә башлаган XIX гасыр ахырларында, мең еллар буена эзлекле рәвештә килә торган язмачылык тарихы-байлыгы булуы мәгълүм. Язылу датасы билгеле булган истәлекләре дигәндә, Болгар дәүләтенең Казан төбәгендә каберташларга язылган штамп-текстлар куелуы [19, с. 47–48], Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы иҗат ителүе, XIII йөздә Төркестан (Яса) әдәби үзәгендә, кимак-кыпчак-искел-болгар-татарларның сөйләмә телендәге уртак сүз, сүзформаларга нигезләнеп әдәбиләштерелгән Әхмәт Ясәви, С. Бакыргани һ.б. иҗаты истә тотыла [17, б. 144]. «Кыйссаи Йосыф» әсәре дә Ясәвиләр хәрәкәтен дәвам итә торган күренекле факт булып санала [4, б. 252–253].

Әдәби телебезнең тарихын эзлекле юнәлештә өйрәнү барышында, XI гасырдан башлап, XX йөзнең башларына кадәр иҗат иткән авторлар, укырга-тыңларга асан булсын, укучылар дога илә искә алсыннар өчен, гарәп-фарсыда язмыйм, төрки телдә язам дип, башламында ук махсус искәртүләре игътибарны җәлеп итә. Әмма төрки телнең бер генә төрле булмыйча, мөселман идеологиясенең коралы-күрсәткече булган гарәп-фарсы алынмалары белән туендырылып, «Котадгу белек» тән башланган (462/1069–1070) аристократ тибында һәм «...Айәт, хәдис мәгънәсе төрки булса муафикъ / Мәгънәсенә йиткәнләр йиргә куйар бүркине...» (146 хикмәт), дип инанган Әхмәд Ясәвинең (1091–1166) «Диване хикмәт»ләре белән башланган халыкчан тибында дәвам ителә. Менә шушы ике юнәлештәге төрки тел, төрле чорда төрле дәрәҗәдә, җирле диалект теле белән баетыла барып, авторлар үзләре белдергәнчә, Болгар төркисендә (XIII), Алтын Урда төркисендә (XIV), иске татар теле – Казан төркисендә (XV), Русиянең Урта Идел буендагы классик иске татар телендә (XVI–XVII–XVIII–XIX йөзләрдә) язылган әсәрләрдә дәвам ителә [16, б. 69–74]. Төрки-татар (иске татар) телендә язма әдәбиятның, сәнгатьле тезмә һәм чәчмә әсәрләре, эш кәгазьләре, фәнни әдәбият, дини-дидактика, иҗтимагый-публицистика, региональ-тарих һ.б. барлык жанр – стильләре дә тәмам формалашып җиткән алтын

чоры була. Әсәрләрдә ислам тәгълиматы нигезендә адәм баласының иманлы-әдәпле, гыйлем-мәгърифәтле булырга тиешлеге мәсьәләләре яктыртыла. Графо-орфографик язылыш дигәндә, гарәп-фарсы алынмалары катгый рәвештә үз чыганак тел кагыйдәсе буенча, төрки-татар сүзләре билгеле бер тәртипкә китерелгән иске имляда бирелә [3, б. 55–57]. 1899 елда, Уфада тел, имля, мәгариф мәсьәләләре буенча җыелган Гыйльми мәҗлестә, традиция булып килә торган язма әдәби телгә, рәсми рәвештә мөнәсәбәт белдерелә, «Русия төркиләре өчен Казан шивәсе лисанын гомуми итеп кабул итәргә» дип, имля буенча 13 пункттан торган карар кабул ителә [11, б. 43]. Аңлашылганча, милләтнең һәм аның әдәби теленең атамасы традиция булып килә торган юнәлештә ныгытыла. Бер-бер артлы «Сарфы төрки» дигән хезмәтләр дөнья күрә.

**2.** XX йөзнең беренче унъеллыгында, тормышта барлыкка килә торган иҗтимагый-сәяси яңалыкларны аңларга тырышу, бигрәк тә татар телендә газета басарга мөмкинлек ачылу белән, гасырлар буена дәвам итеп килә торган иске татар теленең табигатен һәм вазыйфасын аңларга тырышу омтылышы көчәя. «Әдәби телебез нә делдер?» дип «Нур» газетасында башланган фикер алышуда (1905–1914) һәм бу бәхәснең дәвамы буларак, «Шура» журналында «Тел ярышы» уңае белән һәм аннан соң да (1909–1917), шулай ук башка газета, журналларда басылган мәкаләләрдә, язма телнең нинди булырга тиешлеге киң яктыртыла. Газетага дип языла торган мәкаләне нинди «тел» белән язарга тиешбез, дигән сорауга җавап көтелә. Язма телне, нинди вазыйфа үтәвенә карап, төрлечә кулланырга кирәклек мәсьәләсе, XIX гасыр урталарында, М. Иванов (1842), С. Кукляшев (1859) тарафыннан инде мәйданга куелган, язма тел белән сөйләмә телнең бер үк күренеш була алмавын К. Насыйри ачыклаган була [13, б. 3]. XX гасыр башында исә әлеге мәсьәлә, аңлы рәвештә, гасырлар буена килә торган язма традицияне яңарту юнәлешендә күтәрелә. Мәгърифәтче әдипләр, кыйссаи әсәрләрдән килә торган риваять сөйләүчеләрнең сүзен кабатламыйча, укучыга җиткерелергә тиеш вакыйганы үз исеменнән сөйләүгә күчә (Акъегет,1886), ягъни әсәрдәге вакыйганы хикәяләү яңара. Классик әдипләр исә, әдәбият ул сөйләп бару гына түгел, һәр сүз белән күбрәк мәгънә белдерергә кирәк дигән программа күтәрә (Исхакый, 1900, 1903; Әмирхан, 1909), ягъни әдәби әсәрдә вакыйга-хәлләр образлап тасвир ителергә тиеш дигән аң-акыл мәйданга куела [2, б. 9–14]. Телче галимнәр, «...имляда ишетелгәнчә язу тиешле» дип, имля төзәтүне гамәли рәвештә тормышка ашырырга тотыналар [11, б. 45]. Менә шушы вакытларда Г. Ибраһимовның катлаулы иҗат эшчәнлеге башлана. Әлеге эшчәнлекне, көч җиткән дәрәҗәдә зиһенгә алырга тырышу барышында, әдип һәм галим буларак, әлеге яңалыкларның барысы да аның күз уңында тотылуы, аларның һәрберсенә анализ ясалуы, теоретик эшкәртелүе һәм автор үзе искәрткәнчә, «...һәрбер тугърыда эшләнгән кагыйдәләрнең гамәлгә салынырга яраклык чыгу җәһәтенә»,ягъни һәм нәзари, һәм гамәли яктан актуаль булуы максат итеп алына [9, б. 32]. Мәкаләнең темасына бәйле рәвештә, Г. Ибраһимовның эшчәнлегендә, һәр төрле яңарышка мөнәсәбәт белдергәндә, тарихилыкның ни дәрәҗәдә истә тотылуына игътибар итәргә тиеш булабыз.

1907–1909 елларда авторның беренче хикәяләресе басыла [7, б. 399–494]. Әлеге әсәрләрнең һәр өчесе дә, вакыйганы хикәяләү ягыннан карагандә, мәгърифәтче әдипләр башлаганча, авторның үз сөйләме буларак языла.

Автор, мин дип әйтеп укучысына эндәшмичә, бу вазыйфа персонажга йөкләтелсә дә, вакыйга сөйләп бирелә, әдипнең үз чоры әдәби тел байлыгын файдалана белүе күзәтелә. Әлеге юнәлештә, гомумтөрки нигездә, Әхмәд Ясәви хикмәтләре белән гамәлгә куелган (XI г.) һәм, гасырлар буена дәвам итеЛә килгән авторлар үзләре белдергәнчә, халык яратып укысын өчен Болгар-Казан төркисендә язам, дигән халыкчан төрки традициясе дәвам итеЛә. 1910 елда «Яз башы», 1911 елда «Диңгездә» хикәяләре дөнья күрә [7, б. 51–81]. Гәрчә боларның исемнәрендә, «Бер шәкерттән хикәят» һәм «Юл күренешләре» дип гадәти сөйләп бару булачагына ым ясалса да, боларда тасвирлана торган хәлләр җанлана, укучы ишетеп кенә түгел, күрә ала торган халәт тудырыла, ягъни әсәр эчтәлегендәге сүз, бигрәк тә аның исеме итеп бирелгәндә, әсәр эчтәлеге өчен генә кирәк булган яңа мәгънә төсмере белән баетыла. «Яз башы» – елның бер фасылы һәм яшьүсмернең шул вакыттагы гүзәллекне күрә белүдән туган хис-кичерешләре, рухый халәте, аның «күз алдында» (дөресрәге, күңел күзе алдында) хыял белән хис, бергә кушылып, «чынбарлыкка әверелә» [20, б. 92]. Автор, алга таба язылган әсәрләрендә, эстетик эчтәлекне сәнгать чаралары белән тасвирлап образ барлыкка китерү үзенчәлеген камилләштерә барып, татар прозасын кабатланмый торган биеклеккә күтәрә.

Бер үк вакытта, образлап иҗат итә башлаган әдипләрнең уңышын,үзенчәлеген хуплаган тәнкыйть мәкаләләрен яза. Ф. Әмирханның «Хәят» романы турында: «...Җиңел вә җитез кулдан, җиңел вә оста каләм белән, матур, җанлы рәвештә язылган бу җиңел хикәяне мин әдәбият мәйданына чыккан яңа бер хадисә итеп карыйм...», – дип башланган бәяләмәсендә, татар сәнгатьле прозасының XIV гасырдан башланган, 600 еллык үзенчәлекле үсеше күзаллана [8, б. 57–58].

Имля мәсьәләләренә караган фикерләре дә, төрки-татар теле язмачылыгындагы традициялелекне аңлап, аны яңарту юнәлешендә бирелә. «Татар сарфы» китабының «Килик имля мәсьәләсенә» дигән өлешендә: «...Бер телдә ике имля булмаска тиешлегенә ачык инансам да, шунлыктан телемезгә кергән һәрбер сүзне – теләсә гарәби, теләсә башка булсын – татарча имля белән язарга тиеш дип белсәм дә, гарәби, фарси сүзләрне үз имлялары белән язарга калдырдым. Чөнки имлямыз рәсми вә гомуми кагыйдәләр астына алынып бетмәгән, татар сүзләренең язылуы да мәзбүт түгел (тотрыкланмаган)». Авторның бу сүзләрендә, төрки-татар телендәге **язылышның тарихы булуын**, һәм аны кинәт кенә үзгәртеп булмавын аңлавы күренә. Әмма бу хәлнең вакытлыча булуы: «Көне килер, имлямыз гомум тарафыннан кабул ителгән бер юлга керер, шул чакта гарәби сүзләрне дә татарча имля белән яза башларлар», – дип белдерелә [9, б. 30–32]. Билгеле булганча, «имлямызны гомум тарафыннан кабул ителгән бер юлга салу» юнәлешендә, галим күп көч һәм энергия сарыф итә. 1911 елда башланган эш, бер өзлексез диярлек, гарәптән латинга күчкәнче дәвам итеЛә. «...Мәдәни-тарихи, икътисади сәбәпләр аркасында, латинга күчүне мөмкин күрмибез», – дип белдерә [9, б. 308]. Әлеге фикеренең тарихын, орхон әлифбасы, уйгур язуы, гарәп графемаларыннан башлап аңлата: «...төрек халкы эчендәге гыйльми, мәдәни, әдәби үсү моңарчы тик шул гарәби әлифба нигезендә генә барды. ...Латин хәрәкәтен көчәйтеп, шул гарәп нигезендә эшләп торучы зур мәдәни машинаны җимерсәк, нәтиҗә ничек булачак?, ...Бездәге латин мәсьәләсе рус әлифбасы керүгә бер баскыч, бер хәзерлек кенә булачак...», – дип, алдан

күрүчәнлеген белдерә [9, б. 329–330]. Бу хакта безнең күп галимнәребез үзләренең фикерен белдерә, М.З. Зәкиев мәкаләсендә тәфсилләп анализлана [6, б. 19–25; 9, б. 335–360]. Аңлашылганча, Г. Ибраһимовның әдәби әсәрләрдә хикәяләү үзенчәлегенә караган яңарыш мәсьәләләре һәм имля төзәтүгә бәйле нәзари һәм гамәли фикерләре, тарихи эзлеклелеге сакланган нигездә аңлатылуы ачык күренә.

**3.** Шуның белән бергә, әдипнең беренче әсәрләре һәм имля мәсьәләләре белән бер үк вакытта, «Без татармы, төрекме» дигән бәхәскә кушылып, халкыбызның атамасына һәм аның әдәби теле мәсьәләләренә мөнәсбәтле булган мәкаләләре басыла. «Без-татармыз» мәкаләсендә: «...Безнең төреклегемезне берәү дә инкяр кыйла алмый. Ләкин шул як бар төрек-олугъ бер кавем, ул берничә бүлекләргә аерылган. Без дә шул бүлекләрдән берсе – төрек намендән, хасрак исеме татар булган бер кавембез. Без – татар аталган төрек кабиләсе...», – дип, төрек (төрки) һәм татар атамаларының мәгънәсен тәгаенли [10, б. 11–14). Бу очракта, үз вакытында С. Күкләшев (1859), Г. Баязитов («Нур», 1906, № 21) тарафыннан әйтелә башлаган объектив дөрес фикерне кабатлый, әмма: «...Татар дип аталуның сәбәбен тикшерүне тик тарихи бер мәсьәлә итеп, үз әйленә(әрбабенә) ташлыйбыз да, вәкгыйгдә, тормышда «татар» аталып бара бирәбез... Үзебез татар, телебез – татар теле, әдәбиятыбыз – татар әдәбияты, эшләгән һәммә эшебез – татар эшләре, туачак мәдәниятебез-татар мәдәнияте булачак», – дип, татар исемен, халыкның теле, әдәбияты, мәдәнияте атамасы буларак, мәңгелектән килә торган мәгънәдә катгый рәвештә ныгыта [10, б. 14]. Димәк, бу юнәлешләрдә тарихи төркигә бернинди дә мөнәсәбәтебез, катышыбыз юк булып чыга. «Татар сарфы» хезмәтенең керешендә дә төп максаты болай дип билгеләнә: «Тәңре белә, мин иярүне дә, юл ертуны да уйламадым. Минем бөтен мәнбәгем **саф татар теле булды...**» [9, б. 28]. Менә шушы саф татар теле мөнәсәбәтенә куеп карала башлагач, тарихи нигезнең шактый кыскаруы күзәтелә. Авторның: «...татар теленең имля, сарыф һәм нәхү кагыйдәләре аерым бер фән сурәте белән тикшерелә башлауга әле күп түгел, бу хезмәтнең тик егерме еллык гомере бар», – дигән фикерен мәйданга куя, әлеге эшчәнлекнең башы – бисмилласы Каюм Насыйриның «Әнмүзәҗ»е дип белдерә [9, б. 109–113). Ф. Фасеев, хаклы рәвештә, мондый аңлатма бирә: «Татар грамматикасы тарихын автор шулай бик нык киметә ...милли мәктәп-мәгърифәт традицияләрендә язылган әсәрләрне генә алып, бу тарихны бик нык чикләгән. Әлбәттә, бу караш фән тарихы принциплары белән сыеша алмый...», – дип, К. Насыйрига кадәр грамматика язган 30 авторның исемен санап, һ.б. авторларның күп дистәләрчә хезмәтләрен күрсәтергә мөмкин булуын искәртә [9, б. 377–378]. Г. Ибраһимов шул ук мәкаләсендә, «Төрки сарыф» исемле хезмәтләр турында фикер әйтү уңаенда: «...Сарыф ияләре дә, «без татармы-түгелме» мәсьәләсенә аптырап калулары сәбәбендән, әсәрләрен нииндидер томанлы, ике мәгънәле бер исем белән атыйлар», – дип, төрки атамасына кире мөнәсәбәтен белдерә [9, б. 115]. Дөрес, төркине томанлы дигән мәгънәдә: «...Безнең халыкның һаман татар буласы килми. Җитмәсә тагы «без татар түгелмез» дип матбугатка чыгып кычкыралар, әллә нинди бер хыялый түреклек эзлиләр»,-дип, беренче буларак Җ. Вәлиди әйтә [3, б. 199]. «Нииндидер хыялый түреклек эзлиләр», «нииндидер томанлы, ике мәгънәле исем» дигән фикерләр белән, «Шура» да барган «Тел ярышы» нда, ана телемез, саф төрки, саф татар теле дип кулланыла торган

абсолют бер үк мәгънәдәге төшенчәләрнең мөнәсәбәте [16, б. 147], ягъни татар әдәби теленең гасырлар буена дәвам итеп килгән гомумтөрки нигездәге дәвере – традициясе инкяр ителәә башлый. Татар теле дәүләт теле булып яши башлагач, бу фикерләр тагын да мөһимләшә, аны тагын да югарырак күтәрергә кирәк була, әдәби телнең төрки нигезен оныттыру дәвам итеүлә бара. Г. Ибраһимов «...Насыйриларгача әдәби төрки теле ярым чыгтай, чирек госманлы калыбына сугылган чобар төрки теле иде», – дип белдерә. Үз вакытында, К. Насыйри чыгтай атамасын имлядагы төрлелекне аңлату өчен кулланса [12, б. 4] бу очракта, угыз, уйгур, кыпчак кабилә телләренең үзенчәлекләреннән хасыйл булып, һәр аерым дәвердә җирле диалект сөйләмә сүз, сүзформалар белән баетыла килгән төрки телнең (иске татар теленең) «чобар»лыгы, аның эшкә яраксызлыгы дип, кимсетү төсмере белән әйтелә. Автор, «XVI йөз ахырында язылган «Тәварихы Болгария...»дән, Һибатулла Ишанның «Мәҗмәгъ-әл-адәб» еннән,... борынгы дәвернең иң соңгы һәм таланлы шагыйре Шәмсетдин Суфыйдан» мисаллар китерә дә, аларда, чыгтай, госманлы сүзләре белән бергә, гарәпчә, фарсыча сүзләргә зур ирек бирелүе, имляларының искечә булуы күренә дип, К. Насыйри «...гамәли яктан, борынгы әдәби телне ташлап яңаны башлады. ...Кыскасы, мисаллары башта күрсәтелгән борынгы дәвернең әдәби төрки теленнән җырып чыгып, яңа әдәби татар теленә юл ачты», – дип белдерә. Бу хәлнең нәтиҗәсе нинди булуы ассызыклана: «...1910–11 еллардан алып, димәк, Насыйриның вафатыннан ун еллар үткәч, «татар теле» нәзарияттә һәм мәктәптә төрекчәләрне дә, төркичәләрне дә камил җиңде. ...«Тәрҗеман» ның гомуми әдәби төрек теле үзе белән бергә кабергә китте. Насыйриларның әдәби татар теле барган саен көчәеп, яңадан-яңа көчләрне үзенә тартты, эшләтте, зур агымга – елгага әйләнеп, баеп, матурланып, хәзер инде нәзарияте, тарихы белән бергә Татар Җөмһүриятенең дарелфөнүн мөнбәрләрендә өйрәтелү дәрәҗәсенә килеп иреште», – дип, яңа әдәби татар теленең гомуми әдәби төрек (төрки) теленә нигезләнмәгән, аның **яңа әдәби татар теле булуы** горурлык белән җентекләп аңлатыла [10, б. 217, 226].

Г. Ибраһимов «яңа татар әдәби теле»нә чыгтай-госманлы чобар төрки дәвернең мөнәсәбәте юк дип ышандырырга тырышса да, интуитив рәвештә, әдәби тел дигән күренешнең билгеле бер нигезе – җирлеге булырга тиешлеген аңлый һәм фикерен нәзарый яктан формалаштырырга омтыла: «...Мәркәзе урта Волга буенда булган бу хәрәкәт эченә казан татары, касим татары, мишәр, башкорт, алатыр, типтәр, төмән, нугай кабиләләреннән» чыккан шагыйрь, әдипләр барлык әсәрләрен «шул заманның уртак әдәби теле – татар, чыгтай, госманлыдан укмашкан чобар борынгы төрек өслүбе белән яздылар, ягъни укуда гына түгел, әдәби иҗатта да бу сигез кабилә бергә барды», – дип объектив дөреслек белдерелә, һәм әлеге нигез инкарь ителә: «XIX йөзнең соңгы яртысыннан соң татар буржуазиясе көчәя башлый, искене җимереп, яңага юл ача. Моның тәэсирендә яңа идеология, яңа әдәби тел башлангач – алтмышынчы еллардан, Каюм Насыйрилардан алып 1917 нче елгача – ул сигез кабилә һаман әдәби-мәдәни хәрәкәттә бер коллектив, бер җәмәгать уларак бардылар. Борынгы дәвердәге кебек, мәктәбе, театры, матбугатында шул уртак әдәби телне гәмәлгә куйдылар. Шулай ук төрле кабиләдән чыккан әдипләр, шагыйрьләр үзләренең иҗатларын шул өслүб белән мәйданга чыгардылар», – дип аңлата [9, б. 229]. Димәк, «**искене җимереп, яңага юл ачкан яңа идеология**» яңа татар

әдәби теленең нигезе була, сигез кабиләнең сөйләмә теле шушы идеология җирлегендә, яңа уртак әдәби телебезне гамәлгә куялар була. Гамәлгә куела торган өслүбнең ничек булуы аңлатыла: «...К. Насыйри, Г. Камал, Г. Тукай һәм башка казанлылар гәрчә монда тик казан-татар теленең мадДәләре белән генә канәгатьләнсәләр дә, әдәбият моңа сыймады, сыя алмады, кабиләчелек (провинциализм) дигән мәгълүм нәзариянең мөндәриҗәсе киңәйтелде. Шул уртак әдәби коллектив эченә кергән **сигез кабиләнең тел байлыгы**, сарыф-нәхү формалары безнең әдәбиятның уртак малы булып керделәр. Безнең Насыйри белән башланган яңа әдәби телебездә дә сигез кабилә уртак хезмәт иттеләр», – дип белдерә [9, б. 229–230]. Авторның әлеге фикеренә Ф.С. Фасеев түбәндәгечә аңлатма бирә: «Бу раслаудан беркадәр аңлашылмаучылык яки ялгыш нәтиҗә чыгарга мөмкин: К. Насыйри, Г. Тукай, Г. Камал һич тә казанлы-татар шивәсендә генә түгел һәм, гомумән, бернинди шивәдә дә иҗат иткән әдипләрдән түгел. Алар – заманының әдәби телендә иҗат иткәннәр, ягъни иске төрки әдәби телне халыклаштыру, сөйләү теле (койнэ) элементлары белән баету һәм сипләү юлы белән һаман яңара барган гомуммилли татар әдәби телендә язганнар. Боларда саф шивәчелек элементлары (әйтик, Насыйрида – мишәр, Камалда – Казан, Тукайда – Казан, типтәр, мишәр, казакъ) бик, бик аз һәм булганнары да һич тә аларның әдәби тел нигезен хасил итми, аерым төсмер яки стилизация функциясен генә үти. Сигез кабилә уртак хәзмәт иттеләр. ... Әлбәттә, төгәл-фәнни тикшерә башласаң, әдәби телнең боларга хезмәт итүе һәм боларның әдәби тел үсешенә өлешләре бертигез дәрәҗәдә түгел. Бу аларның никадәр уртаклыгына, шәһәр мәдәниятенә, мәктәп-мәгариф, матбугат эшләренә тартылу дәрәҗәсе белән бәйле иде. Гади грамоталык һәм статистика җәһәтеннән генә хөкем йөрткәндә дә, бу регионнарның әдәбият-матбугат белән файдалана алу һәм катнашу, эшләшү дәрәҗәләре бик төрлечәрәк булуы ачыклана» [9, б. 391]. Китерелгән өзектән күренгәнчә, Г. Ибраһимов тарафыннан иске татар теленең традицион төрки нигезе инкарь ителеп, Русия эчендә яши торган төрки кабиләләрнең җанлы сөйләмә теленнән берләшә торган уртаклыкта гына яңа әдәби тел барлыкка килә дигән фикеренең дөрес булмавы аңлашыла. «Кабиләчелек (провинциализм)га игътибар итү», ягъни авторның үзе туып үскән, яки белем алган төбәгендәге җанлы сөйләмә сүзләрне әсәренең тукымасында куллану, төрки-татар әдәби теленең барлык дәверләрендә дәвам ителеп, XIX гасыр урталарында Баһавиның «Бүз йегет»ендә, шул ук гасырның ахырларында Ә. Уразаев-Кормашиның кыйссаларында, казах теленең, М. Акъегет романында татар-мишәр, М. Акмулла иҗатында казах һәм башкорт теле сүзләренең кулланылуы, шулай итеп, әсәр укучыларның даирәсе киңәя баруы күзәтелүе мәгълүм. «Тел ярышы» на языла торган мәкалә авторлары, чит сүзләрдән качу, төрки телнең үз мөмкинлегеннән киңрәк файдаланырга тырышу максатыннан, шул ук алымга мөрәҗәгать итәләр [18, б. 157]. Бу алым, ягъни авторның туган төбәгендәге, яисә аерым персонажларының яшәү урыны белән бәйле халыкчан сүз, сүзформаларны файдалану, Г. Ибраһимовның әдәби әсәрләрендә дә киң чагылыш таба, әмма әлеге күренеш, башка авторлардагы кебек үк, язма традицияне юкка чыгармый, әдәби традиция дәвам ителгән нигездә бара. Язма традиция дәвам ителә дигәндә, гомумтөрки сүз, сүзформалары белән бергә, билгеле бер дәрәҗәдә, гарәп вә фарсы теле алынмаларының кулланылуы күздә тотыла [1, б. 193–203].

**Йомгак.** Гасыр башында беренче шигырен, беренче хикәясен, беренче драмасын яза башлаган һәм еллар үтү белән, тулаем төрки дөньяның классиклары булып танылачак Г. Тукай һәм Г. Ибраһимов, Дәрдмәнд һәм Г. Исхакый, М. Гафури һәм Ф. Әмирхан, С. Рәмиев һәм Ш. Камал, Г. Камал һәм Г. Коләхмәтов – барысы да, язма әдәби норма татар халкының ана теленә нигезләнергә тиешлекне төп принцип итеп күтәрәләр. Бу юлда энергия-көчләрен сарыф итеп, мәкалә һәм аерым хезмәтләр язалар, дәреслек-уку әсбаплары төзиләр, газета-журнал мөхәррирләре буларак, фикерләрен белдерә, тел төзәтү мәҗлесләрдә чыгышлар ясап, язма әдәби тел халыкның җанлы сөйләменә якын булырга тиеш дигән фикерне яклыйлар ...һәм шул ук вакытта, үз чоры әдәби теленең традиция булып килә торган барлык мөмкинлегеннән дә бик иркен һәм оста файдаланалар. Шулай итеп, әле латин графикасына күчкәч тә, татар халкының гыйлем ияләре – танылган мәгърифәтчеләренең язма тел өлкәсендәге эшчәнлеге дәвам итеп, әдәби татар теле үзенең классик иске татар теленә хас булган вариантлыгыннан тулаем чистартылмаган хәлендә кулланылышта булуын дәвам итә, һәр әдипнең иҗатында үзенчә чагылыш таба.

Шул ук вакытта, иҗтимагый-сәяси хәлләргә бәйле рәвештә, ташкын булып барлыкка килгә торган ватып яңарту юнәлешендә, халыкны милләт итеп тота торган сөйләмә тел, язма тел традициясен сакларга кирәклекне аңлау проблемасының булуы көн тәртибенә куела. Бүгенге көннәрдә мөһимлеге арта бара торган әлеге нигезгә куеп караганда, халкыбызга хезмәт күрсәткән олуг шәхесләребезнең кабатланмас бөеклеге һәм катлаулы чор тудырган фаҗигасе ачык күренә.

ӘДӘБИЯТ


1. Бәширова И.Б. XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәби теле һәм Г. Ибраһимов иҗаты // Г. Ибраһимов иҗаты һәм хәзерге заман. Казан: Фикер, 2002. 272 б.

2. Бәширова И.Б. Татар телендә хикәяләү стильләренең үсеше // Фәнни Татарстан, 2016. №1.

3. Вәлиди Җ. Сайланма хезмәтләр: әдәби тел, грамматика, диалектология һәм лексикография мәсьәләләре. Казан: Мәгариф, 2007. 271 б.

4. Гайнетдинов М. «Кыйссасел – әнбия» әсәре // Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. 2014. 1 т.: борынгы чор һәм Урта гасырлар. 415 б.

5. Җәләй Л. Тукай телендә фигыльләр // Совет әдәбияты. 1938. № 3. Б. 58–66.

6. Зәкиев М.З. Беренче Бөтенсоюз тюркология съездында Г. Ибраһимов һәм хәзерге көн // Г. Ибраһимов һәм XXI гасыр. Казан, 2007. 332 б.

7. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. 1 т.: хикәяләр (1907–1929). 509 б.

8. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. 5 т.: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933).615 б.

9. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. Казан, 1987. 8 т.: Төрки һәм татар теле белеме буенча хезмәтләр (1910–1930). 431 б.

10. Ибраһимов Г. Милләт. Тел. Әдәбият: сайланма хезмәтләр. Казан: Мәгариф, 2007. 239 б.

11. Курбатов Х.Р. Татар әдәби теленең алфавит һәм орфография тарихы. Казан, 1999. 138 б.

12. Насыйри К. Әнмүзәҗ. Казан: Тип. ун-та, 1895. 87 б.

13. Насыйри К. Кавагыйде китабәте. Казан: Тип. ун-та, 1892. 32 б.

14. Поварисов С. Пәйгамбәр таңы: Роман. Казан: Матбугат йорты, 1999. 1 т. 286 б.; Күкнең җиденче катында: Роман. Казан: Матбугат йорты, 2 т. 279 б.; Оҗмахка бер адым: Роман. Казан: Матбугат йорты, 2001. 3 т. 320 б.

15. Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. 2014. 1 т.: Борынгы чор һәм Урта гасырлар. 415 б.

16. Татар әдәби теле тарихы (XIII гасыр – XX йөз башы). Казан: ТӘҺСИ. 2015. 1 т.: Фонетика. Графика: язма традицияләр, норма һәм вариантлылык. 696 б.

17. Хәсәнов М. Галимҗан Ибраһимов // Г. Ибраһимов. Әсәрләр: 8 томда. Казан, 1974. 1 т.: хикәяләр (1907–1929). 510 б.
18. Хөснетдинов Р. «Шура»ның «Тел ярышы». Транскрипция: хрестоматия. Казан: КМТТУ нәшр., 2015. 164 б.
19. Языки мира: Тюркские языки. Бишкек: Издательский Дом «Кыргызстан», 1997. 542 с.
20. Яхин Ф.Г. Ибраһимов иҗатында экспрессионизм // Г. Ибраһимов һәм XXI гасыр. Казан, 2007. 332 б.

## «БЕЗНЕҢ ЮЛ» ЖУРНАЛЫ ҺӘМ ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ

***Галимуллин Ф.Г.***

В статье освещается роль классика татарской литературы Г. Ибрагимова в создании татарского литературного журнала советского периода «Безнең юл» («Наш путь»). Прослеживается путь становления этого периодического издания, вокруг которого Г. Ибрагимов сплачивал видных авторов своего времени.

The article highlights the role of the classic of Tatar literature G. Ibrahimov in the creation of the Tatar literary magazine of the Soviet period «Beznең yul» (Our Way). The way of the formation of this periodical is traced, around which G. Ibrahimov rallied the prominent authors of his time.

Быел төп әдәби журналыбыз булган «Казан утлары»на туксан биш ел, дибез. Димәк, бу зур тарихлы басмабызның беренче адымнарын 1922 елдан алып саныйбыз. Нәкъ шушы елның май аенда аның совет чоры элгәрләреннән берсе булган «Безнең юл»ның беренче саны чыкты. Әлбәттә, бу исемгә шул чор вәзгыятенә туры килә торган мәгънә салына. Ник дигәндә, октябрь түнтәрелешеннән соң узган биш ел эчендә әдәбият-сәнгатьнең илдә урнашкан рәсми идеологиягә хезмәт итәргә тиешлеге төп юнәлеш буларак каралды. Бу әлеге басманың да ниндилеген билгеләдә, ул гыйльми-сәяси, әдәби-иҗтимагый айлык журнал булачак дип тәгаенләнде. Димәк, гыйльми-әдәби басма. Әмма шул ук вакытта сәяси-иҗтимагый нигездә икәнлеге дә билгеләнеп куелган. Хәер, аның Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты һәм Халык Коммиссарлары Советы органы булуы да моны ачык күрсәтеп тора (әле ярый, фирка өлкә комитеты органы түгел, алай булган очракта аның йөзе бары тик сәясилек белән генә билгеләнер иде).

Шулай да җәмәгатьчелек журналны әдәби басма буларак күрергә теләде. Инкыйлабка кадәр «Аң», «Шура» кебек журналлардан әдәби сулыш белән танышып барырга күнеккән татар укучылары мондый мөмкинлек булдырылуга нык зарыккан иде. Аны гамәлгә ашыру юлында Галимҗан Ибраһимовның башлап йөрүе дә очраклы булмады. Бу эштә яңа хакимият алдында абруй казанган, шул ук вакытта әдип һәм шәхес буларак ышанычлы, иҗатта, Г. Тукай әйтмешли, үзе дә ат уйната торган шәхес булуы мөһим иде. Дөресен әйткәндә, журналны Г. Ибраһимов җаваплылыгына ышанып ачалар да. Мөхәррирлекне үз кулына алуы да үзенән-үзе аңлашыла. Беренче сан аның «Иҗтимагый-әдәби хәрәкәтләр тарихын тикшерүдә марксизм ысулы» дигән мәкаләсе белән ачыла. Бу зур күләмле хезмәтнең дәвамы алдагы санда урнаштырыла. Аңа «Татар әдәбияты тарихының мөндәриҗәсен билгеләү мәсьәләсе» дигән аныклык кертелүе авторның үткәндә-

ге әдәбиятларны тикшерүдә һәм бәяләүдә совет идеологиясенең төп принципларыннан берсе турында гамьләнүнең үзәккә куелуы турында сөйли. Димәк, бу әлеге басма үз эшчәнлегендә анда бәян ителгәннәрне истә тотарга тиеш дигән сүз иде, димәк, ул программа буларак тәгаенләнде. Әлеге мәкалә Г. Ибраһимовның «Имля, тел, әдәбият мәсьәләләре» (1924), «Әдәбият мәсьәләләре» (1960) китапларында өлешләп басылып киленгән иде, бары тик 1978 елда гына «Әсәрләр»нең 5 нче томында бербөтен итеп бирелде. Бу, дөресен әйткәндә, сүз бара торган басманың гына түгел, тулаем сүз сәнгатебезнең үткәнен, хәзергесен өйрәнүгә күрсәтмә, ягъни методологик нигез хезмәтен үтәүче мәкалә буларак кабул ителде.

Сүз дә юк, Г. Ибраһимов яңа шартларда фикер сөрешен Шәрык әдәбиятлары белән бәйләнештә алып бара алмый. Кереш сүздә үк турыдан-туры рус әдәбиятын яңа нигездә тикшеренүдәге беренче тәҗрибәләрне барлаудан башлап китә. Ахырга кадәр шушы юнәлешне тайпылышсыз дәвам иттерә. Әле Г. Сәгъди, Г. Газиз һәм Г. Рәхимнәрнең бу мәсьәләләргә күп ачыклык кертәчәк әдәбият тарихы китаплары язылмаган, көндәлек килеп чыга торганнарына бүген үк җавап көтелә. Шулай да Г. Ибраһимов татар әдәбияты тарихындагы дәверләрне аеру мәсьәләсендә Г. Сәгъди лекциясендә бәян ителгәннәрне дә хәтереннән чыгармый. Ләкин мәсьәләнең төрле катламнарын аерып чыгару һәм аларны өйрәнүнең юлларын икрар иткәндә ул нигездә үз карашларына таяна. Шулардан башланган сүз егерменче еллар дәвернең иҗтимагый зәминнәре (нигезләре) тирәсенә килеп чыга. Бу мәсьәләдә, әлбәттә, Г. Ибраһимов үзе әйткәнчә, «рус телендәге тарихи материализм хакындагы күп кенә әсәрләргә» таяна һәм башкаларны да шулай эшләргә өнди. Бу мәкаләгә шактый дәвамлы тукталуыбызның сәбәбе шул, «Безнең юл»ның «бисмилласы» шундый рухта булуы журналның гына түгел, бәлки матур әдәбиятыбызның үткәненә һәм бигрәк тә киләчәгенә нинди караштa булырга тиешлеккә дә ачыклык кертә иде.

Бу күрсәтмәләр укучыларга барып ирешкән очракта гына нинди дә булса кыйммәткә ия була. Димәк, әлеге басма, барыннан да элек, менә шушы максат өчен кирәк. Шулай да, күрәсең, журналны оештырып җибәрү төрле кыенлыклар белән бәйләнгән булган. Әйтик, аның беренче саны май аенда чыкса, икенчесе исә июнь-июль айларында, ягъни ике айга бер сан булып чыга. Г. Ибраһимов шул ук елның 27 июнендә «Татарстан» газетасында басылган «Татар җөмһүриятенең икенче елында әдәбиятыбызның язмышы» дигән мәкаләсендә «“Безнең юл” журналын арттыру лазем» дип язып чыккан икән, димәк, болай фаразлау дөреслектән ерак тормый булып чыга. Алай гына да түгел, инде, беричә ел үткәч тә, 1926 елда ул фирка өлкә комитетының матбугат бүлегенә журналның эшен яхшырту кирәклеге турындагы мәсьәләне көн тәртибенә куюны сорап мөрәҗәгать итә. Беренчедән, ул басманың эчтәлегеннән бик үк канәгать түгел. Икенчедән, тиражының кечкенәлеге дә киләчәккә өмет тудырмый. Өлкә комитетының ул вакытлардагы матбугат бүлеге мөдире Латыйф Гомәр сүзләренә караганда, ул болай ди:

Аңа катнашучы, үзләренең әсәрләрен бастыручы бер төркем язучылар яисә журналистлар журналы гына түгел ул, республика журналы ул, партия журналы. Дөресе, бөтен Советлар Союзындагы татарлар өчен чыгарыла торган бердәнбер әдәби һәм иҗтимагый-политик журнал. Шуңа күрә аңа бик нык игътибар итәргә кирәк. Партия өлкә комитетының журналга игътибары җитәрлек түгел. Аның эчтәлеге, эше, торышы һәм планы белән

чын-чынлып кызыксынмый. Хәтта аны тарату мәсьәләсе белән дә җитәрлек шөгыльләнми. Партия ячейкалары төрле журналлар яздыралар, ләкин шулар арасында «Безнең юл» юк [1, б. 190].

Әлеге сөйләшүнең нәтиҗәсе буларак, 1926 елның 25 январенда шушы бүлектә бу мәсьәлә махсус тикшерелә. Г. Ибраһимов докладыннан соң Г. Гали, Ф. С.-Казанлы, С. Атнагулов, Ф. Бурнашлар төрле тәкъдимнәр белән чыгыш ясыйлар. Барыннан да элек сүз журналның укучыларны йомшак җәлеп итүенең сәбәпләрен ачыклау тирәсендә бара. Алар түбәндәгеләргә кайтып кала дип исәплиләр: «Безнең юл» иҗтимагый-сәяси булудан бигрәк, әдәби-нәфис басма булырга тиеш. Аның эше белән элеккечә ТҮБК һәм ХКС түгел (аларның башка эшәре дә күп), Мәгариф Коммиссариаты җитәкчелек итәргә бурычлы. Журналның үз вакытында чыгып баруын да тәэмин итәргә кирәк.

Утырышта тагын бер мөһим мәсьәләгә игътибар ителә – басмага язучыларның төрле агымнарын җәлеп итәргә, аларны «Безнең юл» тирәсенә тупларга. Ул шартларда менә бу соңгысын аеруча әһәмиятле дип санарга кирәк. Чөнки 1925 елның 18 июнь карары игълан ителгәннән соң язучыларны пролетар, крестьян, юлаучыларга бүлеп йөртү башланды. Аларның пролетар дип аталганнарына өстенлек бирелеп, калганнарына, бигрәк тә, «юлаучылар»га кырын кару гадәти хәл булып бара иде. Димәк, бу мәсьәләдә камыт бавын ныграк тарттырганлыкларын фирка өлкә комитетында бераз аңлый башлаганнар дигән сүз. Уйлап карасаң, исең китәрлек, әле бу вакытта хәтта Һ. Такташ та вак буржуазия катламыннан чыккан «юлаучылар» катламында гына дип карала иде бит. Пролетар рухлы язучы дип саналыр өчен, 1924 елда «Гасырлар һәм минутлар» поэмасын язу гына җитмәгән, күрәсең.

Шул ук утырышта журналның яңа редколлегиясе дә раслана. Аңа Г. Ибраһимов, Гомәр Галиев һәм Гаяз Максудов кертелә. Янә шундай искәрмә дә ясала: редколлегиягә тагын ике кеше өстәләчәк, аларны партия өлкә комитеты секретариаты ачыклаячак. Димәк, составта фирка вәкилләре булмаган очракта журналның кирәкмәгән идеология ягына салулап китүе мөмкин икән. Г. Ибраһимов белән Г. Галиевкә дә ышанып бетмәгәч, башкаларга ни сан инде. Гомәр Галиев, журналның сәркәтибе буларак, аның тиешле идеология юнәлешендә булуы һәм вакытында чыгып баруы өчен зур тырышлык куеп эшли. Басма тирәсенә төп каләм көчләрен тупларга тырыша. Әлбәттә, бу эштә Галимҗан Ибраһимовның үз үрнәге дә, аның ихласлылык һәм таләпчәнлек белән, халкыбызның төрле яклап үсеше кирәклегенә инанып, фидакярләрчә хезмәт куюы да оештыру вазифасын үтәде. Әйтик, ул адашы – күренекле галим Г. Нигъмәтинең даими катнашып килүен тәэмин итүне аеруча хуплый. Чөнки ул елларда Г. Нигъмәти бездә иң төп нәзари әзерлекле әдәбиятчыларның берсе булды, шуңа күрә Г. Ибраһимованың фән һәм тәнкыйтьнең алга китүенә аеруча күп файда китерерлек шәхес икәнлеген дөрес бәяли. Аның китаплары Казанда да, Мәскәүдәге ил халыкларының үзәк нәшриятында да чыгып торалар. Бер үк ук вакытта ул газета-журналларда, шул исәптән «Безнең юл»да да күтеп алынган авторларның берсе булып әверелә. 1927–29 елларда гына да аның биредә уннарча мәкаләсе дөнья күрә. «Ун ел эчендә безнең әдәбиятыбыз», «Кави Нәҗми», «Максим Горькийның беренче хезмәт еллары» (1927), «Туфан шигырьләрендә производство мотивлары» (1928), «Яңа башкорт әдәбияты» (Башкортстан җөмһүриятенең унъеллыгы уңае белән), «Үсү һәм тирәнәю елы», «Яңа үр-

ләргә таба» (1929) һ.б. Г. Нигъмәтинең журналда бәхәс кузгатуга исәпләнгән чыгышлары да игътибарны җәлеп итә. «Җиңелчә» тәнкыйтькә «тирән» анализ турында» (1927), «Имзасыз һәм җавапсыз мәкалә турында» (1929) кебек мәкаләләрен шул җәһәттән карарга кирәк.

Г. Ибраһимов үзе дә биредәге бәхәсләрдә катнашудан читтә калмый. 1924 елда «Имля, тел, әдәбият мәсьәләләре» дигән китабына язган кереш мәкаләсендә ул бу хакта үзе дә әйтә. «Моннан ике-өч ел элек «Татарстан» битендә Җ. Вәлиди белән бер көрәш булып үткән иде. Ул аннан «Безнең юл»га күчте. Бу турыда тартышу идеалистлар белән материалистлар арасындагы көрәш иде. Бу мәсьәләне кискен рәвештә бөтен тәфсиле, барлык тармаклары белән өзеп куярга вакыт җитмәде». Шуннан чыгып, ул нәтиҗә ясый: «Татар әдәбиятын тәфсилле рәвештә язып, шул нигез өстенә бинаны корып, тәмам тарих итәргә кирәк булачак» [3, б. 472]. Бу сүзләрдән шул аңлашыла, «Безнең юл» – татар әдәбиятының үткәнен, бүгенгесен барлауа, бу хакта нигезле, зур хезмәтләр булдыруга һәм аның киләчәген күрергә ярдәм итә торган басма буларак, үз вакыты өчен бик әһәмиятле бурыч үтәде. Журналның башка авторлары да Г. Ибраһимов белән фикердәш иде. Бу яктан Г. Гали дә җитәкчесенең иң тугрылыклы каләмдәше булды. Аның «Бер мәсьәлә тирәсендә», «Оешу алдыннан» (1927) кебек шул көннәр өчен аеруча үзәктә торган гамәлләр турында кайнарлык белән сүз кузгатуы үзе генә дә авторның чор сулышы белән яшәвенә мисал иде. Аларның беренчесендә «татар язучыларының оешмасын төзү»нең мөһимлеге турындагы төрле карашларга нигезле бәя бирелә. Ул 1923 елда «Октябрь» һәм «Сулф» төркемнәре арасындагы кайбер бәхәсләрне сагына, хәзер язучылар тынычланып калдылар, битарафлыкка ияләнеп баралар, дип хәвефләнә. Әнә, ди ул, «Безнең юл»ның үткән номерларының берсендә Г. Нигъмәти нәрсә дигән иде: «Яшьләр арасыннан төрле имзалар, яңа талантлар чыгалар, матур-матур әйберләр язалар. Ләкин шуларга җитәкче булырлык, юл күрсәтерлек мәкаләләр күренми». Г. Ибраһимовның бу юнәлештә, мәкаләләр язу белән генә чиләнмичә, татар язуылары җәмгыяте төзү турындагы ниятен куәтли һәм үзе дә нәтиҗә ясап «Татар совет язучылары оешмасы»н төзергә кирәк дигән катгый фикерен белдерә. «Оешу алдыннан» дигән чыгышында исә канәгатьләнү белән «Язучылар ошмасы төзелү хәзер беткән эш хәленә килеп бара» ди дә, бу оешманың нинди булырга тиешлеген турында үз карашын бәян итә.

Биредә бер нәрсәне ачыклап китү зарур. Г. Гали егерменче елларның беренче яртысында, аерым алганда, 1923 елда әдәбият мәйданындагы җанлылыкны (аныңча, активлыкны) юксына. Ни өчен өч-дүрт елда язучылар сабырланып калдылар дигән сорауга җавап бирә алмый, мондый кимчелекне каләмле кешеләрнең үзләреннән генә күрә. Дөресендә, безнең карашыбызча, башка сәбәп тә бар иде. 1925 елның 18 июнендә ил күләмендәге фирка җитәкчелеге «Матур әдәбият өлкәсендә партиянең политикасы турында» дигән карар кабул итте. Анда язучыларны билгеле бер идеология кысаларына кертү буенча гына түгел, аларны оештыру ягыннан да күңеле иҗат ирееге теләгән шагыйрьләргә, әдипләргә һәм драматургларга ят булып тоелган нәрсәләр тагы да бар иде. Аерым алганда, аларны социаль чыгышлары буенча ышанычлы яки чит төркемнәргә бүлеп карау үзе генә дә каләм әһелләренә тигез карамауга китерде. Алар инде талантлары буенча түгел, бәлки нинди катламнан булуларына карап бәяләнә иделәр. Болар, әлбәттә, аларны

сагайта башлады, як-якка карап эш итә башлауларына китерде. Мондый шартларда язучыларның күпчелеге күләгәдәрәк калуны хуп күрәләр икән, моңа гаҗәпләнергә кирәк идеме? Үзе дә шушы мохитне тудыруда катнашырга тиеш булган Г. Галигә мәсьәләнең бу ягын бәяләргә комачаулык итә торган нәрсә – ул да булса аның фиркалеләрчә уйлауны һәм эш итүне табигый дип санавы иде.

Г. Галинең «Бер мәдәни бәйрәм алдыннан» (1927) дигән мәкаләсенә аерым тукталасы килә. Ул Г. Ибраһимовның егерме еллык хезмәт бәйрәменә багышланган. Ягъни Г. Ибраһимовның «Әльислах» газетасының 1907 елның 10 октябреннән башлап басылган «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» әсәре дөнья күрүгә ике дистә ел тулуны зурлап билгеләп үтүгә әзерлек эше башлану – ул бер Г. Ибраһимовның гына түгел, бөтен татар әдәбияты-мәдәнияте һәм фәне өчен әһәмияте ягыннан бер олуг вакыйга буларак бәйрәм ителергә тиешлеген Г. Гали нигезле итеп дәлилләргә алына, аның бөтен татарлар өчен уртак тантанага әверелергә тиешлеген әйтә. Г. Сәгъди дә бу уңай белән «Зур әдипләребездән берсе» дигән мәкалә белән чыкты (1927). Бәйрәм өчен сәбәп булган әлеге хикәя тирәсендәге уйланулары рәвешендә язылган икенче бер мәкаләсендә дә Г. Сәгъди Г. Ибраһимов шәхесенә һәм каләм көченә олы бәя бирә [4, б. 3].

Г. Толымбайский да журналның актив язышучысы. Мәсәлән, «Татар әдәбияты (Еллык хисап урынына)» дигән мәкаләсендә Г. Ибраһимов аның «Безнең юл»да басылган бер тәнкыйть мәкаләсенә игътибар юнәлтә. Гомәр иптәш Уфадагы язучы Г. Фәхринең тугандаш башкорт халкына мөнәсәбәттә урынсыз куелган исем белән басылып чыккан әсәрен сүтеп җыя. Г. Ибраһимов та бу әсәрнең исемен «гаҗәеп бер идеализм» дип атый, Г. Толымбайскийның бәясен хуплый.

Бу елларда, Гыйльми үзәк җитәкчесе буларак та, Г. Ибраһимов халкыбызның гомуми тарихын, шулай ук рухи тормышының төрле катламнарын өйрәнү мәсьәләләрен дә игътибар үзәгендә тота, башка каләмдәшләренең дә бу юнәлешләрдә кызыксынып эшләүләрен күрергә тели. Аның 1925 елда «Безнең юл»да басылган ике мәкаләсе моны ачык күрсәтә. Беренчесендә 1905 елгы революция вакытында татарлар хәрәкәтен өйрәнү өчен материаллар җыюның мөһимлеген искәртә. Бу еллардагы хәл-әхвәлләргә татарларның төрле катламнарының мөнәсәбәте турында тулы бер роман язган әдип буларак (сүз «Безнең көннәр» романы турында бара), ул үзе дә бу мәсьәләләргә тирән үтеп кергән кеше. Шуңа күрә аның сүзе бу очракта белеп әйтүгә нигезләнгән булуы белән кызыклы иде. Өченче санда басылганында исә, ул үзе әйткәнчә, «татар феодализм заманын өйрәнергә» ярдәм итүче материалларны барлый. Аерым алган, Сәхипгәрәй ярлыгы, Хәзинә, Ибн Фадлан сәяхәтнамәләре тирәсендә сүз алып бара.

Әдип һәм галим Г. Ибраһимов үзенең бу чордагы күпкырлы эшчәнлегенә бәйле гамәлләре һәм аларның нәтиҗәләре турында да журнал укучылары белән даими уртаклашып тора. Ник дигәндә, ул башкарган эшләр халкыбыз өчен генә түгел, гомумтөрки әһәмиятлелеге ягыннан да мөһим иде. Әйтик, 1926 елның январь ахыры-февраль башында Бакуда беренче тюркология съезды эшләде. Г. Ибраһимов анда «Төрек телләре имлясы» турында доклад белән чыкты. Әлеге доклад төрки халыкларның гарәп графикасы нигезендәге имлясын тагын да камилләштерү, тугандаш төрки телләрнең үзенчәлекләрен генә түгел, бәлки уртак якларын исәпкә алып, аларны бер-бер-

ләренә якынайтырга омтылу җәһәтеннән дә кызыклы иде. Ул болар хакында «Безнең юл»да журнал укучылары белән сөйләшә, «Беренче тюркология съезды нәрсә бирде?» дигән хисап белән чыга [2]. Кайбер төрки халыклар латинга күчү турында уйласалар да, Г. Ибраһимов катгый рәвештә «бездә латинга күчәргә мөмкинлек юк» дип белдерә.

Әмма инде «Безнең юл»ның 1927 елгы 8 нче санында ТҮБК һәм ХКС-ның татар язуына латин (яңа төрки) шрифты (хәрефе) кертү турында карары игълан ителә. Г. Ибраһимовның рәсми җитәкчелек сәясәте белән туры килеп бетми торган башка мәсьәләләрдәге карашларына да тискәре мөнәсәбәт белдерелә башлый. Бу аның Кырымда авырып яткан чакларына туры килә. Фирканең Татарстан өлкә комитеты аның «Татар мәдәнияте нинди юл белән барырга тиеш?» дигән хезмәтендәге кайбер тезисларына карата да өнәмәүчән фикерләр белдерә. Эш болайга китә башлагач, ул 1930 елдагы 3 нче санында «Ике мәсьәлә уңае белән» дигән хат бастыра, «партия оешмасы тарафыннан күрсәтелгән бөтен хаталарны икърар итәм» дип әйтергә мәҗбүр була.

1927 нче елга әйләнеп кайтсак, Г. Ибраһимовның иҗаты башлануга бәйле бәйрәмгә әзерлекнең барышы журналда тәфсилле яктыртылып бара. Хәтта татарлар яши торган барлык төбәкләрдән моңа багышланган чараларның ничек үткәрелүе турындагы хәбәрләрне җибәреп торуларын үтенеп басма махсус мөрәҗәгать итә. 1928 елдагы икенче сан тулысынча шушы вакыйгага багышлана. И. Рәхмәтуллин мәкаләсенең исеме аеруча күзгә ташлана – «XX еллык бөек әдәби-гыйльми хезмәт бәйрәме». М. Таһиров, Г. Алпаров, З. Бәшири, Х. Наум чыгышлары Г. Ибраһимов эшчәнлегенең төрле якларын яктыртуга багышланган. Бәйрәм үзе 1928 елның 10 мартында Дәүләт театры бинасында уза. Докладларны профессорлар Г. Нигъмәти белән Г. Линсцер ясый. Нык авыруы сәбәпле, Г. Ибраһимов үзенең хезмәт туенда катнаша алмый, Кырымда дәвалануын дәвам иттерергә мәҗбүр була.

Шуңа күрә ул 1927 елдан башлап журналга мөнәсәбәтле эш алып барудан да читләшергә тиеш булды. Шул елның май аенда басманың чыга башлавына 5 ел тулуны билгеләп үтү чараларында да катнаша алмады. Бу вакыйгага багышлап бастырган мәкаләләрендә Ф. Бурнаш, Г. Сәгъди, Х. Вәли, М. Гали, Х. Кәрим, Г. Гали, Г. Кутуй һәм башкалар Г. Ибраһимовның әлеге матбугат чарасын гамәлгә куюдагы эшчәнлегенә югары бәя бирделәр, аны сагынуларын, юксынуларын белдерделәр. Июнь санында үткәрелгән «Язучылар үзләре һәм безнең әдәбият» дип исемләнгән анкетага алынган җаваплар Г. Ибраһимовны укучы буларак та канәгатьләндергәндер дип уйларга кирәк. Һ. Такташ, Г. Кутуй, Х. Туфан, К. Нәҗми, Г. Толымбай, Ш. Усманов, Х. Хәйриләрнең чыгышлары яшьләрдә нәкъ ул күрергә теләгән сыйфатларның шактый үсеш алганлыгын күрсәтә иде. Бу аеруча аларның иҗатларында күренде. Әлеге җәһәттән Һ. Такташ аеруча аерылып тора иде. Мәгълүм булганча, Һ. Такташ иҗатының чәчәк атуы егерменче елларга туры килә. Ул Казанга күчеп килгән елда «Безнең юл» журналы да яшәп китә. Шагыйрьнең Казан чоры иҗаты тулысы белән диярлек әлеге басма белән бәйләнгән. Ул аның битләрендә «Нәләт» (1922), «Мәңгелек әкият» (1923), «Сыркыды авылы» (1925), «Нәни разбойник», «Җырланмаган җырлар турында» (1926), «Мәхәббәт тәүбәсе» (1927) кебек әсәрләрен бастырды. Димәк, Һ. Такташның шагыйрь буларак үсешен шушы басма саннары буенча да эзлекле күзәтү мөмкинлеге бар. Г. Ибраһимов Һ. Такташны «көчле,

үткен таланлы шагыйрь» дип атаган иде. Аның бу бәясе шагыйрьнең шуннан соңгы иҗатында тулысы белән расланды. Әйткәнебезчә, аның үсеш баскычлыры Г. Ибраһимов нигезләгән «Безнең юл» сәхифәләреннән дә күрергә мөмкин. Шуны ук бик күп авторларыбызга карата да әйтергә була.

1929 елның июль аеннан «Безнең юл» чыгудан туктады. Аның урынына ТАППка кергән язучылар органы булган «Атака» журналы пәйда булды. Бераздан «Яңалиф» дигән басма да ике ел дәвамында чыгып килде. 1932 елдан исә, әлеге ике журнал урынына оештырылган яңа басма «Совет әдәбияты» дип атала башлады. Ул, 1965 елга кадәр чыгып, үзенең урынын «Казан утлары»на бирде. Шөкер, бу соңгысы бүген дә исән, гамәлдә. Алай гына да түгел, яше арткан саен, һаман яшәрә, куәтләнә бара. Аңа алга таба да хәерле гомер телик.


ӘДӘБИЯТ

1. Гомәр Л. Әдип һәм көрәшче / Г. Ибрагимов турында истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. Б. 190.

2. Ибраһимов Г. Беренче тюркология съезды нәрсә бирде? // Безнең юл. 1926. № 1, 2.

3. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. 5 т.: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. 586.

4. Сәгъди Г. Зур әдипләребезнең берсе // Кызыл Татарстан. 1927. 20 ноябрь. Б. 3.


## ФОРМИРОВАНИЕ ПРАВОСОЗНАНИЯ В ПРОИЗВЕДЕНИЯХ Г. ИБРАГИМОВА (на примере романа «Глубокие корни»)


***Мулюков У.А.***



В данной статье рассматриваются возможности влияния художественной литературы на формирование правового сознания. На примере романа «Глубокие корни» Г. Ибрагимова исследуются особенности отражения правосознания определенной эпохи, анализируются поступки героев и события.

This article examines the possibilities of the influence of fiction on the formation of legal consciousness. On the example of the novel «Deep Roots» by G. Ibragimov, the features of the reflection of the sense of justice of a certain era are explored, the actions of heroes and events are analyzed.


Творчество Галимджана Ибрагимова – одно из самых ярких и самобытных литературных явлений XX века. Особенности художественного мышления, своеобразие стиля писателя, глубина философской мысли вызывают огромный интерес не только филологов, но и исследователей других областей (истории, философии, культурологии, юриспруденции и др.). Художественное, критическое, методическое наследие и общественная деятельность Г. Ибрагимова представляют поистине уникальный материал для исследования. Например, роман «Глубокие корни» (1926–1928) отражает определенные черты формирующегося советского правосознания и некоторые характерные процессы современной писателю действительности. Надо отметить, что роман написан в один из наиболее интересных и противоречивых исторических периодов. Как известно, в 20-х годах XX века шла активная борьба за формирование нового правосознания; и в правовой, и в литературной сферах эти годы были эпохой поиска новых форм, нового со-

держания, новых подходов и механизмов. В это время литература является одним из важнейших источников правовых знаний для населения.

Философские словари определяют правосознание, как совокупность взглядов, идей, выражающих отношение людей к праву, законности, правосудию, их представление о том, что является правомерным или неправомерным [5, с. 502].

Роман «Глубокие корни» можно расценивать не только как произведение о классовой борьбе, но и как своего рода учебное пособие по уголовному процессу для простых людей, способа внедрения в массовое сознание определенных правовых идей. Конечно же, просим не воспринимать это суждение буквально. Нельзя не отметить, что в первое же десятилетие советской власти все средства управления литературным процессом были мобилизованы для эффективного использования литературы в качестве метода воздействия на массовое сознание.

Следует также сказать, проблема преступления и наказания издревле была излюбленным литературным сюжетом. И роман Г. Ибрагимова начинается с ударной фразы, немедля сообщая читателю, что преступление – одно из самых тяжких, уже состоялось [3, с. 11]. Этим писатель задает не только смысловые горизонты произведения, но и порождает жанровый спор у читателя. С первых же строк романа сразу может привидеться что-то похожее на детектив. Обычно романы начинаются более нейтрально. А у Г. Ибрагимова первая же строка «Убили Фахри» как молотом по голове, звучит как выстрел или как громкое сообщение в полицию. Это уже с первых секунд чтения создает некое напряжение и тревожное ожидание дальнейших событий. Дальнейшее повествование не отпускает от себя читателя, заставляет не отрываться от книги, требует узнать, а что же там дальше? Такое воздействие действительно часто наблюдается в увлекательных детективах: сюжет с интригой и перипетиями. Однако задолго до нас в предисловии к книге известный литературовед Р. Мустафин вполне резонно заметил, что «Глубокие корни» – это не детектив, а большое многоплановое полотно о кардинальных переменах в деревне [3, с. 10]. Пожалуй, согласимся с этим. Хотя в скобках заметим, что при желании книгу вполне возможно воспринимать и как нечто похожее на детектив. Сказанное будет зависеть от того, с какой точки будем смотреть на написанное, да и от настроения читателя. Это вовсе не попытка низвести роман большого социально-нравственного звучания в ряды заурядного детектива, как сочли бы уважаемые критики, например, Ф. Мусин [2, с. 10], а просто признание нами об умении автора захватить читателя в плен своих размышлений о судьбах крестьян на примере описываемого преступления. Ведь книга Г. Ибрагимова ничуть не менее увлекательна, чем некоторые детективы. А в некотором смысле – даже более полезна. Это лишь рассуждения о так называемых жанрообусловливающих факторах, а определение компонентов жанровой структуры произведения – предмет исследования филологов.

В романе мастерски показаны глубокие переживания героев, психологическое описание их сбывшихся и несбывшихся надежд. Тревожное ожидание Гайши – жены убитого, которая еще не знает о его смерти [3, с. 11] наводит читателя на мысли о бренности мира, заставляет переживать вместе с героями.

С самого начала автор указывает на возможность разных версий совершенного злодеяния. Все, как в жизни. Ведь как у следователя, так и у

окружающих редко сразу же складывается полная реальная картина случившегося. Сразу и немедля увидеть правду не всем удается.

Поначалу ясно лишь одно, что есть потерпевший, то есть Фахри, тело которого обнаружили в овраге [3, с. 12]. А также, что смерть его явно неслучайна. Что на языке уголовного кодекса называется умышленным убийством. На это автором романа сразу же указывается описанием места происшествия с приведением не очень-то приятных подробностей. Зато понятнее укладывается в рамки уголовного процесса. Фахри обнаружен мертвым со следами насильственной смерти: лицо продавлено и сплошь запеклось кровью, череп проломлен, желтовато-белой массой вытек мозг [3, с. 12]. Нарисованная писателем картина тяжела, зато сразу же настраивает читателя на серьезный лад. Тут же описываются и вещественные доказательства: следы крови и валяющийся рядом с трупом железный шкворень. Натуралистическое описание шкворня, что он обмотан пеньковой веревкой, а в маленькое отверстие на тонком конце продет кривой гвоздь [3, с. 12] лишь усиливают правдивость картины. А реплики присутствующих, Джиханши бабая, например, опознавшего свой шкворень, тут же создают первые версии случившегося, которые могут увести в никуда. Масла в огонь новых версий подливают слова Джиханши бабая, что этот самый злополучный шкворень он давал активисту Садыку [3, с. 12]. А тут же подхватившего эту версию косого старика Гимади о давней вражде между убитым Фахри и Садыком порохом взрывает собравшихся [3, с. 17–18]. Воспоминания, что было и не было, мгновенно создают имя подозреваемого. Для некоторых, конечно же, это Садык: раз они дрались в молодости между собою, да еще и шкворень Садык брал, так, кто же кроме него может быть убийцей?

Как и положено, к месту происшествия немедля выдвигается следователь Паларусов [3, с. 19]. А дальше все описывается в соответствии с уголовно-процессуальным законом. Производится осмотр места происшествия, при этом приглашаются понятые – относительно грамотные Гимади и Шангарей, по всем правилам составляется схема, замеряется обнаруженный след ноги, изымается орудие преступления и все это удостоверяется всеми участниками осмотра. Как предусмотрено, вызван для экспертизы единственный на всю округу врач Сергей Тимофеевич, который устанавливает причину смерти от ударов по голове: «прикончили двумя ударами, вскрывать труп нет никакой необходимости…» [3, с. 23–27].

На время автор отвлекается на романтические подробности любви в молодости убитого и вдовы Гайшэ [3, с. 27–30]. Но это ничуть не мешает нашему исследованию. А в какой-то мере даже помогает определить направление, в котором следует искать доказательства преступного деяния. Не обошлось в повествовании Г. Ибрагимова и без описания любви другой пары – предполагаемого убийцы Садыка и его верной жены Нагимы. Кстати, это описание тоже помогло автору, да и нам читателям, получить полную картину случившегося. Эта тема любви, прозвучавшая и в воспоминаниях Нагимэ о молодости [3, с. 63–68] не отвлекает от обозначенной нами темы формировании правосознания.

И далее события развиваются согласно закону. Первой допрашивается потерпевшая Гайшэ – вдова Фахри. Хотя никого конкретно подозреваемым она не назвала, но все же возможную классовую подоплеку убийства назвала. Назревающий в обществе классовый конфликт находит художественное

воплощение в ее словах: «не нравилось кое-кому, что землю у них отнял, что подбивает крестьян идти в артель... да кулакам, конечно, … Фахри все на хвост им наступал…» [3, с. 31].

Как нередко бывает в жизни, да и часто описывается, автор указывает и на ложный след – показания старика Гимади о давней драке и недавней ссоре между убитым и Садыком, добавляя еще одного свидетеля [3, с. 37, 40]. Следователю, конечно, пока невдомек заинтересованность этого свидетеля, позднее автор раскрывает и эту причину, но это уже в конце [3, с. 150]. Но пока и допрошенная Рагия тоже туда же. Сначала тараторила, как Садык дрались с Фахри, а под конец уверенно заявила, что убийца, несомненно, Садык [3, с. 16–47]. Здесь же и показания подслеповатого и туговатого на ухо свидетеля Ахми, что он вроде как видел в день убийства вечером, как ругались Фахри и Садык [3, с. 50–51].

Вполне вписывается в рамки уголовно-процессуального кодекса описание процесса опознания Джиханшой бабаем орудия убийства – окровавленного шкворня. Хочешь, не хочешь, а бабаю пришлось признать, что шкворень принадлежит ему, а давал этот проклятый шкворень не кому-нибудь, а самому активисту Садыку [3, с. 41]. Не верит бабай, что убийца – это Садык, ведь и Фахри, и Садык – первые заступники Джиханши бабая и других бедняков – большевистские активисты в их деревне.

Автору романа ведомы и психологические приемы допроса. Описывает, что вроде случайно следователь заметил у Садыка шрам на лбу, да и равнодушно спросил о происхождении шрама. Но тот сразу без утайки рассказал, что в молодости Фахри полоснул ножом Садыка, а много позже, в день убийства, виделся с убитым. Согласно закону, описано и предъявление на опознание орудия убийства – того же шкворня Садыку. Тот и не вздумал отпираться, а сразу же вспомнил, что брал этот злополучный шкворень у Джиханши бабая [3, с.49]. Тут назрела и очная ставка со свидетелем Ахми, приметившего ссорившихся Фахри и человека, похожего на Садыка. И как нередко бывает на очных ставках, возмущение Садыка [3, с. 51].

Порою кажется, что события в книге развиваются помимо воли автора. Видно, что в романе Г. Ибрагимов ищет врагов и друзей советской власти, а следователь – убийцу. Но все равно все это происходит в рамках уголовно-процессуального закона. Вот так на жизненных примерах без излишних назиданий автор и формирует правосознание простых людей. Оценив доказательства в совокупности: показания свидетелей и самого Садыка, опознание шкворня, следователь, вопреки собственному убеждению, подчиняется фактам и принимает решение задержать Садыка по подозрению в убийстве «на основании полученных материалов», как он сообщает Садыку Минлебаеву [3, с. 52]. При этом устами большевистского функционера Гайфуллина приводятся основания следователя Паларусова для задержания, что преступление, в котором подозревается Минлебаев, тяжкое, имеются улики, подозреваемый дружен с деревенскими, где совершено преступление, если оставить его на свободе, он может сговориться с ними и уничтожить следы преступления [3, с. 61]. Кстати в ныне действующем уголовно-процессуальном кодексе и руководящих указаниях Верховного Суда России учитываются те же основания заключения под стражу: тяжесть обвинения, возможность уничтожить доказательства и угрожать свидетелям [4, с. 63 и 1, с. 14].

Для нас представляет интерес также опознание портным Джамали сшитого им давным-давно казакина, подаренного богатеем Вали своему сподручному Ахми, но совсем неудачно пропившему этот казакин [3, с. 89]. Как позднее оказалось, Вали рассчитался казакином за ложные показания Ахми, и не только за это [3, с. 210, 211].

Как нередко бывает, возникли разногласия прокурора и следователя о мере пресечения, поэтому автор, подчиняясь закону, вместе со своими героями ждет предварительного слушания суда [3, с. 1, 61, 84].

Но все же появилась и другая версия обвинения. Бабушка Минзифа рассказала, что в ночь исчезновения Фахри вернулся от Гимади только под утро, пропал шкворень от телеги, а вечно безденежный придурок Ахми дал ей на хранение двадцать рублей, кроме того он повадился просить денег у Гимади, а то и у самого Вали бая, а те почему-то ему давали деньги [3, с. 129–130].

Интересную вещь сообщили и ребятишки, они видели, как старый Гимади украдкой положил в карман железный шкворень, о чем и сообщили следователю [3, с. 131]. И тут уже оказались арестованными бай Вали, старик Гимади и незадачливый Ахми [3, с. 150].

Между тем, автор описывает экономические и контрреволюционные преступления Вали бая и его сотоварищей. В преступлениях, как оказалось, были замешаны еще и чиновники Иванов и Салахиев [3, с. 151].

Мастерски описывает далее Г. Ибрагимов и состоявшийся судебный процесс. Соблюдаются всякие формальности вроде вручения повесток и многое другое [3, с. 144]. Здесь автор демонстрирует и состязательность процесса стороны обвинения и защиты: прокурор Ансаров всеми силами поддерживает обвинение – «раскусил хитрость старой лисы» адвоката Аржанова [3, с. 152–153, 181, 182]. Позднее прокурор уже выступил в прениях с обвинительной речью. И обеспечение национального языка судопроизводства – надлежащее участие дважды в процессе переводчика [3, с. 186]. Все, в общем, как учили.

Автор романа не зря показывает попытку свидетеля Джамали под видом болезни уклониться от участия в процессе [3, с. 149], и как торжество проявившегося правосознания – его добровольную явку в суд [3, с. 210]. Ведь это тоже формирование правосознания. Допросом свидетелей опровергаются утверждения Вали бая, что это его усилиями подняли совхоз. Оказывается, дотацию для четырех совхозов заглотил один Вали Ханов. При этом рабочие его совхоза бедствуют, ночуя на голых нарах, голодают [3, с. 156]. А чиновник Салахиев закрывал на это глаза. Ведь это его поили самогоном и первоклассно кормили три дня, топили ему баню [3, с. 157].

Допрашиваются новые свидетели, как по ходатайству стороны обвинения, так и защиты. Описывается опознание в судебном заседании свидетелем стряпухой Минзифой беззастенчивого вымогателя Низаметдина Худжабаева [3, с. 157]. Она же в судебном заседании опознает Салахиева, для которого сварила четыре курицы и ломала веники для бани [3, с. 185]. Оглашаются показания неявившихся свидетелей [3, с. 185]. Защитник Арджанов задает подсудимым и свидетелям нужные для защиты, порою каверзные, вопросы [3, с. 154, 157, 204, 205, 210], пытается опровергнуть обвинение показаниями Низами Худжабаева [1, с. 182].

Когда надо, председатель суда наводит порядок в зале судебного заседания [3, с. 183, 189]. Огненным ливнем было выступление с обвинительной речью прокурора: он предложил Ахмеда Уразова и Гималетдина Бикмурзина осудить по статье 136 УК каждого к трем годам заключения. Салахиеву и Иванову по статьям 109, 113, 117 и 118 к пяти годам заключения, а организатору Вали Хасанову по статье 58-8 УК прокурор потребовал расстрела [3, с. 216–217]. Приведены и довольно-таки находчивые речи защитников, например, старого адвоката Аржанова в защиту Вали Хасанова, ловко использовавшего татарские поговорки [3, с. 218–219]. То есть, писатель очень верно подметил все особенности уголовного процесса.

Выпущенный на свободу Садык становится свидетелем обвинения [3, с. 200], а каждый из преступников получает по законам того времени.

Приводятся показания подсудимых Ахмета Уразова (Ахми) и Гимадетдина Бикмурзина (Гимади), из которых удалось установить, что один шкворень Гимади дал Ахми, чтобы «проучить Фахри» [3, с. 211], Ахми дважды из-за кустов ударил Фахри по голове, а Гимади принялся заметать следы: перетащил убитого в овраг, подобрал другой шкворень, брошенный Садыком, вымазал в крови и подбросил к трупу, чем поначалу смог запутать следствие. Взял тридцать рублей у бая Вали и отдал их Ахми [3, с. 212].

Таким образом, Г. Ибрагимов описал преступные действия. Хасанов Вали совершал растрату, а Салахиев за взятки-подношения не замечал его нарушений, Иванов же поступившие сигналы из редакции семь месяцев держал под спудом, а некоторые даже сжег, за что от Вали бая получал продукты, даже бриллиантовые серьги жене Иванова подарил этот бай [3, с. 175, 178, 179]. Но всей их распрекрасной жизни мешал Фахри, которого решили «проучить малость», да перестарались. Сегодня Ахми назвали бы киллером, а бая Вали и Гимади – заказчиками. Очень даже к месту для преступников подвернулся активист Садык, на которого пытались свалить убийство.

Показываются и поиски одних заступиться за Садыка, так же как и других оклеветать его [3, с.59, 85, 170], а третьих – добиться расстрела Вали бая [3, с. 218]. Верная супруга Садыка Нагимэ сразу же после задержания забегала, отыскивая соратников мужа и возможных покровителей, чтобы освободить мужа [3, с. 56–59, 83]. И в те времена были мысли о возможности вмешаться в правосудие: «если б я была активисткой, рассуждала про себя Нагимэ, голос мой звучал бы по-иному, я бы знала, кого повидать, на какую кнопку нажать… [3, с. 84]. В наши дни стало модно искать подходы к суду и критиковать правосудие. В те времена по рассказам стариков, такое тоже бывало. Автор избежал соблазна проехаться писательским катком по правосудию. Устами авторитетного с огромным рабочим и партийным стажем Василия Петровича, к которому обратились за помощью, резонно ответил, что стажем кодекс не перешибешь и что надо ждать заседания суда [3, с. 84]. А деятельность рвущихся в судебное заседание и пытавшихся вмешаться в правосудие делегаций из деревни председатель суда решительно пресек: «во время процесса никаким делегациям на суде выступать не разрешается!» [3, с. 183].

На примере ответственного работника Салахиева, полагавшего, что творится беззаконие, автор убедительно показывает, что у разных людей может быть разное правосознание [3, с. 189].

Показано и стремление самого суда к справедливости и скорейшему рассмотрению уголовного дела. Председатель суда Биганов, хотя и тяжело болен, но доводит процесс до конца, твердо выполняя требование закона о несменяемости суда [3, с. 180–181].

Не обошел вниманием автор и законы шариата. Вроде походя, но все же показал необходимость равенства между всеми четырьмя женами Габдуллы хазрета [3, с. 191].

Интересен эпизод, когда красноармеец Шарафи Гайнетдинов раздает добро ишана Габдуллы ошеломленным беднякам [3, с. 196], что говорит о формировании революционного правосознания. Сын Вали бая Мустафа тоже усиленно штудирует уголовный кодекс [3, с. 151], понятно, что не сегодня, так завтра может пригодиться.

Завершается книга вроде бы невесело: провозглашен приговор с очень суровыми видами наказания. Но все же после приведения приговора в исполнение, в романе Г. Ибрагимова заалела заря и взошло яркое солнце. Автор умело показал, что правовое сознание героев подвергается существенным изменениям в ходе революционных или иных преобразований.

Мы так скрупулезно отыскивали и отмечали юридически тонкости, описанные Г. Ибрагимовым, поскольку хотелось показать, что, он хорошо знает не только жизнь крестьян, но и законодательство, а потому роман «Глубокие корни» вполне мог и может повлиять на формирование правосознания. Полагаем, что это ничуть не противоречит заявленной известными филологами задаче, что произведение «нуждается в более разностороннем рассмотрении» [2, с. 10]. Философская идея и психологическая углубленность романа, умение обобщать литературный и правовой материал дают основание утверждать, что произведение Г. Ибрагимова оказало большое влияние на общественное сознание, удовлетворяет эстетические, духовные потребности читателя.

Конечно же, современный читатель должен понимать, в какое время проходил судебный процесс, и делать на это поправки в своих возможных критических суждениях. Но все же удивительно, что книга Г. Ибрагимова «Глубокие корни» актуальна и сегодня, хотя давно уже нет классовой борьбы, но проблема формирования правосознания осталась.

Таким образом, творчество Г. Ибрагимова оказало влияние не только на развитие художественной прозы тюркоязычных народов, но и на формирование правового сознания населения. Г. Ибрагимов, как талантливый писатель, как крупный общественный и государственный деятель, полагаем, отчетливо осознавал, что литература является одним из важнейших источников правовых знаний для населения.

ЛИТЕРАТУРА

1. Бюллетень Верховного Суда РФ. 2014. № 2.

2. Галимджан Ибрагимов и XXI век. Материалы международной научно-практической конференции, посвященной 120-летию со дня рождения Г. Ибрагимова. Казань, 2007. 325 с.

3. Ибрагимов Г. Глубокие корни: роман / пер. с татар. Р. Фаизовой; вступ. статья Р. Мустафина. Казань: Таткнигоиздат, 1973. 223 с.

4. Уголовно-процессуальный кодекс Российской Федерации. М.: Проспект, 2016. 288 с.

5. Философский энциклопедический словарь. Издание 2-е / ред. С.С. Аверинцев, Э.А. Араб-Оглы, Л.Ф. Иличев и др. М.: Советская энциклопедия, 1989. 382 с.

# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫҢ ТОРМЫШКА КАРАШЫН ФОРМАЛАШТЫРУДА ТУГАН ЯГЫНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ РОЛЕ

***Фәтхтдинов Ф.К.***

На территории современного Башкортостана встречается Европа с Азией, и она является соединительным мостом культур различных народов двух континентов. Тут издавна в дружбе и согласии живут славянские, тюркские, финно-угорские народы России. Такая благодатная земля дала стране много знаменитых людей. Одна из таких личностей Галимджан Ибрагимов – видный татарский государственный деятель XX века, писатель, журналист, ученый, педагог. Особенность личности Г. Ибрагимова заключается в том, что в деле созидания духовных богатств, в решении острых национальных вопросов он служил не только своему народу, но и другим братским народам. Так как он воспитан, обучался, трудился в многонациональной общественной среде и хорошо знал проблемы и стремления тюркских народов. Поэтому представители творческой интеллигенции башкир, казахов, крымских татар, адыгеи, черкесов, узбеков называют его своим учителем.

On the territory of modern Bashkortostan, there are Europe and Asia, and it is a connecting bridge of cultures of different peoples of two continents. Slavic, Turkic, Finno-Ugric peoples of Russia live in friendship and harmony for a long time. Such a fertile land gave the country a lot of famous people. One of them Galimdzhan Ibragimov is a Tatar public servant of the 20th century, writer, journalist, scientist, teacher. The peculiarity of G. Ibrahimov's personality is that in the work of creating spiritual wealth, in solving national issues, he served not only his people, but also other fraternal peoples. He was brought up, educated, worked in a multinational social environment and knew the problems and aspirations of the Turkic peoples. Therefore, members of the creative intelligentsia of Bashkirs, Kazakhs, Crimean Tatars, Adygea, Circassians, Uzbeks call him their teacher.

Гаҗәеп бай бүгенге Башкортстан җире илебезгә, төрки дөньясына һәм, әлбәттә, милләтебезгә бик күп талантлар тәрбияләде. Шулар арасында иң чагуларының берсе – күренекле язучы, журналист, галим-филолог, педагог, сәясмән һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимов. Аның шундый киң даирәле шәхес булып формалашуында туган ягы мөһим урынны алып торган. Галимҗан Ибраһимов иҗатының һәм иҗтимагый-сәяси эшчәнлегенең Уфа яклары белән бәйләнеше галимнәр тарафыннан берничә юнәлештә фәндә тикшерелеп, киң җәмәгатьчелеккә җиткерелде инде. Бу аңлашыла да, чөнки ул үзенең бөтен тамырлары белән Уфа ягына, шунда яшәгән халыкларга береккән: анда туган, шәхес һәм әдип булып формалашкан, билгеле җәмәгать эшлеклесе булып төрки дөньясына танылган. Әлбәттә, һәркемнең үзенең туган җире, белем эстәгән, Г. Ибраһимовның үзенең сүзләре белән әйтсәк, «гакылының киң хөррият» [8, б. 9] алган урыны аның зур акыл иясе булып формалашуында мөһим роль уйный. Бу очракта хәзерге Башкортстан һәм Уфа шәһәренең географик урынына да игътибарны юнәлтеп, аларның Европа һәм Азияне тоташтыручы территориаль генә түгел, шулай ук төрле милләт халыкларын берләштерүче мәдәни, рухи күпер икәнлеген дә истән чыгармаска кирәк. 1720 елда ук бу төбәктә бөтен төрки дөньясына танылу алган Стәрлебаш мәдрәсәсендә татар, башкорт, казах шәкертләре белән бергә башка тугандаш халыкларның да вәкилләре белем алган. 1788 елда Уфада

Русиянең Үзәк диния нәзарәте ачылып, аның бөтен Русия мөселман халыкларының үзәгенә әверелүен, шушы җир туфрагының бөек рус язучылары С.Т. Аксаков, А.П. Чехов, опера җырчысы Ф.И. Шаляпинның биографияләре белән бәйле булуын, шушы җирлектә туып үскән рус рәссамы М.В. Нестеров, чуваш халкының классик язучылары К.В. Иванов һәм Я.Г. Ухсайларны, татар һәм башкорт халкы тарихында күренекле урынны билгән сәясмәннәр Мирсәет Солтангалиев һәм Зәки Вәлидиләрне искә алу да күп нәрсә турында сөйли. Шул ук вакытта бөек рус совет тарихчысы, этнографы, көнчыгышны өйрәнүче галим Лев Николаевич Гумилёвның пассионар теориясен нигез итеп алсак, ул чорда Уфа этно-төбәге төрле халыкларның тарихтан килә торган җир-су, рух, тел, гореф-гадәт, яшәеш үзенчәлекләрен туплаган бер җирлекне тәшкил итеп, тугандаш халыклар этносының рухи-мәдәни-сәяси күтәрелүенә булышлык итте. XX гасыр башында Уфа губернасы, бигрәк тә Уфа шәһәре, Евразия халыкларының мәдәни үзәге булуының ачык мисалы – бөтен төрки дөньяга билгеле «Галия» мәдрәсәсе. Чөнки анда татар һәм башкорт милләтле шәкертләр белән бергә казах, үзбәк, кыргыз, төрекмән, кырымтатар, дагстанлы, черкес, адыгейлар [8, б. 8] һәм башка милләт вәкилләре дә белем алган. Галимҗан Ибраһимовның 1906 елда ук шушы мәдрәсәдә төрле милләт шәкертләре белән бергә белем алуы аның башка халыкларга карата булган мөнәсәбәтен формалаштыра. Шушы мәдрәсәдә ныгыган карашлары тәэсирендә кулына каләм алып, беренче мәкалә һәм хикәяләрен яза башлый. Аның 1907–08 елларда Казандагы «Әльислах» газитендә нәшер ителгән «Уфа мәдрәсәләре» (1907), «Шәкертләр аһ-зары» (1908), «Шәкертләр һәм уку» (1908), «Уфа йоклый» (1908) мәкаләләренең төп пафосы татар милли мәгарифе, матбугаты, нәшрияты, рухи мәдәнияте мәсьәләләре өчен борчылулардан һәм аларны тормышка ашыру өчен армый-талмый көрәшергә кирәклеген ассызыклаудан гыйбарәт. Бу инде Галимҗан Ибраһимовның – егерме яшьлек «Галия» мәдрәсәсе шәкертенең – үз туган ягында татар әдәбияты, мәдәнияте, мәгарифе өчен борчылуын, милли матбугатның халыкка аң-белем таратудагы урынын аңлап принципиальлек белән оран салуын, бөтен җәмәгатьчелекнең игътибарын халкыбызның үсеше өчен мөһим булган милләтнең рухи-мәдәни хәвефсезлеген тәэмин итү мәсьәләләренә юнәлтүен исбатлый. Һәркемгә билгеле, рухи-мәдәни үсеш милләтне саклап калу һәм аның киләчәген тәэмин итүнең нигезен тәшкил итә, ә рухи-мәдәни яктан таркалган халыкның киләчәге караңгы. Ул мәкаләләрдән күренүенчә, Галимҗан Ибраһимов милләтпәрвәр шәхес буларак, бу мәсьәләләрне яхшы аңлый һәм шуның өчен милләтнең киләчәге, Русия мөселманнарының мәркәзе язмышы өчен борчылуын белдерә. Бары тик үз милләтенең патриоты гына башка милләтләрне дә ихтирам иткәнлеген без Галимҗан Ибраһимовның эш-гамәлләре аша күрәбез. 1909 елда Уфадагы «Галия» мәдрәсәсеннән киткән вакытта инде ул карашлары ныгыган шәхес, өч әдәби, бер фәнни китап бастырып чыгарган, шактый өлгергән, татар дөньясына таныла башлаган язучы һәм фикер иясе була.

1915–17 елларда яңадан Уфага кайтуы аның үзе укыган «Галия» мәдрәсәсендә укытучылык итүе белән бәйле. Истәлекләрдән күренүенчә, бу чор «анда укучы яшьләргә яңа рух өрә, андагы иҗади һәм иҗтимагый тормышны тагын да җанландырып җибәрә. Дәресләрендә ул шәкертләрне борынгы заманнардан алып иң соңгы көннәргә кадәр формалашып һәм үсеп килгән милли әдәбиятның бай хәзинәләре белән таныштырып кына калмый, аларда

рухи, эстетик матурлык тәрбияләү максатын да куя» [8, б. 13]. Шулай ук бу елларда төрки халыкларының зыялылары тарафыннан үз халкыңны танып белү, башка милләтләргә, аларның омтылышларына, рухи ихтыяҗларына карата ихтирамлы мөнәсәбәт, милләтара бердәмлек тойгылары тәрбияләү буенча да күп эш башкарыла. Төрки халыкларының уртак һәм хосусый сыйфатлары мәсьәләләре турында да матбугатта капма-каршы бәхәсләр калкып чыга. Бу бәхәсләрдән Галимҗан Ибраһимов та читтә торып калмый. Ул инде 1910 елдан башлап, гәзит-журналларда басылган «Татар теле вә татарча язу хакында бер-ике сүз» («Йолдыз», 1910, 12 гыйнвар), «Без – татармыз» («Шура» журналы, 1911, апрель), «Без кем? бәхәсе» («Шура» журналы, 1912, май) һ.б. мәкаләләре халык, милләт төшенчәләрен аңлатуга, үзебезгә генә хас бай сөйләм һәм язма телебез барлыгын раслауга юнәлтелгәннәр. Галимҗан Ибраһимовка «Галия» кебек күп төрле халыкларның уллары укыган мәдрәсәдә милләт һәм милләтара мөнәсәбәтләр мәсьәләсен теоретик яктан гына түгел, гамәли яктан да чишәргә кирәк була.Ул мөгаллимлек иткән елларда мәдрәсәдә укучы төрле милләт шәкертләре үз телләрендә әдәби-иҗади кулъязма журналлар: татарлар һәм башкортлар – «Парлак», кырым татарлар – «Өмет», черкеслар – «Ләгү», казах шәкертләре «Садак» исемле журнал чыгаралар. Бервакыт казах һәм татар шәкертләре арасында тел мәсьәләсендә ыгы-зыгы куба. Шушы уңайдан «Галия» мәдрәсәсе шәкертләренең Уфа зыялылары катнашында җыелышы үткәрелә. Анда Галимҗан Ибраһимов күләмле доклад белән чыгып, төрки халыкларының күп гасырлык үсеш тарихына күзәтү ясый. Аларның дөньяның төрле тарафларына таркалып яшәве берничә мөстәкыйль әдәби телнең барлыкка килүенә, аерым үскән берничә әдәбиятның формалашуына нигез бирүе турында сөйли. Конкрет фактларга таянып, казах халкының үз телендә матбугаты, әдәбияты туып килүе турында да әйтә, «гомуми әдәби телдән аерылып, Насыйрилар салган эз белән татар теленә, татар әдәбиятына кереп китүебез никадәр табигый булса, казахның үзенең әдәбияты тууы да, мәктәпләрендә үз шивәләрен алга сөрү дә шул кадәрле табигыйдер» [3, б. 225–230], – дип исбатлый ул.

Һәр халыкның үзаллылыгы, мәдәниятен, әдәбиятын үстерү хокукын яклаган бу чыгышын соңрак Казандагы «Аң» журналында «Телләре башка булса да, күңелләре бер (матбугатта казах яшьләре тарафыннан кузгатылган тел мәсьәләсе мөнәсәбәте белән)» дигән исем белән бастырып чыгара. «Галия» мәдрәсәсе кысаларында төрле милләт шәкертләре арасында үткәрелгән мондый фикер алышулар, бер яклап, шул милләт вәкилләренең әдәби-мәдәни тормышына тирән эз, зур йогынты ясасалар, икенче яклап, Галимҗан Ибраһимовның үзе өчен дә рухи-сәяси чыныгуның тәгаен тормыш мәктәбенә әйләнәләр. Гомумән, ул мөгаллимлек иткән дәвердә Уфадагы «Галия» мәдрәсәсе Европа һәм Азия халыклары вәкилләрен берләштергән милли-мәдәни үзәккә әверелә. Шушы мәдрәсәдә Галимҗан Ибраһимов тырышлыгы белән оешкан беренче һөнәри татар, башкорт, казах хорын, кыллы оркестрын искә алу да күп нәрсә турында сөйли. Сәйфи Кудаш язуынча, соңыннан бу оркестр Уфа халкының яратып тыңлый торган бер оркестрына әйләнә [1, б. 99]. Мәдрәсәгә музыка укытучысы итеп Варшава консерваториясе профессоры Вильгельм Клименцның эшкә алынуы да аның тәкъдиме белән була. «Галия»дә төрле милләт вәкилләренең бердәм булып, бер-берсенә ихтирам белән, дуслык, туганлык мөнәсәбәтләре белән яшәп белем алулары, әлбәттә, анда мөгаллимлек иткән Галимҗан Ибраһимовның да

тәрбия җимеше. Төрле милләтләргә карата толерантлык идеясе белән тәрбияләнгән ул шәкертләр арасыннан үсеп чыккан Шәехзадә Бабич, Хөсни Кәрим, Сәйфи Кудаш, Хәсән Туфан, Зыя Ярмәки, Вәсим Солтанов, Гыйзетдин һәм Әхкәметдин Исәнбердиннар, Зыя Өммәти, Хәбибулла Габитов, Бәхтияр Мирзанов, Галә Ходаяров, Галимҗан Нигъмәти, Булат Ишемгулов һәм башкалар кебек татар, башкорт шагыйрьләре һәм прозаиклары киләчәктә әдәби тормышның җанлануына этәргеч бирделәр. Казах совет әдәбиятына нигез салучыларның берсе Баембет Майлин, әдәбиятчылар – Жыенгали Тилепбергенов, Ногман Манаев, Габиден Мостафин, үзбәк Мирмухсин Ширмухамедов, черкес Әхмәд Хатков, адыгей Тембот Керашев һәм башкалар Галимҗан Ибраһимов тәэсирендә тәрбияләнеп, белем эстәп – һәрберсе үз милли мәдәниятен үстерүгә зур өлеш керткән шәхесләр.

1917 елгы Февраль революциясе аның тормышына зур үзгәрешләр кертә. Ул үзенең эшчәнлеген мәдрәсә кысаларына гына сыйдыра алмый. Ул зуррак аудитория – татар һәм башкорт халыклары белән эш итәр өчен мәдрәсәнең тарих һәм география укытучысы булып эшләгән язучы Фатих Сәйфи-Казанлы белән Уфада «Ирек» гәзитен чыгаруны оештыра. Аның беренче номеры 1917 елның 30 мартында чыга. 1917 елның көзендә «Ирек» гәзите Уфада чыгып килгән «Солдат теләге», «Авыл халкы» гәзитләре белән берләшеп, «Безнең юл» исеме белән чыга башлый һәм аның да мөхәррире Галимҗан Ибраһимов була. Шул чорның кискен иҗтимагый мәсьәләләрен үзәккә куйган Г. Ибраһимов гәзит аша, көндәлек эшендә булсынмы, Уфаның әдәби җәмәгатьчелеген үз тирәсенә туплау, аңа юнәлеш бирү җәһәтеннән дә активлыгын киметми. Гәзит эшенә Мәҗит Гафури, Шәехзадә Бабич, Сәгыйть Рәмиев, Сәйфи Кудаш, Сәгыйть Сүнчәләйләрне җәлеп итә. Шулай итеп, 1–2 ел элек «Галия» мәдрәсәсендә Уфаның яшь шагыйрьләренә әдәби иҗат сабагы, сүз сәнгатендә осталык дәресе биргән булса, хәзер инде тормыш сабагы, иҗтимагый караш, сәяси юнәлеш сабагы бирә. 1917 елның декабрь ахырында Галимҗан Ибраһимов Учредительное собрание әгъзасы буларак, Петроградка китә.

Русия башкаласында хөкүмәт органнарында эшләгән вакытында да Галимҗан Ибраһимов туган ягыннан аерылмый, форсаты чыккан саен кайтып йөри.

Уфа шәһәрендәге журналистика өлкәсендәге эшчәнлеген гомумиләштереп шуларны әйтергә мөмкин, Галимҗан Ибраһимов татар телендә чыгучы гәзитләрне оештыручы, аларның мәгънәви һәм сәяси юнәлешләрен билгеләүче, иҗади көчләрне туплаучы мөхәррир, ялкынлы публицист, идеолог һәм журналист. Шул ук вакытта «Галия» мәдрәсәсе шәкертләре тарафыннан даими чыгарылып килгән кырымтатарларының «Өмет», черкесларның «Ләгү», казах шәкертләренең «Садак» исемле кульъязма журналлары да аның фатихасы белән һәмул мөгаллимлек иткән чорда дөнья күрә. Шулай итеп, Галимҗан Ибраһимов XX гасыр башында Уфада башка милләтләрнең журналистикасына да нигез салучы булган.Бу гамәлләрне ул халыкның рухи-мәдәни тормышында басма матбугатның ролен яхшы аңлап эш иткән.

Туган ягында төрле милләт халыкларының үзара тату, бердәм яшәүләрен күреп тәрбияләнгән Галимҗан Ибраһимов үзенең бөтен тормышын һәм иҗади эшчәнлеген шул дуслык атмосферасын сакларга һәм сафландырырга юнәлтте. Бу аның иҗатында да ачык чагылды. Үз бәхете өчен көрәшүче «Казакъ кызы»ндагы Карлыгач Сылу образы, күпчелек әсәр-

ләрендә күңелләрендә зур рухи байлык йөртүче, табигый талантка ия булган башкорт образлары булуы моның ачык мисалы. Гомумән, ул үзе дә ике тугандаш – татар һәм башкорт халкының уртак булган гореф-гадәтләре, бәйрәмнәре, ике халыкны берләштерә торган күңел байлыклары йогынтысында тәрбияләнгән шәхес иде. Аның украин шагыйре Тарас Шевченкога зур хөрмәт белән, аның иҗади талантына сокланып язган юллары да игътибарга лаек. «Ул – хөррият каһарманы. Болардан бигрәк ул мәхкүм бер халыкның киң, якты бер дөньяга чыгу юлындагы тарихи идеалының тәмсале мөҗәссәме – ул малорус халкының бөтен иҗтимагый әмәлләренең символы», – дип язды Галимҗан Ибраһимов 1914 елда [3, б. 160]. Әлбәттә, мондый мисалларны аның иҗатыннан һәм тормышыннан күпләп китерергә була. Галимҗан Ибраһимовның башка милләт халыкларына карата ихтирамлы мөнәсәбәте аның шәкертләренә дә күчә. Бер генә мисал, шәкертләре Шәехзадә Бабич һәм Сәйфи Кудаш тугандаш каракалпак һәм казах балаларына аң-белем бирү өчен алар яшәгән төбәкләрдә мөгаллимлек итәләр.

Галимҗан Ибраһимовның Уфа шәһәрендәге яшәвен үзенең «Кызыл чәчәкләр»ендәге тормышның төбеннән күтәрелгән орлык чәчүче белән чагыштырып булыр иде. «Галия» мәдрәсәсе шәкерте буларак, 1906–09 елларда ул белем орлыкларын җыеп, алган белемен, 1915 елга кадәр – яңадан Уфага мөгаллим булып килгәнче, тормыш тәҗрибәсе белән баетып, аларны уңдырышлы туфракка – төрле милләт халкының төрлесе-төрле якка таралган алдынгы карашлы яшьләренә сибеп һәм алар, үз чиратында, Галимҗан Ибраһимовтан алган орлыкларны һәрберсе үз милләте җирлегенә чәчеп таратканнар. Ул уңдырышлы мәдәният орлыклары, шулай итеп, Европа һәм Азия халыклары арасында таралганнар һәм шытып чыгып мул уңыш биргәннәр.

ӘДӘБИЯТ

1. Галимҗан Ибраһимов турында истәлекләр / төзүче һәм әдәби эшкәртүче Афзал Шамов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1966. 424 б.

2. Гимадиев Ү. Талант һәм хезмәт. Өфө: Башкорт. кит. нәшр., 1982. 160 б.

3. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. 5 т. 616 б.

4. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 6 т. 606 б.

5. Ибраһимов Г. Сайланма әсәрләр: 3 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1957. 1 т. 526 б.

6. Ибраһимов Г. Сайланма әсәрләр. 3 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1956. 2 т. 594 б.

7. Мөхәммәдова Г. Эзләнүләр: Документаль повестьлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 376 б.

8. Сафуанов С. Галимҗан Ибраһимов һәм Башкортстан. Уфа: Башкортстан дәүләт педагогия институты, 2000. 51 б.

9. Хасанов М.Х. Писатель, ученый, революционер. М.: Наука, 1987. 318 с.

## МӘКТӘПТӘ Г. ИБРАҺИМОВ ИҖАТЫН ӨЙРӘНҮ ЮЛЛАРЫ

***Абдуллина Д.М., Мөхәрләмова Г.Н.***

В статье определяются пути изучения творчества Галимджана Ибрагимова в старших классах. Монографического характера уроки дают возможность не только глубже изучить биографию писателя, но и раскрыть связь изучаемого литературного произведения с жизнью и творчеством писателя. Современные образовательные технологии, новые методы и приемы, применяемые на этих занятиях, способствуют достаточно полному достижению планируемых результатов у учащихся.

The article defines the ways of studying Galimdzhan Ibragimov's work in high school. The lessons of a monographic nature make it possible not only to study the biography of the writer more deeply, but also to reveal the connection of the studied literary composition with the life and work of the writer. Modern educational technologies, new methods and techniques used in these classes contribute to a fairly complete achievement of the planned results for students.

Югары сыйныфларда язучы иҗаты белән танышу аны җентекләп өйрәнү рәвешендә башкарыла. Бу вакытта әдәби әсәр язучының тормыш юлы һәм иҗаты белән тыгыз бәйләнештә өйрәнелә, чөнки «һәр әдәби әсәрдә аны тудыручы – язучының шәхесе, әдипнең тормышны аңлау-аңлатуы чагылыш таба. Шуңа төшенмичә торып әдәби текстны бөтен тулылыгында, дөрес тикшерүгә ирешеп булмый. Язучы шәхесенең үзенчәлекләрен, холык-фигылен, язмышын, тарихи һәм эстетик карашларын ачыклау аның биографиясен өйрәнү аркылы тормышка ашырыла» [2, с. 278].

Г. Ибраһимовның 10 нчы сыйныфта тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнүгә 4 сәгать бирелә. Бу вакыт эчендә язучы биографиясе белән танышу һәм «Яшь йөрәкләр» романын өйрәнү күздә тотыла. Әйтергә кирәк, Г. Ибраһимов эшчәнлеге белән танышу алдагы дәрестә «XX гасыр башында әдәби тәнкыйть һәм Г. Ибраһимовның тәнкыйди эшчәнлеге» темасын өйрәнү вакытында ук башлана. Бу вакытта XX гасыр башында әдәби тәнкыйтьнең формалашу һәм үсешен тудырган шартларны, әдәби тәнкыйтьнең әдәби үсешкә йогынтысын ачыклау белән бергә Г. Ибраһимовның «Татар шагыйрьләре» мәкаләсе белән танышу, язучының әдәби тәнкыйть үсешенә керткән өлешен бәяләү эше башкарыла. «Татар шагыйрьләре» мәкаләсе белән танышу барышында Г. Ибраһимов ни өчен Г. Тукайны өченче урынга куя, нигә аның шагыйрьлеген шик астына сала? дигән сорауга җавап табу өчен укучыларның игътибарын Г. Ибраһимовның С. Рәмиев һәм Дәрдмәнд иҗатларын бәяләгәндә алардагы нинди сыйфатка өстенлек бирүенә юнәлтү сорала. Дәреслектән шуны дәлилләрлек өзекләрне кабат укыту отышлы. Шул өзекләргә нигезләнеп, Г. Ибраһимовның С. Рәмиев һәм Дәрдмәнд иҗатына бәя биргәндә алардагы хыял, рух, ялкынлы хисләр өермәсе, тормыш турында өстән торып фәлсәфи фикер йөртүгә өстенлек бирүе, бу шагыйрьләрдәге тормыш чынбарлыгыннан өстен торып илаһи бөеклеккә, хыял югарылыгына чыга алуны шагыйрьлек итеп тануы, ә Г. Тукайда нәкъ шул сыйфатлар юклыгын кимчелек итеп күрсәтүе ачыклана.

Укучыларга Г. Ибраһимов шигъриятне романтикларча аңлый, аңа шул яктан карап бәя бирә, С. Рәмиев, Дәрдемәнд иҗатларын югары бәяләп, Г. Тукай иҗатына тәнкыйди караш ташлавы аңлату сорала. Аның Г. Тукайның тормыш чынбарлыгының караңгы якларын да шигърияткә кертүен кабул итә алмаганын, романтизм идеяләре кушуынча шигырь рух, хыял югарылыгында, илаһи матур хисләр, фәлсәфи уйланулар югарылыгында булып, гади тормыш ваклыкларыннан ерак торырга тиеш булып санавын төшендерергә кирәк була.

Укучыларны Г. Ибраһимовның тәнкыйть өлкәсендәге эшчәнлеге белән таныштырганда, әдипнең биредә ике юнәлештә эшләвен, ягъни әдәби тәнкыйть хасиятләрен өйрәнүен һәм аерым язучы иҗатларына бәя бирүен күрсәтеп үтәргә кирәк булыр.

Алдагы дәрес Г. Ибраһимовның тормыш юлы, иҗаты һәм эшчәнлеге турында белемнәрне тирәнәйтү максатын куеп үткәрелә. Дәрес башында –

оештыру, мотивлаштыру этабында М. Гафуриның Г. Ибраһимов турындагы сүзләре эпиграф итеп тәкъдим ителә: Кем ул Галимҗан? Ул әдип кенә түгел. Телче, тарихчы гына түгел. Ул бер татар, казакъ өчен генәме? Юк. Үзбәк, азәрбайҗаннар, тагы әллә кемнәр арасында гына шөһрәт түгел ул. Бөтен Шәрекъның кояшы ул. Менә кем ул Галимҗан!

Әлеге юлларда М. Гафури тарафыннан Г. Ибраһимовның Шәрекъның кояшы дип аталуы укучылар алдына проблемалы сорау рәвешендә куелып, дәрес ахырына бу сорауга җавап таба алачаклары искәртелә.

Дәрестә уку мәсьәләсе буларак укучыларның Г. Ибраһимовның төрле өлкәләрдә эшчәнлек итүе белән таныш булмавы, аның әдәби иҗатын тирәнрәк белү теләге белән бәйле рәвештә проблема булып алга чыга.

Аңлашыла ки, уку мәсьәләсен чишү барышында Г. Ибраһимовның тормыш юлы һәм иҗаты хезмәт куйган эшчәнлек өлкәләре белән таныштыру күздә тотыла. Язучының портреты белән эш тә үзенчәлекле рәвештә үткәрелә ала. Аерым алганда, Г. Ибраһимовның төрле рәссамнар (Л. Фәттахов, П.П. Беньков, Х. Рәҗәпов һ.б.) иҗат иткән портретларын тәкъдим итү уңышлы. Укучылар бу портретларда әдипнең нинди итеп сурәтләнгәнен билгелиләр. Бу вакытта барысына да – йөз чалымнары, күз карашы, киеме, чолгап алган тирәлек сурәтләнешенә һ.б. игътибар итү сорала.

Язучының тормыш юлы белән таныштырганда биографиясендәге төп фактларга тукталып сөйләү сорала. Г. Ибраһимовның гаиләдә яхшы тәрбия алуын, әти-әнисе аны белемле итүләрен тырышуларын ассызыклап аңлатырга кирәк. Белем алган уку йортлары турында сөйләгәндә аның Оренбургтагы мәдрәсәдән шәкертләр күтәрелешендә катнашканы өчен мәдрәсәдән куылуын «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» исемле әсәре белән бәйләп сөйләргә мөмкин. Бу вакытта Г. Ибраһимов максатчанлыгының алга таба белемен дәвам итүендә зур роль уйнаганын искәртеп үтү сорала.

Г. Ибраһимовның күп җирләрдә яшәвен аның дөнья күрү, тормышны төптән өйрәнү, күп белергә омтылуы белән бәйләргә кирәк. Бу вакытта укучыларда дәреснең эпиграфы булган М. Гафуриның сүзләрендә әдипнең Шәрекънең кояшы итеп билгеләнүенә төшенү процессы бара.

Г. Ибраһимовның октябрь инкыйлабын куанып каршы алучыларның берсе булуын, бу елларда иҗат эше белән шөгыльләнүен, дәүләт һәм җәмәгать эшләрендә актив катнашуын ассызыклап сөйләргә кирәк. Бу, үз чиратында, революция идеяләрен хуплап яшәгән Г. Ибраһимовның соңыннан хөкүмәт тарафыннан халык дошманы итеп игълан ителүе һәм кулга алынуы турындагы факт буларак укучыларда проблемалы сорау тууга китерергә тиеш була.

Г. Ибраһимовның күп тармаклы эшчәнлеге белән таныштыру максаты белән укучыларның алдан әзерләнгән «Г. Ибраһимов – укытучы», «Г. Ибраһимов – фән эшлеклесе», «Г. Ибраһимов – тарихчы» темаларына чыгышлары тыңлана ала.

Ахырда укучылар түбәндәге нәтиҗәгә киләләр: Г. Ибраһимов күп өлкәләрдә эшчәнлек күрсәтә: яшь буынны тәрбиләүгә зур көч куя, фән өлкәсендә, аерым алганда тел, әдәбият, тарих буенча хезмәтләр язып, аның үсешенә зур өлеш кертә, тәнкыйтьче буларак шул чор язучы иҗатларына объектив бәя бирергә тырыша.

Г. Ибраһимовның иҗаты белән таныштыру укытучының сөйләве яки укучыларның алдан әзерләнгән Г. Ибраһимовның өч иҗат чоры турындагы чыгышлар ясау рәвешендә башкарыла ала. Һәр чор иҗатына аерым тукталына.

Г. Ибраһимовның башлангыч (беренче) чор иҗатында яшьләр тормышы белән бәйле әсәрләрнең өстенлек итүен, моның яшь язучыны борчыган мәсьәләләр белән бәйле булуын билгелибез. Мисалга «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы», «Яшьлек хәятыннан бер ләүхә» әсәрләрен китерәбез. 1909 елда язылган «Татар хатыныниләр күрми» әсәрендә яшь хатын-кызның иреген кысрыклау проблемасы күтәрелеп, аның сәбәпләрен барлавы ачыклана.

Язучының романтик рухта язылган әсәрләрендә психологизмның, шуның белән бәйле рәвештә геройларның эчке, рухи халәтләренең ачып бирелүен күрсәтәбез. «Яз башы», «Диңгездә», «Сөю – сәгадәт» һ.б. әсәрләр геройларының кешенең рухи бәйсезлегендә чагылыш тапкан яшәү мәгънәсе турында уйлануларын күрсәтергә кирәк булачак. Бу чорда язылган әсәрләрнең сәнгатьчә эшләнешенә тукталып, язучының аларда эмоциональлекне, нечкә лиризмны күрсәтү, кеше күңеленең рухи халәтен, хис-тойгыларын ачып бирү осталыгын билгеләү сорала. Шулай ук бу әсәрләрнең күбесендә тирән фәлсәфә ятуын ассызыклап үтәргә кирәк.

Икенче чор иҗатын тәшкил иткән әсәрләрендә гади халык тормышына игътибар арту, иҗтимагый-сәяси вакыйгаларны сурәтләү өстенлек итүен билгелибез. «Карт ялчы», «Көтүчеләр», «Мәрхүмнең дәфтәреннән», «Табигать балалары» хикәяләренең, «Безнең көннәр» романының моның ачык мисалы булуы күрсәтелә. Күп кенә әсәрләрендә реалистик һәм романтик алымнарның синтезын билгеләп күрсәтәбез.

Г. Ибраһимовның Октябрь инкыйлабыннан соңгы иҗатын революцияне шатлык, куаныч хисләре белән каршы алу нәтиҗәсендә язылган әсәрләр тәшкил итүе күрсәтелә. Мисалга «Яңа кешеләр» драмасы, «Тирән тамырлар» романы, «Кызыл чәчәкләр» повестен китереп була. Шулай ук бу елларда иҗат ителгән «Казакъ кызы» романы, «Алмачуар» хикәясенең татар әдәбиятының иң яхшы үрнәкләре булуын билгеләп үтү сорала.

Язучының «Адәмнәр» исемле 1922 елгы ачлык вакыйгаларын сурәтләгән әсәренең натуралистик алым белән язылуын искәртү алдагы этапта бу алымның хасиятләрен ачыклауга юнәлеш бирә.

Соңгы әйтелгәннәр белән бәйле рәвештә, натуралистик сурәт турында төшенчә бирү, Г. Ибраһимовның «Зәки шәкернең мәдрәсәдән куылуы», «Татар хатыны ниләр күрми», «Адәмнәр» әсәрләренең натуралистик алым белән язылуын аңлату күздә тотыла.

Г. Ибраһимов иҗаты буенча белемнәрне ныгыту максаты белән укучылардан мөстәкыйль рәвештә, кроссворд чишү яки кластер төзетү отышлы.

Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романы өч дәрестә өйрәнелә. Беренче дәрестә максат итеп романда образлар системасын өйрәнү куела. Бу вакытта укучыларда шәхескә кагылышлы нәтиҗә буларак тормышта үз урыңны табарга омтылу хисенә төшенү, ирекле шәхес төшенчәсен аңлау формалаштырылырга тиеш була. Тема белән бәйле рәвештә дәрес башында эпиграф итеп Г. Ибраһимовның «Адәмнең эчке дөньясы, хәят юлында кичергәннәре аның йөзендә эз калдыра» дигән сүзләрен сайларга мөмкин. Әңгәмә барышында Г. Ибраһимов әлеге сүзләре белән безгә нәрсә әйтергә теләве, кеше яшәгән тирәлек аның яшәү рәвешенә, уйларына, хис-кичерешләренә, хыял-өметләренә, кешенең эчке дөньясы аның язмышына ни рәвешле тәэсир итүе ачыклана.

Укучыларның белемнәрен актуальләштереп язучының иҗат портретына штрихлар ясау башкарыла ала. Бу эшкә конкретлык кертү максаты

белән, аны язучы иҗатына кагылышлы 5–7 фактны билгеләтү рәвешендә дә үткәреп була. Шулай ук биредә әсәрнең язылу тарихы турында кыскача мәгълүмат бирү мөһим. Әсәрнең романтизм иҗат методы белән язылуын билгеләп, укучылар 1910 елда илдә милли азатлык хәрәкәтенең көчәюе нәтиҗәсендә һәм тормыш авырлыгыннан да язучылар матурлык эзләп үзләре хыялда тудырган икенче бер дөньяга мөрәҗәгать итү нәтиҗәсендә әдәбиятта романтизм иҗат методы барлыкка килүен билгелиләр. Алар романтик язучының тормыш-чынбарлыкны үзенең героеның күңеле, эчке дөньясы аша яңабаштан үзгәртеп тасвирлавын аңларга тиеш булалар.

Әсәрнең идеясен ачуда төп геройның әһәмияте зур икәнлеген искә төшереп, дәрестә аларга игътибар ителәчәге искәртелә һәм төп герой дип аталырга тиешле Җәләш мулла, Зыя, Мәрьям, Сабирларның һәркайсы турында аерым әңгәмә оештырып, аларны төрле яктан ачыклана, үзара мөнәсәбәтләрен, бу мөнәсәбәтләрдәге каршылыкларны аларның сәбәпләрен ачыла. Мохит, җәмгыять төшенчәләренә бергәләп аңлатма бирәбез. Әсәрдә мохит сүзенең еш кабатлануына игътибар иттереп, аңа салынган мәгънәне ачыклату сорала. Бу хакта дәреслектәге анализда шактый тулы язылган. Автор кешенең тумыштан (яратылышыннан) килгән таланты, мөмкинлекләре, эчке омтылышы, нәрсәгәдер ихтыяҗы була дип дәлилли. Бу Зыяның музыкага омтылышы аша ачыла. (Укучылар аның музыкага булган мөнәсәбәтен әсәр дәвамында билгеләп барып һәм фикерләрен шул өзекләр белән дәлилләрләр.) Аның язмышы аша талантның ачылуы, аның иясенә рухи канәгатьлек китерүе һәм башкаларга хезмәт итүе өчен тиешле җирлеккә-мохиткә эләгүе кирәк яки ул мохит тудырган каршылыкларны җимереп үзенә юл ярырга, үз-үзен расларга тиешлеген дәлилли. Зыяның омтылышлары мохит, шул чорның кануннары белән каршылыкка керә, артык хисчән, йомшак күңелле Зыяның бу карышлыкларны җимерерлек сәләте юк. Бу аның тормышын фаҗигагә китерә. Һәр фикерне әсәрдәге өзекләр белән дәлилләп бару кулай. Бу укучыларны текст белән эшләргә, тиешенчә игътибар белән укымаган укучыларга да әсәрне аңларга ярдәм итә. Соңыннан дәреслектә бирелгән анализның геройлар тормышына кагылышлы өлешен укып нәтиҗә ясала.

Образлар системасын билгеләү максатыннан, әсәрдәге геройларны төп, ярдәмче, аталып кына китүче геройларга аеру эше башкарыла. Төп образларга Җәләл мулла, Зыяны, Сабир, Мәрьям, ярдәмче образларга Гәрәй Мирза, Фатима бикә, Зөләйха абыстай; эпизодик образга – Зыяның сеңлесе; аталучы образларга – Җәләл мулланың кызы, ике улы, Зариф мулла, Ушаков, становой, аш хәзерләүче хатын, авыл кызлары, ике малай һ.б. кертелә. Бу материал схема яки таблица рәвешендә бирелеп, әсәр тексты тулысынча укылганнан соң өйдә тулыландырылырга кушыла ала.

Икенче дәрестә укучылар әсәрне укып бетереп килгән була. Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» әсәренең идея-проблематикасын анализлау күздә тотыла. Алар өчен һәр геройның язмышы ачыкланган. Нәтиҗәләр белән кыйксындырырга кирәк. Төп геройларга аерым игътибар итеп, ярдәмче геройларны да күздән кичерү турыдан-туры дәреснең бүгенге алып чыга. Ни өчен язмышлар шулай тәмамлана? Автор ни әйтергә тели? Әсәрдә нинди проблемалар күтәрелгән? Чишелештән чыгып әсәрнең идеясе нинди дигән сорауга ничек җавап бирергә?

Алдагы дәрестә сөйләшкәннәргә кире әйләнеп кайтып, геройларның максатлары аның мохит таләпләре белән ярашу ярашмавын ачыкларга

кирәк. Ни өчен ата һәм балалар арасындагы каршылык килеп туа? Ул ничек хәл ителә. Сабир-Зыя, Камилә-Мәрьям образларына чагыштырма бәя бирелә. Алар язмышындагы төрлелекнең сәбәпләрен ачыклау мөһим. Әсәрдә нинди проблемалар күтәрелә? Язучы аларны ничек хәл итә? кебек сорауларга җаваплар табыла. Әсәр проблемасының иҗтимагый, фәлсәфи яклары ачыклана. Әсәрнең идеясе ачыклауны күздә тоткан ярдәмче сорауларга җавап табыла. Укучылар, әсәрдә, гомумән, төп сюжет сызыгының Зыя образы белән бәйләнештә баруына игътибар иттереп, автор идеалының Зыя образында гәүдәләнешен мисаллар белән дәлиллиләр. Дәреслектәге анализның да тиешле өлешен укып нәтиҗә ясатырга кирәк.

Зыяның үлеме аның җиңелүе түгел. Ул калганнарга нәтиҗә ясау өчен этәргеч. Кешенең рухын басып, талантына төрле киртәләр корып, хыял канатларын сындырып, хисләренә богау салып кол хәлендә яшәргә, аерым кысалырда гына фикерләргә һәм гамәл кылырга мәҗбүр иткән җәмгыять үсешкә ирешә алмый. «Гомер буена мохит вә язмышның колы булганнар» бу үсешкә этәргеч бирә алмый.

Шулай итеп, укучылар әсәрдәге Зыя образына салынган идеяне аңлап, әсәрнең фәлсәфи тирәнлегенә төшенә алулары кирәк.

Өченче дәрестә Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» әсәренең сәнгатьчә эшләнеше карала. Максат итеп Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» әсәренең сәнгатьчә эшләнешен ачу һәм аның татар әдәбиятында роман жанры үсешендәге әһәмиятен билгеләү куела.

Кыска сораулар белән генә әсәрнең темасын (шәхес азатлыгы һәм милли азатлык), идея-проблемасы (мохит коллары иҗтимагый үсешкә этәргеч бирә алмый һ. б. пафосы (романтик, трагик) ачыклап кителә. Бу яктан караганда әсәр бик җитди. Ә әсәрне укыганда мондый ук катлаулылык сизелми, ул җиңел укыла. Беренче карашка сюжет Зыя һәм Мәрьямнең мәхәббәт тарихын хикәяләүгә нигезләнә кебек. Димәк, язучы төп фикерне укучыга кызыклы һәм үтемле итеп җиткерүнең алымнарын бик оста оештыра алган. Шуңа нигезләнеп әсәрнең сюжет һәм композициясен анализлап үтү сорала.

Әсәрдәге психологизмның бик зур әһәмияткә ия булуын мисаллар белән дәлилләтү кирәк. Төш күрү, хат, эчке монолог һ.б. чараларга аерым тукталырга мөмкин. Символик мәгънәгә ия образ детальләрне (бакча, скрипка, музыка, карт тирәк һ.б.) барлап, аларны мәгънәләрен ачуга ирешергә кирәк. Балалар үз фикерләрен әйтсеннәр, дәлилләсеннәр. Соңыннан гомуми бер фикергә килергә мөмкин. Әмма нәкъ бертөрле фикерләү, бер-берсен кабатлаудан качарга кирәк.

Шул рәвешле, югары сыйныфларда Г. Ибраһимов иҗаты белән таныштыру монографик төс алып, биографиянең өйрәнелә торган әсәр белән бәйләнешен чагылдыручы эзлекле рәвештә төзелгән дәресләр системасын тәшкил итә. Заманча белем бирү технологияләре, әдәбиятны өйрәнүдә кулланыла торган яңа ысул һәм алымнар укучыларның планлаштырылган нәтиҗәләргә ирешүләренә ярдәм итә.

ӘДӘБИЯТ

1. Ганиева Ф.Ә. Әдәбият. 10 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы. 2 кисәктә. 2 кисәк / Ф.Ә. Ганиева, Д.М. Абдуллина, Ч.Р. Рамазанова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. Б. 18–51.

2. Заһидуллина Д.Ф. Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. Яңадан эшләнгән һәм тулыландырылган басма. Казан: Мәгариф, 2004. 367 б.

# ХӨСНИ КӘРИМ – ТАТАР ЯЗУЧЫСЫ, ЖУРНАЛИСТ, ҖӘМӘГАТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ

***Абзалина Р.А.***

Хусни Карим – писатель, журналист, общественный деятель – друг Галимджана Ибрагимова. В публикации представлено стихотворное произведение Х. Карима, которое оказало благоприятное впечатление на Ибрагимова, и его автобиография, хранящаяся в фондах Национального музея РТ.

Husni Karim is a writer, journalist, public figure – a friend of Galimdzhan Ibragimov. The publication presents a poem by Karim, which had a favorable impression on Ibrahimov, and his autobiography, which is kept in the funds of the National Museum of the Republic of Tatarstan.

Ун ел элек 1913 елгы «Аң» журналларын карап утырганда күңелгә дулкын булып килеп кергән бер шигырьгә тап булган идем. Ул – Хөсни Кәримнең «Былбылга» дигән әсәре (автор аны «Зиләйлүк» көенә укырга кушкан).

Хөснетдин Минһаҗетдин улы Кәримов 1887 елның 15 декабрендә Башкортстанның шагыйрьләр бишеге – Дүртөйле районы Тумырҗа авылында туган. Быел аның тууына 130 ел. Бу мәкаләмне язуымның беренче сәбәбе дә Хөсни Кәримнең «Былбылга» дигән шигырен замандашларыма тәкъдим итеп, үземчә, юбилей елында шагыйрьне искә алу.

Икенчедән, Татарстан Милли музеенда Галимҗан Ибраһимовның Хөсни Кәримгә язган өч хаты саклана. Аларны һәм хатыны Зәйнәп белән бергә төшкән фотосын музейга 1958 елның 12 октябрендә Хөсни Кәрим үзе тапшырган.

Хатлар гарәп имласында, кара кара белән язылган. Аларны язучы А. Шамов, Галимҗан Ибраһимовның мирасын бөртекләп барлау максаты белән, 1957 елда «Совет әдәбияты» журналында бастырып чыгарган. Ә менә Галимҗан Ибраһимовның 9 томлыгының IX томында (2000) урын алган, Хөсни Кәрим тарафыннан 1913 ел, 26 октябрьдә язылган хатның (ЦМТР 120006-6[а]) төп нөсхәсе кая икәнлеге билгесез. «1914 ел, 13 майда язылганы – А. Шамовта саклана (ЦМТР 120006); 1914 ел, 12 апрелендә язылганы да аңарда» диелгән.

Язучы мирасының варисы Әлфия апа Шамова (Афзал Шамовның кызы) әтисенең архивын берәр мирасханәгә тапшырган очракта бу хатларның, яисә башка материалларның җеп очлары (ягъни музейда саклanулары) турында киң җәмәгатьчелеккә ирештерүне бурычым дип санадым.

Галимҗан Ибраһимов 1913 елның 18 октябреннән Әхмәтгәрәй Хәсәни тарафыннан «Аң» журналына җаваплы сәркатип итеп эшкә чакырыла: «Хөсни иптәш! Төрмәдән чыкканлы бирле сиңа хатлар яза алганым юк. Ачуланган булсаң, кичерә күр. Үзеңдә дә андый эшләр булгалый торгандыр әле».

«“Аң”ның секретарьлыгын алдым. Буны бәлки ишеткәнсендер дә. Яшь фикер, яшь куәт “Аң” тирәсенә җыелсын иде. Чын мәгънәсе илә әдәби вә мәдәни бер мәҗмуга шәкеленә керсен иде, дим. Синең “Волга” хакындагы мәкаләң миндә. Бәйрәм номерына кертә алмадым. Чөнки Шәһит теге шигыреңне бирде, аны баскач, “Волга” калды, чөнки бер номерда ике имза килешеп бетми», – ди ул үзенең 1913 ел 26 октябрендә язган хатында.

«Теге шигырь» дигәне – «Былбылга» шигыре. Ул «Аң» журналының 1913 ел, 21 нче санында басылып чыккан:

***«Былбылга»***

*Сайрамачы, былбыл, ник сайрыйсың?*
*Өзелә үзәк синең тавышка.*
*Сайрыйсыңмы син дә, минем кебек,*
*Түзалмыйча каты сагышка?*

*Калды мәллә ярың җаннан артык*
*Алларыңа куеп табынган?*
*Яна мәллә йөрәк сулкылдаган*
*Фирак утларына кабынган?*

*Ташладыңны мәңге ялган тормыш,*
*Кара йөрәк тулы җир йөзен?*
*Тынычмыни ялгыз зур урманда*
*Кан-яшь түгеп кичен-көндезен?*

*Сайрашыек бергә, таратыек*
*Йөрәктә оешып калган каннарны;*
*Санашыек башка килеп киткән,*
*Рәхәт үткән аз заманнарны.*

*Саклана күр, мәгъсум урман кошы,*
*Тавышың ишетелсә дә еракка,*
*Беленмәсен сереӊ залимнәргә –*
*Төшерерләр тимер тозакка!*

1912 ел (шигырьнеӊ бу варианты
Дүртөйле район газетасы «Хезмәт байрагы» ның
1957 елгы 25 сентябрь санынннан алынды).

1914 ел, 13 майда язылган хатында Г. Ибраһимов дусты – «Галия» мәдрәсәсендә укыган сабакташы Хөсни Кәримгә болай дип яза: «Мин ышанам, табигать сиңа бер нәрсә биргән. Гомереӊ вафа итсәӊ, син әдәбият галәменә бер әйбер, бик табигый һәм мөмтаз бер әйбер бирергә тиешсеӊ, мин моны хис кылам, ләкин хәзерге ватылган хәлдә улса, чыкмый, җан-тән хәл алсын. Куәт үзе бәреп чыгар…

Тагын әйтәм: җан-тән, нерв вә калеб хәл алсын – куәт үзе бәреп чыгар. Ул куәт нинди булыр, син даими язучы булып күп язып китәрсеӊме, әллә табигатьнеӊ сиңа куйганы – тик бер нәрсә бирерлекме, мин аны белә алмыйм. Ләкин шул бер нәрсә бирүеӊә, шул бер нәрсәнеӊ әдәбиятта ләзем бер мөһим әсәр булып калуына мин, никтер, катгыян ышанам. Еллар буена язмасаң да, бу ышануым кимеми…».

1950 елның 27 гыйнварында язган автобиографиясендә Хөсни Кәрим үзенеӊ тормышы хакында түбәндәге юлларны терки: «Я родился в 1887 году в бедной крестьянской семье, в деревне Таймурзино, бывшей Уфимской губернии, Бирского уезда, ныне Башкирии.

До 13 летнего возраста жил в семье отца, с 1900 года жил самостоятельно. Учился в Медресе. Чтобы найти средство на поддержание себя и продолжения учебы работал черно-рабочим, работал в ремонте Самаро-Златоустовской железной дороги; на мойке Суконной фабрики Акчуриных, на лесной пристани в г. Царицыно и на Лимонадном заводе Штейхера в г. Уфе.

В 1910 году стал изучать русский язык, но из-за отсутствия средств не мог поступить на стационарную учебу, а готовился на экстернат. После Великой Октябрьской Революции без отрыва от производства окончил

Уфимский Педагогический Институт и в 1932 году окончил Институт Совстроительства. С 1919 года член ВКП(б), до болезни (1933 г.) работал на руководящих работах в партийных и советских органах, большей частью по линии народного просвещения и печати. Одновременно занимался литературной деятельностью.

Мною написаны более 270 статей политического и общественного характера, по вопросам просвещения, художественно-литературного. Из художественной литературы издано отдельными книгами и брошюрами около 12-ти названий.

Редактировал журналы «Магариф», «Безнең юл». С 1933 года болею, являюсь персональным пенсионером. После болезни ещё до 1946 года работал, но уже на небольших, а под силу должностях по культпросветработе. С 1946 года совершенно не работаю в учреждениях, а занимаюсь систематизированием своих рукописей».

«Җан-тән хәл алган» вакытларында Г. Ибраһимов өмет иткән һәм «куәт бәреп чыгарган», «әдәбият галәменә бер әйбер»е кайсы булды икән? Хөсни Кәрим кулъязмаларын өйрәнүчеләрдән шушы сорауга җавап көтәбез.

## Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ «ТАТАР ХАТЫНЫ НИЛӘР КҮРМИ» ӘСӘРЕНДӘ ХАТЫН-КЫЗ АЗАТЛЫГЫ ҺӘМ СОЦИАЛЬ АСПЕКТЛАР

***Алеева Ә.Х.***

В статье рассматриваются социальные и художественные аспекты повести «Судьба татарки» Г. Ибрагимова. Анализируются два варианта этого произведения: первое – 1910 года издания и второе – заново переработанное автором в 1929 году. Устанавливается, что во втором варианте «Судьба татарки», в результате литературно-эстетических обобщений, автор кардинально меняет социальное звучание повести. Г. Ибрагимов в данном произведении не только затрагивает актуальную проблему в татарской литературе конца XIX – нач. XX века – социальную свободу женщины в обществе, но и рассматривает проблему судьбы нации через призму общечеловеческой философии.

The article examines social and artistic aspects of the novel «destiny of the Tatars» by G. Ibragimov. Analyzed two variants of this work: first issued in 1910 and the second – newly revised by the author in 1929. It is established that in the second version of «destiny of the Tatars», in literary and aesthetic generalizations, the author kordinalno changing social meaning of the novel. G. Ibragimov in this work not only focuses on the topical issue in the Tatar literature of the late 19th – early 20th centuries – the social freedom of women in society, but also considers the problem of the fate of the nation through the prism of human philosophy.

Күренекле язучы, Яңа татар әдәбиятына нигез салучыларның берсе, кабатланмас талант иясе Г. Ибраһимовның иҗади һәм сәяси эшчәнлеге социаль һәм иҗтимагый алмашынулар, инкыйлаблар чорына туры килә. Аның иҗаты татар халкының иң күркәм тр адицияләрен гомумкешелек мәдәниятенең алдынгы казанышлары белән янәшә куя, баета.

Билгеле булганча, «Татар хатыны ниләр күрми» әсәренең ике варианты бар. Бу әсәрнең эчтәлегенә тукталып тормастан, шуны гына әйтергә

кирәк: беренче варианты күләм ягыннан 80 битләр булса, икенче варианты исә 185 бит тирәсе. Сюжеты үзгәртелгән, әдәби алымнар белән баетылып киңәйтелгән. Аерымлыклар: Гөлбануның туган авылы – беренче вариантта – Күлбашы, икенче вариантта – Караюрга. Закирның авылы – беренче вариантта – Курайлы, икенче вариантта – Бикъяр. Гөлбануның сөйгән егете – беренче вариантта – Зыя, икенче вариантта – Лотфый; кайнатасы – беренче вариантта – Зариф карт, икенче вариантта – Шибай карт. Башка геройларның исемнәре үзгәрешсез, шулар ук калган. Ике вариантта да вакыйгалар төп герой Гөлбану тирәсендә, аның язмышына бәйләп гәүдәләндерелә, сюжет шулай үстерелә, әмма композиция яңача корыла, сюжет сызыгы киңәйтелеп, яңа материаллар өстәлә. Автор һәр ике варантында да XX гасыр башында татар халкының төп яшәеше булган авыл томышын-көнкүрешен, аның тарихын, менталитетын, сәяси-социаль ягын күрсәтеп, искиткеч оста каләм белән сәнгатьчә тасвирлый, татар милли гореф-гадәтләрен, этнографик байлыгын, социаль вакыйгаларны, татар хатын-кызларының авыр тормышын сурәтли. Әсәрдәге төп герой Гөлбануның шәхси язмышын иҗтимагый тормыш чоңгыллары аша уздырып күз алдына бастыра.

Г. Ибраһимов «Татар хатыны ниләр күрми» әсәренең беренче вариантын 1909 елда язып, 1910 елда бастырып чыгара [1]. Бу повесть (әмма шул чор әдәбият белеме кануннарына таянып, автор аның жанрын роман дип билгеләгән) әдип иҗатының романтик чорына караган әсәрләреннән берсе санала.

1929 елда әсәрнең төзәтелгән, өр-яңа сюжетка корылган, романтизм иҗат ысулының төп сыйфатларыннан азат, нигездә социалистик реализм дип аталган принципларга таянып язылган икенче варианты мәйданга чыга [2, б. 291–470]. Биредә инде Г. Ибраһимов Гөлбану образын романтикларча сурәтләүдән баш тартып, патриархальлек белән сугарылган, җенесләр арасындагы мөнәсәбәтләрне сыйфый-социаль күзлектән яктырта. Чөнки бу чор идеологиясе инкыйлабка кадәрге татар хатын-кызларының язмышын бәхетсез итеп сурәтләүне яклый.

Повестьнең беренче варианты төп герой Гөлбануның табигый асылына кайтуы, аның хатын-кыз икәнлеге ачылу белән төгәлләнә. 1929 елда язылган икенче вариантында исә Гөлбануның язмышы фаҗигале рәвештә суга батып үлүе белән тәмамлана.

Дөньяда яшәүнең мәгънәсе иҗат итү, көрәш дип таныган, бөтен гомерен шуңа багышлаган, көрәш казанында өзлексез кайнаган Г. Ибраһимов «...тормыш бер җирдә генә тормый, мәдәният, сәнгать үсә. Шуның белән бергә әдәбияткә булган таләпләр дә арта...» дигән фикердә була [3, б. 396]. Һәм инде матбугатта чыкканына егерме еллап вакыт үткәч, «Татар хатыны ниләр күрми» дигән беренче китабын яңадан эшләп чыгарга дигән уйга килә. Бу хакта аның тормыш иптәше Гөлсем Мөхәммәдова түбәндәгечә яза: «...үзенең әйтүе буенча, аның сәяси карашлары формалашуда, күп нәрсәгә күзе ачылуда роль уйнаган нәрсәләр – ...февраль һәм октябрь революцияләре. Шул вакыттагы көрәшнең эчендә кайнавы иде. Әлбәттә, бу фактлар аны үз иҗатын яңа баштан бәяләргә мәҗбүр иткәннәр. Бу – мәсьәләнең бер ягы булса, икенче ягы – еллар үткән саен, тәҗрибәсе арткан саен, язучының әдәби осталыгы үсә бара, ... чынбарлыкны киң, тирән, тулы, тормышчан, типик сурәттә күрсәтү ысулларын өйрәнә һәм язучы буларак үз-үзенә таләпләре дә арта бара. Шулар нәтиҗәсендә элек язылган кайбер әсәрләренең эчтәлеге аны канәгатьләндерми башлады. Тарихи хакыйкатьне социалистик

реализм методы белән ачып бирергә дигән карашта торып, бу әсәрләрне яңабаштан эшләп чыгарга кирәк тапты» [3, б. 399].

Г. Ибраһимов үзе исә «Татар хатыны ниләр күрми» повестен яңабаштан эшләвенең сәбәбен болай аңлата: «Әсәрнең төп каһарманы булган Гөлбануның авыр язмышы аркылы татар халкының революциягә кадәр тормышындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне тирән рәвештә ачып бирергә мөмкинлекләр бар. Бу мөмкинлекләр китапның беренче басмасында әрәм булып яталар. Биредәге Гөлбануның язмышы ул иске тормыш өчен типик түгел. Бу язмыш – гадәттән тыш бер вакыйга. Вакытында бу вакыйга Эстәрлетамакта булып үткән ... чын вакыйгага нигезләнеп язылган иде. Ул заманда бер яшь кызның авыр тормыш законнарына каршы курыкмыйча көрәшкә чыгып, үз язмышын үз кулына ала белүе мине бик мавыктырган иде. Бу хәл ул вакыттагы иҗтимагый мөнәсәбәтләр өчен табигый, типик бер вакыйгамы, юкмы – ул турыда уйланылмаган. Әмма язучы тормышны чынбарлыктагыча күрсәтергә теләсә, аның язган әсәрләрендәге вакыйгалар, персонажлар тормышның үзеннән мәҗбүри рәвештә туарга һәм тормышның иҗтимагый кануннарын ачып бирергә тиешләр. Ягъни бу вакыйгалар, бу персонажлар тасвирланган тормышның җимеше, үрнәге булырга тиешләр. Ә бу килеш Гөлбану патриархаль тормышның җимеше дә үрнәге дә була алмый...» [3, б. 401–402].

Билгеле булганча, XX йөз башы татар әдәбиятында хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсе актуаль проблемаларның берсе. Г. Ибраһимов «Татар хатыны ниләр күрми» повестенең ике вариантында да бу мәсьәләне үзенчә алымнар белән яктырта. Беренче вариантта автор хатын-кыз азатлыгы проблемасын Гөлбануның очраклы язмышын күрсәтү аркылы хәл итәргә омтыла. Ләкин әсәрдә сурәтләнгән вакыйга татар хатынының мондый аяныч хәлен китереп чыгарган социаль шартлар белән бәйләнми. Нәтиҗәдә хатын-кыз азатлыгы халыкның социаль азатлыгы проблемасына килеп тоташмый кала. Аның сюжетында моңарчы күрелмәгән, гадәттән тыш бер вакыйга гына тасвирлана. Г. Ибраһимовның иҗатын анализлаган галим М. Хәсәнов фикеренчә: «Татар хатыны ниләр күрми»нең беренче вариантының төп сыйфаты һәм әһәмиятле ягы: татар дөньясының төрле өлкәләрендә яшәп килгән патриархаль тәртипләргә каршы чыгу, шәхеснең җәмгыятьтәге хокукы өчен көрәшне күрсәтүдә. Әмма ул художество әсәре буларак югары түгел» [5, б. 18].

Вакытлар үткәч, язучының дөньяга карашы да үзгәрә. Ул беренче планга социаль тормыш шартларын куя, иҗатта сурәтләнгән күренеш-вакыйгалар тормыш шартлары белән тыгыз бәйлелектә булырга тиеш дигән принципны алга сөрә. Әдипнең «Татар хатыны ниләр күрми» әсәренә яңадан әйләнеп кайту сәбәпләренең берсе шуңа бәйле. Шушы принципка нигезләнеп автор повестьнең икенче вариантын – тирән әдәби-эстетик гомумиләштерүләр нәтиҗәсендә, идеясе, социаль яңгырашы ягыннан гаять көчле бер әсәр тудыра. «Мөхәррирдән» дигән кереш сүзендә әдип: «Бу... басмада хикәянең төп мәгънәсе, иҗтимагый нигезе элеккечә калды, әдәби материаллары белән композициясе бөтенләй яңадан эшләнде» [2, б. 292] дип искәртә. Беренче вариантны автор «роман» дип, ә икенче вариантны «хикәя» дип билгели. Әдәби үзенчәлекләре ягыннан караганда әсәр күбрәк повестька туры килә. Соңгы вариантның сюжетында исә башка бик күп татар хатын-кызларыннан аерылып торган язмыш күренми. Биредә татар хатынының шәхси язмышы тормышның иҗтимагый төзелеше белән тыгыз

бәйле. Җәмгыятьтәге социаль сәбәпләр хатын-кызның хокуксызлык статусын билгелиләр; татар хатынының типик язмышы – ул иренең бер хокуксыз колы. Гөлбану – үз-үзенә хуҗа түгел, аның язмышы ире кулында. Җәмгыятьтәге социаль законнар да, дин дә ир ягында. Аларның берсе дә хатын-кыз хокукын танымый. Г. Ибраһимов бу әсәрендә татар тормышындагы патриархаль караңгылыкны, татар хатынының авыр хәлен, фаҗигале язмышын, аны һәлакәткә дучар иткән социаль сәбәпләрне бөтен катлаулылыгы белән ачып бирә. Башка персонажлар да социаль типлар югарылыгында сурәтләнгән. Мәсьәләнең асылы татар крестьянының шәхси сыйфатларыннан бигрәк, шул тормышның иҗтимагый характерында, социаль нигезләрендә икәнлеге күрсәтелә. Әсәрдә социаль статус ягыннан конкрет образлар сурәтләнүе ике төрле социаль катлау крестьяннарның тормышы, дөньяга карашлары әхлак принциплары да капма-каршы булуын күрсәтә.

Әсәрнең ике вариантында да язучы сәнгатьчә тасвир алымнарыннан гаять оста файдалана. Табигать күренешләрен тасвирлау аша кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне сурәтли, табигать белән кешенең рухи халәте арасында охшашлык, уртаклык таба һәм шуның җирлегендә аның эчке дөньясын тирән ача, кеше психологиясенең нечкәлекләрен, геройның эчке кичерешләрен оста яктырта.

Әйтергә кирәк, беренче вариантта төп герой Гөлбануның вакыт ягыннан – балачагын, үсмер чагын, кияүгә чыгып, килен чагын колачлаган тормышы, чит-ят җирләрдә Габдулла булып яшәве сурәтләнгән. Икенче вариантта исә вакыйгалар туйга әзерләнү белән башланып китә. Гөлбануның балачагы бөтенләй сөйләнми, чөнки ул башкаларныкы кебек үк, типик дип кабул ителә. Калган вакыйгалар исә, тышкы тирәлек, табигатьне тасвирлау, геройлар бирелеше, ике вариантта да әллә ни үзгәрешләрсез сурәтләнгән, нәкъ шул заман татар тормышындагыча, халыкчан итеп тасвирланган.

«Татар хатыны ниләр күрми» повестендә Г. Ибраһимов хатын-кыз азатлыгы проблемасының социаль һәм милли азатлык мәсьәләсе белән тыгыз бәйләнгәнен күрсәтә. Хатын-кыз затына карата булган бу авыр газаплардан бары тик иҗтимагый вәзгыятьне үзгәртеп кенә котылырга мөмкин дигән фикер үткәрә.

Автор карашынча, кеше үзенең асылы, физик үзенчәлекләре, хисләре белән беренче чиратта – табигать баласы; бу яктан Гөлбану ике стихия эчендә калган: табигый һәм иҗтимагый. Алар арасындагы каршылык, гармония булмау – кешене фаҗигага, драмага китерә. Геройның табигате җәмгыять тәртипләре белән каршылыкка керә: ул гадел булмаган җәмгыять шартларында меңләгән татар хатыннары кебек яшәүдән баш тарта, җәмгыятьтә кабул ителгән тәртипләр, иске гореф-гадәтләр белән килешмичә, үз тормышын башка юлдан җибәрергә омтыла. Гөлбану туган йортыннан кача һәм ирләр кыяфәтендә ил гизеп йөри башлый. Нәтиҗәдә романтик ялгызак Гөлбану образы тудырыла. Шул ук вакытта язучы җенесләр арасындагы гармонияне бозып, аңа каршы барып бәхеткә ирешеп булмауны да күрсәтә. Ирләр киеме киенеп, Габдулла булып яшәү дә Гөлбануга тулы ирек һәм бәхет китерми.

Повестьнең ике вариантында да Гөлбану үз хәленнән риза түгел, ул хокуксызлыктан чыгу, котылу юлын эзли. Әсәрдә тасвирланган бер Гөлбану гына түгел, башка хатын-кызлар да рәхәт тормышта яшәми. Гөлбануның энисе Фәтхия дә ире Нурый карттан узып бер сүз дә әйтә алмый, ул аның җиденче хатыны. Нурый карт хатын-кызга рәхим-шәфкать күрсәтми, рән-

җетә. Гөлбануның җиңгәсе дә бәхетсез, баласы булмау сәбәпле ире икенче хатынга өйләнгәч, ул хезмәтче булып кала һ.б. Г. Ибраһимов татар хатын-кызларының авыр тормышын, хокуксызлыгын Гөлбану образында гомумиләштереп бирә.

«Татар хатыны ниләр күрми» повестенең романтик метод белән иҗат ителгән беренче вариантында кеше иреген буып торган җәмгыятькә каршы чыккан каһарман Гөлбануның, ягъни «шәхеснең югары күтәрелүе милләтнең, халыкның югары күтәрелүен аңлата... Татар милләтенең уянып килүче милли үзаңын гәүдәләндерә» [4, б. 71]. Икенче вариант язучының кешеләр арасындагы социаль мөнәсәбәтләргә мөрәҗәгать итүе белән әһәмиятле. Бу аның яңалыгы да. Биредә, кешене, шәхесне буып торган искелеккә каршы нәфрәт уяту, хатын-кызның шул җәмгыятьтәге аяныч хәле һәм котылгысыз халәте, чарасызлыгы, ниһаять, һәлакәте социаль шартларда икәнлеге ассызыклана. Димәк, әсәрнең ике вариантта хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсе төрлечә хәл ителә. Беренчесендә язучы хатын-кыз идеалын сурәтләсә, икенчесендә исә хатын-кыз язмышы яңа идеология кысаларында яктыртыла.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, «Татар хатыны ниләр күрми» әсәрендә иске тәртипләрнең шәхес иреген, ахыр чиктә, милләт иреген бууга китерүе аның үсешен тоткарлавы яктыртыла. Әдип бу әсәре белән XX йөз башы татар әдәбиятында хатын-кыз азатлыгы, милләт язмышы мәсьәләсен гомумкешелек фәлсәфәсе яссылыгында күтәрә.


ӘДӘБИЯТ

1. Ибраһимов Г. Татар хатыны ниләр күрми. Эстәрлетамак: «Нур», 1910. 141 б.

2. Ибраһимов Г. Татар хатыны ниләр күрми (өченче басма) // Галимҗан Ибраһимов әсәрләре. 7 томда. Казан: Яңалиф, 1929. 2 т. Б. 291–470.

3. Мөхәммәдова Г. Зур тормыш // Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлекләр-хатирәләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. Б. 346 – 412.

4. Нигъматуллина Ю. Национальное своеобразие эстетического идеала. Казань: КГУ, 1970. 210 с.

5. Хәсәнов М. Галимҗан Ибраһимов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. 331 б.


## НЕПРОЧИТАННЫЕ СТРАНИЦЫ БИОГРАФИИ ГАЛИМДЖАНА ИБРАГИМОВА


***Алишина Х.Ч.***



Сегодня имя Героя труда, татарского писателя и языковеда, издателя, государственного и общественного деятеля, одного из зачинателей современной татарской литературы Галимджана Гирфановича Ибрагимова с большим уважением вспоминают жители Сибири. Они рассказали о встречах с ним в Крыму в 20-х гг. XX века.

Nowadays, the inhabitants of Siberia remember Galimdzhan Girfanovich Ibragimov with great respect as the Hero of Labor, a Tatar writer and linguist, publisher, state and public figure, one of the pioneers of modern Tatar literature. They spoke about the meetings with him in the Crimea in the 1920s of the XX century.


В 2005 году начальник отдела по развитию языков народов РТ Аппарата Кабинета министров РТ, автор ряда монографий и научных статей по татарской песенной поэзии и проблемам национально-языковых отношений

Ким Мугаллимович Миннуллин, внесший большой вклад в реализацию Закона РТ «О языках народов Республики Татарстан», помог Тюменскому государственному университету издать в Казани книгу «Татары земли сибирской (Тюменская область): словник» [1]. Тираж книги безвозмездно был передан в Тюмень, подарен всем людям, чьи персоналии нашли в ней отражение. В частности, педагог, публицист Нелюфер Хафизовна Юсупова [1, с. 73] с большой благодарностью приняла казанский подарок и поделилась воспоминаниями о своем отце Х.К. Ибрагимове, имя которого также было внесено в словник [1, с. 29–30]. Ниже мы приводим фрагменты воспоминаний Н.Х. Юсуповой:

Хафиз Курбан-Галеевич Ибрагимов родился в 1894 г. в д. Чебурга (неоф. название Күкрэнде) Тобольского уезда Тобольской губернии в крестьянской семье. В автобиографии 1948 г. он пишет: по национальности «узбек-сарт», подчеркивая тем самым, что его предки в каком-то колене были «бухарцами». О своих родителях написал, что «они были лишены прав на землю и некоторых гражданских прав». Первоначальное образование получил в родной деревне, затем несколько лет обучался в медресе в д. Саусканы близ Тобольска. Известно, что в 1916 г. он вместе с двумя старшими братьями побывал на прифронтовых позиционных работах.

В 1917 г. Хафиз Ибрагимов уехал в г. Томск и поступил в учительскую семинарию, где готовили учителей начальных классов татарских школ. Там он познакомился с Мунзиром Исхаковым из Омской области (отцом Суфии Мунзировны Исхаковой, к.ф.н., доцента КГПИ). Они учились вместе, и Хафиз любил петь. Когда учился в Томской учительской семинарии (1919–1921), выступал со сцены с сольными номерами, принимал участие в татарских спектаклях, исполнял роль Халиля в музыкальной драме «Галиябану» Мирхайдара Файзи. И, видимо, тогда судьба свела его с гастролировавшим по Дальнему Востоку и Сибири (1918–1926) знаменитым баянистом Файзуллой Туишевым. Туишев пригласил Х. Ибрагимова в свою труппу в качестве солиста.

Хафиз Ибрагимов стоял у истоков ныне известного многим Тобольского татарского педагогического училища. Вот небольшой экскурс в его историю. Сначала оно действовало как мусульманское медресе в с. Ембаево Тюменской области, основанное купцом-меценатом Нигматуллой-хаджи и его братьями Хабибуллой-хаджи и Рахматуллой-хаджи Кармышаковыми. В 1919 г. было передано в распоряжение уездного комитета народного образования, а в 1920 г. было реорганизовано в 3-х годичные педагогические курсы при школе № 34 в д. Новые юрты под Тюменью. А с февраля 1922 г. начало функционировать уже в г. Тюмени как татарский педтехникум, которым руководил Абайдуллин (видимо, Шигап), преподавателями были назначены Гиззат Валиев, Гафур Сулейманов, Хафиз Ибрагимов. Располагалось учебное заведение в Тюмени на улице Ямской, 13. Хафиз Ибрагимов проработал там до 1925 г.

Затем он едет в г. Пермь для продолжения дальнейшего образования и поступает на биологический факультет Пермского университета. Одновременно работает учителем в школе переростков. Однако серьезно заболевает туберкулезом легких и в мае 1927 г., по совету и рекомендации академика Прянишникова, ему пришлось уехать в Крым. Там он проходит климатолечение, продолжал работать в крымскотатарской школе.

Будучи студентом Пермского университета, познакомился с местной девушкой Магафурой Насыровой. В 1931 г. они поженились, ему был 41 год, ей – 30. В Алуште в 1935 г. семья пополнилась дочерью Нелюфер, а в 1940 г. родился сын Наиль.

Хафиз Ибрагимов был разносторонне образованным интеллигентным человеком с передовыми взглядами (знавшие его люди отмечали незаурядный ум, большой талант исследователя, ученого, интересного собеседника), поэтому в Крыму у него вскоре появился круг общения с такими же просвещенными и видными людьми своего времени. Они вместе ходили на концерты, поэтические вечера и другие культурные мероприятия, слушали жившего в Алуште и творившего там писателя Сергеева-Ценского, Владимира Маяковского и других знаменитостей, посещавших Крым. Бывали и личные гости. Из далеких родных мест его посетил учитель-земляк Вагап Ахметов (отец к.ф.н., фольклориста Флоры Вагаповны Ахметовой), часто бывал друг и коллега, автор учебников по татарскому языку, бывший директор татарского педтехникума Тюмени Шигап Абайдуллин. Во время одного из его приездов в научную командировку на более длительный срок они ходили встречать сотрудника Египетского посольства Хади Абайдуллина. И затем они втроем посетили жившего тогда в соседней Ялте великого татарского писателя Галимджана Ибрагимова. Затем Хафиз Ибрагимов бывал его частым гостем. В тот приезд (1927–1928 гг.) они вчетвером – два Абайдуллина и два Ибрагимова (две пары однофамильцев) сфотографировались на память, но впереди был трагический 1937-й год, памятная фотография была уничтожена работниками НКВД. Несмотря на слабое здоровье, всегда стремящийся к знаниям, Х.К. Ибрагимов в 1936 г. заочно окончил Симферопольский пединститут.

Приезда Хафиза Ибрагимова всегда с нетерпением ждали на родине в д. Чебурга (Күкрәнде). Это был большой праздник для жителей села: к нему шли за советом и стар, и млад, к нему тянулась увлеченная знаниями молодежь, и несколько человек молодых людей ему удалось увезти с собой в Крым.

1937 год не обошел стороной их семью. Ибрагимова забрали по доносу, а через год мучений и пыток в Симферопольской тюрьме выпустили. Видимо, оставались еще испытания судьбы, которые предназначалось пройти. С началом Великой Отечественной войны в 1941 г. дочь с бабушкой эвакуировали в г. Пермь (тогда г. Молотов). Жене тоже было разрешено выехать из Крыма с малолетним сыном. И эта самоотверженная хрупкая женщина отправится в фашистский плен вслед за мужем, с годовалым ребенком на руках. Им посчастливилось-таки вернуться живыми из фашистского ада благодаря самоотверженности Магафуры Хасановны. Вернулись они из плена в мае 1946 г. в Пермь: год проработали на предприятиях Главснаблеса, а потом вернулись в родную Чебургу (Күкрәнде). В августе 1948 г. Хафиза Курманалиевича пригласили в РОНО и дали направление в Чебургинскую семилетнюю школу для работы учителем физики и математики. Осенью 1949 г. его не стало».

Отметим, книга «Татары земли сибирской», напечатанная в 2005 г., сослужила хорошую службу. Автору этих строк стали приходить многочисленные сообщения, фотографии, благодарности, письма с биографиями знаменитых людей. Собранный материал в дальнейшем необходимо обобщить,

систематизировать, ввести в научный оборот, издать энциклопедию татар Тюменской области. Хорошим подспорьем при этом станут изданные на татарском языке книги педагога-энтузиаста Люции Хабибуллиной «Туган як әдәбияты» (2002, 2015), «Себердә татар мәгарифе. XX гасыр» (2008).

В монографии «Себердә татар мәгарифе. XX гасыр» автор Л.Б. Хабибуллина, касаясь личности Ш. Абайдуллина, также упоминает имя Галимджана Гирфановича Ибрагимова [2, с. 7]:

«Шихабетдин Гиззетдинович Абайдуллин (1897–1938) родился в Новых юртах (Янавыл или Новые юрты сейчас входят в состав Тюмени). Окончил медресе «Галия» в Уфе. Работал завучем Тюменского педтехникума, который в 1925 г. был переведен в Свердловск. В течение 12 лет работал завучем, директором педтехникума в Свердловске. Он не только талантливый учитель, но и опытный методист, ученый. Разработал и напечатал учебники татарского языка, словари, читал лекции по татарскому языку и литературе не только в педтехникуме, на курсах повышения квалификации учителей, но и в высших учебных заведениях.

Ш.Г. Абайдуллин оставил глубокий след в истории татарского народного образования. Он был включен в комиссию по переходу на систему «Яналиф», опубликовал на эту тему ряд статей в местной свердловской газете «Социализм юлы». По приглашению Хатипа Усманова выступал с докладами в Казани на различных конференциях. В Казани он встречался с Мажитом Гафури, Галимджаном Ибрагимовым, познакомился с Хамитом Ярми, поэтом Хусаином Аминовым. А Хафиз Ибрагимов был его близким другом.

В целях завершения научно-педагогического произведения Ш.Г. Абайдуллин едет в Крым к жившему и работавшему там Х.К. Ибрагимову. Они вместе едут в Симферополь, работают там в богатейшей городской библиотеке. В один из дней встречают сотрудника Египетского посольства Хади Абайдуллина и едут к Галимджану Ибрагимову, который в 1933–34 гг. отдыхал и лечился в Ялте. Долго беседуют, фотографируются на память» (перевод наш. – *Х.А.*)

Глубокий знаток истории татарской литературы, опытный педагог, автор авторитетных изданий, лауреат премии РТ имени Каюма Насыйри Люция Бадретдиновна Хабибуллина далее пишет: «Мәктәп дәреслекләреннән классик әдәбиятыбыз вәкилләре – Галимҗан Ибраһимов, Кәрим Тинчурин, Фәтхи Бурнаш, Мөхәммәт Галәү, Җамал Вәлиди, Хәсән Туфан, Шамил Усманов кебек асыл затлар алып ташланды, әдәбиятыбыз бушап калды. Ун ел эчендә ике тапкыр әлифба алыштыру, татар мәктәпләрен ябу өстенә, намуслы, әхлаклы акыл ияләре – мәгърифәтчеләр юк ителде» [2, с. 19].

Завершая данную статью, в заключение выражаю искреннюю благодарность директору Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова доктору филологических наук, профессору, члену-корреспонденту Академии наук РТ, члену президиума Российского комитета тюркологов ОИФН РАН Киму Мугаллимовичу Миннуллину за оказанную помощь в издании книги «Татары земли сибирской» с очень ценным и дорогим для меня вступительным словом «Сохранив себя в веках», специально написанным действительным членом Академии наук РТ, заслуженным деятелем науки РФ и Республики Татарстан, лауреатом Государственной премии Татарстана в области науки и техники, почетным членом Турецкого

лингвистического общества, доктором филологических наук, профессором Дилярой Гарифовной Тумашевой.

ЛИТЕРАТУРА

1. Татары земли сибирской (Тюменская область) : словник / авт.-сост. Х.Ч. Алишина. Казань: Магариф, 2005. 80 с.

2. Хәбибуллина Л.Б. Себердә татар мәгарифе (XX гасыр) = Из истории народного образования Тюменской области в XX веке / науч. ред. Х.Ч. Алишина. Тюмень: Тюм. дом печати, 2008. 527 с. [на тат. яз.].

3. Хабибуллина Л.Б. Туган як әдәбияты = Литература родного края: учеб. пособие для учащихся 5–11 кл. на татар. яз. В 2 ч. / Л.Б. Хабибуллина; науч. ред. Х.Ч. Алишина. Тюмень: Изд-во ТюмГУ, 2002. 260 с.

4. Хәбибуллина Люция. Туган як әдәбияты = Литература родного края: учеб. пособие для учащихся 5–11 кл. на татар. яз. / под ред. Х.Ч. Алишиной. 2 изд. доп. и перераб. Тюмень: Типография «Печатник», 2015. 448 с.

## ТВОРЧЕСТВО Г. ИБРАГИМОВА В МЕЖЛИТЕРАТУРНОМ КОНТЕКСТЕ

***Аминева В.Р.***

На материале произведений Г. Ибрагимова и русских писателей 2-й половины XIX в. (прежде всего Ф.М. Достоевского и Л.Н. Толстого) устанавливаются виды диалогических отношений между текстами, принадлежащими разным национальным литературам: «“свое” как противопоставленное “чужому”» и «“свое” как переструктурированное “чужое”». Рассматривается логико-семантическая программа, концептуализирующая универсальную оппозицию «мир – человек» в романе Г. Ибрагимова «Молодые сердца». Выявляется специфика концепции драматического в прозе татарского писателя, противопоставленная динамической конфликтной модели характера, активности событийных и диалогических рядов в произведениях русских писателей второй половины XIX в. Анализируются принципы и приемы психологизма в рассказе Г. Ибрагимова «Угасший ад». Второй вид диалогических отношений осуществляет своеобразное взаимоналожение семантических полей «своего» и «чужого» художественно-эстетического опыта. «Чужая» словесная позиция, трансформируясь в «иную», становится одним из кодов в данной художественной системе, без знания которого невозможно ее адекватное восприятие и понимание.

The types of dialogical relations between the texts belonging to different national literatures are established in the article on the example of the literary works of G. Ibragimov and Russian writersof the second half of the XIX century (first of all L.N. Tolstoy and F.M. Dostoyevsky): «“self” is opposed to “other’s” and“self” as the restricted “alien”». Logical and semantic program conceptualizing universal opposition “world – human being” in G. Ibragimov's novel «Young hearts» is considered. The specific character of the drama concept in prose of the Tatar writer is revealed and contrasted to dynamic and conflict model of the character, activity of eventful and dialogical lines in the literary works of the Russian writers of the second half of the XIX century. The principles and methods of psychologism in the story «Extinct Hell» are analyzed. The second type of dialogical relationship consists in the overlap of the semantic fields of the two national culturesaesthetic experience. The «alien» verbal position being transformed into the «different» one becomes one of the codes in the given artistic system without knowledge of which its adequate perception and understanding is impossible.

Известно, что потребность самоопределения «я» среди «других» реализуется через различные виды отношений «своего» и «чужого». Из всего многообразия этих отношений между произведениями Г. Ибрагимова и русских писателей XIX в. наиболее значимы следующие их типы: «“свое”, противопоставленное “чужому”» и «“свое” как переструктурированное “чужое”». Они образуют диалогические системы, репрезентативность которых обеспечивается тем, что в них проявляются основные тенденции национального культурно-исторического развития, обнаруживается взаимодействие конвергентных и дивергентных механизмов межлитературного процесса. Противопоставляя себя «другому», литература выдвигает на первый план структурно-семантические комплексы и эстетические конструкции, в которых манифестируется ее уникальность и самобытность, причастность бытию «единственным и неповторимым образом» (М.М. Бахтин). Тип диалогических отношений, который определяется нами как «“свое”, противопоставленное “чужому”», устанавливается при сопоставлении логико-семантических отношений между субъектом и объектом, человеком и миром в произведениях Г. Ибрагимова и русских писателей XIX в.

Взаимоотношения человека и мира в произведениях русских писателей строятся на отрицании как сопоставимости, так и несопоставимости явлений, в чем находит выражение дихотомичность (И.П. Смирнов) русского мышления, не допускающего ничего промежуточного, плавного, смешанного. Так, в романах Ф.М. Достоевского имеет широкое распространение и исследуется во всевозможных вариациях психоэтическая структура «двух бездн» человеческой души. Смена одной позиции другой, их взаимопреход, борьба, отождествление, непрекращающееся колебание героев между альтернативными полюсами релятивизируют все внешне устойчивое, сложившееся и готовое.

В татарской прозе 1-ой трети XX в. модель мира создается иным типом отношений, означающим, что два явления несовместимы, существуют изолированно. Такой характер корреляции анализируемых семантических категорий и конститутивность его в качестве структурообразующего признака в татарской прозе исследуемого периода обусловлены социальными и историческими условиями рубежа веков: распадом прежнего уклада жизни, переоценкой существующих морально-этических норм. В татарской национальной культуре начинают действовать логико-семантические отношения, разрушающие состояние согласованности, непротиворечивости, неразрывности. Данная логико-смысловая программа концептуализирует универсальную оппозицию «мир – человек» в произведениях Г. Ибрагимова.

В романе «Молодые сердца» (1912) Г. Ибрагимов прослеживает процесс распада былого общественного единства, отрыва человека от среды в разных его качествах и стадиях. Как социальное существо человек выпадает из коллектива. Так, выбранная героем романа форма духовного творчества – музыка – эквивалентна социально-идеологическому новаторству. Но любовь к музыке толкает Зыю к таким формам поведения, которые нарушают социальную норму, и ставят его в положение преследуемого. Как член родоплеменного союза человек в этом мире бесконечно одинок. У него нет опоры ни в семье, ни в любви. Даже жизненные положения, которые с неизбежностью, онтологически конъюнктивны, например, вступление в брак, оказываются опасными, несут горе и страдания. Наконец, как личность он

отчуждается от своего «я», входит в противоречие с самим собой: Марьям дает согласие на брак с Фахри в состоянии нравственного затмения или самоотчуждения, интерпретируемом самой героиней как бессознательное, бредовое.

По линии причастности / отверженности развиваются и взаимоотношения человека и природы. Человек традиционно мыслится как микроэлемент природы, чутко откликающийся на любые токи, идущие от окружающего его космоса. Но в создаваемой картине мира принцип одновременного участия в общем порядке мира, причастности к нему не действует. Космический пейзаж в его безмерности, неизменности и вечности внеположен точечному существованию человека, инобытиен по отношению к его жизни. Подчеркивается его самодостаточность, замкнутое бытие, равнодушие и беспристрастное отношение к людям. Трагическая судьба героев романа, соотнесенная с общественно-исторической атмосферой времени, предстает как одно из проявлений всемирного кризиса цивилизации, достигшего той стадии, когда распадение первоначальной связи человека с обществом и природой приобретает катастрофический характер.

Процесс ломки вековых устоев национальной жизни разрывал естественные связи поколений, разъединял «отцов» и «детей», разделял единый национальный мир на отдельные социально-идеологические сферы. Герои, принадлежащие к молодому поколению, вынуждены были решать проблему самоопределения: подчиниться твердым, устоявшимся формам жизни, законам и традициям своей среды или обособиться от них, противостоять им, обрести духовную и нравственную независимость. Сыновья Джаляла-муллы Сабир и Зыя выбирают второй путь. Эти герои предельно противоположны и в то же время уравнены как стороны распавшегося целого. Сквозь индивидуальные и типические различия братьев просматриваются универсальные оппозиции реального и идеального, материального и духовного, разума и чувства. Принадлежность героев к двум полярным мирам: один из них обитает «здесь» – в реальном, земном мире, другой устремлен к идеалу, запредельному Абсолюту («там»), – обнаруживается в психологическом рисунке их характеров, в событийной линии романа, в мотивационной системе сюжета, наконец, в пространственных ракурсах произведения. Распад целостного существования человека проявился и в антитезе высокой духовной любви Зыи м Марьям, отношения которых заканчиваются катастрофой и дисгармонией, и обыкновенного семейного счастья, которое обретает Сабир.

В ситуацию выбора своего пути вовлечены все сколько-нибудь живые духовные силы нации. Отсюда напряженность и острота идеологических споров, возникающих между «отцами» и «детьми», шакирдами и муллами. В жизненной позиции второстепенных персонажей романа варьируются две противоположные «мировоззренческие установки»: разрыв с традициями, напряженная устремленность к новым жизненным принципам, переоценка ценностей – с одной стороны; и умение усвоить уроки жизни, принять факты и законы действительности, которые невозможно изменить, т.е. то, что прежде было неприемлемо, согласовать свою цель с обстоятельствами, идти по готовой, проложенной колее – с другой. Благодаря сюжетному параллелизму два противоположных типа поведения и мироотношения не производят впечатления просто индивидуального поиска, но выступают как

характерные приметы эпохи, сообщающие изображаемому конфликту широту, многозначность и историческую симптоматичность. Сходство сюжетных линий уравнивает исключительные и обыкновенные судьбы как варианты одних и тех же универсальных категорий, раскрывающих судьбу личности в современной общественно-исторической ситуации, соотношение устойчивого и изменчивого в человеческой жизни, преходящего и вечного.

Ситуация перехода от одной эпохи к другой, исторического обновления мира предстает таким его состоянием, как распад былого общественного единства, разрыв между природой и человеком, материей и духом, небом и землей и т.д. Г. Ибрагимов рисует кризисное состояние современного ему общества, социальных, нравственных, идейных его оснований, и тот раскол, разъединение, взаимное непонимание, которыми этот кризис сопровождается. Трагедия человеческой отъединенности обнаруживается им в пределах обширного смыслового репертуара. Столкновение различных жизненных систем, социально-идеологических позиций формирует конфликт как структуру, сочетающую в себе эпические и драматические начала.

Рост духовного самосознания личности и обострение ее противоречий со средой, обществом, миром предстает как закономерность современной жизни, определившая характер действия в произведениях этого периода, его напряженную динамику, насыщенность драматическими коллизиями, связанными между собой в целую систему. Но монологическая сосредоточенность героев на своих переживаниях, эмоциональном самосознании и самоопределении противопоставлена динамической конфликтной модели характера, активности событийных и диалогических рядов, определяющих специфику концепции драматического в произведениях русских писателей XIX в.

Тип диалогических отношений: «свое» как переконструированное «чужое», – актуализируется в историко-литературные ситуации, когда возникает необходимость пересмотреть привычный взгляд на мир, устоявшиеся правила и нормы, происходят поиски новых художественных средств и приемов; а также усиливаются контакты между национальными литературами. Это вид диалога, при котором «свое» видится с точки зрения «другого», в его системе оценок; вместе с тем раскрывается и культуротворческая, созидающая роль «чужого». Оно оказывается уже не совсем «чужим», но является «модуляцией» «своего».

Примечательно в этом плане функционирование традиций русской психологической прозы в татарской литературе 1-ой трети XX в. В ней получили развитие принципы и приемы психологического изображения, характерные для «диалектики души» – формы психологического анализа, нашедшей классическое выражение в творчестве Л.Н. Толстого. Ф. Амирхана, Г. Ибрагимова, Г. Исхаки, Ш. Камала, Г. Рахима и др. объединяет стремление понять внутренний мир человека в его противоречивой сложности, непрестанном изменении и борьбе противоположных начал. Новым ценностно-смысловым установкам соответствует глубокий аналитизм, исчерпывающее воссоздание и объяснение динамики душевной жизни человека.

В рассказе Г. Ибрагимова «Уты сүнгән җәһәннәм» («Угасший ад», 1911) человек изображается в двух измерениях: в его социально-исторической и психологической конкретности и в универсально-родовой сущности. Зафиксировав разрыв между внутренними потенциальными возможностями

человека и их реализацией, писатель ставит вопрос о духовном самоопределении личности, свободе и предопределенности ее судьбы, ответственности за свои поступки и выбор жизненного пути. Эти проблемы решаются целиком изнутри сознания персонажа, в его кругозоре и на его языке. В качестве основного элемента структуры образа выступает аналитическое объяснение и оценка характера героя. Художественной рационализации подвергаются просвечиваемые самосознанием потаенные глубины души.

Персонаж-рассказчик переживает тяжелую душевную драму, вспоминая юношеские мечты и сравнивая два периода своей жизни, которые разделяет девять лет. В прошлом он был одухотворен идеей общественного блага, думал о гражданском поприще, хотел служить народу, искреннее верил в то, что сможет найти достойное применение своим силам и способностям. В прошлом – жажда идеала, устремленность в область высших духовно-нравственных ценностей, готовность к подвигам и жертвам; в настоящем – томительное однообразие будней обыкновенного деревенского муллы, который ходит в гости, хоронит усопших, отпускает за приношения грехи. Юный пыл души, интенсивность внутренней жизни сменяются ощущением полной безнадежности, инертностью и апатией.

Духовный кризис, переживаемый героем, получает в рассказе глубокое философско-психологическое истолкование. Рассуждения Садыка о своей судьбе содержат разные варианты объяснения его драмы. Один из них указывает на действие универсального и таинственного закона жизни: «Хәятта һәрнәрсә акрын бара, сизелмәстән килә, – мин дә шулай булдым» [1, с. 128]. В жизни все происходит как-то постепенно, подкрадывается незаметно – так случилось и со мной» [2, с. 261]. Другой связывает духовную деградацию героя с «волнами житейского моря» – стихийным потоком бытия, волей судьбы, действием внешних роковых сил: «Тоткасыннан тотып, ишекне уңга да, сулга да борган кебек, үзем теләгән якка борырга уйлаган хаят куәтле дулкыны илә элеп алган да, диңгезгә ташланган бер җомычка рәвешендә уйнатып йөртеп, ниһаять, караңгы бер авылга, томан эченә китереп ташлаган, шунда мулла ясаган» [1, с. 128]. «Волны житейского моря, под ударами которых я надеялся выстоять, подхватили меня, закружили в водовороте, как щепку, и в конце концов бросили в темную, невежественную деревню» [2, с. 261]. В произошедшей с Садыком перемене можно обвинять и повседневный быт, среду, обстоятельства. К числу факторов, детерминирующих падение героя можно отнести и характер современной исторической ситуации. Садык ясно понимает обреченность каких бы то ни было надежд и упований, не видит перспективы духовного исцеления, поэтому будущее представляется ему как фатальное движение к неотвратимому концу – духовному омертвению и физической смерти.

И все же, с точки зрения героя, главная причина его жизненной катастрофы – в нем самом, в свойствах его натуры. Садык признается себе, что оказался человеком мягким и слабым, подверженным чужим влияниям, не нашел в себе силы, чтобы бороться, идти против течения. Возникают мотивы вины героя за утрату высоких ценностей, которыми он обладал, измены юношеским идеалам. Жизненный опыт старого приятеля Гильмана Кахирова, с которым Садык учился в медресе, наглядно убеждает его в том, что в конечном счете все зависит от самого человека, от его выбора, нравственной стойкости, верности своей мечте. Гильман Кахиров, когда-то

бывший бедным и голодным шакирдом-сиротой, которого все обижали и никто не любил, преобразился до неузнаваемости. Пройдя через испытания, различные жизненные перипетии (бежал из медресе с паломниками-казахами, учился в Стамбуле, вернувшись в Россию, учительствовал и т.д.), он достигает внутренней свободы и независимости, обнаруживает способность к духовному росту. Итак, личность может противостоять и преодолевать влияние обстоятельств. Но самообличения героя – это и свидетельство глубины его натуры. Они вызваны требовательностью к себе, внутренней честностью.

Кардинальная особенность реалистической характерологии, проявившаяся в произведении – многогранная и разнокачественная обусловленность поведения и судьбы героя – сближает используемые Г. Ибрагимовым принципы художественного освоения действительности с творческим методом русских писателей XIX в. Но в рассказе «Угасший ад» не показано взаимодействие внутренних сил человеческой души с внешним миром. Разномасштабные и несоизмеримые детерминанты объединяются лишь в поле сознания субъекта речи – героя-рассказчика, отражают сложный и противоречивый процесс самопознания. Это существенно расширяет возможности психологического изображения. Главным средством раскрытия характера является исповедальный самоанализ героя, что оправдывает прямое проникновение в содержание его переживаний, выявление их скрытой сущности.

Душевное состояние воссоздается в его психологической объемности, в эмоционально-чувственных и интеллектуальных проявлениях. Потрясение, вызванное встречей с Гильманом Кахировым, взрывает медленно и плавно текущую жизнь муллы. В потрясении этом – боль и ужас, растерянность и смятение. Сложные сплетения чувств проступают в вопросах, нервном и страстном движении интонации, повторах и эмоциональных контрастах. Проснувшаяся мысль срывает умиротворяющую завесу, долгое время застилающую взор, и взмывает на вершину некоей высшей истины, с позиций которой все обретает новый смысл, – наступает прозрение. Мысль усиливает страдания. Разрушение душевной цельности персонажа приводит к резкой драматизации психологического процесса.

Духовное пробуждение героя выводит его за пределы сложившегося социально-бытового уклада жизни, обыденного существования, освобождает от ограниченности и косности, возвышает над окружающим миром. Этот взлет духа, требующий максимальной концентрации внутренней энергии, способность к самопознанию указывают на истинный масштаб личности героя, не соответствующий его внешнему бытию. Перед нами не только «психологическая драма падения, исповедь духовно погибшего» [3, с. 114], но и момент интенсивного самопознания и самоуглубления, самоотверженный, обжигающий своей непосредственностью и искренностью отчет перед собственной совестью, демонстрирующий умение мужественно, без страха и обольщений смотреть в лицо действительности. Автор утверждает суверенность и самоценность духовной жизни личности, постигающей всю глубину своего падения, открывающей в себе все самое сокровенное и настойчиво пытающейся дойти до самой последней степени ясности. В пределах мгновения, выхваченного из потока времени, одного душевного состояния, ставшего этапом в духовной биографии героя, он обретает свое подлинное «я», трансцендентное наличному бытию. Значительность персонажа как

психологического типа заключается в редком даре – обнажить заповедные тайники собственного внутреннего мира и выработать новую точку зрения на себя и обстоятельства своей жизни. Эта возможность для героя нового видения действительности определяет доминирующую роль форм, непосредственно изображающих его внутреннюю жизнь.

Представленный уровень самосознания позволяет перейти к размышлениям о законах природы и о сути человеческой личности. За конкретно-историческими мотивировками открывается универсальный план осмысления изображаемого. Интеллелектуально-духовное переживание и познание включается в контекст бесконечного природно-космического процесса. В темной уединенной комнате большого дома Садык садится у окна и вглядывается в плотную, тревожную темень сада, окруженного тишиной ночи. В одиночестве, отрешившись от земной суеты, он погружается в думы, прислушиваясь к самому себе, к голосу своей души. Это состояние обрамляет ночной пейзаж, размыкающий сознание героя вовне, навстречу природным стихиям.

Движение жизненного потока воплощается в убаюкивающем шепоте ночного дождя, в котором улавливается некий ритм, дающий ощущение равновесия и покоя, отрешения от мук и тревог. Моросящий дождь вследствие своей «нескончаемости» выводит из земного времени в вечность, погружает в глубины бессознательного. Прислушиваясь к этой «музыке» ночного бытия, в которой звучит голос вечности, рассказчик устремляется к неведомому и запредельному. В такие ночи герой находит заветную цель, которая позволяет оторваться от внешней действительности и возвышает над ее законами. Сознание субъекта речи выражено в смысловой слитности природных образов и созерцательно-медитативного состояния, совмещенного с обобщенной рефлексией.

Трагическая энергия пережитого потрясения разрушает установившееся созвучие явлений человеческого и природного миров, согласие между макро- и микрокосмом. Природа, размеренная и прекрасная в своей гармонии и ритме, в инстинктивной целесообразности и самодостаточности всего происходящего, – основная данность мира, которая расстилается перед человеком как спасительный цикл смены дня и ночи, света и тьмы, времен года и т.д. Утро и вечер, заход и восход, день и ночь находятся между собой в состоянии равновесия, взаимодополняя и гармонизируя друг друга. Чередование возникновения и исчезновения, рождения и умирания, распада и становления воспроизводит замкнутый круг вечного возвращения к одному и тому же, круговорот космических и земных метаморфоз. Нарушение космического равновесия – временное и транзитивное состояние, которое сменяется восстановлением исходного порядка. Но непрерывному обновлению мира противостоит быстротечность жизни человека, необратимость происходящих с ним изменений. Если в природе и в мироздании объединены начало и конец, рождение и умирание, бытие и небытие, то в микрокосме индивидуального существования цикличность замещается линейностью.

Расхождение между временными эпохами мира и человека, вселенским и индивидуально-личным бытием усиливается вносимой в описание душевного состояния героя психологической конкретикой. В качестве средства индивидуализации переживания выступает сравнение своего

душевного опыта с признанием поэта: «Караңгы һәм дә таңы ерак, – / Уты сүнгән җәһәннәм минем төн» [1, с. 130]. «Моя жизнь – угасший ад, / Она мрачна, зари не видно» [2, с. 262]. Субъективно-личное начало проявляется в трагически безысходной думе о себе, в ощущении неустранимых преград, фатального жизненного тупика: «Шагыйрь үзенең төнен “таңы ерак” ди. Димәк, ниһаясез түгел, качан да булса бер таң ата; димәк, алда бер өмит бар. Әмма миндә алай түгел; гомерем, кояшын, язын югалтып, кара төнгә әйләнгән дә, ул төннең таңы ерак кына түгел, бер дә юк; ул төн мәңге, мәңге» [1, с. 130]. «Поэт жалуется, что “зари не видно”. Для него когда-нибудь заря все же наступит, значит, есть надежда. У меня ее нет. Моя жизнь лишена света и весны, она превратилась в ночь. И нет ей ни конца, ни края – моя ночь беспредельна» [2, с. 262].

Слово рассказчика идет по горячим следам душевного момента, вбирая в себя всю его экспрессию, и в то же время внедряется в будущее, укрупняя очертания данной ситуации. Этой раздвигающейся временной перспективе соответствует нарастание эмоциональной напряженности. Чувства отчаяния, обреченности, смятения, боли, сотрясающие душу, расширяют свои границы, перерастая во всеобъемлющую реакцию на мир. Временной сдвиг – перевоплощение настоящего в будущее, воссоздание будущего как настоящего – обладает экспрессивной остротой и в то же время выглядит завершающим этапом в развитии мысли. Итог размышлений о себе звучит как безысходная и всеохватывающая истина, отметающая какую бы то ни было надежду. Переживания, исполненные драматической энергии, порождены не только реальными невзгодами судьбы, но и ее роковыми и грозными стихиями, пробуждающими ассоциации с запредельным. Сравнение жизни с угасшим адом, своих переживаний с адскими муками, будучи очень выразительным, указывает не только на силу страданий, ведущих к полной диссоциации и деперсонификации, но и на поглощение человека антимиром бытийствующего зла, «инобытие» на этом свете.

Самоанализ субъекта высказывания представляет собой скорбное и мужественное погружение в трагедию, которое открывает в глубинах индивидуального, сокровенно-интимного общее, универсальное. Обобщающая направленность психологического анализа связана с использованием для выражения эмоций языка символически осмысленной внешней реальности. Соизмеримость двух планов: частного, единичного и универсального, – обнаруживается в диффузности микро- и макрокосма. Окружающее человека космическое целое не просто воздействует на него. Борьба света и тьмы в мироздании приобретает для героя экзистенциальную значимость. Гроза «проникает» в сферу микрокосма личности и сообщает ей пророческую ясность видения. Рассказчик шаг за шагом двигается к все более глубокому образному постижению скрытого смысла событий, произошедших в его жизни, и своей собственной участи. Вспышка молнии, раскат грома и последовавшее за этим падение в бездну обретают символическую смысловую перспективу: гроза – это и природная стихия, и деталь, усугубляющая драматическую атмосферу эпизода, и образ, передающий ощущение неустроенности и катастрофичности бытия в мире, и символ угрозы, нависшей над героем, и предвестие его гибели. Проекция пережитого героем потрясения на природно-космический фон укрупняет масштабы его судьбы.

Рассказ героя о себе обладает исчерпанностью объяснений и мотивировок, придающих повествованию драматизм и напряженность. Но вместе с тем проиллюстрированная «история» души хранит в себе некую загадку – тайну самого человека. Аналитические формы психологизма используются для создания типического характера – воплощения определенной, исторически и социально детерминированной психологии. Но вся словесно-речевая система, процесс сознания, пути осмысления человеком его собственного душевного опыта выявляют в нем неповторимо-личное, индивидуальное начало.

Аналитизм, имеющий по преимуществу рационалистическую основу, взаимодействует с синтетическими методами раскрытия внутреннего мира человека: обобщенно-целостным изображением основных стадией духовного пути; кратким «суммарным» обозначением эмоциональных состояний (смятение, тревога, ужас, др.); с хронотопическими способами психологизма (душевную драму героя репрезентируют оппозиции верха и низа, дня и ночи, прошлого и будущего, высоты и глубины); обращением к пейзажу для передачи переживаний, настроений персонажа и специфики его восприятия мира, образам и мотивам, имеющим символический подтекст (гроза, молнии, гром, дождь, солнце, соловей, др.), лейтмотивным психологическим характеристикам (устремленность в небеса, падение в бездну, пробуждение, гибель души). С помощью разных типов психологизма писатель высвечивает в образе героя «метафизическую» основу, связанную с онтологическими проблемами человеческого существования, трагедией утраты смысла жизни.

Рефлектирующие герои Г. Ибрагимова (рассказы «Любовь – счастье», «На море», «Угасший ад») в таких своих качествах, как готовность размышлять о философских основаниях мира, смысле индивидуального существования, способность к самоанализу и самопознанию, умение давать нравственную оценку ситуации и своим душевным движениям, поступкам, преобладание центростремительного начала, порождающего богатство интеллектуальной и эмоциональной жизни и др., близки персонажам Лермонтова, Тургенева, Гончарова, Толстого, Достоевского и акцентируют в них устойчивые, повторяющиеся, «архетипические» черты. Раскрывая трагические противоречия жизни и сознания людей, татарский прозаик использует разработанные русскими писателями способы и приемы психологического изображения: рационализацию психологического процесса, представляющую внутренний мир человека через его самоанализ и самораскрытие; воспроизведение потока душевной жизни, тяготеющее к исповедальности; изображение миросозерцательных реакций на действительность как формы нравственно-философских исканий, движения мыслей и чувств, эмоциональных состояний, моментов самоуглубления и самопознания, рождающих новое отношение к миру, и т.д.

Рассмотренный вид диалогических отношений осуществляет своеобразное взаимоналожение семантических полей «своего» и «чужого» художественно-эстетического опыта. «Чужая» словесная позиция, трансформируясь в «иную», становится одним из кодов в данной художественной системе, без знания которого невозможно ее адекватное восприятие и понимание. Чужая / иная словесная практика выступает как план выражения для нового содержания – внутреннего мира человека, принадлежащего иному типу культуры. Возникающие при этом добавочные ассоциации

увеличивают семантическую емкость «исходных», осваиваемых моделей и структур. Контекст иной литературы раскрывает их архетипичность, способность порождать новые смыслы.

Итак, в основе межлитературных диалогов лежит «нераздельность и неслиянность» «Я» и «Другого». Между ними устанавливаются эстетические отношения взаимоотражения и взаимоосвещения. Две ценностно-смысловые системы взаимодействуют друг с другом: контрастируют между собой, творчески усваивают «чужой» опыт, выстраивают семантически родственные высказывания о мире и т.п., – образуя различные виды корреляций, которые служат для подчеркивания схожести или маркирования отличий. В «точке» диалогического контакта текстов, принадлежащих разным национальным литературам, рождается смысл, который требует не формально-логической и содержательной трактовок, актуализирующих его внутреннюю неоднородность, но функционального толкования, раскрывающего его роль в формировании целеустановки, характеризующей сопоставляемые тексты. Она может быть сходной («“свое” как переструктурированное “чужое”») или различной («“свое”, противопоставленное “чужому”»).

ЛИТЕРАТУРА:

1. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. 1 т. 512 б.
2. Ибрагимов Г. Красные цветы. Роман, повесть, рассказы. Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. 336 с.
3. Халит Г. Портреты и проблемы. Избранные статьи разных лет / Г. Халит. Казань: Татар. кн. изд-во, 1985. 344 с.

## ОСОБЕННОСТИ ИЗОБРАЖЕНИЯ ДЕРЕВНИ В ПОВЕСТИ «АДӘМНӘР» («ЛЮДИ») Г. ИБРАГИМОВА

***Ахметова М.А.***

Статья посвящена рассмотрению художественного принципа «сборности» изображения в повести Г. Ибрагимова «Люди», реализованной Н. Гоголем в комедии «Ревизор», но с противоположными художественными задачами. Г. Ибрагимов отображает страшные картины голода начала 20-х гг. XX в., выражает глубины трагедии пережитого тогда народом бедствия. Анализируются различные смысловые уровни заглавия повести, стиль и её язык, хронотоп, изображение пейзажа и условные формы изображения.

The article is devoted to consideration of the art principle of «sbornost» of the image in G. Ibragimov’s story «Адәмнәр» («People») implemented by N. Gogol in the comedy «Auditor», but with opposite art tasks. G. Ibragimov’s village describes not only generality of the image of terrible pictures of hunger of the beginning of the 20th of the 20th century, but also expresses depths of the tragedy endured then by the people. Various semantic levels of the title of the story, style and its language, a chronotope, the image of a landscape and conditional forms of the image are analyzed.

В изображении деревни в повести «Адәмнәр» («Люди») Г. Ибрагимов использует художественный принцип изображения, реализованный Н. Гоголем в комедии «Ревизор», в котором город задуман как некий «сборный» город, «целостность и округленность» которого «сочетались с его полной

однородностью с теми обширными пространствами, которые лежали за «городской чертой», является «сборным, предельно обобщённой единицей обобщения» [2, с. 24]. Деревня Г. Ибрагимова – тоже «сборная», но делает он её такой в связи с прямо противоположными Гоголю художественными задачами: не для достижения комического эффекта, а с целью предельно обобщённого изображения страшных картин голода начала 20-х гг. XX в., более полного выражения глубины трагедии, пережитого тогда народом.

Символично заглавие, обнаруживающее в течение повести различные свои смысловые уровни. Один из уровней: быть человеком – значит, сохранять способность к идентификации, «узнаванию» себе подобных. Наиболее ярко это выражается в сцене встречи Гарая с Намаджаном возле остатка недоеденного псом трупа старика Галима, которая даёт нам понять, что голод довел людей до того, что они были не в состоянии признавать себе подобных. Обессиленный, со впалыми щеками, со стянутыми от голода губами, своей внешностью напоминающий, скорее, покойника, нежели живого человека, Гарай, не поздоровавшись и не поприветствовав Намаджана, с удивлением смотрел то на него, то на кровавые куски трупа, раскиданные собакой по белому снегу: «Гарай, неужели ты не в состоянии человека признать?» (Перевод наш. – *М.А.*) [1, с. 288].

Другой уровень: быть человеком – быть способным к проявлению естественных человеческих чувств, сострадания. Многих же персонажей, как мы видим в повести, голод приводит к тому, что у них нет сил не только достойно похоронить умерших, но даже пожалеть хотя бы самых близких, как, например, у Гарая, потерявшего жену: «Сошлись они по любви. И на самом деле, прожили в любви и согласии. Жена родила ему здоровых и крепких, как наливное яблоко, детей. И жизнь строили вместе, совместным трудом. Только нет теперь уже рядом Сатиры. И не вернуть ее никогда. Нет той, которая бы поддержала мужа в тяжелые минуты… Но Гарай не мог об этом думать. Жалкие крохи еды, которые он вчера съел, вновь запустили в его сердце машину, которая скреблась изнутри когтями. Сто, нет, тысяча этих когтей, казалось, что-то выскребают, отнимают остатки сил из сердца и всего его тела, существа. И смерть Сатиры смешалась со всеми этими ощущениями» (Перевод наш. – *М.А.*) [1, с. 303–304].

Следующий уровень: быть человеком – это жить согласно с законами человеческого общежития, а не так, как в повести: «Объяснения в любви, никах-свадьба, подарки, гости, застолье, поздравления – все это осталось в прошлом. Такие вещи давно были забыты» (Перевод наш. – *М.А.*) [1, с. 311–312].

Далее: быть человеком – сохранять способность различать жизнь и смерть. Утратой этого можно, например, объяснить тот факт, почему зять Гарая Минлебай «по ошибке» был признан мёртвым и помещен в клеть вместе с покойниками.

Наконец, быть человеком – значит, самоидентифицироваться, сохранять человеческий облик, сохранять себя самого и своих близких. А если всё собрать воедино, то окажется, что по Г. Ибрагимову быть человеком – значит, сохранять память: о том, что ты человек и живёшь среди себе подобных – со всеми вытекающими отсюда правами и обязанностями.

Утрата людьми человеческого облика наглядно представлена в портретах персонажей. Особую боль вызывают описания голодающих детей: «Дети лежали обессиленные. Они старели не по месяцам, а по дням и по

часам. Руки стали тонкими, как тростинки. Ребра выпирали, словно щепки. Шеи, толщиной с запястье, стали некрасиво удлиняться... Даже у Зайни, который никогда не болел, начали гнить десны, выпали все зубы и волосы. У восьмилетней красавицы Нафисы похудело и стянулось круглое личико. Маленькие косточки выпирали каждая по отдельности, кожа обвисла, покрылась морщинами, и она выглядела как маленькая 70-летняя старушка. Сейчас они даже не плачут, выпрашивая еду. Если есть – поглощают еду, если нет – продолжают лежать в том же обессиленном состоянии» (Перевод наш. – *М.А.*) [1, с. 312]. Но словно не желая верить в полную утрату людьми человеческого облика, автор всё-таки даже такую страшную повесть называет «Адәмнәр» и по ходу повести к обозначению сельчан применяет это слово – причём именно в ключевых, узловых моментах сюжета, сигнализируя о них и словно напоминая людям об их человеческой сущности, как, например, в главе 7. Или в главе 9, связанной со сценой грабежа Намаджана, где показано, как Намаджан использует ситуацию голода в удовлетворении своих потребностей, в том числе самых низменных, связанных, например, с Марьям. Любопытно, что по отношению к наживающемуся на чужом голоде Намаджану Г. Ибрагимов совершенно не применяет заглавного понятия, давая понять тем самым, что существо, само, а не по воле непреодолимых обстоятельств, лишающее себя человеческой сущности, не достойно называться человеком.

История Марьям тоже работает на реализацию центральной художественной установки повести – создания образа «сборной» деревни. Трагическая история Марьям в повести Г. Ибрагимова не единична и не исключительна, доказательством чего служит несложившаяся судьба соседки семьи Гарая – Фатимы, которую продали за пятнадцать фунтов муки.

Изображённое Г. Ибрагимовым отличается предельной типизацией – от того, что явления, здесь воспроизведённые, были повсеместны на том пространстве России, которое постиг повальный голод. Типизация нужна Г. Ибрагимову не только для достижения предельной обобщённости изображения, а чтобы сказать всю правду о творящемся в Поволжье.

Деревня здесь – хронотоп, художественное «времяпространство» (М. Бахтин), где царствует Смерть, заполнившая его полностью, практически вытеснившая малейшие проявления жизни: «Все вокруг поглотила темная смерть» [1, с. 287]. Смерть предстаёт как некая всеобъемлющая космическая «тёмная» материя, пожирающая людей и всё живое на этом пространстве художественной «вселенной» Г. Ибрагимова. Пространством смерти, например, предстаёт в повести даже обычная клеть – кладовая при избе, по определению предназначенная для хранения в ней предметов хозяйственных нужд, но используемая обитателями ибрагимовской деревни для складывания сюда покойников.

Это настоящий мир мёртвых («үлекләр дөньясы»), изображению которого позавидовали бы создатели фильмов ужасов. Образы «живых» трупов населяют его. Границы между живыми и мёртвыми практически стёрты. Поэтому нет ничего удивительного, к примеру, в том, что Минлебая по ошибке считают мёртвым и отправляют в ту же клеть, где лежат трупы. И вполне естественно, что по отношению к доходягам Г. Ибрагимов употребляет оксюморон в духе того же Гоголя («мёртвые души»), но в другом порядке слов – «җанлы мәетләр» («живые мертвецы») [1, с. 324]. Правда,

живыми они становятся тогда, когда в них вселяется надежда о спасении, связанная с вестью о том, что в деревню идут обозы с хлебом. Но даже теперь в сельчанах, от неимоверного голода нападающих на этот обоз, трудно узнать людей. Это лишь тени («күләгәләр») бывших людей.

В создании художественного пространства автор опирается на принцип психологического параллелизма, издавна используемый в произведениях фольклора и в мифологии: ибрагимовский пейзаж призван не только передать беспросветный мрак происходящего, но и выразить состояние персонажей и самого автора. При изображении пейзажа Г. Ибрагимов порой прибегает также к приёму антитетичного параллелизма. Например, природа, полная умиротворения, словно улыбается Гараю, идущему с топором в руке, которым он скоро зарубит пса Актырнака на мясо. Будто пытаясь утешить человека, высокие звёзды блещут, как бриллианты. Но Гараю, до смерти голодному и озабоченному тем, как накормить семью, они кажутся… пиалами. Нельзя в связи с этим не удивиться органичности образов, используемых автором: пиала – это ведь сосуд для пищи.

Для пера Ибрагимова характерно сгущение мрака жизни голодающих до такой степени, что изображённое порой начинает казаться чем-то условным, нагнетенным усилием автора до ирреальности, картина начинает восприниматься как плод его фантазии. Ужас яви переходит в кошмар и наоборот (что еще страшнее!) – кошмар оборачивается явью. В финале повести Гарай, доведённый голодом до сумасшествия, убьет, чтобы утолить им голод, своего ребёнка, которого в его сне с той же целью умерщвляет старуха. Чтобы прервать бесконечно тянущийся кошмар сна-яви, Гараю остаётся покончить жизнь самоубийством. Подчеркнём, что убийство Гараем собственной дочери с целью пропитания и спасения своей жизни – тоже типичное для дней страшного голода в Поволжье явление.

Основу повести составляют, конечно же, люди, доведённые голодом до звериного, даже хуже звериного, состояния (по ним и названо произведение). Состояние их, не пережившим ими пережитое, понять невозможно. И выразить, при всём писательском мастерстве автора повести, оказывается сложным. Мысль об этом вынесена Г. Ибрагимовым в финал произведения. Писатель не находит исхода изображённому и своей боли. Финальные строки повести не менее ужасающие: из мальчика Зайни, мечтавшего спастись от голода в городе, слепят пельмени. Чем мотивирован этот финал? Безусловно, логикой развития художественной мысли, всё той же верностью «правде жизни». Или же чем-то иным, обусловившим принцип «сборности» в повести и пророчески ощущаемым татарским писателем на очередном страшном изломе отечественной истории, подтверждающем ничем не преодолимую закономерность её развития, основанную на бесправии, унижении, несправедливости, вековой нищете, обездоленности – на том дурном, чему в нашей многострадальной стране конца края так и не видать.

ЛИТЕРАТУРА

1. Ибрагимов Г. Г. Хикәяләр, повесть, роман (Рассказы, повесть, роман) / төз. Р. Акъегет (сост. Р. Акъегет). Казан: Татар. кн. изд-во, 2007. 463 с.

2. Манн Ю.В. Сборный город // Манн Ю.В. Комедия Гоголя «Ревизор». М.: Худож. лит., 1966. С. 10–32.

## Г. ИБРАҺИМОВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ИСКЕ ЯЗМА ТЕЛ ҺӘМ ҖИРЛЕ СӨЙЛӘШ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕНӘ КҮЗӘТҮЛӘР

***Булатова М.Р.***

В данной статье рассматриваются языковые особенности произведений классика татарской литературы Г. Ибрагимова, приводятся многочисленные примеры.

This article discusses the linguistic features of works of the classic of the Tatar literature G. Ibrahimov, the numerous examples are provided.

Башкортстан Республикасының гүзәл бер җирлегендә туып-үскән күренекле татар язучысы, әдәбият галиме, тарихчы, лингвист, методист-педагог һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимов калдырган мирас искиткеч бай һәм күп кырлы. Татар әдәбиятын формалаштыру, аны үстерү, сүз сәнгате үсешенә һәм тел күренешләренә бәйле төрле чараларны хәл итүдә гаять зур өлеш керткән олы шәхес ул.

Белүебезчә, XX гасыр башында иске татар язма әдәби тел нормаларыннан әкренләп арыну, хәзерге татар язма әдәби телен формалаштыру процессы бара. Г. Ибраһимовның башлангыч чор иҗатында да иске татар язма әдәби теленә хас күренешләрнең актив кулланылуы билгеле. Биредә «Табигать балалары», «Уты сүнгән җәһәннәм», «Карак мулла», «Карт ялчы», «Татар хатыны ниләр күрми», «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» һ.б. әсәрләрендә күзәтелгән тел үзенчәлекләренә тукталып узабыз. Язучының туган төбәгенә (язучы туган Солтанморат авылы татар теленең стәрлетамак сөйләшенә карый) генә хас булган сөйләм берәмлекләренә дә игътибар ителәчәк.

Г. Ибраһимов иҗатында иске татар язма әдәби теле белән уртак күренешләрдән: тәңгәллекләр – *ңл~лг*: *яңлыш* [4, б. 130] – ялгыш, *яңлышлыклар* [4, б. 129] – ялгышлыклар, *ңл-ңг: маңлай* [4, б. 134, 144 һ.б.] – маңгай; борынгы *г* авазының саклануы: *олуг* [4, б. 127, 168] – олы, *агыз* [4, б. 412, 420] – авыз, *агыру* [4, б. 410] – авыру, *агырлыкларының* [4, б. 403] – авырлыкларының, *тугры* – туры, *угырлаша* [4, б. 138] – урлаша һ.б.

Милли әдәби тел формалашу чорында элекке чордан ук килгән интервокаль позициядә саңгырау һәм яңгырау авазларның параллель кулланылуы дәвам итэлә. Бу үзенчәлек Г. Ибраһимов әсәрләрендә дә күзәтелә: *Чү, **екетләр...*** [4, б. 143]. *Мәдрәсә хәмияте берлән кайнаган **екетләр** берәм-берәм үз кулларының куатене сыныйлар* [4, б. 135]. – *Ну, **егетсең, егет!** – диде* [4, б. 144]. Соңга таба яңгырау вариант төп нормага әйләнә.

Язучы әсәрләрендә ***җ***-лаштыру күренеше дә игътибарны җәлеп итә: *җуатырга* [4, б. 208], *җегет* [4, б. 158], *җә инде* [4, б. 122], *җомычка* [4, б. 128], *җылаганы* [4, б. 130], *җуан* [4, б. 218], *җуанырлар* [4, б. 145] һ.б.

Шул ук вакытта мишәр сөйләшләренең төп үзенчәлекләреннән берсе булган ***й***-лаштыру күренеше дә чагыла, иске татар теленең китаби теле традициясе итеп каралган *й*-лаштыру Г. Ибраһимов әсәрләрендә еш очрый: *йирдә* [4, б. 121], *йитә* [4, б. 125], *йиткерергә* [4, б. 126], *йирдән* [4, б. 128], *йитмәячәк* [4, б. 134], *йиңеллек* [4, б. 135], *йибәрә* [4, б. 132, 137], *йиренә йиткереп* [4, б. 144] һ.б.

Асылда язучы урта диалектка хас *җ*-лаштыруны көнбатыш диалекттагыча *й*-лаштыру белән иркен аралаштыра. Гомумән, XIX гасырда һәм

XX гасыр башында язылган әсәрләрдә сүз башы позициясендә *җ*-лаштыру һәм *й*-лаштыру параллель кулланылган. Бу факт әлеге күренешнең ул чорда нормалашып өлгермәгәнлеген раслый.

XIX гасыр – XX гасыр башында исем фигыльнең ***-мак/-мәк*** формасы актив кулланылышта булган. Әлеге формалар Г. Ибраһимов әсәрләрендә дә очрый: *...аны бер дә тотмый саклап **килмәктә** булган зур бер мукшы бае берлән...ярышу бара* [4, б. 140]. *... бер ташландык өй кеби **күренмәктә** иде* [4, б. 400]. *... исбат **итмәктә** иде* [4, б. 407]. *...урманнар элеккечә яшел, сандугачлар һаман өзлексез **сайрамакталар** иде* [4, б. 96]. *Шуңа күрә Галиләр бу кибәннәрен, яңага чаклы суктырып, сатып **бетермәк** булганнар* [5, б. 451].

Бу күренеш кайбер татар сөйләшләрендә (эчкен, саз ягы, байкыбаш, златоуст, бәрәңге, камышлы, минзәлә һ.б.) сакланган, әмма сирәк кулланыла. Башкортстанның көньяк ареалы татар сөйләшләрендә (кормантау, тепекәй, учалы, бәләбәй, стәрлетамак) борынгы ***-мак/-мәк*** формасы нигездә ***кирәк*** модаль сүзе белән кулланыла [1, б. 154; 2, б. 160].

Г. Ибраһимов әсәрләрендә, хәзерге әдәби тел нормаларыннан чыгып карaганда, диалекталь булып саналган инфинитивның ***-мага/-мәгә*** формасы сирәк булса да очрый: *Зәкидән көләргә, юк-бар нәрсәләр **сорашмага**, төрле ләкабләр (кушамат) **такмага** башладылар* [4, б. 404]. *...**сорашмага** башлады* [4, б. 404].

Исем фигыльнең *-мак* формасы юнәлеш килеш кушымчасы *-га, -ка* белән кушылып инфинитивның *сорашмага* ← сораш (боерык) + *-мак* (исем фигыль) + *-ка* (юнәлеш килеш) төрен барлыкка китерә. Монда, фономорфологик процесс нәтиҗәсе рәвешендә, → *макка* → *макга* → *мага* килеп чыккан. Иске татар әдәби телендә *-мага/-мәгә* киң кулланылышта була, хәзерге көндә ул – диалекталь күренеш.

Бу үзенчәлек урта диалект сөйләшләренең олы буын вәкилләрендә саклана (минзәлә сөйләшенең бәләбәй урынчылыгы, златоуст, эчкен, нократ, касыйм, бәрәңге, бастан, пермь һ.б.). Казан арты сөйләшләрендә дә, бигрәк тә *алмаға килү* сүзтезмәсе рәвешендә, кулланышта: *Қыd алмаға киләләр пар атлар җигеп* [1, б. 153].

I һәм II зат кушымчалары да язучы әсәрләрендә иске татар әдәби телендәгечә: *Курыкма**ңыз*** (әд. курыкмагыз) [4, б. 209]. *Нигә җыелышты**ңыз*** (җыелыштыгыз)? [4, б. 133]. *Җыенды**ңыз**мыни* [4, б. 135]. *Кууы**ңыз**ның бөтен зарары – шул унбиш тиен* [4, б. 135]. *... ни өчен ишеге**ңез**не бикләде**ңез**, нигә ут сүндерде**ңез**?* [4, б. 97]. *Сугасы**ңыз** килә икән... бире**ңез** минем билетларымны* [4, б. 135].

Исем һәм башка сүз төркемнәрендә дә шулай ук: *Чәе**мез**дә* (әд. чәебездә) *аерым бер тәм булачак иде* [4, б. 122]. *Күп булса берәр чынаяк чәй эчкән**мез**дер* (эчкәнбездер) [4, б. 122]. *Зиһенемә шагыйре**мез**нең, заманында ятлап та, әллә качан оныткан бер шигыре килә* [4, б. 130]. *Күрәсе**мез** бар* [4, б. 145].

Тартымлы исемнәрнең төшем килешен ***-ыны/-ене*** (хәзерге әдәби телдә *-ын/-ен*) кушымчалары белән ясау автор сөйләменә характерлы: *Бөтен тирә-як халкы аның исемене* (әд. исемен) *ишетү берлән калтырый башлый* [4, б. 132]. *Үзе үлгәч, коесыны* (коесын) *тазартканнар икән* [4, б. 132]. *Екетләр берәм-берәм үз кулларының куәтене* (куәтен) *сыныйлар* [4, б. 135]. *Аның куылачагыны* (куылачагын) *белгәнгә, һәрбер шәкерт мәсҗеткә*

*бармый, башка йиргә дә китми* [4, б. 136]. *Күзләрене* (күзләрен) *аңа кадап торалар* [4, б. 136]. ... *атларыны* (атларын) *җиктереп* [4, б. 137], *атыны* (атын) *урлап* [4, б. 138]. *Күзләренең яшене* (яшен) *яшерергә лөзүм (кирәк) тапмыйлар* [4, б. 145].

Кайбер әсәрләрендә ***-дык/-дек*** кушымчалы фигыльнең актив кулланылышын күрәбез. *-ган/-гән* урынында борын-борыннан язма әсәрләрдә кулланылган *-дык/-дек* кушымчалары угыз-төрек үзенчәлекләре булып тора. *-дык/-дек* формасы тартым белән һәм чыгыш килешендә килә, һәм ул хәзерге әдәби телдәге *-ганга күрә* формасына туры килә. Мисаллар: *Маэмурият, бөтен тирә-якка гам булган бу теләкне игътибарсыз калдырырга имкяг* ***тапмадыгыннан*** (тапмаганга күрә)*, карак мулланы бөтен гаиләсе берлән бергә мәңгегә Якутскига сөрде* [4, б. 146]. *Күлнең аргы башында* ***булдыгыбыздан****, авылга кайту өчен... теге куркыныч камышны үтү лазем иде.*

Гомумән, иске татар әдәби телендә синтетик җөмләнең хәбәре булып торган *-дык/-дек* формасындагы фигыль төрле бәйләүче формаларны алып, җөмләләр арасында төрле мәгънә мөнәсәбәтләре урнаштырган: а) *-декчә* (дәрәҗә-күләм мөнәсәбәте), б) *-дыкта* (вакыт мөнәсәбәте), в) *-дыктан, -дыгымнан, -дыгыбыздан* (сәбәп мөнәсәбәте).

XIX йөзнең икенче яртысында һәм XX йөз башында киләчәк заман хикәя фигыльләрдә элек актив булмаган ***-ачак/ -әчәк*** кушымчалары киң кулланылышка керә. Г. Ибраһимовның туган төбәк җирле халык сөйләшендә хәзер дәбик кулланылмаган бу форма язучы әсәрләрендә шактый: *Никах укылганчы шул өндәүче өендә кал****ачак****, аннан кыз катына кил****әчәк*** [4, б. 247]. *Донда, Кубаньда ... генералларга каршы сугышырга, тагы кан, тагы газап, үлем эченә кит****әчәк*** [5, б. 474]. *Аның бүгенге төне тыныч бул****ачак*** [5, б. 473].

Билгеле булганча, ***бу*** алмашлыгы хәзерге татар әдәби телендә кыек килешләрдә килгәндә һәм төрле грамматик формалар ясалганда ***м*** авазына башланып языла. Иске татар язма әдәби телендә исә ул барлык очракларда да ***б*** авазына башлана. Г. Ибраһимовта да шулай ук: ***Буны*** *мулла үзе тәсдикь кыйлды* [4, б. 139]. *Анлар* ***бундый*** [4, б. 135]. *Икенчедә алыннарны* ***буңар*** *бирәләр* [4, б. 141]. ***Бундан*** *өч ел элек ... бик зур эшкә батырган* [4, б. 142]. ***Бунларның*** *һәр икесе* [4, б. 134]. ***Бунлар*** *хакында* [4, б. 132].

***Ул*** алмашлыгының күплеге ***анлар*** рәвешендә кулланылу очраклары бар: *Һәркем анлар* (әд. алар) *хакында* [4, б. 132]. *Нәселләре белән карак инде анлар* [4, б. 132]. *Анлар план буенча эшкә керешкәннәр генә иде* [4, б. 143].

Бәйлекләр дә иске татар язма әдәби телендәгечә: *кеби* – кебек, *вә* – һәм, *илә* – белән, *бәгъзесе* – кайсы, *берлән* – белән, *соңра* – соңыннан, *кәррә* – тапкыр һ.б.

***Кыйлу*** фигыленең күп кулланылышы: *Үзенә* ***кыйлынган*** *усаллыкны һич вә һич тәкъдирдә онытачак адәм булмаганга,....* [4, б. 142]. *Эчтән кызыгу хис* ***кыйлалар*** [4, б. 145]. *Эш* ***кыйла*** *алмауларыны уйлап* [4, б. 145]. *Хис* ***кыйлдыру*** [4, б. 12]. *Миңа бик зур эш* ***кыйлалар*** [4, б. 135].

Г. Ибраһимов әсәрләренең тел бизәкләрен күзәткәндә, алардагы диалекталь үзенчәлекләргә дә игътибар итү мөһим.

Грамматик диалекталь күренешләргә килгәндә, Башкортстанда туган татар язучыларына хас үзенчәлекләрнең берсе – иркәләү-кечерәйтүне белдерә торган ***-кай/-кәй*** кушымчаларының, әдәби тел белән чагыштырганда, актив кулланылуы (мәсәлән, М. Гафури, Дәрдемәнд һ.б.). Г. Ибраһимов әсәрләрендә дә алар аеруча күзгә ташлана: *Вәликәй, Саткай* [4, б. 198].

*Җиңгәкәем, мине ни эшләтерләр инде?* [4, б. 231]. *Әнкәем, бирмәгез аңа* [4, б. 231]. *Әткәй, тизрәк бул, килделәр* [4, б. 236]. *Бик зур өмитләр көткән бу «малкай»лары югалса яки урланып читкә җибәрелсә...* [4, б. 145]. *Сөйләмә инде, Сәфәр туганкай* [4, б. 160]. *Шулай икән, гөлкәем* [4, б. 230].

Башкортстан татар язучыларының үзенчәлеге тагын шунда: *-кай/-кәй* кушымчасы абстракт мәгънәле яки җансыз әйберләрне белдерә торган исемнәргә, сыйфатларга, алмашлыкларга, бәйлек сүзләр һәм ымлыкларга да ялганып килә: *канаткайлары, чишмәкәй. Япраккайлар да яшьләнде... Тау аскайларында бөрлегән, тау өскәйләрендә карлыган...*(Дәрдемәнд) [2, б. 99].

Шуны да әйтеп узу урынлы булыр, «Башкортстанның көньяк» ареалы татар сөйләшләрендә *-кай/-кәй* кушымчасының тагын түбәндәге вазифаларны үтәве билгеле: а) эмоциональ-экспрессив мәгънәне белдермәскә мөмкин (*Күрше аwыл қыдықайы белән килде*); б) *нәмә, нәстә, нәрсә* сорау алмашлыкларына ялгануы (*нәмәкәй, нәстәкәй, нәрсәкәй*); в) җансыз, абстракт мәгънәле исемнәргә ялгануы (*әпекәй, хәтеркәйем*); г) таныш булмаган кешеләргә карата (*Урамдағы бер хатынқайдан сорадым* (кормантау сөйл.), *бер ирекәй килә* (турбаслы сөйл.); д) сүзъясагыч кушымча булуы (*сәпәкәй итү* (кормантау сөйл.) – әд. кул чабу, *мәшкәй* (учалы сөйл.) – бирән); е) охшашлык мәгънәсен белдерү (*Бигрәкләр атақай баласы инде* (кормантау сөйл.); ж) стәрлетамак сөйләше вәкилләрендә, мишәр диалекты, златоуст сөйләше һәм керәшен татарларындагы кебек, кеше исемнәрен кыскартып *-кай/-кәй* кушымчаларын ялгау (*Халкәй* – Халиулла) [1, б. 83–85; 2, б. 96–99;3, б. 208–210].

Күләм, үлчәм, сан ягыннан чагыштыру өчен әдәби *чаклы* (шулай ук *тикле, кадәр* һ.б.) бәйлеге белән беррәттән ***чикле*** диалекталь формасы да хас: *Эш бу чикле тыгылып килгән елларда кешегә өмәгә йөрү түгел, ...* [4, б. 196]..... *киләсе көзгә чикле сабыр итим* [4, б. 195]. *Шулай итеп, ул бик гади агым буенча барып, мәхәлләнең михрабына, мөнбәренә чикле йитте* [4, б. 137].

*Чикле* бәйлеге урта диалектның тау ягы, каргалы, Түбән Кама керәшеннәре, лаеш, пермь, минзәлә, бөре, турбаслы, богрыслан, көнбатыш (мишәр) диалектның чистай, стәрлетамак сөйләшләрендә таралган [6, б. 749; 1, б. 168].

Җөмләдә сүз тәртибендә аермалыклар да очрый: *Уйлаганнар магазинны алдарга* [4, б. 139] – Магазинны алдарга уйлаганнар. *Фәсхи белән Алтынбай, таң иртәдән* (иртә таңнан) *караңгы кичкәчә чабып...*[4, б. 320].

Билгеле, диалектизмнар әдәби телне баетуда саекмас чыганак булып хезмәт итә, телнең тарихи үсешен күзалларга да ярдәм итә. Чөнки җирле сөйләмдә әдәби телдә кулланылмаган, телнең аерым бер үсеш этабына гына хас булган сүз яки форма сакланып калырга мөмкин. Г. Ибраһимов әсәрләрендә, башка матур әдәбият әсәрләрендәге кебек, лексик берәмлекләр теге яки бу геройның сөйләмен аерым бер төбәктә генә кулланылган сүзләр ярдәмендә баету, тәэсир көчен арттыру һ.б. өчен файдаланыла:

***Алап*** – тал чыбыгыннан үреп балчык белән ясалган савыт, ашлык йөртү өчен кулланыла: *Боларның ишкән, иштергән арканнары, ясаткан бөятләре, тәгәрмәч тугымнары, алап, чуман, чиләкләре, күчәр, көрәкләре, бөккән чана табаннары зур базарларга юл салды* [4]. Чагыш.: көнбатыш диалектның стәрлетамак, урта диалектның минзәлә сөйләшләрендә шул ук [6, б. 36].

***Күләнкә*** – әд. күләгә, күләгәле җир: *Астына яңа гына чапкан печән түшәп, өстенә күләнкәлек ясадык* [4, б. 200].... *күләнкәләргә кердек* [4, б. 199].

***Кечек*** (< бор. төрки *kičig, kičüg*) – әд. кечкенә: *Кечек атны егып...* [4, б. 143]. *Бу тайдан кечек, чандыр, аз итле, бераз бөкрерәк аркалы, ләкин гаҗиб дәрәҗәдә сөйкемле һәм җанлы ат чыга* [4, б. 141].

***Каулау*** – әд. куалау: *Ахрысы бик артык шәп каулаганмындыр: кояш та батып өлгермәде, мин солыга килеп җиттем* [4, б. 150]. *Шулай да, ятып калганчы атып кал дип, атларны кауларга тотындык* [4, б. 152]. *Бер-берсен тапташырдай булып бераз каулаштылар да....* [4, б. 199]. Чагыш.: балтач, мамадыш, норлат, камышлы сөйләшләренә дә хас [6, б. 401].

***Салфит*** (< рус. салфетка) – бирeдә: табында кунаклар алдына җәю өчен бирелә торган озын сөлге: *Ширбәт алынуга ике табынга ике салфит җәелде* [4, б. 257]. *Зур кызыл ашъяулыкны болар җәйде, ишектән түргә сузылган тоташ салфитны болар таратты* [4, б. 256]. Чагыш.: дөбъяз, казан арты керәшеннәре сөйләшләрендә бу мәгънәне белдергән сүз *алсузма,* ә златоуст, минзәлә, стәрлетамак сөйләшләрендә *салфитка* дип атала [6, б. 41, 559].

***Таштабак*** – әд. фарфор тәлинкә: *Тагы тәрилкәләр, табын уртасындагы сай таштабактан әйләнеп йөри торды* [4].

***Тәрилкә*** (< рус. тарелка) – әд. тәлинкә: *Тагы чынаяклар, тәрилкәләр шалтыравы белән табыннар тулды* [4, б. 257]. *Бавырсакларны тәрилкә-тәрилкә кунаклар алдына таратып, чәй ясый башладылар* [4, б. 257].

***Тукал*** – әд. мүкләк (рус. комолая, безрогая): *Ул бар күңеле белән шул куе сөтле зур ак тукалга багланган иде* [4, б. 355]. *Сабира да аны яклады, булмас, тукалны бирмәм, диде* [4, б. 356]. Чагыш.: *тукал* лексемасы татар теленең урта диалекты кормантау, златоуст, эчкен сөйләшләрендә шул ук мәгънәдә кулланыла [2, б. 231].

Язучының әсәрләрендә шундый диалекталь сүзләр дә очрый: *чуар пима, ак пима, карсак, түндәк башы, чапак тел* һ.б.

Башлангыч чор иҗатында төрек һәм гарәп-фарсы алынмаларына бай булса, соңга таба рус һәм Европа телләреннән кереп, халыкта нормалашып бара торган сүзләргә игътибар итә. Шуңа күрә әсәрләрендә рус сүзләрен иркен кулланган һәм кайбер сүзләрне үзгәртеп, үзебезнең телгә җиңелрәк итеп язганы да күренә: *Яхшы* ***пенснесен*** *– күзлеген* [4, б. 214]. *Саескан, – дип, – затсыз кара* ***мужик****, – дип акырынды* [4, б. 280]. *Бу сөаль бөтен мәдрәсәне вә бөтен* ***толчокны*** *зур тәшвишкә салды* [4, б. 134]. *Хәзрәт****, политсәгә****-фәләнгә хәбәр ителмәве берлән әмер итеп, дәресханәгә керә* [4, б. 134]. ***Фәйләсуф*** *та булып китәм бугай* [4, б. 129]. *Шуны* ***духтырлар*** *төшерә алмагач,....*[4, б. 230]. *Кеше үтерергә җыендыңызмыни,* ***подлислар****... караул!..* [4, б. 135].

Кайбер рус сүзләре урынына татар теленең үз байлыгы нигезендә сүзләр ясарга омтылуы сизелә: ***дәресханә*** *– класс,* ***эсселек үлчәве*** *– градусник* [4, б. 180] һ.б.: ***...дәресханәдән*** *хәзрәт йөгереп чыгып, шәкертләрне таратты* [4, б. 135].

Шулай итеп, мәшһүр әдибебез Г. Ибраһимов язма әдәби телне дә, җирле сөйләш үзенчәлекләрен дә тирәнтен белеп, шуларны үзенең иҗатында тиешле дәрәҗәдә кулланган. Иҗатының баштагы чорында заманында актив һәм аңлаешлы булган китаби гарәп-фарсы алынмаларын, соңрак рус теленнән кергән сүзләрне кулланса да, аларны җөмләдә бик урынлы куйган. Язучының туган як колоритын яктырткан диалекталь сүзләр, төрле сурәтләү чараларына мул теле аша милләтебез яшәешен яктырткан бай эчтәлекле әсәрләре хәзерге көндә дә яратып укыла.

ӘДӘБИЯТ
1. Булатова М.Р. Морфологические особенности татарских говоров ареала «Юг Башкортостана». Казань, 2013. 240 с.
2. Булатова М.Р. Курмантауский говор среднего диалекта татарского языка в этнолингвистическом аспекте. Казань: Изд. «Магариф – Вакыт», 2016. 384 с.
3. Булатова М.Р. Семантические функции аффикса *-кай/-кәй* в татарских говорах юга Башкортостана // Академик Э.Р. Тенишев и тюркский мир: материалы Международного тюркологического симпозиума, посвященного выдающемуся тюркологу академику Эдхаму Рахимовичу Тенишеву (24 апреля 2012). Казань: КФУ, 2012. С. 207–210.
4. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. 1 т.: хикәяләр (1907–1929). 511 б.
5. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 3 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1956. 2 т.: сайланма әсәрләр. 595 б.
6. Татар теленең зур диалектологик сүзлеге / төз.: Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Д. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 839 б.

## Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ «ТАТАР ХАТЫНЫ НИЛӘР КҮРМИ» ӘСӘРЕНДӘ ХАТЫН-КЫЗ ЯЗМЫШЫ

***Вафина А.М.***

В статье рассматривается повесть одного из видных татарских писателей XX века Г. Ибрагимова «Судьба татарки». Исследуются персонажи произведения. Обращается особое внимание на приемы автора, которые позволили ему рассказать о своих героях.

The article discusses the story of one of the prominent Tatar writers of the twentieth century of Galimzyan Ibragimov, «The fate of the Tatars». The article examines the characters of the work. Emphasizes techniques of the author, which enabled him to tell about his characters.

Татар әдәбиятында татар хатын-кызларын олылаган, аңа мәдхия җырлаган, язмышы өчен борчылган әсәрләр күп. Р. Фәхретдиновның «Сәлимә, яки Гыйффәт» (1898), Г. Исхакыйның «Өч хатын белән тормыш» (1898), «Кәләпүшче кыз» (1900), «Остазбикә» (1910), Ф. Кәриминең «Мирза кызы Фатыйма» (1907), Г. Ибраһимовның «Татар хатыныниләр күрми» (1909) әсәрләр шундыйлардан. Шулар арасында Галимҗан Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» повесте XX гасыр башы татар әдәбиятының матур һәм гыйбрәтле өлгесе.

Совет хакимияте елларында Г. Ибраһимов «Татар хатыны ниләр күрми» әсәренең икенче вариантын яза. Әлеге повестьта заман таләп иткәнчә югары катлам кешеләрен тәнкыйть итү, хатын-кызның төрле авырлыкларга дучар булуы, хокуксызлыгы, дөресрәге иске тормышны инкарь итүгә игътибар ителә. Ул беренче тапкыр 1910 елда, Эстәрлетамакта, «Каләм» ширкәтендә басылып чыга. Китапның титул битенә «Беренче җөзья» дип куелган һәм «Ирләр сурәтендә йөргән хатын, Эстәрлетамак өязендә булган вакыйга» дип язылган. Әсәрнең кереш өлешендә һәм авторның замандашы Хәлил Маннан истәлекләрендә бирелгәнчә, әсәрнең барлыкка килүенә шул елларда элекке Уфа губернасы Стәрлетамак өязе Сәмән авылында булып узган фаҗигале бер вакыйга сәбәп була. Шул ук редакция тарафыннан бу әсәр 1911 елда икенче тапкыр бастырыла. Шуннан сон Г. Ибраһимов повестьне 18 ел буена аерым китап итеп тә, җыентыкларга да бирми. Бары тик

1929 елда гына яңадан эшкәртеп укучы игътибарына тәкъдим итә. «Татар хатыны ниләр күрми»дә Гөлбану исемле татар кызының гыйбрәтле язмышы тасвирлана. Әсәрнең беренче варианты кызның Закирга кияүгә бирелгәнчегә кадәрге көнкүрешен, эш-гамәлләрен тасвирлау белән башлана. Яшь кызның уңганлыгына басым ясала. «Гөлбану йорт кирәкләрен тиз-тиз тегеп бетереп, тагын шул приданлыкка тотына иде. Яулыклар, намазлыклар, өстәл вә түшәк япмалары һәм чолгаулар эшләп әлеге мәүһүм егеткә алып китәчәк нәрсәләр хәзерләнә иде», – ди бу хакта әдип [3, б. 83]. Гөлбануның өмәләрдә, иген эшләре кебек чараларда актив катнашуы да автор игътибарыннан читтә калмый. Кыз озату, килен төшерү кебек күренешләр аша татар халкының борынгыдан килгән матур милли традицияләре, гореф-гадәтләре хакында сүз алып бара. Шулай да, яшь гомерен көнкүреш эшләре белән генә уздыру Гөлбануга канәгатьлек бирми. Шулай да, ул тормышын дүрт стена эчендә үткәрергә мәҗбүр. Автор героиняның шул заманда хөкем сөргән җәмгыять кануннарын үзгәртергә сәләтсезлеген кат-кат исбатлый. Кызның атасы да баласын төрле җыеннарга, бөтен авылда гомуми хәл, лязем булганга гына җибәрә. Гомумән, дикъкате шәл, күлмәк кебек әйберләргә юнәлтелгәнлектән Гөлбануның гыйлем турында уйларга вакыты калмый. Г. Ибраһимовның «... педагогия – бала тәрбиясе фәненнән хәбәре күп иде: баланы иске чүпрәккә бик каты биләп, кабык бишеккә салып дылгылдатып тирбәтергә, җыласа яки карышса кыйнарга, һәр эштә бик каты тотарга тиешлеген ул билгамәл белгән иде», – дигән сүзләре шуңа дәлил [3, б. 87]. Шулай ук әсәрдә Гөлбануның сабырлыгына, үз башына төшкән авырлыкларны гамәле, хәйләкәрлеге нәтиҗәсендә җиңеп чыгуына басым ясала. Аңа хас булган әлеге сыйфатлар беренче вариантта ачык чагыла. Кыз үз ризалыгыннан башка Закир исемле егеткә кияүгә бирелә. Икенче басма кияүнең ямьсезлеген, бозыклыгын, кәләшнең аны яратмавын ачык күрсәтүе белән аерылып тора. Повестьнең икенче вариантында Зариф карт вафат булгач, аның ике хатыны, дүрт улы үзара тату яши алмау сәбәпле, йорт вә малны дүрткә бүлеп, дүртесе дүрт җирдә бик ярлы һәм кечкенә йортларда яшиләр. Закир, Гөлбану һәм Сабирадан гыйбарәт булган гаилә кечкенә генә бер йорт салып үзләренчә, ярлы тормышта көн күрәләр. Заманында мул тормышта яшәгән гаиләнең ярлылана баруын автор Закирның игътибарсызлыгыннан, булдыксызлыгыннан, эшлексезлегеннән, эчүеннән күрә. Беренче вариантта егетнең мәрхәмәтсезлегенә, ерткычлыгына түзә алмаган Гөлбану ире өеннән качып китәргә мәҗбүр була. Хикәядә аның тормыш юлында күргән кыенлыклары, ир-егетләр кыяфәтендә качып йөрүләре, нәтиҗәдә туган нигезенә әйләнеп кайтуы тәфсилләп сөйләнә. Монда Г. Ибраһимов татар хатын-кызларының гасырлар дәвамында яшәп килгән иске гадәтләргә, тормыш таләпләренә каршы протест белдерүен билгеле. Азатлык, бәхет өчен көрәш юлына баскан геройны әдәбият мәйданына чыгара. Әдип раславынча, кешенең бәхетле булуы үзеннән тора. Г. Ибраһимов кызның җиңеп чыгуын күрсәтү аркылы мәгънәле бер ишарә ясый. Ул иске тормыш тәртипләренең җиңелүен раслый.

Аерым бер тәнкыйтьчеләр, әдәбият белгечләре язучының бу әсәрендә сурәтләнгән вакыйгаларның социаль шартлар белән бәйләнмәвен, хатын-кыз азатлыгы халык азатлыгы проблемасына тоташмый дигән фикерне уздыралар. Шуңа күрә дә, Октябрьдән соң үзгәртеп язылган вариант бу уңайдан уңышлырак, идеясе, социаль яңгырашы гаять көчлерәк булуын

билгелиләр. Г. Ибраһимов әсәрнең икенче вариантын совет хакимияте таләпләренә, сәясәтенә туры китереп язарга мәҗбүр була. Муллаларның үзара ызгышуларын, төрле әхлаксыз гамәлләр аша байлык туплауларын, шәригать кануннарын бозулары һ.б. сурәтли. Бередә югары катлам вәкилләренең вәхшилегенә, гади халыкны изеп яшәүләренә, кеше хокуксызлыгына аеруча зур игътибар бирелә. Гөлбануның фаҗигале язмышы мисалында хатын-кызның ирексезлегенә, бәхетсезлегенә басым ясала. Төп игътибар сыйнфый аерымлануларга юнәлтелә [2, б. 221].

Г. Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» повестенең икенче варианты «Бер атна эчендә кызга ике яучы килде» дигән җөмлә белән башланып китә [4, б. 225]. Шушы җөмлә укучыны кыз тормышында булачак кискен үзгәрешләргә әзерләп куя. Гөлбануга килгән яучыларның берсен әтисе тиз генә борып җибәрсә дә, Шибай кантуннан килгәнен бора алмый. Әсәрдәге вакыйгалар Нурый карт йортында туйга әзерлекне тасвирлау белән дәвам итә. Автор хуҗаларның туйга чакырылган кунакларны, аеруча кодаларны бик дулкынланып көтүләре турында яза. «Кунак килен Мәрхәбә белән матур җиңги Мәфтуха кызның бирнәләре, эшәнчекләре белән тулы ак калайлы зур ике сандыктан чыккан киҗеле сөлгеләр, чигүле намазлыклар белән өйнең бөтен ялангач стеналарын бизәп бетерәләр» [4, б. 269]. Гөлбану үзе дә ундүрт яшеннә алып киндер суга, үзенә һәм булачак киявенә сөлгеләр, ашъяулыклар, күлмәкләр һ.б. бик күп бүләкләр әзерли... «Менә шулай итеп, унҗиде яшенә кергәндә, кызның эшәнчеге, бирнәсе бик бай булып әзерләнеп җитте» [4, б. 272]. Кызганыч ки, алга таба шушы байлык, кыз өчен түләнгән мәһәр Гөлбануның бәхетсезлегенә, фаҗигага этәрә. Кызының Сабира йортында кичергән авыр тормышын белсә дә, әтисе Нурый Гөлбануның ирен ташлап кайтуына каршылык белдерә. «Өч йөз сум мәһәрне ничек ташлап китәсең», ди ул. Повестьта кодалар атының койрыгы киселүе дә кызның язмышын авырлаштыра. Алга таба әлеге вакыйга Сабира тарафыннан кызны рәнҗетү максатыннан күп мәртәбәләр телгә алына. Вакыйгалар барышында яшь килennең кайнанасы Сабираның да гомере буе иренең камчысын ашап яшәве ачыклана. «Сабира бу кыйнаулардан бик күп газап татыды. Йөзе, күзе канланып, бите, башы ертылып, адәм күзенә күренергә оялырлык чаклары күп булды» [4, б. 279], – диелә бу хакта әсәрдә. Г. Ибраһимов иҗатын өйрәнгән З. Сәлахова язганча: «Ул Гөлбану килен булып төшкән гаиләнең эчке халәтен чагылдыру өчен кирәк. Бу үз чиратында Гөлбануның киләчәк язмышын билгеләүдә дә зур роль уйный. Аның үзен дә алга таба шундый ук язмыш көтә, вакытлар үтү белән Гөлбануны ире Закир кыйнап ташлый» [5, б. 207]. «…анасы ягыннан Закир төште, кечкенә соры күзләрен ерткычландырып, кулындагы дилбегәләре белән хатынына ыргытылды, кызып, үзен-үзе онытып, эштән чыгарганчы кыйнады да, күлмәкчән көенчә, ишектән типкәләп тышка, суык карга этәреп җибәрде, үзе шапылдатып ишекне япты» [3, б. 409]. Шул рәвешле Г. Ибраһимов Гөлбану образы аша татар кызларының аянычлы, шул ук вакытта фаҗигале язмышын ача. Гөлбануның кайнатасы Шибай үлгәннән соң, кәләшнең тормышы бик авырлаша. Иренең кыйнаулары, кайнананың явызлыгы, игезәк балаларның үлүе Гөлбануны соңгы чиккә җиткерә – ул суга ташланып үлә. Шулай итеп, Г. Ибраһимов кызның рухи һәм физик яктан юк ителүен эволюцион үсештә бирә. Мондый типтагы геройларны сурәтләү аша милләтнең рухи язмышын чагылдыра, аянычлы тормышын тасвирлауда мөһим факт булып тора.

ӘДӘБИЯТ

1. Бакиров М. Туй йолалары һәм аларга бәйләнешле поэтик әсәрләр // Мирас. 1998. № 4. Б. 81–95.

2. Баязитова Ф.Г. Ибраһимов әсәрләрендә этнографизмнар // Г. Ибраһимов һәм хәзерге заман: Тууына 115 ел тулуга багышланган фәнни конференция материаллары. Казан: Фикер, 2002. Б. 218–225.

3. Ибраһимов Г. Татар хатыны ниләр күрми // Мирас. 2003. № 4. Б. 83.

4. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. 1 т.: хикәяләр (1907–1929). Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. 528 б.

5. Сәлахова З.Г. Галимҗан Ибраһимов иҗатында натурализм // Галимҗан Ибраһимовның иҗат дөньясында. Казан, 2012. 375 б.

## ФЛҮН МУСИН ХЕЗМӘТЛӘРЕНДӘ Г. ИБРАҺИМОВ

***Габидуллина Ф.И., Җундибаева А.К.***

В данной статье рассматриваются научные труды известного ученого-литературоведа Ф.М. Мусина, посвященные изучению творчества Г. Ибрагимова.

The scientific works of well-known scientist, literature critic F.M. Musin, devoted to the study of creativity of G. Ibragimov, are analysed in this article.

Кол Гали исемендәге Халыкара премия лауреаты, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, филология фәннәре докторы, профессор, күпләгән гыйлем әһелләренең остазы Флүн Мослах улы Мусин (1939–2009) үзенең фәнни эшчәнлеген 1960 елларда әдәби тәнкыйтьтән башлый. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына күчкәч, ул әдәбият белгече сыйфатында татар әдәбияты тарихын өйрәнүгә алына. 1987 елдан 2008 елга кадәр Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеген җитәкләп, әдәбият тарихын өйрәнүне оештыру эшләре белән дә шөгыльләнә.

Ф.М. Мусин – 1970–2006 елларда әдәбият фәне һәм тәнкыйть өлкәсендә иң актив эшләүче галимнәребезнең берсе. Аның татар әдәбиятының төрле актуаль мәсьәләләренә, язучыларның, бигрәк тә прозаикларның иҗатларына һәм аерым әсәрләренә багышланган тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләре үзәк матбугатта даими дөнья күрә. Галим-тәнкыйтьченең әдәбият тарихын һәм җанлы әдәби процессны җентекләп өйрәнү-тикшерү нәтиҗәсендә барлыкка килгән «Тормыш сынавы аша» (1969), «Тарих һәм заман» (1974), «По координатам жизни» (1976), «Связь времен» (1979), «Көмеш көзге» (1989), «Гаяз Исхакый» (1998) һ.б. татарча һәм русча китаплары исә алтмышынчы-җитмешенче еллардагы татар совет прозасының проблемаларын, үсеш тенденцияләрен, үзенчәлекләрен, көчле һәм көчсез якларын конкрет әсәрләр мисалында анализлаган җитди хезмәтләр итеп каралырга хаклы. Бу хезмәтләрендә галим, әдәбият фәне һәм бөтенсоюз әдәбияты ирешкән казанышлар югарылыгыннан торып, татар прозасының бүгенге хәленә күз ташлый, аның сан һәм сыйфат ягыннан үзгәрешләрен, тематикасын, жанр үзенчәлекләрен, аерым язучыларның теге яки бу жанрга керткән өлешләрен, яңалыгын тикшерә, бер үк вакытта әдәби традицияләрдән файдалану юллары, әдәби герой һәм чынбарлык, халыкчанлык, прозада документаль нигез, тарихилык, милли стиль, әдәбиятның публицистик пафосы кебек мөһим теоретик проблемалар турында да сүз алып бара.

Әдәбият галиме фәнни-тәнкыйди эшчәнлегендә Г. Ибраһимов иҗатын да читләтеп үтми. Үзенең күпсанлы фәнни-тәнкыйди хезмәтләрендә ул язучы эшчәнлегенең төрле якларына игътибар итә. Ф. Мусинның Г. Ибраһимов иҗатын өйрәнүгә багышланган зур күләмле фәнни мәкаләләренең берсе «Г. Ибраһимов иҗатын өйрәнүнең торышы һәм бурычлары» дип атала һәм ул язучының тууына 115 ел тулуга багышлап языла. Мәкаләдә галим Г. Ибраһимовны «...тарихның XX гасырга караган бик мөһим чорын танып-белүдә бу дәвердәге иң күренекле шәхесләребезнең берсе» [2, б. 12], дип бәяли һәм аның күпкырлы эшчәнлеген өйрәнү зур әһәмияткә ия булуын ассызыклый. Алга таба мәкаләдә язучы иҗатының өйрәнелү торышына гомуми күзәтү ясала һәм кичектергесез хәл ителәсе мәсьәләләр күтәрелә. Галим фикеренчә, Г. Ибраһимов эшчәнлеге гуманитар фәннәрнең игътибарын күптәннән җәлеп итеп килә. Аның хакында докторлык һәм кандидатлык диссертацияләре якланган, монографияләр, күпсанлы мәкаләләр язылган. Күренекле җәмәгать эшлеклесе әдип, галим, мәгариф әһеле, журналист һ.б. булган бу олы затның элегрәк әдәби иҗаты активрак өйрәнелгән. М. Хәсәнов монографияләрендә, «Татар әдәбияты тарихы»нда, урта мәктәп дәреслекләрендә, күпсанлы мәкаләләрдә бу иҗат төрле яклап анализланган, аның төп сыйфатлары ачыкланган, әдәбиятыбыз тарихындагы урыны билгеләнгән. Шул ук вакытта автор соңгы елларда язучы иҗатының фән игътибарыннан читтәрәк калып килүенә туктала һәм Совет чоры идеологиясе кысаларыннан чыга башлап, классик фәнни позицияләргә күчү татарның иҗтимагый-тарихи үткәнен өйрәнүгә дә карашларны шактый яңартырга кирәклеген күрсәтә. Ни кызганыч, галим күтәргән әлеге проблеманың бүгенге көндә дә актуаль булып калуын күзәтәбез.

Ф. Мусин, Г. Ибраһимовның күпкырлы эшчәнлеген яктыртуга карата хәзерге карашлар рухында яңартып өйрәнергә алынганда, берничә мөһим мәсьәләне алга куя: иң әүвәл ул бу иҗатны фактик яктан тулырак белү кирәклеген ассызыклый. Мәгълүм ки, совет чорында ул вакыттагы идеологик карашлар бу мирасны бөтен барлыгында белергә мөмкинлек бирми, кайбер әсәрләре күләгәдә калдырыла. 1980 еллардан «ак тап» булып килгән шундый әсәрләреннән «Адәмнәр» повестена игътибар ителә башлады һәм ул әдәбият тарихына да кайтарылды. Галим бик тирән мәгънәле бу әсәрнең әле фәнни тулы анализ һәм бәя алмавын билгели. Аның 20 нче еллар татар прозасын һәм идея, һәм эстетик яктан баета торган әсәр икәнлеге ачыкланып беткәне юк һәм ул бу хәлнең күпмедер дәрәҗәдә «Адәмнәр» повестеның темасы белән идеясен бутау күренешләре күзәтелүен дә ассызыклый: «ачлык әсәрнең темасын тәшкил итә, ә аның идеясе адәм балаларына киң фәлсәфи анализ һәм бәя бирү белән бәйләнгән. Повестьның прозабыз тарихындагы роле әнә шул идеясе зур тәэсир көче белән чагылдыруына бәйле» [2, б. 13].

Г. Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» һәм «Безнең көннәр» романнарының беренче вариантлары «ак тап» хәлендә кала килүенә дә борчыла галим, күп очракта әлеге әсәрләр фәнни тикшеренүләрдә дә үтеп барышлый гына искә алыналар. Чынлап та, инкыйлабка кадәрге татар дөньясын объектив сурәтләү ягыннан беренче вариантлар күбрәк игътибарга лаеклылар, чөнки ул чорда әдип тормышны гомум милли позициядән торып яктырта, шунлыктан анын турында дөресрәк фикер йөртә, бу хәл беренче вариантларның тормышны танып-белү әһәмиятен дә арттыра. Безгә билгеле

булган икенче вариантлар, совет чоры идеологиясе кысаларында языла һәм авторның үткәндәге яшәешкә сыйнфый-тенденциоз каравын көчәйтә, бу хәл ахыр чиктә хикәяләүнең танып-белү мөмкинлекләрен дә чикли. Нәтиҗәдә, хәзер беренче вариантларның идея-эстетик кыйммәте арта. Шунысы куанычлы, хәзерге әдәбият белемендә бу юнәлештә шактый санда фәнни мәкаләләр дөнья күрде инде.

Мәкаләдә Г. Ибраһимовның фәнни-теоретик карашлары әле тиешенчә өйрәнелмәгән булуы да аерым урын ала. Әгәр әдипнең XX йөз башында татар әдәбияты теориясенә нигез салучыларның берсе булуын, совет чорында да бу өлкәдә әйдәп баручылардан булып калуын искә алсак, әлеге мәсьәләне өйрәнүнең гомумән татар әдәбият белеме тарихын фәнни яктырту өчен бик мөһим икәнлеген ачыклый алырбыз. Ф. Мусин да Г. Ибраһимовның әдәби-теоретик карашлары һәм күзәтүләре хәзер әдәбиятыбыз тарихын һәм теориясен чын фәнни нигездә өйрәнү өчен дә файдалы булуын искәртә. Мисал өчен тарихны чорларга бүлү мәсьәләсен алсак, галим биредә әдипнең әлеге мәсьәләгә кайбер карашлары бүген дә фәнни кыйммәтен саклавын билгеләп үтә. Тарихны чорларга бүлү мәсьәләсен алсак, галим биредә әдипнең әлеге мәсьәләгә кайбер карашлары бүген дә фәнни кыйммәтен саклавын белдерә.

Бер үк вакытта автор Г. Ибраһимовның әдәби-теоретик карашларында һәм бәяләмәләрендә фәнни яктан бәхәсле һәм тенденциоз моментлар да очравын әйтә. Моңа мисал итеп Г. Исхакый белән Г. Тукай иҗатларына биргән кайбер бәяләрен китерә: «...мондый очракларда без Г. Ибраһимовның әлеге әдипләрнең иҗат максатларын һәм үзенчәлекләрен искә алмыйча, аларның кайбер әсәрләре хакында шактый субъектив фикер йөртүе белән очрашабыз. Мәсәлән, Г. Исхакыйның мәгърифәтчел романтизм рухында язылган «Мөгаллимә» пьесасы героинясы Фатыйма образына ул реалистик позициядән торып шактый тенденциоз бәя бирә. Шигърияттә образлылык һәм хислелек мәсьәләләрен абсолютлаштыра төшеп карау исә аны Г. Тукайның реалистик-публицистик рухтагы кайбер әсәрләрен берьяклырак бәяләүгә китерә» [2, б. 14]. Шулай ук галим күзлегеннән Г. Ибраһимовның революциядән соңгы фәнни-теоретик карашларында инде байтак дәрәҗәдә шул вакыттагы идеология йогынтысында барлыкка килгән субъективлык та читтә калмый: «...гомумән әдәбиятны һәм конкрет әдәби әсәрне эчтәлек ягыннан бәяләгәндә, ул кайчак сыйнфый-социологик караш тора, ягъни үткәндәге әдәби мирасны мәгънә ягыннан яңа заман өчен искергән һәм хәтта зарарлы дип саный. Форма, поэтика мәсьәләләрендә исә фәннирәк позициядә кала, ягъни әдәби мирасның сәнгати тәҗрибәсен һәм табышларын яңа заман әдәбиятында да файдаланырга мөмкин дип карый» [2, б.15].

Г. Ибраһимовның күпкырлы эшчәнлеген фәнни объектив бәяләү турында сүз алып барганда, хәзерге көндә аның мәгарифкә караган өлеше үзгә бер әһәмияткә ия икәнлеген дә әйтеп узу урынлы булыр. Татар дөньясында яңарыш хәрәкәтен башлап җибәргән җәдитче-мәгърифәтчеләр идеалларын һәм эшен яңа гасыр башында кабул итеп алып, ул да милләтне яшәтүдә һәм үстерүдә мәгарифкә зур өметләр баглый, шунлыктан бу эштә үзе дә турыдан-туры катнаша. «Мәдәни халыкларның мәктәпләрендә иң әһәмият бирелеп, укытылуы лазем вә фарыз дәрәҗәсендә тотылган фәннәрнең иң беренчесе "Тел вә әдәбияты миллия"дер», дип һәм шунлыктан татар мәгарифендә дә туган тел белән әдәбиятны укытуга зур игътибар биреп, ул матбугат битләрендә бездә бик мөһим бу эшнең торышын һәм бурычларын яктырткан мәкаләләр белән чыга, әлеге предметлар буенча дәреслек-хрестоматияләр әзерләп чыгара. Әйтергә кирәк, аның педагогик карашларында

һәм уку әсбаплары әзерләү өлкәсендәге тәҗрибәсендә бүген дә милли мәгариф эшендә файдаланырлык нәрсәләр бар. Шул сәбәпле, әдипнең мондый эшчәнлеге дә ныклабрак өйрәнүне көтә. Шулай ук хәзерге фәнни мөмкинлекләрдән чыгып, бу иҗатны теоретик планда да, идея-эстетик яссылыкта яңартып өйрәнү сорала. Галим үз мәкаләсендә әлеге проблеманы да читләтеп үтми. Моннан тыш язучының иҗат ысулы һәм стиле, андагы шәхес концепциясе, традиция һәм яңалык, жанрлар системасы һ.б. төрле яссылыкта өйрәнергә тиешлеген дә искәртә ул. Безнең фикеребезчә, аеруча әдәби әсәрләрдәге миллилеккә игътибарны көчәйтү уңышлы булыр иде.

Галим мәкаләдә Г. Ибраһимов мирасын яңа позициядән торып өйрәнергә алынганда, иң әүвәл аның ысулы мәсьәләсен уйлабрак тикшерергә кирәклеген һәм бу гамәлнең гомум әһәмияткә ия булуын да күрсәтә. Һәм мисал өчен моңа кадәр әлеге чор әдәбиятыбызда иҗат итү ысулларын нигездә романтизмга һәм реализмның ике төренә кайтарып калдыруны аеруча, сыйнфый-социаль яктан җитлеккәнрәк дип, тәнкыйди реализмга өстенлек бирелүен, мәгърифәтчелек реализмының исә түбәнрәк сортлы итеп каралуын билгели. Мондый карашларны ул совет чоры идеологиясенә бәйләп аңлата һәм Г. Ибраһимов иҗатында, башка күп замандаш каләмдәшләренеке кебек, күбрәк мәгърифәтчелек идеяләренә нигезләнгән романтизм һәм реализм рухы белән сугарылганлыгын ачыклый.

Ф. Мусин Г. Ибраһимовның гасыр башындагы иҗатын фәнни өйрәнүдәге хәл итәсе мөһим бурычларның чираттагысы итеп аның стилен атый. Әдипнең ул вакыттагы иң зур сәнгати казанышын нәкъ менә стиль өлкәсендәге эзләнүләре һәм табышларын күрсәтә. Чынлап та, узган гасыр башындагы әдәбиятыбыз бу өлкәдә актив эзләнүләр алып бара. Чөнки ул үзенең милли мөстәкыйльлеген һәм әдәби дөньядагы урынын байтак дәрәҗәдә шушы юл белән билгеләргә омтыла. Бу яктан Г. Исхакый, Г. Тукай. Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, С. Рәмиев, Дәрдемәнд иҗатлары аеруча игътибарны җәлеп итә. Бу әдипләрнең гомум әдәби-эстетик үсештә тоткан урыннары да шактый дәрәҗәдә аларның иҗат үзенчәлекләре белән билгеләнә. Шундый каләм осталарының сәнгатьчә актив эзләнүләре һәм табышлары нәтиҗәсендә гасыр башында татар милли әдәби стиле формалаша һәм бу хәл әдәбиятыбызның иң зур казанышларыннан берсенә әверелә. Болар барысы XX йөз башындагы индивидуаль стильләрне һәм милли стильне өйрәнүнең никадәр мөһим булуын күрсәтә. Әгәр дә әлеге дәвердә «өслүб» төшенчәсе «метод» мәгънәсендә дә кулланылуын искә алсак, стиль мәсьәләсен фәнни танып-белүнең әһәмияте тагын да артачак. Әлеге мәсьәлә бүгенге көндә дә көн кадагында кала бирә һәм аны киләчәктә бигрәк тә әдәби тел белән тыгыз бәйләнештә өйрәнү сорала.

Ф. Мусин Г. Ибраһимовның инкыйлабтан соңгы иҗатын фәнни-теоретик планда өйрәнү бурычын хәл итү хәзер бер үк вакытта актуальләшә дә һәм катлаулана да дип билгели. Автор моны совет чоры әдәбиятыбызны хәзерге фәнни карашлардан чыгып анализлауда һәм бәяләүдә Г. Ибраһимов кебек әйдәп баручы әдипләр иҗатыннан аерылгысыз булуда күрә, чөнки мондый иҗатларда әдәбиятыбызның әлеге бик катлаулы һәм каршылыклы чордагы хәл-әхвәле аеруча ачык чагыла. Икенчедән, «совет чоры әдәбиятын яңача өйрәнү кебек гаять авыр бурычны хәл итү беренче чиратта Г. Ибраһимов шикелле флагман әдипләр иҗатына нигезләнеп алып барылырга тиеш» [2, б. 18].

Шулай ук Г. Ибраһимовның совет чоры иҗатын теоретик планда өйрәнгәндә, бу дәвергә караган мирасын социалистик реализм кысаларында гына бәяләү үзен акламавы да дәлилләнә. Автор фикеренчә, язучының «Татар хатыны ниләр күрми» һәм «Безнең көннәр» романнарының 20 нче елларда дөнья күргән беренче вариантлары, яңа чынбарлыкка багышланган «Яңа кешеләр» драмасы һәм «Кызыл чәчәкләр» повесте башлыча романтик ысул белән язылганнар. Гомумән алганда, Ф. Мусин әлеге мәкаләдә бүген дә актуальлеген югалтмаган хәл ителәсе мәсьәләләрне күтәрә.

Г. Ибраһимов иҗатын өйрәнүгә багышланган икенче зур күләмле мәкалә «Күләгәдә ниләр бар?» дип атала. Мәкалә Г. Ибраһимовның күренекле якташы М. Акмулла кебек үк әдәбияттагы яңарыш өчен көрәштә әйдәп баручы булуын дәлилләү белән башлана: «...якташының эшен дәвам итеп, Г. Ибраһимов XX йөз башында яңарыш өчен көрәштә әлеге хәрәкәтнең лидерларының берсенә әверелә. Акмулла белән Г. Ибраһимов эшчәнлеге халкыбызның гасырлар дәвамында мөһим милләтара миссия башкаруын ачык чагылдыра. Ягъни башкорт, казах һәм башка төрки халыкларның иҗтимагый-рухи тормышында да актив катнашып яки аны үз әсәрләрендә яктыртып, алар төрки дөньяның күренекле эшлеклеләренә әверелде» [3, б. 42]. Ф. Мусин мәкаләдә Г. Ибраһимов эшчәнлеге мисалында татарның әлеге милләтара миссиясе әле бик аз өйрәнелгән хәлдә калуын, халкыбызның төрки дөньядагы абруен күтәрә торган бу мәсьәләне хәл итү өчен Г. Ибраһимовның шул юнәлештәге эшчәнлеген тагын да ныграк өйрәнергә чакыра.

Галим Г. Ибраһимовның татар әдәбиятындагы роленә тукталып, аны өйрәнү өлкәсендәге эшлисе эшләрне ачыклый. Иң элек ул әдипнең XX йөз башындагы иҗатын һәм идея, һәм эстетик яктан тагын да нигезләбрәк, бер үк вакытта күпмедер яңартып та өйрәнү кирәклеген ассызыклый: «...үткән елларда бу иҗат күбрәк шул вакыттагы идеологиягә нигезләнеп яктыртылды, нәтиҗәдә бигрәк тә аның милли максатчанлыгы һәм асылы күләгәдәрәк калдырылды. Чынлыкта ул Г. Исхакый кебек үк милләтпәрвәр әдип һәм иҗатында милләт яшәеше белән язмышының мөһим мәсьәләләрен үзенчәрәк яктыртты. Г. Ибраһимовның бу чор иҗатын теоретик планда өйрәнү дә әле байтак дәрәҗәдә киләчәк эше булып кала. Биредә, бигрәк тә, жанр һәм стиль мәсьәләләре игътибар сорый. Чөнки бу яктан Г. Ибраһимов әсәрләре узган гасыр башы татар прозасында шактый үзенчәлекле урын алып тора һәм аның кызыклы поэтик сәхифәсен тәшкил итә» [3, б. 43].

Бу мәкаләдә дә галим Г. Ибраһимовның XX гасыр башындагы мирасында тәнкыйть белән әдәбият фәненә караган хезмәтләрен дә читләтеп үтми. Аерым алганда, Ибраһимовның Тукайга биргән кайбер бәяләрнең объективлыктан читтәрәк торуын һәм шуның белән күп төрле бәхәсләргә сәбәпче булуын искәртә. Шулай ук галим язучының теге-бу әдипнең иҗат максатын яки юнәлешен исәпкә алмыйчарак һәм шәхси карашлардан чыгып кына фикер йөртүгә мисал итеп «Татар шагыйрьләре» хезмәтен дә күрсәтә. Мәсәлән, ул язучының, бер яктан, Тукайның иҗат эволюциясен гомуммөселманлык идеясеннән татарлыкка күчү рәвешендә күзалласа һәм шул нигездә теленең дә халыклашуын таныса, икенче яктан әлеге халыклашуның шагыйрьнең гомумән стиленә тәэсирен бер яклырак аңлата һәм бәяли. Ачыграк әйтсәк, үз халкының авыр тормышын һәм аянычлы язмышын чагылдыру максатында, Тукайның шигъرияттәге традицион «югары» өслүбтән гавамгә якын «түбән» өслүбкә күчүен Ибраһимов кабул итеп бетерә

алмый. Гомумән, поэзиягә романтик караштa торган, ягъни аны илаhилык, гүзәллек һәм нечкә хисләр дөньясы итеп караган Ибраһимовка Тукайның шигъриятне «җирләштерергә» омтылуы ошап бетми. Моның нәрсәгә китерүен ул берничә мисалда күрсәтеп бирә. Әйтик, «шагыйрь» һәм «сөю» төшенчәләрен синонимнар итеп караган Ибраһимовка Тукай мәхәббәт турында язганда бу хис белән үзе илһамланмый һәм укучыны да илһамландыра алмый кебек тоела, һәм ул Тукайның бик борынгыдан шагыйрьләрне әсир итеп килгән әлеге хисне чагылдырган шигырьләрен болай бәяли: «...болар бит йөрәк ялкыныннан түгел, тел вә баш хезмәтеннән генә туарга мөмкин». Галим үзенең моның белән килешмәвен белдерә һәм ул «Тукайның мәхәббәт турында кайчак салкынрак кан белән һәм күбрәк акылга нигезләнеп язуын, күрәсең, шагыйрьнең шәхси язмышы белән, ягъни кыска гына гомерендә саф мәхәббәтне ныклап татып өлгерә алмавы» [3, б. 44] белән аңлата.

Г. Ибраһимов үз мәкаләсендә Тукайның табигать күренешләрен укучыга тәэсирле итеп сурәтли алмавын да искәртә, һәм бу хәлне шагыйрьнең әлеге күренешләрне традицион рухта күзаллаудан читләшүе белән бәйләп аңлата. Мәсәлән, яз, Ибраһимовча, моңа кадәр «йөрәкне кузгатырлык вә рухка сәгадәт бирерлек җәмал вә гүзәллек» дөньясы, ә көз «адәмгә картлыкларны, үлемнәрне искә төшерә вә шундый тәэссорат, күңелсезлек уята». Тукай исә, яз һәм көз турында язганда, әлеге стереотипны юкка чыгара. Шунлыктан аның шигырьләрендә, Ибраһимов фикеренчә, «язны да хис кыйлмыйсың, көзне дә».

Бу күренешне Ф. Мусин Ибраһимовның Тукай әсәрләрендәге табигать сурәтләнешен кайчак кабул итә алмавы, гомумән алганда, аларның бу дөньяны поэзиядә яктыртуга төрлечәрәк караулары белән аңлата. Аның фикеренчә, Ибраһимов табигать күренешләрен шигърияттә тасвирлауның төп максатын аларны кешеләрдә иң күркәм һәм изге хисләр тудыручы гүзәллек дөньясы итеп сурәтләүдә күрсә, Тукай әлеге күренешләргә күбрәк үзенең билгеле бер уй-фикерен чагылдыру чарасы итеп карый. Ибраһимов искә алган «Яз», «Яз галәмәтләре» һәм «Көз» кебек шигырьләрендә ул, мәсәлән, яз белән көзне милләт язмышы турында уйларын чагылдыруда файдалана бип белдерә. Ике бөек шәхес арасындагы бәхәсне галим Г. Ибраһимовның Тукайның реалистик халыкчан иҗатын романтикларча бәяләү нәтиҗәсе дип аңлата.

Хәлле һәм зыялы гаиләдә тәрбияләнеп, романтик рухлы шәхес булып формалашкан яшь Ибраһимовның ул вакытта әле тормышка да, әдәбиятка да еш кына шундый караштa торуын билгели. Мәсәлән, ул Г. Ибраһимовның поэзияне күбрәк хис дөньясы итеп күзаллавын, ә тумыштан ук диярлек ятим калып, балачактан ук тормышның ачысын җитәрлек татыган Тукай исә яшәешкә аек акыл белән караучы һәм шәхес булып җитлегүен, шунлыктан иҗатында да акыл, уй-фикер өстенлек алуын раслый. Шул нигездә галим романтик Ибраһимов белән реалист Тукайның иҗатларында идея-эстетик яктан кызыклы гына аермалар булганлыгын, һәм хәзер бу ике әдипнең XX гасыр башында бер-берсенә мөнәсәбәтен ачыклаганда, шушы хакыйкатьне истә тотарга чакыра.

Моннан тыш, мәкаләдә Ф. Мусин Г. Ибраһимов тормышында тагы бер мөһим чорны – совет чорындагы фаҗигале язмышын яктыртуга игътибарны арттырырга кирәклеген әйтә. Биредә сүз әдипнең үзе ихластан хезмәт иткән системаның корбанына әверелүен ачу турында бара. Аның бу чор иҗатын яңартып өйрәнгәндә исә, беренче чиратта, аны революциягә кадәргесе белән

күчемле бәйләнештә анализлауга дикъкатьне көчәйтү сорала. Мәгълүм ки, моңа кадәр бу иҗатның әлеге ике дәверен бер-берсеннән аерып карау, ә кайчакта хәтта капма-каршы куюда күзәтелә иде. Галим фикеренчә, бу ялгыш позициядән арынып, хәзер Ибраһимов прозасының ике чорын үзара бәйләнештә өйрәнү XX йөз татар әдәбиятын, аның ике мәгълүм дәвере арасында билгеле бер каршылыклар булуга карамастан, бербөтен әдәби процесс итеп күрсәтүгә булышачак. Чөнки Ибраһимов әдәбиятыбыз тарихында XX йөз башы белән совет чорын үзара бәйләп торучы күпер вазыйфасын башкарды. Бу эш бер үк вакытта Ибраһимовның совет чорындагы иҗат эволюциясен дә нигезләбрәк ачарга булышачак. Галим искәртүенчә, тикшеренүләрдә әдипнең бу чор иҗатындагы тагын бер үзенчәлеге әле һаман игътибардан читтәрәк кала. Монда сүз авторның заман идеологиясенә бәйле рәвештә әйтергә теләгәне белән әсәрнең объектив мәгънәсе арасында кызыклы гына аерма хасил булуы турында бара. Бу үзенчәлекне бигрәк тә «Кызыл чәчәкләр» повесте белән «Тирән тамырлар» романы мисалында ачыкларга мөмкин. Аларда әсәрнең язучы таланты белән тудырылган объектив мәгънәсе авторның башта үз чоры рухында әйтергә теләгәненнән киңрәк тә, тирәнрәк тә булып чыккан. Ни кызганыч, бүгенге көндә дә бу мәсьәлә ачык булып кала бирә.

Шулай ук галим язучының 20 нче еллар иҗатын, аерым алганда идеологик сәбәпләр аркасында совет чорында онытылуга дучар ителгән «Адәмнәр» повесте соңгырак вакытларда кабаттан өйрәнелә башласа да, аның идея-эстетик кыйммәте һәм 20 нче еллар әдәбиятында тоткан урыны әле тиешенчә ачылмавын; Г. Исхакыйның «Дулкын эчендә» пьесасы, Ф. Әмирханның «Шәфигулла агай», Ш. Усмановның «Шәмсетдин бай» повестьлары кебек, бу әсәр дә үзенең объектив мәгънәсе белән совет системасына тәнкыйтьчел карауга корылуын, шушы позиция повестьның жанр һәм стиль табигатенә дә эз салуын билгеләп үтә. Ягъни ул елларда әдәбиятта илдә төзелә торган яңа җәмгыятьне романтик планда һәм оптимистик формаларда яктырту хакимлек иткәндә, Г. Ибраһимов шушы ук җәмгыятьтә барлыкка килгән, дөресрәге, китерелгән ачлыкны үтә кырыс буяулар берән сурәтли. Табигый, бездәге социализмны дөньядагы иң гадел һәм кешелекле җәмгыять дип күрсәткән совет пропагандасы бу әсәрне кабул итә алмый, ул яңа тормышны каралтып тасвирлауда гаепләнә. Әлбәттә, хәзер исә аны совет җәмгыятендә дә социаль фаҗигаләр булганлыгын һәм аларны яктырту өчен трагедия жанры кирәклеген раслаган әсәр дип карарга һәм бәяләргә кирәк.

Г. Ибраһимовның совет чоры мирасының мөһим өлешен тәнкыйть һәм әдәбият фәненә караган хезмәтләре тәшкил итә. Ф. Мусин бу өлкәдә дә тикшеренүләрне дәвам итү кирәклегенә туктала. Хәзер инде без бу юнәлештә галимне борчыган әлеге мәсьәләнең күпмедер дәрәҗәдә хәл ителешен күрәбез, Т.Н. Галиуллин, Д.Ф. Заһидуллина, Т.Ш. Гыйләҗев һ.б. галимнәребезнең күпсанлы фәнни-тәнкыйди эзләнүләре шуны раслый.

Милли әдәбиятыбызның классигы, XX гасыр татар тарихындагы бөек шәхес Г. Ибраһимов мирасы – бәяләп бетергесез зур хәзинә. Шушы рухи хәзинәне киң катлау укучыларга җиткерүдә армый-талмый хезмәт итүчеләр өчен Флүн Мослах улы Мусинның Г. Ибраһимов иҗатын өйрәнүгә багышланган күпсанлы башка фәнни хезмәтләре дә киләчәктә бик күп яңа эзләнүләргә нигез булып торачагы бәхәссез.

ӘДӘБИЯТ

1. Даутов Р.Н., Рахмани Р.Ф. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 2 т. Б. 171–173.

2. Мусин Ф.М. Г. Ибраһимов иҗатын өйрәнүнең торышы һәм бурычлары // Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман: Тууына 115 ел тулуга багышланган фәнни конференция материаллары. Казан: Фикер, 2002. Б. 12–19.

3. Мусин Ф.М. Күләгәдәниләр бар? // Татарстан. 2007. № 3. Б. 42–45.

## ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫҢ БӨЕК ОСТАЗЫ

*Гайнетдинов А.М.*

Статья посвящена анализу религиозных взглядов выдающегося ученого Шихабутдина Марджани, которые повлияли на мировоззрение, убеждения и жизнь Галимджана Ибрагимова. Этот ученый был для него как духовный наставник и образец для подражания, который своим примером воспитал в нем достойные качества и повлиял на его будущее.

The article is devoted to analysis of the religious views of the outstanding scientist of Shihabutdin Marjani, which influenced the attitudes, beliefs and lives of Galimdzhan Ibragimov. This scientist was for him as a spiritual mentor and role model, who taught him decent quality and affected his future.

Галимҗан Ибраһимов – мәшһүр язучы, фән галиме, күренекле җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе генә түгел, ә үзен дин белгече буларак та таныткан шәхес булган дияргә мөмкин. Ул төрле дини уку йортларында төпле дини белем алган: башта авыл мәдрәсәсендә, аннары 1898–1905 елларда Оренбургның «Хөсәения» дини уку йортында укыган, 1906 елның көзендә исә Уфадагы «Галия» мәдрәсәсендә өч ел гыйлем туплаган. Шул сәбәпле, Г. Ибраһимовның ислам тәгълиматларын, дини фәлсәфәне яхшы белүе төрле әсәрләрендә, мәкаләләрендә ачык сизелә.

1915 елда, бөек җәдидче галим, тарихчы, педагог, этнограф, шәркыять белгече, дини реформатор Шиһабетдин Мәрҗанинең тууына 100 ел тулу мөнәсәбәте белән, төрле искә алу чаралары үткәрелгән, мәкаләләр язылган, хәтта Салих бине Сабит Гобәйдуллин тырышлыгы белән «Мәрҗани» дигән аерым бер китап та басылып чыккан. Бөтен татар газета-журналларында диярлек Шиһаб хәзрәтнең тормыш юлын һәм эшчәнлеген яктыртуга багышланган чагыштырмача күп мәкаләләр басылып чыккан. Шул исәптән, Г. Ибраһимовның да «Аң» журналында әлеге бөек татар галименең кайбер хезмәтләре хакында ике саллы мәкаләсе дөнья күргән: «Бөек остазымызның кайбер тәэлифләре. Юбилей мөнәсәбәте илә тәнкыйть» һәм «Бөек остазымызның тарихи бер тәнкыйте». Беренчесен галим Хәй Хисмәтуллин, гарәп графикасыннан кириллицага күчереп, бераз кыскартулар белән кабат бастырып та чыгарган [2, б. 48–61]. Ләкин анда кайбер хаталар җибәрелгән һәм мәкалә дә журналның беренче санында түгел, ә икенчесендә басылып чыккан дип күрсәтелгән [2, б. 61].

Г. Ибраһимовның «Бөек остазымызның кайбер тәэлифләре. Юбилей мөнәсәбәте илә тәнкыйть» мәкаләсе Ш. Мәрҗанинең атаклы «Нәзурәтел-хак» (китапның тулы исеме «Нәзурәтел-хаккый фи фәрадыйятил-гыйшаи вә ин ләм ягыйбәш-шәфәкъ» – «Шәфәкъ кызыллыгы бетмәсә дә, төнге намазның фарызлыгы өстән төшмәве хакында хакыйкатьне карау»)

һәм «Мөстәфадел-әхбар» (китапның тулы исеме – «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» – «Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр») хезмәтләрен фәнни-объектив бәяләүгә һәм анализлауга багышланган. Мәгълүм булганча, «Назүрәтел-хак» әсәре 1870 елда дөнья күреп, бөтен ислам галәмен диярлек тетрәндергән һәм уйланырга мәҗбүр иткән. Ул халыкны аң-белемгә, иҗтиһадка (шәригать мәсьәләләрен үзлектән тикшереп, мөстәкыйль фикер йөртүгә) чакырган һәм схоластикадан, тәкълидтән (элекке дин галимнәренә, мәзһәбләргә сукырларча иярүдән) арынырга өндәгән. Г. Ибраһимов искәртеп узганча, бу әсәр башка ислам галимнәренең хезмәтләреннән язылу тәртибе, өслүбе ягыннан берни белән аерылмаса да, эчке ягы белән бөтенләй үзгә, үзенчәлекле икәнлегенә басым ясаган. Җәдидче галим үзе дә тышкы кыяфәте белән башка дин әһелләре кебек булса да, үзенең эчке рухи дөньясы, дини карашлары белән алардан нык аерылып торган. Г. Ибраһимов фикеренчә, ул һәр акылы булган кешене, «иҗтиһад ишекләре»н ачып, Коръән һәм хәдисләр белән шәригать мәсьәләләрен үзлегеннән тикшереп, мөстәкыйль фикер йөртергә, нәтиҗә ясарга чакырган.

Хәй Хисмәтуллин, Мәрҗани динне дөньядан һәм тормыштан, фәнне диннән аерган [9, б. 20], «фән һәм сәламәт акыл диннән өстен» дигән тезисны күтәргән, дип яза [9, б. 30]. Бу, әлбәттә, дөреслеккә туры килми, чөнки ул исламны фәкать төрле әкият-хорафатлардан, элекке галимнәрнең ялгыш фикерләреннән арындырып, киресенчә, динне тормыш һәм фән белән бәйләгән.

Г. Ибраһимов Шиһаб хәзрәтнең хезмәтләре белән яхшы таныш булган: «Нәзурәтел-хак», «Әл-бәркыль-вәмид» һәм башка әсәрләрен мәдрәсәдә укыган чагында бик дәртләнеп укыган [1, б. 12], «Мөстәфадел-әхбар» китабын да укып чыгып, шуңа карата да уңай фикерләрен язган [1, б. 16–19].

«Назүрәтел-хак» әсәре, гомумән алганда, ястү намазының җәйге көннәрдә дә өстән төшмәве, шәфәкъ кызыллыгы бетмәсә дә, барыбер аны уку мәҗбүри икәнен исбат итүдән гыйбарәт. Ләкин бу мәсьәләгә карата җавабын язу алдыннан Мәрҗани бик озын кереш өлеш язган һәм менә шунда аның инкыйлаби фикерләре мәйданга чыккан, халыкны сукырларча дини мәзһәбләргә иярергә түгел, ә, бәлки, исламның төп чыганаклары булган Коръән һәм хәдисләрдән дәлил тапканнан соң гына теге яки бу гамәлне яки гыйбадәтне үтәү тиешле икәнен исбатлаган. Г. Ибраһимов әлеге хезмәтнең асыл кыйммәте төп өлешендә түгел, ә озын мөкаддимәсендә, ягъни китапның беренче алтмыш битендә икәнлеген искәртеп, түбәндәгечә яза: «Мөкаддимәдәге фикерне берничә сүздә җыярга туры килсә: Аллаһ азат яраткан акылга богау салмагыз, мөэминнең фикере хөр, менә Коръән, менә хәдис – шуларны өйрәнсен дә үзе аңлаганча ышансын вә гамәл кылсын. Мин үземнең һичкемнең фикер һәм мәзһәбенә иярергә мәҗбүрмен дип белмим... рәвешенә нәтиҗә ясарга мөмкин иде» [1, б. 13].

Г. Ибраһимов үзе укыган мәдрәсәдә ни рәвешле укытканнарын да кыскача әйтеп узган: анда схоластик белемнәр биргәннәр, урта гасырда яшәгән галимнәрнең сүзләренә сукырларча иярергә өйрәткәннәр, төрле гыйбарәләрне аңламыйча, фикерләмичә, ятлату белән мәшгуль булганнар. Мәсәлән, игътикад өлкәсендә әшгари яки матүриди, фикыһ өлкәсендә хәнәфи мәзһәбенә (ягъни Әбү Хәсән Әшгари, Әбү Мансур Матүриди, Әбү Хәнифә атлы борынгы галимнәргә) иярүне мәҗбүри итеп куйганнар, моны эшләмәүчеләрне җәһәннәм белән куркытканнар. Г. Ибраһимов язганча, элекке ка-

димче мөдәррисләр «әшгари», «хәнәфи» сүзләре белән шәкертләрнең йөрәген һәм акылын томалаганнар: «Бисмилла», «Аллаһ», «Коръән» сүзләре белән янәшә өйрәтелгән ул «әшгари», «хәнәфи» сүзләре безгә, бер безгә генә түгел, һәр мөселман баласына җиде яшьтән керә башлап, мохитның тәэсир итә баруы белән алар йөрәкнең төбенә кадәр тамыр җәеп, бөтен гакли хәятны каплап ятканнар [1, б. 13].

Ни өчендер Г. Ибраһимов үзләрен мәдрәсәдә, ышану өлкәсендә әшгари һәм хокук өлкәсендә хәнәфи мәзһәбләрендә булырга кирәк, дип укытканнарын сөйли. Гадәттә, элекке татар мәдрәсәләрендә әшгари түгел, ә матүриди өйрәтмәләрен сеңдерергә тырышканнар, әшгари гакыйдәсе исә Төньяк Кавказ якларында киң таралган. Бу очракта Г. Ибраһимов ялгыш сөйли (тик бу версиягә ышануы кыен) яисә, чыннан да, Оренбург мәдрәсәсендә әшгари гакыйдәсе өйрәтелгән булып чыга. Бәлки, андагы мөгаллимнәр Төньяк Кавказда (мәсәлән, Дагыстанда) гыйлем алганнар һәм шәкертләргә анда укытылган белемнәр буенча дәрес биргәннәр булса кирәк.

Г. Ибраһимов язганча, бөек дини реформатор югарыда искә алынган мәсьәләләрне күтәреп, кешеләрнең дини авторитетларга сукырларча иярүен нык тәнкыйтьләгән, иҗтиһадка чакырган, тәкълидтән тыйган. Ул заманда Коръән-хәдисне гади кешегә аңларга һәм аларга мәгънә бирергә ярамый, дигән фикер куәтле булса да, Мәрҗани иҗтиһад капкаларын ачкан һәм башкаларны да шул капкадан керергә чакырган. Моның өчен Коръәнне, йөзләгән хәдисләрне яттан белү таләп ителмәвен, бу бары тик галимнәр эше түгел икәнлекне аңлатырга тырышкан. Ислам чыганакларын белгән мөселман үзе үк галим-мөҗтәһидкә әйләнә һәм шәригать мәсьәләләрен үзе тикшереп, мөстәкыйль фикер йөртә, нәтиҗә ясый ала, дип санаган галим. Әхмәдһади Максуди Мәрҗанинең әшгари белән матүридигә бернинди катнашы булмаганлыгын белдергән: «Игътикадта әшгари түгел, матуриди дә булмады, мөгътәзили яки шигый да түгел иде, ләкин Мәрҗани иде. Мәрҗанилеге дә Коръән вә Сөннәткә тулысынча иярүдән һәм болардан башкаларның һичберенә дәлилсез иярмәүдән гыйбарәт иде» [4, б. 454].

Мәшһүр дин галиме Ризаэтдин Фәхретдин гакыйдә китапларының шул әшгари белән матүриди мәзһәбләренең фикерләре белән тулганлыгына кайгырып түбәндәгечә язып калдырган: «Ислам дөньясында Әһлес-сөннә вәл-җәмәга юнәләше исеме белән укыла торган гакыйдә китапларының Әһлес-сөннә вәл-җәмәга юнәлеше булудан бигрәк кәлам әһеле, ягъни әшгари вә матүридиләр юлы икәнлеген, анда булган темаларның Коръән вә сөннәткә туры килүдән бигрәк тә мөгътәзиләләрне кире кагу нигез итеп алынганлыгы аңларга вә шушы фикерне Аллаһ ризасы өчен һичкемнән курыкмый сөйләргә тиешле иде» [8, б. 285]. Шулай ук ул, Әбү әл-Хәсән әл-Әшгари белән Әбү Мансур әл-Матүридигә иярүчеләр генә чын мөселман була, дип хаслап әйтүнең дәлилсез, надан кешеләрнең үз хыяллары белән әйтелгән сүзләр, дип яза [7, б. 110].

Г. Ибраһимов исламда булмаган, ләкин наданнар тарафыннан дингә көчләп тагылган ялган ышануларны бер-бер артлы тасвирлап, шундый бозык игътикадлар аркасында кешенең фикере «шундый богаулар белән богауланып, мәңгелек таш зинданга бикләнгәнлеген» сөйләгән, бөтен ислам дөньясын бу бәладән коткаручы шәхес итеп Ш. Мәрҗанине санаган. Дөрес, аңа хәтле Габденнасыйр Курсави да халыкның акылына салынган богауны өзәргә тырышкан, тик, Г. Ибраһимов фикеренчә, аның халыкка тәэсире алай

ук көчле булмаган. Белгәнебезчә, Мәрҗани әйткән фикерләрне иң беренче булып күренекле дин галиме Г. Курсави инде XIX гасыр башында ук әйткән. Үзләренең ирекле карашлары өчен аларның икесенә дә кадимчеләр тарафыннан «кяфер», «имансыз» мөһере сугылган. Шулай ук Исмәгыйль Гаспралы, Габдерәшид Ибраһим да Шиһаб хәзрәт кебек хәлне үзгәртә алмадылар, дип санаган Г. Ибраһимов.

Хәзерге заманда безгә «Нәзурәтел-хак» әсәренең ни рәвешле көчле тәэсир иткәнлеген аңлавы кыен, аны фәкать шул чорда яшәгән мөселманнар гына бөек реформаторның батырлыгын, бөеклеген, олуг дәрәҗәсен хакыйкый рәвештә күрә һәм тоя алганнар. Г. Ибраһимов та, ничә еллар буе фанатизм белән сугарылган бозык ышанулар зинданында ябылып яткан, соңра Мәрҗани аркасында азат ителгән кеше буларак, «Нәзурәтел-хак» хезмәтенә иң югары бәя биргән.

XX гасыр башында күтәрелгән дини проблемалар бүгенге көндә дә бик актуаль, әйтерсең лә, Г. Ибраһимов мәкаләләрен хәзерге заманда яшәүче милләттәшләребезгә юллаган, чөнки, кызганычка каршы, хәзерге мәдрәсәләребездә дә һаман шул «матуриди», «хәнәфи» сүзләре белән шәкертләрнең йөрәкләрен һәм акылларын томалыйлар, кайбер дин әһелләре схоластика, обскурантизм, эксклюзивизм, фанатизм белән сугарылган, кадимчелектә урын алган идеяләрне халыкка көчләп такмакчы булалар. Шул ук вакытта исә үзебезнең җирлектә бөек татар мәгърифәтчеләре тарафыннан язылган китаплар, дәреслекләр читтә кала. Иманыбыз камил, әгәр дә фәкать данлыклы җәдидче галимнәребезнең хезмәтләрен тупласак һәм алар буенча гына ислам мәгарифен үстерсәк, тиз вакыт эчендә безнең динебездә экстремистик һәм радикаль карашлар, агымнар шунда ук юкка чыгар иде.

Бүгенге көндә кайбер кадими карашлы галимнәр, Мәрҗанине хәнәфилек белән тыгыз бәйләмәкче булып, аның хакында дөрес булмаган кайбер фикерләрне тараталар. Хәтта «Татар энциклопедия»сендә: «Мәрҗани, исламның гомуми нигезләмәләре хакында сүз кузгатканда, хәнәфи мәзһәбенә катгый рәвештә ияреүгә кушкан», – дип язылган [6, с. 74]. Бу зур, тупас хата, чөнки Шиһаб хәзрәт хезмәтләрендә, киресенчә, моның капма-каршысын белдергән: «Бер фәкыйһнең генә фәтваләрендә тукталып, аның мәсләгенә фанатикларча, тиешле дәлилләр белән дә нигезләмичә, ябышу ярамый» [5, с. 68]; «Чынлыкта, әгәр дә берәр галимгә ияру һәм тәкълид кылу мәҗбүри булса, бу кешеләрне кысар, уңайсызландырыр иде. Кешеләрнең тулысынча галимнәргә ияруләрендә җиңеллек һәм киңлек юк» [5, б. 69–70]; Аларның (мәзһәбләргә нигез салучыларның) берсенең булса да: «Минем мәзһәбемә генә ияр», – дип әйтүе турында һичбер хәбәр дә килмәде, ә, бәлки, моның капма-каршысы гына килде [5, б. 321]; Берәүгә дөрес хәдис ирешә икән, ничек инде аңа: «Әбү Хәнифә, я Малик, я Шафигый, я Әхмәд, я башка берәүнең фикерен белми торып, бу хәдис белән гамәл кыла күрмә», – дип әйтергә мөмкин?! [5, б. 314].

Күргәнебезчә, Г. Ибраһимов, шулай ук Р. Фәхретдин, Х. Габәши, Т. Ильяси, Һ. Атласи, Ш. Шәрәф, Г. Гыйсмәти һ.б. мәгърифәтче галимнәр Мәрҗанинең хәнәфи мәзһәбенә ияреүгә кушмаганын, ә, бәлки, Коръән һәм Сөннәткә мөрәҗәгать итеп, һәр мөселманга иҗтиһад кылып, дини мәсьәләләрдә үзләренә җавап эзләргә боерганын әйтеп калдырганнар. Галим фәкать табигатьләре белән акыллары сай, фикерләүгә сәләтсез булган кешеләргә

генә, чыгарма рәвешендә, нинди дә булса мәзһәбкә ияреpгә рөхсәт иткән [5, б. 27].

Г. Ибраһимов бөек остазын түбәндәге сүзләр һәм эпитетлар белән искә алган: бөек остаз, куәтле мөтәфәккир (фикер иясе), җәсүр (кыю) бер каһарман, гаюр (горур) каһарман, фикри хәятта революция ясаучы, зур галим, яхшы атаның баласы, Казанның беренче мөдәррисе, таң чулпаны, иң куәтле мөәссир (тәэсир итүче), даһи, даһи акыл иясе, бөек мөхәккыйк (дөреслекне тикшерүче), тар рамкаларны ватучы, яңаны ясаучы, үзенә кадәр булмаган нәрсәне тудыручы, милли тарихка нигез салучы, тарихыбызның мөҗиде (иҗат итүчесе) һ.б.

Г. Ибраһимов «Бөек остазымызның тарихи бер тәнкыйте» мәкаләсендә «Мөстәфадел-әхбар»да Мәрҗанинең «Тәварихы Болгария» әсәрендәге уйдырмаларны ни рәвешле фаш итүенә, ялган белән тулганлыгын оста исбатлавына сокланып түбәндәгечә язган: «Моны язса, сөйләсә, аны, табигый, яратмаячаклар, сүгәчәкләр, җәһәннәмгә җибәрәчәкләр, ләкин ул моңа төкерми дә; үзең ни нәрсәне хак дип ышангансың, төп игътикадың белән нинди фикерне хакыйкать дип табасың – аныңча шуны үзең ышанганча язарга тиешле. Халык яратмый, сүгә, мең төрле гөнаһларда гаепләп, сине хур итәргә тырыша, дөньяда булдыра алмаса, дингә, вөҗданыңа чабаталы аягы белән кереп, сине җәһәннәмгә җибәрә икән – барысын, теләгәнен кылсын, ике тиенлек әһәмияте юк. Үзе чын дип ышандымы, ул халыкның ничек каравын аслан игътибарга алмый – шуны сөйли, яза һәм эшли. Халыкның мондый һөҗүм вә төһмәтләренә каршы ул бер дә канын бозмый, аның бик табигый эш икәнен аңлый, аңа бер дә исе китми» [3, б. 40].

Шулай ук рухи остазының батырлыгына гаҗәпләнеп: «Замандагы халыкның өрүенә ул вакыйган бер дә илтифат итмәде, аны аңламадылар, урыныннан чыгардылар, мең төрле гаеп вә төһмәт яктылар, чабаталы аяклары белән аның саф вөҗданын таптап, аны мөгътәзилә вә кяфер ясадылар – җәһәннәмгә хөкем иттеләр. Ул һаман үз юлында, үзенең ялгызлыгы белән мәгъруp бер хәлдә дәвам итте», – дип сокланган Г. Ибраһимов [3, б. 40]. Ул үзенең рухи остазының җәмгыяттә таралган мәгънәсез гадәтләргә иярмәвен; хәтта надан байлар «бик күп лыгырдый башласалар, башка чара булмагач: «Кит, ахмак, син нәрсә аңлыйсың», – дип таяклап чыгарудан да тартынмавын; кызу полемик канга ия булганга, бәхәсләрдә дошманнарына каршы каты һөҗүм белән ташлануын; кешеләрнең кәефләре кырылмасын, сүзем ачы булмасын, дип кайгырмавын; сүзләре өчен алар миңа зыян салырлар, дип курыкмаганлыгын искәрткән. Г. Ибраһимов әлеге бөек акыл иясе һичбер вакытта хак сүзен әйтүдән тыелмаганын, башкалар турында да уенда булганын яшерергә, икейөзләнергә, һәрнәрсәне үз исеме белән атаганлыгын да мактап телгә алган. Ул Мәрҗанине фикри хәятта революция ясаучы буларак сурәтләгән, чөнки галим ул замандагы мөселман кешесенә телгә алырга да курыккан мәсьәләләрне күтәргән һәм, шул рәвешле, Г. Ибраһимов аны акыл хөррияте өчен бөтен ислам галәменә каршы барырга курыкмаучы шәхес итеп тасвирлаган. Шуңа күрә бөтен ислам дөньясы аның исемен ихтирам белән искә алуын, халкыбыз да аны бик кадерле бер урынга утыртуын әйткән Г. Ибраһимов. Үзе дә, остазына чын күңелдән рәхмәтле булып, һәрвакыт аны яхшы сүз белән генә искә алган.

Г. Ибраһимов атаклы галим Мәрҗанине фәнни яктан өйрәнүчеләрнең иң беренчеләреннән булган, чөнки шәригать мәсьәләләрен яхшы белгән,

динне дөрес аңлаган, яхшы фикерли белгән. Мәкаләләрендә ул Шиһаб хәзрәтнең холкы-әдәбе, күркәм сыйфатлары, батырлыгына сокланган һәм аны үзенең бөек остазы итеп санаган, үрнәк итеп куйган, олуг фикерләрен алган. Тормышындагы авыр мизгелләрендә ул, мөгаен, остазын исенә төшереп, алга таба көрәшергә көч табып, тагын алга баруын дәвам иткәндер. Безгә аның көчле шәхес булып тәрбияләнүендә, дөньяга карашы формалашуында, күркәм сыйфатларга ия булуында, милләтнең якты киләчәге өчен көрәшүендә, ялкынлы мәкаләләр, зәвыклы әсәрләр һәм саллы хезмәтләр язуында Шиһабетдин Мәрҗанинең зур роль уйнаганлыгын беркайчан истән чыгармаска кирәк.

ӘДӘБИЯТ


1. Ибраһимов Г. Бөек остазымызның кайбер тәэлифләре. Юбилей мөнәсәбәте илә тәнкыйть // Аң. 1915. № 1. Б. 7–19.

2. Ибраһимов Г. Бөек остазымызның кайбер тәэлифләре (юбилей мөнәсәбәте илә тәнкыйть). Казан: Татар. кит. нәшр., 1968. Б. 48–61.

3. Ибраһимов Г. Бөек остазымызның тарихи бер тәнкыйте // Аң. 1915. № 2. Б. 39–47.

4. Мәрҗани: Фәнни-популяр җыентык. Казан: Җыен, 2010. 704 б.

5. Мәрҗани Ш. Нәзурәтел-хаккый фи фәрадыйятил-гыйшаи вә ин ләм ягыйбәш-шәфәкъ / Ш. Мәрҗани. Казан: Хозур, 2013. 336 б. (Гарәп телендә).

6. Татарская энциклопедия: В 6 т. / гл. ред. М.Х. Хасанов, ответ. ред. Г.С. Сабирзянов. Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 2008. Т. 4: М–П. 768 с.

7. Фәхреддин Р. Җәвамигыль-кәлим шәрехе. Оренбург, 1916. 552 б.

8. Фәхретдин Р. Мәрҗани җыентыгына күзәтү // Шура. 1915. № 9. 285 б.

9. Хисмәтуллин Х. Шиһаб Мәрҗани // Шиһабетдин Мәрҗани. Казан: Татар. кит. нәшр., 1968. Б. 20.


## Ә. ЕНИКИ ҺӘМ Г. БӘШИРОВ ТӘНКЫЙТЕНДӘ Г. ИБРАҺИМОВ ШӘХЕСЕНӘ КАРАШ


***Гайнуллина Г.Р.***



Классики татарской литературы А. Еники и Г. Баширов считают своим наставником великого татарского писателя Г. Ибрагимова. В публицистике писателей ярко отображена личность духовного наставника. По мнению писателей второй половины XX века, Г. Ибрагимов является основателем татарской прозы.

Classics of tatar literature A. Eniki and G. Bashirov believe his mentor, the great tatar writer G. Ibragimov. In journalism, writers vividly displayed the personality of a spiritual mentor. According to the writers of the second half of the twentieth century, G. Ibragimov is the founder of tatar prose.


Һәр чор, һәр милли әдәбиятның үзенчәлекле сыйфатлары бар, шуларны ачыклау, табу, мөмкин кадәр күбрәк һәм төгәлрәк билгеләү әдәбият хакында сөйләшүне, аны бәяләүне дә төгәлләштерә. Рухи мирасыбызның, милли хәзинәбезнең бай катламын әдәби-тәнкыйди мирас тәшкил итә [4, б. 512]. Язучылар әдәби барышның һәр дәверендә иҗатларын тәнкыйди эшчәнлек белән бергә кушып, үреп баралар. «Тәнкыйди фикер, карашлар тарихы урта гасырларны иңләп, борынгы чорга, халык авыз иҗатына барып тоташа да, әдәбият белеменең бу тармагы, фән буларак, XX гасыр башында калыплаша һәм әдәби хәрәкәттә күп мәсьәләләргә бәя биреп, мөнәсәбәт белдереп, татар сүз сәнгатенең сыйфат яңарышында, күтәрелешендә зур роль уйный» [3, б. 3].

Мәгълүм булганча, XX гасыр башы «өр-яңа сүз сәнгатенә, реалистик әдәбиятка нигез сала. Шушы әдәбиятны бәяләү өчен әдәби тәнкыйтьне үстерү ихтыяҗы барлыкка килә» [6, б. 3]. Әдәбият галиме Д. Заһидуллина карашынча, XX йөзнең 1960–80 еллары – татар әдәбиятының милли нигезләргә кайту чоры – татар прозасында яңа эзләнүләр, яңа сукмаклар, психологизмның, тәнкыйди башлангычның көчәюе, лирик-эмоциональ башлангыч алга чыгуы, публицистик башлангычның урын алуы кебек сыйфатларның алга алынуы, стиль тенденцияләренең, сәнгати алымнарның байлыгы белән билгеләнә [7, б. 4]. Хәлбуки, милли нигезләргә кайту чоры әдәбиятында әдәби тәнкыйть тә милли әдәбиятны бәяләү җәһәтеннән башка югарылыкка күтәрелә. XX йөзнең 1960–80 еллары татар прозасын өйрәнүгә мөнәсәбәтле әдәби-тәнкыйди материал язучы иҗатын, әдәби-мәдәни барышка бәя кысаларында билгеле күләмдә өйрәнелә килә. Әдипләрнең үз тәнкыйди эшчәнлегеннән, каләмдәшләренең аның әсәрләре хакында әйтелгән бәя-хөкемнәрдән башка язучының әдәби эшчәнлеген күзаллау мөмкин түгел.

Әдәбият галиме Ә. Закирҗанов карашынча, әдәби тәнкыйтьнең зур өлешен язучы тәнкыйте тәшкил итә [8, б. 250]. Галим XX гасырның икенче яртысында бу күренешнең аеруча активлашуын билгеләп үтә. Аерым бер проблеманы бергәләп хәл итү турында уйлану, әдәби барышның киләчәген фаразлау максатыннан әдәби тәнкыйтьнең язучы тәнкыйте дип исемләгән төре аеруча әһәмияткә ия. Язучыларның тәнкыйди язмалары күпсанлы матбугат битләрендә һәрдаим дөнья күрә.

Татар әдәбияты классигы Г. Бәшировның «Көзге ачы җилләрдә» документаль әсәрендә (1983–1985) язучының шәхси тормышы, әдәби иҗатка килүе, әдәбият мәйданында исем алуы турындагы истәлекләре бәян ителә. Әсәрдә XX йөз башы, егерменче-утызынчы еллар, Бөек Ватан сугышы чорындагы әдәби-мәдәни барышка кагылышлы гаҗәеп кызыклы һәм ачык фикер-карашлар, татар әдәбияты классиклары турында бәһаләп бетергесез фактлар тәкъдим ителә. Язучыларның тормыш юлы, даирәсе турындагы документаль характердагы материалның шул чор әдәби мохитенең үзендә кайнаган язучы җиткерүе гаять әһәмияткә ия. Әсәрдә Г. Ибраһимов, Ш. Камал, М. Галәү, Х. Туфан, Г. Гали, Г. Толымбайский кебек әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлына кагылышлы фактлар төрле әдәби тәнкыйть жанрлары кысаларында тәкъдим ителә.

Истәлекләр арасында иң кыйммәтлеләреннән берсе дип Г. Ибраһимов турындагысын атап үтәргә мөмкин. Г. Бәширов өлкән остазы турында кайта-кайта сөйли, тулы бер иҗат очеркы тудыра. Иҗат очеркында төп игътибар язучының уй-фикерләренә, сәнгать элементларын һәм иҗат биографиясен бәяләүгә юнәлтелә: «Ул үз-үзенә дә, яшьләргә дә бик таләпчән булды. Галим башлы, шагыйрь йөрәкле бу революционер реалистик прозабызга киң юл салучы, республикадагы гыйльми үзәкнең председателе һәм РСФСР Художество академиясенең фәхри әгъзасы, барыннан да бигрәк зур талант иясе булса да, аның белән сөйләшкәндә, үл үзенең өстенлеген сиздермәс һәм син үзеңне «кечкенә кеше» итеп хис итми идең. Аның белән утырганда тормыш ничектер баерак, мәгънәлерәк булып күренә, дөньяны тагын да биегрәк ноктадан күрәсең кебек тоела башлый иде. Авыру сәбәпле үзе Ялтада яшәсә дә, без аның әдәбиятыбызга йогынтысын һәрвакыт сизеп тордык» [1, б. 81–82]. Г. Бәширов өлкән әдипнең атлар яратуын, хәтта республикада

атлар саны кимүе өчен борчылуын билгеләп үтә. Әдип һәм галим буларак республикада гына түгел, бөтен Урта Азиядә һәм Казахстанда танылган олы дәрәҗәле кеше булуына карамастан, үзен тәкәббер тотмавына соклана.

Әйтергә кирәк, Г. Ибраһимовның үзе белән очрашулар күп кенә каләмдәшлернең истәлек язмаларында урын ала. Бу җәһәттән әдәбият гыйлемендә шактый эзләнүләр барлыгын билгеләп үтү зарур. Л. Минһаҗева карашынча, язучы И. Салаховның әдәбиятка ныклап юл алуы Г. Ибраһимов исеме белән бәйләнгән була [9, б. 12].

Татар әдәбиятының йөзек кашы Ә. Еники «Хәтердәге төеннәр» исемле җыентыгында Г. Ибраһимов шәхесенә аерым язма багышлый. «Безне ул өйрәтте» дип исемләнгән мәкаләсендә ул үзен «Галимҗан мәктәбе» вәкиле дип исемли [5, б. 9]. Мәкалә Г. Ибраһимовның язучы буларак теленә һәм стиленә игътибар бирү ягыннан әһәмияткә ия. Әдип алдан ук «бу гаять зур, колач җитмәс эшне» [5, б. 7] үз өстенә алуның ни дәрәҗәдә җаваплы булуына басым ясап үтә. Мәкалә әдәби текстта хикәяләү алымнарын нәзари яссылыкта барлауга йөз тота. Ә. Еникинең бу фикер-карашлары әдәбиятчылар тарафыннан билгеле күләмдә яңгыратылуын да ассызыкларга кирәк [2, с. 204].

Проблемалы мәкалә жанрына тартым әлеге хезмәтендә Ә. Еники болай яза: «Галимҗан Ибраһимовка кадәр безнең яңа проза бик яшь иде әле. …Асылда Европа төшенчәсендәге проза әдәбияты бездә XX йөзгә кергәч кенә күтәрелеп китә. Ләкин ул чактагы роман, повесть, хикәяләрнең теле никадәр чуар, стиле (хикәяләү алымы) никадәр примитив булуын әйтеп тә торасы юк» [5, б. 8]. Прозага Ф. Әмирхан белән Г. Ибраһимов килеп керүен әдип «проза әдәбиятының яңа биеклеккә күтәрелүе, өр-яңа сыйфатлар белән баюы, рус һәм Европа прозасына охшаш бер кыяфәткә керүе» дип бәяли: «Без чын мәгънәсендәге роман һәм хикәяләр укый башладык. Хәтта чәчмә әдәбиятлары әле туып та өлгермәгән тугандаш халыклар да, татар прозасына игътибар итеп, аңардан өйрәнә, үрнәк ала башладылар» [5, б. 8].

Остаз әдип Г. Ибраһимовның тел-стиле турындагы сүзне әдип хикәяләүне кайсы яктан баетуы турындагы сорауга җавап белән дәвам итә һәм аерым якларга тәфсилләп тукталa. Ә. Еники карашынча, беренчедән, Г. Ибраһимов «хикәяләү чарасының компонентларын бик нык арттырды: без инде аның әсәрләрендә кешеләрнең тулы портртларын күрәбез, характер үзенчәлекләрен, рухи кичерешләрен ачык сизәбез; безгә инде ул үзенең әсәрләрендә вакыйганы хикәяләү өчен кирәк булган вакыт, хәл-шарт, көнкүреш элементларын әйтеп кенә узмыйча, аларны детальләр ярдәмендә ачык картиналар итеп сурәтләп күрсәтә» [5, б. 8]. Икенчедән, «әдипнең әсәрләре шигърияткә бай», ягъни табигатьне чагылдыруга аерым игътибар бирә башлый, авторның фикерен көчәйтү өчен символик образ, табигать күренешен файдалана. Өченчедән, Г. Ибраһимов «диалог формаларын төрләндерә, эчке монологларга киң урын бирә, хикәяләүне һәрвакытта да хәрәкәтчән алып бара» [5, б. 8].

Әдипнең теле турында Ә. Еники аерып билгеләп үтә: «Асылда ул безгә проза теленең иң үтемле, саф татарча үрнәген эшләп калдырды. Аның бу үрнәгендә без телебезнең гаҗәеп бай эчке мөмкинлеген, фикерне әйтеп бирә алуда һәм сурәтләп күрсәтүдә зур сәләткә ия булуын күрдек. Галимҗан аркасында безнең телебез, үзенең саф татарча булуын саклаган хәлдә, ничектер мәдәниләште, камилләште» [5, б. 9]. Ахыр килеп, әдип Г. Ибраһимовтан

соң әдәбият мәйданына аяк баскан әдипләрең «аның көчле йогынтысына бирелүен» табигый дип саный.

Шул рәвешле, татар классиклары Г. Бәширов, Ә. Еники үзләрен Г. Ибраһимов мәктәбе вәкилләре дип исәпли. Милли әдәбиятыбызның йөзек кашы Г. Ибраһимов классик татар прозасына нигез салучыларның берсе буларак әдәбият тарихында лаеклы урын тота.

ӘДӘБИЯТ


1. Бәширов Г.Б. Көзге ачы җилләрдә // Сайланма әсәрләр: Казан: Татар. кит. нәшр, 2005. 5 т. Б. 17–182.

2. Гайнуллина Г.Р. Жанрово-тематическое своеобразие публицистики А. Еники 1960–1980-х годов // Филология и культура. Philogy and Culture. № 4 (42), 2015. С. 203–205.

3. Гыйлаҗев Т.Ш. Рецензияләрдән тәгъзияләргә: XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. 254 б.

4. Gilazov T.Sh, Karabulatova I.S., Sayfulina F.S., Kurakova Ch.M. and Talipova G.M. Between the East and the West: Phenomenon of Tartar Literary Criticism in the Lingvo-Cultural Aspect // Mediterranean Journal of Social Science. 2015. Vol 6, No 3, S2, May 2015. P. 508–517. Doi:10.5901/mjss.2015.v6n3s2p508http://www.mcser.org/journal/index.php/mjss/article/view/6534/6261

5. Еники Ә. Хәтердәге төеннәр: Мәкаләләр, очерклар һәм истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. 234 б.

6. Заһидуллина Д.Ф. Әдәбият кануннары һәм заман (Татар әдәбият нәзариясенең барлыкка килүе һәм үсеш баскычлары). Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. 271 б.

7. Заһидуллина Д.Ф. Яңа дулкында (1980–2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык). Казан: Мәгариф, 2006. 255 б.

8. Закирзянов А.М. Жанр «эссе» в современной литературной критике (на примере татарского литературоведения) // Вестник Вятского государственного гуманитарного университета. Филология и искусствоведение. 2010. № 2. С. 120–124.

9. Мингазова Л.И. Творчество Ибрагима Салахова: Основная проблематика и ее художественное воплощение: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1998. 25 с.


## ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ҺӘМ ВАКЫТЛЫ МАТБУГАТ


***Галимҗанова Э.М.***



В данной статье рассматривается послереволюционная публицистика Г. Ибрагимова.

This article deals with post-revolutionary journalism G. Ibragimov.


Галимҗан Ибраһимовның инкыйлабтан соңгы публицистик эшчәнлеге киңкырлы һәм катлаулы. Ул җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе буларак илдә барган зур үзгәрешләр үзәгендә була, иҗтимагый-сәяси вакыйгалар эчендә кайный. Күп кенә газета-журналлар оештыруда катнаша, кайберләренең идея һәм юнәлеш бирүчесе була. Үзе дә вакытлы матбугат битләрендә еш кына мәкаләләр белән чыгыш ясый, илдә барган мөһим вакыйгаларга үзенең карашын, мөнәсәбәтен белдерә, оештыру һәм аңлату эшләре алып бара.

1918 елның гыйнварында Милләтләр эшләре буенча халык комиссариаты карамагында Үзәк мөселман комиссариаты төзелә. Комиссариатның рәисе М. Вахитов, урынбасары итеп Г. Ибраһимов һәм Ш. Маннатов билгеләнә. Комиссариат органы тарафыннан Мәскәүдә «Чулпан» газетасы оештырыла. Әлеге газетаның фактик мөхәррире Г. Ибраһимов була. Беренче татар совет газетасы булган «Чулпан»ның 1918 елның 18 гыйнвареннән 1919 елның башларына кадәр, барлыгы 45 номеры дөнья күрә. Газета баштан

20000 тираж белән таратылса, соңрак аның тиражы ике тапкыр арттырыла. Г. Ибраһимов белән бергә газета чыгаруда М. Вахитов, Ш. Әхмәдиев, М. Максуд, Г. Касимовлар катнашалар.

Әлеге газетада беренче чиратта комиссариат эшләренә кагылышлы мәкаләләр урын ала. Мәсәлән, Г. Ибраһимовның «Комиссариатның эшләячәк эшләре» [4], «Мәркәз мөселман комиссариатының мәрхүм Милли идарә эшләре хакындагы хисабы мөнәсәбәте илә бер-ике сүз» [5], «“Чулпан” һәм комиссариат» [13] һ.б.

«Чулпан» комиссариат тарафыннан оештырылган беренче газета була, аннан соң тагы егермеләп газета чыгарыла. Мәдәният, сәнгать, әдәбият мәсьәләләренә дә зур урын бирелә. Шулай итеп, «Чулпан» татар совет журналистикасы тарихында беренче карлыгач була.

1918 елның октябрь урталарында Г. Ибраһимов Казанга кайта. Рәсми рәвештә ул 1919 елның башларына кадәр комиссариат әгъзасы булып исәпләнсә дә, яңадан Мәскәүгә әйләнеп кайтмый. «Чулпан» газетасы да Казанга күчерелә һәм 1918 елның 12 мартыннан Казан мөселман комиссариаты тарафыннан чыгарылып килгән көндәлек сәяси, әдәби, иҗтимагый «Эш» газетасы белән кушыла. «Эш» газетасы 1918 елның 12 мартыннан 1920 елга кадәр Ш. Әхмәдиев мөхәррирлегендә чыга. Әлеге газетада Г. Ибраһимов К. Якубов, Х. Урмановлар белән хезмәттәшлек итә. Шулай ук комиссариат эшләренә багышланган «Үзәк мөселман комиссариаты коллегиясенең киңәшмәсе турында» [11], «Мәркәз һәм урыннарда мөселман комиссариатлары» [6] һәм Казан мөселман комиссариатының төзелүенә бер ел тулуга багышланган «Иҗтимагый революция вә татар зыялылары» [3] исемле мәкаләләрен бастыра.

1919 елның язында ул Кызыл армиягә ярдәм йөзеннән Колчак бандалары яулап алган Себер, Урал арты җирләренә чыгып китә. «Йөреп чыккан сызыгым – ди ул – Красноуфим, Екатеринбург, Камышлов, Төмән, Ишим, Ялуторовский, Петропавел һәм Курган шәһәрләре булды». Дүрт ай сәфәр кылып, «Башта подводчик, аннан соң теләсә кемне, теләсә нәрсәне, теләсә кая ялланып илтүче ямщик, иң соңыннан Петропавел казначействосыннан сатучылык шәһадәтнамәсе алып, авылдан авылга ураклар, чалгылар сатып йөрүче сыйфаты белән» күп кенә мәгълүматлар туплап кайта һәм «Дошманнар арасында дүрт ай» исемле мәкалә яза. Ул берьюлы берничә газетада, баштан «Кызыл юл», аннан «Эш», «Кызыл армия»газеталары битләрендә дөнья күрә [2]. Әлеге макәләдә сәфәренең нәтиҗәсен болай дип күрсәтә: «Һәркөн үлем көтеп, һәр көне, һәр сәгате бер гомер дәрәҗәдә тирән, үткен тәэссерат белән кичергән бу дүрт ай бер художник революционер өчен елларча язганда бетә алмаслык материал бирде, чишелүе өчен елларча эшләргә мохтаҗ булган мәсьәләләрене алга китереп куйды»[2].

Г. Ибраһимов 1919–23 елларда шулай ук «Эшче», «Кызыл Шәрекъ яшьләре», «Кызыл армия» газеталары һәм «Кызыл Шәрекъ» журналы белән дә шактый гына хезмәттәшлек итә. «Шәрекъ пролетариаты вәкилләре арасында»[15], «Шәрекъ халыкларының съезды» [16], «Шәрекъның бөек революционеры Мулланур иптәш Вахитов» [14], «Пролетариат диктатурасы һәм Ленин» [7] кебек иҗтимагый сәяси темаларга мәкаләләр һәм «Эшче» газетасының бишьеллыгына багышлап берүк исемдәге «Пролетариат сүзе» исемле ике мәкалә бастыра [8].

1921 елдан башлап шактый мәкаләләре «Татарстан хәбәрләре»ндә басыла. 1922 елның маенда РКП (б) ның өлкә комитеты аны газетаның сый-

фатын яхшырту, сәяси идея ягыннан ныгыту өчен «Татарстан» газетасына беркетә. 1924 елның маеннан «Татарстан» «Кызыл Татартан» исеменә үзгәртелә. Г. Ибраһимов соңгы көннәренә кадәр әлеге газеталарда мәкаләләрен бастыра. Бу елларда аның публицистикасында милләт мәнфәгатьләрен кайгыртып язылган язмалар да күренә башлый. «Пролетариатның яңа гыйльми йортлары арта» исемле мәкаләсендә эшче-крестьян балаларына, бигрәк татар авылларыннан килгән балаларга гыйльми уку йортларына керү өчен бердәнбер юл булган рабфаклар оештырылуның әһәмиятен күрсәтеп болай ди: «Татар хезмәт халкы балалары башкаларга керүгә хәзерләнеп җитмәгәнгә, бу рабфакның кирәклеге шәрекъ тормышында аерым зур бер эш иде» [9]. «Бондюг пролетариаты арасында» мәкаләсендә ул Бондюг заводы эшчеләренең урыслар белән чагыштырганда күпкә аяныч шартларда яшәүләрен искәртә: «Мәсьәләнең үзәге менә кайда: җүеш, пычрак, тар сасы таш «номерлар»да, саз эчендә, хлор агуы астында агуланган начар, сасы квартирларда бу «җәй көне тышта йоклап, кыш көне сыймагач, берсе өстенә берсе ятарга мәҗбүр кечкенә тар бүлмәләр»дә торучылар һәммәсе, һәммәсе, тик татарлар, тик татар эшчеләре генәдер» – ди ул. Моның сәбәпләрен дә күрсәтеп уза: «Һәркемгә мәгълүм, революциягә чаклы завод хуҗасы Ушков урыс капиталисты иде. Татар эшчеләренең квалификациясе түбән, аңлары зәгыйфь, көрәшләре аз, тыңлаучанлыклары зур булганга, күп эшләтеп, аз түләп, начар квартирда тотып, боларның канын, пролетариатның оешып, көрәшкә барган катлавы булганга, күбрәк эчәргә корган эксплуатациясе моңа сәбәп иде. Монда мөнәсәбәт крәстиянгә дә, зыялыга да бар иде», – ди ул. Татар җөмһүрияте төзелүгә дүрт ел вакыт үтсә дә, заводта җитәкчелек эшләрендә дә татарларның юк дәрәҗәсендә булуларын әйтә: «Бондюг заводында утыз цех бар, – ди ул, – болар эчендә, тик бер генә, тик бер генә заведующий татардан. Ул да әле яңа гына кергән. Хәлбуки, элеге заманның кабахәт мирасы белән көрәшеп, татар пролетариатыны күтәрүне чыннан уйланса, бу утыздан берне байтак арттырырга мөмкин»булыр иде ди. «Тик шул юл белән генә без татар пролетариаты арасында квалификацияне, сәяси аңны күтәрербез» дигән нәтиҗә ясый [1]. «Татарстан җөмһүриятенең дүрт елы эчендә партия оешмасы» исемле мәкаләдә шул ук мәсьәлә дәвам иттерелә. Мәкаләдә партия сафларында да татарлар саны русларга караганда күпкә аз булы әйтелә. Дүрт ел эчендә саннарның үсеше чагыштырылып бирелә. «Татарлаштыру турында дүрт ел буенча күп сөйләдек. Кайбер эшләр дә юк түгел. Ватык, җимерек тел белән булса да, һәммә вывескаларга татарча яздырдык. Мәктәпләргә, совет аппаратларына азмы-күпме татарны керттек. Татардан совет чиновнигын беркадәр арттырдык. Ләкин бөтен хәрәкәтнең төп үзәге булган партия организациясендә татарлашу – татар эшче-крәстияннәрен партиягә һәм аның аппаратларына кертүдә эшләнгән эшләр әле һаман бик аздыр, ди ул [10].

Г. Ибраһимов инкыйлабтан соңгы иҗтимагый эшчәнлегенең әһәмиятле тармакларыннан берсе – аның мәгариф өлкәсендә яңача оештыру эшләре алып барудагы хезмәте. Ул 1925 елның башында республика Мәгариф комиссариаты каршында оешкан Гыйльми үзәкнең җитәкчесе итеп билгеләнә һәм 1927 елның 17 мартына, Кырымга дәваланырга киткәнче шунда эшли.

Мәгариф һәм әдәбият өлкәсендә беренче журналларны нигезләүче һәм аларның мөхәррире була. 1918 елда мөселман комиссариатында эшләгәндә ул педагогика буенча беренче татар журналы «Мәгариф»не оештыра. Аның

беренче номеры 1918 елның 7 ноябрендә чыга. 1922 елның маенда «Безнең юл» журналы дөнья күрә.

Йомгаклап әйткәндә, Галимҗан Ибраһимов совет чорында татар вакытлы матбугатын оештыруга, формалаштыруга зур көч куйган, милли тарихыбызда үз эзен калдырган олпат шәхесләрнең берсе.

ӘДӘБИЯТ

1. Бондюг пролетариаты арасында // Кызыл Татарстан. 1924. 2 июнь.
2. Дошманнар арасында дүрт ай // Кызыл юл. 1919. 7 сентябрь; Эш. 1919. 15 сентябрь; Кызыл армия. 1919. 16 сентябрь.
3. Иҗтимагый революция вә татар зыялылары // Эш. 1919. 10, 11, 12 март.
4. Комиссариатның эшләячәк эшләре // Чулпан.1918. 30 апрель.
5. Мәркәз мөселман комиссариатының мәрхүм Милли идарә эшләре хакындагы хисабы мөнәсәбәте илә бер-ике сүз // Чулпан. 1918. 24 август.
6. Мәркәз һәм урыннарда мөселман комиссариатлары // Эш. 1918. 7 ноябрь
7. Пролетариат диктатурасы һәм Ленин // Кызыл армия. 1920. 22 апрель.
8. Пролетариат сүзе // Эшче. 1923. 23 август; Татарстан. 1923. 27 сентябрь.
9. Пролетариатның яңа гыйльми йортлары арта // Татарстан. 1923. 22 октябрь.
10.Татарстан җөмһүриятенең дүрт елы эчендә партия оешмасы // Кызыл Татарстан. 1924. 25 июнь.
11.Үзәк мөселман комиссариаты коллегиясенең киңәшмәсе турында // Эш. 1918. 4 июль.
12. Хасанов М. Галимджан Ибрагимов. Казань: Татар. кн. изд-во, 1969. 432 с.
13. Чулпан» һәм комиссариат // Чулпан. 1918. 28 февраль.
14. Шәрекъның бөек революционеры Мулланур иптәш Вахитов // Кызыл Шәрекъ. 1920. № 1.
15. Шәрекъ пролетариаты вәкилләре арасында // Кызыл армия. 1919. 26 декабрь.
16. Шәрекъ халыкларының съезды // Кызыл Шәрекъ.1920. № 5–6.

## СОЦИАЛИСТИК РЕЛИЗМНЫҢ ДЕТЕКТИВ ФОРМАГА ЙОГЫНТЫСЫ (Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романы мисалында)

***Галиуллин Р.Р.***

В статье рассматривается трансформация детективной формы повествования под влиянием социалистического реализма. Роман Г. Ибрагимова «Глубокие корни» («Тирән тамырлар») изучается как первое детективное произведение в советской татарской литературе.

The article considers the transformation of the detective form of the narrative under the influence of socialist realism. G. Ibrahimov's roman «Deep Roots» («Tirun tamyrlar») is studied as the first detective work in Soviet Tatar literature.

Дөнья әдәбиятында, белгәнебезчә, детектив әсәрләргә карата укучы кызыксынуы XX гасыр буенча кимеми, ә киресенчә, үсә генә бара. Россиядә инкыйлаб булган чорда Европа илләрендә андый дәрәҗәдә зур тетрәнүләр күзәтелми. Димәк, әдәбият та үзенең социаль, сәяси карашларын кискен үзгәртми. Совет илендә исә без күзәткән детектив әсәрләр сәясәткә бәйле үзгәрешләргә дучар булалар. Беренче планга шәхес мәнфәгатьләре түгел, ә сыйнфый каршылык чыга. Россиядә һәм СССРда детектив махсус совет детективы рәвешендә булдырыла, алга таба ул башка социалистик илләрдә тарала. Аларда яхшылык белән начарлык конфликты антогонистик сыйныфлар кысаларында карала, ә соңрак дәүләт идеологиясе тарафыннан

билгеләнгән социалистик һәм антисоциалистик конфликтка трансформацияләнә [2].

Кайбер галимнәрнең совет детективына карата фикерләре үтә кискен, алар аны форма буларак бөтенләй танымыйлар. В.П. Руднев шундыйлардан: «Совет детективы бөтенләй юк иде, чөнки совет чынбарлыгында шәхси шымчылык институтлары булмады һәм шәхси инициатива рәвешендә хакыйкатьне эзләү идеясе юк иде, моннан башка чын детектив юк, була да алмый», – дип әйтә ул [7, б. 223].

Ләкин мондый очракта совет чорында иҗат ителгән әсәрләрне кайсы жанр формасы кысаларында карарга соң дигән сорау туа. Алар үзләренең төп характеристикалары, үзенчәлекләре буенча детективка тиң бит. Безнеңчә, алар һичшиксез детектив әсәрләр, соцреализм, совет чынбарлыгын үзләренә сеңдергән, трансформацияләнгән детектив әсәрләр кебек өйрәнелергә лаек.

Совет чоры татар әдәбиятынның башлангыч чорын, 1920–1930 еллар әдәбиятын күзәтсәк, галим, язучы Галимҗан Ибраһимов иҗаты беренче сафларда тикшерелә. Үзенең әсәрләрендә ул революция вакыйгаларын, ялкынлы революционерларның аяусыз көрәшен, яшь совет хөкүмәтенең аякка басуын һ.б. сурәтли.

Безне кызыксындырган детектив әсәрнең совет чоры әдәбиятында беренче үрнәге дә нәкъ менә Г. Ибраһимов исеме белән бәйле. «Революциядән соңгы әдәбиятыбызда детектив сюжет алымнарына беренчеләрдән булып Г. Ибраһимов үзенең “Тирән тамырлар” романында мөрәҗәгать итә» [5, б. 250]. Ф. Хатипов та бу романның детективка якын булуын әйтә: «Автор биредә детектив материал белән эш итә» [11, б. 11].

Романының беренче битендә үк укучы Фәхринең үле гәүдәсенә тап була. Автор аның үз үлеме белән үлмәвен дә әйтеп бирә. «*Фәхрине үтереп ташладылар*» [3, б. 137]. Фәхринең үле гәүдәсе натуралистик, реалистик, хәтта физиологик нечкәлекләр белән сурәтләнә. «*Аның йөзе изелеп, канга баткан, баш сөяге ватылган, маңгае, чигәләре буй-буй җимерелгән, мие сары аксылланып тышка актарылган, муены, сул як кулбашы канлы туфрак белән укмашып беткән иде. Янында ук зур, калын тимер кендек тә табылды. Моның нечкә башы бөтенләй кара канланып каткан иде*» [3, б. 138]. «Натуралистик тасвирлар Г. Ибраһимовның “Тирән тамырлар” романында да очрый. Монда натурализмның ике төре дә чагылыш таба. Әдип үзе ачып бирә торган вакыйгаларны натуралистик сурәтләр чолганышында тасвирлый. Язучы биредә натурализмның биологик төрен кулланып, физиологик күренешнең фаҗига дәһшәтен тулы итеп укучы күз алдына китерсен өчен натуралистик мотивларга мөрәҗәгать итә» [9, б. 166].

Әйткәнебезчә совет чорында детектив әсәр трансформация кичерә, шулай булгач шәхси мөнәсәбәтләр сыйнфый позициягә күчә, ягъни теге яки бу шәхеснең кайсы катламга, сыйныфка бәйле булуыннан гыйбарәт. Ф. Хатипов шул ук фикерне әйтә: «Традицион җинаять һәм җәза сюжетын Г. Ибраһимов капма-каршы торучы көчләрнең социаль тамырларын ачып, кешеләрнең бу көрәшкә катнашу психологиясен ачыклау өчен куллана» [12, б. 20]. Кеше гомере, кеше каны соңгы планда, баштан җәмгыять, хуҗалык, сәясәт.

«Тирән тамырлар»дагы геройларның барысын да тискәре һәм уңай персонажларга җиңел итеп бүлеп була, Г. Ибраһимовның үз геройларына карата симпатиясе дә сизелә. Ләкин монда да шул ук сыйнфый күзлектән

бүленеш күзәтелә. «“Тирән тамырлар”да персонажның нindилеге бер үлчәм белән – революциягә, гражданнар сугышына мөнәсәбәте, катнашы белән билгеләнә» [11, б. 12].

Большевиклар, партия әһелләре, комсомоллар, гади крестьян халкы (Фәхри, Садыйк, Шәнгәрәй, Рәгыя һ.б.) – уңай; байлар, кулаклар, ярдәмчеләре, сатлыкҗаннар (Вәли, Гыймади, Салахиев, Иванов һ.б.) – тискәре персонажлар.

Шулай да автор советларны бары тик уңай яктан гына гәүдәләндерми. Романда моңа берничә мисал очратырга мөмкин: Садыйкның Зирекледәге «кара көчләр»гә каршы көрәше, аның боерыгы нигезендә ишан аттырылу шундыйлардан. «*Унтугызынчы елда, Колчакның кара дулкыны, хәзерге Татарстан җөмһүриятенең күп туфрагын басып кереп, Казан шәһәренә якыная башлаган көннәрдә, фронт авызында халыкка дин исеменнән Садыйк Миңлебаев бу ишанны аттырды*» [3, б. 153]. Әсәр ахырында автор бу хәлләрне яңадан искә төшерә, Садыйкның сүзләрен җентекләп укучыга җиткерә: «*– Син Шәмси, – диде, – мылтыклы, патронлы ике кызылармеец иярт тә, – диде, – менә Шәрәфиләр белән бергә Зирекле авылына бар. Анда ниндидер кара көчләр кайнаштыра. Күрәсен күрерсең. Атарлык булса, безгә хәбәр итәрсең, – диде*» [3, б. 355]. Ләкин авторның кулланган чагыштыруларына күз салсак, көчләрнең кайсысы чынлап кара, кайсысы ак дигән икеләнүле сорау туарга мөмкин. «*Чәүкә көтүенә лачын сугылды. Яисә сарыклар өстенә көтелмәгән арыслан сикереп төште. Ишанның бөтен йорты, өйләре, кешеләре, бөтен Зирекле авылы менә шулай кайный башлады*» [3, б. 355].

Шәрәфинең якын тирә авыл кешеләренең хөрмәтенә ия булган, бер гаепсез 70 яшьлек ишанны советларга каршы халыкны котыртучы кара көч дип атуы да – тетрәндергеч хәл. Автор укучыга совет хөкүмәте исемле тәңкәнең ике ягын да күрсәтергә тели кебек. «*Ишан соңгы сүзен әйтеп бетерә алмады, үзалдына дулкынланып торган халык диңгезе өстеннән бөтен тирә-якны гөрелдәтеп каты мылтык ату тавышы шартлады. Гәүдә чалма-чапаны белән җиргә ауды. Уң кулы белән йөрәген тотты. Ләкин үлмәгән иде. Егет ишанның маңгаена төзәп тагын берне атты. Шуның белән тыны кысылды*» [3, б. 359].

Бу уңайдан үзенең мәкаләсендә Ф. Хатипов түбәндәгеләрне яза, аның фикерләре белән килешми булмый: «Шулай итеп, кеше гомерен кою бер очракта җинаять санала, бөтен роман шуның тамырларын юллауга багышлана, икенче мәлдә үзенә күрә бер егетлек кебегрәк итеп бирелә, аның өчен берәүне дә хөкем каршына китереп бастырмыйлар. Бу җәмгыятьтә, әсәрдән аңлашылганча, төрле кешенең кадере төрлечә булып чыга» [11, б. 11].

Рәгыянең хатыннар белән талашып, сугышып йөрүләре дә укучыда уңай тәэсир калдырмый. «*Орыш вакытында үзен-үзе белмичә, җенләнә башлый, кисәү агачы белән бәреп, бер хатынның күзен чыгара. Аерырга, туктатырга килгән яшь киленнең бер уч чәчен йолкып ала, битләрен, ирennәрен тырнап, канга батырып ташлый*» [3, б. 266].

Хөкемнең чишелешенә яңадан сыйнфыйлык эз сала. Гыймади, Әхми, Салахиев белән Ивановларга – «*өч ел – алты ел арасындагы зинданнарның бәхет санады*», Вәли байга исә: «*– Иҗтимагый саклау чараларының иң югарысы!*» [3, б. 386]. Гәрчә ул турыдан-туры үтерүче булмаса да (Фәхрине фактик яктан Әхми үтерә), Вәли Хәсәнов үзенең сыйнфый чыгышы белән

гаепле булып чыга. Роман финалы совет чынбарлыгына тиң – кеше каны аркылы якты киләчәккә юл тоту. Бу әсәрнең соңгы битләрендә ачык чагылыш тапкан: «*Вәли Хәсәнов караңгы төндә урманга чыгарылып атылды. Киң Идел өстендә, нуры белән дөньяны балкытып, якты кояш күтәрелде*» [3, б. 386].

Детектив романның төп юнәлеше – җинаятьне ачу. Бу моментны мөмкин кадәр тоткарлап калу өчен, автор сюжетны ялган, бутаучы эпизодлар белән баета. «Тирән тамырлар»да Г. Ибраһимов сәяси моментлар, хуҗалык проблемаларына мөрәҗәгать итә, революция, гражданнар сугышы елларын сурәтләү-бәяләүне кертеп, сюжетны чуарландыра. «...Детектив моменттан башланган роман тора-бара бөтен заманны, аның төп үсеш тенденцияләрен гәүдәләндергән киң полотнога әверелә. Фәхринең үтерелү сәбәпләрен тулырак күз алдына китерү өчен авторга үткәнгә – империалистик сугыш, Февраль һәм Октябрь революциясе, гражданнар сугышы елларына да мөрәҗәгать итәргә туры килә. Болар барысы ахыр чиктә Фәхри биографиясенең турыдан-туры халык тарихы белән бәйләнгән булуын ачуга, ә аның үлемен яңа тормыш төзү өчен көрәштә зур югалтуның берсе итеп күрсәтүгә китерә» [5, б. 251]. Традицион рәвештә тышкы һәм эчке сюжетларны аерып була. Беренчесен Паларусов алып барса, икенчесе Вәли Хәсәнов һәм иптәшләре кулында. Монда да сыйнфый аспект өстенлек итә: Паларусов – коммунист, Хәсәнов – «*контра бабай*».

«Тирән тамырлар»да өч төп персонажны аерып күрсәтергә мөмкин: корбан – Фәхри, җинаятьчене ачкан кеше – Паларусов, җинаятьче – Вәли Хәсәнов. Җинаять эше роман дәвамында алып барылса да, Вәли бай белән, иптәшләре белән укучы әсәр башында ук таныштырыла.

Совет чорындагы детектив әсәрләрнең сере бары тик бер юл белән чишелгәне факт – җинаятьне ачкан кеше хокук саклау оешмасыннан гына була ала. Бу да, билгеле, сәясәткә бәйле. Үзлектән эшләүче детектив җинаятькә, җинаятьчегә, корбанга сыйнфый күзлектән карамаска да, партия сызыгын якламаска да мөмкин. Милиция, прокуратура хезмәткәрләре исә совет идеологиясен яклап, сыйнфый күзлектән чыгып хөкем чыгара, җәза бирә.

Паларусов сыйнфый яктан характерлана – коммунист, революционер һ.б. «*Паларусов үтерелгән Фәхри белән яхшы таныш иде. Алар теге авыр, кытлык елларда бергә эшләделәр... ачлыкка, үлемгә каршы фронтта бергә көрәштеләр. Фәхри волбашкармада рәис иде. Паларусов ул чакта үзәкнең агенты иде. Киңәшмәләрдә, җыелышларда еш-еш очрашырга туры килде*» [3, б. 151].

Паларусов жанр формасы таләпләренә нигезләнеп, акыллы, зирәк, хәйләкәр итеп сурәтләнә. «...Тикшерүче Паларусов Фәхрине үтерүчене табар өчен бик күп нәрсәне өйрәнергә, белергә кирәк икәнен аңлый. Нәтиҗәдә әлеге җинаятьнең серен ачу әсәрдә катлаулы һәм көрәшле чорны киң колачлап, төрле яклап күзаллауны сорый» [5, б. 251].

Вәли Хәсәнов «Тирән тамырлар» сюжетында төп урынның берсен алып тора. Бу образ автор тарафыннан каршылыклы итеп бирелә. Сыйнфый яктан күпчелек роман персонажларына ул дошман, ләкин кеше буларак Вәли бай күпне күргән, күпне кичкән. Гомер буе үзенең тире, каны белән җыйган малларын, кибет-йортларын яңа хөкүмәт тартып ала. Болар турында ул җаны әрнеп сөйли. «*Советтан тире заводын алды. Ел ярым шунда эт булып эшләдем. Алты мең акча тыктым. Нәтиҗә чыкты? Совнархозга*

*керен карадым. Анда аякланып кына барганда, конкурентларым ектылар. (...) Бездә нәрсә генә юк иде. Һәммәсе очты бит! (...) Бер өеңдә – балалар бакчасы, бер өеңдә – техникум, бер өеңдә диспанцер түгелме? Магазиннар кая? Берсендә – Татурман, икенчесендә – Татмашина, өченчесендә Таткитап хуҗалык итә түгелме? Менә шулай икән дөньясы!*» [3, б. 235].

Барыр чамасы калмагач, совет хөкүмәтенә баш иеп ярдәм сорады, аңа артта калган совхоз биреп, аякка күтәрергә куштылар. «*Сине менә совхозга куйсак, дөрес юл белән барырга сүз бирәсеңме, диде [Җәмилов]. Мин телдән аңа вәгъдә бирдем. Күңелемнән ант иттем. Җәмилов мәрхүм әйтте: менә сиңа совхоз, диде, өч елда аякка бастыр. Бастыра алмасаң, минем күземә күренмә. Урының зиндан булыр, диде. Моңа сүз бирдем. Менә шулай мин* «*Хезмәт*»*тә эшкә тотындым... һәм дүрт ел эчендә бөтен Волга буенда беренче үрнәк совхоз дәрәҗәсенә җиткердем...*» [3, б. 305]. Ләкин бу очракта да Вәли Хәсәнов гаепле булып чыга.

Билгеле, аны гаепсез дип тә әйтеп булмый: Әхми белән Гыймадины котыртучы ул, Салахиев, Иванов белән таныш булуларыннан файдаланып, аларны үз ягына аударуы да юк түгел.

Детектив алымнардан тыш, Г. Ибраһимов романында сыйнфый көрәшнең ин дәрәҗәдә кырыс, түгелгән канның ни кадәр күп булуын, вәхшилекнең ни дәрәҗәдә булганлыгын сурәтләү өчен, алда әйткәнебезчә, натуралистик алымнарга еш мөрәҗәгать итә. Шулай да аларның күбесе сюжет сызыгына бәйле түгел. Җиһанша картның крестьяннарның баш күтәрүләрен гаскәр тарафыннан бастырылуын тасвирлавы, Фәхринең атасы Тимершаны үтерү күренеше моңа ачык мисал: «*Шуннан яшь әфисәр кызып сүгенде дә штык белән Тимершаның эчен каерып җибәрде. Аннан эчәгеләр, каннар агып, Тимершаның авызын, йөзен, кулбашларын, бөтен, гәүдәсен буядылар...*» [3, б. 175].

Әсәрдәге сурәтләнгән кулаклар бунты да үзенең вәхшилеге белән укучыны тетрәндерерлек. «Кулакларның мәгънәсез, укучыны тетрәндергеч вәхшилекле баш күтәрүләре дә төп сюжетның үсешенә бәйле түгел» [4, б. 24]. Биредә дә натуралистик алымнар кулланып сурәтләнгән комсомол Бирәхмәт белән мөгаллим Хәбибнең ничек үтерелү күренеше, атка бәйләп авыл буйлап йөртелүләре игътибарга лаек. «*Аның кулы, аягы сынды, башы изелде, эчәгеләре агып чыкты. Идән кара кан белән тулды. Әллә ничә мужикның кулы, җиңе канга буялды.(...) Арканга тагылган мөгалимнең канлы башы капка баганысына килеп уралды. Ат бер омтылды – ала алмады, тагы омтылды – тагы ала алмады, шундагы кечкенә этнең өрүеннән куркып, өченче тапкыр омтылган иде – баш, ике баганага кысылып, өзелеп калды. Бирәхмәт белән Хәбибнең гәүдәсен өстерәп, айгыр абзарга чапты*» [3, б. 257–258].

Ачлык елларын да автор язмыйча калдырмый. Г. Ибраһимов кешеләрнең ни дәрәҗәдә җәфа чиккәннәрен, ачлыктан интеккәннәрен сурәтләп бирә. Иң куркынычы – бала-чаганың бу ачлыкның корбаннарына әверелүләрен күрсәтә. «*Өлкәннәр бер хәл! Балаларның язмышлары бик авырга калды. Башта эчләрен тырнап-тырнап: – Икмәк бир! Икмәк бир! Икмәк бир! – дип еладылар. Талашып-ызгышып беттеләр. Хәзер инде тындылар. Куәтләре юк. Йөзләре кибеп саргайды. Тәннәрендә ит әсәре калмады, кара саргылт җыерчыклы тиреләре кечкенә, нечкә сөякләренә ябышып катты. Алар хәзер җыерчык битле, җитмеш яшьлек карчык кебек күренәләр. Күзләрендә*

*нур, җан бетте, сүнеклек капланды, аннан тик хәлсез ачлык газабы карый. Бирсәң, сүзсез чәйнәп йотлыгалар, булмаса, дәшми, тынмый, бозлы, салкын почмакта, иске киемнәргә уралган килеш, бөгәрләнеп ята бирәләр»* [3, б. 248–249].

Күргәнебезчә Г. Ибраһимов үзенең әсәрендә революция чорын, гражданнар сугышы елларының ни дәрәҗәдә авыр булуын сурәтли. Шулай да «Тирән тамырлар»да детектив башлангыч көчле икәнлекне исәпкә алып, аерым нәтиҗәләр ясарга мөмкин.

1917 елгы инкыйлабтан соң әдәбиятта яңа этап – соцреализм дәвере башлана, моннан чыгып, барлык әсәрләр җәмгыятьне, анда барган процессларны сыйнфый күзлектән сурәтләүгә дучар ителә. Детектив жанр формасы буржуаз әдәбиятның үрнәге булса да, совет әдәбиятында да юкка чыкмый. Аның беренче үрнәге булып Г. Ибраһимов әсәре тора. Шул ук вакытта детектив әсәрләр трансформация кичерә – шәхси мәнфәгатьләр арткы планга күчеп, сыйныфлар көрәше алга куела.

Шулай итеп, Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романы революциядән соң совет чорында иҗат ителгән беренче детектив әсәр буларак бәяләнергә хокуклы, гәрчә бу әсәр совет әдәбияты тарихында детектив буларак каралмаса да. Бу роман совет әдәбияты тарихында бары тик сыйнфый күзлектән, социалистик реализм методының ачык мисалы рәвешендә генә анализлана килде [1; 6]. Яисә галимнәр аны күмәкләштерү сәясәтен сурәтләүче әсәр дип карадылар. «Күмәкләштерү сәясәтенең башлануы белән авыл романы, социалистик канунның бер үзенчәлегенә әверелгән колхоз романы жанрына трансформацияләнә» [8, б. 278]. Бу күзлектән Г. Ибраһимов әсәрен М. Шолоховның «Поднятая целина» романы белән янәшә куеп була. «Авылдагы бәрелешләр турында бездә тәүге сүз әйтүче Г. Ибраһимов булды. (…) Әдәбият белемендә бу роман күмәкләштерү турындагы әсәрләр рәтендә карап йөртелә» [11, б. 9].

«Тирән тамырлар» татар совет әдәбиятында яңа жанр формасына нигез салды, алга таба аңа мөрәҗәгать иткән авторлар һичшиксез Г. Ибраһимов тәҗрибәсен кулланганнар. «Нәтиҗәдә, детектив хикәяләү алымнары социалистик реализмның иҗат палитрасына органик рәвештә килеп керәләр һәм аны баеталар» [5, б. 252].

Роман үзе детективның татар әдәбиятында формалашуында мөһим урынны алып тора, чөнки XX гасырның икенче ярысында иҗат ителгән детектив әсәрләр турыдан-туры сыйнфылык позицизиясенә таянып иҗат ителмәсәләр дә, соцреализм кысаларыннан азат була алмаганнар. Г. Ибраһимов әсәренең персонажлары сыйнфый домшманнарга түгел, ә социалистик кануннарга буйсынмаган һәм бу кануннарны саклаучы милиционер образларына әвереләләр.

Гомумән бу чор әдәбиятка гына йогынты ясамаган билгеле. Совет хөкүмәтенең башлангыч чоры зур бер дәүләттә яшәгән кешеләрнең тормышын гына түгел, ә аларның фикер сөрешен үзгәртергә тырышкан аянычлы, канлы дәвер булып тарихка кереп кала.

ӘДӘБИЯТ

1. Гайнуллин М.Х. Татар әдәбияты. XIX йөз: Югары уку йортлары өчен. Казан: Таткнигоиздат., 1957. 656 б.

2. Галиуллин Р.Р. Утопические мотивы в советской татарской литературе (на примере повести «Агидель» М. Амира и романа «Когда рождается прекрасное» // В мире научных открытий. 2015. № 3 (63). С. 184–189.

3. Ибраһимов Г.И. Тирән тамырлар // Сайланма әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. 5 т. 456 б.
4. Кадыров О.Х Романтизм Галимжана Ибрагимова. (Творчество и эстетика): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1967. 31 с.
5. Мусин Ф. Көмеш көзге. Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 256 б.
6. Нуруллин Н.З. XX йөз башы татар әдәбияты. Казан: КДУ нәшр., 1966. 426 б.
7. Руднев В.П. Энциклопедический словарь культуры 20 века. М.: Аграф, 2001. 608 с.
8. Скороспелова Е.Б. Русская проза XX века: от А. Белого («Петербург») до Б. Пастернака («Доктор Живаго»). М.: ТЕИС, 2003. 608 с.
9. Сәләхова З.Г. Г. Ибраһимов иҗатында натурализм // Г. Ибраһимов һәм хәзерге заман. Казан: Фикер, 2003. Б. 164–170.
10. Татар әдәбияты тарихы (1917–1941). 6 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 4 т. 568 б.
11. Хатипов Ф. Мөлкәтебезне барлаганда // Мөлкәтебезне барлаганда. Иҗади портретлар, тәнкыйди-теоретик мәкаләләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 273 б.
12. Хатипов Ф. Истоки психологизма татарской прозы // Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман: Тууына 115 тулуга багышланган фәнни конференция материаллары. Казан: Фикер, 2002. Б. 18–24.

# Г. ИБРАҺИМОВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ГОМУМИЛӘШТЕРҮЧЕ СҮЗЛЕ ТИҢДӘШ КИСӘКЛӘРНЕҢ КУЛЛАНЫЛУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

***Галләмов Ф.Г.***

В статье рассматриваются особенности употребления предложений с обобщающими словами при однородных членах в произведениях Г. Ибрагимова. Выделяются структурные типы обобщающих слов. В зависимости от позиции обобщающих слов к однородным членам предложений определяются их синтаксические функции.

The article considers the peculiarities of sentence performance of general words with homogeneous parts of the sentence in the works by G. Ibragimov. It distinguishes the structural types of general words. Depending on the position of general words to homogeneous parts of the sentence their syntactic functions are determined.

Тиңдәш кисәкләр янында гомуми мәгънәле исемнәр, алмашлыклар һәм алмашлыклы исем сүзтезмәләр килә. Мондый сүзләр теләсә нинди тиңдәш кисәкләр янында түгел, ә бәлки санау интонациясе һәм тезүче теркәгечләр ярдәмендә тезелеп килгән кисәкләр янында гына булалар. Күзәтүләрдән күренгәнчә, тиңдәш ияләр, тәмамлыклар, урын хәлләре янында гына гомуми мәгънәле сүзләр килә. Гомуми мәгънәле сүзләр күпчелек предмет мәгънәсен белдерүче сүзләр янында киләләр, ә процесс белдерүче сүзләр бик сирәк кенә гомумиләштереләләр. Бу телдә исем алмашлыкларының күп булуы, ә фигыль алмашлыкларының булмавы белән аңлатыла.

Гомумиләштерүче сүзләр булып, күпчелек *барысы да, һәммәсе дә, бөтен нәрсәдән, барысын да, болар һәммәсе, һәммәсен, һәммәсе, бар нәрсә, бөтенесендә, һичбере, һичнәрсә, бар да* һ.б. билгеләү һәм юклык алмашлыклары килә. Билгеләү алмашлыклары белән бирелгән гомумиләштерүче сүзләр раслау җөмләләрдә, ә юклык алмашлыклары белән бирелгәннәре инкяр җөмләләрдә була. Юклык алмашлыкларыннан *берни дә, һичнәрсә,*

*һичбере, берсе дә* актив. Юклык алмашлыклары булган инкяр җөмләләр бик сирәк кулланылалар. Гомуми мәгънәле сүзләр күпчелек раслау җөмләләрдә була: *Мәхәббәт белдерешү, никах-туй, мәһәр, кунак, мәҗлес, тәбрикләшү –* *һәммәсе* шуның белән тәмам булды (Г.И. – *мисаллар Г. Ибраһимов әсәрләреннән китерелә).*

Моннан тыш, исемле исем, санлы исем, фигыльле исем һ.б. төрле сүзтезмәләр белән дә бирелә ала: Бик күп *мәдәният әһелләре* укытып чыгарган ул: *язучылар, шагыйрьләр, артистлар, мөгалимнәр, табиблар, юристлар, очучылар...* (Г.И.); Икенче өстәлдә тагын *өч кеше – студент Мостафа, Шәләнге кооператоры Низами, боларны чакыручы Сираҗи* түгәрәкләнеп бер-берсенә капланганнар (Г.И.); Утарга кеше түгел, кош-корт та очып керә алмас, биек койма, өстә чәнечкеле тимерчыбык, ишегалдында берсен-нән-берсе усал *ике эт: бүре Лорд һәм овчарка нәселеннән – Барс,* икесе дә баусыз иректә йөри (Г.И.); Хатын-кыз өйне корып йөргәндә, Сарсымбай үзе әле *яңа килеп җиткән маллар – бияләр, кушар, сыерлар* арасында иде (Г.И.).

Шулай итеп, гомумиләштерүче берәмлекләр аерым сүз, гади һәм катлаулы сүзтезмә рәвешендә кулланылалар. Фактик материал күрсәткәнчә, гомумиләштерүче берәмлекләр, башлыча, исем сүз төркемнәре белән белдереләләр**.**

Тиңдәш кисәкләр һәм гомумиләштерүче сүзләр янында *да/дә/та/тә* теркәгечләренең булу-булмавына карап, аларның берничә төрен күрсәтергә мөмкин:

1) тиңдәш кисәкләр санау интонациясе белән бәйләнәләр, гомумиләштерүче сүзләр янында да тезүче теркәгечләр юк: Төн буенча дәвам иткән бу зарларыннан мин Гөлбикәнең бөтен гомере белән танышып җиттем. *Аның күп җылкылы бай башкортның кызы булуы, авылларындагы бер хәлфәне сөюе, ләкин аталары, ул татар дип, аңа бирмәүләре, көчләп, җылатып Карман бай дигән берәүгә яшь хатынлыкка сатулары, андагы көндәшлек тормышы, иренең эчеп кайтып кыйнавы, ахырдан аның рустан эчеп кайткан вакыт аты-арбасы белән тирән чокырга төшеп үлүе, аннан соң менә шул Җомагылга бирүләре, аның бар малын, йортын эчеп бетерүе, сугышуы, аны бер дә яратмавы – һәммәсе* күз яшьле кызганыч сурәтләр белән минем үз алдымнан кичтеләр (Г.И.);

2) тиңдәш кисәкләр үзара санау интонациясе белән бәйләнеп, гомумиләштерүче сүз янында *да/дә/та/тә* теркәгечләре кулланыла: Монда *биек-биек үрләр, тирән-тирән чокыр, елгалар – барысы да* урман белән капланган (Г.И.);

3) тиңдәш кисәкләр *да/дә/та/тә* теркәгечләре ярдәмендә бәйләнәләр һәм гомумиләштерүче сүзләр янында да кулланылалар. Моны аларның грамматик яктан ярашып килү үзенчәлеге дип карарга кирәк: *Кибет тә, Талипов белән Шомбытовның үлеме дә, пистолет та – һәммәсе дә* Матвеевка каршы сөйләүче дәлилләр (Г.И.).

Татар синтаксисында яшәп килүче «Тиңдәш кисәкләр нинди җөмлә кисәге булса, гомумиләштерүче сүз дә шул ук җөмлә кисәге функциясен башкара» дигән фикер [4, б. 490; 3, б. 83] бик үк дөреслеккә туры килеп бетми. Бу ялгышлык гомумиләштерүче сүзләр белән тиңдәш кисәкләрнең барысын бер кисәккә каратудан килеп чыга. Тиңдәш кисәкләр иң беренче чиратта гомумиләштерүче сүзгә, аннан соң гына ул буйсынган сүзгә иярә. Гомумиләштерүче сүзләр белән тиңдәш кисәкләр арасында тезүле бәйләнеш

түгел, ә ияртүле (аныклаулы яки төгәлләүле мөнәсәбәт) була. Аннан соң алар мәгънә ягыннан да бертигез түгел. Гомуми мәгънәле сүз тиңдәш кисәкләрнең мәгънә суммасына тигез була. Шунлыктан алар тигез хокуклы җөмлә кисәкләре түгел һәм бер синтаксик вазифа башкара алмыйлар. Моны гомумиләштерүче сүзләрнең җөмләдәге урыннарына бәйләп аңлатырга кирәк [1, б. 31–33].

1. Башта гомумиләштерүче сүзләрнең тиңдәш кисәкләрдән алда урнашу очрагын карап узыйк. Бу очракта гомумиләштерүче сүз аныкланмыш, ә тиңдәш кисәкләр аныклагыч вазифасын башкаралар. Аныкланмыш җөмләнең теләсә нинди кисәге булып килә ала. Аныкланмыш булып килгән гомуми мәгънәле, җыелма күплекне белдерүче сүзләр чын мәгънәсендә тиңдәш кисәкләр белән бер үк функцияне башкаручы гомумиләштерүче сүз була алмыйлар. Алар, киресенчә, эчтәлекләре ягыннан тиңдәш кисәкләр белән аныкланалар. Бу кисәкләр үзара грамматик яктан бер-берсенә ярашып киләләр. Әлеге үзенчәлек бары аныклагыч белән аныкланмышка гына хас. Бер грамматик формада килүләрен исәпкә алып кына аларны бер синтаксик вазифа башкаралар дип ялгышалар. Чынында исә, бу ике синтаксик категория арасындагы мәгънә мөнәсәбәте, интонация үзенчәлеге исәпкә алынмый. Димәк, гомумиләштерүче сүз белән тиңдәш кисәкләр арасындагы мәгънә мөнәсәбәтен, интонация үзенчәлеген, грамматик яктан ярашуларын исәпкә алып, алар арасында аныклаулы мөнәсәбәт булуы ачыклана.

Гомумиләштерүче сүзләр, алмашлыклар белән генә бирелмичә, кайбер җыелма күплекне белдерүче сүзләр (исемнәр) белән бирелергә мөмкин. Бу очракта алар тиңдәш кисәкләрдән алда урнашалар. «Гомумиләштерүче сүз аныкланмыш, ә тиңдәш кисәкләр аныклагыч функциясен башкаралар» [2, б. 96]. Мәгълүм булганча, аныкланмыш җөмләнең теләсә нинди кисәге вазифасын үти. Мәсәлән, ия булып килә: *<u>Башка хатыннар</u> – дивана карчык, ялчы Каләмпер, Айбала* аңа булышлык кылалар (Г.И.). Бу җыелма күплекне белдерүче сүзләр алдыннан гомумиләштерүче билгеләү алмашлыклары килергә мөмкин. Бу очракта гомумиләштерүче сүз булып килгән алмашлыклы исем сүзтезмәне икесен бер җөмлә кисәге итеп алырга кирәк.

Аныклагычлар тиңдәш кисәкләр белән бирелгәндә, аныкланмыш үзенең составында билгеләү һәм юклык алмашлыклары булмаса да гомумиләштерә: Ялтырап чыккан кояшның нуры бөтен дөньяны яктыртып, берничә айлардан бирле үлек хәлендә җансыз булып торган *<u>табигатькә</u>, ягъни агачларга, суларга, хайваннарга вә инсаннарга* яңадан җан бирмәктә исә дә, эсселеге илә рәхәтсез итәрлек дәрәҗәдә түгел иде (Г.И.).

Димәк, алда карап кителгән очракларның барысын да аныклаулы мөнәсәбәт нәтиҗәсе итеп карарга кирәк.

2. Тиңдәш кисәкләрдән соң килгән гомумиләштерүче сүз тезүле бәйләнештәге сүзләр белән шулай ук икесе бер җөмлә кисәге була алмый. Тиңдәш кисәкләр гомумиләштерүче сүзгә буйсынган булалар. Алар арасындагы ияртүле бәйләнешне кайчандыр иялек килеше һәм III зат (берлек, күплек) тартым кушымчалары тәэмин иткән. Тиңдәш кисәкләрдәге иялек килеш кушымчасы кыскарган. Бу очракта билгесез килеш формасында килеп, тиңдәш кисәкләр гомумиләштерүче сүзгә карата аергыч вазифасын башкара, ә аерылмыш җөмләдә ия була: *Ир, хатын, бала-чага, яшь-карт – <u>һәммәсе</u>,* эшләрен, сүзләрен уеннарын онытып, Яманкул чокырына агылдылар (Г.И.). Иялек килеше һәм тартым белән үзара бәйләнгән тиңдәш кисәкләр

белән гомумиләштерүче сүзле җөмләләрне Г. Ибраһимов әсәрләрендә параллель очратырга мөмкин: Колхоз рәисенә әйт: *шәп шоферлар, яхшы механик, кирәкле кешеләрнең барысын да* хәзерләсен (Г.И.). *Шул зур елгалар, карт урманнар, шул матур чәчәкләр арасында аккан каннарның, түгелгән күз яшьләренең, чигелгән хәсрәтләрнең һәммәсе* йөрәктән күтәрелеп башка менделәр, аннан дөньяны каплап каттылар да, аккош балалары кебек тезелеп, моңланган яшьләрнең саф музыкалары белән каядыр югала башладылар, күккә таба менеп, безне коткаралар кебек булды (Г.И.).

Кайчакта тиңдәш кисәкләргә иялек килеше һәм тартым кушымчасын ялгап та булмый. Бу грамматик күрсәткечләрне гомумиләштереп килгән сүзтезмә компонентлары кабул итәргә мөмкин: *Шаһбаз, Гыйлаҗи, Фазыйл, Гали, мин – без барыбыз* яшьтәшләр дип йөри идек (Г.И.).

Тиңдәш кисәкләр һәм гомумиләштерүче сүзнең бер синтаксик функция башкармаулары түбәндәге мисалда да ачык күренә. Тиңдәш кисәкләр эндәш сүзләр, ә гомумиләштерүче сүзтезмә ия булып килгән. Атрибутив мөнәсәбәт *сез(нең) һәммәгез* кисәкләре арасында: *Әфләтуннар, Аристолар, Әбүгалисина, Фәраби, Ибне Рөшдләр, Коперник, Ньютон, Декарт, Кант, Вольтер, Гете, Спенсер һ.б., – сез һәммәгез* <...> җавап бирергә үзегезне бурычлы санамыйсызмы?.. (Г.И.).

Бик еш кына тиңдәш кисәкләрдән соң килгән гомумиләштерүче исемнәр нәтиҗә чыгару, гомумиләштерү өчен кулланыла торган кереш сүзләр белән бергә киләләр: *Шәһәрнең шул бизәкләре, шул шау-шулы театрлары, шул матур музыкалы опералары, концертлары, шул бай китапханәләре – кыскасы, мәдәнияте* сине тагы тартыр, син тагы боларны сагына башларсың (Г.И.).

Димәк, тиңдәш кисәкләр һәм гомумиләштерүче сүздән торган төзелмәләр *хаҗчылар(ның) һәммәсе, китаплар (ның) бөтенесе* һ.б. сүзтезмәләр рәвешендә төзелгәннәр. Шулай булгач, тиңдәш кисәкләрдән соң килгән гомумиләштерүче сүзләрне аерылмыш, ә тиңдәш кисәкләрнең үзләрен аергыч итеп карау дөрес була.

Тиңдәш кисәкләкләрне берьюлы ике сүз гомумиләштереп килергә мөмкин. Тиңдәш кисәкләр ия функциясендә килгәнлектән, я булмаса ике хәбәрлек үзәге тәшкил иткәнлектән, бу очракта тезмә кушма җөмлә формалаша, ә тиңдәш кисәкләр һәр ике җөмләгә карата уртак була: *Картлар, өлкәннәр, хатыннар – һәммәсе* арбаларга утырганнар, *кайберләре* дөягә менгәннәр (Г.И.).

Тиңдәш кисәкләрдән соң килә торган гомумиләштерүче сүз тиңдәш хәбәрләр алдында кабатлап бирелсә дә, кушма җөмлә барлыкка килә. Тиңдәш кисәкләр аларның һәр икесе өчен уртак була. Кабатлау монда мәгънәне көчәйтеп тә килә: *Күз күргән бөтен дөнья, әллә кайдан баскычланып менгән таулар, киң басулар, урманнар, үзән елга буйлап сузылган тигез болыннар – һәммәсе* тирән ак кар белән төренгәннәр, *һәммәсе* якты кояш астында гаҗәп бер матур саф аклык белән ялтырап уйныйлар иде (Г.И.).

Тиңдәш җөмләләрне гомумиләштерүче сүз кабатланып бирелсә, катнаш кушма җөмлә формалаша: «*Әнә киң яланнар, әнә уйсу болыннар, әнә зур урманнар – һәммәсе* яшәреп утыралар, *һәммәсенең* өсләрендә куе яшел төс хәтфәләр, *һәммәсенең* йөзләрендә язның матур шатлыгы балкый» (Г.И.). Бу очракта өч атау җөмлә өч тезүле бәйләнештәге җөмлә белән гомумиләштерелгән. Аларның кабатланып килүе мәгънәне тагын да көчәйтеп килә.

Тагын бер мисал карап китик: *Күп заманнар ялгыз калса, балалар авырса, ач торса, ирен сөргенгә җибәрсәләр, зинданга япсалар, урыныннан куып чыгарсалар, тагын әллә ниләр килсә – <u>һәммәсендә, һәммәсендә</u>* шул тирән ышаныч аңа юаныч бирә, Садыйкның күңелендә үзенең, кадерләнеп тирән сакланып асралуы, аның өстенә капланган караңгылыклар эчендә бер якты эз була иде (Г.И.). Бу мисалда тиңдәш булып килгән өлеш 4 иярчен тәмамлык җөмләдән тора, ә гомумиләштерүче сүз *һәммәсендә* баш җөмлә ролен башкаручы һәр ике җөмләнең тәмамлыгы функциясен башкара. Бу очракта гомумиләштерүче сүзнең функциясе ялгызак мөнәсәбәтле сүз функциясенә тиң була.

Менә бу мисалда да тезүле бәйләнештәге җөмләләр гомумиләштерелә һәм гомумиләштерүче кисәк баш җөмлә составында ялгызак мөнәсәбәтле сүз ролен башкара. Тиңдәш җөмләләр иярчен җөмлә булып киләләр: *Дөнья бармы, син кайдадыр яшәгәнсеңме,ниләрдер эшләгәнсеңме, тормышның мәшәкатьләре артыннан чапкансыңмы – <u>һәммәсе</u>* әһәмиятләрен, кирәкләрен югалталар, заманның агуы тоелмый (Г.И.).

Бу мисалда алдагы җөмләдәге тиңдәш ияләр гомумиләштерелә: Ул арада *Сафа бабай, әткәй, күршеләр* килеп, мине ат башыннан кочаклап алдылар, *<u>һәммәсе</u>* мактый, *<u>һәммәсе</u>* рәхмәт укый (Г.И.). Кабатланган гомумиләштерүче сүзләр мәгънәне көчәйтеп киләләр һәм күптезмәле катлаулы кушма җөмлә барлыкка китерәләр.

Шул тәртиптә күптезмәле катлаулы кушма җөмләләрнең ияләре гомумиләштерелә: *Балалар* уеннарын ташлады, *киленнәр, кызлар* баса торган камырларын калдырды, *Ситдыйк кебек*, җәмәгать мәсьәләләреннән читтә калырга тырыша торган *кешеләр* дә ясап яткан арбаларын, ишкән җепләрен оныттылар, *һәммәсе*, әнә шул куркыныч хәбәрнең дулкыны белән җигелеп, Фәхри өе тирәсенә агылып килделәр (Г.И.).

Гомумиләштерүче сүзгә логик басым төшкәндә, ул, тиңдәш кисәкле җөмләдә кулланылмыйча, яңа җөмлә башына чыгарылырга мөмкин. Бер күренешне тасвирлаган хикәя җөмләләрдән торган мөстәкыйль җөмләләр тезмәсендәге тәмамлык, ия кисәкләр гомумиләштерелә: Паларусов портфеленнән кәгазьләрен чыгарды. Кыздырып барган кояш нуры астында, ваклап-тармаклап, *җинаятьнең урынын* сыйфатлап язды. Чокырның уң як ярында саргылт комда тирән *аяк эзе* бар. Пычрак, яңгырлы чакта басылганга охшый. Шуны үлчәп алды. Карт имәннән Байрак белән «Хезмәт» арасында сузылган *тар сукмакны* аеруча карады. *Боларның һәммәсене* кәгазьләргә сызыклар белән сурәтләп ясады (Г.И.).

Абзац төзелешендә тиңдәш кисәкләрнен роле, күләме арта бара. Аларның функциясе хикәяләүдә эпик стиль барлыкка китерү, вакыйгаларны масштаблы, зур күләмле итеп бирү, күренешләрнең, вакыйгаларның билгеләрен күпертеп күрсәтү һ.б. гыйбарәт. «Кызыл чәчәкләр» повестеннан бер генә мисал китереп үтик: Базар кайный. Әллә нинди күз күрмәгән, колак ишетмәгән товарлар белән тулган кибетләрнең алдында, умарта корты кебек, <u>халык</u> шаулый: *кысык күзле, түбән карашлы, кара-соры чикмәннән чувашлар; киң маңгайлы, елгыр күзле, ак чикмәнле кара башкортлар; күбесе итекле, картузлы, кыска киемле, зур сары сакаллы, озын мыеклы руслар; көмеш тәресен ялтыратып йөргән озын кара киемле поплар; ак йөзле, ак сакаллы, кара казакилы, итекле яки читек-кәвешле сәүдәгәр татарлар*, – *<u>һәммәсе</u>* алалар, саталар, алдыйлар, алданалар, үзара гөж киләләр...

Бер үзе бер абзац тәшкил итә торган бу өзек тиңдәш кисәкләрнең күплеге белән аерылып тора, алардан тыш чагыштырулы төзелмәләр, синтетик иярчен җөмләләр дә урын алган. Язучы базар күренешен шундый нык катлауландырылган бер җөмлә белән тасвирлый да бирә. Әлеге мисал үрнәгендә Г. Ибраһимовның абзац төзү осталыгына хас тагын бер үзенчәлеккә игътибар итәргә кирәк: һәр сүзнең җәенкеләндерелгән аергычлары бар, алар, җитмәсә тиңдәш кисәкләр булып килеп, җөмләне тагын да катлауландыралар.

Шулай итеп, гомумиләштерүче сүз белән килгән җөмләләрне анализлаганда, гади җөмлә белән генә чикләнмәскә кирәк. Шул рәвешле катлаулы кушма җөмлә составындагы тиңдәш җөмләләр дә гомумиләштерелә ала. Бу очракта гомумиләштерүче сүзе булган җөмлә баш җөмлә, ә тиңдәш җөмләләр баш җөмләгә карата төрле мәгънә мөнәсәбәтендә торып буйсына. Әгәр без синтаксиста яшәп килгән ялгыш фикергә таянып эш итәбез икән, катлаулы кушма җөмләләрдәге барлык җөмләләр дә бер функция башкара дип карарга туры килә. Мәсьәләгә шулай якын киләбез икән, хата рәвештә тиңдәш иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмләләрне, күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә дип билгеләргә туры килер иде.

3. Гомумиләштерүче сүзләр бер үк вакытта тиңдәш кисәкләр алдыннан да, алардан соң да килә алалар. Әлеге синтаксик категорияләрне грамматик, логик һәм семантик яктан карап, шундый нәтиҗәләргә килергә мөмкин: тиңдәш кисәкләр һәм гомумиләштерүче сүзләр төрле җөмлә кисәге вазифасын башкаралар. Алда килгән гомумиләштерүче сүзләр тиңдәш кисәкләр белән аныклаулы мөнәсәбәттә булалар, алар үзара аналитик чара белән бәйләнәләр. Аныкланмыш теләсә нинди җөмлә кисәге (ия, тәмамлык, аергыч, хәбәр һ.б.) була, ә тиңдәш кисәкләр бары тик аныклагыч вазифасын гына башкаралар. Соңыннан килгән гомумиләштерүче сүзләр тиңдәш кисәкләр белән иялек килеше һәм III зат тартым кушымчасы белән бәйләнәләр, алар үзара төгәлләүле мөнәсәбәттә булалар. Гомумиләштерүче сүз (аерылмыш) теләсә нинди җөмлә кисәге (ия, тәмамлык, урын хәле һ.б.), ә тиңдәш кисәкләр гомумиләштерүче сүзгә карата бары тик аергыч вазифасында булалар. Димәк, гомумиләштерүче сүзләр ияртүче, ә тиңдәш кисәкләр иярүче кисәк булалар. Тиңдәш кисәкләрдән алда килгән гомуми мәгънәле сүзләр (исемнәр, алмашлыклар) тиңдәш кисәкләрне гомумиләштермиләр, киресенчә, аларның эчтәлекләре тиңдәш кисәкләр белән аныклап бирелә. Ә соңнан килгәннәре бик күп билгеләре ягыннан ачыкланалар, төгәлләнәләр.

Күп очракта гомумиләштерүче сүзләрнең һәр икесе бер грамматик формада килә, тиңдәш кисәкләр дә яраклаштырыла: Кисәк *<u>бөтен нәрсә</u> – клумбадагы чәчәкләр, вокзал янындагы каштан агачлары, зәңгәр киосклар, баганадагы түгәрәк сәгать – <u>бөтенесе дә</u>* урыннарын ташлап артка таба кача башладылар (Г.И.).

Г. Ибраһимов әсәрләрендә бу төрдә төзелгән җөмләләр шактый күп кулланылган. Бу очракта тиңдәш кисәкләр гомумиләштерүче сүзләрнең берсе белән генә ярашып килә. Гомумиләштерүче сүзләрнең икесе ике грамматик формада булып, аерым җөмләләрдә төрле җөмлә кисәге функциясен башкарырга мөмкин. Түбәндәге мисалда беренче җөмләдәге гомумиләштерүче сүз тәмамлык, икенчесендә ия вазифасын башкара. Тиңдәш кисәкләр беренчесенә карата аныклагыч, ә икенчесенә карата аергыч вазифасын башкара: Нәрсә бар, *<u>һәммәсен</u>* алдык: *балта, пычак, сәнәк, имән казык – <u>бары да</u>* ярады (Г.И.).

Шулай итеп, бу очракта тиңдәш кисәкләр ике вазифалы булалар: беренчесенә карата аныклагыч, ә икенчесенә карата аергыч ролендә киләләр. Димәк, традицион синтаксистагыча гомумиләштерүче сүзләр белән тиңдәш кисәкләрне бер җөмлә кисәге итеп карау бу очракта да дөрес булмый.

Чын мәгънәсендә тиңдәш кисәкләрдән соң килгәннәре генә гомумиләштерә. Гомумиләштерүче сүз алдыннан сызык куела, чөнки ияләк килеше һәм тартым кушымчалары кыскара, ике арада үзенчәлекле пауза ясала. Ә алдан килгәне исә гомуми мәгънәгә ия булса да, ул гомумиләштерми, киресенчә, аның мәгънәсе тиңдәш кисәкләр белән аныклана. Бу очракта тиңдәш кисәкләр алдыннан, аныкланмыштан соң ике нокта куела, бу, бердән аныклау интонациясен белдерсә, икенчедән, тиңдәш кисәкләр саналып китүен искәртә.

Тиңдәш кисәкләр һәм гомумиләштерүче сүзләр проблемасын хәл иткәндә, гади җөмлә белән генә чикләнмәскә, катлаулы кушма җөмлә, мөстәкыйль җөмләләрнең дә гомумиләштерелә алуын истә тотарга кирәк, Г. Ибраһимов әсәрләрен укыганда, без моның матур үрнәкләрен күрәбез. Анда атау җөмләләр, күптезмәле катлаулы кушма җөмләләр үзләре яисә аларның ияләре һәм башка кисәкләре, аерым абзац тәшкил иткән мөстәкыйль җөмләләр һ.б. гомумиләштерелеп бирелгәннәр.


ӘДӘБИЯТ

1. Галлямов Ф.Г. Структурно-семантическое осложнение простого предложения в татарском языке: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. Уфа, 2007. 62 с.

2. Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле синтаксис һәм пунктуациясе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 258 б.

3. Мифтахов Б.М. Татар теле. 6 кл. өчен дәреслек. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. 136 б.

4. Хангилдин В.Н. Татар теле грамматикасы: Морфология һәм синтаксис. Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. 642 б.


## «ЯШЬ ЙӨРӘКЛӘР» РОМАНЫНЫҢ ФӘЛСӘФИ-ПСИХОЛОГИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ


***Ганиева-Гыйниятуллина А.Ф.***



В статье рассматривается роман Г. Ибрагимова «Молодые сердца». Подчеркивается философско-психологический характер и многогранность произведения. В романе отношение к музыке главного героя Зии объясняется историко-культурными условиями татарской жизни начала XX века.

The article considers the novel by G. Ibragimov, «Young hearts». It emphasizes the multiple layers and the philosophical, the psychological aspect of the novel. The attitude to music of the protagonist Zia is due to historical-cultural conditions of the Tatar life of the early twentieth century.


Г. Ибраһимов – Г. Тукай, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан кебек мәшһүр талант ияләре белән берлектә көнчыгыш традицияләренә нигезләнеп үскән татар әдәбиятын Европа һәм рус сәнгате казанышлары белән баетып, аны югары баскычка күтәргән олуг әдипләребезнең берсе. Үз халкының милли асылын аңлау, аңа чиксез зур мәхәббәт, күпьяклы тирән белем, туктаусыз алга – мәгърифәткә омтылыш, нык характер, фидакарь хезмәт аны бик яшьли олуг талант итеп таныта.

Иҗат юлын «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» (1907) повесте белән башлап җибәргән егет егерме биш яшендә «Яшь йөрәкләр» (1913) кебек киң планлы, татар тормышын, аның рухи-мәдәни торышын төрле яклап ачкан югары сәнгать җимеше иҗат итәрлек язучы булып җитлегә.

Д. Заһидуллинаның «Г. Ибраһимов иҗатында йөзек кашы булган романтик әсәр «Яшь йөрәкләр» романы – ХХ йөз башында иҗат ителгән олы эпик жанр үрнәкләре арасында фәлсәфи-психологик характеры белән аерылып тора» [1, б. 117] дигән фикере белән килешми мөмкин түгел. Ул татар әдәбиятында беренче роман булуына карамастан, Г. Ибраһимов иҗатында гына түгел, гомумән, ХХ йөз башы прозасында югары бәягә лаек гүзәл әсәрләрнең берсе.

Сурәтләү объекты итеп романда татарның зыялы катлау вәкилләре – мулла һәм морза гаиләләре алынган, шуларга бәйле автор ХХ йөз башы татар тормышына карата үзенең фәлсәфи карашларын җиткерә. Әсәр һәркайсын аерым карарга мөмкин булган катламнардан тора: анда язмыш фәлсәфәсе дә, татар мәдәниятенең артталыгына автор борчылуы да, аталар һәм балалар мөнәсәбәте мәсьәләләре дә бар.

Романда иң мөһим катлам – әсәрнең идея-максаты да шуның белән билгеләнә – төп геройның музыкага мөкиббән мөнәсәбәте. «Яшь йөрәкләр» әсәреннән тыш Г. Ибраһимов әлеге мәсьәләгә карата үзенең карашларын публицистик мәкаләләрендә дә чагылдыра [2, б. 178–201].

Эш шунда ки, шәркый-гарәби традицияләрдә үскән шигърият гасыр башындагы яңарыш чорында яңа куәт белән күтәрелеп китә. Ә сәнгатьнең башка төрләре – музыка, рәсем, сынлы сәнгать дини һәм колониаль сәбәпләр аркасында татарда юк дәрәҗәсендә кала бирә. Халыкны агарту, аң-белем тарату эшендә күп хезмәт куйган татар мәгърифәтчеләре һәм әдипләре Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Р. Фәхретдин, Г. Тукай, Г. Исхакый, Ф. Әмирханнар әлеге сәнгать төрләренең рухи әһәмиятен аңлыйлар һәм үзләренең хезмәтләрендә, әсәрләрендә рәсем, музыка сәнгатьләрен тыючы кадими карашларга каршы чыгалар [4, б. 355–356].

Үз милләтен югары үсешкә ирешкән башка халыклар белән бер дәрәҗәдә күрәсе килгән Г. Ибраһимов та әлеге сәнгать төрләренең бездә дә булырга һәм үсәргә тиешлеген укучыга аңлатырга теләп «Яшь йөрәкләр» романын иҗат итә. Әсәрнең төп герое Зыя – шул йөкләмәне үтәүче буларак эшләнгән образ. Ул авторның рупоры – сәнгать турындагы уй-фикерләрен укучыга җиткерүче. Авылның зыялы яшьләре арасында булган бер моназәрәдә ул «Тәңре мине үз каршысына чакырып та “Җә, колым, Зыя, ни максудың бар, ни телисең, сөйлә – бу көн ни сорасаң шуны бирәм”, – дисә, мин аңа: “Татар угылы татардан чын мәгънәсе белән даһи булган бер рәссам һәм дә татар рухында булган барлык гармонияләрне вә барлык тирән серләрне, хәзинәләрне тәмамы белән ачып бирерлек мәртәбәдә куәтле булган бер композитор җитешсен! Мин шуны сорыйм!” – дияр идем» [3, б. 181] ди.

Үз чорында төрле дәрәҗәдәге шагыйрьләр күп булып та, рәсем һәм музыка сәнгатькярләренең булмавына ул көенеп һәм ярым шаярып «Мин халыкның вә бер кавемнең җанын тергезү, йөрәгенә җан бирү бу икедән башка мөмкин була дип ышанмыйм...Шуңа күрә дә, җае чыкса, мин ун мөхәрриребез белән ун шагыйребезне бер чын композитор берлән даһи бер рәссам бәрабәренә бер дә кызганмыйча сатып җибәрер идем...» ди [3, б. 181].

Зыя үзенчәлекле холыклы булган Җәләй мулла гаиләсендә тәрбияләнә. Данлы-шанлы нәселе белән масаеп, үзе әллә ни майтара алмаган ата балаларының да дин юлыннан китүен, ахун дәрәҗәсенә ирешүен тели. Җәләй – ХХ йөз башындагы тар карашлы татар аңын чагылдырган образ. Дин кабыгына бикләнеп, алгарышны берьяклы кабул иткән шундый муллалар татарга үсәргә, дөньяга чыгарга комачаулый, рухи-мәдәни үсешне тоткарлый.

Ата һәм аның уллары арасындагы каршылык тормыш таләпләренә төрлечә караштан туган аңлашылмаучылыктан. Монда язучы үзе һәм Г. Ибраһимов иҗатын өйрәнүче галимнәр билгеләп үткәнчә, мохит мәсьәләсе алгы планга чыга. Әсәрнең геройлары мохит коллары буларак тасвирлана. Аларның берсенең дә диярлек олы бәхеткә ирешә алмавы яшәү рәвешенең дөрес түгеллеген күрсәтә.

Зыяның музыкага мөнәсәбәте әсәрдә милли яссылыкта карала. Урыс картының оста итеп татар көйләрен уйнавы да түгел, зур, дәрәҗәле театрларда яңгыраган опералар, бөтен дөньяга мәшһүр классик музыкалар да түгел, нәкъ менә халыкның үз көйләре, моңнары әсир итә егетне. Сабый чакта ук төнге йокысын бүлеп ишетелгән никрутлар җырының җанга якынлыгын тойган бала, үсә-үсә аның мәгънәсенә төшенә. Һәр халыкның табигате, холкы аның тарихи үткәне, язмышы белән бәйле. «Чын милли музыка – халыкның йөрәгендә булган тойгыларының тудырган җимеше, җанының ахы, зарларыдыр. Татарның асыл табигате бөек, җаны мәртәбәле, йөрәге бик хәссас (сизгер) булып, икенче яктан, язмышы бик агыр, тарихының соңгы сәхифәләре баштанаяк көенеч илә хәсрәт белән тулыдыр. Язмыштан мөтәәссир (тәэсир) булмавы мөмкин булмаган музыкасы да шуның өчен гел җылый, гел моңлана... Мин үземне дә ул тугрыда халыкның угылы саныйм һәм йөрәгемнең музыкага мөнәсәбәтендә шул язмышның катышы бар дип беләм» ди [3, б. 185]. Зыя «халык күңелендәгесен әйтеп бирә торган» милли композитор булу турында хыялланды. Тик мохит аңа хыялларын тормышка ашырырга мөмкинлек бирмәде. Шуңа төп геройның үлеме мохиткә, тар карашлы татар аңына авторның протесты булып аңлашыла. Якыннары аны аңлап та бетермәде кебек. Әмма иң мөһиме – укучы аңлады, ХХ йөз башы татар җәмәгатьчелеге аңлады. Шулай итеп, Г. Ибраһимов кешенең дөньяга карашын киңәйтүдә, рухи матурлык тәрбияләүдә, милләтнең үзбилгеләнешендә, үсешендә һәм танылуында милли сәнгатьнең роле әһәмиятле булуын ассызыклый.

Роман геройларның эчке каршылыгын, фәлсәфи уйлануларын, психологик кичерешләрен оста сурәтләве белән татар әдәбиятында, чыннан да, яңалык була. Авторга рус классик романнарының тасвири чараларын, кешенең рухи халәтен ачу үрнәкләрен өйрәнү иҗади җим булган. Г. Ибраһимов шулар үрнәгендә мәхәббәтнең татар холкына, менталитетына гына хас үзенчәлекләрен гаҗәеп осталык белән тасвирлый алган. Мәрьям белән Зыяның саф, керсез сөюе, җир мәхәббәте генә булмыйча, илаһилаштыру дәрәҗәсенә күтәрелеп сурәтләнә. Ана-бала мөнәсәбәтләре исә якты, нурлы, укучы күңеленә үтеп керерлек җылылык белән чагылдырыла. Ана белән кызның бер-берсен күз карашларыннан да тоемлауларын язганда авторның тормышны гаҗәп тирән аңлавына сокланмый мөмкин түгел. Ә инде ана-ул мөнәсәбәтләре әсәрдә аеруча бер ягымлылык белән сурәтләнә. Зөләйханың сөекле газиз улын солдатка озату газаплары, кичерешләре укучы күңеленең иң нечкә кылларын тибрәтерлек итеп бирелә. Зыя солдатка алынды дигән

көннән башлап ана сүз белән аңлатып бирә алмый торган хәсрәткә төшә: ябыга, көя, «зур күзләре әллә кая эчкә батып, һәрнәрсәгә авыр, җитди, өмитсез карый торганга» [3, б. 225] әйләнә. «Дөньясы тузылган, эшләрендә тәртип беткән... Намазларын гадәттәгедән озак һәм күп укый. (...) Дөнья тын, авыл йокыга чума, өйләрдә ут сүндерелеп, һәркем онытыла, икенче дөньяга китә – менә шул вакыт ул намазлыгын җәя, янына басып кына кечкенә шәмен куя да тын вә ярым караңгы өйдә, пакь намазлык өстендә кулында тәсбих, алдында «Коръән» улдыгы хәлдә, сынган күңелдән илаһи бер хөлус» (ихласлык) белән тәңрегә тәүбәсен, догасын, теләген гарыз итә – ялына, ялвара. Бәгъзан шул хәлдә таңнар атып китә...» [3, б. 225]. Аның кичерешләрендәге әһәмиятле бер моментка игътибар итү кирәк. Әни кешегә бала һәрвакыт газиз. Тик автор иҗат иткән инкыйлабка кадәрге чорда – интернационализм идеясе сеңдерелгәнче – халыкта милли, дини асылны саклау хисе көчле була. Зөләйханың борчылуы улының җан һәм тән исәнлеге өчен генә түгел, ул аның «мыжгырдап торган чәчле, тәреле адәмнәр арасында, башында картус булган хәлдә, бисмилласыз, сул кулы белән тотып чучка ите ашап» [3, б. 226] утыруыннан, «коръән укый торган матур тавышының бетүеннән», «йөзенең урыс төслегә әверелүеннән» [3, б. 226] курка. Ана кеше баласының рухын, иманын кайгырта. Бусы аның өчен иң мөһиме дә. Шулай милләт гасырлар буе үзенең асылын саклап килгән. Сүз уңаеннан әйтеп китү урынлы булыр, бүгенге көндә безнең балаларыбызны бернинди икеләнүсез чит мохиткә – рус балалар бакчаларына, мәктәпләренә илтеп тапшыруыбыз милли үзбилгеләнешебезне саклауга иммунитетыбыз калмаганны күрсәтүче дәлил.

Искә төшерсәк, Мәрьям дә шундыйрак хисләр кичерә. Бер яктан, Зыя солдатка алынгач «йокылы-уяулы» халәттә аның Фәхригә кияүгә чыгып куюы мохит белән аңлатылса, икенче яктан, Зыя белән ул күңеленнән гомерлеккә хушлаша. «Күпләр аннан кайтмый да, кайтса да, әллә ничек үзгәреп, икенче адәм булып кайта, – Мәрьям шуларны эче белән сизә дә, “аның” бу китүен мәңгегә аерылудыр сыман тоя. Гүя ул китә дә югала, бетә; бетмәсә, югалмаса да, Мәрьямгә сөйгән яр була алмый» [3, б. 221].

Әсәрдә Зыя белән Мәрьям тормышындагы бәхетсезлек язмышка бәйләп аңлатыла. Романда шундый бер вакыйга бар: егет белән кызның чираттагы бер очрашуында коточкыч җинаять эшләнә. Бакчада качып утырган пар алдына кисәк кенә каравылчы Хаҗи килеп чыга һәм «уйнашчылар тоттым» дип сөрән сала башлый. Сөеклесенең саф исеменә тап төшерүдән куркып – андый «тотылулар»ның нәтиҗәсе ни белән бетәсен күз алдына китереп – һәм каушап калган Зыя наганы белән картны атып үтерә. Кызны өенә озатканнан соң, мәетне ярдан түбән ыргытып эзне югалта. Ятим картны эзләүче, сораучы булмый. Автор да мәетнең Зыя белән Мәрьямнең төшләренә өрәк булып кереп куркытуын әйтеп кенә үтә һәм бу турыда бүтән искә алмый. Әлеге вакыйга әсәр тукымасына ятып бетмәгән кебек тоелса да, алга таба булачак бәхетсезлекләрнең башы булып тора. Озак тормый патша хезмәтеннән азат ителә дип көткәндә Зыяны солдатка алып куялар. (Биш-алты ел – сөргенгә бәрәбәр). Зыя алынгач, Фәхригә кияүгә чыккан Мәрьям ирен үтерүдә гаепләнеп сөргенгә сөрелә. Чынлыкта, ирен үтермәсә дә, аңа җәза кеше үтергәнгә бирелә. Болар исә әсәрдә гөнаһсыз ялчының гомерен өзүләре өчен бирелгән җәза булып аңлашыла. Автор моны дини тәгълиматка таянып яза: адәм баласы бу дөньяда һәр адымы

өчен җаваплы, хәтта ялгышлык белән кылган гөнаһларына да ачы язмыш белән түләргә мөмкин.

Сүзне йомгаклап шуны әйтәсе килә: Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романы – тормышның күп якларын иңли; укучыны уйланырга этәрә, гүзәллекне күрә белергә өйрәтә торган матур әсәрләрнең берсе. Иҗат ителүенә йөз елдан артык вакыт үтсә дә, ул укыган саен яңа яклары белән ачыла гына бара.


ӘДӘБИЯТ

1. Заһидуллина Д. Галимҗан Ибраһимов // Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. 4 т.: XX йөз башы. 533 б.

2. Ибраһимов Г. Альбом мөнәсәбәте белән бер-ике сүз // Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. 5 т.: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). 616 б.

3. Ибраһимов Г. Яшь йөрәкләр // Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. 2 т. 478 б.

4. Минһаҗева Р. Галимҗан Ибраһимов иҗатында руссочыл традицияләр // Галимҗан Ибраһимовның иҗат дөньясында. Казан, 2012. 375 б.


## ОБРАЗ МАЛОЙ РОДИНЫ В ТВОРЧЕСТВЕ ГАЛИМДЖАНА ИБРАГИМОВА (на примере рассказа «Чубарый»)


***Гаязов А.С.***



Известный татарский писатель и государственный деятель Г.Г. Ибрагимов является одним из ярких представителей деятелей культуры начала XX века, который активно участвовал в революционных событиях 1917 года и Гражданской войне, последующих преобразованиях в России. Большой вклад внесен Г.Г. Ибрагимовым в развитие татарской литературы первой трети XX века. В творчестве Г.Г. Ибрагимова определенное внимание обращено на показ богатой природы и колоритных образов жителей Башкирского края. Ярким образцом этой картины является сюжет рассказа Г.Г. Ибрагимова «Чубарый». В данном произведении показан процесс взаимодействия различных человеческих образов, подчеркивается необходимость диалога между людьми, выделяется необходимость философского осмысления реальности.

The famous Tatar writer and public figure G.G. Ibragimov is one of the brightest representatives of the cultural figures of the early XX century, who actively participated in the revolutionary events of 1917 and the Civil war and subsequent reforms in Russia. A large contribution is made by the G.G. Ibragimov in the development of the Tatar literature of the first third of the XX century. In the works of G.G. Ibragimov some attention drawn to display the rich nature and picturesque images of the people of the Bashkir region. A vivid example of this picture is the plot of the story G.G. Ibragimov «Chubary». This work shows the process of interaction of various human images, the necessity of dialogue between people, highlight the need for philosophical understanding of reality.


Деятельность известного татарского писателя и языковеда, государственного деятеля Галимджана Гирфановича Ибрагимова серьезно повлияла на общественное сознание тюркских народов России первой трети XX века. Он был свидетелем и участником событий революционных собы-

тий и Гражданской войны, многих общественно-политических явлений в царской и советской России.

Несмотря на многообразие форм его деятельности, следует отметить, что своеобразной основой его активной жизненной позиции являлось литературное творчество, которое проявлялось в форме разнообразных содержательных произведений прозы. Здесь большое значение для раскрытия всех граней его многообразного таланта имела его малая родина. Он является уроженцем деревни Султанмуратово Стерлитамакского уезда Уфимской губернии (ныне – Аургазинский район Республики Башкортостан). Атмосфера привольных башкирских степей, лесов и горных массивов влияла с ранних лет на формировавшееся творчество Г. Ибрагимова. В его произведениях фигурируют образы башкир и татар, которые стремятся быть активными ради достижения своих целей.

Связь башкирской и татарской литературы давняя, она многосторонняя и проявляется в самых различных формах. Тема «Галимджан Ибрагимов и башкирская литература» в некоторой степени помогает раскрыть характер взаимосвязей обеих литератур. Г. Ибрагимов – художник, теоретик литературы, общественный деятель, оказавший большое влияние на формирование братских литератур, в том числе и башкирской.

Одним из важных начальных этапов жизнедеятельности Г.Г. Ибрагимова стала работа в качестве преподавателя в медресе «Галия» в Уфе. Известный писатель пропагандировал творчество таких гениев мировой литературы, как Гомер, Данте, Шекспир, Шиллер, Гёте, Байрон, Фирдоуси. Одновременно Г.Г. Ибрагимов глубоко интересовался жизнью башкирского народа. Он изучал древнюю историю башкир, его вдохновлял отважный дух башкир в полевых сражениях и их стремление к победе. В своих произведениях Галимджан Ибрагимов описывает красоту внутреннего мира образа башкира, широту души, положительные человеческие качества. Он считал, что термин «баш» из этнонима «башкорт» является своеобразным фундаментом будущего успеха – этот народ добьется всех материальных и духовных богатств, которые может предоставить судьба.

В качестве достаточно яркого примера можно рассмотреть один из рассказов Г. Ибрагимова под названием «Чубарый (История одной любви)». Повествование ведется от имени автора, который выступает в образе мальчика Закира. Он описывает событие, связанное с приобретением лошади в крестьянское хозяйство. Этот эпизод связан с неожиданным решением известного башкирского борца Алимгула о подарке в виде красивой тучной гнедо-чалой кобылы для отца автора – борца Мухамедхафиза. В связи с этим показывается предыстория данного события. Долгое время татарин Мухамедхафиз был победителем сабантуев по борьбе, прославившись быстрыми победами в ходе состязаний, однако постепенно нашелся другой батыр, который сумел победить борца Мухамедхафиза. Им оказался башкир Алимгул. Автор с увлечением описывает процесс борьбы двух богатырей. Весьма интересными представляется описание начало поединка: «Богатыри, как бы испытывая силы, сначала пробуют браться за пояса, а потом, положа руки на спину друг другу, под взором тысяч глаз, начинают ходить по круглому полю». В этой характеристике писатель образно и емко воссоздает картину спортивного состязания. При этом автор проводит сравнение с хищниками: «Как лев и тигр, положившие передние лапы на

спину один другому, эти два богатыря уже полчаса ходят по кругу». Динамика единоборства национальной борьбы Г.Г. Ибрагимов обозначает следующими словами: «Вдруг опять совсем неожиданно башкир-богатырь прижал Мухамедхафиза к себе, упал с ним на землю и с такой силой перебросил его через голову, что тот отлетел далеко и всей тяжестью рухнул на левую руку». Данный эпизод приводит к выводу о зрелищности и красоте единоборств тюркских народов. В то же время писатель показывает драматизм ситуации ввиду использования победителем запрещенного приема в виде подножки. Последнее обстоятельство вызывает у Алимгула раскаяние и сожаление, которое выражается в его неординарном поступке спустя несколько лет после победы на борцовском ковре. Алимгул начинает испытывать физические и душевные терзания относительно правомерности своей победы на состязании борцов. В итоге, он приходит к решению о необходимости передачи породистой лошади в качестве подарка для проигравшего соперника. Откровения башкирского борца вызывают искренние восхищения у героев рассказа и автора. Они отмечают благородство души башкира в этом поступке.

В представленном сюжете автор отмечает сложность личной ситуации главных героев рассказа – семьи Мухамедхафиза. На почве клеветнического доноса оказался осужден старший брат, а единственная сестра вопреки воле родителей вышла замуж. Словами главного героя автор отмечает, что приобретенная башкирская лошадь «…принесла в наш дом благополучие. Измучившийся без лошади отец за два дня приучил не знавшую до этого времени хомута кобылу к упряжке и начал работать так, будто собирался перевернуть мир. К нам пришел достаток». Таким образом, писатель подчеркивает обучаемость башкирской породы лошадей, что было важной поддержкой для сельских жителей.

При показе образа села писатель отмечает многочисленность поголовья жеребят. Яркими красками автор раскрывает сюжет относительно содержания лошади в крестьянском хозяйстве отца главного героя. В связи с этим обращается внимание на богатство природных ресурсов Башкортостана. В качестве примера здесь приводится описание окрестностей озера Кондызлы, где сельские жители получали большие уловы различных рыб.

Большое впечатление на читателя производит описание окрестностей реки Узан. Под влиянием красоты природы Башкортостана главный герой рассказа произносит знаменательные слова: «Люблю я свою деревню! Люблю ее горы, которые закрывают деревню с севера. А еще больше люблю дремучий лес, который растет и шумит тысячи лет на этих горах!» После этого писатель подчеркивает разнообразие растительного мира родного края в виде насаждений щавеля, земляники, малины, смородины, орехов. Автор стремится показать связь с внешним миром, отмечая взаимосвязь реки Узан с крупными водоемами в виде рек и Каспийского моря. Диалоги детей – героев рассказа о достопримечательностях родного края производят впечатление реальности происходящего.

Ключевым сюжетом рассказа является эпизод, связанный с рождением жеребенка. Герои рассказа восхищаются внешним видом жеребенка и прогнозируют счастливое будущее. Один из персонажей дедушка Сафа говорит: «Ну, Закир, большое счастье тебе привалило – гнедо-чалая кобыла башкира отца твоего поставила на ноги, а тебе дала чубарого жеребенка».

Автор умело раскрывает дальнейшую канву событий. Главный герой показан энергичным и заботливым хозяином при уходе за жеребенком. Жестокое испытание в виде нападения стаи волков на конский табун заставляет Закира сильно переживать. Его чувства начинают проявляться и тогда, когда отец Закира принимает решение об использовании подросшего жеребца для вспашки земли. Здесь автор упоминает о плодородных башкирских угодьях, которую герои рассказа планируют ввести в земледельческий оборот. Однако мнение главного героя Закира повлияло на решение его отца и последний отказывается использовать жеребца при вспашке. В итоге, Закир принимает решение о необходимости подготовить своего коня для скачек на сабантуях.

Автор показывает значение сабантуя для героев рассказа. Он отмечает, что серьезными конкурентами на скачках должны были быть горные башкиры. В связи с этим отец и дедушка стали помогать Закиру в подготовке коня к скачкам. Автором развернуто показан непосредственный процесс подготовки к скачкам и ярко описываются лошади конкурентов. Среди них выделяется описание аргамака горных башкир.

Своеобразным апогеем сюжета рассказа является показ самого процесса конных скачек. Картина соревнования двух лошадей башкирской породы ярко воспроизводится автором. В последний момент у финиша дистанции главный герой выходит первым и завершает скачку. Однако Закир не получает награду как победитель, что вызывает у него протест против устроителей соревнований. Резкий поступок главного героя в виде нанесения удара плеткой старосте деревни является концентрированным выражением чувств, но люди поддерживают Закира. Однако победа вскоре проявляется и негативным образом: жеребец Чубарый погибает после соревнований.

Таким образом, в данном рассказе Г.Г. Ибрагимова обозначены красоты родного края, драматизм сельской жизни, обозначаются черты характера людей, живущих на башкирской земле. Писатель призывает к необходимости любви к природе, растительному и животному миру, диалогу между людьми, философскому осмыслению реальности.

В своих произведениях Г.Г. Ибрагимов могучим писательским талантом фактически поставил памятник земле башкирской, великодушному башкирскому народу. В произведениях писателя мы ощущаем дыхание нашей родной земли, запах ее трав и цветов, слышим журчание прозрачных ручьев и главное – видим людей, живущих на этой земле со своими радостями и горестями. Следует быть благодарным писателю, который своим изумительным талантом наряду с образами татар, изобразил удивительные по своей пластичности и жизненности образы представителей башкирского народа. Его роль в истории башкирской литературы проявилась во многом. Наряду с Мажитом Гафури, Шайхзадой Бабичем и другими деятелями культуры Галимджан Гирфанович Ибрагимов стоял у истоков большого пути башкирской литературы XX века.

ЛИТЕРАТУРА

1. Ибрагимов Г. Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. 5 т.: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933) / бишенче томны төзүче, текст, искәрмә һәм аңлатмаларны әзерләүчеләр: М.Х. Хәсәнов, Р.Р. Гайнанов. 615 б.

2. Ибрагимов Г. Әсәрләр: 9 томда. Казан: Фикер, 2000. 9 т.: хатлар һәм документлар / җыентыкны төзүче, текст һәм аңлатмаларны хәзерләүче Ф.И. Ибраһимова. 454 б.

3. Ибрагимов Г. Чубарый (История одной любви) // http://kitaphane.tatarstan.ru/ibr_3.htm

# ҮЗ ЯЛКЫНЫНДА ДӨРЛӘП ЯНГАН ӘДИП

***Гыйльманов Д.Ш.***

Сталинские репрессии коснулись и Галимджана Ибрагимова. 29 августа 1937 года он был арестован и по этапу отправлен в Казань. Тяжелая болезнь в условиях заключения усугубилась до крайней степени, и 21 января 1938 года писатель скончался в тюремной больнице.

Stalin's repressions had concerned Galimdzhan Ibragimov. On August 29, 1937 he had been arresten and had been sent to Kazan. The writer died of serions illness from the hardest condi tions in prison's hospital.

XX гасыр – социаль тетрәнүләр, революцияләр, катаклизмнар чоры иде. Аларның иң күренеклесе, әлбәттә инде, Рәсәйдә социалистик революция белән тәгәлләнгән революцияләр чылбыры. Илдә диктатура урнашты. СССР дип аталган тоталитар системаның үз халыкларына карата кулланылган төп эш методларының берсе булып террор киң колач ала.

Моның мисалы – бихисап. Бу хактагы тарихи документларны, мәкаләләрне, истәлекләрне укыганда, әле дә чәчләр үрә тора. Шул көннәр турында Татарстанның халык шагыйре – Гамил Афзал болай дип язган:

Большевиклар искелекне җиңде,
Яңа юлга чыгып шат булдык,
Яңа юлдан барган идек инде,
Колымага килеп тап булдык.

Бу юлларда әйтелгән язмышка күп кенә татар язучылары да дучар ителде. Алар арасында Г. Ибраһимов та бар иде.

Г. Ибраһимов революция алды елларында эсерлар партиясе әгъзасы була, соңрак аның сул канатында тора, Октябрь инкыйлабы елларында большивиклар белән хезмәттәшлек итә һәм аларның платформасына күчә.

Бу елларда Г. Ибраһимов милли мәсьәләләр буенча күп эшли, милли дәүләтчелек проблемаларын күтәреп чыга. Билгеле, аның бу өлкәдәге эшчәнлеге большевикларның шовенистик сәясәтенә туры килми. Россиянең төрки милләтләренә хөрлек, дәүләтчелек булдырырга омтылган Г. Ибраһимовның яңа дәүләткә кирәге булмый. Яңа хөкүмәт органнары аны 1919 елларда ук Колчак армиясе тылына җибәреп юк итмәкче була, ләкин ул аннан исән-сау әйләнеп кайта.

Г. Ибраһимовның башы өстендә кара болытлар егерменче елларның икенче яртысында куера башлый. НКВД хезмәткәрләре аны көне-төне күзәткәннәр. Әдипнең эшчәнлеге һәм аның белән аралашкан кешеләр турындагы мәгълүматлар тиешле урыннарга җиткерелә торган.

Александр Солженицын үзенең «Архипелаг ГУЛАГ» әсәрендә язганча, 1937 елларда шәхес культының яңа дулкыны киң колач җәя, коммунистлар партиясенең танылган әгъзалары кулга алына һәм төрмәләргә ыргытыла [5, б. 89].

Бу дулкынга Г. Ибраһимов та эләгә. Әдип 1937 елның 29 августында Ялтада үпкә авыруыннан дәваланып яткан җиреннән кулга алына [4, б. 108].

Революция өчен җанын-тәнен кызганмаган, үзенең бөтен иҗатын һәм практик эшчәнлеген революциягә багышлаган язучыны троцкийчы контр-

революцион оешма төзеп, Сталинга, совет-партия җитәкчелегенә каршы һөҗүм әзерләүдә гаеплиләр.

Г. Ибраһимов Казанга сентябрь башларында китерелә һәм Пләтән төрмәсенә ябыла. Берничә көннән соң ялыктыргыч сорау алулар башлана. Бу мыскыл итүләр, түбәнсетүләр болай да авыру һәм көнне-көнгә көчкә генә ялгап барган әдипнең соңгы көчен дә, саулыгын да алып китәләр. Сорау алулар вакытында, Г. Ибраһимовны сындырып үзләренең кара гамәлләренә ирешер өчен, тикшеренүчеләр әдипкә медицина ярдәме күрсәттермиләр.

Хәле никадәр генә авыр булмасын, әдип тикшерүчеләрнең уйдырма протоколларына кул куймый, иректә калган язучы дусларына яла якмый. Тәмам бетерешкән, эштән чыккан Г. Ибраһимовны 21 октябрьдә төрмә лазаретына күчерәләр. Хәле бераз яхшырганны күреп, тикшерүчеләр сорау алуларны дәвам итәләр. Ләкин шуларның берсеннән инде Г. Ибраһимов камерага үз аягы белән кайта алмый. Аны, ике ягыннан култыклап, сакчы белән санитарка алып киләләр. Ул бөтенләй хәлсезләнә, тамактан кала. Өстәвенә юеш, дымлы, салкын бүлмәдә тотылу да Г. Ибраһимовның сәламәтлегенә зыян сала. Төрмәдә Г. Ибраһимовка тиешле медицина ярдәме күрсәтергә мөмкинлекләр булмый. Ялтада көнаралаш юдырылып торган ярым үпкәсе дә тәмам эштән чыгып, сулыш ала алмый башлый. Шундый приступларның берсе 1938 елның 21 гыйнварында әдипне якты дөньядан мәңгелеккә алып китә. Әдип, кайбер тикшеренүчеләрнең әйтүенчә, Архангель зиаратындагы гомуми чокырга күмелә.

Бүгенгесе көндә Арча зиаратында Г. Ибраһимов «каберендә» торган һәйкәл дә шартлы рәвештә генә куелган. Г. Ибраһимовның кайда күмелгәнен ачыктан-ачык күрсәткән документларның әле бүгенгесе көндә дә табылганы юк [2, б. 171]. Палачлар үзләренең кара гамәлләрен яхшы яшергәннәр.

Г. Ибраһимовның кабере билгесез булган кебек, әдипне кулга алганда Ялтадагы квартирасыннан алынып зур чемоданга салынган язулар да, ике капчыкка тутырылган китаплар да эзсез югала. Шулай ук, Г. Ибраһимовның Ялтага дәваланырга киткәндә Дәүләт музееның кыйммәтле экспонатлар саклый торган подвалына урнаштырып калдырылган Казандагы өй җиһазлары да, искиткеч бай китапханәсе дә таланган, төрлесе-төрле якка таралган, беришләре юкка чыгарылган, яндырылган. Музейга куярлык әйберләре дә калмаган.

Г. Ибраһимовның үлем алдыннан: «Утыз елдан артык эшләгән эшләремнең соңы шулай булыр дип уйламаган идем. Партиям алдында да, халкым алдында да минем гаебем юк. Тарих аны үзе тикшерер, раслар, дөрес бәһа бирер» [3, б. 265], – дип әйткән сүзләре әдип үлеп 17 ел (1955) үткәч кенә раслана. Үзе кабызыган утта дөрләп янган әдипнең намуслы исемен, бай иҗатын торгызу, әсәрләрен халыкка кайтару буенча эшләр башлана.

ӘДӘБИЯТ

1. Баттал Г. Миражга алданган язучы // Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр / төз. Р. Акъегет. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. Б. 446–456.

2. Мостафин Р. Галимҗан Ибраһимовның соңгы көннәре // Казан утлары. 1990. № 7. Б. 166–171.

3. Мөхәммәдева Г. Олы юл: документаль повесть. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. 272 б.

4. Литвин А.Л. Запрет на жизнь. Казань: Татар. кн. изд-во, 1993. С. 108–122.

5. Солженицын А. Архипелаг ГУЛАГ. 1918–1956: опыт художественного исследования. Ч. I–II / под. ред. Н.Д. Солженицыной. СПб.: Азбука, Азбука-Аттикус, 2017. 640 с.

# Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ «БЕЗНЕҢ КӨННӘР» РОМАНЫНДА ТАТАР МИЛЛИ МӘГАРИФ СИСТЕМАСЫНЫҢ БИРЕЛЕШЕ

***Даутов Г.Ф., Әхмәдгалиева Г.Г.***

К творчеству известного татарского прозаика Г. Ибрагимова всегда было приковано особое внимание литераторов, критиков разных эпох. Это объясняется тем, что он сумел описать в своих произведениях самые волнующие проблемы общественности: нравственность, порядочность, духовность и любовь к своей Родине.

В данной статье рассматривается тема татарского национального образования, которую поднимает Г. Ибрагимов в своем романе «Наши дни». Автор акцентирует внимание на изменении мировоззрения и отношения к образованию шакирдов описываемого времени, что отражается в душевных переживанияхгероев через призму нравственных и социальных пороков татарского общества начала XX века.

The creativity of the famous Tatar novelist G. Ibrahimov was always attracted by the attention of writers, critics of different eras. This is due to the fact that he was able to describe in his works the most disturbing problems of the public: morality, decency, spirituality and love for his Motherland.

This article deals with the theme of the Tatar national education, raised by G. Ibragimov in his novel «ur days». The author focuses on changing the outlook and attitude towards the formation of the shakirds of the time described, which is reflected in the spiritual experiences of the heroes through the prism of the moral and social defects of the Tatar society of the early 20th century.

Кайвакыт студентлардан әллә нинди сәер сораулар чыгып куя. Мәсәлән, бер кызыбыз XX йөз башы әдәбияты буенча лекциядән соң «Кем бөегрәк: Галимҗан Ибраһимовмы, Гаяз Исхакыймы?» дип сорады. Сорау, сабыйларча, беркатлы булса да, уйланырга мәҗбүр итте…

Әйе, бөеклек категориясенең үлчәү берәмлекләре юк, аны бизмәнгә салып, чагыштырып карап булмый. Югарыда телгә алынган ике әдипнең иҗатлары да, язмышлары да бер-берсенә охшаш та, шул ук вакытта төрле дә: икесе дә мулла балалары, икесе дә шул чор руханилары өчен хас булган рәхәт һәм җайлы тормыштан баш тартып, Сталин диктатурасын үз җилкәләрендә татыганнар. Әмма Г. Исхакый большевизмга каршы ачыктан-ачык көрәш юлын сайласа, Г. Ибраһимов исә, килешеп, фикерләрен шул заманда хакимлек иткән законнар кысасында үткәрергә тырышкан.

Иҗатларындагы төп уртаклык – миллилек, милли гамь. Иҗат иткән һәр әсәрендә диярлек, татар яшәешенең бер ягы ачыла. Г. Ибраһимов «Татар хатыны ниләр күрми?» әсәрендә (тематикасы исемендә үк чагылыш таба), Г. Исхакый «Теләнче кыз»ында бер үк проблемаларны күтәрәләр. Беренче әдибебез дәүләтчелеге югалган татар мохитендә талантның фаҗигагә дучар ителүен «Яшь йөрәкләр»дә ачып бирсә, шуны ук Исхакый «Мулла бабай»да гәүдәләндерә. Мондый параллельләрне күпләп китерергә мөмкин. Ләкин Г. Ибраһимовның татар-иҗтимагый сәяси тормышының энциклопедиясе дип саналырлык «Безнең көннәр» романы әдәбият дөньясында аерым урын алып тора.

Альп тауларыннан алып, Сахалин утрауларына кадәр җәелгән империянең XX йөз башындагы тынгысыз тормышын әдип, образлы итеп: «Төн

караңгы. Дөнья тын. Ләкин диңгез шаулый. Диңгез төбендә кемгәдер ачу белән үкеренә. Аның куәтле дулкыннары, тау-тау булып, биек, ташлы, текә ярларга һөҗүм итәләр. Күңелгә шом килә: гүя менә-менә тагы бер-ике тапкыр сугып атылачаклар да дөньяны каплап китәчәкләр», дип, башланып китә дә, икенче бүлекне «Кяфер узара сугыша» дип атап, татар тормышына, анда барган үзгәрешләргә күчерә: «Шул җомга көн кич, теге кызыл байрак күтәреп йөргән фетнәчеләрнең башлыклары арасында элек яһүд байда приказчик булып торган Габдрахманны күргәннәр… Әйтәләр: «Мәдрәсәгә исламия шәкертләре арасында остазларына каршы көрәш башланган икән», диләр» [2, б. 12].

Кемнәр генә, җәмгыятьнең нинди генә катламнары, нинди генә партияләр юк әсәрдә! Шулай да, язучы тарафыннан аеруча игътибарга лаеклысы һәм романда зур урын алып торучы күренеш – ул мәдрәсә һәм аның шәкертләре. Бу урынлы да, чөнки, бердән, XX йөз башында уку-укыту мәсьәләләре татар милләтенең яшәү-яшәмәү кебек иң әһәмиятле, көнүзәк мәсьәләсенә әверелгән була. Икенчедән, ул инде белем алу системасы булудан туктап, халыкны урта гасырлардагыча фикерләүдән тартып чыгарып, заман таләпләренә җавап бирердәй менталитет формалаштыру, шуның аркылы тарих арбасыннан, дөресрәге, инде поездан төшеп калмау өчен көрәш була. Өченчедән, сәяси көрәшнең алдынгы сафларында һәрвакыт укучы яшьләр барган. Шуңа күрә, язучы үзе билгеләгәнчә, «шәкерт чуалышы» менә мондый таләпләр куюдан башлана: «Мәдрәсәләргә яңа тәртип кертелсен. Мантыйк (логика), схоластика ташлансын! Европа фәннәре – тарихлар, җәгърафияләр, һәндәсәләр (геометрия), химия – укылсын! Урыс теле мөкәммәл (тулы) булсын! Фөнүне җәдидә (яңа фәннәр), рәдде нәсара (христиан диненнән кире кагу), тәфсир, хәдис, әдәбият дәресләре программада булсын!» дип, гариза бирәчәкләр. Әгәр инде мөдәррисләре бу теләкләрне кабул кылмаса, мәдрәсәнең дүрт-биш шәкерте җыелып, бергә уку башлаячак, ди» [2, б. 144].

СССР дигән дәүләттә коммунизм тәрбияләү хакимлек итте. Коммунистик идеология интернациональ дип белдерелде, газеталарның беренче битендә дә «Бөтен дөнья пролетарийлары, берләшегез!» дигән өндәмә торды һәм миллилек тулысынча инкарь ителде, 1917 елга кадәр булган тормыш тоташ кара буяулар белән сурәтләнде. Шул исәптән, татар халкының үткәне, аның мәгариф системасы һәм мәктәп-мәдрәсәләре дә наданлык оясы итеп күрсәтелде. Күренекле галим Равил Әмирхан бу хакта болай ди: «Еш кына татар халкы революциягә кадәр мәдәният дөньясыннан читтә калган, үз эченә бикләнгән, басылган, томана, надан, үзенең милли мәктәпләре, дәресләкләре, хәтта үз язуы да булмаган бер халык иде, дигән сүзләрне ишетергә туры килә. Кайбер «тарих белгечләре»нең фикере буенча, татарларны җәһаләт (наданлык) баткагыннан, янәсе, бары тик Октябрь инкыйлабы гына тартып чыгарган һәм мәдәниятнең олы баганалы юлына алып чыккан икән» [1, б. 145].

Ләкин, «Безнең көннәр»дән югарыда китерелгән өзекне укыганнан соң, башка уй килә: совет белгечләре әйткәнчә, надан һәм томана булган шәкертләре реформа таләп итеп чыгарга сәләтле булырлар иде микән? Ул, чынлап та басылган булса, укый-яза белмәсә, Европа стандартлары турында сүз алып бара алыр идеме? Шәкертләр тарафыннан укытуны таләп ителгән фәннәре да игътибарны җәлеп итә. Тарих, җәгърәфия кебекләре аңлашылса

да, рәдде нәсара (христиан динен кире кагу), хәдис (пәйгамбәрләр сүзләре) фәннәрен уку-укыту программасына кертүне сораулары күп кенә нәрсәләр турында сөйли. Димәк, XX йөз башы татар укучы яшьләре, беренчедән, бөтен нәрсәне кире кагучы атеист һәм нигилист түгелләр, икенчедән – бөтен нәрсәгә сукырларча ышанучы дини фанатиклар да булмаганнар. Алар исламны фәнни нигездә аңларга омтылып, динне «әдәп вә әхлак» дип яшәгәннәр дигән сүз. Юк, ул замана татар яшьләре һич кенә дә басылган, аңнары схоластика белән томаланмаган була. Шул ук вакытта тагын бер сорау туа – әгәр мәктәпләребез начар, заманнан артта калган икән, кайда һәм ничек күзләре ачылган соң бу егетләрнең, замана сулышын тоярлык әзерлекне кем биргән? Моңа бер генә аңлатма булырга мөмкин: мәдрәсәләребезнең белем бирү дәрәҗәсе совет фәнни әдәбиятында тасвирлаганча түбән булмаган. Моңа халкыбызның белемгә омтылып яшәвен дә өстәргә кирәк. XVIII гасырдан ук Бохарага, Сәмәркандка кадәр җәяүләп барып, белем алучы яшьләребез – дөньякүләм билгеле булган галимнәребез Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдиннәребез – моңа ачык мисал.

XIX йөз ахыры, XX гасыр башы татар мөгаллимнәренең фидакарьлеге һәр халык, һәр чор өчен үрнәк булырлык. «Безнең көннәр»дә шәкерт кузгалышы белән бәйле вакыйгада әйтеп үтелгән укытучыларның күркәм образы бирелә. Менә «Исламия» мәдрәсәсе шәкертләре җыелышында ислах, ягъни реформа таләп итәләр. Яшьләргә хас булганча, аларда максимализм көчле: бар үзгәрешләр шул ук вакытта һәм тулысынча үтәлгән булсын. Алар протест белдереп, революцион «Сада»ны җырлыйлар, кызып китеп, лампа, тәрәзә пыяласын ваталар. Мәдрәсә җитәкчесе мөдәррис Гали хәзрәт, «…егерме ел гомерен төрле мәдрәсәләрдә гыйлем алуга биргән», «…иске, кадим мәдрәсәләргә дошман ителгән…», аннан Мәккә, Мәдинә, Истамбул, Мисырда белем алган, «…Русиягә кайтып, Мисыр, Истамбулның яңа мәдрәсәләре кебек мәдрәсә торгызмак булып, эшкә тотынган…» кеше, ике, хәтта өч ут арасында кала: бер яктан, чуалышлар булуны сәбәп итеп, мәдрәсәне ябып куярга теләгән хөкүмәт; икенче яктан, мәдрәсәнең бөтен чыгымнарын түләп баручы һәм, әлбәттә, укучы яшьләрнең мондый кыланышларына канәгать булмаган байлар; өченче яктан – шәкертләр. Гали хәзрәт нишләргә белми, барысын да җайларга, бу ситуациядән чыгарга тиеш, тик барысы да аны гаепле дип саный. Мәсәлән, шәкерт төркеменнән берәү кычкыра: «Ябылсын! Кадалсын мәдрәсәң! Ач калудан куркасыңмы, ул ябылса?». Һәм дәүләтчелеген югалткан, ләкин өметен югалтмаган халкының киләчәген мәгарифтә күргән татар мөгаллиме Гали хәзрәтнең моңа җавабы: «Бу сүзне кем әйтә? Кем әйтә? Их, җаным, бик артык баласың. Артык сабыйларча карыйсың! Бир миңа берничә миллион акча! Мин Парижның беренче университеты кебек мәдрәсә төзермен! Ул кирәк. Бу кирәк. Без ачбыз. Моннан чыккач, эшкә ярамыйбыз, дисез. Урыслар фәлән кыйла, төгән кыйла, безнекеләрдә юк, дисез! Мин үзем дә аны беләм, кулдан килгәне бары да эшләнә. Әмма юкны кайдан алыйк: кая зур биналар? Кая яхшы мөгаллимнәр? Кая яхшы дәреслек, китаплар? Кая һәртөрле фәнни әсбаб алырга байлык? Кая акча? Татар дөньясында булмаганны бүген генә мин кайдан алыйм?» [2, б. 154].

Татарларның белемгә омтылышы, мәгариф өлкәсендә ирешкән уңышлары патша хөкүмәтен нык сагайта. Әле 1870 елда ук Россиянең мәгариф министры Д.А. Толстой тарафыннан «Конечной целью образования всех

инородцев, живших в пределах нашего отечества, должно быть обучение их и слияние с русским народом», дип билгеләнгән эшчәнлекнең төп авырлыгы татарлар өстенә төшә [3, б. 35]. Чөнки империянең үзәк өлешендә яшәүче халыклар арасыннан бары тик татарларның гына үз мәктәпләре, үз уку-укыту системасы булган һәм самодержавие әлеге системаны җимерү өчен мөмкин булганнарның барысын да куллана. Романда ул болай тасвирлана: «Хөкүмәт мөселманнар арасында социализм эзли, революция эзли. Шулай ук пантюркизм эзли, панисламизм эзли. Шуңа күрә прокламация баскан яки сәяси түгәрәккә йөргән һәрбер шәкерт жандармнарны ничаклы борчыса, Кәрим Гайфинең кызыл фәсе белән тар кара җөббәсе, русча китаптан файдалана алмаганга күрә, Истамбул басма дәреслекләр буенча укыткан һәрбер мөгаллим, аның квартирында табылган һәртөрле Мисыр, Төркия басма китаплар – охранка алдында гаҗәп зур шөбһәле әйберләр, куркынычлы әйберләр булып күренәләр».

Кәрим Гайфи – романда тасвирланган чорның гадәти дә, гадәти дә булмаган баласы. Язмышы, шул чорда күпләргә хас булганча, Истамбулда дөньяви мәктәптә белем алган, яхшы әзерлекле укытучы. Ләкин ул, башкалардан аермалы буларак, искиткеч сәләтле була: «Әгәр Төркиядә калса, фән дөньясында яхшы урын табарлык галим булып чыгуында шик ителми иде. Әгәр үзе теләсә, Төркия хөкүмәте тарафыннан Европага укырга җибәреләчәк, аннан бетереп кайткач, Төркиядә профессор булып калачак иде». Ул, бәлки, Төркиядә калган да булыр иде, ләкин Төркиянең үзендә дә милли күтәрелеш, яңарыш дулкыны мәйданга чыга, мәмләкәтнең алдынгы карашлы кешеләре, дөньякүләм фикер йөртеп, төрки кавем, төрки кардәшлек хакында уйлана башлаган вакыт. Шундыйларның берсе – Әхмәд Мидхәт (1844–1913) – төрек язучысы, мәгърифәтче, төрек әдәбиятында кыска хикәягә һәм романга нигез салучы. Романнар, хикәяләр, пьесалар һәм тарих, дин, философия, география мәсьәләләренә багышланган китаплар авторы аңа кайтырга киңәш бирә һәм егет, укытам дип, шул эшчәнлегем белән милләткә хезмәт итәм, дип кайтып, дәртләнеп эшкә тотына. Ләкин илдә революция шаукымы дулый. Революция бар нәрсәне, искеме, яхшымы, начармы икәнен тикшереп тормыйча, инкарь итү дигән сүз. Җәмгыятьнең күнегелгән тормыш рәвешен яклаучыларны ул читкә этәрә, я бөтенләй юк итә, шуңа күрә «Кузгатылган һәрбер дулкын, күтәрелгән һәрбер көрәш мөгаллим Кәрим Гайфине шәкерт ялкыны белән капма-каршы куя торган булып китте».

Әнә шундый каршылыклар белән яши татар дөньясы XX йөз башында. Болар барысы да Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» романында тормышчан детальләр, тулы канлы образлар аша фаҗигасе дә, тантанасы да гәүдәләндерелә. Дөрес, бу әсәрдә сурәтләнгәннәрнең бер өлешенә, мәгариф өлкәсендә барган вакыйгаларга гына туктадык. Ләкин алар да, татар яшәешендәге катлаулы иҗтимагый вәзгыятьне шактый төгәл күзалларга ярдәм итәләр.

## ӘДӘБИЯТ

1. Әмирхан Р. Иманга тугрылык. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. 145 б.

2. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. 4 т. 462 б.

3. Махмутова А. П.А. Столыпин: «...направить серьезные усилия к пресечению национально-татарского образования...» // Эхо веков / Гасырлар авазы. 1998. № 3–4. Б. 35.

4. Мингазова Р.А., Габидуллина Ф.И. Тема любви в рассказе Г. Ибрагимова «Любовь – счастье» // Научные труды SWorld. ООО «Научный мир»: Иваново, 2013. Т. 26. № 1. С. 12–15.

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ГАРӘБИ ЧЫГЫШЛЫ ФИГЫЛЬЛӘР ҺӘМ АЛАРНЫҢ Г. ИБРАҺИМОВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ КУЛЛАНЫЛЫШЫ

***Денмөхәммәтова Э.Н.***

В работе рассматриваются формы словообразования глаголов татарского языка от арабских лексем. Несмотря на то, что ученые-лингвисты и общественные деятели (в том числе и Г. Ибрагимов) в разные годы выражают свои не только позитивные мнения относительно данного пласта заимствованной лексики в тюркских языках, арабские слова плотно закреплены в языке, используются как отдельные лексемы и в различных словообразовательных формах как корень или основа татарского слова. Об этом свидетельствуют и примеры из произведений Г. Ибрагимова.

The work deals with the forms of word formation of the Tatar language verbs from Arabic tokens. Despite the fact that linguistic scientists and public figures (including G. Ibrahimov) in different years express their not only positive opinions on this layer of borrowed vocabulary in Turkic languages, Arabic words are tightly fixed in the language, used as separate lexemes and In various derivational forms as the root or foundation of the Tatar word. This is evidenced by examples from the works of G. Ibragimov.

Гасырлар дәвамында төрки телләрдә билгеле бер атама, предмет, сыйфат, билге, эш-гамәлләрне белдергән гарәп һәм фарсы телләреннән кергән сүзләр бар. Аларга карата галимнәрнең, җәмәгатьчелекнең фикере төрле елларда гел үзгәреп торган. Кемнәрдер аларны телдән чыгарып ташлау турында сүз йөртсә, башкалары, киресенчә, рус-европа сүзләрен аларга алыштыруны хуп күргән. Күренекле галим, әдәбиятчы, киң җәмәгать эшлеклесе Г. Ибраһимовның да алынма сүзләргә карата үз фикере булган. Ул тел үзенең «Татар телен җиңеләйтү турында тезислар»ында «Татар әдәби теленең иң төп нигез материалы үзебезнең ана телебездән алынырга тиешле. Татарчада сүзләр була торып, болар урынына башка һичбер телдән һичбер сүз кертелмәсен!», дип белдерә, һәм «моңарчы әдәбият-матбугат дөньябызны каплап, әдәби, гыйльми әсәрләрне хезмәт халкына аңламаслык ясауга сәбәп булган гарәбизмгә каршы көрәш башларга, боларны ташларга кирәк» ди. Әмма түбәндәгеләрне бу кагыйдәдән чыгарылма буларак тәкъдим итә: «1) гарәпчәдән кереп тә, халык эчендә үз теле кебек үзләшкән сүзләр элеккедәй үз урыннарын саклыйлар (каләм, китап, дөнья, шәйкать, мәрхәмәт, рәхмәт, мәктәп, мәдрәсә, кабер, ахирәт, хикәя кебекләр); 2) Әдәбиятыбызда киң рәвештә таралып, гражданлык алып, үз сүзләребез дәрәҗәсендә үзләшкән атамалар, сүзләр, гарәпчәдән булсалар да, һаман да матбугатыбызда кулланылырлар (әсәр, шигырь, әдәбият, мәгариф, милләт, тарих, мисал, гыйлем, фәлсәфә, әхлак, хезмәт, тәрәкъкый, мәсьәлә, хәреф кебек); 3) Исламның үзендә генә булып, татарча һәм башка телләрдә дә булмаган мәгънәләрнең аталмалары шул гарәпчә яки фарсыча рәвешендә йөртелер» [3, б. 261–263]. Әлеге фикер бүгенге көндә дә актуаль. Чыннан да телебез калыбына яраклашкан гарәп алынмалары татар телендә актив кулланылышта йөри, сүз ясалышында катнашып, яңа татар берәмлекләре барлыкка китерә. Мондый күренеш фигыль сүз төркеменә караган сүзләрдә дә күзәтелә.

Фигыль төрки тел белемендә иң мөһим сүз төркеме булып санала һәм аңа хас грамматик категорияләрне өйрәнү, фигыль формалары турында бәхәсләр алып бару галимнәрне күп еллардан бирле үзенә җәлеп итеп тора. Бу сүз төркемен өйрәнү И. Гиганов, М. Иванов. А. Казем-Бек, К. Насыйри, Ш. Әхмәров, Г. Нугайбәк һ.б. кебек олпат шәхесләрнең хезмәтләрендә үк башлана. Алга таба В. Хангилдин, Д. Тумашева, Ф. Ганиев, К. Зиннәтуллина, Ф.Хисамова, Н. Салахова, М. Мәрдиева, Д. Шәйхәйдарова һ.б. хезмәтләрендә төрле яссылыкта тикшерелә [6, б. 71–72].

Тел белемендә фигыльләрнең грамматик категорияләрен өйрәнү белән беррәттән, аларның ясалыш ысулларын тикшерүгә дә зур игътибар бирелә. Беренче төрки грамматикаларда ук фигыль ясаучы кайбер кушымчаларның күрсәтелүе һәм фигыль булмаган сүзләрдән кушма фигыльләр ясалышы турында беренче мәгълүматларның булуы проблема белән XIX гасырда ук кызыксынулары турында сөйли [5, б. 324; б. 361–362]. Ш. Рамазанов, В. Хангилдин, Д. Тумашева хезмәтләрендә дә татар телендәге фигыльләр монографик планда өйрәнелә, ә галим Ф. Ганиев исә фигыль ясалышын өйрәнүгә саллы-саллы хезмәтләр багышлый [1; 2].

Төзелешләре ягыннан татар телендәге фигыльләр синтетик һәм аналитик төрләргә бүленәләр. Синтетик төргә тамыр һәм суффиксаль фигыльләр кертеп карала. Аналитик төзелешле фигыльләр, үз чиратында, дүрт төркемчәне тәшкил итәләр, төрле сүз төркемнәреннән ясалалар. Кушымчалау ысулы белән ясалган фигыльләрдә кушымчаның ясаучы нигезе, кушма фигыльләрдә беренче компонент булып, чыганак тел ягыннан саф татар сүзләре дә, алынмалар да килә ала [5, б. 328]. Шуңа күрә хәзерге татар әдәби телендә кулланыла торган фигыльләр арасында ясаучы нигезе башка тел сүзе булган берәмлекләр (шул исәптән гарәп теленнән кергәннәр дә) шактый очрый.

Гарәп телендә исә фигыль иң мөһим сүз төркеме санала, чөнки, формалары күп булу белән беррәттән, исемнәр ясауда да зур роль уйныйлар. [9, с. 151]. Ләкин татар телендә гарәп фигыльләре турыдан-туры фигыль ролен башкармыйлар, бары төрки-татар кушымчалары ярдәмендә һәм кушма фигыльләрдә нигез ролен үтәп кенә, предметның эшен, хәлен процесс рәвешендә белдерә алалар. Бу күренешне М.И. Мәхмүтов «...гарәп теленең төрле сүз төркемнәреннән алынган сүзләрнең татар телендә башлыча исем сүз төркеменә караулары» белән аңлата [4, б. 813].

«Татар грамматикасы»нда хәзерге татар әдәби телендә продуктив булган фигыль ясаучы 14 кушымча күрсәтелгән [4, б. 326–374]. Шуларның өчесе – -ла/-лә; -лан/-лән һәм -лаш/-ләш – аеруча актив булулары белән аерылып торалар. Г. Ибраһимов тарафыннан мондый кушымчалар белән ясалган гарәби тамырлы фигыльләр еш кулланылалар һәм төрле мәгънә төсмерләре белдерәләр. Мәсәлән, исемгә ялганып килгән -ла/-лә сүз ясагыч кушымчасы белән ясалган фигыльләр а) ясаучы нигез белдергәнне башкаруны аңлата: *исәплә, хәтерлә, хөрмәтлә* һ.б. *Кычкырып бирелгән сәламгә каршы башына ак урамал сарган, фәкыйрьчә, ләкин бары белән пакь киенгән бер киленчәк чыкты, **хөрмәтләп** эндәште («Казакъ кызы»);*

ә) кемне яки нәрсәне дә булса ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәткә дучар итүне белдерә: гаеплә, дәвала, тәрбиялә, каһәрлә һ.б.; ***Газаплама*** *(«Кызыл чәчәкләр»)*; *Ялгышмасам, ундүрт ел үткән була...* ***Тәрбияләп*** *яшәтәләр үзен («Казакъ кызы»);*

б) ясаучы нигез белдергән мөнәсәбәтне, үзлекне, сыйфатны күрсәтә: кадерлә, хөрмәтлә, назла һ.б.; *Вак акчаларны бөтен ике йөзәрлеккә алмаштырып, йөрәк өстенә бөти ясап тектем дә, Уралның тирән шахталары белән **бәхилләше**п, Зәңгәр чишмә ягына таба юл тоттым («Кызыл чәчәкләр»); Ил агасы өлкән аксакал Биремҗан әкә моны **куәтләп** алды («Казакъ кызы»);*

*в*) ясаучы нигез белдергән үзлекне бирә: нурла. *Бөтен өебезне **нурла**, балакай («Казакъ кызы»);*

г) сыйфатка ялганып килгән әлеге кушымча, ясаучы нигез белдергән билгене күрсәтә: хәзерлә, кыйммәтлә, хәләллә. *Бу арада елкы малы **кыйммәтләнд**е («Казакъ кызы»);*

д) ясаучы нигез белдергән сыйфатны алуны искәртә: тәгаерлә, тәвәккәллә, тәмамла, хәзерлә һ.б. *Ишектән самавырын күтәреп киленчәк керде, чәй **хәзерләде** («Казакъ кызы»).*

Төзелешләре ягыннан -ла/лә кушымчасы ялгана торган ясаучы нигез тамыр яки кушымчалы, кушма сүз дә булырга мөмкин.

Гарәп теленнән кергән сүзләргә -лан/-лән кушымчасы ялганып, түбәндәге мәгънәләрне белдергән фигыльләр ясала:

а) ясаучы нигез белдергән үзенчәлекне, сыйфатны яки билгене күрсәтә торган сүзләр: зарлан, шиклән, гайрәтлән, гарьлән. *Урамнарда, базарларда, Зәңгәр чишмә буйларында очрап, Галиләр, Фазыйллар, Гыйлаҗилар белән бик күп тапкыр бергә уйнап, **җенләнеп**, көрәшеп, башка компанияләргә каршы сугышларга катнашып, үзе бик күп баһадирлыклар күрсәткәч кенә Шаһбаз безнең арада үз булып китә алды(«Кызыл чәчәкләр»). Ансыз да матур зур күзләре бөтенләй ачылып, **нурланып** уйныйлар («Кызыл чәчәкләр»). Көннәрнең берендә, Тынычбай атаның елы тулганда, бата кылырга дип илнең өлкәннәре җыелган зур бер кымыз мәҗлесендә, күп уен-көлкедән соң, заманның авыраюыннан, дошманның җәфасыннан **зарланып**, әңгәмә ачылды. Сүз сүзне тартты, картларның берсе, камчысын уйната биреп, әйтә салды («Казакъ кызы»).*

ә) ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтләрне башкаруны аңлаткан берәмлекләр: гадәтлән, өметлән, файдалан һ.б. *Болардан бер нәрсә дә чыкмавы билгеле булганга, без инде капка ачып **мәшәкатьләнмибез** («Кызыл чәчәкләр»); Җырлауга, **моңлануга**, көлке сүз әйтеп башкаларны мыскыл итәргә туры килсә, ул инде дошманнарга гына түгел, безнең үз йөрәкләребезгә дә еш-еш агулы укларын кадый («Кызыл чәчәкләр»).*

б) гарәби чыгышлы сыйфатка ялганып, ясаучы нигез белдергән үзенчәлекне, билгене һәм сыйфатны күрсәткән сүзләр: горурлан, рәхәтлән, шатлан. *Шаһбаздан бигрәк без **шатландык** («Кызыл чәчәкләр»); Казакъның гадәте буенча, хәзер инде җегет ата – аналарыннан, өлкәннәрдән яшеренрәк, киленчәкләр аркылы, кызның куенында булырга хак алган; һәм караңгы төннәрдә, җәйләүләр тынгач, аның күңеле **сабырсызланып** Карлыгач-Сылуның тирмәсенә тарта торган булды («Казакъ кызы»); Азымбай гаҗиб бер сабырлык белән өченче мәртәбә тотынды һәм җиңде: бия, бер-ике тарткач та, **рәхәтләнеп** аякларын ике якка аерды, имчәкләрдән сөт агып китте («Казакъ кызы»).*

-лаш/-ләш кушымчасының ясаучы нигезе булып, исем һәм сыйфатлар, аваз ияртемнәре килә ала. Гарәп исемнәренә ялганып, әлеге кушымча түбәндәге мәгънә төсмерләре ясый:

а) ясаучы нигез белдергән шәхескә хас үзенчәлекне алуны: дуслаш, ахирәтләш: *Без ниектер бик тиз **дуслашып** киттек («Кызыл чәчәкләр»);*

ә) ясаучы нигез белдергән эш-хәрәкәтне башкаруны да аңлата: исәпләш, серләш. *Без бу кавем белән **исәпләшергә** тиеш, балалар («Казакъ кызы»);*

б) сыйфатка ялганып, ясаучы нигез белдергән үзлекне алуны да күрсәтә: хәрәмләш. *Дөрес булсын, **хәрәмләшмәгез**! («Алмачуар»).*

Гарәп теленнән кергән *сәлам* сүзе татар телендә исем сүз төркеменә карый, ымлык вазифасын да үти һәм ясалма фигыльләрдә сүз ясаучы нигез булып та тора. Бу сүздән ясалган фигыль ясаучы нигез белдергәнне әйтүне аңлата. Г. Ибраһимов әсәрләрендә ул еш кулланыла: *Миннән, – диде, – яхшыларны **сәламлә**, аксакаллар мәҗлесенә барып, әңгәмәләрен ишетә алмавыма күңелем бозылып калды! («Казакъ кызы»).*

Г. Ибраһимов әсәрләрендә, хәзерге көндә сүз ясамый торган кушымчалар исемлегендә урын алган -ай/-әй кушымчасы ялганып, гарәп нигезеннән фигыль ясалу очрагы теркәлгән. Бу – хәзерге татар әдәби телендә «үз-үзеңне артык эре тоту, масаю; кукраю, һавалану» [7, б. 316] мәгънәсендә йөргән кәпрәю фигыле. Аның ясаучы нигезен гарәп телендәге «зур, олы, мөһим» мәгънәсенә ия КӘБИР асыл сыйфаты тәшкил итә. *Дөньяны күп күргән, атаклы чәчәннәр белән сүз көрәштергән Азымбай бу аксакал алдыңда үзен югалтты, хәтта бераз **кәпрәя** дә төште («Казакъ кызы»).*

Ф. Ганиев татар телендә фигыль булмаган сүзләрдән фигыльләрнең регуляр ясалышында итү, булу, кылу, килү, ясау, кебек ярдәмче фигыльләр катнаша, ә бирү, китерү, алу, ярдәмче фигыльләре белән ясалган кушма фигыльләр телдә күп түгел дигән фикер белдерә [2, б. 86]. Г. Ибраһимов әсәрләрендә исә, фигыль булмаган компоненты – гарәп яки фарсы сүзе, икенче компоненты буларак итү, булу, кылу, алу ярдәмче фигыльләре белән ясалган кушма фигыльләр дә еш күзәтелә. «Татар грамматикасы»нда «...беренче компонент буларак татар телендә итү фигыле белән алынма сүзләр шактый күп кулланыла. Революциягә кадәр гарәп һәм фарсы сүзләре беренче компонент булып килгәннәр» дип искәртелеп үтелә [5, б. 364], әмма язучының инкыйлабка кадәр язган хикәяләрендә дә, инкыйлабтан соң иҗат ителгән әсәрләрендә дә мондый фигыльләр еш күзәтелә.

Гарәп чыгышлы исем + итү калыбы: *тәүбә ит, икърар ит, хөкем ит, өмет ит, шөкер ит, хезмәт ит, файда ит, гамәл ит, зыян ит, кабул ит, гомер ит, зарар ит, хәбәр ит, хәрәкәт ит, хыянәт* ит һ.б. бик күп фигыльләрдә очрый. Мәсәлән, *Тагы бераз китсәгез, йортлар кечерәя, каралтылар, егылмасам ярар дип куркып, үзләренең иске черек терәкләренә таяна төшеп, һәр җилгә калтыранып, һәр яңгырны эченә алып, язмышның бөтен көчләре алдында ыңгырашып **гомер итәләр** («Кызыл чәчәкләр»)*; *Мал да, бүләк тә **өмет итмәгән** идем («Кызыл чәчәкләр»).*

Гарәп нигезле сыйфат + ит моделен *хәрәм ит, канәгать ит, сабыр ит, мәслихәт ит, фаш ит, әрәм ит, газиз ит* кебек мисалларда күреп була. *Сез дә миңа зур шәһәрләрнең берсенә бергәләп кунакка **рәхим** итегез («Кызыл чәчәкләр»); Яңгырбайның байбичәсе Гөлбарчын белән бераз киңәш кылсаң, ике якның чамасын тартып карасаң, **зарар итмәс**! («Казакъ кызы»).*

Булу ярдәмче фигыле ярдәмендә ясалган фигыльләр дә күп. Алар гарәп исеме + булу ярдәмче фигыле моделе буенча ясалганнар: дус бул, файда бул, сәбәп булу, кавем булу һ.б. *Арабыздан тик Шаһбазның гына кайда туганын белмиләр; минем бу газиз дусымның дөньяга килүе анасының*

*кабергә китүенә* ***сәбәп булганга,*** *атасының кем икәне һичберәүгә мәгълүм булмаганга, бу баланың гомереннән беренче сәгатьләрен һичбер өй үзенә алырга теләми («Кызыл чәчәкләр»).* Шул ук ярдәмче фигыль гарәп сыйфатларына ялганып, әрәм булу, зар булу, балигъ булу, фаш булу мәгълүм булу һәлак булу гашыйк булу риза булу һ.б. кебек хәзерге татар әдәби телендә дә иң актив кулланылышта йөри торга фигыльләр ясый [8, б. 108]. Аларның әдип иҗатында актив булуы, аның әдәби телдә язуы һәм хәзерге көндә дә теленең аңлаешлы, аһәңле булуын күрсәтә. Мәсәлән, *Кайберләре үзенең саранлыгы белән* ***мәгълүм булганга,*** *алдан сатулашып алабыз. («Кызыл чәчәкләр»);* ***Харап булган*** *икән! Имеш, борчакны ашыйсыз.* («Кызыл чәчәкләр»); ***Насыйб булса,*** *дөньялар тынычлангач, яңадан кайтып, әткәң-әнкәңне күрерсең... Бер минут торма, хәзер кит! – ди. – Дөньяның берәр җирендә безнекеләр бардыр әле, шуларны эзләп табарсың үзең! – ди* («Кызыл чәчәкләр»).

Гарәп тамырларына кыл ярдәмче фигыле ялганып ясалган мисалларны да күрергә мөмкин. Бүгенге көндә мондый сүз ясалыш калыбы архаик форма буларак исәпләнсә дә, гөнаһ кыл, тәүбә кыл, дога кыл, хөсет кыл, шөкер кыл, хөрмәт кыл, сәҗдә кыл фигыльләрен сөйләмдә кулланабыз. Аларны Г. Ибраһимов әсәрләрендә дә очратырга мөмкин: *Карлыгач-Сылу бу кич* ***кабул кыла*** *алмый: карагым үпкәләмәсен, бик каты наукасланып калдым, ди («Казакъ кызы»); Саламалайкем... Кәефең ничек, бай? – дип исәнләште дә, киез өйнең түренә, паласлар өстенә барып утырып,* ***фатиха кыл****ган сыман битләрен сыйпады («Казак кызы»).*

Бирү фигыле ярдәмче фигыль буларак, шулай ук кушма фигыльләр ясауда актив катнаша. Гарәп исеменә ялганып килгән *бирү* фигылен сәлам бирү, акыл бирү, җан бирү, хәбәр бирү, сер бирү/бирмәү, кебек кушма фигыльләрдә еш очратырга мөмкин.

Алу ярдәмче фигыле кушылып ясалган кушма фигыльләр исә сирәгрәк очрый, әмма Г. Ибраһимов тарафыннан кулланылган гыйбрәт ал, сабак ал, савап ал сүзләрен моңа мисал буларак китереп була.

Төрки телләрдә, шул исәптән татар телендә дә, үзенчәлекле күренеш – фигыльдән фигыль барлыкка килүе шактый еш күзәтелә. Тюркологлар мондый фигыльләрне тезмә фигыльләр дип атыйлар! [5, б. 368]. Ләкин, алдан искәртелгәнчә, гарәп фигыльләренең татар телендә турыдан-туры үз функцияләрен үтәмәүләре аркасында, гарәби чыгышлы сүздән кушымчалау ысулы белән ясалган фигыльләр генә тезмә фигыль буларак Г. Ибраһимов әсәрләрендә урын алалар. Аларның гарәби чыгышлы сүз тамырын табуы ансат түгел, чөнки ялганган аффикслары шактый күбәеп китә. Шулай да, зарыгып бетү, тәк рарлап тору, исәпләп чыгару, илһамланып йөрү һ.б. кебек тезмә фигыльләр автор иҗатында очрый. *Байтүрәләрнең утыз ел буенча, урыс түрә белән берләшеп, Сары-Арканы нинди хурлыкка, коллыкка төшерүләре, үзләре дәүләт-мал арттырып, илне җирсез-сусыз калдырып бөлгенлеккә салулары, алар сүзе белән җир аударылган, Өмбенең, Симинең, Яман Каланың, Тургайның, Кызылъярның зинданнарында даласын, итен, кымызын, анасын сагынып, тимер рәшәткә эчендә елап утырган казакъ балаларының газапланулары акрын, сабыр тел белән кунакның күз алдыннан үтте, елларынача* ***исәпләп чыгарыды*** *(«Казакъ кызы»).* Шуңа да игътибар итәргә кирәк: ясаучы нигез, кушма фигыльләр ясалышындагы беренче компонент ролен үтәүче алынма сүзләр татар телендә исем яки сыйфат сүз төркеменә

карасалар да, нигез телдә алар исем, сыйфат, сыйфат фигыль, төрле баблардагы масдарлар буларак йөриләр.

Кайбер алынма сүзләрдән аналитик төзелешле фигыльләр дә, синтетик төзелешле фигыльләр дә ясала. Мәсәлән, Г. Ибраһимов *исәпләү* яки аның *хисалау* вариантын, *исәп итү*, *исәпләшү* формаларында да куллана; *гаепләү, гаеп итү, гаеп кылу* буларак сүз уйната; хөрмәтләү һәм хөрмәт итү, хөрмәт кылу дип тә яза. Шул рәвешле татар әдәби телендәге сүзләрнең тамырдаш синоним вариантлардан бик уңышлы файдалана.

Кушымчалау ысулы белән генә ясала торган фигыль ясалуда катнаша торган гарәп сүзләре түбәндәгеләр: *хәтерлә, шикләнү, рәхәтләнү, нурлану*.

Бары аналитик фигыльнең беренче компоненты буларак кына катнаша торган гарәп сүзләренә *тәүбә, шөкер, зиярат, хезмәт, кәсеп, сәүдә, кабул, мәрхәмәт, золым, харап, хыянәт, гафил, һәлак, газиз, мәрхүм* һ.б. ларны мисал итеп китереп була. Г. Ибраһимов тарафыннан да алар бары аналитик фигыль ясалышында гына кулланылганнар.

Йомгаклап, шуны әйтергә мөмкин: Г. Ибраһимов – татар телен үстерүгә, гадиләштерүгә зур хезмәт куйган галим. Ул чит тел берәмлекләрен татар телендә күпләп куллануга каршы булса да, татарчалашкан, тел тукымасында үзгәртелгән алынмаларны куллануга уңай караган, үз сөйләмендә дә аларны файдаланган. Гарәп тамырыннан ясалган фигыльләрнең татар теленең сүзъясалыш структурасына ярашуы шуңа дәлил булып тора. Алар әдип әсәрләрендә еш очрыйлар, әмма татар сөйләмен бозмыйлар.

ӘДӘБИЯТ


1. Ганиев Ф.А. Образование сложных слов в татарском языке. М.: Наука, 1982. 150 с.

2. Ганиев Ф.А. Суффиксальное образование глаголов в современном татарском литературном языке. Казань: КГУ, 1976. 108 с.

3. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. китап. нәшр, 1987. 8 т. 432 б.

4. Мәхмүтов М.И. Татар әдәби теленә кергән гарәп-фарсы элементлары //Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. Казан: Иман, 1993. 2 т. Б. 793–853.

5. Татар грамматикасы. Өч томда. М.: Иман; Казан: Фикер, 1989. 1 т. 511 б.

6. Татар грамматикасы. Өч томда. М.: Инсан, Казан: Фикер, 1999. 3 т. Зәкиев М.З. Синтаксис. 512 б.

7. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан: Матбугат йорты, 2005. 848 б.

8. Федорова Э.Н. Татар халык мәкальләрендә гарәп һәм фарсы алынмалары. Казан: Казан дәүләт университеты, 2004. 249 б.

9. Халидов Б. Учебник арабского языка. Ташкент: Укутувчи. 1981. 650 с.


## Г. ИБРАҺИМОВ ХЕЗМӘТЛӘРЕНДӘ ТАТАР ФОЛЬКЛОРЫ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ


***Җамалиева Л.Ф.***



В данной работе рассматриваются вопросы деятельности Г. Ибрагимова в области татарской фольклористики. Анализируется глава «Народная литература» теоретического труда «Вопросы литературы», а также статья «Одно из нужных направлений проблем языка и литературы».

This article discusses issues of G. Ibragimov of the Tatar folklore. This article examines the activities of the G. Ibragimov of Tatar folklore. Examines theoretical article «National literature» and «One of the necessary directions to the problems of language and literature» by G. Ibragimov.

Татар әдәбияты классигы, әдәбият галиме, тәнкыйтьче Г. Ибраһимов хезмәтләрендә халык авыз иҗаты мәсьәләләренә дә зур урын бирелгән. Әдипнең 1910 нчы елда дөнья күргән «Әдәбият мәсьәләләре» хезмәтенең икенче бүлеге «Халык мосаннәфаты» дип атала. Ягъни, халык авыз иҗаты. XX йөз башында халык авыз иҗаты Г. Тукай, Г. Рәхимнәрнең хезмәтләрендә «халык әдәбияты» төшенчәсе белән тәкъдим ителсә, Г. Ибраһимовта ул «халык мосаннәфаты» дип бирелә. Әдип фольклорга «халык арасында авыздан-авызга күчеп йөри торган, фәкать шул халыкның зиһенендә генә сакланып килгән вә чыгаручысы мәҗһүл *(билгесез)* булган, борынгы заманнан калма әсәрләрнең мәҗмугы» дигән билгеләмә бирә. Г. Ибраһимов халык авыз иҗатының төп сыйфатларын да үзенчә шәрехли. Халык иҗаты әсәрләренең башта бер кеше тарафыннан иҗат ителеп, аннан башкалар теленә күчкәч, күп җирләргә таралып, авторы онытылып, коллектив иҗат булып китүенә игътибар итә [1, б. 24]. Әдип, халык укымышлы булган саен, әкиятләргә ышанмый башласа да, аларның әһәмияте кимемәвенә, киресенчә халык иҗаты үрнәкләренең җыелып, җыентыклар буларак басылуына игътибар итә. Әлеге хезмәттә Г. Ибраһимов татар халык авыз иҗаты хакында үзенең шәхси күзаллаулары белән генә уртаклашып калмый. Әдипнең әлеге мәсьәлә буенча әзерлекле, рус фольклорына караган бик күп хезмәтләр белән таныш булуы күренә. Г. Ибраһимов, XIX йөздә үк рус фольклорын һәм этнографик материалларны җыю эшчәнлеге алып барган И.П. Сахаров, А.В. Терещенко, И.М. Снегирев хезмәтләрен атый. Шулай ук бу чорда рус халык иҗатын җыю өчен махсус комиссияләр оештырылуына, тарихи һәм мифологик мәктәп булдырылуына һәм бу эшләр белән үз чорының күренекле фольклорчылары һәм этнографлары булган А.Н. Веселовский, А.И. Соболевский, И.Н. Жданов, В.Ф. Миллер, Н.П. Дашкевич, М.Г. Халанский һ.б. шөгыльләнүенә игътибар итә. Шунысы әһәмиятле, Г. Ибраһимов фольклорның сәнгатьнең барлык төрләренең дә чишмә башы, нигезе булуына басым ясый. Халык иҗаты үрнәкләренең уку китапларына, хрестоматияләргә кертелүен әйтә. Халык иҗаты һәм әдәбият бәйләнышларына мисал итеп, А.С. Пушкин, А.В. Кольцов, Н.А. Некрасов, Ф.М. Достоевский һ.б. авторларны телгә ала. Татар халык авыз иҗатының жанрларга бүлү мәсьәләсенә якын килеп, Г. Ибраһимов әкиятләр; җыр вә бәетләр; мәкальләр; табышмакларны аерып чыгара. Әкиятләрне мифологик персонажлар белән бәйле һәм ислам әсәрләре дип ике төркемгә бүлә.

Әдипнең күзәтүләре бик кызыклы. Ул татарларда руслардан аермалы буларак, күренекле шәхесләр белән бәйле фольклор әсәрләре булмауга борчыла: «Һәр милләт үзенең борын заманда гомум өчен берәр эш эшләгән адәмнәре хакында бик күп әкият ихтирагъ кыйлган *(иҗат иткән)*. Мәсәлән: руслар үзләренең Олег, Владимир кебек тарихта мәгълүмрәк кешеләре, хәтта бик соң килгән Бөек Петрлары хакында әллә никадәр әкиятләр сөйлиләр, аларны фәүкыльгадә *(гадәттән тыш)* бер адәм ясыйлар. Бездә исә бу нәүгы әкият һич юктыр. Борынгы татар дәүләтләре, Болгар ханлыклары хакында халыкта һичбер нәрсә сөйләнми, аларның дөньяда булганын бөтенләй белмидер... Шунлыктан, милләтнең үткәне вә аның әкябире көллиян *(зур, абруйлы кешеләре бөтенләй)* онытылып, мәҗһүлият *(билгесезлек)* пәрдәсе эченә кергәндер» [1, б. 28]. Әдипнең бу борчылуы, чыннан да урынлы.

Г. Ибраһимов, халык авыз иҗаты жанрларыннан җыр, табышмак һәм мәкальләрнең инде халыкка мәгълүм булуын, шул сәбәпле алар хакында

сөйләү ихтыяҗы булмавын белдерә. Әмма тезмә әсәрләрнең җырларга һәм бәетләргә бүленүләренә басым ясый. Бәет эчтәлегендә җыр текстларындагы гомуми нәрсәләр генә түгел, ә бәлки фаҗигале вакыйгалар сурәтләнүгә игътибар итә. Мәкаләдән бу чор бәетләре үзәгендә «катль *(үтерү)*, иртидад *(диннән чыгу)*, сугыш, солдатлык, суга бату вә башкача бер адәмнең бер хәсрәте хакында» кебек фаҗигаләр булуын күрәбез. Бер гасырдан соң, кызганычка каршы, әдәби кыйммәте ягыннан мактана алмаса да, бәет жанры сан һәм тасвирланган фаҗиганең төре ягыннан бик үсте. Ә бәет текстлары аша заман үзгәрешен бик ачык тоемларга мөмкин.

Хезмәттә Г. Ибраһимовның фольклор һәм язма әдәбият арасындагы багланышларга мөнәсәбәте дә ачык күренә. Бу юнәлештә үрнәк күрсәтүче, аның фикеренчә, Г. Тукай. Халык әкиятләре йогынтысында язылган «Шүрәле», «Су анасы» әсәрләрен ул иң гүзәл үрнәкләр дип саный, аларның халыкчан теленә, табигыйлегенә соклана. Әмма язма әдәбиятка нигез булсын өчен, халык авыз иҗаты ядкәрләрен, беренче чиратта халыктан җыеп алу, җыентыклар итеп бастыру зарур. «Безнең зыялыларның күбесе әле гавам эченнән бөтенләй ерак китеп бетмәгән, вә аңлы адәмнәрнең беркадәресе чи гавам эчендә дә яшиләр. Шундый адәмнәребез халык авызындагы әкият, бәет, җыр, табышмак вә мәкальләрне бер дә үзгәртми җыя барсалар, милли әдәбиятымыз өчен бер хезмәт итмеш булырлар. Боларның ни файдасы булыр, дип уйларга ярамый. Һәм алай уйламасалар да, мәдәни кавемнәрнең буңа әһәмият бирүләре безә гыйбрәттер» – дип яза Г. Ибраһимов [1, б. 29]. Әдип фольклорны җыю һәм өйрәнүнең әһәмиятен бик төгәл бәяли. Беренчедән, халык иҗаты ядкәрләре «милли тел вә милли лөгатьнең бердәнбер хәзинәләредер. Болар эченнән татарча бик тугъры тасвирлар вә җөмләләр табарбыз». Икенчедән, «Болар гавамыбызның (халыкның) психологиясен белүдә бердәнбер чарадыр. Болар гавамның һәм тарихы, һәм хиссият вә әфкяредер. Гавамның рухының көзгеседер» дип билгели. Г. Ибраһимов фольклор материалын уку китапларына кертүгә дә зур игътибар бирә. Аларны яшьтән өйрәтү балаларда үз халкына якынлык уята дип саный. Һәм хезмәтне йомгаклап, халык авыз иҗаты әсәрләрен бер дә үзгәртми җыя башларга һәм икенчедән, шагыйрь һәм язучылар үз иҗатларында фольклорга нигезләнсеннәр иде дигән фикер үткәрә.

1910 нчы елда Г. Ибраһимовның әлеге хезмәте дөнья күргәннән бераз соңрак, 15 нче апрельдә Г. Тукай Шәрык клубында «Халык әдәбияты» лекциясен укый [2]. Әгәр ике хезмәтне чагыштырып карасак, алардагы уртак фикерләрне күрербез. Г. Тукай хезмәтендә җыр жанрын анализлауга күбрәк урын бирелә, ә Г. Ибраһимовта, гомумән, фольклор мәсьәләләренә карата. Икесе дә фольклорны халыкның рухи халәте күрсәткече дип саныйлар. Ике автор да халык иҗатына билгеләмә бирә, аның төп сыйфатлары – телдән иҗат ителүе һәм таралуы, коллектив иҗат нәтиҗәсе булуы, вариантлылыгына игътибар итәләр.

Г. Ибраһимов та, Г. Тукай да тагын бер мәсьәләдә бер төрле үк фикер йөртәләр. Бу – халык иҗатының язма әдәбиятка нигез булуы. Икесе дә руслардан А.С. Пушкин, А.В. Кольцов иҗатларына фольклорның тәэсире турында язалар, татар әдәбиятының да халык иҗаты традицияләре нигезендә үсүен телиләр. Г. Тукай, фольклор материалларына ияреп язылган җырларны «соңгый җыр» дип атый [2, б. 180].

Г. Ибраһимовның фольклор өлкәсендәге тагын бер әһәмиятле хезмәте – 1926 нчы елда дөнья күргән «Тел-әдәбият мәсьәләләренең кирәкле бер тармагы (Татар халык әдәбияты турында)» мәкаләсе. Бу инде әдипнең халык иҗаты хакындагы күзаллаулары, гомуми фикерләре тезмәсе генә түгел. Әлеге язмада Г. Ибраһимов шул чорда Татар халык мәгариф комиссариатының Гыйльми үзәге тарафыннан фольклорны җыю-туплау эшчәнлегенең торышы, бу юнәлештә эшләүчеләр хакында тәфсилле мәгълүмат бирә. Иң кызыклысы, шул чорда ук, Гыйльми үзәк тарафыннан төрки җөмһүриятләргә аталмаларны өйрәнү тәҗрибәсе турында сорап махсус хатлар язылган. Алардан килгән җавапларга нигезләнеп, ул халык иҗатын өйрәнүнең әһәмиятен күрсәтә: «Халыкны өйрәнү, өлкәне өйрәнү мәсьәләсе эчендә, шулай ук яңа әдәби тел һәм аталмалар төзүдә халык әдәбиятына зур бер чишмә башы итеп карау һәммә төрек халыкларында да бер метод урынын алды» [3, б. 491]. Аның фикеренчә, «асыл саф тел – тик халык әдәбиятында гына сакланадыр». Шуңа да, телнең төп үзенчәлеген, аның нормаларын өйрәнүдә халык иҗатының ярдәме зур булачак. «Шуңар күрә бездә халык әдәбиятын җыю, тикшерү-тәртипләү эше, тел-әдәбият мәсьәләлренең бик кирәкле бер тармагы буларак, хәзерге көндәге гыйльми-әдәби эшләребезнең алдынгыларыннан итеп мәйданга куелырга тиешледер» дип, галим, бу мәсьәләнең бик актуаль булуына басым ясый. Алга таба галим Руста, Европада бу мәсьәләнең күптән өйрәнелүен әйтә, XIX йөздә бертуган Гриммнәр методы буенча академик Ф.И. Буслаевның рус халык әдәбиятын җыю һәм тикшеренү фәнни нигезләве хакында әйтә. Татарларда бу эшне К. Насыйриның башлавы, алга таба Казанга килгән венгр галиме Ю. Мессарош, аңа ярдәм иткән Х. Бәдигый, Г. Рәхим, Ф. Туйкин, Г. Исхакый, А. Таһиров һ.б. тарафыннан дәвам иттерелүе турында яза.

1926 нчы елның 20 нче маенда Гыйльми үзәкнең коллегия җыелышында фольклорны җыю, тәртипләү, бастыру чараларын күрү өчен өч кешелек махсус комиссия оештырыла. Комиссиягә М. Корбангалиев, Х. Бәдигый, Г. Рәхим керә. Г. Ибраһимов бу эшкә гыйльми-нәзари мәсьәлә дип кенә карамавын белдерә. Хезмәтнең гамәли әһәмиятен фольклор материалының алга таба халык тормышын, халыкның фикерен, икътисадын өйрәнү, төрле аталмалар, әдәби телнең эшләнүендә гаять әһәмиятле чыганак булуда күрә. Галим фольклор материалын халыктан җыеп алуның гыйльми таләпләрен бик төгәл билгели: материалны халык авызыннан ничек ишетелгән, шул көенчә язып бару; кайдан, кемнән, нинди кабиләдән, кай районнан табылганын төгәл күрсәтү. Чөнки бу бер үк материалның таралу географиясен, төрле төбәкләрдәге уртаклыгын һәм аермасын билгеләргә ярдәм итә дип саный. Шул ук вакытта, әдип, татар халык авыз иҗатын җыеп анализлаган вакытта башка төрки халыклар, рус һәм Европа халыклары белән дә уртаклыгын да өйрәнү мөмкинлеген дә күрсәтә. Төрле халыкларның фольклор материалының зур бер өлеше «бәйнәлмиләл» маллардыр, ягъни халыкара уртак материаллардыр, дип исәпли. Әдип шушы чорда татар фольклористикасының көнүзәк проблемаларын ачык билгели, Гыйльми үзәк алдына халык иҗатын җыю; төрле вакытта җыелып та басылмый ятканнарын, басылып та таралып ятканнарын туплау; һәммәсен гыйльми метод белән тикшереп, системага салу; аннан соң тәртипләп бастырып чыгару кебек конкрет бурычлар куя. Моның озакка сузылган дәвамлы эш булачагын ассызыклап, Гыйльми

үзәкне шушы эшне башкаручылар өчен юнәлеш бирүче, шуны оештыручы буларак күрә.

Г. Ибраһимов, халык иҗатының гомуми мәсьәләләре белән кызыксынудан тыш, бу өлкәдә эшләүчеләрнең хезмәтләрен дә игътибар үзәгендә тоткан. Шулардан үз чорының күренекле әдибе Шәехзадә Бабичның иҗатына, эшчәнлегенә бик тәфсилле бәя биргән «Вакытсыз һәлак булды», Каюм Насыйриның киңкырлы эшчәнлеген тасвирлаган «Каюм бабаның йөз еллыгы» мәкаләләрендә әлеге шәхесләрнең татар фольклорын җыю, бастыру һәм фәнни өйрәнүгә керткән өлешләрен бик югары бәяләгән [4].

XX йөз башында фольклорны өйрәнгән, аны әдәбиятның чишмәсе дип санаган әдип, үзенең әдәби иҗатында да халык традицияләреннән бик мул файдаланган. Мисалга аның «Яз башы», «Карт ялчы», «Табигать балалары», «Алмачуар», «Кызыл чәчәкләр», «Яшь йөрәкләр», «Казакъ кызы», «Татар хатыны ниләр күрми» һ.б. әсәрләрен китерергә була.Саналган әсәрләрнең халык иҗаты белән бәйләнеше бүгенге фольклорчыларны да кызыксындыра [5]. Бу юнәлештә иң актив эшләүчеләрнең берсе – галимә Айсылу Садыкова. Г. Ибраһимов әсәрләренең фолькор белән бәйләнешен өйрәнеп, 1992 нче елда ул кандидатлык диссертациясе яклый һәм шуның нигезендә 1995 нче елда «Фольклор в эстетике Галимджана Ибрагимова» дип аталган монографиясен бастыра. Әдипнең идея-эстетик карашлары формалашуга фольклорның йогынтысы, язучының хикәяләрендә фольклорны куллану үзенчәлекләре, әдипнең прозасында дастан традицияләре үсеше, аерым әсәрләрендәге фольклоризмнарның вазифасын тикшерүгә багышланган әлеге монография Г. Ибраһимов иҗатының төрле хасиятләрен өйрәнүдә бик җитди фәнни хезмәт. А. Садыкова, әдипнең татар фольклорын, аның язма әдәбиятка йогынтысын тикшерүгә багышланган хезмәтләрен анализлап, Г. Ибраһимов, үзенең матурлык идеалын халык авыз иҗатында тапкан дигән нәтиҗә ясый [6, б. 22].

Йомгаклап әйткәндә, Г. Ибраһимов иҗаты, аның фәнни һәм тәнкыйди эшчәнлеге еллар дәвамында киң планда тирәнтен өйрәнелсә дә, ул бүгенге көн тикшеренүчеләре өчен дә бик бай әдәби-мәдәни мирас булып тора.

## ӘДӘБИЯТ

1. Ибраһимов Г. Халык мосаннәфаты. Әдәбият мәсьәләләре // Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. 5 т. : әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр. Б. 23–30.

2. Тукай Г. Халык әдәбияты // Г. Тукай. Әсәрләр: 5 томда: проза. Публицистика (1907–1913). Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. Б. 164–185.

3. Ибраһимов Г. Тел-әдәбият мәсьәләләренең кирәкле бер тармагы (Татар халык әдәбияты турында) // Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. 5 т.: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр. Б. 490–495.

4. Ибраһимов Г. Вакытсыз һәлак булды // Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. 5 т.: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр. Б. 314–329.; Ибраһимов Г. Каюм бабаның йөз еллыгы // Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. 5 т.: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр. Б. 482–489.

5. Җамалиева Л. Г. Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» әсәрендә туй йоласының әдәби чагылышы // Наследие Г. Ибрагимова и тюркский мир. Материалы Международной научно-практической конференции, посвященной 125-летию со дня рождения Г. Ибрагимова (17 апреля, 2012 г.). Казань, 2012. С. 147–149; Сайфуллина Ф.С., Замалиева Л.Ф. Народный свадебный обряд как литературный первоисточник в татарской прозе // Филология и культура. № 3 (29). 2012. Казань: КФУ. С. 146–149.

6. Садыкова А. Фольклор в эстетике Галимджана Ибрагимова. Казань, 1995. 105 с.

# «КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫ ТАРИХЫНА КАЙБЕР МӘГЪЛҮМАТЛАР ҺӘМ ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ЭШЧӘНЛЕГЕ

***Заһидуллина Д.Ф.***

Статья посвящена истории становления литературно-художественных журналов на татарском языке в первой трети XX в. Рассмотрены условия, в которых появились первые печатные журнальные издания; дан анализ общественного и художественного профиля журнала «Шура». Также прослежена летопись истории создания журнала «Аң», рассмотрены его облик и содержание, личности и вклад участвовавших в данном проекте татарских интеллектуалов, роль и место в журнале Г. Ибрагимова, его деятельность в качестве ответственного секретаря. На основе представленного материала сделан вывод о том, что исторически становление татарских литературно-художественных периодических печатных изданий обусловлено и подготовлено не только журналом «Безнең юл», но также и появлением журнала «Аң».

Some data to the history of «Ogni Kazani» magazine and G. Ibragimov's activities Article is devoted to the history of formation of literary and art magazines in Tatar. In it conditions of creation of the first printing journal editions are considered, the profile of the Shura magazine is determined. Also the chronicle of creation of the «Ang» magazine, its shape and content, participating in this projects Tatar intellectuals, a role and G. Ibragimov's place in this case, activities of the writer as the responsible secretary of the magazine is traced. The conclusion is on the fact that historical roots of formation of the literary and art periodic printing edition in Tatar are connected not only with the magazine «Bezneng yul», but also with the magazine «Ang».

Калын журнал (бигрәк тә әдәби-мәдәни басма) мәйданга чыгу һәр милләт тарихында күренекле урын тота: ул дөньяви фикерләүче зыялылар катламы формалашу хәбәрчесе, рухи-мәдәни күтәрелеш билгесе кебек кабул ителә. Шуңа күрә XIX гасыр татар мәгърифәтчеләре дә, XX гасыр башының Европага йөз тоткан җәдитчеләре дә татарча журнал чыгару хыялын тормышка ашырырга омтылалар, уңышсызлыкларга очрап та, әлеге фикердән баш тартмыйча, яңадан-яңа адымнар ясыйлар. XX гасыр башында аваз салган татарча журналлар милләтне саклап калу, үстерү хакында бәхәсләр мәйданына әверелә, аларның сәхифәләрендә сәясәт, мәдәният, милләт мәнфәгате белән яшәргә өйрәтү кирәклеге көн кадагына куела.

Татар телендә вакытлы матбугат булдыру юлыннан киртәләр алып ташлануга, иң оператив төр – газеталар – белән бергә, шунда ук беренче журналлар булдыру адымнары ясала. «Әд-дин вә әл-әдәб» (1906, Казан), «Чүкеч» (1906, Оренбург), «Дин вә мәгыйшәт» (1906, Оренбург), «Туп» (1907, Әстерхан), «Карчыга» (1908, Оренбург), хәтта чит илдә – Истамбулда гамәлгә куелган «Казан» (1905) кебек басма журналлар тиз арада популярлык казана. Беренче журналларның «нигезен иҗтимагый-сәяси басмалар тәшкил итә» [4, б. 348]. Тиз арада алар арасында үз юлын табу, профильләшү башланып китә. Татар вакытлы матбугаты мәйданында дини юнәлешле, балалар өчен, хатын-кызлар өчен, сатирик, икътисад яки уку-укыту һәм тәрбия мәсьәләләренә багышланган басмалар пәйда була. Дөрес, бер генә журнал да милли әдәбият үрнәкләреннән һәм әдәбият мәсьәләләреннән читтә кала

алмый. Әмма бер үк вакытта әдәбият, сәнгать мәсьәләләрен алга куйган журнал булдыру кирәклеге дә гел әйтелеп килә. Бертуган Рәмиевләр фатихасы белән 1906 елда «Вакыт» газетасына кушымта булып аваз салган «Шура» 1908 елда мөстәкыйль журнал статусында гамәлгә куелгач, ул әлеге ихтыяҗларга җавап бирә башлый. Исемен дә «киңәш мәҗлесе» мәгънәсендә билгеләп, журналның беренче санында басманың максатларын күрсәткән программ язмада мондый сүзләр бар: ««Шура» милләтне гыйлемле, мәгърифәтле итмәк хакында мәшвәрәт мәҗлесе улачактыр. Эстәдеге кемсә ошбу мәҗлестә сөйләр вә эстәдеге адәм дә тыңлар. Шәхсияттән вә гарыздан[1] саф улмак шарты илә, милләт мәнфәгате арзусы илә язылмыш мәкалә вә фикерләр өчен «Шура» битләре һәрвакыт ачыктыр» [3, б. 6]. Һәм чыннан да, М. Госманов сүзләрен кабатлап, басмага мондый бәя бирергә мөмкин: «Ә журналда басылган материаллар арасында ниндиләре генә юк! Зур проблемаларны күтәргән иҗтимагый, иктисадый, фәлсәфи, дини темаларга багышланган тирән эчтәлекле хезмәтләр белән янәшәдә чын сәнгатьчә язылган әдәби әсәрләр – шигырьләр, хикәяләр булыр» [3, б. 7].

Шуңа да Х.Й. Миңнегуловның түбәндәге сүзләре бик урынлы: «Журнал-мәҗмугаларның иҗат көчләрен туплауда һәм үстерүдә, әдәбиятны алга җибәрүдә һәм пропагандалауда, гавамны тәрбияләүдә һәм оештыруда нинди мөһим урын тотуы дөнья мәдәни тормышында күптәннән расланган хакыйкать. Ә инде милли хокуклары бик нык кысылган, үз мөстәкыйль мәмләкәтләре булмаган халыклар өчен аларның роле бермә-бер арта. Мисалга 1908 елның 10 гыйнварыннан 1917 елның ахырына кадәр Оренбургта Ризаэддин Фәхреддин мөхәррирлегендә, Рәмиевләр ярдәмендә чыгып килгән (барлыгы – 240 сан) атаклы «Шура» журналын гына алып карыйк. Андагы байлык, фикер-мәгълүматка исең-акылың китәр! Ул чын мәгънәсендә халыкның киңәш-табыш мәйданы, парламенты, дәүләте кебек. Бүгенге «Казан утлары» үзенең рәсми тарихын 1922 елда дөньяга килгән «Безнең юл» журналыннан башлый. Әмма чынлыкта аның рухи нигезләре «Шура»га барып тоташа. Аларның һәр икесен дә дәүләти фикерләү, киң колачлылык, халыкка, туган телгә, әдәбиятка хезмәт итү сыйфатлары берләштерә» [6, б. 11].

Әмма «Шура» да XX йөз башы мәдәни күтәрелешен әйдәп барган зыялылар өчен аз тоела: татар мәдәни мәйданында рус мәдәниятендәге «Весы», «Золотое руно» тибындагы, үз укучысын заман әдәбияты-сәнгате белән таныштыруны, шулай гакълый-мәдәни яктан камилләштерүне төп максат итеп куйган журнал булдыру идеясе гел яңгырап тора. XX йөз вакытлы матбугаты мәйданында әдәби яктан иң эчтәлекле һәм иң югары сыйфатлы «Аң» журналы туу исә Әхмәтгәрәй Хәсәни исеме белән бәйле була.

Әхмәтгәрәй Сибгатулла улы Хәсәнов (1883–1933) – XX йөз башы мәдәни тормышында иң күренекле урын тоткан «Гасыр» нәшриятының хуҗасы, язучы, драматург, тәрҗемәче. Ул – Г. Тукайның, Ф. Әмирханның якын дусты, мәсләктәше, фикердәше. Университетларда белем алган, рус-европа мәдәниятен яхшы белгән, җитеш гаиләләрдә тәрбияләнгән татар яшьләренең рухи-фикри лидеры, аларны милли мәдәнияткә хезмәткә тартучы [1, б. 408].

Журнал чыгару карарының кабул ителү вакыйгасы Т. Мамлиевның 1912 елның 31 июлендә язылган доносында түбәндәгечә сакланып калган:

---

[1] Гарыз – дәгъва.

«Татар әдәбият түгәрәге июльнең 26-сында Евангелистовский урамда Хәсәнев йортында җыелды. Җыелыш тиз көннән калын рус журналлары шикелле бер әдәби, сәяси журнал чыгарырга карар бирде. Бу журнал яшь татар милләтчеләрен берләштерергә тиеш булачак. Журнал Хәсәневлар исеменнән чыгачак. Җыелышта булган кешеләр: Гәрәй, Барый Хәсәневлар, Фуат Туктаров, Габдулла Гыйсмәтуллин, Габдулла Тукаев, Фатих Әмирхан, учитель Гафур Колахмәтов, Исмәгыйль Аитов, Гыйльметдин Шәрәф, Галимҗан Ибраһимов, Габдеррахман Кәрәм» [5, б. 51]. Бу исемлек үзе генә дә күп нәрсә турында сөйли.

Ә. Хәсәни журнал оештыру идеясен күп еллар күңелендә йөртә. Исемен Г. Тукай тапкан журнал Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Г. Рәхим, Г. Гобәйдуллин, Һ. Атласи, Җ. Вәлиди, Ш. Камал, Ф. Агиев, С. Сүнчәләй, Ш. Камал, С. Рахманколый кебек иң талантлы иҗатчыларны үз тирәсенә берләштерә. 1912 елның 15 декабреннән 1918 елның мартына кадәр айга ике тапкыр басыла килеп, 123 сан тәшкил иткән «әдәби, фәнни, сәяси вә иҗтимагый рәсемле журнал» татар халкы өчен мөһим идеологик, рухи, мәдәни проблемаларны күтәрә, яңалыкларны мәйданга чыгаручы гына булмыйча, бәлки әдәбиятта тәҗрибәләр (экспериментлар) ясаучы үзәккә әйләнә.

«Аң» – Г. Тукай тапкан исеменә тугры калып, татарларның аңын, дөньяга карашын үзгәртүгә хезмәт итә. Журналда даими рәвештә, әдәби әсәрләр белән беррәттән, фән, сәясәт, икътисад мәсьәләләренә багышланган мәкаләләр, сәнгать, театр, музыка өлкәсендәге яңалыкларга күзәтүләр, тарих һәм дин, мәгариф һәм тәрбия, матбугат торышы, аерым шәхесләргә кагылышлы язмалар тәкъдим ителә. «Аң» авторлары татар укучысын дөнья мәдәниятендә барган процесслар белән таныштыруны махсус башкара, проблемага төрле яклап якын килә. Аның битләрендә әдәбиятның нинди булырга тиешлегенә караган бәхәсләр бара, Г. Ибраһимовның, Х. Кәримнең, Г. Рәхимнең, Н. Хәлфинның һ.б. әдәбиятчыларның теоретик характердагы язмалары дөнья күрә [1, б. 19].

«Аң»ны булдыручы иҗади төркемнең татар әдәбиятын алга җибәрү теләге нинди әсәрләргә өстенлек бирүдә бик ачык күренә [1, б. 349–395]. Әдәби барышны әйдәп баручы, «Аң» журналының һәр санында берничәшәр әсәр белән катнашучы Ф. Әмирхан, Ш. Камал кебек әдипләр, дөнья әдәбиятындагы идея-эстетик эзләнүләр кимәлендә әсәрләр язып, аларның милли, бер язучыны да кабатламый торган, яңгыраш һәм моң җәһәтеннән укучыга үз һәм якын булуына ирешә. Фәнни-фәлсәфи җәһәттән көчле, үткен фикерле, киң карашлы, дөнья әдәбиятын бик яхшы белүче М. Хәнәфи татар укучысы өчен күтелмәгән тирәнлекләргә үтеп керә, «укучы кабул итмәс» дигән киртәләр алдында туктап калмый, әдәбиятыбызны лирик-фәлсәфи эчтәлекле, хисси-эмоциональ, чын мәгънәсендә җәүһәрләр белән баета. Филологик әзерлекле, укымышлы, әдәбият тарихы һәм тәнкыйте өлкәләрендә дә актив эшләп килүче, әдәби күренешләргә бик сизгер, тоемлы, зәвыклы Г. Гобәйдуллин һәм Г. Рәхим әсәрләре эшкәртелү дәрәҗәсе, төгәлләнгәнлеге белән аерылып тора. Алар артыннан журнал битләренә Фәйзи (Вәлиев), Ә. Тангатаров, К. Тинчурин, Н. Гасрый һәм башкалар аяк баса. Гасыр башы әдәбиятында яңарыш олы бер хәрәкәткә әверелә.

Кызганычка каршы, әлеге журналның рухи атасы Ә. Хәсәни дә, аны булдыруга көч куйган күп кенә татар зыялылары да шәхес культының канлы тегермәненә эләгә. Шул сәбәпле, «Аң» татар әдәби журналы тарихыннан тө-

шереп калдырыла. Башкача калын әдәби журналыбыз тарихын 1922 елның май аеннан чыга башлаган «гыйльми-сәяси, иҗтимагый-әдәби һәм икътисадый» мәсьәләләргә багышланган «Безнең юл»дан башлап җибәрүне аңлатып булмас.

Әмма мәдәни барышның үз кануннары: «Безнең юл», кызыл идеологиягә манчылса да, нәкъ менә «Аң» традицияләрен дәвам итә. Бу фикернең дөреслегенә инану өчен журналның бүген ачык танышу мөмкинлеге булган саннарын карап чыгу да җитә. Чөнки аны оештыручылар, басмага максат билгеләүчеләр – үз заманында «Аң»ның милли кыйбласын ныгыткан Галимҗан Ибраһимов, Шәһит Әхмәдиев һ.б. Хәтта басманың исеме дә февраль революциясе көннәрендә Г. Ибраһимов Ф. Сәйфи-Казанлы һәм журналист Ш. Сүнчәләй белән бергә оештырып җибәргән һәм, 7 ай дәвамында (30 марттан сентябрьгә кадәр) «Ирек» исеме белән чыгып, аннары «Безнең юл» дигән яңа исем алган газетага барып тоташа.

Нәкъ менә «Аң», башка бик күп зыялылар кебек үк, Г. Ибраһимовның журналистлык тәҗрибәсен ныгытуда зур роль уйный. 1909 елда Казанга күченеп килүгә, Галимҗан Ә. Хәсәни белән дустанә мөнәсәбәтләр урнаштыра. Аның күпчелек китаплары Хәсәниләрнең «Гасыр» нәшриятында басыла. 1913 елның 3 гыйнварында Х. Кайбышевка Киевтән язган хатында, Ибраһимов Хәсәнинең һәм Ф. Әмирханның үзен ачылып килүче «Аң» журналына рәсми язышырга чакыруын телгә ала [2, б. 69]. 1913 елның 16 сентябрендә Ибраһимов, Ә. Хәсәни чакыруын кабул итеп, «Аң» журналына җаваплы сәркатип булып эшкә урнаша.

«Аң»да эшли башлауга, Ибраһимов журналга шактый үзгәрешләр кертүгә ирешә. Үз җаваплылыгында чыгарылган беренче санда ук ул «Фәнни вә фәлсәфи мәсьәләләр», «Хатын-кыз галәменнән» дигән бүлекләр ача. Беренче бүлеккә язылган кереш сүзендә фәнни материаллар урнаштыруның мөһимлеге ассызыклана, икенче бүлек алдынгы татар хатын-кызлары хакында мәгълүмат бирү, татар җәмгыятендә хатын-кызның урыны, хәле кебек актуаль мәсьәләне тикшерү бурычы куя. Бу санда – «Милләтне ничек аңлыйсыз?», алдагысында «Яңа елда ни телисез?» дигән анкеталар белән эшләү башлана. Журнал битләрендә көн кадагына суккан мәсьәләләр турында сөйләшүгә киң катлау укучылар тартыла.

«Аң» да тулысынча үз тәртипләрен урнаштыра башлаган Г. Ибраһимов 1914 елның 13 февралендә кинәт кенә, бигрәк тә сәяҗси сәбәпләргә бәйле, Казанны калдырып Киевкә китеп бара. 25 апрельдә Хөсни Кәримгә язган хатында ул үзенең китү сәбәпләренә кагыла: «Казаннан зарарсыз гына жалованье, мәсьүлиятле эшне ташлап китү халыкка ят күренде. Моны күпләр төрлечә хәмел иттеләр. Син дә «Аң»нан китү дигән шикелле карыйсың. Юк, алай түгел, мин «Аң»нан китмәдем, Казаннан киттем. «Аң»ны Кавказда, Киевтә, Мәскәүдә, һич булмый икән, Әстерхан, Уфада чыгарырга булса иде, мин аны ташламас идем» [2, б. 81].

Г. Ибраһимовның менә шушы тәҗрибәсе «Безнең юл» журналының концепциясен төзегәндә зур роль уйный. Беренче санда басма «даими язышучылар» исемлеге бирә: анда Г. Ибраһимов беренче итеп аталган. 1 нче (май) һәм 2 нче (июнь-июль) саннарында язучының күләмле «Иҗтимагый-әдәби хәрәкәтләр тарихын тикшерүдә марксизм ысулы» хезмәте тәкъдим ителә. 1925 елдан Ибраһимов журнал редколлегиясенә керә, 1926 елның 25 гыйнварында редколлегия рәисе итеп билгеләнә. Бу урында

«Безнең юл», «Мәгариф» журналларының 1925–1927 елларда Г. Ибраһимов җитәкләгән Гыйльми Үзәк тарафыннан нәшер ителүне дә онытмаска кирәк.

Шулай итеп, олы юбилейлар чорына килеп кергән «Казан утлары»бызның тарихи тамырлары тагын да тирәнгәрәк китә дияргә нигез бар. Аның 95, 100 еллыкларын уздырганда 1912 елның 15 декабрендә татар вакытлы матбугаты мәйданында пәйда булган «Аң» журналын, аны оештыручыларны да ихтирам белән искә алу кирәк.

ӘДӘБИЯТ


1. Әхмәтгәрәй Хәсәни: фәнни-популяр җыентык / төз. Д. Заһидуллина, А. Батталова, Л. Йөзмөхәммәтова. Казан: Җыен, 2011. 395 б.
2. Галимҗан Ибраһимов. Әсәрләр. 9 томда. Казан, 2000. 9 т.: хатлар һәм документлар / төз. Ф. Ибраһимова. 463 б.
3. Госманов М. «Шура» журналы һәм аның библиографик күрсәткече // Госманов М.Г., Мәрданов Р.Ф. «Шура» журналының библиографик күрсәткече. Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2000. Б. 4–18.
4. Журнал // Татар энциклопедиясе. Т. 2. Казан: ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институты, 2010. Б. 347–348.
5. Мансуров Г. Татар провокаторлары. М., 1927. 76 б.
6. Миңнегулов Х.Й. «Казан утлары» һәм татар халкының әдәби-мәдәни мирасы //«Казан утлары» журналы һәм милли мәдәният: Төбәкара фәнни-гамәли конференция материаллары (Казан, 17 май, 2012 ел.). Казан, 2012. Б. 11–13.


## Г. ИБРАҺИМОВ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ЯҢАРЫШЫ


***Закирҗанов Ә.М.***



В статье рассматривается роль Г. Ибрагимова в возрождении татарской литературы начала XX века. Выявляются историко-культурные и общественные предпосылки, оказавшие существенное влияние на формирование его взглядов, как писателя и гражданина. Раскрываются нравственные и философские поиски писателя на разных этапах развития его творчества.

The role of G. Ibragimov at the beginning of the 20 century`s tatar literature`s rebirth is shown in the article. The author of the article pays attention to historical-cultural and social background, which influenced G. Ibragimov strongly as a writer and a citizen. The writer`s moral and philosophical searches on different stages of his work are revealed.


Галимҗан Ибраһимов – күпгасырлык татар әдәбияты күгендә янган иң якты йолдызларның берсе. Иҗаты XX гасырның беренче чирегенә караса да, сәнгати табышлары, яңалыгы, аларның әдәби барышка йогынтысы ягыннан ул тулы гасырның төп әдәби көчләреннән санала. Шуның белән бергә, әдип XX гасыр башы татар мәдәни тормышының үзәгендә булып, әдәби иҗаттан тыш, әдәбият белеме, мәгариф, тарих, публицистика, иҗтимагый фикер үсешенә яңа рух өсти, һәрбер өлкәдә тирән һәм мәгънәле эз калдыра.

Башкортстанның Авыргазы районы Солтанморат авылы (элекке Уфа губернасы, Эстәрлетамак өязе) бәрәкәтле туфрагында туып-үсеп, күршедәге Кешәк авылы, Оренбургтагы Вәли мулла, Уфадагы «Галия» мәдрәсәләрендә белеп алганнан соң, Г. Ибраһимовның «тормыш университетлары» башлана. Казакъ далалары, Әстерхан яклары, аннары Киев, Одесса, Сухуми, Уфа һ.б. шәһәр-төбәкләрдә яшәп, инкыйлаблар чорына хас гаять шау-шулы, шул ук вакытта кайнап торган халык тормышы белән танышу, «халыклар төр-

мәсе» булган патша Россиясендәге күпсанлы халыклар белән аралашу, булачак әдипкә бай материал бирә, аның дөньяга каршын, милли үзаңын үстерә, милли-азатлык көрәшенә китерә.

Мулла гаиләсендә туып-үсеп, мәдрәсә гыйлеменә таянып, мөстәкыйль рәвештә дөньяви фән нигезләрен үзләштергән Г. Ибраһимов, беренче чиратта, әдәби һәм иҗтимагый эшчәнлеккә тартыла. Табигатьтән бирелгән сәләт, акыл аңа җәмгыятьтә үз урынын табарга ярдәм итә һәм ул тиз арада төрки-татар дөньясында танылу ала, милли лидерларның берсе булып җитешә. Шуңа да Г. Ибраһимов тормышын, иҗатын, эшчәнлеген, социаль һәм милли азатлык өчен көрәшен татар дөньясында XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында урын алган Яңарыш хәрәкәтеннән аерып карап булмый. Г. Ибраһимов татар милли әдәбиятын нигезләүчеләрнең берсе булып тора. Аның әдәби-эстетик карашлары мәгърифәтчелек, аннары җәдитчелек хәрәкәте дулкынында формалашып, Шәрык һәм Гареб әдәби-эстетик фикерен үзләштерү аша XX йөз башы татар әдәбиятында яңа сүз булып яңгырый.

Мәдрәсәдә укыган елларда ук әдәби иҗатка килеп, халыкның авыр тормышы, яшәп килгән гаделсезлек, хокуксызлык өчен тирән борчылу белән язылган «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» (1907) әсәреннән соң язылган «Татар хатыны ниләр күрми» (1909), «Яз башы» (1910), «Диңгездә» (1911), «Сөю – сәгадәт» (1911), «Карак мулла» (1911), «Яшь йөрәкләр» (1912), «Көтүчеләр» (1913) хикәяләрендә искелек һәм яңалык каршылыгы, милли яшәеш мәсьәләләре белән кушылып, яңа алымнар аша бирелә. Актив эзләнүдә булган әдип, мәгърифәтчелек әдәбиятында урын алган романтик сурәтлелекне чор, заман рухы белән үреп, Европа тибындагы романтизмның җирләшүенә зур өлеш кертә. Әлеге әсәрләрдә, әйләнә-тирәнең аяусыз, караңгы чынбарлыгын тулырак ачу максатында, романтик хыял дөньясына мөрәҗәгать ителә һәм алар бу чор әдәбиятында «параллель рәвештә мәгърифәтчелек реализмы, романтизм, тәнкыйди реализм, символизм иҗат методларының үсүен һәм үзара тәэсир итешүе»н [1, с. 110] күрсәтә. XX йөз башы татар әдәбиятының тизләтелгән үсеш юлы үтүе Г. Ибраһимовның әдәби-эстетик эзләнүләрендә ачык чагыла. Иҗатының беренче этабында романтик сурәтлелек белән мавыккан әдип алга таба чынбарлыкны реалистик кабул итүнең яңадан-яңа юл-алымнарын эзли башлый. Нәтиҗәдә «Карт ялчы» (1912), «Табигать балалары» (1914), «Безнең көннәр» (1914), «Габдрахман Салихов» (1916) һ.б. әсәрләре дөнья күрә. Г. Ибраһимовның Октябрьгә кадәрге иҗаты татар әдәбиятының зурлыгын чыгылдырып, дөнья әдәбиятының бер өлеше буларак каралырга тиешлеген дәлилләү булып тора. Моңа нигез булып әдипнең татар сүз сәнгатенә алып килгән яңалыгы, үзенә хас стиль үзенчәлекләре тора. Аларны гомумиләштереп, түбәндегәчә күрсәтергә мөмкин: 1) әсәрләрендә реализм һәм романтизм синтезына ирешеп, кырыс чынбарлык күренешләренең эмоциональ-лирик пафос белән үрелеп баруы; 2) искелек-яңалык көрәшен татар милли яңарышы белән бәйлелектә яңа баскычка күтәреп тасвирлау; 3) әсәрләрдә, бер яктан, хаплыкның гомумилштерелгән образы ачылу, икенче яктан, катлаулы, каршылыклы яңа герой типларын мәйданга чыгару; 4) хатын-кызларның авыр язмышын сурәтләү аша матурлык идеалын раславы; 5) реалистик һәм шартлы-романтик сурәтлелекнең гаҗәеп бай төсмерләрен тирән лиризм, портрет һәм пейзаж характеристикалары, бай һәм җор тел аша ачу. Гомумән, әдипнең әлеге чор иҗатындагы сәнгати фикерләү осталыгы, ул сурәтләгән дөньяның гаять

төрле, бай, кызыклы һәм тормышчанлыгы әдәбияттагы яңарыш сыйфатларын баета.

Г. Ибраһимов XX йөз башы татар әдәбиятын совет чоры белән бәйләп, аның бөтенлеген тәэмин итүче авторларның берсе һәм иң күренеклесе булып кала. Гасыр башы Яңарышының, «алтын чор»ының дәвам итүе, шифалы йогынтысы буларак, Бөек Ватан сугышына кадәрге татар әдәбиятында урта гасырлардан килүче әхлакый кыйммәтләрне яклау һәм саклау, дуслык-бердәмлеккә омтылу, гаделлек һәм хакыйкать эзләү идеяләре урын алган икән, монда Г. Ибраһимовның гаять зур роле бар. Инкыйлабларны шатланып каршы алган язучы, халыкны бәхетле итү максатын куйган яңа хакимияткә бөтен барлыгы белән хезмәт итә. «Яңа кешеләр» (1920), «Кызыл чәчәкләр» (1921), «Алмачуар» (1922), «Адәмнәр» (1923), «Казакъ кызы» (1923), «Тирән тамырлар» (1926) әсәрләре әдипнең икеләнү-уйлануларын, бәхәсле эзләнүләрен шактый тулы чагылдыра. Г. Ибраһимовның инкыйлаб чорында ук язылган «Яңа кешеләр» драмасы вакыйга-күренешләргә бәя биреп кенә калмый, бәлки яңа җәмгыятьне төзүчеләрнең формалашуын һәм моның гаять җитди эчке каршылыклар аша баруын сурәтләве белән аерылып тора. Әдипнең проза әсәрләрендәге социаль типлар индивидуаль характеры, үз йөзе белән үзенчәлекле, чор вакыйгалары белән гаять тыгыз берегеп яшәүләре, шул рәвешле сурәтләнүләре белән әдәбиятта яңа сүз буларак яңгырый. Язучының совет чоры иҗаты каршылыклы булып, бертөрле генә бәяләнми. Аның әдәби-эстетик эзләнүләрендә үзара каршылыкта булган гуманизм һәм диктатура, шәхес иреге һәм сыйнфый дошманны юк итү кебек төшенчәләр урын ала. Әмма Г. Ибраһимовның эстетик идеалын гомумкешелек кыйммәтләрен яклау һәм милли мәнфәгатьләрне кайгырту теләге билгели. Р. Ганиева язганча, «матурлык эстетикасына тартылучы, кешенең ireккә һәм бәхеткә хокукын раслаучы» [2, с. 34] язучы булып таныла. Шуңа да ул олы гуманист булып кала.

Г. Ибраһимов иҗаты – халкыбыз тарихының гаять өермәле булган XX гасырның беренче чиреге елъязмасы, хроникасы. Аның хикәя-повестьларында, романнарында Октябрьгә кадәрге шәкертләр, руханилар тормышы, хатын-кызлар язмышы, инкыйлаб вакыйгалары, гражданнар сугышы фаҗигаләре, әлеге тарихи вакыйгалар уртасында калган татар халкының яшәү рәвеше, теләк-омтылышлары, хыяллары кабатланмас вакыйгалар булып күз алдына бастырыла. Г. Ибраһимов әсәрләрендәге тормышчанлык, көнкүреш детальләре, романтик төсмерләр тудырган бизәклелек, кырыс натуралистик сурәтләр, илаһи сихри дөньяга алып китә торган тирән, нечкә лиризм һәм башка беркемнеке белән дә бутап булмый торган, төгәл, матур, ягымлы, тормышның бөтен буяуларын үзенә җыйган гаять бай һәм халыкчан тел үзенә тартып тора. Ф. Миңнуллин язганча, «музыкаль симфония кебек аның теле. Ул тел кәефне үзгәртә: күңелне тетрәтә яки рәхәтлек бирә. Әгәр сез «Безнең көннәр»не укыганда татар дөньясына диңгез дулкыннары кебек шаулап революция килүен, «Казакъ кызы»нда дала киңлеген, дала кояшы кайнарлыгын тоясыз икән – моның хикмәте Галимҗан Ибраһимовның теле гаҗәеп бай, музыкаль булуында. Әсәренә алган материалларның үзенчәлегенә карап искиткеч җылы, лирик та, кырыс, шомлы да ул тел» [3, б. 308].

Г. Ибраһимов тел, әдәбият галиме, тәнкыйтьче, педагог буларак та бай мирас калдыра. «Борынгы ислам мәдәнияте» (1909), «Әдәбият мәсьәләләре» (1910), «Татар сарыфы» (1911), «Татар шагыйрьләре» (1913), «Татар имля-

сы» (1914), «Яңа әдәбият» (1914), «Әдәбият дәресләре» (1914), «Татар телен ничек укытырга?» (1916) һ.б. мәкалә-китаплары, дәреслек-кулланмалары бүген дә кыйммәтен җуймаган хезмәтләр булып тора. Д. Заһидуллина фикеренчә, Г. Ибраһимов «әдәбият кешенең, авторның рухын эчке дөньясын чагылдыра» дигән фикерне алга куеп, XX йөз башында татар әдәбият фәнендә «рухиятчеләр» дип атарга мөмкин булган мәктәпне формалаштыра. Шул рәвешле әдәбият фәне алга таба зур адым ясый: әдәбиятның сурәтләү объекты итеп, кешенең эчке дөньясы, психологиясе билгеләнә, ә милли рухка тәэсир итүе, хис-кичерешләрне баетуы аның вазифасы буларак карала башлый [4, б. 260–272]. Г. Ибраһимовның «Татар әдәбияты» (1922), «Татар әдәбиятын өйрәнү юлында» (1923), «Татар әдәбияты җәмгыяте» (1927) һ.б. хезмәтләре үз чоры әдәби хәрәкәтенең асылын ачу белән игътибарга лаек. Аларда идеология тәэсире, хәтта вульгар-социологик карашлар чагылса да, милли әдәбиятның 1920-30 еллардагы үсү-үзгәрү тарихын аның хезмәтләреннән башка бөтенлекле күзллап булмый.

Г. Ибраһимов татар матбугатын ныгыту, үстерү мәсьәләсендә башлап йөрүчеләрнең берсе була. 1913 елда «Аң» (Казан), 1917 елда «Безнең юл» (Уфа), «Ирек» (Уфа), 1918 елда «Чулпан» (Мәскәү) һәм Совет хакимияте урнашкач «Эшче», «Кызыл Армия», «Кызыл яшьләр», «Безнең юл», «Мәгариф» газета-журналларын оештыручы, кайберләренең мөхәррире буларак үзен оста журналист, оештыручы итеп таныта. Шул чор әдәби хәрәкәтенә, иҗтимагый-мәдәни яшәешкә Г. Ибраһимов гаять зур йогынты ясап, байтак өлкәләрдә әйдәп бара, үсеш-үзгәреш юлларын билгели.

Гомумән, XX гасыр татар әдәбияты, фәне, теле, публицистикасы үсеше Г. Ибраһимов эшчәнлеге белән гаять тыгыз бәйле. Шуңа да әдип иҗатын милли һәм гомумкешелек идеаллары күзлегеннән тикшерү, әлеге бөек шәхеснең татар әдәби-эстетик фикеренә алып килгән яңалыгын, аның үзеннән соңгы сүз сәнгатенә тәэсирен, милли яңарыштагы урынын заман биеклегеннән торып бәяләү җитди бурыч булып кала.

ӘДӘБИЯТ


1. Нигматуллина Ю.Г. Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. Казань: Фэн, 1997. 190 с.

2. Ганиева Р.К. Литературные традиции и взаимосвязи в творчестве Г. Ибрагимова // Галимҗан Ибраһимов һәм XXI гасыр: Тууына 120 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. Казан: ТӘһСИ, 2007. С. 32–45.

3. Миңнуллин Ф. Узаман // Балта явызлар кулында. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. Б. 301–310.

4. Заһидуллина Д.Ф. Әдәбият кануннары һәм заман. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. 271 б.


## САБАН ТУЕ БӘЙРӘМЕНЕҢ Г. ИБРАҺИМОВ ИҖАТЫНДА ЧАГЫЛЫШЫ


***Закирова И.Г.***



Г. Ибрагимов, хорошо знавший традиции татарского народа, очень достоверно, со всеми деталями, описывает празднование Сабантуя. С давних пор это событие сопровождалось различными народными обрядами, наполнено радостной, светлой атмосферой праздника. В праздниках отражается «дух народа», мировоззрение, его национальный, самобытный характер.

G. Ibragimov, who knew the traditions of the Tatar people, described the celebration of Sabantuy very reliably, with all details. For a long time this event was accompanied by various folk rites, filled with a joyful, bright atmosphere of the holiday. In the holidays, the «spirit of the people» is reflected, the world outlook, its national, original character

Г. Ибраһимовның һәр әсәре татар халкының гореф-гадәтләре, традицияләре, ышанулары, йолалары турында информация саклый. Еш кына язучының иҗатында йола-бәйрәмнәрнең аерым бер этаплары тәфсилле бәян ителә. Бу яктан алар этнографлар, фольклорчылар өчен дә мөһим чыганакларның берсе булып тора. Г. Ибраһимов иҗатында татар халкының сабан туе, өмәләре, ат саклаулар, аулак өйләр, егетләрнең гармун уйнап урам әйләнүләре тасвирлана.

Татар халкының сабан туе бәйрәме, аның аерым йолалары әдипнең «Алмачуар» хикәясендә, «Яшь йөрәкләр» романында бәян ителә, «Карак мулла» хикәясендә искә алына. Әлеге әсәрләрдә язучының төп игътибары ат чабышларына бирелгән. Әмма Г. Ибраһимов сабан туеның башка бик күп йолаларын да игътибарсыз калдырмый. Бу әсәрләргә нигезләнеп XIX–XX гасырлар чигендәге сабан туе бәйрәмен күзалларга мөмкинлек туа.

Г. Ибраһимов сабан туен бер көнлек бәйрәм буларак кына сурәтләп калмый, сабан туе алдыннан була торган әзерлекләрне, сабан туе алды йолаларын да тәфсилле бәян итә. Әсәрләрдә сабан туеның бөтен халыкның көтеп алган бәйрәме булуы, бәйрәм рухы яхшы тоемлана.

Сабан туен бөтен кеше көтеп алса да, көрәшчеләр, чабышкы ат хуҗалары өчен әзерлек эшләрен, атларны чабышка әзерләүне күп алда башлыйлар. Мәсәлән, «Карак мулла» хикәясендә татар бае Сафа һәрвакыт чабышкы атлар тота. Ул сабан туенда ярышта җиңәрлек ат эзли, тай алып сабан туе чабышкысы үстерә. «Яшь йөрәкләр» романында да шушы ук тема алга таба үстерелә. Романның бер герое Җәләш (Җәләлетдин) хәзрәтнең дә бер мавыгуы атлар белән бәйле – «Ул һәрбер сабан туенда, башка атларны икешәр чакрым артта калдырып, гел беренче килерлек булган бер чабышкы тотуны сөя һәм шуның өчен кайда чабышкы булуы өмитле бер тай, бер ат сатылса, ул ала, тәрбияли, шуны чабышкы ясарга хәзерли» [1, б. 248]. Димәк, ат хуҗалары сабан туена әзерлекне берничә ел алдан башлыйлар.

«Алмачуар» хикәясендә чабышкы атны тәрбияләү тулы этабы белән тасвирлана. Колынның тугач та аякланууын күреп, «Шәп мал аякланып туа» [2, б. 517] дигән ышануга нигезләнеп аңа баштан ук зур өметләр баглана. Икенче яшькә чыкканда тайның ялын, койрыкларын кыркып «кыркымыш» ясыйлар. Өченче яшендә тайлар «беренче сабанга керә». Чабыш аты булырга юралган Алмачуарны эшкә җикмиләр: «Урманга, тауга-ташка, сабан-сукага җиксәң, ул ничек чаба алачак?» [2, б. 525]. Шул ук вакытта тайны әкренләп сабан туена әзерлек тә башлана. «Менәм, чабыштырам, чабарга өйрәтәм, тирә-якта беренче чабышкы ясыйм» [2, б. 525]. Чабыш атын әзерләүгә җитди якын килгәннәр, чабышкы асраган картлардан да өйрәнгәннәр, алар да тәҗрибәләре белән уртаклашкан. «Заманында күп чабышкы асраган Сафа карт, яз чыккач ук, эткәйгә моның юлларын өйрәтте: нәрсә ашатырга, ничек эчертергә, көн саен ничек аз-аз гына йөртеп кайтарырга – һәммәсен әйтеп бирде [2, б. 526]. Сабан туе җиткәндә атның рационы да үзгәрә. Аңа печәннең корысын гына бирәләр, бүлеп-бүлеп солы салалар, азлап-азлап апара суы эчерәләр [2, б. 526]. Бу әсәрдә ат чабышларының бер

көнлек кенә бәйрәм йоласы булмыйча, татар халкының аңа җитди хәзерлеге дә сурәтләнә.

«Яшь йөрәкләр» романында сабан туе иртәсе тасвирлана. Бәйрәм кояш чыгу белән башлана: «Икенче көнне кояш чыгуга бөтен авыл аякка баса. Кара урманның кешеләре, алты яшьлек баласыннан алтмыш яшьлек картларынача, сабан туе дәрте белән җилкенә» [1, б. 252]. Сабан туеның бер бизәге – кунаклар кабул итү. Бу көнне «чит авылдан кунаклар җыела» [1, б. 252]. Сабан туена кунаклар килү традициясе татар халкында хәзергә кадәр дәвам итә. Татар авылларына кунаклар сабан туе вакытын туры китеп кайталар. Сабан туе кеше гомеренең бер еллык этабы тәмамлануын, икенче яңа ел башлануын да күрсәтеп торган вакыт та. Читкә китүчеләр бу бәйрәмдә туган-тумачалары, дуслары, авылдашлары белән очраша. Г. Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр» повестендә читкә китеп эшләүчеләрнең дә сабан туена кайтып җитәргә тырышулары турында сүз бара. Кыш буе шахталарда, төрле промысльләрдә эшләгән игенче егетләр, сабан туе белән башлана торган кыр эшләренә кайтып җитәргә омтылган. Әсәргә кергән җырда да сабан туеның кайту вакыты икәне аңлашыла:

Сандугачлар килгән безгә,
Китмәсләр микән көзгә;
Язгы сабан туйларына
Кайтырбыз микән без дә [2, б. 427].

Шахтага акча эшләргә киткән Солтан да язгы сабан туена кайтып җитәргә тырыша: «Сентябрьдә китәм, язгы сабан туена кайтып җитәрмен насыйп булса, дигән идем» [2, б. 439].

Сабан туе алды йолаларының берсе – бүләк җыю. Сабан туе өчен бүләк җыю йоласы бәйрәм буласы көнне яки бер көн алдан үткәрелә: «Авылның барлык егетләре атка менеп, яшь килен төшкән йортлардан сөлге-фәләннәр җыеп йөриләр» [1, б. 248]. Бүләк җыю йоласы хәзерге вакытта да уздырыла. Хәзерге вакытта бүләк җыйганда һәр йорттан бүләк бирергә тырышалар. Шулай да, күп кенә төбәкләрдә яшь килен бүләгенә аерым игътибар бирелә. Кагыйдә буларак, яшь килен сабан туе өчен махсус бүләк – чиккән сөлге әзерли. Кунак кызлардан чиккән кулъяулык алалар. Иң матур, зур чиккән сөлге сабан туенда беренче килгән атның муенына салынган. Башкалары да бүләксез калмаган. «Нәзек, суырылган, танылмас мәртәбәдә тиргә баткан юртаклар берәм-берәм килә тора, сөлгене ала торалар» [1, б. 254].

Сабан туе көнне сөлге җыю күренеше «Алмачуар» хикәясендә дә урын алган: «Бүген бөтен авылның асты өскә. Әллә ничә йөзләп егетләр ат менеп чыкканнар да, яшь киленле йортларга кереп, сөлге җыеп йөриләр» [2, б. 526]. Сабан туе көнне егетләр сабан туе бүләге өчен сөлге җыйса, ул көнне балалар өйдән өйгә кереп йомырка җыйганнар. Малайлар, кайсы атта, кайсы җәяү, өйдән өйгә йомырка сорарга чыкканнар. Аларга яшелле-кызыллы буяуга буяп әзерләп куйганнар» [2, б. 527].

Татар халкының тагын бер йоласын искә төшерү урынлы булыр. Чабышта иң соңгы килгән ат та бүләксез калмаган, аның өстенә алдан адарынган кешеләр үзләренең сөлгеләрен салган. Бу күренеш «нәзер сөлгесе» дип телгә кергән.

Сабан туе өйләгә таба башланып киткән: «Өйләгә таба авылның кыйбла як башындагы зур чирәмгә сабан туе өчен мәйдан ясыйлар да, бөтен халык

шунда агыла» [1, б. 252]. Сабан туйлары һәрвакыт авылга якын, авыл күренеп торган җирдә үткән.

Сабан туйларында ир-егетләр белән хатын-кызлар мәйданның ике ягында булган. Хатын-кыз ярышларга катнашмаган, кагыйдә буларак, тамашачы сыйфатында гына бәйрәм караган. «Бер якта аллы-гөлле, кызыллы-яшелле чүпрәк диңезе үз алдына дулкынланып тора, – болар хатын-кызлар. Икенче якта бик куе булып, арләр бер түгәрәк ясап оешканнар» [2, б. 527].

Г. Ибраһимовның «Алмачуар» хикәясе дә сабан туе, сабан туендагы ат чабышы, чабышкы атлар темасын дәвам итә. Әдип бу әсәрендә сабан туеның икенче бизәге – көрәшне дә тасвирлый. Хикәядән сабан туйларының бөтенесе бер төрле булмаганы, зур һәм кечерәкләре булганлыгы аңлашыла. Зур сабан туйларына үз тирә-якларындагы сабан туйларда мәйдан тоткан көрәшчеләр килгән. «Менә бервакыт Чишмәдә зур сабан туе ясала. Асыл сөяк чабышкы атлар, үз тирәсендә исем казанган көрәшчеләр, шәп йөгерүче егетләр бу җыенга йөзәр чакрымнан киләләр – көч сынамакчылар, үзләрен күрсәтмәкче, дан алмакчылар» [2, б. 506]. Сабан туйларының зур һәм кечкенәгә бүленүе турында «Алмачуар» хикәясендә дә мәгълүмат саклана: «Бүген сабан туе!

Андый-мондый гына түгел, тирә-якта бик сирәк була торган, – бик зурысы, бик шәбе! Данлыклы чабышкылар җыелалар. Атаклы көрәшчеләр киләләр. Исемле йөгерек ирләр бүген көчләрен сынашмакчылар» [2, б. 525].

Сабан туеның төп ярышлары – көрәш, ат чабышы һәм ир-егетләрнең йөгерү буенча узышы булганлыгы аңлашыла.

Хикәядә көрәш түбәндәгечә сурәтләнә: «Ике баһадир, билләрен берәр тартып сыныйлар да, бер-берсенең сыртларына кулларын салган хәлдә, бөтен халыкның күзе астында, түгәрәк мәйданда әйләнәләр» [2, б. 506]. Көрәшне мәйданда бөтен кеше күзәтә. Шуңа күрә хәрәмләшергә дә урын калмый. Бәхәсле очракларда көрәшчеләрне яңадан мәйданга чыгаралар: «шау-шу күтәрәләр, яңадан көрәшергә чыгуны сорыйлар» [2, б. 507]. Татар көрәшендә җиңүнең шарты – көндәшеңне җирдән күтәреп алып, баш аркылы аркасына салу. Әсәрдә җиңү шулай сурәтләнә дә: «Тагы кинәттән, һич көтелмәгән бер секундта, башкорт каһарман сиздермәстән генә кысып ала да үзе җиргә ята, баш очыннан Хафиз баһадирны шундый көч белән селтәп җибәрә ки, ул, әллә кая барып, сул кулы өстенә бик каты егыла» [2, б. 507].

Г. Ибраһимов «Алмачуар» хикәясендә ат чабышын да бәян итә. Атлар зур сабан туйларында унбиш, гадәти сабан туйларда җиде-сигез чакрымга чабалар. Әсәрдә чабышта катнашучы малайларның киеме, яулык бәйләве, камчылары, чабыш башланып китү, аның барышы һәм атларның узышуы тасвирлана.

Йомгак ясап әйткәндә, Г. Ибраһимов иҗатында татар халкының күп кенә йолалары турында мәгълүмат сакланып, алар онытыла бара торган йолаларны, күренешләрне торгызырга да ярдәм итә торган чыганак та булып тора.

ӘДӘБИЯТ

1. Ибраһимов Г. Сайланма әсәрләр. 1 том. Казан: Татаркнигоиздат, Матур әдәбият редакциясе, 1957. 528 б.

2. Ибраһимов Г. Сайланма әсәрләр. 2 том. Казан: Татаркнигоиздат, Матур әдәбият редакциясе, 1956. 596 б.

# Г. ИБРАҺИМОВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ӨСТӘЛМӘЛӘР ҺӘМ АЛАРНЫҢ ЛЕКСИК-СЕМАНТИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Закирова Л.Р., Габидуллина Ф.И.*

Язык художественной литературы всегда был предметом внимания лингвистов и язык произведений Г. Ибрагимова тоже был неоднократно изучен. Несмотря на это существуют еще многие аспекты пополнения лингвистических учений относительно стиля и языковых особенностей великого классика татарской литературы. Одной из таких областей можно назвать употребление присоединительных конструкций в прозе Г. Ибрагимова. В его произведениях активно употребляются присоединительные конструкции разных семантических групп. В данной статье рассматриваются лексико-семантические свойства присоединительных конструкций в произведениях Г. Ибрагимова.

The language of fiction has always been a subject of attention of linguists and language of the works of G. Ibragimova, too, were repeatedly studied. Despite this there are still many aspects of the replenishment of the linguistic teachings on style and language peculiarities of the great classics of Tatar literature. One such area can be called the use of conjunctive constructions in the prose of G. Ibragimova. His works are actively used connecting design to different semantic groups. This article examines lexical-semantic properties of the conjunctive constructions in the works of G. Ibragimova.

Галимҗан Ибраһимов (1887–1937) – бай иҗади мирас калдырган язучы. Ул – күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, татар әдәбиятының классигы, әдәбият теориясен һәм тәнкыйден үстерүгә зур өлеш керткән шәхес, тел, әдәбият, тарих фәннәре өлкәсендә эшләгән күренекле галим һәм мөгаллим. Күренекле әдип тел байлыгыннан файдалануга, андагы төрле үзенчәлекләрне чараларны урынлы  куллануга бик таләпчән була [1, б. 50]. Язучы әсәрләре тел җәүһәрләренә бай булуы, телнең энҗе-мәрҗәннәреннән уңышлы файдалана белүе белән дә  башка әдипләр иҗатыннан аерылып тора. Аның әсәрләрендә без иҗатының яңгырашын, аһәңлелеген, сафлыгын  күрсәтүче тел-сурәтләү чараларын да, стилистик фигураларны да, күп кенә катлаулы синтаксик төзелмәләрне дә очрата алабыз.

Белгәнебезчә, һәр язучы тел хәзинәсеннән үзенчә файдалана. Ул сүзләрне сайлап алуда, тел сурәтләү чараларын үзенчәлекле итеп куллануда һәм җөмлә төзелешенең бирелешендә күренә. Г. Ибраһимов, мәсәлән, бер үк мәгънәне бирү өчен төрле лексик-стилистик һәм фразеологик чараларны эшкә җигә, халыкның җанлы сөйләмен әдәби калыпка салып, күңелгә үтеп кererлек, тирән тойгылар уятырлык әдәби әсәрләр тудыра.

Әдип әсәрләрендә мәгънәгә, сөйләм яңалыгына игътибар юнәлдерү максатыннан татар синтаксисында өстәлмәләр дип аталучы синтаксик берәмлекләрне дә еш очратабыз. Әлеге мәкаләбез дә Г. Ибраһимов әсәрләрендәге өстәлмәләр, аларның башка кисәкләр белән бәйленешен, кулланылыш үзенчәлекләрен тикшерүгә багышлана.

«Өстәлмә конструкцияләр» дип нинди дә булса яңалык хәбәр итә торган җөмләдән соң килеп, шушы җөмләнең аеруча да мөһим булган, сөйләм яңалыгын тәшкил итә торган берәр берәмлеген, кисәгенә өстәмә аңлатма бирүче катлаулы төзелмәләргә әйтәләр. Ул гадәттә аерым җөмлә булып оеша. Ләкин шунысы мөһим: әлеге кисәкне алдагы җөмлә составына кертеп карасаң да, сөйләмгә зыян килми, өстәлмә конструкция дип аталучы кисәк

мәгънә төсмеренә бернинди зыян китермичә, җөмләдә теге яки бу җөмлә кисәгенә күчеп китә. Шунысы мөһим: әлеге җөмләләрнең яңгырашы тексттагы башка җөмләләрдән аерылып тормый. Ә шушы өстәмә рәвештә ниндидер кисәкне ачыклаучы сүзне җөмлә тышына чыгарып, Г. Ибраһимов үз иҗатынының табигыйлеген самимилеген, тәэсир көчен бермә-бер арттыра.

Сөйләм телен әдәби әсәргә бөтен үзенчәлекләре белән алып керүдә Г. Ибраһимов әсәрләре башка әдипләр иҗаты арасында үзенең кабатланмас рухи хәзинә булуы белән аерылып тора. Аның «Татар нәхүе» (татар синтаксисы) хезмәтендә бу алым, әлеге синтаксик характерлы үзенчәлек буларак телгә алынмаса да, нәкъ менә шушы әдиптә өстәлмәләрнең формалашу, активлашу мөмкинлекләре күренә башлый [3, б. 112]: Коридорда унсигез камера бар. Дүртесе Баязитныкы кебек тар, кечкенәләр. *Ялгыз утыручылар өчен* («Безнең көннәр»). Әлеге җөмләләр, бер-берсе белән бәйләнеп, бер синтаксик бөтен – кыска гына текст барлыкка китерәләр. Соңгы җөмләгә игътибар итсәк, ул алдагы җөмләгә өстәмә мәгълүмат биреп, эчтәлек һәм синтаксик яктан шушы җөмлә белән тыгыз бәйләнештә тора. Бу җөмләләрне бер-берсеннән аерсаң, текстның мәгънәви бөтенлегенә зыян килә. Әдип иҗаты әлеге җөмләләрнең бер-бер артлы килеп, бер-берсен тулылындырып, татар синтаксисына яңа төшенчә алып керүләре белән зур әһәмияткә ия.

Г. Ибраһимов әсәрләрендә кулланылган өстәлмәләрне, җөмләдә нинди мәгънә төсмере белдерүенә карап, түбәндәге төрләргә бүлеп карарга мөмкин:

1) Беренче җөмләдәге яисә үткәндә өзелеп калган фикер дәвам иттерелә: Аяксыз, кулсыз булып кайтсаң да, син минеке. Башкаларга күзем дә төшми. *Күңелем дә* («Кызыл чәчәкләр»); Яратам мин үзебезнең авылны. *Авылның төньягын каплаган зур тауларны* («Алмачуар»). Әлеге җөмләләрдә соңгы төзелмәләр беренче җөмләдәге эчтәлекне тулыландырып, конкретлаштырып, өстәмә мәгълүмат алып киләләр.

2) Әйтелгән фикернең билгесен ачыклау нияте белән кулланылган өстәлмәләр дә әдип иҗатының индивидуальлеген күрсәтүче мөһим чара булып торалар: Гаҗәеп бай бүлмә. *Китаплар, гәзитләр белән тулы* («Кызыл чәчәкләр»); Утыз сумга Садыйк байның бер келәтен алдык. *Зур гына, иркен генә* («Кызыл чәчәкләр»). Күргәнебезчә, соңгы төзелмәләр алдагы җөмләдәге исем белән белдерелгән объект яки субъектның билгесен ачыклап киләләр. Сыйфат белән конкретлаштырылмаса, бу күренеш яки предметлар безнең күз алдыбызга гомуми планда гына килеп басарлар иде.

Кайвакыт теге яки бу фикернең билгесен ачыклаучы мондый өстәлмәләр бер-бер артлы килеп, аерым җөмләләр булып та формалашырга мөмкиннәр: Буген сабан туе. Андый-мондый гына түгел. *Тирә-якта бик сирәк була торган. Бик зурысы, бик шәбе* («Алмачуар»). Әлеге җөмләләрдәге ачыклаучы сүзләрнең берсе сыйфат белән белдерелсә, икенчесе үткән заман сыйфат фигыль белән бирелгән.

Өстәлмә конструкцияләр тиңдәшләнеп, бер җөмлә булып оешып та килә алалар: Явыз киленем көчләгәч, авылга икмәккә барганымны да әйтермен. *Акташ фетнәсен дә, мужикларның котырганын да* («Тирән тамырлар»). Әлеге җөмләдә туры тәмамлыклар беренче җөмләгә өстәмә рәвештә мәгълүмат алып киләләр.

3) Өстәлмәдәге сүзләр беренче җөмләдә бирелгән хәбәргә тагын да ныграк ышандыру өчен кулланылалар. Әлеге очракта өстәлмә булып чын-

нан да, дөрестән дә, бер шиксез кебек сүзләр кылә: Менә монысы чын дөресе! *Чыннан да* («Кызыл чәчәкләр»).

4) Нинди дә булса бер фикергә капма-каршы мәгънәдәге өстәлмәләр. Әлеге өстәлмәләр еш кына антоним сүзләр һәм каршы куючы теркәгечләр белән белдереләләр. Әлеге җөмләләрнең үзенчәлеге шунда: өстәлмәләр составындагы сыйфатлар төп җөмләдәге сыйфатка контекстуаль антоним булып киләләр. Җөмләдән аерып карасаң, әлеге сыйфатлар капма-каршылык мәгънәсен югалталар. Сафа картның да биш кенә бәбкәле бер казы бар икән. Аларның бәбкәләре зуррак. *Ләкин ямьсезрәк* («Алмачуар»); Атасы Акташта крестьян. *Ярлы. Ләкин каты йөрәкле* («Тирән тамырлар»).

5) Охшату-чагыштыру мәгънәсен белдерүче өстәлмәләр дә Г. Ибраһим иҗатында еш кулланылып, күренешләр арасындагы охшашлыкны белдереп киләләр: Охшыйлар шул, балам... бар да охшыйлар. *Ике тамчы су кебек*. Хәзрәт тә охшый. *Коеп куйган кебек* («Тирән тамырлар»).

6) Киләчәккә ышаныч, өмет белән карауны белдерүче өстәлмәләр: Сентябрьдә китәм. Язгы сабанга кайтып җитәрмен. *Насыйп булса* («Кызыл чәчәкләр»).

7) Теге яки бу әйбернең күләменә игътибар юнәлдерү кирәк булганда да, Г. Ибраһимов еш кына саннарга, күләм-чаманы белдерүче рәвешләргә, билгеләү алмашлыкларына, күләм мәгънәсен белдерүче исемнәргә мөрәҗәгать итә: Әткәйнең көздән чыгарып калдырган ташы бар икән! *Алты сажень*! («Кызыл чәчәкләр»); Мылтыклы кеше атның камытын кисеп җибәргәч, Николай патша акчалары коелып төшкәнен дә сөйләрмен. *Барын-барын да. Инәсеннән җебенәчә* («Тирән тамырлар»).

8) Г. Ибраһимов иҗатында өстәмә хәбәр биреп, хәбәрне тагын да конкретлаштыру максатыннан кулланылган өстәлмәләр дә бихисап. Әлеге хәбәрләрне җөмлә эченә кертеп урнаштырсак, алар аныклагыч вазифасын үти башлыйлар: Ләкин ул бирешми, һаман дулый. *Тыпырчына, кизәнә* («Казакъ кызы»); Шулай да аңардан куркалар. *Карулашмыйлар* («Тирән тамырлар»).

9) Кире хәл мәгънәсен белдерүче өстәлмәләр: Ул Мөгаллим Хәбип – эт ул! *Коммун булмаса да* («Тирән тамырлар»). Җөмлә эченә кертеп карасак, әлеге өстәлмәләр кире хәл булып, төп җөмләнең хәбәренә буйсыналар.

Шулай итеп, XX йөз башларында нәкъ менә Г. Ибраһимов тарафыннан актив кулланыла башлаган, сөйләмнең экспрессивлыгын арттыручы, мәгънәне калкуландыручы, өстәмә мәгълүмат бирүче әлеге өстәлмәләр хәзерге вакытта матур әдәбият, публицистика телендә әһәмиятле стилистик чарага әйләнделәр. Бу алым инде инде хәзер язучылар, шагыйрьләр, журналистлар тарафыннан аңлы рәвештә, синтаксик экспрессия чарасы буларак кулланыла [2, б. 179]. Ә бу исә Г. Ибраһимовның чын әдәби тел остасы булу белән бергә, татар тел гыйлемен үстерүдә зур сәләтле, киң эрудицияле галим икәнлегенә тагын бер тапкыр ышандыра.

ӘДӘБИЯТ

1. Габидуллина Ф.И. Проблемы изучения жанровой природы татарского романа // Филологические науки. Вопросы теории и практики. Тамбов: Грамота. Ч. I. № 7 (25). 2013. С. 49–51.

2. Габидуллина Ф.И., Мирсиапова Л.Р., Саттарова Г.Г. Лингвопоэтические особенности поэзии Р. Миннулина // В мире научных открытий. 2015. № 3 (63). С. 178–184.

3. Сафиуллина Ф.С. Татар телендә сүз тәртибе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. Б. 109–112.

# ТРАДИЦИИ И КУЛЬТУРНЫЕ ЦЕННОСТИ ТЮРКСКИХ НАРОДОВ В ПРОИЗВЕДЕНИЯХ Г. ИБРАГИМОВА

***Зарипова-Четин Ч.А.***

Великий писатель, основоположник романтизма в татарской литературе, филолог, критик, историк, педагог, государственный и общественный деятель начала XX века Г. Ибрагимов оставил неизгладимый след в литературе и культуре не только своего, но и других тюркских народов. Его произведения, достоверно отразившие жизненный уклад и национальные ценности татарского народа, являются энциклопедическими произведениями, прославившими татар на весь мир. Наблюдательность и любовь к фольклору и культуре тюркских народов дали возможность Г. Ибрагимову в своих произведениях наравне с татарскими традициями описать традиции, жизненный уклад и культурные ценности и таких родственных народов, как башкирского и казахского.

The great writer, the founder of romanticism in Tatar literature, philologist, critic, historian, teacher, state and public figure of the early twentieth century, G. Ibragimov left an indelible mark in the literature and culture of not only his own but also other Turkic peoples. His works faithfully reflected the way of life and national values of the Tatar people and are encyclopedic works that glorified the Tatars to the whole world. Observanceandlove of folkloreandculture of the Turkic peoples enabled G. Ibrahimov to describe the traditions, way of life and cultural values of such kindred peoples as the Bashkirs and Kazakhs in their work salong with the Tatar traditions.

Великий писатель, основоположник романтизма в татарской литературе, филолог, критик, историк, педагог, государственный и общественный деятель начала XX века Галимджан Ибрагимов (1887–1938) оставил неизгладимый след в жизни, литературе и культуре не только своего, но и многих других тюркских народов.

Ренессанс, который был отмечен в Европе в XIV–XVI вв., вследствие разных причин до татар дошёл позже, только к концу XIX века и получил свой расцвет в начале XX столетия. Ренессанс среди татар был отмечен возрождением национальных традиций, духовным и культурным взлетом и стал отправной точкой в развитии литературы. Естественно, что национальный Ренессанс был бы невозможен без собранного тысячилетиями духовного наследия и культурного богатства. Поэтому татарская литература в начале XX века прежде всего надеялась на свою тысячелетнюю историю и подпитывалась ею [2, с. 3].

Несомненно, фольклор и культурные ценности – главные факторы в формировании нации. Татарская литература начала XX века (Г. Исхаки, Г. Тукай, Ф. Амирхан, Г. Ибрагимов, Г. Камал и др.) в этом плане оставила предыдущим поколениям бесценное наследие. Так, произведения Г. Ибрагимова «Табигать балалары» («Дети природы»), «Татар хатыны ниләр күрми» («Судьба татарки»), «Алмачуар» («Чубарый») достоверно отразили жизненный уклад и национальные ценности татарского народа и являются энциклопедическими произведениями, прославившими татар на весь мир. Эти произведения ценны прежде всего тем, что они дают будущим поколениям реальные представления об истории, жизни, традициях и культурных цен-

ностях татарской деревни [9, с. 14]. Поэтому так важен их перевод на языки других народов, особенно тюркских, и преподавание их в вузах не только Татарстана и России, но и других стран. Например, в университетах Турции на отделениях «Современные тюркские языки и литературы» эти произведения должны быть программными в обучении татарскому фольклору и литературе, наряду с произведениями Г. Исхаки, А. Тукая, М. Галяу, Г. Баширова, М. Магдиева и других татарских поэтов и писателей. Как отметил известный татарский литературовед Г. Халит, «умение раскрывать события, межличностные отношения и личность с только ему присущим характером через повседневную жизнь, обычаи, этнические детали (легенды, верования, поверья, песни, пословицы, поговорки и т.д.) – главная особенность таланта Г. Ибрагимова» [12, с. 37]. Обучение фольклору и умение пользоваться им в своем творчестве требовал Г. Ибрагимов и от других писателей. Он подмечал и высоко ценил положительный опыт в данной области [8, с. 24].

Г. Ибрагимов родился 12 марта 1887 года в Башкирии в татарской деревне Султанмурад, находящейся к югу от г. Уфы. Сказочная красота природы Башкирии непременно сыграла свою роль в становлении Г. Ибрагимова как писателя и позже с большой любовью была описана им почти во всех его произведениях. Жизненный уклад деревни, традиции, обычаи, тонкости земледелия и животноводства – все это писатель впитал в себя с самого раннего детства и поэтому в его произведениях деревня и жизнь крестьянина занимают особое место. Более того, описывая природу, быт, традиции, одежду, домашних животных, жизнь земледельца и полевые работы, он к месту и удачно использовал диалекты татарского языка, которые известны в таких регионах расселения татар, как Султанмурад, Стерлитамак, Минзелинск, Златоуст и Пермь, подчеркивая тем самым самобытность и богатство родного языка.

Самый верный способ узнать поближе тот или иной народ – это изучение его традиций и духовного богатства. Поэтому татарские писатели начала XX века кроме как к истории своего народа, обратились и к историческоу прошлому, жизненному укладу, традициям и других тюркских народов. Так, например, в 1908 году К.Бикколов издал роман «Туркистан», в котором ознакомил татарского читателя с жизнью и культурными ценностями народов Средней Азии. Г. Монасыйпов в романе «Таранҗы кызы яки Хәлимнең беренче мәхәббәте» («Дочь таранчи или Первая любовь Халима») обратился к историческому прошлому уйгурского и китайского народов. В рассказе Г. Рафикый «Вакытлы никах» («Временное обручение», 1913) на примере судьбы Селима и Хакиме из Кашгара дана богатая информация о традициях и обычаях местных тюрков. Данные произведения обогатили татарскую литературу не только с точки зрения содержания, но и подготовили почву для разработки новых тем [2, с. 177–179].

Начиная со школьных лет в деревенской школе Г. Ибрагимов рос, играя с башкирскими детьми, и проникся уважением и любовью к традициям и культурным ценностям башкирского народа. В 1898 году родители отправили будущего писателя вместе со старшим братом Шакирджаном для обучения в Оренбург в медресе Хусеиния, где в то время получали образование по новой системе «усул-и джедид». Однако его туда не приняли и пришлось ему поступать в медресе Моллы Вели. Вследствие того, что Г. Ибрагимов в 1905 году принял участие в бунте шакирдов, ему пришлось оставить данное медресе. В 1906 году он продолжил обучение в Уфе в медресе Галия. В тот же

год в данное медресе поступил и Маджит Гафури, который в последующем стал известным поэтом татарского и башкирского народов. Г. Ибрагимов и М. Гафури сдружились и остались верны своей дружбе до конца своей жизни. Как отзывался о нем народный поэт башкирского народа и аксакал Мустай Карим, «Г. Ибрагимов был писателем, который родился на земле Башкирии, вдыхал её воздух, пел её песни и был вспоен её родниками» [3, с. 145].

Поэтому во многих произведениях Г. Ибрагимова действия происходят в деревнях и городах, находящихся в переделах башкирской земли, и писатель от всей души с любовью описывает жизнь, национальные особенности, богатый фольклор башкирского народа и несравненную природу этого края («Йөз ел элек» («Сто лет назад»), «Табигать балалары» («Дети природы»), «Яшь йөрәкләр» («Молодые сердца»), «Татар хатыны ниләр күрми» («Судьба татарки»), «Яңа кешеләр» («Новые люди»), «Алмачуар» («Чубарый»), «Башкорт кызы Гөлбикә» («Башкирка Гульбике») и др.). Известный башкирский писатель, драматург и журналист Давут Юлтый в 1920–1930-х годах писал: «Не родился до сегодняшнего дня другой писатель, который бы так мастерски описал богатую природу Башкирии, как Галимджан Ибрагимов. Можно сказать, что подобно тому, как Г. Ибрагимов при помощи богатой природы и прекрасными образами создал великие произведения в татарской литературе, так и оригинальными образами из башкирской жизни Гульбике и Чубарого он помог создать основу башкирской литературы» [14, с. 6]. В произведении «Татар хатыны ниләр күрми» («Судьба татарки»), изданном в 1910 году в городе Стерлитамак в библиотеке «Калем», башкирские реалии раскрылись с еще большей полнотой и получили особую огласку. В повести события происходят в семье кантона Шибая, накопившего свое богатство, обдирая башкирский народ. В данном произведении Г. Ибрагимов живописно описал не только традиции и жизненный уклад татар, но и дружбу и теплые отношения между татарским и башкирким народом, их взаимообогащение и культурный обмен песнями и традициями. В тоже время писатель с грустью в сердце рассказывает о том, как земли трудолюбивых башкир стали переходить в руки таких алчных собственников, как Шибай [7, с. 101–102].

Несмотря на то, что «Башкорт кызы Гөлбикә» («Башкирка Гульбике») является одной из частей романа «Безнең көннәр» («Наши дни»), по содержанию и сюжету он считается самостоятельным произведением. В данном рассказе Г. Ибрагимов описал песенное богатство, искренность и гостеприимство башкирского народа. В то же время в данном произведении Г. Ибрагимов впервые в татарской и башкирской литературе создал образ башкирской женщины. По этому поводу Д. Юлтый писал: «Г. Ибрагимов так нежно описал Гульбике, что, читая произведение, поневоле ощущаешь себя в объятиях той природы, где она живет. Эта природа оживает с необъяснимой силой и красотой! Её необыкновенная чистота щекочет нам нос, блаженно волнуя самые тонкие струны души» [1, с. 132–138]. В данном произведении описаны не только несравненная природа Башкирии, полукочевой жизненный уклад, быт башкирского народа и женская доля башкирки, но и тема сбора и сохранения душевного клада и жемчужины народа – народных песен [11, с. 16–17].

Роман Г. Ибрагимова «Яшь йөрәкләр» («Молодые сердца»), написанный в 1912 году, также важен с точки зрения отражения теплых взаимо-

отношений двух родственных народов – татарского и башкирского. В этом романе основной мотив – стремление личности к свободе, который рассматривается в контексте счастья личности [15, с. 118].

Природа Башкирии, где родился и вырос писатель, судьба народа, его чаяния и надежды с любовью описаны и в другом произведении Г. Ибрагимова – в рассказе «Табигать балалары» («Дети природы»). А в произведении «Алмачуар» («Чубарый») описан древний праздник татарского и башкирского народов Сабантуй, во время которого устраиваются конные скачки и другие соревнования. В рассказе «Карт ялчы» («Пожилой слуга») Г. Ибрагимов естественным образом в события вплетает башкирские народные песни. В повести «Кызыл чәчәкләр» («Красные цветы») писатель в описание природы часто вплетает исторические легенды и предания башкирского народа. Автор настолько влюблен в башкирский фольклор, что даже в произведение «Тирән тамырлар» («Глубокие корни»), в котором описываются события, происходящие в Татарстане, Г. Ибрагимов вводит образ молодого башкирского парня Алемгола с его любовью к башкирским песням и напевам.

В 1915 году Г. Ибрагимов переезжает в Уфу и начинает работать преподавателем языка и литературы в медресе Галия, где когда-то сам обучался. В эти годы он активно пропагандирует татарскую и башкирскую культуры и помогает башкирским писателям и поэтам выйти на литературную арену. Один тот факт, что учителем таких известных башкирских и татарских поэтом, писателей и ученых как Ш. Бабич, С. Кудаш, Г. Нигмати, Х. Туфан, Б. Ишемгол, А. Бикмурзин, был Г. Ибрагимов, лишний раз говорит о влиятельной личности писателя [1, с. 136].

В 1915–1917 годах медресе Галия становится центром литературного и культурного движения татарской и башкирской молодежи. Такие деятели литературы и культуры как Г.Ибрагимов, М. Гафури, Ш. Бабич, Х. Туфан, С. Куйдаш, Б. Ишемгол, Ф. Сейфи-Казанлы, С. Сунчелей, С. Гобеши были выпускниками данного медресе. Первым писателем, написавшим о творчестве М. Гафури и Ш. Бабича после октябрьской революции 1917 года, также был Г. Ибрагимов.

В Уфу в медресе Галия с целью получить образование вместе с передовой татарской и башкирской молодежью приезжали представители казахского, киргизского, узбекского, дагестанского, черкезского и других народов. К тому же во время летних каникул Г. Ибрагимов ездил на Кавказ и учил ногайских (татарских) детей читать и писать. А после того, как был вынужден покинуть и медресе Галия, будущий писатель продолжил педагогическую деятельность в казахских степях и в Астраханской губернии. К тому же, работал разнорабочим на Урале. Наблюдательность и любовь к фольклору и культуре тюркских народов дала возможность Г. Ибрагимову в своих произведениях наравне с татарскими и башкирскими обычаями и культурными ценностями описать традиции, культуру и жизненный уклад и казахского народа [10, с. 252]. Так, в произведении «Казакъ кызы» («Дочь степи»), написанном в 1911 году и изданномв 1924 году в Москве, Г. Ибрагимов описал жизнь родственного татарам казахского народа в важный для них отрезок истории: родовые распри, надежду народа на освобождение от патриархального уклада, желание женщин выходить замуж по собственному желанию и т.д. Это произведение по праву можно назвать энциклопедией жизни

казахского народа. Как писал татарский литературовед н. XX века Г. Рахим, «Произведением «Казакъ кызы» («Дочь степи») Г. Ибрагимов еще раз показал себя эрудированным и чувственным писателем, работающим в широком эпическом плане. Это произведение напоминает нам великие тюркские дастаны, пропахшие степью, и песни, сложенные оригинальными степными поэтами» [11, с. 58].

Жизнь, традиции и культуру родственного казахского народа Г. Ибрагимов знал не понаслышке. Вследствие того, что во время русской революции 1905 года будущий писатель участвовал в бунте шакирдов, он был изгнан из медресе Моллы Вели в Оренбурге. Шесть месяцев Г. Ибрагимов учительствовал в казахских степях и изучил фольклор и жизненный уклад этого народа, получал вдохновение, слушая песни народных певцов, и описал все это мастерским пером в романе «Казакъ кызы» («Дочь степи»). Как справедливо заметила татарский литературовед А. Садекова, в татарской литературе не было еще произведения такого международного уровня, изображающего сложную жизнь степного народа, его очень специфическую жизнь и традиции в таком широком эпическом плане [11, с. 58]. С первых до последних страниц в романе с восхищением описываются традиции, одежда, кухня, народное творчество, культурные ценности казахского народа и природа степи, где данный народ кочевал испокон веков. Все эти детали помогли раскрыть и психологию и философию жизни казахов. Широкие казахские степи, где пасутся стада коней и баранов, животноводство, восторг и праздничное настроение во время кочевки из одного пастбища в другую, застолья с мясом, кумысом и развлечениями, родовые распри, борьба за власть, за место под солнцем – все это составляет основу произведения. Традиции, обычаи, этнографические детали и казахские слова, использованные Г. Ибрагимовым, неимоверно обогатили произведение и создали все условия, чтобы читателям была понятна кочевая жизнь казахского народа и чтобы они проникнулись его духовной жизнью [5, с. 270–271]. Известный казахский писатель Сабит Муканов про Г. Ибрагимова писал: «Казахи считают Г. Ибрагимова своим – казахским – писателем. Казахи уважают Ибрагимова за то, что он с такой любовью описал нашу жизнь» [6, с. 540].

Многие традиции, описанные в романе, до сих пор живы среди казахского народа. А некоторые исчезли под воздействием современной жизни. Однако было бы неверно считать, что эти традиции и обычаи были присущи только казахскому народу. Многие из них были общими для всех тюрков-кыпчаков – татар, башкир, казахов и киргизов. И эта общность лишний раз подтверждает величие и единство тюркского мира и даёт возможность представить воочию прошлое и татарского народа [4, с. 273].

Всё творчество и деятельность Г. Ибрагимова была направлена на усиление дружбы между родственными народами. Туркменский поэт Берды Кербабаев верно заметил: «Во время установления Советской власти, по сравнению с литературами народов Средней Азии, татарская литература была намного развитой. И важную роль в этом сыграл Г. Ибрагимов» [6, с. 539].

Великий азербайджанский писатель Самед Вургун назвал Г. Ибрагимова «великим писателем среди всех восточных народов в Советском Союзе». Башкирский писатель и литературовед Кирей Мерген также отметил, что такие великие сыны татарского народа, как Г. Тукай и Г. Ибрагимов, своим

мастерским пером стали примером для всего тюркского мира. Башкирский народный поэт Сейфи Кудаш признавал Г. Ибрагимова своим наставником, а Давут Юлтый подчеркнул, что Г. Ибрагимов был одним из основателей башкирской советской литературы [13, с. 199].

В заключение было бы уместно привести слова известного татарского писателя Фервазa Миннулина: «Творчество и талант Г. Ибрагимова стали примером и школой мастерства для казахского, киргизского, башкирского, азербайджанского и узбекского народов» [6, с. 540–541].

ЛИТЕРАТУРА


1. Аккөбәков Р. Беззең бөек якташыбыз // Галимҗан Ибраһимов һәм XXI гасыр. Тууына 120 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. Б. 132–138.

2. Бәширов Ф. XX йөз башы татар прозасы. Казан: Фикер, 2002. 287 б.

3. Гимазиев Й. Талант һәм хезмәт: (Галимҗан Ибраһимов иҗаты турахында әзәби-публицистик мәкаләләр) .Өфө: Башкортстан китап нәшр., 1982.

4. Зарипова-Четин. Ч. Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы» романында казакъ халкының гореф-гадәтләре һәм мәдәни кыйммәтләре // Галимҗан Ибраһимов һәм XXI гасыр: Тууына 120 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. Б. 273–287.

5. Zaripova-Çetin Ç. Alimcan İbrahimov’un Eserleride Tatar Başkurt ve Kazak Türklerinin Kültürel Değerleri. Ankara: BENGÜ, 2016. С. 369.

6. Ибраһимов Г. Сайланма әсәрләр. Казан: ТаРИХ, 2002. 542 б.

7. Исламов Ф.Ф. Татар әдәбиятын укытканда милләтара бәйләнеш (Идел буе һәм Урал ягы халыклары үрнәгендә). Казан: Татарстан фәннәр академиясе тарих институты, 2000. 228 б.

8. Мәхмүтов Х. Г. Ибраһимов фольклор турында // Фольклор жанрларын анализлау. Казан: Казан дәүләт университеты нәшр., 1986. 128 б.

9. Мингазова Л.И. Творчество Ибрагима Салахова: Основная проблематика и ее художественное воплощение: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1998. 25 с.

10. Mingazova L.I., Galimullin F.G., Galimullina A.F. folk heroes in the poetry of the people of the Volga and Ural regions // Journal of Language and Literature (Baky, Azerbaijan). 2014. № 5 (4) С. 252–555.

11. Садекова А. Фольклор в эстетике Галимжана Ибрагимова. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, 1995. 260 с.

12. Халит Г. Галимҗан Ибраһимов (Тормышы һәм иҗаты). Кереш мәкалә // Г. Ибраһимов. Сайланма әсәрләр: 3 томда. Казан: Таткнигоиздат, 1957. 1 т. 608 б.

13. Хәсәнов М. Галимҗан Ибраһимов // Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 4 т. Б. 181–200.

14. Юлтый Д. Галимҗан Ибраһимов // Башкорт аймагы. 1928. № 6. С. 6.

15. Яруллина. Р. Г. Ибраһимов иҗатында ирек идеясе // Галимҗан Ибраһимов һәм XXI гасыр: Тууына 120 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. Казан, 2007. С. 115–120.


## «ГАЛИМДЖАН ИБРАГИМОВ – ГЛАЗАМИ МОЛОДЫХ» десять лет и вся жизнь…


***Ибрагимов А.О., Ибрагимов М.Х.***



Настоящей статьей авторы освещают свои исследования о своем знаменитом родственнике Галимджане Ибрагимове, которые велись ими в течение последних 10 лет. Результат поисков привел к неожиданным результатам, которые имели резкое отличие от ранее опубликованных материалов и сведений о нем, что связано с ранее существовавшим коммунистическим режимом. Следуя вновь установленным сведениям и фактам, авторы подготовили ряд статей, которые легли в основу научно-популярного издания «Г. Ибрагимов глазами

молодых», в которое включены копии с оригиналов документов архивов НКВД (ныне ФСБ), воспоминания его родственников и ранее не опубликованные документы и сведения о нем.
Как мы видим, авторы, будучи потомками Г. Ибрагимова, осуществляя поиск нового, находили новые страницы истории не только одной широко известной личности, но всей нашей великой родины с ее богатой историей.
Поэтому авторы надеются, что настоящей публикацией сумеют донести до широкой публики о больших возможностях семьи и школы для достижения поставленной задачи.

In this article the authors outline their research about his famous relative the Galimdzhana Ibragimov, who conducted them over the last 10 years. The result has led to unexpected results, which was a sharp contrast to previously published materials and information that is associated with the previous Communist regime. Following the newly established information and facts, the authors have prepared a series of articles that formed the basis for the popular scientific edition «Galimzhan Ibragimov through the eyes of young», which includes copies of the original documents of the archives of the NKVD (now the FSB), memories of his relatives and previously unpublished documents and information on it.
As we can see, the authors, being descendants of Ggalimdzhana Ibragimov, seeking a new, found a new pages of history not only of one well known person, but all over our great country with its rich history. Therefore, the authors hope that this publication will be able to convey to the public about the great opportunities families and schools to achieve the task.

В 2007 году в республиках Башкортостан и Татарстан отмечался юбилей Галимджана Ибрагимова – одного из первых Героев Труда СССР, видного государственного и общественного деятеля, классика татарской литературы, автора множества научных публикаций по истории и краеведению. Потомки рода Ибрагимовых активно принимали участие в проводимых мероприятиях. Младшее поколение семьи Ибрагимовых впервые столкнулось с массой вопросов об истории рода и удивительных людях – дальних и близких родственниках.

А началось всё гораздо раньше, в 1967 году.

Ибрагимову Габделхаку Газизджановичу, двоюродному брату Галимджана Ибрагимова не давала покоя мысль, что о знаменитом родственнике так мало известно широкой публике. Начало поисков следует отнести к 1967 году, т.к. документы датированы Габделхаком Ибрагимовым «31 марта 1967 г.». Именно их и нашел сын Габделхака – Марат в старом фибровом чемодане.

Это были уникальные семейные архивные документы, включающие редкие фотографии, письма, открытки с фронта, газеты и многое другое. Теперь за дело взялся Марат Хакович.

Была составлена наиболее полная родословная семьи Ибрагимовых. Причем, в исследовании помогали уже внучатые племянники Адель, Даниил и Арсений.

Родословная помогла в значительной степени расширить границы наши поисков. Наиболее ранние сведения о роде Ибрагимовых относятся к Ахмету, родившемуся в 1587 году. Всего было установлено и сведено воедино 12 поколений рода Ибрагимовых, насчитывающих более 350 человек. В древо родословной были внесены Ибрагимовы, находящиеся в близком

родстве с Галимджаном Ибрагимовым. На сегодняшний день известно более 900 человек данного рода.

Много было «перелопачено» архивов, библиотечных фондов, литературы, Internet ресурсов. В работе помогали родственники из разных городов Башкортостана, Татарстана, Узбекистана, работники Национального музея РБ, сотрудники школ, ВУЗов, Научных институтов, Архивов и просто неравнодушные люди.

Первоначально, в 2007 году была создана экспозиция из 8 планшетов, которая обзорно описывала жизнь и деятельность Галимджана Ибрагимова с момента его рождения 12 марта 1887 года и до смерти в тюремной больнице города Казань. В дальнейшем, по мере обнаружения новых сведений из различных архивов, включая ФСБ России, место его кончины пришлось поставить под сомнение.

На Архангельском кладбище Казани стоит памятник, но родственники Галимджана Ибрагимова полагают, что его необходимо считать кенотафом – памятником, установленным на месте, которое не содержит останков покойного.

Впервые тема «Галимджан Ибрагимов – глазами молодых» появилась в выступлениях юных исследователей Ибрагимовых Адель и Даниил в 2009 году при непосредственном участии в качестве научных руководителей О.К. Бабенко и М.Х. Ибрагимова.

Большой стаж педагогической работы О.К. Бабенко и жизненный опыт М.Х. Ибрагимова в значительной степени помогли осуществить намеченные планы по раскрытию жизни одной из ярких личностей начала XX века. Одним из крупных итогов всей поисковой работы по теме «Галимджан Ибрагимов – глазами молодых» явилось издание научно-популярной книги «Галимджан Ибрагимов», выпущенной татарским книжным издательством в 2012 году к 125-летию со дня его рождения.

В книге читатели могут проследить практически весь жизненный путь Галимджана Ибрагимова, который начинается с шакирда в медресе «Валия» в городе Оренбург (в столь раннем возрасте он уже проявил себя как яркая личность) и до присвоения звания «Герой Труда» в 1928 году. Авторы раскрывают ранее неизвестные страницы жизни и деятельности Галимджана Ибрагимова, которые по неизвестным причинам умалчивались в течение длительного времени. Стереть память о таком человеке пытались в 1937 году, в год его ареста и последовавшей загадочной смерти Галимджана Ибрагимова 21 января 1938 года. Но пришло время «оттепели» и по настоянию татарской общественности и просто неравнодушных людей 24 сентября 1955 года за подписью Председателя Комитета Государственной безопасности при Совете Министров Татарской АССР было принято Постановление об отсутствии, которым было признано: «Следственное делопроизводство по делу прекратить за отсутствием в действиях ИБРАГИМОВА состава преступления…» [1, с. 77].

Благодаря выполненной поисковой работе были восстановлены нарушенные связи родственников на территории бывшей СССР, т.к. многие разъехались по всей стране во время Великой Отечественной войны. В 2012 году семье Ибрагимовых удалось обновить мемориальную доску Галимджану Ибрагимову, которая ранее была установлена на фасаде дома № 35 по Бульвару Галимджана Ибрагимова в 1967 году, при активном содействии и на

личные сбережения Ибрагимова Габделхака Газизджановича. В 2012 году был создан фильм о Галимджане Ибрагимове «Молния в ночи».

Считаем, что настоящей работой по сохранению памяти своего рода, его знаменитого Галимджана Ибрагимова, мы, возможно, сможем заинтересовать молодых, начинающих краеведов; она может быть использована на уроках татарского языка, классных часах и будет служить примером для подрастающего поколения в деле познания своего рода, знаменательных личностей и тем самым внесут свой вклад, в историю своей Родины – России. Проведенная на протяжении десяти лет исследовательская работа говорит о прямой связи семьи и школы, которая имеет показательные итоги.

Считаем данное непрерывное исследование по теме, не меняющей своего основного названия: «Галимджан Ибрагимов – глазами молодых» одной из заслуг преподавательского состава учебного заведения, а свою роль семья проявляет на общности интересов, находясь в постоянном поиске нового.

ЛИТЕРАТУРА

1. Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых / [авт.-сост. М.Х. Ибрагимов]. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. 336 с.

## ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ҺӘМ ӘМИРХАН ЕНИКИ

***Идрисов Р.Р.***

Классик татарской литературы Г. Ибрагимов оказывает огромное воздействие на формирование художественного мира молодого А. Еники. На примере наставника у него складываются идейно-эстетические принципы художественного освоения действительности, особенности художественного видения мира, творческий метод и индивидуальный стиль. Плодотворно было его воздействие в идейно-эстетических поисках художественой индивидуальности.

The classics of national literature influence greatly on the formation of artistic world of young writers. Like an instructor the young writers have ideologically-aesthetic principles of artistic mastering of reality, peculiarities of artistic world view, creative approach and individual style. A creative example of his elder friend, G. Ibragimov played the decisive role in artistic world formation of an outstanding Tatar writer Amirkhan Enykeev. The influence was great in ideologically-aesthetic searches of artistic individuality, in formation of poetic world in the creative works of the writer.

Күренекле татар әдибе Әмирхан Еники үзенең язучы булып формалашуына әдәбиятыбыз титаны Галимҗан Ибраһимовның хәлиткеч тәэсире хакында әледән-әле искәртеп килде. Бигрәк тә әдип шәхесе һәм иҗат, язучының дөньяга карашы, аның әдәби дөньясы кебек төшенчәләргә кагыла ул уртаклык һәм тәэсир-йогынтылар. Еникинең әдип хакындагы фикерләре аның публицистикасында бер бөтен төзек система булып күз алдына килә. Барыннан да элек Еники игътибары өлкән әдипнең остазлыгына юнәлтелә, шулай ук татар әдәбиятына Г. Ибраһимовның бәрәкәтле традицияләре хакында дәлилле күзәтүләр ясала. Еникинең «Безне ул өйрәтте», «Әдипнең терелеп кайтуы», «Бер сорауга бер җавап» мәкаләләре турыдан-туры Г. Ибраһимовка багышланган. Шулай ук әдип иҗатының үзенчәлекле нәтиҗәсе булган «Соңгы китап»та да классик әдип хакында кызыклы фикер-уйланулары

кергән. Әдипнең васыяте булып кабул ителгән соңгы мәкаләләренең берсе – «Санаулы көннәр» эссесында да Ә. Еники Г. Ибраһимов мирасын саклауны кайгырта.

Еникигә әдәби остазы Г. Ибраһимовның йогынтысы әлегә ныклап өйрәнелмәгән. Яшь язучының дөньяга карашы, аның иҗат йөзе һәм әдәби дөньясы формалашуда өлкән әдипнең ролен билгеләү мөһим теоретик һәм практик әһәмияткә ия.

Еникинең балачактан әдәбиятка тартылуында хәлиткеч рольне Г. Тукай һәм Г. Ибраһимов иҗатлары уйнаган. «Галимҗан Ибраһимов әсәрләрен мин унбер-унике яшемнән үк укый башладым... Укырга шомарып җиткәч һәм укуның тәмен белә башлагач, мин инде, әйткәнемчә, бер китапны да ычкындырмыйча «йота» башладым... Ләкин шулар арасыннан минем күңелемне аеруча Галимҗан Ибраһимов биләп алды. Ул барсына караганда да татарчарак һәм шомарак яза кебек иде, шуңа да аның әсәрләрен, су эчкәндәй, бик җиңел укып була иде», – ди ул [1, б. 100].

Бу чорда Г. Ибраһимов аны тулысынча биләп ала, яшь малай иҗат психологиясе әлифбасын да әдип әсәрләре мисалында үзләштерә кебек. Һәм, бәлки, булачак әдип шәхесенең нигезе дә шул иҗат үрнәгендә салынгандыр. Истәлекләрдән күренгәнчә, яшь Әмир әдип әсәрләрендәге геройларның прототиплары, андагы хронотоп, топослар хакында уйлана, иҗат психологиясе серләренә төшенү омтылышлары ясый. Бу күзәтүләре хакында, инде олуг әдип булгач, Еники: «Әйе, Солтанморат белән Дәүләкән арасы ерак түгел, Солтанморатта булган хәлләрнең һәм кешеләрнең бездә дә булуы бик табигый, хәтта вакыт-вакыт күңелгә, әдип нәкъ менә бездән алып язмадымы икән дигән уй да килеп куйгалый иде... Менә мин әйтәм, Гыйрфан мулла да, үзенең кечкенә Галимҗанын ияртеп, Дәүләкәннең ат базарыннан узмадымы икән? Юк, узгандыр, узмыйча булмас, һәм кечкенә Галимҗан да Алмачуар кебек асыл сөякләрне, бәлки, шул Дәүләкән базарында күргәндер дә әле», – ди ул [1, б. 101].

Бу үзенчәлекле фәнни-филологик эзләнүләрен Еники гомере буе дәвам итә. Һәм язучының иҗат лабораториясе өчен мөһим булган кызыклы гына нәтиҗәләргә дә килә. Бу хакта әдип болай дип әйтүне кирәк дип таба: «Соңыннан күп еллар үткәч, мин Г. Ибраһимовның чынлап та безнең Дәүләкәндә булуын белдем... Ләкин ни өчен соң әле мин бу хыяллану-юрауларны язып торам? Кабатлап әйтәсем килә: Галимҗан Ибраһимов мине бала чагымнан ук әсир иткән зур язучы булып кына түгел, ә безгә якын җирдән – Солтанморат авылыннан чыккан атаклы бер кеше буларак та минем күңелемә бик нык кереп утырган иде. Әдипкә карата булган бу үземә бер якынлык тойгысы миндә гел сакланып килде. Моның билгеле бер әһәмияте бар, укучы соңга табарак үзе дә күрер дип ышанам», – ди ул [1, б. 102].

Әдип булырга карар иткән яшь Әмирне моңлы, нурлы Казанга барыннан да элек якташы Галимҗан Ибраһимов кояшы тартып китергән булып чыга. Булачак әдип аның эзләре буйлап бара, аның кебек язучы буласы килә. «1925 елның азагында мин Казанга килдем. Хәзер инде тере Галимҗан Ибраһимовның үзен дә күрү, шәт, насыйп булыр. Аны гына түгел, гел хыялымда йөргән Фатих Әмирхан белән Галиәсгар Камалны да күрермен дим әле, – мин беләм, алар шушында, Тукай туфрагында яшиләр. Әйе, күпне күрергә, күпне белергә дип килдем мин бу “хикмәтле һәм мәгърифәтле” чал Казанга!» [1, б. 102].

Күрүебезчә, татар мәркәзенә Еники анык кыйбла-маяклар белән килә, бу чорда яшь иҗатчының әдәби-эстетик зәвыгы урнашып беткән диярлек була. Талантлар бик иртә өлгерә, аларның ачылып китүе өчен шартлар гына булсын! Остазы Галимҗан Ибраһимовның әдәби процесстагы урынын да бик ачык күрә яшь каләм иясе: «Кыскасы, М. Горький үзенең бәхәссез авторитеты белән рус әдәбиятында нинди урын тоткан булса, Галимҗан Ибраһимов та безнең әдәбиятта шундыйрак урын тота иде дисәм, әллә ни арттырып җибәрү булмас дип уйлыйм. Һәрхәлдә миңа шулай күренә, шулай тоела иде» [1, б. 103]. Остазының шул чор әдәби хәрәкәтендә беренче урында торуын тоемлый, дөрес аңлый яшь Әмир.

1962 елда язылган «Безне ул өйрәтте» исемле мәкаләсендә Ә. Еники: «Мине, язучы кешене, ул иң әүвәл әдип-художник буларак кызыксындыра…

Бишенче елдан соң әдәбиятка бер үк вакытта диярлек Фатих Әмирхан белән Галимҗан Ибраһимов килеп керделәр… Бу ике олы талант аркасында безнең проза әдәбияты яңа биеклеккә күтәрелде, өр-яңа сыйфатларга баеды, ул инде чынлап та рус һәм Европа прозасына охшаш бер кыяфәткә керде. Без чын мәгънәсендә роман һәм хикәяләр укый башладык…

Шулай итеп, Г. Ибраһимов безнең проза әдәбиятыбызда хикәяләүнең үрнәк булырлык гүзәл бер тел-стилен тудырды», – дип язды [2, б. 9]. Мәкаләнең йомгаклау өлешендәге сүзләр Ә. Еникинең үзенә дә кагыла кебек: «…аңардан соң әдәбиятка килгән язучылар, барысы да диярлек аның көчле йогынтысына бирелеп, теге яки бу дәрәҗәдә Галимҗан стиле белән яза башладылар… Әлбәттә, алар иярүчеләр генә булып калмадылар, чын талантка ия булганнары телебезне баетуда, әдәби осталыкны үстерүдә үзләреннән дә зур өлеш керттеләр, ләкин барыбер аларның һәркайсы “Галимҗан мәктәбе” аша узды» [2, б. 9].

Г. Ибраһимовның язучыга шифалы йогынтысы шәхси мөнәсәбәт, бәяләр белән дә аңлатыла. Китаплары аша гына таныш булган әдипне Ә. Еники күреп тә кала. Һәм бу очрашу булачак әдипкә бик көчле тәэсир итә: «Сүз дә юк, авыру әдип белән бу очрашуның миңа тәэсире бик зур булды. Әгәр мин 1955 елны партия Үзәк Комитетында Галимҗан Ибраһимовның эшен яңадан карауны үтенеп хат язганмын икән, әнә шул 1937 елда әдипне үз күзем белән күрү миңа ул хакта тәвәккәлләп язарга, һичшиксез, ярдәм иткәндер, дип уйлыйм», – диде ул [3, б. 475].

Әдип әсәрләренең художество-әдәби агы Еникинең игътибар үзәгендә тора. Шулай ук дөньяга караш һәм әдәби мәсләктә дә алар уртак позицияләрдә торган, дип әйтергә нигез бар. Бу ике әдипнең иҗатларындагы уртаклык менталитет берлегенең стильдә чагылышында, Башкортстан материалына еш мөрәҗәгать итүдә, Еникидәге эпиклык сулышында, телләренең байлыгында күзәтелә. Шул ук вакытта кайбер аерымлыклар да күзгә ташлана. Мәсәлән, әдипләрнең әсәрләрендәге башкорт халкы вәкилләренең образларында. Еникидә тугандаш халык вәкилләре гел уңай булып гәүдәләнсә, Г. Ибраһимов әсәрләрендә ул башкачарак чагылыш таба [5, б. 157–171].

Күрүебезчә, турыдан-туры иҗади тәэсир-йогынтыдан тыш, әдип шәхесенең үзенчәлекләренә дә игътибар итә Еники. Онытылмас очрашу, якташлык хисе, туган туфрак тойгысы, гаделсезлек корбаны булган Г. Ибраһимов белән теләктәшлек хисе дә язучыга якын булган дип әйтергә тулы нигез бар [4, б. 444–447].

Әдәбиятчы галимнәр М. Хәсәнов, Ү. Гыймадиев, М. Мәһдиев, С. Сафуанов, С. Поварисов хезмәтләрендә искә алынган әдип әсәрләренең җирлеге, прототиплар, хронотоп, язылу тарихы, иҗат лабораториясе мәсьәләләре дә Еники игътибарыннан читтә калмаган, билгеле. Бу хакта Еникинең төрле хезмәтләрендә сибелеп бирелгән әдип хакындагы фикерләре сөйли. Г. Ибраһимов Еникинең даими рәвештә игътибар үзәгендә була. Әдипнең архивында Г. Ибраһимовның Мәскәүдә үтәчәк юбилей кичәсенең татар телендә булган өчен генә тыелуы уңаеннан туган борчылулы уйланулары теркәлгән. Аны Солтанмораттагы тергезелгән музейга үзе җибәргән тарихи ядкярләр язмышы да кызыксындыра. Ә. Еники үзен һәрдаим остазы орбитасында тоя, һәм ул гомере буе дәвам итә.

ӘДӘБИЯТ


1. Еники Ә. Әдипнең терелеп кайтуы // Казан утлары. 1966. № 11. Б. 100–111.

2. Еники Ә. Хәтердәге төеннәр: мәкаләләр, очерклар һәм истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. 224 б.

3. Еники Ә. Соңгы китап: Истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 504 б.

4. Еники Ә. Әсәрләр: 5 томда. Казан: Татар кит. нәшр., 2004. 5 т.: публицистик язмалар, мәкаләләр. 479 б.

5. Ибраһимов Г. Хикәяләр, повесть, роман. Казан. Татар. кит. нәшр., 2007. 463 б.


## Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ «КӨТҮЧЕЛӘР» ХИКӘЯСЕНДӘ ВАХИТНЫҢ РОМАНТИК ЭЗЛӘНҮЛӘРЕ


***Каюмова Г.Ф.***



В статье предпринимается попытка анализа романтических исканий главного героя рассказа Г. Ибрагимова «Пастухи». В произведении, гармонично сочетающем себе синтез реализма и романтизма, повествуется о нищенской жизни старого и больного старика, бывшего пастуха Аптераш и его сына Вахита. Однако Вахит, полная противоположенность отца, не спешит смириться с реальной действительностью. Романтические искания ведут его в мир искусства, любви, природы, воспоминаний.

This article is considered an analysis of Ibrahimov's story «Cattlemen». «Cattlemen»is a story, in which the interweaving of realism with romanticism is expressed. The story tells about the old man Apterash – a cattleman, tired of hard life and poverty. First, the old man works in a mill, then hires a cattleman and lives in a shack of earth floor. His last days he is forced to spend with different people who look after him in turn. The son of the old man Vahit is his opposite. The idea of the story is connected with this image. Vahit is revealed as a romantic hero, rebelling against cruelty and dreaming of happiness and spiritual freedom. Vahit, striving for beauty, is contrasted to reality.


Г. Ибраһимовның «Көтүчеләр» хикәясе 1913 нче елда, истибдадтан соң, яңа инкыйлаб күтәрелеше чорында иҗат ителә. Хикәядә, авыр тормышта газап чиккән, коллык тәкъдире белән тәмам килешкән, күндәм Әптерәш карт һәм аның, күңеле белән матурлыкка омтылган, гаделсезлекка карата кискен каршы торган, бунтарь холыклы Вахит тормышы турында бәян ителә.

Хикәяләү, Г. Ибраһимовның башка хикәяләрендәге кебек үк, беренче заттан, төп герой − «мин» исеменнән алып барыла. Вахит сурәтләвендә

без әтисенең башта тегермәндә эшләвен, соңыннан көтү көтәргә ялланып, коточкыч шартларда, җир идәнле куышта гомер сөрүен күрәбез. Әмма бар тормышын авыр хезмәткә багышлап, ахыр чиктә сый-хөрмәткә лаек Әптерәш карт соңгы көннәрендә чиратка салынып, өйдән-өйгә йөреп, мал өендә, бозаулар арасында соңгы сулышын ала.

Күрәбез, моңарчы язылган «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» (1907), «Яз башы» (1910), «Диңгездә» (1911), «Сөю – сәгадәт» (1911) хикәяләреннән аермалы буларак, автор игътибарын социаль гаделсезлеккә, гади кеше һәм аның җәмгыятьтәге урыны турында реалистик рухтагы уйлануларга юнәлтә төшкән. Үзенчәлекле реализм һәм романтизм иҗат ысуллары синтезында язылган әлеге хикәясендә Г. Ибраһимов үзен рус, аурупа әдәби-фәлсәфи карашларын аңлы рәвештә үзләштереп, шәрык җирлегендә иҗади үстерүче буларак чыгыш ясый. Ул төрек әдәбияты вәкилләре К. Задә, Ш. Сөләйман, С. Тәүфыйк, А. Рәсим, А. Хәмид, Х. Зыя, Т. Фикрәт әсәрләре аша француз әдәбияты философлары, әдипләре хезмәтләре белән дә танышу мөмкинлеге ала [3, б. 128].

Хикәядә Әптерәш карт фаҗигасе куе реалистик буяуларга манылса, аның улы Вахит образы, аның белән бәйле вакыйгалар чылбыры романтик сурәтләнештә тәкъдим ителә. Әптерәш карт кебек хезмәт кешеләренең көйсез язмышы җәмгыятьтә меңнәрнең уртак фаҗигасе булып яңгырый.

Вахит исә – хыялдагы каршылыклы образ. Авылдашлары тарафыннан «ярлы тәкәббер» кушаматы алган Вахит бәхет, рухи азатлыкка омтылучы, тормышның, авылдашларының гаделсезлеге һәм мәрхәмәтсезлегенә каршы баш күтәрүче романтик герой буларак ачыла. Хикәянең исеменә салынган мәгънәгә дә игътибар итү сорала. Беренчесе – туры мәгънәсендә авыл көтүчеләре – Әптерәш һәм аның улы. Икенчесе, Р. Ганиева фикерен хупласак, «көтүчеләр» − дөньяның акыл ияләре, халыкны бергә туплаучылар, әйдәп баручылар, укымышлы кешеләр, гыйлем ияләре дигән мәгънәне аңлата. Өстәвенә, «әдип хикәясендәге «көтүчеләр» метафорасы Аурупа рус фәлсәфи фикереннән, әдәбияттан килә торган эчтәлек белән дә баетыла.... Шәрык һәм Гарәп мәдәниятеннән, француз һәм рус әдәби-эстетик фикерләреннән килгән традицияләр бергә килеп очраша һәм синтезлаша» [1, б. 229]. Хикәядә автор, Вахит сүзләре белән алланың барлык илчеләрен, мәдәни кешелекнең барлык «көтүчеләрен» җавапка чакыра. Гомумән, Р. Ганиева үзенең дәлилле фикерләре белән мәктәп дәреслегендә «көтүчеләр» дип − «алма пеш, авызыма төш» дип, Вахит кебек, янәсе кул кушырып кына, үз бәхетләрен көтеп ятучылар дип аңлатучыларга каршы чыга. Дөрестән дә, хикәядә халыкны көтүче, аны туры юлга алып чыгучы образ – Гайсә пәйгамбәр образы. Вахит аның сурәтен рәсемнәр залында күрә «Сөйлә, Гайсә! Син адәмнәрнең бәхетсезлеге, аларны рәхәтлеккә чыгару турында күп уйладың; әйт, нинди фикергә, нинди нәтиҗәгә килдең? Кан түгү бетәчәкме? Милләте, дине башка булганлык өчен дошманлашуларның бер чиге булачакмы? Әйт, боларга ирешүдә син күп уйлавыңның нәтиҗәсендә нинди юлны кыскарак таптың?» – дип мөрәҗәгать итә аңа хикәя герое Вахит [2, б. 80]. Автор аны Әптерәш кебек ярлы халыкның яклаучысы, коткаручысы итеп сурәтләгән.

Бунтарь рухлы, хакыйкатькә омтылучы романтик образ Вахит чынбарлыктан әнә шулай рәсемнәр сараена, виртуаль дөньяга да «качып» карый. Әмма каршылыклы фикерләре өстен чыга: «Рафаэль! Синең мадонналарың

матур! Ләкин менә шул миллионнарча Әптерәш картлар өчен аңардан нинди мәгънә?» – дип монда да коткару тапмаганын таный. Әсәрнең кульминация өлешендә, этисе Әптерәшнең үле гәүдәсе янында ул үзенең көтүчеләргә ышанычын тәмам югалтуын күрсәтә: «Әфләтуннар, Аристолар, Әбугалисина, Фараби, ибне Рөшдләр, Коперник, Ньютон, Декарт, Кант, Вольтер, Гете, Спенсер һәм башкалар, – сез һәммәгез шул гәүдә алында җавап бирергә үзегезне бурычлы санамыйсызмы? Юлыгызның яктылыкка, бәхеткә, ирекккә ирештермәвен тәҗрибәдә күреп, яңа юллар эзләргә кушмыйсызмы?» [2, б. 81].

Романтикларга хас булганча, Вахит хакыйкатьне, күрәбез, сәнгатьтән, хәтта мәхәббәттән дә эзләп карый. Ул этисе кебекләргә карата булган гаделсезлектән котылу юлларын билгеләргә омтыла. Ләкин нәрсә булганын бик белергә теләсә дә, җавап таба алмый: ни өчен аның этисе мондый аяныч хәлләргә төшкән, ни өчен әнисе бик яшьли үлгән – әлегә сәбәбе ачыкланмый. Кеше иҗтимагый хәлләргә карап түгел, инсаният кануннары буенча яшәргә тиеш тә югыйсә. Вахитның җан өзгеч: «Дөньяң шундый матур, без ник болай бәхетсез соң, Ходаем!!» [2, б. 82], сүзләре кайтаваз булып, хикәягә риторик сорау төсмере бирәләр.

Вахит юанычны табигатьтән дә эзләп карый. Автор хисләр матурлыгын табигать гүзәллеге белән янәшә куеп тасвирлый. Яшьләр күңелендәге сөю дулкыннары һәрчак табигатьнең искиткеч манзарасы биргән рәхәтлеккә кушып сурәтләнә. Бер үк вакытта мәхәббәт – табигатьнең матурлыгын күрергә ярдәм итүче көч, кешенең күңел күзен ачучы могҗиза. Ул этисенә ияреп килгән Сараны тауларга, урманнарга алып чыга, бергәләшеп, шома ташлар, матур чәчәкләр җыялар.

Язучы геройның рухи дөньясының чагылышын Сарага булган мөнәсәбәттә тасвирлый. Бу мәхәббәт Вахитның бер төрле генә барган тормышына, сүнә барган җанына шулкадәр көчле тәэсир итә, егетнең үпкә-шөбһәләрен оныттыра, җаны канатландыра: «Һәр көн йокыдан уянгач, шунда бару, матур Сарам белән бергә, икәү генә уйнау өмете минем йөрәгемне кузгата торган булды» [2, б. 68], – дип белдерә яшь Вахит.

Болардан тыш Вахитның романтик күңелен биләүче, хатирәләргә салучы – ул әнисенең якты образы. Вахит иң авыр вакытында әнисен сагына, дөньяның аны җәберләгәне өчен күз яше белән бушанасы килә: «Ләкин ул кабердә... Башка һичкем мине аның кадәрле сөя алмый... Мин берәүгә дә кирәк түгел, мин үзем дә һичкемне, һичкемне якын күрмим, һичберсен яратмыйм, ярата алмыйм» [2, б. 190].

Әсәрдә Вахитның эти-әнисен югалтудан туган сагыш, үкенеч, чарасызлык мотивлары миллионнарны авыр тормыштан, коллык газапларыннан азат итүне, дөнья философлары кушканча, табигый кануннар буенча яшәргә кирәклеген раслау кебек масштаблы проблемалар калку куелган.

ӘДӘБИЯТ

1. Ганиева Р. Татарская литература: традиции, взаимосвязи. Изд-во КГУ, 2002. 272 с.

2. Галимҗан Ибраһимов: тәрҗемәи хәле, истәлекләр, әсәрләр, анализ үрнәкләре, дәрес эшкәртмәләре, сценарийлар / [фәнни җит. Д.Ф. Заһидуллина; проект авт. һәм төз. Т.Р. Шакирова]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. 199 б.

3. Мингазова Р.А. Проблема женского счастья в раннем творчестве Г. Ибрагимова // Вестник Костромского государственного университета им. Н.А. Некрасова. Т. 14. № 2. С. 127–129.

# Г. ИБРАҺИМОВ ИҖАТЫНДА ИЯРТҮЧЕ ТЕРКӘГЕЧЛӘР

***Кириллова З.Н.***

Данная статья посвящена исследованию подчинительных союзов в произведениях видного писателя, публициста, ученого и общественного деятеля Г. Ибрагимова. В целях создания полноценной картины по использованию союзов были проанализированы произведения и других писателей начала прошлого века. В результате исследования подчинительные союзы были представлены по активности употребления, а в каждой группе были определены особенности их использования.

This article is devoted to a research of subordinating conjunctions in works of the prominent writer, publicist, scientist and public figure G. Ibragimov. For creation of a full-fledged picture on use of the unions have been analysed the work and other writers of the beginning of the last century. As a result of a research subordinating conjunctions have been presented on activity of the use, and in each group features of their use have been defined.

Гомумтөрки истәлекләрдә дә, аерым төрки телләрнең беренче язма чыганакларында да бер-бер артлы тезелеп барган гади җөмләләр өстенлек ала. Алар ярдәмендә тезүле бәйләнеш тә, ияртүле бәйләнеш тә белдерелергә мөмкин була [4, б. 162]. Ләкин тел үсеше дәвамында аерым җөмләләрне тезеп бирү генә барлык мәгънә төсмерләрен бирә алмый башлый. Нәтиҗәдә, төрки телләрдә, бер яктан, иярчен җөмләнең хәбәрен затланышсыз фигыль формалары белән белдерү, икенче яктан, гади һәм кушма җөмләләрдә теркәгеч яки теркәгеч сүзләрне куллану арта бара. Теркәгечләрнең төрки телләрдә урын алуына гарәп һәм фарсы телләренең көчле йогынтысы да этәргеч бирә.

Тюркологлар фикеренчә, борынгы төрки язма истәлекләрдә үк теркәгечләр кулланыла [1, б. 131], IX–XI гасырлардан башлап исә төрки телләрдә гарәп һәм фарсы телләреннән кабул ителгән теркәгечләр зур урын ала башлый [5, б. 505].

Чыгышыбызның максаты – күренекле язучы, галим, публицист, җәмәгать эшлеклесе Г. Ибраһимов иҗатында ияртүче теркәгечләрнең урынын ачыклау. Моның өчен без аның әсәрләренә генә түгел, мәкаләләренә дә мөрәҗәгать иттек. Моннан тыш, шул чор хакында теркәгечләрне куллану үзенчәлекләре ягыннан тулы картина тусын өчен, XX гасыр башында иҗат иткән башка язучыларның әсәрләрен дә файдаландык. Аерым алганда, Г. Ибраһимовтан тыш, З. Һади, Ф. Кәрими, Г. Исхакый, Г. Тукай, Н. Думави, М. Гафури, Ф. Әмирхан, Ш. Камал әсәрләреннән дә мисаллар урын алды.

Билгеле булганча, XX йөз башы татар әдәбиятына 1905–1917 нче еллар арасында иҗат ителгән әсәрләр кертелә. Бу чор татар әдәбиятын монографик планда тикшергән Ф.К. Бәширов исә хронологик чикләрне 1901–1918 еллар белән билгели [2, б. 7]. Безнең тарафтан тикшерелгән язучылар арасыннан З. Һади һәм Ф. Кәрими иҗатлары әлеге бүленешкә туры килә.

Татар милли әдәби теле формалашып җиткән, тел үзенчәлекләре ягыннан гаять зур төрлелеккә ия булган XX гасыр башы татар әдәби телендә һәм шул исәптән Г. Ибраһимов әсәрләрендә ияртүче теркәгечләрнең кулланылыш үзенчәлекләрен тикшерү нигезендә без түбәндәге нәтиҗәләргә килдек:

1. XX гасыр башы татар әдәби телендә иң күп кулланылган ияртүче теркәгеч – хәзерге вакыттагы кебек үк, **чөнки** теркәгече. Аның кулланылышы буенча түбәндәге үзенчәлекләрне күзәтергә мөмкин: 1) әлеге теркәгеч күпчелек очракта яңа җөмлә башында бирелә. Мәсәлән, *Сорашсаң, әллә нинди бер хәл туар кебек булды. Чөнки һичкемгә ышанмыйм. Чөнки бөтен дөньяда мине үз итеп иркәләүче һичкем юк...* (Г. Ибраһимов) *Ник йөри мондый вакытта, ник өендә ятмый ул? Чөнки ул – мескин, ятим ул, ятар урын тапмый ул...* (Н. Думави); 2) чөнки теркәгеченең баш җөмләдән өтер белән аерылган иярчен җөмлә составында килү очракларына да мисаллар шактый күп: *Кем укытырса, бәддога итәрем, чөнки ул ысулы җәдидчеләр, һәр нәрсәне татарчага тәрҗемә итеп, үз телебездә укытмакчы булалар икән* (Ф. Кәрими). *Вәлид хәзрәт чәйне шикәр илә эчмидер, чөнки шикәр үләксә сөягеннән ясала дип, бәгъзе адәмнәрдән ишеткән, үзе дә шикәрне утта яндырып, шикәрдә кан барлыгына күреп, нәҗеслеге илә хөкем иткән* (З. Һади); 3) баш җөмләдән соң килгән иярчен җөмлә чөнки теркәгече белән башланган очракта, аның алдына өтер куелырга тиеш булса да, ике нокта белән бирелгән мисаллар да табылды. Мәсәлән, *Һәм ул табигый дә: чөнки бу көрәш аларның яшәү тамырларына балта чабудыр* (Г. Ибраһимов). *Бераз эчем пошты, күрешкәнемә дә үкенә башладым: чөнки сөйләгән сүзләрем, бәлки, хәзрәткә каты да килгәндер* (Ф. Кәрими); 4) шулай ук Г. Ибраһимовның 1910 елда язылган мәкаләсендә чөнки теркәгеченнән соң ике нокта куелган җөмлә дә урын алган: *Чөнки: милләт үзенең аңлы яшьләренә ничек мөгамәлә кыйла? – дип сөаль куелса, җавап уларак бик кыска рәвештә: сүгә... – димәк лаземдер.*

2. XX гасыр башы татар әдәби телендә, сәбәп мөнәсәбәтен белдерү өчен, чөнки теркәгеченнән тыш, фарсы теленнән кергән **зира** һәм гарәп чыгышлы **мадам ки** теркәгечләре дә кулланыла, әмма аларның саны чагыштырмача күп түгел. Зира теркәгече үзе генә дә, шулай ук ки теркәгече белән дә килә ала. Ләкин без бу теркәгечкә Г. Ибраһимов әсәрләреннән мисаллар таба алмадык. Башка язучылардан мисаллар: *Берлин кебек биек бер пайтәхетнең театросын вә нимсәләрнең кибар галәмен күрмәк арзусы илә бардык. Зира биек шәһәрләрдәге театроларда, вә хосусы илә операда, ул шәһәрнең иң кибар кыйсьме булынаюр* (Ф. Кәрими). *Ләкин, борадәрем, хата итәсез, зира бер нәрсәне белү өчен мотлак үзең кылу лязем түгелдер* (Г. Исхакый).

Шунысы кызык: «чөнки», «әгәр шулай икән» мәгънәләрен белдерүче мадам ки теркәгеченең төрле язучылардагы бирелеше аерыла. Мәсәлән, Г. Ибраһимов мадам ки рәвешендә куллана: *Мадам ки – һәммәгә мәгълүм – шул озын бер мөддәттә, әүвәлән, безгә бер эш эшләмәде, мадам ки, әһлиятле (булдыклы) адәм утырганда байтак эшләр башкарырлык бер биек мәнсабны ишгаль итеп (биләп), эш юлын бикләде, мадам ки, ул азга гына канәгатьләнгән адәмнәр тарафыннан да «менә фәлән кыйлды!» дип әйттерерлек нәрсә күрсәтмәде...* Ф. Кәрими аны мадами ки рәвешендә тәкъдим итә: *Мадами ки, сезгә боны аңлатмак мөмкин улмады. ... Бу җавапның шафи булмаячагын (файдасы тимәсен) кәндемез дә беләюр идек. Мадами ки, анларда – низам уйләдер: анлар, әлбәттә, таләп итәчәкләр һ.б.* Шул ук теркәгечне Ф. Әмирхан мадамә ки буларак куллана: ... *Мәдәнияте юк бер милләтнең промышленносте була алмый, мадамә ки ул юк әле, сыйнфый низагларга да иртә.*

3. Г. Ибраһимов иҗатында һәм, гомумән, ул иҗат иткән чор татар әдәби телендә кулланылыш ешлыгы ягыннан икенче урында торучы ияртүче теркәгеч – иярчен җөмләләрнең барлык мәгънәви төрләрен дә диярлек төзүдә катнашып, күбесенчә стилистик мәгънә белдерү өчен хезмәт итә торган **ки** теркәгече. Әлеге теркәгеч кергән җөмләләр арасында *иярчен ия җөмлә*ле төзелмәләр беренче урында тора. Мәсәлән, *Шунысы шаян дикъкать ки (зур игътибар итәрлек): сәүдә эшләрем, бик аз гына кимчелек илә, әүвәлгечә барачак, тик елында ике мәртәбә, сәүдәнең мөһим вә кызу чагында, ай ярымшар мөддәткә генә өйгә кайтып киләчәкмен, ди* (Г. Ибраһимов). *Мәгълүмдер ки, майның унбишләрендә Петербургта төн аслан булмый диярлектер* (Ф. Кәрими). *Каләм кулда була торып, яшь шагыйрьгә Мәгълүмдер ки, курку белән өркү харам* (Г. Тукай). Күренгәнчә, ки теркәгечле ия җөмләләрнең күбесе мәгълүмдер, аңлашыла (аңлашылды), мәсьәләдер, кызганыч сүзләре белән килә. Кулланылыш ешлыгы буенча икенче урында *иярчен күләм җөмлә*ле төзелмәләр тора, аларның күбесендә ки теркәгече мөнәсәбәтле сүз белән бергә кулланыла. Мәсәлән, *Бу шундый бөек вә гали бер максат ки, моның өчен никадәрле авырлык күтәрелсә, никадәрле корбаннар бирелсә дә күп булмаячак* (Г. Ибраһимов). *Карыйм-карыйм да шул дәрәҗәгә җитәм, әткәйгә шул дәрәҗәдә охшатам ки, һушымнан язып: «Әткәй, синме?» – дип кычкырып кочаклаудан үземне чак тыеп калам* (Г. Ибраһимов). *Голамабызның хәлен күреп, шул дәрәҗәдә эчем пошты, күңелем нечкәрде ки, аулакта булсам, һичшиксез, җылаган булыр идем* (Ф. Кәрими). *Бу уйлар мине шулкадәр ваттылар ки, мин таң атмыйча йокыга китә алмадым* (Ф. Әмирхан). *Бу семья эчендә фәкыйрьлек шул дәрәҗәгә җиткән булырга кирәк ки, мин, хәзер дә булса бабайның күрше баерак авыллардан икмәк сыныклары теләнеп алып кайтканын исемдә тотамын* (Г. Тукай). Ки теркәгече кулланылган җөмләләрнең өченче мәгънәви төре – *иярчен тәмамлык җөмләләр*. Мәсәлән, *Белмидер ки, тәкъдирнең каләме адәм үзе улып, тәкъдирне язып йөрегәнен* (З. Һади). *Мин өмит иткән идем ки: татлы бер мосахәбә (сөйләшү) булсын, хәзрәт безгә дөньябыз, ахирәтебез өчен шәригатьтән вә мәгыйшәттән нәсихәтләр вә вәгазьләр бирер, вә хикмәтле-хикмәтле сүзләр сөйләр дип* (Ф. Кәрими).

Ки теркәгече шулай ук архаиклашкан шөйлә (шулай) сүзе белән килеп, шул рәвешчә мәгънәсен дә белдерә: *...шөйлә ки, алар үзләренең теләгән сүзләрен музыка илә әйтә алалар* (Г. Ибраһимов).

Ки ияртүче теркәгече һәрвакыт баш җөмлә составында килсә дә, Г. Ибраһимовтан табылган бер мисалда ул иярчен вакыт җөмләдә урын ала: *Качан ки халык күтәрелде, качан ки ач-ялангач, изелгән халык, кызыл байраклар белән урамга чыгып, полициянең туп вә мылтыкларына каршы* «*Икмәк! Ирек!*» *дип кычкырып каршы барды, качан Петроград урамнары кан белән, шәһит каһарманнар гәүдәсе белән тулды – шуннан соң гына ирек бирелде, тик шул каннар, шул корбаннар гына тәхетне җимереп, аның тирәсенә сыенучыларны үзләре хәзерләгән зинданнарга тутыра алды.*

4. Традиция буенча аналитик чара итеп каралса да, хәзерге вакытта синтетик иярчен шарт җөмлә эчендә тикшерелә торган **әгәр** теркәгече XX гасыр башында шулай ук шактый зур урын ала. Әлеге теркәгеч иярчен җөмләдә күбесенчә шарт фигыль кушымчасы, сирәк кенә исә (ирсә) сүзе белән бергә кулланыла; әгәр, гәр, әгәр дә формаларында килә ала.

Мәсәлән, *Әгәр дә бу рәвешчә даимән иганә кыйлсалар, башка шәһәр байларына гыйбрәт ула белерләр* (Г. Ибраһимов). *Әгәр милләтегезгә аз гына шәфкать вә мәрхәмәтең бар исә, шул вакытларда анларны тугры юлга күндер* (Ф. Кәрими). *Бала анадан туар инсан улып, әгәр дә инсан тәрбиясе бирелмәс исә, калыр хайван улып* (З. Һади). *Әгәр шул мәдрәсәнең исемене былчыратучылардан үч алу фикере булмаса иде, һич керә алмый идем* (Г. Исхакый). *Әгәр кушсаңыз, баш өсте, ни әйтсәңез, шуны кабул күрәм, итәм* (Ш. Камал).

5. Г. Ибраһимов, шулай ук Ф. Кәрими әсәрләрендә «әгәр дә» мәгънәсен белдерә торган **кашки / кяшки** теркәгечле берничә җөмлә табылды. Мәсәлән, *Кашки берничә ел русча укысам, һич булмаса, язучы яки учитель булып, һәм халыкка, һәм үземә хезмәт итәр идем* (Г. Ибраһимов). ... *Кашки мөмкин булып та бер ханәкага (суфилар, дәрвишләрнең тору урыны) бикләнсәм, җаным тынырдай тоела* (Г. Ибраһимов). *Бәгъзесе өчен сөенәсең, кяшки шуның кебек вакытлар тагын килсә иде дип, буш җирдә өмидләрдә булынасың* (Ф. Кәрими).

6. Әгәр сүзеннән ясалган **гәрчә** ияртүче теркәгече [6, б. 351] кире шарт мәгънәсен белдерү өчен хезмәт итә. Узган гасыр башы әдәби телендә ул күбесенчә шарт фигыль кушымчасы яки исә (ирсә) сүзе һәм да/дә кисәкчәсе белән бергә кулланыла: *Әүвәлге хәят – гәрчә кайгылы булса да, аның кайгыларында да бер ләззәт, бер дәрт бар, истикъбальне (киләчәк) уйлау бик зур җуаныч төсле була иде* (Г. Ибраһимов). *Гәрчә депутатның йортында бер хатыны вә ике-өч баласы бар иде исә дә, яше кырыклар чамасында гына булдыгыннан, икенче хатын алырга әүвәлдән үк нияте бар иде* (Ф. Кәрими). *Гәрчә соңыннан Фәхретдин хәзрәтнең указы кайтса да, фәкать Җиһанша хәзрәткә иптәш мулла булды* (З. Һади). Кайбер мисалларда гәрчә теркәгече аерымланган кире хәл ясау өчен хезмәт итә: *Табигать тарафыннан бирелмеш зиһен вә башка куәи мәгънәвияләр (мәгънәви куәт, сәләт), гәрчә чамадан артык булмаса да, бик түбән түгел иде* (Г. Ибраһимов). *Ул, гәрчә башкаларны катыштырмыйча, үзем шулай, үземнең хәлем менә шул дип, үзенә генә карап сөйләсә дә, вакыйгъдә (чынында) ул сүзләрне һәр татар шәкерте сәгать саен, минут саен сөйли* (Г. Ибраһимов). *Гәрчә анда тугъмасам да, мин бераз торган идем, Җирне әз-мәз тырмалап, чәчкән идем, урган идем* (Г. Тукай).

7. Хәзерге язма әдәби телдә актив кулланыла торган **гүя** теркәгече баш җөмләдән аңлашылган эш-хәлнең үтәлү рәвешен чагыштыру юлы белән белдерә. XX гасыр башында да әлеге теркәгеч кушма җөмлә компонентларын гына түгел, ә җөмлә кисәкләрен бәйләү өчен дә кулланыла, ки теркәгече белән бергә дә килә ала. Мәсәлән, *Мин, гүя, аның шул әйләнүенә сихерләнеп, гомернең кая барганын, уйнауның, балалыкның ни икәнлеген белми яшим* (Г. Ибраһимов). *Бу кыз күренгәч, гүя томан күтәрелде* (З. Һади).

8. Хәзерге вакытта ияртүче теркәгеч, теркәгеч сүз яки аныклаучы теркәгечкә керүләре тулысынча хәл ителмәгән **хәтта, аеруча, ягъни, мәсәлән** теркәгечләре XX йөз башында да актив кулланылышта булалар һәм я аныклагыч җөмлә кисәген, я аныклагыч җөмләне формалаштыруда катнашалар: *Аның өст-башы, чәч, мыегы вә гадәте тәмамән руснықы төсле булып, бу хәле күп кешеләр тарафыннан аның чын мөселман булуында шик кыйлырга сәбәп булмакта, хәтта кайбер вакыт «чукынган имеш» хәбәрләре дә*

*чыкмакта исә дә, ул вакыйгдә, чын ихласлы бер мөэмин иде* (Г. Ибраһимов). *Бер караганда, апа, Мәрфуга апа, әни, абый, хәтта теге кунак кызлары да мине җәбер иткәннәр шикелле тоелалар, икенче караганда, мин үзем болай сугыша башлап начар эшләгәнмен шикелле тоела* (Ф. Әмирхан). *Фазыл әфәнде шатланып китте. Хәтта үзе сизмәенчә дә урыныннан селкенеп тә куйды* (Г. Исхакый). Бары Ф. Кәримидә генә хәтта ролендә килгән **вә лү** теркәгече табылды: *Белмәгән бер шәһәргә барылдыгы вакыт, вә лү аз да булсын, әүвәлдән беркадәр мәгълүмат алмак иҗап ителер (соралыр. – З.К.)* (Ф. Кәрими).

9. Узган гасыр башында хәзерге әдәби телдәге аеруча, аерым алганда, бигрәк тә теркәгечләре мәгънәсен белдерә торган **хосусән, ба хосус, ба хосус ки, хосусы илә ки, бәлхассән** теркәгечләре кулланылышта йөри. Алар арасында хосусән барлык язучылар иҗатында да урын ала, соңгыларына мисалларның күбесе исә Ф. Кәримидә генә күзәтелде. Мәсәлән, *Гәзитәләремезне мөрәттәб (тәртипле рәвештә – З.К.) укып барган кеше бу нәүгъ (төр – З.К.) мәгънәсезлекләргә еш-еш очрар. Хосусән, «Вакыт»ның бу хакта кыйлган юмартлыгын күреп, тәгаҗҗеб вә хәйрәттән (гаҗәпләнү һәм хәйран калудан – З.К.) үзене тыя алмас* (Г. Ибраһимов). *Безнең хатибымыз үзенең озын вә шактый тәртипсез ачы сүзләр белән вә шул җөмләдән хосусән бабаның (И. Гаспринский – З.К.) үзенә дә тәүҗиһ ителгән (юнәлтелгән) ихтирамсызлыклар белән тулы нотыкын тәмам иткәч инде...* (Ф. Әмирхан). *Ба хосус, бу вакытларда, яңа ашлык өлгермәс борын, бичаралар ачлыктан үләр чиккә җиткән булалар* (Ф. Кәрими). *Хосусы илә ки, без, шимди, Алманиягә барыюрбыз, ләкин кәндемез немесчә белмәюрбез* (Ф. Кәрими). *... Мостафа Нури әфәнде намында бере бәңа кәнденең рәсмен һәдия итте. Боңа бәлхассән тәшәккер итәрәм* (Ф. Кәрими).

Йомгаклап әйткәндә, Г. Ибраһимов иҗатында һәм, гомумән, XX гасыр башы татар әдәби телендә ияртүче теркәгечле җөмләләр шактый күп кулланылган. Хәзерге әдәби телдә дә актив булган теркәгечләр – әгәр, гүя, чөнки, ягъни, мәсәлән, хәтта һ.б. белән беррәттән, гарәп яки фарсы чыгышлы мадам ки, зира, вә лү, хосусән, ба хосус, ба хосус ки, хосусы илә ки, бәлхассән кебек теркәгечләрнең дә урын алуы тикшерелгән чорда, бер яктан, халыкчан тел формалашу процессы баруны күрсәтә, икенче яктан, госманлы төрек, гарәп һәм фарсы теле элементларының да саклануы һәм көчле йогынтысы белән аңлатыла.

ӘДӘБИЯТ


1. Абдурахманов Г.А. Исследование по старотюркскому синтаксису (XI век). М.: Наука, 1967. 210 с.

2. Бәширов Ф.К. XX йөз башы татар прозасы. Казан: Фикер, 2002. 287 б.

3. Гаджиева Н.З. Основные пути развития синтаксической структуры тюркских языков. М.: Наука, 1973. 408 с.

4. Гаджиева Н.З., Серебренников Б.А. Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Синтаксис. М.: Наука, 1986. 284 с.

5. Закиев М.З. Татарская грамматика. Т. III. Синтаксис. Казань: Татар. кн. изд-во, 1995. 576 с.

# ЛИТЕРАТУРНАЯ И ОБЩЕСТВЕННАЯ ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ ГАЛИМДЖАНА ИБРАГИМОВА СКВОЗЬ ПРИЗМУ СОВРЕМЕННОСТИ

***Куртсеитов Р.Д.***

В статье рассматриваются литературная и общественная деятельность Галимджана Ибрагимова, его влияние на развитие литературы и духовной культуры тюркских народов, в том числе крымскотатарского, органическая духовная связь с Крымом и представителями крымскотатарской литературы. Делается попытка осмысления содержания его последнего крымского периода жизни, сложных общественно-политических процессов того времени, системность репрессий и разрушительные их последствия.

The article examines the literary and public activities of Galimdzhan Ibragimov, his influence on the development of literature and spiritual culture of the Turkic peoples, including the Crimean Tatars; organic spiritual connection with the Crimea and the representatives of the Crimean Tatar literature. An attempt is made to comprehend the content of his last Crimean period of life, the complex social and political processes of that time, the systemic nature of repressions and their destructive consequences.

Величие писателя, поэта, общественного деятеля определяет время. Юбилейные даты приходят и уходят, их будет много, пока существует народ, который чтит своего славного сына. Деяния великих, без преувеличения, людей, к которым относится Галимджан Ибрагимов, принадлежат не только татарскому народу, но и близким по своему этническому происхождению и исторической судьбе народам, вовлеченным в единый круговорот истории. Границы его внутреннего мира превзошли многие внешние границы этнических образований и государств.

Всю свою относительно недолгую жизнь, длиной в полвека, он созидал, писал, организовывал, руководил. Ему было уготовано судьбой прожить ее на стыке двух веков, двух политических измерений, заката Российской империи и зарождения советской эпохи. Все это отразилось, несомненно, в судьбе этой неординарной личности. Этнокультурный мир Г. Ибрагимова был настолько широк, что позволял ему понять, прочувствовать, интегрироваться в культуры многих народов и отразить их в своих литературных произведениях.

Он погружался в инокультурную среду, чтобы разглядеть и прочувствовать внутренние социальные механизмы функционирования этноса, то есть увидеть народ изнутри со всеми его проблемами и возможностями. Еще задолго до установления советской власти с ее пропагандируемым официальным интернационализмом Г. Ибрагимов длительное время в силу своих литературных и общественно-политических интересов окунается в жизнь национальных окраин огромной страны, причем, в самую гущу.Работая школьным учителем в казахской степи, изучает быт, народный уклад, совершенствует знания родственного тюркского языка. Пишет свой роман «Казакъ кызы» («Дочь степи»). Педагогическая деятельность позволяет ему лучше познать духовный мир различных народов. Работает учителем на Кавказе, где пестрота этнических культур и языков намного превышает многообразие родного Поволжья.

Что побуждает Галимджана Ибрагимова открывать новые и новые этнические горизонты? Прежде всего, любовь к своему народу: человек, находясь на чужбине, живет с мыслью о Родине, о родной земле, о своем народе. Общеизвестно, что для того чтобы стать интернационалистом, прежде всего необходимо стать немного националистом – патриотом.

Эта деятельность позволяет ему пройти своеобразную жизненную школу наподобие «моих университетов» А.М. Горького. По мнению литературоведов, он в чем-то похож на него, и эта схожесть, видимо, закономерна. А.М. Горький провел часть своей жизни в Крыму, в крымскотатарской среде, и оставил свои произведения, связанные с жизнью коренного народа. А.М. Горького, как никого другого, крымские татары считают своим по духу поэтом и писателем. В дореволюционный и особенно в послереволюционный период, он часто встречался с крымскотатарскими литераторами на даче «Теселли» в Форосе.

Г. Ибрагимов в сорокалетнем возрасте вынужден был поселиться в Крыму, а вернее в Крымской АССР в г. Ялте. В Ялтинском районе до тотального выселения по национальному признаку в 1944 г. в структуре населения коренное население составляло более 80%, в селах сохранялись традиционный уклад жизни, этническая культура, которые привлекали внимание многих писателей, ученых и, вообще, творческих личностей.

Казалось бы, Г. Ибрагимов в последние десять лет своей жизни, обладая величайшим талантом, жизненным и общественно-политическим опытом, мог обогатить свое литературное наследие и значительной крымской тематикой. Однако тяжелая болезнь донимала его, общественно-политическая ситуация в стране и, в частности, в Крыму, не позволяла ему как бывшему члену оппозиционной большевикам эсеровской партии чувствовать себя спокойно. Волны террора на полуострове шли один за другим. Белый террор сменился красным. С окончательным установлением советской власти они изменили только свою форму. На второй год пребывания Г. Ибрагимова в Крыму разворачивается громкий политический процесс, инициированный Сталиным, – «Дело Вели Ибраимова». Жертвой тоталитарной системы становится не только председатель КрымЦИКа Вели Ибраимов и целая когорта его коммунистических соратников, но и видные общественно-политические деятели, связанные с «Милли Фирка», в том числе литераторы и ученые. В 1928 году в жернова репрессий попадает поэт Амди Герайбай. Двадцативосьмилетнего классика крымскотатарской поэзии помещают в Бутырскую тюрьму, где он умирает до суда. Многие видные деятели крымскотатарской интеллигенции, ученые в это время вынуждены покидать родную землю, среди них поэт, ученый-тюрколог с мировым именем Бекир Чобан-заде, впоследствии репрессированный [1].

Общественно-политическая обстановка в Крыму, где любая известная или даже малоизвестная личность могла быть обвинена в любом или во многих «…измах», не способствовала творческой деятельности. Причем, чем выше и значимей была личность тем уязвимей и беззащитной она была.

«Наиболее ранние сведения о Галимджане Ибрагимове в крымскотатарской прессе относятся к дореволюционному периоду. Так, в газете «Терджиман» («Переводчик»), издававшейся Исмаилом Гаспринским, 21 февраля 1913 года сообщается о том, что увидел свет роман Г. Ибрагимова «Молодые сердца» («Яш юреклер»). Книга издана добротно, пишется в заметке,

имеет объем в 400 страниц, стоимость книги составляет 1 рубль 30 копеек. О самом авторе сказаны весьма лестные слова в том смысле, что Г. Ибрагимов отличается изысканностью пера, ясностью изложения и занимает одно из ведущих мест среди тюркоязычных писателей России», – пишет известный крымскотатарский литературовед профессор Исмаил Керимов [2].

Другой известный крымскотатарский ученый-литературовед Керим Джаманаклы, который всю свою послевоенную часть жизни посвятил научно-преподавательской деятельности в Татарской АССР, работал в Елабужском педагогическом институте, приводит имена известных деятелей культуры крымскотатарского народа, которые учились в медресе «Галия» в Уфе и слушали лекции Галимджана Ибрагимова в 1915–1916 гг. Среди них будущий известный драматург Умер Ипчи, поэт Абдулла Лятиф-заде, Якуб Мусанниф и др. К. Джаманаклы был одним из первых ученых-литературоведов, защитивших диссертационное исследование по крымскотатарскому фольклору в довоенном Крыму. У. Ипчи, А. Лятиф-заде, Я. Мусанниф, как и многие другие стали, жертвами политических репрессий. Наиболее трагической стала «кровавая ночь» 17 апреля 1938 года, когда в одну ночь в г. Симферополе был уничтожен весь цвет крымскотатарской интеллигенции [3].

Трагическая судьба и творческая деятельность драматурга У. Ипчи стали предметом отдельного диссертационного исследования Исмаила Керимова, еще до массового возвращения репрессированного крымскотатарского народа в Крым.

Влияние Галимджана Ибрагимова на молодое поколение крымских литераторов, и их знакомство с татарской литературой, по свидетельству И. Керимова, отмечал Нарком просвещения Крымской АССР Рамазан Александрович [4].

Народный комиссар просвещения Р. Александрович в 1937 г. будет снят с занимаемой должности и расстрелян в «кровавую ночь» в апреле 1938 года.

В годы «большого террора» избежать репрессий таким личностям, как Г. Ибрагимов, было просто невозможно. Один ведущих историков, крупный специалист по советскому периоду истории Татарстана профессор Индус Тагиров говорит в одном из предъюбилейных интервью о том, что даже тяжело больной Галимджан Ибрагимов, который не мог самостоятельно передвигаться, находился под неусыпным контролем НКВД, буквально каждый вздох его фиксировался.

Библиографы отмечают, что с 1918 по 1936 годы было осуществлено 54 издания его работ на многих языках народов СССР. Спектр его научных интересов был очень широк: от литературно-художественных произведений до лингвистических и литературоведческих работ. Ему принадлежат «Морфология татарского языка», «Синтаксис татарского языка», «Теория литературы» и многие другие работы.

Десять лет крымской жизни были наименее плодотворными. Это можно проследить по хронологии написания и издания работ. Интерес к личности Г. Ибрагимова в Крыму был высок, здесь отмечают его сорокалетие и публикуют информацию об этом мероприятии.

По данным профессора И. Керимова, в начале 1932 года главный редактор крымскотатарского журнала «Большевик ёлу» Якуб Мусанниф (Айсерезли) направил Г. Ибрагимову в Ялту письмо, в котором просил писателя прислать что-нибудь для публикации в альманахе, посвященном 15-летию

Октябрьской революции. В ответном послании, написанном 21 апреля 1932 года, Г. Ибрагимов сообщает следующее: «Дорогой товарищ Мусаниф. К сожалению, в данный момент не имею под рукой что-то готовое и не могу написать что-либо для вашего альманаха в спешке. Но я надеюсь дать материал для будущих выпусков альманаха. Вы знаете, что вот уже 5-й год я нахожусь на лечении в Ялте. Моя мучительная болезнь не дает мне возможности участвовать в общественной жизни Крыма. Но в последнее время мое здоровье идет на поправку и мне удается понемногу знакомиться с Крымским фронтом революции. До этого я участвовал на Казанском фронте партийного дела. Кроме того, издал рассказ «Башкъырт къызы Гюльбике» и другие зарисовки, посвященные башкирской жизни. Из быта Казахстана мной опубликован роман «Къазакъ къызы». Теперь же, если мне позволит здоровье, я надеюсь написать произведение, посвященное революционной борьбе крымских масс и их общественной жизни. Я очень сильно полюбил Крым. Он стал для меня новой литературной родиной, самой красивой, самой значительной на свете, возбуждающей во мне наиболее глубинные и неистовые чувства. Эти чувства побуждают меня взяться за перо и писать о Крыме. По мере выздоровления, буду стремиться, чтобы задуманное мною увидело свет. Буду стараться исполнить свой долг на литературно-научном фронте Крыма. Те материалы, которые я задумал послать в ваш альманах, связаны с этими надеждами» [2].

Произведений, посвященных революционной деятельности крымских масс, пока не найдено, возможно, он просто не успел их написать, учитывая политическую атмосферу того времени в Крымской АССР и СССР, его физическое состояние в целом. В истории нет сослагательного наклонения. Если бы…???

В Крым приезжали многие поэты и писатели, каждый из них оставил свои произведения, посвященные этой земле и его народу, среди них А.С. Пушкин, Л.Н. Толстой, А.П. Чехов, А.М. Горький, М. Волошин и многие другие, кто-то из них прожил здесь несколько дней, а кто-то годы.

Галимджан Ибрагимов не имел возможности писать о Крыме, за исключением статьи о крымскотатарском театре [5], но он был учителем, у которого здесь были благодарные ученики, которые слушали его лекции и выступления еще в медресе «Галия», формировались как личности и внесли значительный вклад в развитие крымскотатарской литературы и культуры. Деятельность Галимджана Ибрагимова, связанная с Крымом, еще недостаточно исследована. Его работа на первом съезде по переводу алфавитов тюркских народов на латиницу в 1926 году может пролить свет на возможные контакты с профессором Б. Чобан-заде и другими известными реформаторами письменности тюркских народов.

В тот период национально-государственного и культурного строительства в молодых национальных автономиях РСФСР контакты и сотрудничество самых передовых государственных и общественных деятелей были регулярными, учитывая работу Г. Ибрагимова в мусульманской комиссии при Наркомнаце СССР и последующей его деятельности.

Галимджан Ибрагимов как выдающаяся личность, известный литератор, общественно-политический деятель, оставил после себя огромное интеллектуальное наследие, которое необходимо использовать во благо созидания. Использование опыта решения языковых, образовательных проблем

в 20–30-х гг. прошлого века в наших республиках и современного опыта Республики Татарстан позволили бы более эффективно их решать на современном этапе развития.

ЛИТЕРАТУРА

1. Урсу Д.П. Чобан-заде: Жизнь. Судьба. Эпоха: научное издание. 2-е изд. Симферополь: Крымучпедгиз, 2013. 276 с.

2. Керимов И.А. Крымскотатарская довоенная пресса о Галимджане Ибрагимове // Научный бюллетень: орган науч.-исслед. центра «Рукописная книга» при каф. крымскотатар. и тур. лит. КИПУ. 2008. № 13. С. 2–4.

3. Урсу Д.П. Очерки истории культуры крымскотатарского народа (1921–1941 гг.) / Д.П. Урсу. Симферополь: Крымское учебно-педагогическое государственное издательство, 1999. 144 с.

4. Александрович Р.У. Инпчи аркъадашнынъ 20-йыллыкъ эдебий фаалиетининъ юбилейи / Рамазан Александрович // Енъи дюнья. 1936. 16 июль.

5. Ибрахимов Г. Мектюп / Г. Ибрахимов // Большевик ёлу. 1932. № 6–7. С. 41.

## ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ: ШӘХЕСЕ ҺӘМ ТРАДИЦИЯЛӘР ХАКЫНДА УЙЛАНУЛАР

***Минһаҗева Л.И.***

Галимджан Ибрагимов был вдохновителем и отправным толчком в начале творческого пути у многих молодых авторов. Ибрагим Салахов был один из тех писателей. Жизнь и творческий путь И. Салахова полны сложностей, противоречий и драматических эпизодов. В то же время, позже, его сложная биография стала иметь большое влияние на его произведения. Получивший известность еще в студенческие годы, благодоря своим произведениям, молодой и перспективный писатель в 1937 году становится жертвой культа личности И. Сталина, лишается на десять лет свободы и на пять лет гражданских прав.

Galimdzhan Ibragimov was the inspiration and starting impetus for many young authors at the beginning of their creative path. Ibrahim Salakhov was one of those writers. The life and creative path of I. Salakhov are full of complexities, contradictions and dramatic episodes. At the same time, later, his complex biography had a great influence on his works. A young and promising writer, already known for his works in his student years, in 1937 became a victim of the personality cult of Stalin. He was imprisoned for ten years and deprived of civil rights for five years.

Татар әдәбиятының күпгасырлык үткән юлы, билгеле бер дәрәҗәдә өйрәнелгән тарихы бар. Әмма, җәмгыять тормышында бара торган тирән үзгәрешләр йогынтысында, бу тарихны яңартып өйрәнү һәм яктырту ихтыяҗы һәрдаим туа тора. Чөнки әлеге тарихта онытылган яки тыелган яңадан-яңа исемнәр, өйрәнелмәгән яисә бик аз өйрәнелгән әсәрләр барлыгы ачыклана. Шундыйлар арасында, соңарып булса да әдәбият тарихында үз урынын тапкан талантларның берсе, Ибраһим Салахов исеме дә бар.

Әдипкә игътибар арту аның «Колыма хикәяләре» әсәре басылып чыгу белән бәйләнгән иде. Әлеге әсәрнең язылу сәбәбе һәм тарихы гына түгел, бәлки, И. Салаховның анда чагылган гыйбрәтле язмышы да байтак дәрәҗәдә Галимҗан Ибраһимовка барып тоташа. Эш шунда, 1937 елда яшь язучы И. Салахов тормышының көтелмәгән якка үзгәреп китүе Г. Ибраһимов исеме

белән бәйләнә. Авторның «Колыма хикәяләре» романыннан, истәлекләреннән һәм «күп кенә каләмдәшлернең истәлек язмалары»ннан [2, б. 13] күренгәнчә, шәхес культы еллары башлангач, ул Г. Ибраһимов белән К. Нәҗми арасында элемтәче булуда гаепләнә. Нәтиҗәдә, суд карары нигезендә, ун елга ирегеннән һәм биш елга гражданлык хокукларыннан мәхрүм ителә.

Шул ук вакытта И. Салаховның әдәбиятка ныклап юл алуы да Г. Ибраһимов белән бәйләнгән була. Бу олы әдип әсәрләре белән ул Кукчәтау җидееллык татар мәктәбендә укыган елларында ук таныша башлый. Мондый танышлыкның ничек башлануын Ибраһимов әсәрләрен укырга яраткан, «китап жене кагылган» бабасы белән бәйләп, Г. Ибраһимовның 80 еллык юбилее уңаеннан язылган «Еллар сәхифәсе» дигән истәлегендә ул түбәндәгечә искә ала: «...кичләрнең берсендә миңа Г. Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» повестен укырга туры килде. Барыбызга да бик ошады. Моңа кадәр бабай нинди китап туры килсә, шуны алып кайта иде. Ә менә «Татар хатыны ниләр күрми»не укыгач Күкчәтау буенча йөреп, Г. Ибраһимов китабын гына эзләде» [6, б. 14]. Шушы елларда автор бабасы тарафыннан Казаннан кайтарылган «Казакъ кызы», «Безнең көннәр», «Кызыл чәчәкләр» әсәрләре белән дә танышуын яза.

«Казакъ кызы» романын укыганнан соң И. Салаховның бабасы әйткән сүзләр әлеге әсәргә генә түгел, гомумән, Г. Ибраһимовның язучылык талантынада  югары бәя булып тора: «Бирсә дә бирә икән Ходай кешегә башны. Мин инде утыз ел торам казах илендә. Җәйләвеннән, кышлавыннан кайтмыйм. Ә менә рәтләп күз салмаганмын. Хәзер яңа күргәндәй булып утырам» [6, б. 14].

Чыннан да, «Казакъ кызы»нда Г. Ибраһимов узган гасырларда казах даласында башланган иҗтимагый-социаль үзгәрешләрне, катлаулы тормыш панорамасын, хатын-кызның рухи азатлыкка омтылышын тасвирлау белән бергә, дала табигатен, аның матурлыгын күрсәтүгә дә шактый зур урын бирә. Биредә әдипнең әдәби осталыгы төрле яктан – сюжет һәм композиция төзүдә, геройларның эчке дөньясын ачуда, табигать күренешләрен тасвирлауда, мавыктыргыч телендә дә ачыла. Нәкъ менә шулар, яшь Ибраһимга, аның бабасына, һәм гомумән, Салаховлар гаиләсенә нык тәэсир итә дә инде.

Алга таба, шул ук истәлегендә И. Салахов Н. Арсланов табып биргән «Алмачуар» хикәясен кызыксынып укуы, икенче көнне үзенең дә беренче тапкыр казах авылында күргән ат бәйгесе турында хикәя язып каравы, Н. Арслановның аны мактавы турында әйтеп уза. «Г. Ибраһимов белән танышуым шулай башланды, – дип дәвам итә автор. – Матур әдәбиятның беренче онытылмас ләззәтен мин аның әсәрләре аша татыдым, сихерләндем, һәм шул тылсымлы дөньяга атларга, кулыма каләм алырга җөрьәт иттем, канатландым. Акыл көче белән ныгытылмаган алсу өметләр генә иде әле бу. Әмма ничек кенә булмасын, бу өмет омтылышны Галимҗан аганың гүзәл, музыкаль әсәрләре уятты, һәм әдәбият мәйданына чыгарга өндәде» [6, б. 15]. Димәк, И. Салаховның язучылык эше белән шөгыльләнә башлавы ук Ибраһимовның әсәрләре тәэсире белән бәйләнгән булып чыга.

Әдәби иҗатка килү юлын чагылдырган «Беренче адымнар» истәлегендә дә автор Күкчәтау җидееллык татар мәктәбенә Г. Ибраһимовның кырык еллык юбилее уңаеннан аның исемен бирү тантанасы турында дулкынланып яза. Биредә И. Салаховны яшь Ибраһимовның гүзәл әсәрләре генә түгел,

бәлки «кабарып торган чәч, киң маңгай, уйчан күзләр, калку күкрәк, мәһабәт сынлы әдипне» гәүдәләндергән портреты да сокландыра [7, б. 28].

Алга таба Ялтада Г. Ибраһимов белән турыдан-туры очрашудан соң И. Салахов озак вакытлар әдип образы белән рухланып яши. Бу очрашудан алган тәэсирләре аның «Колыма хикәяләре»ндә ачык чагыла. Автор Г. Ибраһимовның кешелек сыйфатларын, тышкы кыяфәтен, ул яшәгән шартларны күрсәтүгә аеруча дикъкать итә. Әдипне гади, тыйнак шәхес буларак чагылдыра. Яшь язучылардан мәдхия хаты алган Г. Ибраһимов үзенең «бөек түгел», бары эшче каләм – иҗат кешесе булуын искәртүенә дә басым ясый. (И. Салаховның «Колыма хикәяләре» романында әйтелгәнчә, әлеге хатка кул куйган яшь язучылар. «Кызыл Татарстан» газетасы хезмәткәрләре Галимҗан Мөхәммәтшин, Ләбиб Гыйльми, Касыйм Шәйхетдинов, Сөббух Рафиков һ.б. 1937 елда кулга алыналар [5, б. 18].

Г. Ибраһимов турындагы икенче бер истәлегендә И. Салахов авыру хәлендә дә әдипнең тулы канлы, җанлы тормыш белән яшәвен күрсәтә: шул хәлендә дә ул Казанда басылган барлык китаплардан, газета-журналлардан хәбәрдар. Әдәбиятка яңа килгән яшьләр, аларның әсәрләре белән кызыксына.

И. Салаховны бер үпкә белән яшәгән авыру әдипнең үзен жәлләмичә, ару-талуны белмичә көннәр буе әсәрләре өстендә эшләве, аларны кабат-кабат күчерүе таң калдыра. «Адаш» дип эндәшүе исә И. Салаховның иҗат эшенә дәрт өсти.

Тәнкыйтьчеләр татар халкының милли һәм социаль азатлыкка, яңа тормышка омтылыш юлында алдану-фаҗигаләрен Г. Ибраһимов «әсәрләрендә гаять тулы һәм тирән, бөтен катлаулылыгы һәм каршылыклары белән чагылдырды» [3, б. 7; 9, б. 9] дип, әдипнең хакыйкатне ничек бар шулай гәүдәләндерүенә басым ясыйлар. Өлкән әдипнең шушы сыйфатлары алга таба И. Салахов өчен үзенә бер иҗат үрнәгенә әверелә.

Кече яшьтән үк Г. Ибраһимовның шушындый әсәрләрен укып үскән И. Салахов бигрәк тә реабилитациядән соңгы иҗатында Г. Ибраһимовның әлеге үрнәгенә, шушы юнәлешенә ияреп тормыш хакыйкатен ничек бар – шулай укучыларга җиткерергә омтыла. Аның бу омтылышы шәхес культы елларын чагылдыруда аеруча ачык күренә. Бу теманы ул башлап 1965 елда басылып чыккан «Күкчәтау далаларында» романында яктыртты һәм анда байтак дәрәҗәдә үзенең шәхси биографиясенә таянды.

Роман жанрындагы беренче тәҗрибәсе булган «Күкчәтау далаларында» да әсирлектә вакытта сак эш итәргә, алдын-артын карап фикер йөртергә өйрәнгән әдип хикәяләүне ике планда алып бара: беренче планда рәсми идеология рухына туры килгән чирәм җирләрне үзләштерүне яктыртырга алына һәм бу эш әсәр эчтәлегенең күзгә бәрелеп торган өске катламын тәшкил итә. Шул ук вакытта, шушы рәсми идеологиягә лояль битлек астында автор, үзенең шәхес культы елларында күргән-кичергәннәренә нигезләнеп, совет системасының гаделсез якларына да игътибар итә һәм бу хакта хикәяләү әсәр эчтәлегенең икенче катламын хасил итә. Әлбәттә, язучының үзенә менә шушы икенчесе якынрак һәм мөһимрәк. Романның вакыт сынавын үтә ала торган кыйммәте дә шушы катлам белән бәйләнгән.

Шулай итеп, әсәрнең икенче катламы Сәет Батталовның шәхес культы елларында катлаулы һәм авыр язмышын чагылдыруга корылган. Шул ук вакытта герой язмышы романда шактый киң иҗтимагый яңгыраш та ала. Чөнки бу язмыш тоталитар режимны үзенә бер гаепләү акты булып

яңгырый, һәм шушы ук яңгыраш, инде шактый ук киң урынны биләп, авторның «Колыма хикәяләре» әсәрендә дәвам игтерелә.

«Колыма хикәяләре» басылып чыкканнан соң әсәрнең сәнгатьлелеген, жанрын, телен, образлар системасын төрле яклап анализлаган Тәлгать Галиуллин, Фоат Галимуллин, Фәрваз Миңнуллин, Рафаэль Мостафин һ.б. әдәбият белгечләренең мәкаләләре дөнья күрде, һәм гомумән, тәнкыйть әсәрне «шәхес культы корбаннарына куелган һәйкәл» дип бәяләде, һәм бу бәядә хаклык бар. Чөнки «Тарихыбызда 1930–1937 еллар татар интеллигенциясе өчен зур сынау вакыты буларак билгеле» [1, б. 19]. Аның язылу максаты да бит авторның төрмә-лагерь юлларында очрашкан дусларының исемнәрен аклау, аларны халыкка кире кайтару, «меңләгән, йөз меңләгән хаксыз һәлак булган революция фидакарьләренең фаҗигасен күрсәтү» белән бәйләнгән [4, б. 14].

И. Салахов бер истәлегендә Г. Ибраһимовның үзенә тәэсирен бәяләп, түбәндәгечә язды: «Бу очрашулар (Ялтада әдип белән очрашулар) миңа иҗат хезмәтемнең серле ишекләрен ачты, армый-талмый эшләргә, укырга, өйрәнергә, өйрәнергә, өйрәнергә кирәклеген төшендерде» [8, б. 3]. Димәк, Г. Ибраһимов әсәрләрен уку, аның белән очрашу, аралашу И. Салаховның үз иҗатына да нык тәэсир иткән, һәм алда карап үтелгән «Күкчәтау далаларында», авторны Тукай премиясе лауреаты иткән «Колыма хикәяләре» әсәрләренең язылуына да без Г. Ибраһимовның тәэсире зур булган дип әйтә алабыз.

ӘДӘБИЯТ


1. Бертуган Бикколовлар / төз. авторлар Ф.С. Сәйфуллина, И.Г. Гомәров. Казан: Җыен, 2016. 448 б.

2. Гайнуллина Г. Развитие татарской автобиографической прозы в 60–70 годы XX века: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2001. 24 с.

3. Ибраһимов Г. Сайланма әсәрләр / төз. һәм кереш сүз авторы Л.И. Мингазова. Казан: ТаРИХ, 2002. 542 б.

4. Мингазова Л.И. Творчество Ибрагима Салахова: Основная проблематика и ее художественное воплощение: автореф: дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1998. 25 с.

5. Салахов И. Колыма хикәяләре. Фаҗига-хроника. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 256 б.

6. Салахов И. Еллар сәхифәсе / Г. Ибраһимовның тууына 80 ел // Ялкын. 1967. № 3. Б. 14–15.

7. Салахов И. Беренче адымнар // Ялкын. 1973. № 4. Б. 28–29.

8. Салахов И. Киләчәк буыннар белсен // Социалистик Татарстан. 1988. 4 декабрь.

9. Хасанов М. Галимҗан Ибраһимов: шәхесе һәм иҗаты, ул яшәгән заман турында уйланулар // Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман. Казан: Фикер, 2002. 272 б.


## Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ «ЯШЬ ЙӨРӘКЛӘР» РОМАНЫНДА ИКЕ МӘХӘББӘТ МОДЕЛЕ


***Минһаҗева Р.Ә.***



В статье дан анализ двух моделей любви, представленных Г. Ибрагимовым в романе «Молодые сердца» (1912). Платоническая модель любви основана на романтической чувственности, согласно которой любовь – это великое чувство, данное свыше, показана в образе Зии и Марьям. Аристотелевская модель – прагматичная, рассудочная, нашедшая свое продолжение в руссоистско-толстовской модели идеальной семьи, представлена в образе Сабира и Камили.

The article represents the analysis of two types of love, given in the novel «Young hearts» written by G. Ibragimov (1912). Platonic model of love is based on the romantic sensuality which says that love is a great feeling given from God and it is shown through the characters of Ziy and Maryam. Aristotle's model is pragmatic, rational, and it is found its continuation in the russoistic-tolstoy model of an ideal family; and it is shown in the characters of Sabir and Kamilya.

Галимҗан Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романы (1912) XX йөз башы татар әдәбиятында психологик роман жанрын ачып җибәрүче тәүге әсәрләрдән санала. Әдәбиятчы Г. Сәгъди аны «рухи роман» дип атый [6, б. 24]. Г. Халит исә аның татар прозасында беренче психологик роман булуын искәртә: «Яшь йөрәкләр»нең үзәгендә, чорның иҗтимагый мәсьәләләреннән бигрәк, кеше характерының бик индивидуаль-психологик төсмерләре, аларның мораль-этик контрастлары куелган» [8, б. 123].

Билгеле булганча, психологик эчтәлектәге әсәрләр үзәгендә мәхәббәт тора. Романда ул универсаль эчтәлектә бирелә: гашыйклар арасындагы мәхәббәт, туганлык мәхәббәте, балага мәхәббәт, ата-анага мәхәббәт, үз-үзеңә мәхәббәт, халыкка мәхәббәт, атка мәхәббәт, җиргә мәхәббәт, музыкага мәхәббәт һ. б.

Без әлеге мәкаләбездә Г. Ибраһимов калку итеп сурәтләгән ике төп мәхәббәт моделен анализларбыз.

Әдәбиятчы Н. Трапезникова искәртүенчә: «Романтики изображали любовную страсть как таинственное (подразумевалось от бога) и фатальное чувство, от которого невозможно спастись» [7, с. 38]. Г. Ибраһимов әсәрләрендә дә бу искәрмә түгел. Мәсәлән, «Гыйшык корбаннары», «Сөю сәгадәт» хикәяләрендә автор нигездә Әфләтүн (Платон) мәхәббәтен үзәккә куеп тасвирласа, «Яшь йөрәкләр» романында гашыйклар арасындагы мәхәббәтнең ике төп моделен, ягъни Арастуча (Аристотель) мәхәббәтне дә күреп була.

Беренчесе − традицион-романтик рухта бирелгәне, хисләр өермәсе белән өретелгәне − Зыя белән Мәрьям арасындагы мәхәббәттә, икенчесе – салкын акыл белән үрелгәне, я булмаса «акыл кайчылары» белән киселгәне Сабир белән Камилә мөнәсәбәтләрендә чагылыш тапкан.

Романтик традиция буенча төп геройлар Зыя белән Мәрьямнең мәхәббәтләре бишектән үк башлана. Музыкадан соң, мәхәббәт – Зыя өчен яшәү мәгънәсе. Романтик мәҗнүн буларак, Зыя, сөйгәнен сәнгать әсәренә тиңләштереп, рухани матурлыкны алга чыгарып сурәтли: «Мәрьямнең йөзенә, сер, илаһият, нур вә ялкын илә туган ул зур кара күзләренә тик бер генә мәртәбә карасын, – ант итәм, ул даһи ихтыярын югалтыр, дөньясын онытыр да, тәңренең бу мөмтаз сәнгате – рухан матурлыкның ниһаясен аңлаткан, йөрәктә булган барлык голүвият вә җәмалне ингыйкас иттергән (чагылдырган) ул йөз, ул кара күзләр алдында гали бер коллык белән сәҗдә итәр» [5, б. 115].

Мәрьям дә Зыяны өзелеп ярата: «Мин аны бишектән бирле яратам, бала чагымнан бирле сөям... Аны уйлау, аның сурәте белән ләззәтләнү, аны сөю – минем йөрәгем белән бергә кан булып, ит булып үскән. Аңа мәхәббәт – минем җанымның бер кисәге. Бер кисәге генә түгел, бөтен торышы, барлык куәте...», – дип, үзенең пантеистик эчтәлектәге мәхәббәтен белдерә [5, б. 215].

Шәхси теләк-омтылышларга ирек булмау, төрле чикләүләргә каршы ризасызлык романтик геройларның аерылмас халәте итеп, ялгызлыкны алга чыгара. Бары тик ялгыз калган вакытларда гына алар даими уйлануда, күз яшьләре тулы хатлар язуда, яисә «тыелган шөгыльләре» – берсе музыка белән, икенчесе мәхәббәт романнары уку белән юана алалар.

Күрәбез ки, Зыяның сөйгән кызы Мәрьямнең рухи дөньясы сәнгать әсирлегенә кереп капкан: ул мәхәббәт романнары белән «җенләнә». Бу уңайдан А.С. Пушкинның «Дубровский» повестендагы Маша Троекурова искә төшә. Ул да Мәрьям кебек, хыялында «роман» кичерә. «Уединенная жизнь и французские романы сильно развили в ней не чувство, не страсти, а фантазию, и она считала себя действительно готовою на все жертвы для того, кого она полюбит» [2, б. 638], – дип яза бу хакта В. Белинский.

Дөрестән дә, төрек романнары белән мәшгуль хыялый Мәрьямнең күңел биләмәсендә бөтенләй икенче һәм үзе генә белгән хур кызлары, батыр егетләр, тылсым-могҗизалар белән тулы, җир тормышыннан төптән аерылып торучы дөньясы бар. Ул гүя шулар тормышы белән яши. Р. Ганиева күзәтүләрен куәтләсәк: «Мәрьям, бөтен дөньясын онытып, реалистик төрек әдәбиятын башлап җибәрүчеләрдән Халид Зыя Ушаклыгөлнең «Нәмидә», «Фәрди вә шөрәкя» кебек романнарын укый, үзенең эчке дөньясын аларда мәхәббәт чире белән, Нәмидәләр, Һәҗәрләр, Наилләр, Тайфурлар хәяты белән үлчи, бу геройларның фаҗига, канлы күз яшьләре белән үрелгән мәхәббәтенә үзенең якты өметләрен каршы куя» [4, б. 137].

Татар мәҗнүннәре, хыялый Зыя белән Мәрьям мәхәббәттә хатлар аша аңлашалар. Әсәр тукымасында хатларның бөтенесе китерелмәсә дә, яшьләрнең бик еш, көн саен диярлек хат язышулары турында искәртелә. Хикәяләүдә, эпистоляр элемент буларак, бу хатлар укучының әсәрдәге вакыйгаларга карата ышандыру көчен арттыралар, сюжет-эчтәлеккә документаль дөреслек кертәләр, геройларның эчке дөньясын тулырак ачарга ярдәм итеп, аларның укучы күңеленә аеруча җанлы, эмоциональ итеп уелып калуына ярдәм итәләр.

Г. Ибраһимовның, төрле сәбәпләр аркасында бер-берсе белән очраша алмыйча, зарыгып беткән гашыйк парлары Зыя белән Мәрьям өчен хат алышу бердәнбер «кавышу» чарасына, яшәешләренең әһәмиятле бер юанычына әйләнә.

Солдатка алынып алдыннан Мәрьям белән бакчадагы төнге очрашуы килеп чыкмагач, сөйгәненә карата мәхәббәт һәм шул ук вакытта аерылу сагышы хисе белән тулы хатын: «Минем йөрәгем шулай ди» [5, б. 212], – дип тәмамлануыннан, тагы бер кат Зыяның үз йөрәген генә тыңлаучы, ихлас күңелле кеше икәнен күрәбез.

Фәхригә кияүгә чыккан Мәрьямнең Зыяга – казармага − язган җавапсыз калган тәүбә-истигъфар хатлары бер укучыны да дулкындырмыйча, кызгану хисләре уятмый калмыйдыр. Бу хатлардан күренгәнчә, нәкъ менә яратмаган кешесе Фәхри белән тормышын бәйләү Мәрьямнең характерына гыйсъянлык чаткысы сала да: «...мин хәзер назлы туташ Мәрьям түгел, мин бу падлисның астында яту белән ниһаясез кыйммәт булган һәм кызлык вөҗданың белән үз сөйгәнеңә генә бүләк итәргә тиеш дип хис ителгән надир (сирәк) кодсиятемне югалтсам да, бу авыр фаҗига миннән бер пәрдәне алды, минем көчемне, каһарманлыгымны каплап торган бер мәгънәви диварны җимерде... Мин хәзер үзем уйлаганнан артыгын эшли алам» [5, б. 253].

Хатларның романда иң әһәмиятле тагы бер йөкләмәсе бар: алар дөньяны герой-персонажлар күзлегеннән күзәтергә мөмкинлек ачалар. Әдәбият белгече В. Әминева хаклы искәрткәнчә: «В произведениях Ф. Амирхана, М. Гафури, Г. Ибрагимова, Г. Исхаки и др. объективный мир изображается согласно формам его восприятия и осмысления героями. Например, роман «Молодые сердца» захвачен стихией исповедального слова, повествование ведется с точки зрения Зыи, Марьям, иногда других героев» [1, б. 9–20]. Әсәрдә алар тормышта үз урынын эзләүче Зыя белән Мәрьямнең тәүбәистигъфарлык сүзен җиткерү кебек мөһим функция дә үтәп киләләр. Күрәбез, хатлар – Зыя белән Мәрьямнең хыялый, тәэсирләнүчән, акыл белән түгел, хис-тойгы белән яшәүче романтик инсаннар икәнен күрсәтәләр.

Г. Ибраһимов, бу әсәрендә дә илаһи мәхәббәт темасын дәвам итеп, тагы бер кат аның югарыдан иңдерелгән бөек хис икәненә басым ясый, Мәхәббәттә никах иреге мәсьәләсенә, йөрәк, күңел кушуына дикъкать итү зарурияте хакында әйтә, бернинди тышкы һәм эчке кануннар, җәмгыяви тәртипләр бу табигый күренешкә киртә булырга тиеш түгел, ди. Зыяның Мәрьямгә язган соңгы хатында бу мәсьәлә аеруча ачык чагыла: «Дөньяда ничә җан булса, шунча йөрәк, шунча табигать бар; һәм шунча теләк вә әмәл бар. Берәү берне, берәү икенчене эзли. Һәммә кешенең һәммә теләге табигый, һәммә эше хак вә тугры. Шуңа күрә дә һичкем һичбер төрле теләге, һичбер төрле әмәле өчен гаепле дә түгел, мәсьүл ителергә дә ярамый... Чөнки – табигый. Алла мине сөяр өчен яраткан, йөрәгемә сөю җәүһәрен куйган. Шуңа күрә сөюне теләү, аны бер рухани зарурат итеп хис кыйлу – миңа табигый...» [5, б. 293].

Кызганыч, яшьләр арасында шулай матур башланган мәхәббәт үзенең бәхетле финалына барып җитми кала. Зыя хәрби хезмәткә алынгач, юанычы булган мәхәббәт романнарындагы бәхетле, баллы тормыш турындагы уйларыннан айнып бетмәгән Мәрьям, мәҗбүриләтеп диярлек, күрмәгән, яратмаган, табигате белән кабул итә алмаган шәһәр кешесе Фәхригә кияүгә бирелә. Әмма сөйгәне Зыяны һич оныта алмый, һәрдаим аны уйлап, газап утлары чигә. Соңыннан, ирен үтерүдә гаепләнеп, сөргенгә сөрелә. Зыя да, белүебезчә, гомере көтелмәгәндә бик иртә өзелү сәбәпле, үзенә тиң Мәрьям белән тормышын бәйләргә өлгерми кала.

Икенче мәхәббәт сызыгы, дөресрәк әйтсәк, үрнәк руссочыл гаилә моделе Сабир белән Камилә мөнәсәбәтләрендә чагылыш таба. Бу геройлар – хыялый Зыя белән Мәрьямнән аермалы буларак, тормышка яраклаша белүче, реаль максатлар белән яшәүче яшьләр.

Сабир – Зыяның бертуган абыйсы. Аның Зыяга бер дә охшамавын автор болай ассызыклый: «Ул, гомумән, табигате белән артык назик, артык ялкынлы хиссияткә таныш түгел. Ул гакыл, салкын мөхакәмә колы, шуларның күргәзүенчә бара» [5, б. 55]. Яратылышы белән беркемгә буйсынырга яратмаган, бәйсезлеккә омтылган, авыр, сабыр табигатьле Сабир, мәдәни тормышны ташлап, «үз табигатенә ягышлы бер дөнья табарга тәбган мәҗбүрият хис итеп, моның өчен дә тын, караңгы авылга югалырга карар» бирә [5, б. 58].

«– Мин сүзем, гакылым белән генә түгел, үземнең инстинктым белән үк авыл ягына карыйм. (...) Анда булыр минем үземнең бер колач кына булса да җирем, булыр үземнең сукам, үземнең атым. (...) Мин үз эшемне эшләп, үземә һәм үземнең ирегемә үзем хуҗа булырмын. Азат булырмын. Миңа шул җитә дә», – ди [5, б. 60].

Яшьләр икесе дә саф, идеаль табигать балалары. Сабир бар йөрәге, сулышы белән «мәдәни» шәһәрне күрә алмый. Геройның «модалы» шәһәр хәятенә, һәртөрле фән-гыйлемгә ачы тәнкыйть яудыруы аша, автор Г. Ибраһимовның ул еллардагы фәлсәфи-эстетик карашларында сәнгать-мәдәният-гыйлемгә карата формалашкан бик тә каршылыклы тәнкыйди фикер сөрешен, төгәлрәк әйткәндә, руссочыл-толстойчыл карашларның көчле йогынтысын күреп була. Ж.-Ж. Руссо тәгълиматы буенча җир эшкәртү һәм аның җимеш-уңышлары белән яшәү – кешенең табигый гамәл-теләге ул. Бу табигый теләкне бозучы фән-мәгърифәткә, аның нәтиҗәсе булган мәдәни һәм техник алгарышка олугъ фикер иясенең карашы, беләбез, үтә кискен һәм кырыс була.

Руссочыл табигый кеше концепциясе буенча автор Сабирны вакытында шәһәр тормышын ташлаттырып, авылга, табигать кочагына җибәреп, җир кешесе – игенче хезмәте культын раслаттырып, аның киләчәген уңай якка хәл итә. Нәтиҗәдә, Сабирның эше дә гөрләп барачак, үзенә тиң парны бик җиңел табып, бер нинди каршылыксыз өйләнеп тә куячак.

Ул, атасы Җәлал мулла хаҗга китеп югалгач, әнисе янында төп йортта төпләнеп, өйләнергә уйлый. Булачак кәләшенә куйган таләбен иң әүвәл Җәббар мулла белән Кәрим мәхдүмгә белдереп, үзенә − «Әлифне таяк дип, вауны чукмар дип белмәгән, әмма табигате белән бик тере, артык җанлы иптәш» эзләвен әйтә. «...мин үзем дә авыр, басынкы кеше. Хатыным да шулай булса, безне җир күтәрә алмас... Шуңа күрә, очып торсын, үләм дип аска карап йөрмәсен, хәятле, хәят дәртле булсын. Фәгъгаль (актив, эшлекле) булсын... Шул сыйфатлары табылып, укымаган булса – минем өчен ул бигрәк мөнасиб. Ул зат укымаган, димәк – яратылышы, табигате, табигый нәфасәтләре үз хәленчә, бөтен көенчә калган; тышкы тәэсирләр белән бозылмаган димәктер... Бу – гаҗиб табигать булырга тиеш. Мин, мөмкин булса, гыйлем вә мәдәният дигәннең төсен дә күрмәгән, уку вә китап дигәннең исен дә иснәмәгән, бәдәви (культурасыз) кызлары эченнән шундый бер табигатьне сайлап алыр идем... Аннан соң, әллә нинди назик хисле, шагыйрь кыяфәтле булсын дигән теләгем дә юк. Чөнки мин гыйшык эзләмим... Ул күрер күзгә чибәр, таза, табигый гакыллы булса, шуның өстенә баягы сыйфатлары да кушылса, минем дигәнем булды» [5, б. 283].

Булачак хатыны − Камилә нәкъ менә Сабир куйган таләпләргә җавап бирүче хатын-кыз булып чыга. Госманнар өендә танышып, яшьләр тиздән кавышалар да. Бары тик Камилә генә үзенең шаян, уенчак табигате белән Җәлал мулланың авыр холкыннан айнып кына килүче Сабирлар йортына моңарчы күрелмәгән ямь-җан кертеп җибәрә, иренә яхшы хатын, җәберләнеп яшәгән каенанасы Зөләйха абыстайга уңган килен булып китә.

Күрәбез ки, Арастуча, прагматик аек акылга нигезләнгән Сабир-Камилә мәхәббәт сызыгы үзенең бәхетле дәвамын таба. Автор, бәхет бары тик гаиләдә генә мөмкин дип, сәламәт гаилә тантанасын раслый.

Димәк, «Яшь йөрәкләр» романында Г. Ибраһимов «яшь йөрәкләре» Зыя, Мәрьям, Сабир, Камилә ярдәмендә ике мәхәббәт моделен күрсәтә.

Беренчесе − гашыйклар Зыя белән Мәрьям арасындагы мәхәббәт − романтик рухта, югарыдан иңгән бөек хис кебек кабул ителә. Аларның Әфләтүни мәхәббәтен тасвирлаганда, автор руссочыл-романтик әдәбиятның күп кенә сәнгати-эстетик мөмкинлекләреннән – хат язу, төш күрү алымнарыннан, табигать-бакча образларыннан да уңышлы файдаланган. Шәхес

азатлыгын кыскан, никах иркенә аяк чалган иҗтимагый шартлар аркасында яшьләрнең гыйшыклары фаҗигале тәмамланса да, әсәрдә мәхәббәт – мәңгелек дигән идея төгәлләштерелә.

Икенчесе − аек акылга нигезләнгән Сабир – Камилә мәхәббәте – үзенең бәхетле дәвамын гаилә тормышында таба. Гомумән, бу яшьләрнең бер-берсенә тартылуларуның максаты да гаилә кору, руссочыл идеал гаилә моделен раслау. Шуңа күрә аларның мәхәббәтләре дә иң әүвәл бәхетле никахтагы тормыш рәвешендә тәгаенләнә.

Күренгәнчә, үзенең беренче, киң планлы һәм киң колачлы [3, б. 49] романында Г. Ибраһимов, яшь парлар арасында ике төр мәхәббәткә тукталып, «табигать балалары»н мәхәббәт фәлсәфәсе үзәгенә куеп сурәтләүгә, аларның табигый хисләр иреген яклауга ирешкән. Ул Шәрекъ һәм Гаребтән килгән әдәби традицияләргә мөрәҗәгать итә, табигый инстинктларны, хис-тойгынлыкны үзәккә куеп, романтикларча, мәхәббәтнең мәңгелеген раслый.

ӘДӘБИЯТ


1. Аминева В. Р. О категориях сопоставительного литературоведения // Сопоставительная филология и полилингвизм: материалы Всерос. научно-практ. конф., г. Казань, 29–31 окт. 2002 г.) / [под общей ред. А.А. Аминовой, Н.А. Андрамоновой]. Казань: КГУ, 2003. С. 19–20.

2. Белинский В.Г. Собрание сочинений: в 3 т. Т. 3: Статьи и рецензии 1843–1848. М.: ОГИЗ, 1948. 982 с.

3. Габидуллина Ф.И. Проблемы изучения жанровой природы татарского романа // Филологические науки. Вопросы теории и практики. Тамбов: Грамота, 2013. Ч. I. № 7 (25). С. 49–51.

4. Ганиева Р. Галимҗан Ибраһимов һәм көнчыгыш әдәбиятлары // Казан утлары. 1977. № 3. Б. 134–141.

5. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. 2 т.: Яшь йөрәкләр. Казакъ кызы / текстларны, искәрмәләр һәм аңлатмаларны А.Ш. Шамов, Р.Р. Гайнанов әзерләде. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. 478 б.

6. Кара: Җәләлиева М.Ш. Әдип Галимҗан Ибраһимов // Әдәбиятыбызның җырлы чишмәләре. Казан: Мәгариф, 2001. Б. 15–41.

7. Трапезникова Н. С. Эволюция романтизма в романе: (проблема взаимосвязи направлений во французской литературе 60–80 гг. XIX в.). Казань: Изд-во КГУ, 1980. 202 с.

8. Халит Г. Чынлык һәм гүзәллек гармониясе: (Г. Ибраһимовның эстетик карашлары үсешен күзәтү тәҗрибәсеннән) // Казан утлары. 1977. № 3. Б. 121–134.


## Г. ИБРАҺИМОВ ИҖАТЫНДА ШӘХЕС ФАҖИГАСЕ


***Миңнуллина Ф.Х., Гарипова Л.Ш.***



Статья посвящена изучению поэтики трагического как формы образного мышления и ее отражения в произведениях Г. Ибрагимова «Красные цветы», «Новые люди» и «Люди», где показана драма человека, на долю которого выпали суровые жизненные испытания. Проблема противостояния героев трагическим обстоятельствам в безвыходной ситуации в каждом из рассматриваемых произведений решается по-разному.

The article is devoted to the study of poetics tragic as forms of creative thinking and its reflection in the works of G. Ibragimov, «Red flowers», «New people» and «People» which shows the drama of a man, who have borne severe trials of life. Problem confrontation of the heroes of the tragic circumstances in a desperate situation in each of these works dealt with in various ways.

Татар әдәбияты классигы, күренекле җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе Галимҗан Ибраһимов – утыз елдан артык иҗат гомерендә бай һәм күпкырлы мирас калдырган, сәяси-тарихи вакыйгалар тәэсирендә барган үзгәрешләрне әсәрләрендә чагылдырган шәхес. Ул да, башка бик күп зыялылар кебек, 1917 ел инкыйлабын шатланып каршы ала. Иҗатының икенче чорында язылган «Яңа кешеләр» (1920), «Кызыл чәчәкләр» (1922), «Тирән тамырлар», (1928), «Безнең көннәр» (1934) кебек әсәрләренә вакыйгаларны тарихи эзлеклелектә, сыйнфыйлык принципларына таянып бирү хас. Шулай да, Г. Ибраһимовның иҗатын бәяләгәндә сыйнфыйлык принцибына гына таянып түгел, ягъни байлар-ярлылар, аклар-кызыллар каршылыгы аша гына якын килү объектив булмас. Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар», «Безнең көннәр» романнарында, «Яңа кешеләр» драмасында, «Кызыл чәчәкләр» повестенда революция алып килгән үзгәрешләрне, халыкның көрәш юлын, яңа кеше һәм җәмгыять формалашуын, халыкның аянычлы һәм шул ук вакытта фаҗигале язмышын күзалларга була. Шундый иҗат җимешләренең берсе булган «Кызыл чәчәкләр» (1922) хикәясендә, мәсәлән, совет тәртипләре урнашу, гражданнар сугышы вакыйгалары, яңа тормыш төзү күренешләре тасвирлана. Беренче карашка, әсәрдә чор идеологиясенең йогынтысы шик уятмый, әсәрнең конфликты да капма-каршы сыйныфларның каршылыгына корыла. Әсәрнең багышлавында: ««Кызыл чәчәкләр» хикәясе якты, азат көннәр өчен көрәш юлында һәлак булган иптәшләргә багышлана» дип язуы да шуңа ишарә [4, б. 7]. Әйтергә кирәк, Г. Ибраһимов «…татар авылындагы сыйнфый катламнар – сәүдәгәрләр, муллалар, һөнәрчеләр, ярлы крестьян вәкилләренең – 1917 елгы вакыйгаларга мөнәсәбәтләрен ача. Повесть татар җәмгыяте өчен актуаль булган милли азатлыкка ирешү юлларына кагылышлы бәхәсне үзәккә куя» [10, б. 100]. Халыкның төрле сыйныфларга каравы исә повестьта йортларның үз дәрәҗәләренә карап урын алуларында да чагылыш таба. Геройлары да шул авылның төрле урамнарында, байлыклары төрлечә булган йортларда туып үсәләр.

Повесть бала чаклары, үсмер еллары империалистик, Октябрь инкыйлабы, гражданнар сугышы чорына туры килгән биш егет язмышын колачлый. Повестьның сюжеты, геройларның эш-гамәлләре, уй-хыяллары да шул көрәшне күрсәтүгә буйсындырыла. Әлеге көрәш һәм геройларның холык-фигыльләре, киләчәк язмышлары аларның социаль чыгышлары белән тыгыз бәйләнештә ачыла. Шуларга бәйле рәвештә, әдип ил күләмендә барган үзгәрешләрне чагылдыра. Төрле социаль катлам вәкилләре булган Шаһбаз, Солтан, Гыйлаҗи, Фазыйл белән Галине – бергә уйнап үскән, аерылгысыз дусларны – әдип инкыйлаб елларында капма-каршы лагерьларда калдыра һәм тарихның шушы «чәнечкеле киртә»се тугрылык, мәрхәмәт-миһербанлык кебек төшенчәләрнең юкка чыга баруына китерә, туң күңелләр, бәгырьсезләрне «тудыру», кешене явызлыкка, вәхшилеккә этәрә. Инкыйлаби күтәрелешләргә кадәр дәвам иткән дуслык чор каршылыкларына очрап юкка чыга. Кан коюга нигезләнгән бәрелеш башлангач, егетләр арасында үзара аңлашылмаучанлык туа. Геройларга икеләнүләр, күңел тынычсызлыгы, ялгышулар аша инкыйлаб тудырган үзгәрешләрне кабул итәргә һәм һәрберсенә аларны үз вөҗданы, үз намусы аша кичерергә туры килә. Балачак дусларның язмышы, тормыш юлы аянычлы һәм фаҗигале. Бу хәлләрне илдә хөкем сөргән социаль-сәяси тәртипләр белән аңлатып

була. Мәсәлән, дусларның берсе булган, бала чактан зирәклеге, тапкырлыгы белән дан казанган Фазыйл гражданнар сугышы елларында аклар ягында көрәшә, соңыннан совет ягына күчә: «Колчактан өмет киселгәч, Фазыйл мең азап белән башкортларга килеп кушыла. Шулар аркасында үзен коткара. Бөтенләй безнең якка чыга. Советчыл булып китә» [4, б. 123]. Әлеге геройга җан бәргәләнүләре, эчке газаплар кичерергә, «сыйнфый дошманның сугышы ут белән су кебек каршы куйса да», ахырда үз-үзен җиңәргә көч табып, иптәшләре белән «миләрнең, йөрәкләрнең юллары тагы бергә кушылып ага» башларлык юл үтәргә туры килә.

Әсәрнең төп герое Солтанны исә автор сыйнфый көрәш юлына бастыра, яшәүнең асылын, мәгънәсен шунда күрә дигән нәтиҗә чыгара. Шулай да Г. Ибраһимов яңа тормыш тарафдары булган, халыкның азат, бәхетле киләчәген көрәштә күргән Солтан, Шаһбаз, Гыйлаҗи кебек образларга тирән мәгънә йөкли. Язучы еш кына көрәш юлында Солтанның бер аягын югалтуын искә төшерә. Яңа тормыш өчен көрәшкә багышлаган, шул юлда сәламәтлеген югалткан бу герой исә җәмгыять тарафыннан онытылып, энисе Гайшә, сөйгәне Галимә ярдәменә генә кала. Моны исә бер кеше генә кичергән авырлык дип түгел, ә киресенчә, көрәш юлында меңләгән кешеләрнең газап чигүенә ишарә итүче фактор дип тә бәяләргә мөмкин. Повестьта ятимлектә үскән Шаһбаз да гыйбрәтле, фаҗигале язмышлар галереясына керә. Ул, дусты Солтан кебек, яңа тормыш өчен көрәш юлына баса, шул юлда гомере аянычлы тәмамлана: Фирганәдә басмачылар тарафыннан үтерелә. Баштарак ил күләмендә башланып киткән үзгәрешләргә катнашмаган, балта остасы буларак танылган Гыйлаҗи да сугышка алына, Герман ягына әсир төшә, балта эшенә йөри, кулын сындырып, туган җиренә әйләнеп кайта. Инкыйлаб эшенә кушыла һәм шул юлда һәлак була.

Яңа тормышны кабул итә алмаган Гали яңа хакимият урнашу дәверендә мал-мөлкәтен югалта, ак офицер була, Себергә чигенә, аннан кире туган якларына кайта, соңыннан үз-үзенә кул сала. Көрәш барышында аның үз авылдашларын үлемгә хөкем итүе, балачак дусты Гыйлаҗига да коточкыч хыянәте – аны җәзалап үтерүе, «мәңгелек дуслыкка кырыгар мәртәбә ант итешү»не онытып, кешелегеннән язып түбән тәгәрәве аша үзгәрешләр дәверенең фаҗигасе күзаллана. Бу геройлар язмышы – илдәге меңнәрчә сугыш корбаннары язмышы да. Аларның язмышлары «автор мөнәсәбәте» белән түгел, тирәлек, тормыш кануннары белән хәл ителә. Кеше белән шартлар арасындагы каршылыклар игътибар үзәгенә куела. Г. Ибраһимов аянычлы язмышлы шәхесләр аша халык фаҗигасен күрсәтә. Повестьнең исеменә чыккан кызыл чәчәкләр дә символик мәгънәгә ия, кызыл төс – кан, үлем, «кызыл» инкыйлаб тәртипләре; алар әсәрнең үкенечле язмышлар, халык фаҗигасенә мөнәсәбәтле икәнлегенә алдан ук ишарә итә.

Сыйнфый нәфрәтнең үсүе, аның кеше холкын ничек үзгәртүе белән бәйле күренешләр Г. Ибраһимовның «Яңа кешеләр» драмасында Тимеркәй, Батырхан кебек геройларның эш-гамәлләрендә дә чагылыш таба. Әдипнең бу әсәрендә яңа җәмгыять төзү өчен көрәшкә күтәрелгән геройлар өстенлек итә, сыйнфый көрәш идеясе, яңа система дошманнарын юк итү конфликты үзәккә куела. Шулай да, Г. Ибраһимов пьесасында сыйнфый каршылыкларны гына түгел, ә яңа җәмгыятьне төзүче кешеләрнең формалашуын, үз чорының канлы вакыйгаларын, гражданнар сугышы фаҗигаләренә бәйле рәвештә шәхес фаҗигасен дә күзалларга мөмкин.

Батырхан ярлы егет һәм гади халык мәнфәгатьләрен яклый, кызыллар яклы. Хәйри исә, киресенчә, авыл бае, баррикаданың икенче ягында. Гаилә мәсьәләләренә бәйле башланган катлаулы мөнәсәбәтләр, алга таба сыйнфый каршылык, Батырханның Хәйри ризалыгыннан башка кызына өйләнүе алар арасындагы «чокырны» тагы да тирәнәйтә.

Драма тәнкыйть тарафыннан да төрлечә бәяләнә. Мәсьәлән, Г. Нигъмәти фикеренчә: «Авылдан чыгып, революциягә катнашкан көчләр турында Г. Ибраһимов «Яңа кешеләр» дигән пьесасын яза. Анда бердән, югарыдагы («Кызыл чәчәкләр»дәге) дусларын әүвәлге өчесен хәтерләткән Тимеркәй, Гайнетдинов кебек типлар рәтеннән, тагын ярлы гаиләдән чыгып, мең газап белән укып белем алган һәм соңыннан партиягә кергән мөгаллимә Камәр; хатыны Зәйнәп исеменә кара ягардай яман хәбәрләр тараткан өчен кулак Кәҗә Якупның угылы Саткайның башын өзеп каторгага эләккән, герман сугышы вакытында аннан качып фронтка киткән һәм Октябрь көннәрендә кызыл командир булып сугышта гайрәтлекләр күрсәткән Батырхан кебек типлар да бар» [6, б. 121]. Г. Халит билгеләгәнчә, кайбер мәкаләләрдә һәм рецензияләрдә пьесадагы кайбер образларның, аерым алганда, Батырхан образының дөреслеге шик астына куела. Элекке каторжанның уңай герой сыйфатында революцион хәрәкәттә катнашуы типик түгел, революцион чынбарлыкка туры килми дип санала [8, б. 58]. «Яңа кешеләр»нең төп герое субъектив яктан үрнәк, уртак һәм гүзәл идеаллар өчен газаплар чигүче» кеше булырга тиешлеге билгеләнә.

Барлык персонажлар да сыйнфый карашларга бәйле рәвештә капма-каршы ике лагерьга бүленәләр, ягъни алар совет властен яклаучылар, яки аның дошманнары буларак хәрәкәт итәләр. Геройларның шәхси язмышлары да шул бәрелешләрдә, социаль-тарихи үзгәрешләрдә хәл ителә.

Әсәрнең исеме үк яңа герой концепциясе хакында сүз баруын күрсәтә. «Г. Ибраһимов революция тудырган һәм революцияне ясаган көрәшчеләрне «яңа кешеләр» дип атый, яңа дәвернең үзенчәлеген һәм өстенлеген иң әүвәл шундый каһарманнарда күрә» [1, б. 170]. «Яңа кешеләр» драмасында Батырхан, Камәр, Тимеркәйләр, нәкъ менә тигезлек, ирек өчен көрәш юлына баскан геройлар булып торалар. Әмма аларның бу канлы көрәш юлына килүдә үз юллары бар. Шуларга бәйле рәвештә, автор аларның характерларында, үз-үзләрнең тотышларында барлыкка килгән үзгәрешләргә дә туктала. Мәсәлән, югарыда күрсәтелгәнчә, кызыл командир булып җитешкән Батырхан 7 ел хатыны турында гайбәт сүз сөйләгән Саткайны балта белән сугып үтергәне өчен каторгага сөрелә. Аннан качып, Бөтендөнья сугышы фронтлары аша инкыйлаб хәрәкәтенә килеп кушыла. Автор аны һич тә кансыз командир итеп кенә сурәтләми. Ул үзенең гөнаһлы булуын да аңлый. Акгвардиячеләрнең бер гаепсез кешеләрне үтерүләрен күргәч кенә, канлы үч алу юлына килә [10, б. 167]. Әсәрдә сурәтләнгән яшь буын вәкиле Тимеркәй дә игътибарга лаек. Вакыйгалар үстерелешендә ул кызу канлы, хаксызлыкны, гаделсезлекне кабул итә алмаучы шәхес буларак ачыла. Егетнең Вәли абыйсын үтерүе һәм: «Агайны гына түгел, андый урында туган атайны да кызганмам мин!» [4, б. 410], – дип әйтүе аеруча тетрәндергечтер. Ул гомумкешелек бәхетенә көрәш, кан кою юлы белән генә ирешеп була дип уйлый. Драмада кеше, гаилә фаҗигасе ил фаҗигасе югарылыгына куела. Кешелексез, аяусыз бәрелешне тасвирлаган драмада туганлык проблемасы күтәрелә. Пьесада бер авыл, гаилә кешеләренең үзара дошманлашуы,

бер-берсен үтерүләре аша заман тудырган фаҗигаләр билгеләнә. Герой фаҗигасен тудыручы төп сәбәп – социаль җирлек, ил күләмендә барган трагик вакыйгалар белән бәйле.

Батырханны да, Тимеркәйне дә яңа җәмгыять өчен көрәш, гражданнар сугышы рәхимсезлеккә өйрәткән, алар тигезлекне, бәхетле тормышны көч, кан коюю белән генә урнаштырып була дип уйлыйлар. Галимовның үле гәүдәсен күргән Шәйбәк бабайның: «Әй, туган! Син тагын кан түккәнсең икән! Ярамас, бер дә ярамас иде!» дип кисәтүенә Батырхан: «Юл бер генә! Менә шушы канлы юл – изге юл» [4, б. 126], – дип җавап бирә. Төп геройларның эш-гамәлләре гомумкешелек кануннары белән бәхәскә керә. Шулай да, Батырхан өлкәннәрнең сүзләрен кире какмый, хатасын бераз булса да таный. Соңрак Тимеркәйнең акланмаган эш-гамәлләрен гаепли башлый. Димәк, герой акрынлап кеше канын коюның мәгънәсезлеген аңлау юлына баса. Шул рәвешчә, Г. Ибраһимов таныш материалларга таянып, шул чор кешеләренең җанлы портретларын, гыйбрәтле язмышларын ача, татар халкы тарихындагы канлы вакыйгаларның тагын берсен күрсәтүгә ирешә.

Авторның ил күләмендә барган трагик вакыйгаларны әсәрләренә нигез итеп алуы «Адәмнәр» повестенда да чагылыш таба. Заманында әсәр төрлечә бәяләнде, бериш тәнкыйтьчеләр аны язучының уңышсыз әсәрләреннән берсе дип билгеләделәр. Кайбер мәкаләләрдә төп кимчелек итеп ачлыкның коточкыч күренешләрен куе буяулар белән бирү, ачлык сәбәпләрен ачмау саналса [5], икенчесендә авторның уңышсызлыгын фаҗига вакытында авыл халкына совет хөкүмәте күрсәткән ярдәмне киң рәвештә тасвирламауда күрделәр: «21 нче ел ачлыгының иң бөек фаҗигасе – советлар Россиясен чолгап алган капиталист хөкүмәтләрнең складларындагы миллион потлар икмәкнең, ачтан үлә торган эшче – крестьянга бирелмичә диңгезгә түгелүе; капиталист мәмләкәтләрнең хәзинәсендә өелеп яткан алтын запасларының йөздән бер өлеше генә бирелгәндә дә, миллионнарның үлемнән котылачагы, советлар хөкүмәтенең ачлык белән көрәшү юлында иткән фидакарьлеге, аның ачлык фәлакәте астында калган авылга, балаларын суеп ашаганнарга җәза бирер өчен генә түгел, шул ачларга чын-чыннан ярдәм кулын сузар өчен барганлыгы вә бу юлда эшче-крестьяннар хөкүмәтенең һичбер капиталистлар мәмләкәтендә күрелмәгән рәвештә, зур фидакарьлекләр күрсәтүе – болар барсы да ул авыр елларның тарихына яндырылып язылырга тиеш моментлар булып, шуларны карт язучының оста каләме белән җанлы рәвештә китереп бастырып, хәзерге яшь буында ачлыкның сәбәпләренә һәм сәбәпчеләренә ачу кузгатасы урында, «Адәмнәр» укучыны «кеше бармаклары», «бот итләре», яшь хатыннарга өрми торган (!) этләр арасында әйләндереп йөртә» [2].

Тәнкыйтьчеләр заман рухына хас булганча, «Адәмнәр» повестеннан совет хөкүмәтенең ачларга ярдәмен тасвирлауны таләп итәләр. Мәсәлән, язучы, әдәбият галиме Г. Толымбайский «Иптәш Г. Ибраһимовның бу хикәясе ачлык елының бер почмагыннан дөрес, хакыйкый тасвир. Хикәя бераз озайтылып, ачлык вакытында эшләгән советлар, «ара»лар һәм бәйнәлмиләл (интернационал) эшчеләр оешмасы эшләренә урын бирелсә, китапның соңына куелган рәсем кебек китапның тышына да ачлыктан берәр рәсем куелса, хикәя тагын да тулырак булыр иде» [7], – дигән теләген җиткерә. Г. Ибраһимов «Адәмнәр» повестенда авыл халкының ачлыктан кыргыйлык, кеше ашау дәрәҗәсенә килеп җиткән крестьян психологиясен бөртекләп-төпченеп сурәтли. Язучының башка әсәрләреннән аермалы буларак, ул куркыныч,

дәшһәтле вакыйгалардан, кара буяулардан гыйбарәт. «Адәмнәр» повестенең беренче битләре үк трагик вакыйгаларны бирү белән башлана: «Үлем үзенең кара канатларын җәйде. Җир йөзе гүя шуның астында капланып калды. Тирә-як куркыныч караңгы каберлекләр, ләхетләр белән, бер үлгәч терелеп чыккан җанлы мәетләр белән тулды. Адәмнәрнең йөрәге моңа чыдамады, урыныннан кузгалырлык куәте булганнар куркышып, дөньяның төрле ягына качтылар. Төркестан, Кавказ, Себер далаларын шуннан таралган хәлсез шәүләләр басты» [3, б. 130]. Ачлыктан җәфа чиккән халыкның авыр язмышы, әлеге афәттән бер-берсе хисабына качарга омтылуы бәян ителә.

Әсәр Галим картны сурәтләү белән ачыла. Әмма вакыйгалар үстерелешендә аны башка образлар алмаштыра. Р.Ф. Харрасова билгеләгәнчә: «…фикерләү ноктасының еш кына үзгәрүе дә, игътибарда тотылган геройларның алмашынуы да табигый бара, укучы бу хакта хәтта уйламый да. Әлбәттә, әсәр Гәрәйнең һәм баласының үлеме белән тәмамланганга, аның гаиләсенә бәйле күренешләр күбрәк булганга, кемдер төп герой сыйфатында аны яисә Зәйнине кабул итәргә һәм әсәр бер гаилә тарихы рәвешендә оеша дип тә санарга мөмкин» [9, б. 121]. Шунысы игътибарга лаек, «Адәмнәр» повестенең 1931 елгы басмасы әдип тарафыннан үзгәртелеп басыла: монда ач авылга ярдәм килү эпизоды өстәлә.

Автор ач халыкның азык-төлеккә ерткычларча ташлануын бөтен нечкәлекләре белән тасвир итә: «…ач күләгәләр бер-берен таптап, алдагы чаналарда кар сырып бетергән капчыкларны берәм-берәм өстерәп тарткалап, җиргә кар өстенә тәгәрәттеләр, хәлсез куллары, зәңгеләдән йомшарган тешләре белән газапланып капчыкларны өзгәләделәр, ертып-ертып җибәрделәр, чана тирәсе бәрәңге белән тулды. Карга туң, чи бәрәңгеләр сибелделәр» [9, б. 167]. Әлеге өстәмәләр шул заман таләпләре, идеологиясе, тәнкыйте белән бәйле.

Г. Ибраһимов реаль-чынбарлыктагы куркыныч хәлләрнең дәһшәтлелеген күрсәтү максатыннан, әсәргә кеше ашау вакыйгаларын да кертеп җибәрә. Кеше ашаучыларга каршы көрәшкән Гәрәй дә, мәсәлән, алга таба кызы Нәфисәгә ит, ризык итеп карый башлый. Язучы яшәү белән үлем арасындагы көрәш аша аерым бер кешеләрдә кешелек сыйфатларының юкка чыгуын ассызыклый. Кеше ашау дәрәҗесенә кадәр җиткән адәмнәр, автор тарафыннан натуралистик сурәтләнә. Автор әлеге фаҗигане гасырлар дәвамында формалашып килгән әхлак кануннарын, кешелек сыйфатларын юкка чыгаручы көч булуын ассызыклый. Моның сәбәпләре исә совет хакимиятенең халыкны рәхимсез талавы һәм 21 нче елларда Идел буенда булып узган корылык. «Адәмнәр» әсәре халкыбызның фаҗигале язмышын, чынбарлыкны тасвирлавы белән игътибарга лаек. Г. Ибраһимов халык тарихында булган чынбарлыкны аерым бер кешеләр язмышы мисалында бирә. Повестьта сурәтләнгән геройлар – фаҗигале язмышка дучар булган ачлык корбаннары. «Галимҗан Ибраһимов крестьян тормышының революциядән элекке тыныч вакытындагы хәлен тасвир белән генә калмады, шуның өстенә ул бу киң тормышның революция (февраль-октябрь) дулкыннары эчендәге бөек кузгалышын, андагы төрле иҗаби (уңай), сәлби (кире, тискәре) күренешләр һәм типларны да үзе алган мәүзугъларында (темаларында) тулы нәфис итеп эшләп бирә алды. («Кызыл чәчәкләр», «Адәмнәр»)» дип яза Г. Сәгъди үзенең «Зур әдипләребезнең берсе» мәкаләсендә («Кызыл Татарстан», 1927). Чыннан да, язучының укучы тарафыннан зур хуплау тапкан, төрле каршылыклы бәя дә алган

әсәрләрендә заман сулышы, әхлакый кыйммәтләр үзгәреше, татар кешесенең киң борылышлар чорындагы гыйбрәтле һәм фаҗигале язмышы бирелә. Әсәрләрендә шәхес һәм ил фаҗигасе җәмгыятьтәге тәртипләр аша ачыла. Тарихи дәвернең драматизмын, кешеләр язмышын яктырту – болар барысы да Г. Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр», «Адәмнәр» һ.б. әсәрләрендә көчәеп киткән тенденцияләрдән. Әдип үзенең геройлары аша үткән чорның социаль күренешләрен, халык язмышын, аның яшәешен, уй-фикерләрен, катлаулы тормышларын сурәтләп, чынбарлыкта хөкем сөргән социаль, әхлакый тәртипләр турында сүз алып бара һәм укучысына тарихның катлаулы, фаҗигале елларын күрсәтеп, тагын бер кат уйланырга чакыра.

ӘДӘБИЯТ


1. Арсланов М. «Новые люди» в постановке Мухтара Мутина // Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман: Тууына 115 ел тулуга багышланган фәнни конференция материаллары. Казан: Фикер, 2002. Б. 67–72.
2. Госманов Ш. Әдәбият дөньясында адәмнәр // Безнең юл. 1924. № 3. Б. 149–150.
3. Ибраһимов Г. Адәмнәр // Әдәби мирас. Казан: Татар. кит., нәшр., 1997. 138 б.
4. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар .кит. нәшр.,1976. 5 т. 454 б
5. Нигъмәти Г. Октябрь һәм әдәбият // Кызыл шәрык. 1922. № 1. Б. 82–85.
6. Нигъмәти Г. Сайланма әсәрләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1958. 232 б.
7. Толымбайский Г. «Адәмнәр» // Татарстан. 1924, 9 гыйнвар.
8. Халит Г. Герои, рожденные революцией. Казан: Татар. книгоиздат., 1967. 258 с.
9. Харрасова Р. Г. Ибраһимовның «Адәмнәр» повесте // Галимҗан Ибраһимов һәм XXI гасыр. Казан, 2007. Б. 12–124.
10. XX гасыр татар әдәбияты тарихы: 2 томда. Казан: Казан университеты, 2011. 1 т. 230 б.


## КОНЦЕПТ *ПРОСТРАНСТВО* В ПРОЗЕ Г. ИБРАГИМОВА


***Миргалимов И.Ф.***



В данной статье концепт *пространство* определяется особым исследовательским интересом, как единица сознания, развивающимся в рамках антропоцентрического подхода к языку в творчестве Г. Ибрагимова. Пониманию сущности концепта *пространство* в творчестве Г. Ибрагимова способствовало обнаружению и раскрытию устойчивой индивидуальной ассоциации *природа – лес*, так как концепт *пространство* реализуется через глобальную оппозицию «мир – природа», где лексема *природа* выступает в значении места (поля, леса, горы, водные пространства).

In this article, the concept space is defined by a special research interest, as a unit of consciousness, developing within the framework of anthropocentric approach to language in the works of G. Ibragimova. An understanding of the essence of the concept of space in the work of G. Ibragimova contributed to the discovery and disclosure of stable individual associations of nature – the forest, as the concept of space is realized through the opposition of the global «world – nature», where the token nature is in the value space (fields, forests, mountains, bodies of water).


Наличие бинарных оппозиций, как «универсального средства познания мира, особенно активно используемого и осознанного как таковое в XX веке» [2, с. 38], в произведениях Г. Ибрагимова мир воспринимается как многочисленные взаимоисключающие явления, противоборствующие силы, как единство противоречий. Данные оппозиции, как и оппозиции «жизнь –

смерть», «счастье – несчастье», лежат в основе описания любой картины мира и носят универсальный характер. Однако если в общеязыковой картине мира левая часть оппозиции обычно маркирована положительно, а правая – отрицательно [2, с. 39].

Если рассмотреть прозу Г. Ибрагимова, то можно отметить, что концепт *пространство* представлен одной (глобальной в его мировосприятии) оппозицией – «дөнья (мир) – табигать (природа)», а также пронизывающими обе части оппозиции и подчиненными данной оппозиции категориями «протяженность» и «движение». Где лексема *табигать* выступает в значении «место вне городов (поля, леса, горы, водные пространства)» [4, с. 430].

Особенностью творчества именно этого автора является то, что правый член универсальной оппозиции («природа») реализуется, прежде всего, через такой компонент концепта *пространство*, как *Урман (Лес)*.

Именно Лес занимает пространство вне села и организует пространство в целом. Характерно, что Лес мыслится обобщенно: *Башын бер читкә янтайта төшеп, сагаеп, тынын кысып* ***урман*** *ягына колак салды ул («Кызыл чәчәкләр»)* [1, с. 32]. *Урта бер җирдә, юлга* ***урман*** *тоташа. («Көтүчеләр»)* [1, с. 98].

Автор не вдается в детализацию, редко упоминает названия растений и животных, не выделяет каких-либо запоминающихся объектов, неповторимых особенностей рельефа: *Читтәрәк үскән чәчәкләрне күрмичә ул кинәт туктап калды, тезләренә төште һәм, бөтен җир шарын кочып алырга теләгәндәй, кочагын киң җәеп,* ***урман аланына*** *капланды... («Көтүчеләр»)* [1, с. 165]. В описаниях «лесных» пейзажей вообще преобладают формы множественного числа: *Шыр ялангач калган* ***агачлар*** *аңа бәхетсезлек турында хәбәр итә кебек тоелды. («Табигать балалары»* [1, с. 132]; *Урман эчендә исә агач ботаклары һәм куе урман үләннәренең күләгәсе шомлы итеп җиргә төшкән бер вакыт иде бу («Көтүчеләр»)* [1, с. 296].

Немаловажным для реализации концепта нам представляется тот факт, что Лес в произведениях Г. Ибрагимова не только мыслится обобщенно, но и предстает как идеализированное, во многом романтизированное пространство. Главный герой произведения *«Табигать балалары»* стремится попасть в Лес. Таким образом, Лес воспринимается, прежде всего, как альтернатива Дому. Это подчеркивается через целую систему конкретных номинаций живой природы (растения, звери и птицы), присущих лесу, а также через указание времяпрепровождения, типичного для сельского жителя, вырвавшегося на природу (собирание грибов, ягод, цветов и т.п.): *Урманнарыбыз искиткеч безнең:* ***җиләк, гөмбә*** *җыеп бетермәслек була («Табигать балалары»)* [1, с. 345]. *Урманга кузгалак, какы, җиләк җыярга баргач, үләннәр, аларга кунып ялтыраган чык тамчылары, һавадан нокта булып кына күренүче тургайлар турында әллә ниләр сөйләп бетерә иде («Татар хатыны ниләр күрми»)* [1, с. 338].

Но Лес отнюдь не всегда безопасен. С радужными и идиллическими соседствуют откровенно устрашающие картины, изображающие своего рода дикий Лес. Страх перед Лесом, по мнению З.Г. Салямовой, «соотносится с семой архетипического значения леса как враждебного человеку топоса, являющегося средоточием опасности», причём актуализируется данное архетипическое значение «всегда, вне зависимости от творческой индивидуальности писателя» [4, с. 12]. Характерно, что в этом случае Лес не только

олицетворяется, но и персонифицируется. Его заполняют уже не *деревья*, *цветы* и *ягоды*, а *чаща*, *бурелом*, *коряги*, *пни* и *корни*. В Лесу и над ним царствует *мрак*, подобный первобытному Хаосу, еще не разделенному на землю и небо, свет и тьму, день и ночь: *Әйләнә-тирәне томалап алган* ***дөм караңгылык****, җил һәм агачлар шавы күңелгә шом өстәп тора... («Тирән тамырлар»)* [1, с. 498]; ***Агачлар шомы*** *аңа киләчәк бәхетсезлекләрдән хәбәр бирә кебек. («Тирән тамырлар»)* [1, с. 484]*; Мәһабәт имәннәр янынннан узганда да күңеле сискәнмәде, йөрәккә* ***шом салып****,* ***куе агачлар*** *арасыннан үрелеп карап калган зур төпкә дә борылып та карамады... («Тирән тамырлар»)* [1, с. 499].

Лес – ядро пространства в произвдениях Г. Ибрагимова. Помимо этого в его произведениях можно обнаружить такие номинации, связанные с правым членом оппозиции, как *җир (земля), кыр (поля)*: *Моң, караңгы җир йөзе гакес итте нурлар бөркелеп. («Тирән тамырлар»)* [1, с. 502]*; Ә көннәр бер-берсенә үтә дә охшаган иде: иртән кояш белән торасың, кое суында бит чылаткач, ашап аласың да, кыр яисә урман эшенә китәсең («Көтүчеләр»)* [1, с. 347].

Лес для Г. Ибрагимова – это принадлежность к живому, другой мир, который параллельно живет с человеческим миром.

Значительно реже встречаются номинации различных водоемов – *елгалар (реки), күлләр (озера), чишмәләр (ручьи)*. Вместе с тем данные компоненты также мыслятся предельно обобщенно – обычно используется форма множественного числа. Кроме того, они не существуют самостоятельно, а вовлечены в реализацию ключевого компонента пространства – Леса. Река, Озеро, Ручей либо граничат Лесом, либо находятся в Лесу. Характерно, что Реки, Озёра и Ручьи не представляют собой препятствий на пути героя и не становятся источниками опасности:

*Җәй шулай, әмма кышлар, кышлар авыр инде. Елга боз астына кача, карт урман ак кар белән кәфенләнеп, тагы да картаярак төшкән шикелле күренә; көннәр кыска, төннәр озын авыр, басынкы һәм куркыныч. («Көтүчеләр»)* [1, с. 349]; *Тауның кара көйгән зур ташлары арасыннан шаулап куәтле елга төшә. («Көтүчеләр»)* [1, с. 342]; *Урманда сулар-елгалар агып китәр. Аннан соң җирләр кибәр. Без, ди, былтыргы кебек кардан ашлык башаклары җыярбыз. («Тирән тамырлар»)* [1, с. 511].

В соответствии с тем же архаическим и традиционным русским пространством Море, не свойственное средней полосе России, всегда находится далеко и принадлежит другому пространству, «краю земли»: *Тулган айны күрмәде, ялтыраган күл аңа сихерле* ***диңгез*** *кебек тоелды, үткен күзенә авыл читендәге тирмә янына бәйләнгән иярле ат чалынды («Тирән тамырлар»)* [1, с. 509].

Удалённость «чужого», «другого» пространства подчёркивается тем, что оно может простираться до моря (океана). Это соответствует мифологическим представлениям, согласно которым море (океан) является воплощением иного, дальнего мира.

Помимо этого Море в соответствии с общеевропейской романтической традицией выступает символом абсолютной свободы, абсолютно открытого пространства:

*Диңгез сулары кебек зәңгәрләнеп уйный торган зур, матур күл буена утырганга, бу авылны Зәңгәр чишмә дип атыйлар... («Кызыл чәчәкләр»)*

[1, с. 158]; *Моны юкка кұл диләр. Бу бит диңгез. Диңгезнең дә матуры, зуры! («Кызыл чәчәкләр»)* [1, с. 162].

В произведениях Г. Ибрагимова пространство воспринимается как равнина, гора, возвышенности, поле: *Мәрхүмнең балалары Кавказ тауларындамы, Азия чүлләрендәме, башка бер җирләрдәме үлеп калсалар, бердәнбер варисы ул булачак иде. Карт моны уйлап, туганының әйберләре әрәм-шәрәм булмасын дип өйгә керде. («Адәмнәр»); Тышта салкын һава уйный. Җил тәрәзә төбендә, морҗаларда ажгырып нәрсәләрнедер каерырга-җимерергә азаплана да, ахры, булдыра алмаганга ачудан киң яланнарга, каршы тауларга, урманнарга елап кача... («Адәмнәр»); Басуны әйләндек, арба тутырып яшел печән төядек тә иң еракка – борчак җирләренә килеп чыктык («Кызыл чәчәкләр»)* [1, с. 169].

Горы, скалы, заснеженные Вершины не встречаются на пути героя (они, как и Море, вне «своего» пространства), а только виднеются на горизонте, становясь, как и Моря, своего рода контекстными синонимами слова «далеко». Холмы и Овраги, напротив, – это часть «своего» пространства. Они вовлечены в реализацию ключевого компонента внегородского пространства – Леса.

Стойкость двухчленной оппозиции обеспечивается ещё и отсутствием других равнозначных сфер. Деревня относится к Лесу благодаря своей «естественности», близости с природой, отсутствию больших населенных пунктов.

Таким образом, Лес представляется Г. Ибрагимову очень обширным, вмещающим в себя множество городов, лесов, водоёмов, с одной стороны, пёстрым, как лоскутное одеяло, а с другой – в некоторой степени однообразным пространством. Как будто герой смотрит на него сверху, причём с достаточно большой высоты.

ЛИТЕРАТУРА

1. Ибраһимов Г. Сайланма әсәрләр. Казан: ТаРИХ, 2002. 642 б.
2. Руднев В.П. Словарь культуры XX века. М.: Аграф, 1997. 384 с.
3. Салямова З.Г. Натурализм в творчестве Галимджана Ибрагимова: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2004. 23с.
4. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан: Матбугат йорты, 2005. 848 б.

## С. ПОВАРИСОВНЫҢ ТАРИХИ-БИОГРАФИК ТРИЛОГИЯСЕНДӘ ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ОБРАЗЫ

***Мотыйгуллина Ә.Р.***

В статье содержится анализ трёх романов о татарском прозаике, общественном деятеле Галимджане Ибрагимове С. Поварисова. Особое внимание уделяется приёмам и способам раскрытия биографического героя Галимджана. Выявлена специфика авторской позиции.

The article contains the analysis of the three novels about the Tatar prose writer, public figure the Galimdzhana Ibragimov S. Povarisov. Special attention is given to techniques and methods of disclosure of the biographical hero Galimdzhana. The specificity of the author’s position.

*Килер заман, һәр язучының үзен,*
*сүзен вә шәхси тормышын инәсеннән*
*җебенә кадәр тикшереп чыгарлар әле.*

Г. Тукай

Халык үзенең үткәнен, бөек шәхесләрен бервакыт та онытмаган. Һәр шәхес даими рәвештә искә төшерелеп, хатирәләрдә яңартылып торган. Үткәнне яңартуның бер жанры – ул тарихи-биографик романнар. Аларда аерым шәхеснең тормыш юлы, эшчәнлеге яктыртылып, сәнгатьчә сурәтләү чаралары белән баетыла. И. Нуруллинның Г. Тукай һәм Ф. Әмирхан турындагы китаплары, Ш. Маннурның «Муса» романы, К. Миңлебаевның «Бакый» романы, С. Поварисовның Г. Ибраһимовка багышланган трилогиясе һ.б.

Күренекле язучы, җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимов турында беренчеләрдән булып хатыны Өммегөлсем Мөхәммәдова 1960–970 елларда «Яшьлек көннәре» дигән повесть яза. Әсәрнең беренче кисәгендә ул Г. Ибраһимовның шәкертлек елларын сурәтли. Оренбургта уку елларын әдипнең «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясенә таянып яктырта. Ө. Мөхәммәдова Галимҗанның Уфадагы «Галия» мәдрәсәсендә укуы чорына аеруча киң туктала. Уку йортының мөдәррисе Зыя Камали, башка күркәм остазлар тирәсендә аның рухи җитлегүенең эволюциясен күрсәтә.

Күренекле галим С. Поварисов гомере буе Г. Ибраһимов иҗаты, шәхесе белән кызыксына. Башта 1974 елда ук Уфада «Г. Ибраһимов стиленең үзенчәлекләре һәм аларны мәктәптә өйрәнү» дигән методик кулланма бастырып чыгара. 1980 елда исә, әдәбият дәресләрендә куллануны максат итеп, «Г. Ибраһимов прозасында образлар системасы» дигән икенче хезмәтен тәкъдим итә. Шул рәвешле, әдипне өйрәнү берничә дистә елга сузыла.

Ул әдип һәм галим буларак әлеге зур эшкә бик озаклап һәм җентекләп әзерләнә, дистә еллар дәвамында аның туган авылы Солтанморатка кайта, анда яшәгән халык белән аралашып, бай материал туплый, һәр очраган мәгълүматны теркәп бара, архивларда эзләнә, төрле фактларны чагыштыра, бер эзлклелеккә сала.

Озак еллар дәверендә эзләнүләрнең нәтиҗәсе буларак С. Поварисовның фәлсәфи мотивларга корылган трилогиясе «Пәйгамбәр таңы», «Күкнең җиденче катында», «Оҗмахка бер адым» «Казан утлары» журналында, соңыннан китап булып басылып чыга. Беренче карашка, әйтерсең лә, ул – пәйгамбәрләр, фәрештәләр турындагы әсәр. Ә аның каһарманы җир кешесе, язучы, олуг галим, милләт, халык өчен бөтен барлыгын биргән шәхес Г. Ибраһимов. *Әдип турында «Галимҗан Ибраһимов – үзе яшәгән заман кебек катлаулы һәм каршылыклы язмышка ия кеше. Ул әдип, галим буларак та, җәмәгать эшлеклесе, шәхес буларак та бүгенге көнгә кадәр бөтен тулылыгы белән ачылып җитмәгән әле»,* – дип яза кереш сүздә Рөстәм Акъегет [4, б. 4].

Галимҗанның балачак һәм яшүсмер еллары трилогиянең беренче кисәге «Пәйгамбәр таңы»ында сурәтләнә. Әдипнең шәхес буларак формалашкан еллары һәм гомеренең соңгы көннәре «Күкнең җиденче катында» һәм «Оҗмахка бер адым» романнарында тасвирлана.

Трилогиянең беренче кисәгендә Галимҗан Ибраһимовның 1887–1906 еллар аралыгындагы тормышы гаҗәеп гыйльми дөреслеккә нигезләнеп

бирелгән. Роман алты бүлектән тора. Сюжет сызыгы Галимҗанның гомер юлын колачлый.

Роман «Бала көткәндә» дигән бүлектән башлана. Романнарның буеннан-буена автор пәйгамбәр сүзен кабатлый. Иң элек Галимҗанны пәйгамбәр дип атасы Гыйрфан мулла әйтә һәм әлеге сүзне язып куя: «*Уянып киткәч, һушына килә алмыйча, озак кына иңке-тиңке килеп утырды ул. Шуннан киштәдәге Коръәнне алып, беренче битенең үк бер кырыена «Пәйгамбәр таңы» дип язып куйды*» [1, б. 33].

Дини фәлсәфәне дә ныклап өйрәнгән автор Галимҗанның дөньяга килүен сурәтләгән күренешне, борынгы дини китаплардагыча, уратып-уратып, тирән мәгънәләр белән бәйләп бирә. Шул рәвешле, Галимҗанның туган көне пәйгамбәр таңы дип билгеләнә. Димәк, бу – әлеге баланың гадәттән тыш җан иясе буласына ишарә. Галимҗанның атасы Гыйрфан мулла «*бер тәмле-татлы төш күрде...: «Шуннан Җәбраил фәрештә аның колагына өрде, аннан йөрәгенә керде. Гыйрфан гадел сахабәгә әйләнде. Ул да әйтте: «Балаң пәйгамбәр таңында туды, пәйгамбәрләрне заман-дәвер барлыкка китерә, улың дәвер пәйгамбәре булыр*», – диде» [1, б. 33].

Галимҗанга исемне әтисе Гыйфран мулла куша. Әтисе аңа туган көненнән үк зур өметләр баглый, улының киләчәктә зур ачышлар ясыячак киләчәк дәвер пәйгамбәре – галим кеше булачагына ышана. Исеме дә Галим, үзе дә бөек бер галим булсын дигән теләктә, Алла исеменнән «җан» сүзен дә өстәп куюны мәслихәт таба.

Галимҗан Ибраһимов шәхесен сурәтләү өчен автор психологик яктан нык тәэсир итәрлек күренешләрне тасвирлый. Моңа мисал итеп, Ибраһимовның күзен каләм белән тишүен алырга була. Әмма әлеге күренешләрне автор ике урында төрлечә бирә. Беренче кисәктә: «*Давылда туган улларының... «халык дошманы» дигән «дан» алачагын, шуны раслау өчен кулына каләм биргәч, шул каләмнең очлы ягы белән җан ачуы килеп үз күзенә үзе кадаячагын болар һич кенә дә акылларына китерә алмыйлар иде, билгеле*» [1, б. 33]. Өченче кисәктә: «*Шуннан «мужик», нәрсәдер эшләргә кушып, тегеләргә бармагы белән ниндидер билге күрсәтте. Алар икесе ике яктан Ибраһимовны беләкләреннән килеп тотулары булды, «мужик» ручкасын Галимҗанның күзенә атты. Күзләрдән кан чәчрәп чыкты. Шуннан соң аны вәхшиләрчә кыйнарга тотындылар. Изделәр-изделәр дә үлекләр бүлмәсенә чыгарып ыргыттылар*» [3, б. 462].

Халкыбызның яшәү рәвешен, гореф-гадәтләрен, йолаларын С. Поварисов бик белеп һәм җиренә җиткереп сурәтли. Романда шулай ук Галимҗанның туган авылы, аның табигате, халкы зур урын алып тора. Укучы романны укыганда, үзе дә сизмәстән Солтанморат авылының елгаларына, тугайларына, урман, таш-тауларына тартыла башлый.

Роман бүлекләренең исеме ата-ана исеменнән әйтелгән сүзләргә (фатиха) нигезләнә. (1 нче бүлек: «Бала көткәндә»; 2 нче бүлек: «Тәпи басып киткәч...»; 3 нче бүлек: «Бәла – аяк астында...» һ.б.) Шуны дәлилләп һәр бүлектә «Ана фатихасы»ннан юллар китерелә. Әйтик:

«*Карынымны ярып чыктың, балам – гөлем,*
*И күз нурым, йөрәк-бәгърем, якты көнем;*
*Үс сөелеп иман белән, булып матур,*
*Сынма җилдә, давылларда нык, каты тор!*»
*(Ана фатихасы).*

Әсәрдәге шигъри текстлардан тыш поэтик-стилистик яктан баету чарасы буларак мәкаль-әйтемнәр, төрле тапкыр фразеологизмнар кулланыла. Әдип халыкчан сурәтләрдән, чагыштыру-метофоралардан уңышлы файдалана: «*Кызлы йорт – кызыклы йорт*», «*Ни чәчсәң шуны урырсың*», «*Булырдайның буыныннан билгеле*», «*Ходай язмаган эш булмас*», «*Алгы итәгеңне бала бассын, арт итәгеңне мал бассын*», «*Бармаклар да тигез түгел*», «*Ата сүзе-иман*», «*Ата әйтә-хак әйтә*», «*Ата йөзе – ил йөзе*», «*Күз өчен Җәй яхшы, авыз өчен Көз яхшы*», «*Аяк тәпелдәмәсә, авыз чәпелдәми*», «*Җәйнең җәймәсе киң, ләкин дә җәелеп утырмауны бел*», «*Күңел пыяла – дөрес чиртмәсәң – уала*», «*Йолдыз караңгыда яктырак яна*», *Суның тирәнлеген таяк белән, кеше акылын теле-фикере белән үлчиләр*», «*Сөйдергән дә тел, биздергән дә тел*», «*Күңеле аламаның теле алама*» һ.б. Автор халыкчан сурәтләүләрне кулланып, геройның кечкенәдән мәгълүматлы, фикерле икәнлеген күрсәтергә тели.

Тынгы белмәс холкы, аң-белемгә омтылуы Галимҗанны «Хөсәения», «Галия» кебек шул чорның күренекле мәдрәсәләренә алып килә. Аңа кадәр әтисе Гыйрфан хәзрәттән укырга-язарга өйрәнгән зирәк малай Оренбурдагы «Вәли» мәдрәсәсенә укырга бирелә. Тумыштан ук дөньяга ачык күз белән карап, хәлфәләр өйрәткәннән күбрәк белергә омтылган малайны биредәге уку программасы һәм укыту барышы һич кенә дә канәгатьләндерми. Нәтиҗәдә, 17 яшьлек яшүсмер мәдрәсәдән куып чыгарыла. Бу аның шәхес булып формалашуы өчен хәлиткеч адым була.

Шул рәвешле, трилогиянең беренче кисәге бу дөньяга бәхетле булырга, туры үз максатына ирешеп баручы Галимҗанның 1906 елда Уфадагы «Галия» мәдрәсәсенә укырга китүе белән тәмамлана. Роман Хәсәнә абыстайның «И Ходаем, балаларга, барлык бәндәләргә бәхет бир, бозыклыклардан сакла, илдә тынычлык булсын», – дигән теләкләре белән төгәлләнә [1, б. 287].

Трилогиянең «Күкнең җиденче катында» дигән кисәге Галимҗанның шәхес, фикер иясе булып формалашуының, дөньяны танып-белүенең һәм алдагы көннәргә юл эзләвенең, адашулар-сөрлегүләр аша, ниһаять, үзен илһамландырган юлга төшүенең катлаулы тарихын сурәтләүгә багышланган. Аның күзаллаулары, төрле хәлләрдә бихисап кешеләр белән аралашуы, илдәге катлаулы вакыйгаларны бәяләве аша без шул еллар мохитен, мәгълүм шартларда Г. Ибраһимовның тулаем җәмгыятькә мөнәсәбәттә карашлар системасы барлыкка килүен күрәбез.

1906 елның көзендә ул Уфага килә һәм әле яңарак кына ачылган «Галия» мәдрәсәсенә укырга керә, анда өч ел укый. «Галия» мәдрәсәсе Г. Ибраһимовның тормышында тирән эз калдыра, аның рухи офыгы киңәюгә, әдәбият дөньясына тартылуына уңай йогынты ясый. Нәкъ менә шушы чорда аның беренче әдәби әсәрләре дөнья күрә башлый. «Галия» мәдрәсәсеннән киткәч, Г. Ибраһимов берникадәр вакыт казакъ далаларында, Уралда төрле эшләрдә эшләп йөри. Әстерханның нугай татарлары арасында мөгаллимлек итә һәм 1909 елның ахырларында Казанга килә.

Казанда яшәгән бу беренче чорында (1909–1912) Г. Ибраһимовның иҗат активлыгы аеруча көчәя. Ул үзенең инкыйлабка кадәрге иҗатында күренекле урын тоткан романтик хикәяләрен, «Яшь йөрәкләр» (1912) романын яза. Бу әсәрләрендә композиция һәм сюжет төзү осталыгы, образлар тудырудагы психологик тирәнлек, тел-сурәтләү чараларының байлыгы

Г. Ибраһимовны шул заманда ук татар прозаикларының алгы сафында баручы сүз остасы итеп таныта.

Трилогиянең икенче кисәге әнә шулай бу дөньяга зур эшләр килгән һәм инде күп яктан максатына ирешеп баручы 30 яшьлек ир затының эш-хәрәкәтләрен сурәтләүдән гыйбарәт. Аның әле Солтанморат авылында «патшаны төшерттерәсе», аннан Уфага кайтып, көрәшкә кушылып китәсе, «Ирек», «Безнең юл» гәзитләренә җитәкчелек итәсе, Уфадан Петербургка Оештыру җыены (Учредительное собрание) делегаты булып барасы, Русия Үзәк Мөселман эшләре комиссариаты җитәкчесе урынбасары вазифасын башкарасы, шунда «Чулпан» гәзитенә мөхәррирлек итәсе, язган әсәрләренең кайберләрен кабат үзгәртеп чыгасы һәм башка бик күп нәрсәләр эшлисе, Ялтада 10 ел дәвамында дәваланасы бар.

Бу чорда Г. Ибраһимов әдәби тәнкыйть һәм публицистика өлкәсендәге эшчәнлеген дә киң җәелдереп җибәрә. Мәкаләләрендә ул татар әдәбиятының барышына, аерым жанрларның үсешенә, гомумән татар матбугатына, сәнгатькә, милли театрга, әдәби телгә, тарихка бәйләнешле күп төрле актуаль мәсьәләләрне күтәреп чыга һәм аларны заманның алдынгы идея-эстетик карашлары нигезендә хәл итәргә омтыла.

Г. Ибраһимов Казанга килүгә «Казакъ кызы» романын язарга керешә. Г. Ибраһимов 1912 нче елда Киевка китә, мөселман студентлары җәмгыятендә эшли, аларның Бөтенроссия съездын оештыруда катнаша. 1913 елның апрелендә сәяси эшчәнлек алып барган өчен кулга алына. Шул вакытта «Казакъ кызы» романын да алып калалар. Ул романын сорап Киевка берничә тапкыр бара, әмма кире кайтармыйлар.

Казанга кайтып «Аң» журналында җаваплы сәркатип булып эшләгәннән соң, 1914 елны кабат Киевка китә, аннан Уфага кайта һәм 1915–1917 елларда кайчандыр үзе укыган «Галия» мәдрәсәсендә укыта. Бу чорда әдипнең эстетик һәм иҗтимагый карашлары тагы да ачыклана төшә, әдәби иҗатында җитди үзгәрешләр, яңа сыйфатлар барлыкка килә: ул үз әсәрләрендә иҗтимагый проблемаларны кыюрак күтәрә башлый, хезмәт кешеләренең реалистик образларын сурәтләүгә таба кискен борылыш ясый.

Шул рәвешле, трилогиянең икенче өлеше шулай ук гыйльми дөреслеккә туры китереп язылган. Һәрбер күренешне язучы тел-сурәтләү чаралары ярдәмендә һәм, әлбәттә, үз фантазиясен эшкә җигеп сурәтли. Трилогиянең әлеге кисәгендә Галимҗанның барлык көче халык бәхете, бәхетле тыныч тормыш өчен бирелгәнлеге тасвирлана.

Трилогиянең өченче кисәгендә С. Поварисов зур җәмәгать, фән эшлеклесе Г. Ибраһимовның «халык дошманы» дигән кара ягылганнан алып, төрмәдә вафат булуына кадәрге тормыш юлын яктырта. 1917 елгы Февраль революциясеннән соң актив рәвештә иҗтимагый-сәяси тормышта катнаша башлый. 1917 елны язучы Ф. Сәйфи-Казанлы һәм журналист Ш. Сүнчәләй белән бергә «Ирек» газетасын чыгара. Ул татар-башкорт мөселман сул эсерлар партиясенең оештыручылары һәм җитәкчеләренең берсе. 1917–1918 елларда Милләт Мәҗлесе һәм Учредительное собрание депутаты. 1918 елда М. Вахитов һәм Ш. Манатов белән берлектә РСФСРның Милләтләр эшләре буенча халык комиссариаты карамагындагы Үзәк мөселман комиссариатын оештыруда катнаша, комиссар урынбасары була. 1919–20 елларда Үзәк мөселман хәрби коллегиясе әгъзасы, бер үк вакытта РКП (б) ҮК каршындагы Шәрекъ халыклары коммунистик оешмаларының Үзәк бюросында мат-

бугат бүлеге редколлегиясе җитәкчесе, «Кызыл Шәрекъ» журналы хезмәткәре. 1920 елдан ТАССР Мәгариф халык комиссариатында. «Безнең юл», «Мәгариф» журналларының оештыручысы һәм мөхәррире, 1925–27 елларда Гыйльми Үзәк җитәкчесе, бер үк вакытта Татарстан төбәкләрен өйрәнү бюросы рәисе.

Нинди генә дәрәҗәләргә ирешмәсен, 1937 елның 29 сентябрендә Г. Ибраһимов кулга алына. Кичен Г. Ибраһимов һәм аның тормыш иптәше бүлмәсенә өч НКВД кешесе килеп керә. Бүлмәнең астын өскә китереп тентиләр, Г. Ибраһимовны кулга алалар, ә аның тормыш иптәше Хәдичә ханым, ире артыннан ияреп, Казанга китә. Ләкин аны да «халык дошманының хатыны» дип төрмәгә кертеп ябалар, бер ай буе җәзалыйлар, ә чыгаргач ул «*анасыннан аерылып калган бәбкәдәй, ялгыз башын кая куярга белмичә, шәһәр урамнарында аптырап йөри*» [3, б. 428–429]. Хәдичә шулай урам буйлап йөргәндә, хәлсезләнеп, һушын югалтып егыла. Бәхетенә күрә аны изге күңелле кешеләр өйләренә алып кайтып ашатып-эчертәләр, яңа киемнәр бирәләр. Бу кеше Г. Ибраһимов ябылган Пеләтән төрмәсендә эшләгән сакчы Нурмөхәммәт була. Нурмөхәммәт – изге күңелле кеше, ул Г. Ибраһимовны коткару уе белән янып-көеп яши. Ул гына да түгел, бу төрмәдә эшләгән Фатыйма исемле табибә ханым да Г. Ибраһимовны ничек тә булса коткарырга кирәк дип уйлый. Алар, җае чыкканда, очрашуын да оештыралар. Кызганычка каршы, Фатыйма белән Нурмөхәммәтне дә төрмәгә утыртып куялар. Ит яхшылык, көт яманлык кебегрәк килеп чыккан бу хәл өчен Г. Ибраһимов соңгы сулышына чаклы кайгыра.

Төрмәдә сорау алу вакытында Г. Ибраһимовка күп тапкыр «халык дошманы» булуын танып, кул куюын таләп итәләр. Ләкин ул үз кыйбласына тугры булып кала. Соңгы сорау вакытында аны бик каты кыйныйлар. 1938 елның 21 гыйнварында ул үлә.

Шул рәвешле, С. Поварисов үзенең Г. Ибраһимов тормышы һәм эшчәнлеге хакында булган трилогиясенең өченче кисәгендә репрессия елларында илнең алтын баганасына торырлык ватан каһарманнарының харап булуы хакында ачынып яза. Совет властен оештыру һәм ныгыту өчен көчен һәм сәләтен кызганмаган, коммунистлар партиясенең һәр карарын тормышка ашыру өчен хәтта фанатикларча хезмәт иткән көрәшче-революционерның шундый хәлгә дучар булуы аны тетрәндерә, аптырашта калдыра.

Шулай итеп, күренекле галим С. Поварисов Г. Ибраһимов турында әдәби әсәр язып, тарихи үткәннәрне искә төшерә, халык тарафыннан танылган әдипнең тормыш һәм иҗат сәхифәләрен сүз сәнгате чаралары ярдәмендә сурәтләүгә ирешкән.

## ӘДӘБИЯТ


1. Поварисов С. Пәйгамбәр таңы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 288 б.
2. Поварисов С. Күкнең җиденче катында. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 279 б.
3. Поварисов С. Оҗмахка бер адым. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. 464 б.
4. Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр / төз, кереш сүз авт Р. Акъегет. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. 543 б.

# Г. ИБРАҺИМОВ ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ РУСЧАГА ТӘРҖЕМӘЛӘРЕНДӘ РЕАЛИЯЛӘР

***Мөгътәсимова Г.Р.***

В статье рассматриваются наиболее частотные виды реалий, встречающиеся в рассказе Г. Ибрагимова «Диңгездә». Приводятся понятия для определения слов-реалий в отечественном переводоведении. Описываются различные приемы передачи слов-реалий на русский язык.

The article deals with the most frequent types of realities that occur in the story G. Ibragimova «Diңgezdә». The concepts for the definition of real-life words in Russian translation are given. Various methods of transmitting words-realities into Russian are described.

Г. Ибраһимов әсәрләре төрле телләргә тәрҗемә ителгән. Әлеге телләр арасында рус, үзбәк, башкорт, чуваш һәм башка телләрне атарга мөмкин. Без үзебезнең мәкаләбездә Г. Ибраһимовның «Диңгездә» хикәясенә [4, б. 16–31] һәм аның рус теленә тәрҗемәсе «На море» [3, б. 238–247] әсәренә игътибар итәрбез. Атаклы классик язучының «Кызыл чәчәкләр» повестен һәм дистәдән артык хикәясен, шул исәптән «Диңгездә» хикәясен дә Галимҗан Ибраһимовның йөзьеллык юбилеена хәзерлек уңаеннан, хикәяче-прозаик, тәрҗемәче Солтан Шәмси русчага тәрҗемә итеп, Татарстан китап нәшриятында ике аерым китап итеп бастырып чыгара.

Тәрҗемә – кешенең бик борынгы шөгыльләренең берсе. Аның барлыкка килүе телләр төрлелеге һәм этник төркем вәкилләренең аралашырга омтылуына нигезләнә. Мәдәниятара бәйләнешләрнең киңәюе һәм фәнни-техник белемнәрнең таралышы шартларында тәрҗемә белән кызыксыну тагын да арта.

Һәр халыкның мәдәниятенә, тормыш-көнкүрешенә, гореф-гадәте һәм йолаларына бәйләнешле сүзләр реалияләр дип йөртелә. Реалия аерым бер халык телендә, тормыш, яшәү рәвешендә киң кулланылыш алса да, башка телләр һәм халыклар өчен чит булып яңгырый, һәм башкаларда, гомумән кулланылмый. Әдәбият белгечләре һәм әдәби тәрҗемә осталарының фикерләренә караганда, әдәби әсәрнең милли бизәлеше реалияләр аша чагылыш таба. Әсәр үзенең темасы буенча халык тормышына никадәр якынрак торса, аның милли колориты шулкадәр ачыграк күренә.

Реалияләрне тәрҗемәдә дөрес бирү – тәрҗемәченең мөһим бурычларыннан берсе. Әлеге проблема гыйльми хезмәтләрдә бары тик XX гасырның 50 нче елларында гына күтәрелә башлый. Реалия атамаларын тәрҗемә итү милли һәм тарихи үзенчәлекләрне бирү процессында туган авырлыкларның зур өлешен алып тора. Милли колоритны чагылдыра торган сүзләр буларак, әйткәнебезчә, реалияләр бары илленче елларда гына өйрәнелә башлаган. Аларны Л.Н. Соболев, Г.В. Чернов, М.П. Алексеев, Г.В. Шатков, А.В. Федоров, Я.И. Рецкер, А.Е. Супрун кебек галимнәр тикшергән. Элек реалияләрне рус галимнәре экзотик лексика, безэквивалентная лексика дип атаганнар. Әлеге сүзләрнең һәммәсен милли, тарихи, җирле, көнкүреш төсмере, тәрҗемә телендә тәңгәллекләре булмау берләштерә. Алар – һәрвакыт табигый рәвештә халыкның милли карашы һәм көнкүреше белән тыгыз бәйләнгән сүзләр. Реалиягә чагыштырмача төгәл билгеләмәне С. Влахов һәм

С. Флорин биргән. Алар фикеренчә, «реалия ул бер халыкның тормыш-көнкүрешенә, социаль һәм тарихи яктан алга китүенә характерлы булган, икенче халыкта исә, киресенчә, чит-ят булган объектларны белдерә торган сүзләр» [1, б. 73].

Гомумән, әдәби тәрҗемәнең күп кенә мәсьәләләре әсәрнең милли колоритын саклау һәм тәңгәлләштерүгә бәйле. Тәрҗемәче теге яки бу илнең тормышын, гореф-гадәтләрен, йолаларын, гомумән, милли үзенчәлекләрен чагылдырган кайбер реалияләрне тәрҗемә иткәндә, кыенлыклар кичерә. Тәрҗемә, иң беренче чиратта, укучыга аңлаешлы адекват мәгънәгә ия булырга тиеш. Әгәр дә бу үзенчәлек тулысынча исәпкә алынмаса, тәрҗемәдә текстның «экзотизация»се барлыкка килә, әгәр дә кирәгеннән артык бирелсә, «креолизация» барлыкка килә.

Реалияләрне тәрҗемәдә биргәндә, кайбер кыенлыклар белән очрашырга туры килә. Мәсәлән, тәрҗемә ителә торган телдә тәңгәл килгән сүз, эквивалент, аналог булмавы; реалиянең мәгънәсе (семантикасы) белән беррәттән, колоритын, милли һәм тарихи үзенчәлеген бирү зарурлыгы. Р.А. Юсупов билгеләвенчә, реалия атамаларын чыганак телдәгечә куллану укучыга чыганакның милли колоритын тоярга мөмкинлек бирә [6, б. 128].

Г. Ибраһимов әсәрләрен тәрҗемә иткәндә дә реалия атамаларын тәрҗемә итү шактый авырлык тудыргандыр. Тәрҗемәче С. Шәмси төрле тәрҗемә алымнары кулланып тәрҗемә иткән. Реалия атамаларын тәрҗемә итүдә транслитерация алымы күренә. Әлеге берәмлекләр арасында төрле өлкәләргә караганнары бар: дини лексика (Җәбраил, әссәламегаләйкем, фәрраш, мәчет, хәзрәт, мәдрәсә, шәкерт һ.б.), ономастик лексика (Нурый, Әстерхан, Мәккә, Мәдинә һ.б.). Мәсәлән, *Жаның гарешләрдә, күңелеңдә изгелек тулы, сөю тулы, гыйшык тулы, тәннең иблисе җеңелеп тапталган, сиңа* ***Җәбраил*** *юлдаш булган – Душа витает в голубых просторах, ты полон милосердия, люви и счатья, дьявол в тебе убит и растоптан, и сам* ***Джабраил*** *тебе спутник;* ***Әссәламегаләйкем****, нихәл? –* ***Ассалям алейкум****!.. Как дела, сынок?; Ул үзенең Нуретди****н*** *икәнен, ләкин халык телендә* ***«Фәрраш Нурый»*** *дип йөртелгәнен, ... сөйләп алды. – Он назвал себя Нуретдином, но люди, оказывается, зовут его* ***фарраш Нури****; ... күп еллардан бирле* ***Әстерханның*** *зур* ***мәчетләреннән*** *берсендә фәрраш булып торганлыгын ... – ... уже многие годы служит в одной из больших* ***мечетей Астрахани*** *... ;* ***Хәзрәт*** *яхшы кеше булган –* ***Хазрет*** *был человеком добрым ... .*

Тәрҗемәдә транслитерация алымын кулланып, С. Шәмси кайбер төгәлсезлекләр дә җибәргән. Мәсәлән, *Сәйфи* исемен *Сафа* дип тәрҗемә итә: *Нурый бабайның бәхетенә каршы, шул мәхәллә мәчетенең фәррашы* ***Сәйфи*** *карт үлеп китә, ... . – К его счастью, дед* ***Сафа****, служитель мечети, неожиданно умер.* Шулай итеп, русчага тәрҗемәдә башка бер персонажны күрәбез.

Тәрҗемәче кайбер татар сүзләрен русча аңлату ысулы белән биргән. Мәсәлән, *Ишанның олы* ***хәлфәләреннән*** *берсе Нурый бабайга үзенең йөзле әйбәт тәсбихын да биргән – Один из ближайших к ишану* ***наставников*** *подарил ему дорогие четки; Әйләнсәм, каршымда бер татар карты: кыска буйлы, ябык, нечкә, бераз бөкерерәк гәүдәле, алгарак очланып килгән иягендә берничә бөртек сакалы, җеп кебек кенә калдырып кырылган мыек; өстендә иске* ***җилән****, ... – Обернувшись, увидел перед собой старика-татарина: небольшого роста, щупленький, сутуловатый, на остром подбородке козлиная бородка, усы в ниточку; на плечах* ***летнее пальтишко****.... Җилән*

ул – эченә мамык куймый гына киң итеп теккән элекке милли өс киеме (хәзерге җәйге пальтога бераз охшаган) [5, б. 778]. Татарча-русча сүзлекләрдә исә әлеге сүзне *джиля́н, азя́м (летнее пальто, пыльник)* дип тәрҗемә итәләр [2, б. 73]. «Диңгездә» әсәренең тәрҗемәсендә нәкъ шулай бирелгән булса, бу реалия рус халкы өчен аңлашылмаган булыр иде. Бу очракта тәрҗемәче С. Шәмси уңышлы ысул сайлаган.

С. Шәмси «Диңгездә» хикәясен тәрҗемә иткәндә, функциональ алмаштыру ысулын да, ягъни функциясе белән татар реалиясенә якын торган күренешне белдергән сүзне куллана. Бу – бик җиңел ысул түгел, чөнки төрле ике халыкка хас реалияне чагыштыру мөмкинлеге һәрвакыт очрап тормый. Тәрҗемәче хикәядә очраган *ката* сүзен *галоши* лексемасы белән бирергә тәкъдим итә: *Әйләнсәм, каршымда бер татар карты: ... аягында кырылып беткән иске читек белән зур **ката**, ... – Обернувшись, увидел перед собой старика-татарина: ... обут в ичиги и **галоши**.... **Ката*** – кыска кунычлы киез яки күн аяк киеме [5, б. 240], ә ***галош*** – күн яки киез аяк киемнәрен юешләнүдән саклау өчен кия торган резин аяк киеме [1, б. 121]. Әлбәттә, төрле аяк киемнәре, әмма бер максаттан файдаланылганнар.

«Диңгездә» хикәясендәге реалия атамаларын тәрҗемә итү өчен, транскрипция алымы да күзәтелә. Әлеге алым ономастик лексиканы тәрҗемә иткәндә аеруча файдаланылган. Мәсәлән, *Ул үзенең **Нуретдин** икәнен, ... сөйләп алды. – Он назвал себя **Нуретдином**, ....*

Тәрҗемәче татар халкына хас кайбер кием-салым атамаларын, дини лексиканы да русчада транскрипция ысулы белән бирә: *Житез карт **ишанга** мөрит тә булып өлгергән – Оказалось, что бойкий старик успел стать мюридом **ишана** и обласкан им; Ул, **чалма**, җилән, читек, кәвеш киеп, бушаган араларда мәчеткә дә йөри башлый – Урвав от службы время, он все чаще появлялся в мечети в **чалме** и халате... .* Ә менә җөмләдәге кайбер кием-салым атамаларының гомумән тәрҗемә ителмәвен исә җитди җитешсезлек дип атарга була.

Шулар белән беррәттән, тәрҗемәченең күп кенә этнографик реалияләрне бөтенләй төшереп калдыруы тәрҗемә әсәренең сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәсен киметә. Мәсәлән, ***Шәкертләргә дә, хәлфәләр дә** бик ярый, ни кушсалар, шуны эшли – Нури и здесь служил хорошо, исполнял все, что ни прикажут; Ләкин Нурый, кара эшне, кара халыкны яратмаганга, һаман да **мулла, мәдрәсә, мәчет тирәсендә** берәр хезмәт эзли – Отвыкший от тяжелой работы Нури стал искать себе место **при мечети**, так как успел привыкнуть к служителям культа.*

Нәтиҗәдә, Г. Ибраһимовның «Диңгездә» хикәясендәге реалияләрне тәрҗемә итүдә транслитерация алымының өстенлек итүен күрәбез. Бу ысул күп очракта уңышлы булып чыга. Тәрҗемә аша бирелгән реалияләр арасында милли колоритны дөрес тоярга мөмкинлек биргәннәре күбрәк, ә аларны төшереп калдыру очраклары исә эчтәлекне бозуы ачыкланды.

Татар әдәбиятының күренекле әсәрләрен рус укучыларына җиткерү – тәрҗемәче өчен бик җаваплы һәм мактаулы эш. Монда, беренчедән, Г. Ибраһимовның классик әсәрләре тәрҗемәсен бирә алган рус теленең көче, сүз байлыгы һәм, икенчедән, тәрҗемәченең дә осталыгы ачык чагыла.

ӘДӘБИЯТ


1. Влахов С., Флорин С. Непереводимое в переводе. М., 2006. 448 с.
2. Ганиев Ф.А. Татарча-русча сүзлек. Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. 463б.

3. Ибрагимов Г. Красные цветы. Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. 336 с.
4. Ибраһимов Г. Хикәяләр, повесть һәм роман. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. 463 б.
5. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан: Матбугат йорты, 2005. 848 б.
6. Юсупов Р.А. Тәрҗемә һәм сөйләм культурасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. 240 б.

# РУС ТЕЛЛЕ МӘКТӘПЛӘРДӘ Г. ИБРАҺИМОВ ИҖАТЫН ӨЙРӘНҮНЕҢ КАЙБЕР АСПЕКТЛАРЫ

***Мөкимова Н.Ә.***

В статье рассматриваются некоторые аспекты изучения творчества Г. Ибрагимова в общеобразовательных организациях основного общего образования с обучением на русском языке, а именно, вопросы изучения произведений писателя по нескольким образовательным программам, проблемы анализа культуроведческой лексики.

The article examines some aspects of the study of creativity G. Ibragimov in general education organizations of basic general education with teaching in Russian, namely, the study of works of the writer on several educational programs, the problems of analysis of cultural studies vocabulary.

Җәмгыятьтәге, белем бирү системасындагы, татар әдәбияты тарихы, әдәбият белемендәге яңарыш-үзгәрешләр мәктәптә «Әдәбият» предметын укытуга төрлечә тәэсир ясады. Моңа бәйле гомуми белем сыйфатына таләпләр, укыту программаларының эчтәлеге, дәреслекләрнең төзелеше турында яңа карашлар барлыкка килде. Әдәбият укытуны яңа нигезләргә кору, аның сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген күтәрү өчен методик алым-чараларны камилләштерү, укучыларны китап уку белән кызыксындыру – көн тәртибендә торган мәсьәләгә әйләнде. Д.Ф. Заһидуллина билгеләвенчә, «Мәктәптә әдәбият – иң әһәмиятле, кирәкле, файдалы предметларның берсе. Әдәбиятны өйрәнү, – барыннан да элек, әдәби әсәрнең, язучы иҗатының, чор әдәбиятының асылын аңлау, тикшерә-анализлый, төгәл бәяли белү дигән сүз ул» [1, б. 3]. Татар баласында татар әдәбиятын, милли гореф-гадәтләрне өйрәнүгә ихтыяҗ уяту гына түгел, ә әдәбиятыбызны, мәдәниятебезне белүче һәм киләчәктә аның үсешенә үз өлешен кертергә сәләтле һәм әзер балалар үстерү зарур.

Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучы татар балаларына «Татар әдәбияты» предметы Ф.Г. Галимуллин, З.Н. Хәбибуллина, Х.Г. Фәрдиевалар төзегән программа нигезендә һәм шул программа буенча әдәбият дәреслекләре буенча укытылып килде. Бу программа буенча, 5 нче сыйныфта Галимҗан Ибраһимовның тормыш юлы турында белешмә бирү, «Яз башы» хикәясен укып, кеше һәм табигать мөнәсәбәте, туган як табигатенең матурлыгы, аның белән хозурлану темаларының күтәрелүе һәм сәнгатьчә хәл ителешен өйрәнү каралган. 7 нче сыйныфта Г. Ибраһимовның иҗаты турында белешмә бирү, «Алмачуар» хикәясен өйрәнү, төп геройларның эчке кичерешләрен, хайваннарга карата миһербанлылык хисләренең бирелешен тикшерү күз уңында тотыла. 11 нче сыйныфта 1996 елда нәшер ителгән программа буенча «Казакъ кызы» романы өйрәнелсә, 2011 елда чыккан программада «Яңа кешеләр» драмасын өйрәнү тәкъдим ителгән иде [3].

Федераль дәүләт белем бирү стандартларында, башка бик күп таләпләр белән бергә, нәтиҗәле белем бирүдә күптөрле ресурсларны эченә алган мәгълүмати тирәлек булдыруга әһәмиятле урын бирелә [4, б. 46–47]. Әлеге вакытта татар теле һәм әдәбияты буенча, стандарт таләпләренә туры китереп, яңа укыту-методик комплекслары төзелә. Рус телендә гомуми төп һәм урта белем бирү оешмаларының татар сыйныфлары өчен татар әдәбиятыннан яңа программа һәм УМК (методик әсбап, 2 кисәктән торган дәреслек, эш дәфтәре һәм электрон кушымта) авторлары – Ф.Ф. Хәсәнова, Г.М. Сафиуллина, М.Я. Гарифуллина. Автор-төзүчеләр 5–6 нчы сыйныф укучыларын күбрәк кычкырып укырга, мөстәкыйль рәвештә әдәби китаплар укырга теләк уятырга, 7–8 нче сыныфлар белән кычкырып актив укуларына, әдәби текстларны тирәнрәк анализлауга игътибар итәргә кирәклекне, 9 нчы сыйныфта алдагы елларда укылганнарга нәтиҗә ясау, әдипләрнең биографияләрен тирәнтен өйрәнү, яңа темалар, проблемалар белән таныштыру, укыганны тирәнрәк аңларга, төрле белешмә әдәбиятны кулланырга өйрәтүне искәртәләр. 10–11 нче сыйныфларда әдәби мирас хронологик эзлеклелектә, тарихи яссылыкта, ягъни әдәбият тарихы курсы рәвешендә үзләштерелә. Татар классиклары монографик планда өйрәнелә. Рус телендә белем алучы татар балаларының төрле әзерлектә булуларын исәпкә алып, материаллар дәреслекнең 1 нче һәм 2 нче кисәкләренә бүлеп бирелә. Дәреслекләр концентризм принцибына (дәрес предметының төп эчтәлеге бер үк булган, ләкин, кайсы баскычта булуына карап, күләме һәм катлаулылыгы белән бер-берсеннән аерыла торган бүлекләр) нигезләнеп төзелгән.

Бу программада Г. Ибраһимовның тормыш һәм иҗат юлын өйрәнүгә зур игътибар бирелгән. Авторлар 5 нче сыйныфта «Яз башы» һәм «Фәгыйлә» хикәяләрен өйрәнергә, 7 нче сыйныфта «Табигать балалары» әсәреннән өзек белән танышырга һәм хезмәт кешесен данлау, табигать һәм аның балалары арасындагы бәйләнеш, татар халкында киң таралган өмәләр, яшьләрнең активлыгы кебек сорауларны карарга тәкъдим итәләр. «Алмачуар» хикәясен өйрәнү, бала һәм ат, ата һәм бала, бала һәм староста арасындагы мөнәсәбәт, сүзеңдә тору һәм тормау мәсьәләләре, Закирның Алмачуарга һәм башка атларга мөнәсәбәте, җиңү бәясе, Закирның психологик кичерешләре, хайваннарны ярату хисләре мәсьәләләрен тикшерү 8 нче сыйныфта планлаштырылган. 9 нчы сыйныфта «Сөю – сәгадәт» хикәясен уку, яшьләр һәм мәхәббәт темасы, сөюнең тирәнлеге, сафлыгы, хисләрнең чисталыгын белдерүдә пейзажның роле кебек сорауларны карау таләп ителә. 11 нче сыйныфта «Казакъ кызы» романын өйрәнү каралган [2].

Сүз сәнгате кеше тормышын, чынбарлыкны билгеле бер дәрәҗәдә милли традицияләр аша тасвирлый, халыкның уй-кичерешләрен, гомумән, милләтнең тарихи язмышын үзәккә куя. Аның төп материалы, әсәрне төзү коралы – сүз, нинди дә булса конкрет бер халыкның теле. Нәкъ әдәби әсәрдәге сүзләрдә халыкның гореф-гадәтләре, акылы һәм асылы, тормыш-көнкүреше, милли йөзе чагылыш таба.

Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына ана теле укыту программасында укучыларда лингвистик (тел), аралашу (коммуникатив), этнокультура өлкәсенә караган (культурологик) компетенцияләр булдыру рус мәктәбендә татар теленә өйрәтүнең максатын тәшкил итә дип билгеләнгән. Этнокультура өлкәсенә караган компетенция, ягъни телне милли-мәдәни яссылыкта үзләштерү ул, – укучыларны сөйләмгә өйрәткәндә, рухи, эстетик тәрбия һәм

белем бирү чарасы буларак, милли үзенчәлекләрне чагылдырган текстлар белән эшләү, тормыш-көнкүреш, гореф-гадәт үзенчәлекләрен, сынлы сәнгать әсәрләрен, халык авыз иҗаты үрнәкләрен белү, татар сөйләм этикетына ия булу [3, б. 23].

Димәк, тел һәм әдәбият укытучылары, иң беренче чиратта халыкның асылын, тарихын, тормыш-көнкүрешен, гореф-гадәтләрен чагылдырган сүзләргә һәм төшенчәләргә игътибар бирергә яки тел һәм мәдәният бәйләнешен күрсәтергә тиеш. Әгәр дә укытучы укучыларын мондый сүзләрне табарга, аларга аңлатма бирергә, үзләштереп, истә калдыру, сөйләмдә куллану юлларына өйрәтә алса, укучыларның лингвомәдәни компетенцияләре формалашачак. Шуның нигезендә этнокультура өлкәсенә караган компетенцияне дә булдырырга мөмкин.

Әдәби әсәрләрдә кулланылган татар халкының тарихын, көнкүрешен чагылдырган сүзләргә тулы аңлатма бирү зарури. Чөнки алар күбесенчә тарихи һәм архаик сүзләр рәтендә йөриләр. Бу – бер булса, икенчедән, шәһәр мәктәпләрендә укучы татар балалары өчен бу сүзләрне аңлау бигрәк тә кыенлык тудыра. Әсәрнең телен аңламау әсәрне тулысынча үзләштермәүгә китерә.

Г. Ибраһимовның «Алмачуар»ындагы иң беренче чиратта игътибарга алынырга тиешле эквивалентсыз (рус телендә турыдан-туры тәрҗемәсе булмаган) сүз (лингвокультурема) – *сөенче.* Ул әсәрдә берничә тапкыр кабатлана һәм Закирның колынны бик теләп, зарыгып көтеп алуын күрсәтә. Сөенчегә бүләк әзерлеген сорап йөдәткән малайларга әллә кайчан әзерләп куюы турында әйтеп тынычландыра, ә инде хәбәр салынгач, «каз кавырсыннары, чүпрәкләр сатып, сөенчегә дип әзерләгән алты тиен акча» сын карап та тормый, яшергән җирдән тиз генә ала да Фәхри малае Сәпәргә китереп тә тоттыра. Колын туу – Закирга зур сөенеч, көч түгеп җыйган акчасы да җәл түгел. Әлеге күренеш халкыбызның тагын бер бик яхшы сыйфаты – хәстәрлекле булуының да чагылышы. Димәк, җиде-сигез яшьлек Закир да инде хәстәрлекле булып үсә. Бу – бүгенге көндә яшь буынны тәрбияләүдә актуаль мәсьәләләрнең берсе.

Хикәяне өйрәнү барышында атчылык лексикасына һәм дини лексикага караган бер төркем сүзләргә (*мөәзин, манара, азан, өйлә намазы, бисмилла, сөбханалл*а) тукталырга кирәк. *Тай, айгыр, бия, туры бурлы, колын, чабышкы, кырыкмыш* һ.б. шундый сүзләргә аерым игътибар бирелергә тиеш.

Әдәбият дәресләрендә әсәрнең телен өйрәнү барышында укучыларда сүзгә игътибарлы караш тәрбияләнә, халыкның мәдәниятенә һәм тарихына кызыксыну уяна, сүзлек белән, өстәмә әдәбият белән эшләү күнекмәләре, фәнни-тикшеренү эшләре белән шөгыльләнүнең беренче адымнары булдырыла, укучылар теге яки бу мәгълүматны эзләп интернет челтәренә чыгалар һәм бу үз чиратында информацион технологияләрнең алымнарын куллануны тормышка ашыруга ярдәм итә.

Телгә милли-мәдәни яктан якын килү ике-өч телле шәхесне тәрбияләүгә, укучыларның лингвомәдәни компетенциләрен формалаштыруга, туган халкының мәдәниятен, тарихын ихтирам итүгә, толерантлы шәхес тәрбияләүгә хезмәт итә, төп гомуми белем программаларын үзләштерүнең планлаштырылган шәхескә юнәлтелгән нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек тудыра.

Бүгенге көндә Г. Ибраһимов иҗатына карата төрле, капма-каршы фикерләр булуга карамастан, әдәбиятчылар, методистлар, укытучыларда язучының бөеклеге, каләменең осталыгы, әсәрләренең эстетик кыйммәтлелеге

турында шик юк.Татар әдәбияты титаны – Г. Ибраһимов иҗатының актуальлеген һәм яшь буында кызыксыну уятканлыгын Башкортстан Республикасы Сәрлетамак шәһәренең 5 нче санлы гимназиясендә инде унберенче тапкыр үткәрелгән «Ибраһимов укулары» Республика фәнни-гамәли конференциясе тагын да исбатлый.

ӘДӘБИЯТ

1. Заһидуллина Д.Ф. Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. Казан: Мәгариф, 2004. 367 б.

2. Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен татар әдәбиятыннан программа (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 5–9 нчы сыйныфлар / Ф.Ф. Хәсәнова, Г.М. Сафиуллина, М.Я. Гарифуллина. Казан: Мәгариф – Вакыт, 2014. 51 б.

3. Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар: 1–11 нче сыйныфлар / Ч.М. Харисова, К.С. Фәтхуллова, З.Н. Хәбибуллина. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 239.

4. Федеральный государственный образовательный стандарт основного общего образования / М-во образования и науки Рос. Федерации. М.: Просвещение, 2011. 48 с.

## Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ «ТИРӘН ТАМЫРЛАР» РОМАНЫНЫҢ КАЙБЕР ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

***Мөхәммәтшин Ф.М.***

Данная статья посвящена анализу романа Г. Ибрагимова «Глубокие корни» с точки зрения концепции эпохи и героя. Все персонажи произведения – не только участники криминальной хроники, но и активные борцы за претворение в жизнь своих идеалов.

This article is devoted to the analysis of the novel by G. Ibragimov, «the Deep roots» from the point of view of the concept of era and character. All the characters work – not only the participants of the crime, but the  aktive fighters for the implementation of their ideals.

Г. Ибраһимовның Октябрь инкыйлабыннан соң иҗат ителгән әсәрләрендә сыйнфый көрәш, революция вакыйгаларын сурәтләү алгы планга чыга. Язучының совет хакимияте дәверендә үзгәртелеп язылган «Безнең көннәр», «Тирән тамырлар» романнары шуның ачык мисалы. Әсәрдә инкыйлабтан һәм гражданнар сугышыннан соңгы вакыйгалар, ягъни авылдагы социаль каршылыклар сурәтләнә.

«Тирән тамырлар» романы «Фәхрине үтереп ташладылар» дип башланып китә. Әсәрнең сюжеты әлеге вакыйгалар белән тыгыз бәйләнештә тора. Ягъни ул бәйләп торучы детальгә әверелә. Геройларның характерлары да аның үтерелү фактына мөнәсәбәттә ачыла. Яңа төзелеп килүче совет дәүләтенең «дошманнары»н ачуга, күрсәтүгә зур урын бирелә. Г. Ибраһимов аерым вакыйгаларга әйләнеп кайту юлы белән Фәхригә характеристика бирә, эш-гамәлләрен тасвирлый. Якыннарының искә төшерү нәтиҗәсендә тулыландырыла бара. Соңыннан автор: «Бу – татар крестьян активистының иң гади биографиясе булып килеп чыкты», – дигән нәтиҗә ясый. Димәк, монда автор аның ярдәмендә шул елларга туры килгән авыл кешесенең тормыш юлын күрсәтә.

Әйтергә кирәк, «Татар совет әдәбиятының беренче детектив әсәре дә Г. Ибраһимов исеме белән бәйле [2, б. 133]. Ф. Хатипов та Г. Ибраһимов

бу романына тукталып, аны детективка якын булуын әйтә: «Автор биредә детектив материал белән эш итә» [5, б. 11]. Романының беренче битендә үк Фәхринең үтерелүе билгеле була. «Фәхрине үтереп ташладылар», – дип автор аның үз үлеме белән үлмәвен искәртә [4, б. 137]. Фәхринең үле гәүдәсе янында канлы кендек табыла. Җиһанша карт үз әйберен таный, берничә көн элек аны Садыйкның алып чыгуын әйтә. Шулай итеп, әсәргә Садыйк – Нәгыймә сюжеты килеп керә. Фәхрине үтерүдә гаепләнгән Садыйк ил күләмендә барган вакыйгаларда актив катнаша. Аның аша язучы эшчеләр сыйныфының җитәкче ролен башкаруын раслый. Гайшә башта ук Фәхринең Садыйкны үзенең дусты, көрәштәше дип кенә түгел, революция укытучысы да итеп каравын әйтә [6, б. 255]. Димәк, алар инкыйлаб, яңа тормыш өчен көрәшүчеләр, аның алгы сафында баручылар. Өлкән буын вәкиле Җиһанша образы аша әдип авылда барган үзгәрешләрне, сыйнфый көрәшләрне 1905 елгы вакыйгалар белән бәйли. Ул халык акылын, хәтерен, тарихын җиткерүче образ буларак гәүдәләнә.

М. Хәсәнов фикеренчә, Г. Ибраһимов Гайшә белән Нәгыймә аша яңа тип хатын-кыз образларын тудыра [6, б. 228]. Алар яңа җәмгыять төзүдә актив катнашучылар. Әсәр ахырында Гайшәнең колхоз рәисе итеп куелуы шуның бер мисалы. Иҗтимагый эшчәнлек белән шөгыльләнү, шәхси тормыш хакында уйламау шул заман таләбе иде. Шулай да, автор үз героиняларын иҗтимагый эшчәнлек белән генә түгел, шәхси тормышларына да игътибар итүче затлар итеп тә сурәтли. Мәсәлән, шәхси тормышы хакында уйламаган, яңа тормыш төзү юлында актив катнашкан Фәхри гаиләсенә аерым бер йорт салып керү турында уйламый. Әлеге катлаулы, авыр эшне көчле рухлы, хезмәт сөючән Гаишәгә башкарып чыгарга туры килә.

Күренә ки, романда әдип кешеләр арасындагы шәхси мөнәсәбәтләрне сыйнфый позициягә бәйләп ача. Әсәрнең үзәгендә егерменче еллар әдәбиятына хас сыйнфый көрәш идеясе ята. Ф. Хатипов та: «Традицион җинаять һәм җәза сюжетын Г. Ибраһимов капма-каршы торучы көчләрнең социаль тамырларын ачып, кешеләрнең бу көрәшкә катнашу психологиясен ачыклау өчен куллана», – дип яза [5, б. 20]. Шуларга бәйле рәвештә, романда ике конфликт аерылып чыга: җинаятьче – корбан, җинаятьче – җинаятьне ачучы конфликтлар. Шулай да әсәрдә конфликтның тамырлары тирәнрәк икәнлеге ачыла, бу – сыйныфлар конфликты. Фәхретдин Гыйльманов белән көрәштәше Паларусов – ялкынлы революционерлар, большевиклар, Вәли Хәсәнов – бай, сыйнфый дошман, контра [2, б. 134]. Әсәрдә җинаять тикшерү эше роман дәвамында алып барыла һәм әсәр ахырында җинаятьче – Вәли Хәсәнов булуы ачыклана.

Романның нигезендә иҗтимагый конфликт ята. Ул Фәхри белән Вәли Хәсәнов арасындагы көрәштә чагыла. Вәли Хәсәнов «Хезмәт» исемле хуҗалыкка җитәкче булып килә. Үз эшен белеп башкара. Колхозны аякка бастыра. Аның тирән тамырларның бер тамыры Гыймади, Низамилар булса, икенчесе совет аппаратында эшләүче Шамов, Салахиевларга барып тоташа. Мәгълүм булганча, әсәрдә Фәхри үз вакытында «Уртак» исемле комуна төзи. Ләкин, җитәкчеләрнең тәҗрибәсезлеге, халык белән эш итә алмаулары нәтиҗәсендә ул җимерелә. Әлеге «эшмәкәрләргә» капма-каршы итеп «Хезмәт» совхозы, аның рәисе Вәли Хәсәнов сурәтләнә. М. Хәсәнов язганча: «Вәли бай – әсәрдәге кире образларның беренчесе. Революция нәтиҗәсендә мал-милкеннән аерылган капиталист һәм алпавыт….

Лəкин иске тормыш əйлəнеп кайтмый, кикриге сындырылган хəлдə, ул үзе əйлəнеп яңадан кайта һəм элекке танышлары, сыйнфый дуслары ярдəмендə совет хуҗалыгына җитəкче эшенə кереп оялый» [6, б. 228]. Беренче карашка, Вəли белəн Фəхри арасындагы каршылык аша язучы сыйнфый көрəшнең кискенлеген бирə кебек. Иванов, Салахиев сюжет сызыгы да әлеге көрəшнең асылын көчəйтə. Советка каршы көрəшкəн, əмма соңыннан яңа хөкүмəткə хезмəт итə башлаган Вəли Хəсəновның: «Аяклы мал болай иде: əҗəл җитмəгəнгə генə үлə алмый яткан бер корчаңгы бия, ике карт алаша, җəй көне дə ябагасын коймаган бер бетле тай. Тəкə китерелмəгəнгə кысыр калган дүрт сарык – менə барлык җан иясе шулар иде. Ашлыкның хəле дə шуңа охшаш иде: анан-моннан ерткалап, əйтерсең, исерек кул белəн чəчелгəн, шундый тигессез чыккан дүрт дистинə арыш аламасы ята... Əйтер хəлем юк, сəвит бик ныклы булышты. Кулдан барын һəммəсен бирə торды. Мин үзем дə тəүлегенə унсигезəр сəгатьтəн ким эшлəмəдем. Шулай итеп, дүрт ел эчендə менə нəрсəлəргə ирештек: хəзер совхозда, вак-төяген исəплəгəндə, аяклы мал йөз башка җитте. Болар эчендə җимертеп җигəрлек унике баш ат бар. Бөтен тирə-як крəстиəннəргə нəсел яңартып торган яхшы черкас тəкəлəр, менə дигəн холмогор үгезлəр, яхшы нəсел, таза кан айгырлар бар. Мин өч басудан күп басуга күчтем. Мин башлап трактор китердем. Минем машиналарым тирə-як авылларда гөжлəтеп эшлəп йөрилəр» [2, б. 307], – дигəн сүзлəре аның Фəхрилəрдəн аермалы буларак оештыру сəлатенə ия булган кеше буларак күрсəтə. Шунсы да игътибарга лаек, романда Вəлинең Фəхрине үтерүдə гаеплəүнүе əйтелə, əмма турыдан-туры аның бу җинаятьтə катнашуы хəбəр ителми. Җинаять конкрет мисаллар белəн дəлиллəнмəсə дə Вəли Хəсəнов үлем җəзасына хөкем ителə. Иванов белəн Сəлəхиев биш елга төрмəгə ябыла. Романда зур имəн агачының авуы да тирəн мəгънəгə ия. Ул идарə итү салəтенə ия булган, үз эшен белеп башкарган шəхеслəрнең юк ителүенə ишарə итə дип əйтə алабыз. Əйтергə кирəк, Г. Ибраһимов совет хөкүмəте яклылыарны да уңай яктан гына гəүдəлəндерми. Мəсəлəн, Садыйкның Зирекледəге «кара көчлəр»гə каршы көрəше, аның боерыгы буенча ишанны атып үтерү шуны дəлилли. Сыйнфый көрəшнең кан коюга нигезлəнүе ачыклана. Мондый күренешлəрне тулырак ачу максаты белəн əдип, натуралистик алымнарга да мөрəҗəгать итə. З. Сəлахова билгелəвенчə: «Язучының бу елларда язылган əсəрлəре өчен дə натурализм күренешлəре ят түгел» [1, б. 191]. Галимə фикеренчə, «Тирəн тамырлар» романында натуралистик алымнарның əдəби-эстетик вазифасы бик тə зур. Фəхринең этисе – Тимершаны үтерү күренеше моңа ачык мисал. «...Эчəгелəр, каннар агып, Тимершаның авызын, йөзен, кулбашларын, бөтен, гəүдəсен буядылар» [2, б. 175]. Фəхринең дə Яманкул чокырында табылган үле гəүдəсен сурəтлəгəн урыннарда да натуралистик алымнар күзаллана. Бу фаҗигане автор түбəндəгечə сурəтли: «Аның йөзе изелеп, канга баткан, баш сөяге ватылган, маңгае, чигəлəре буй-буй җимерелгəн, мие сары аксылланып тышка актарылган, муены, сул як кулбашы канлы туфрак белəн укмашып беткəн иде» [4, б. 6]. Əмма совет идеологиясенə тəнкыйть сүзлəре əйтергə ярамаган бу дəвердə, автор турыдан-туры белдермичə, үзенең тəнкыйди карашын геройларның эш-гамəллəре, сүзлəре аша җиткерə. М. Җəлəлиева язганча «Тирəн тамырлар» – «татар милли тарихын, аның заманнар агышында кичереп килгəн фаҗигасен иңлəп алган əсəр» [3, б. 6]. Г. Ибраһимов үзенең əсəрендə революция чорын, гражданнар сугышы елларының ни дəрəҗəдə

авыр булуын сурәтли. Сыйнфый көрәш, яңа тормыш төзү, меңләгән халыкның каны коелу вакыйгалары күзаллана.

ӘДӘБИЯТ

1. Галимҗан Ибраһимовның иҗат дөньясында. Казан, 2012. 375 б.

2. Галиуллин Р.Р. Татар детективы «Тирән тамырлар» белән бай // Г. Ибраһимов мирасы һәм төрки дөнья: Г. Ибраһимовның тууына 125 ел тулуга багышланган Халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары (17 апрель, 2012 ел). Казан. 2012. 265 б.

3. Җәләлиева М.Ш. Әдәбиятыбызның җырлы чишмәләре. Казан: Мәгариф, 2001. 230 б.

4. Ибраһимов Г.И. Сайланма әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. 508 б.

5. Хатипов Ф. Истоки психологизма татарской прозы // Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман: Тууына 115 тулуга багышланган фәнни конференция материаллары. Казан: Фикер, 2002.

6. Хәсәнов М. Галимҗан Ибраһимов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. 335 б.

## НАЧАЛЬНЫЙ ЭТАП ИЗУЧЕНИЯ ТАТАРСКОГО ЭПОСА: ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ Г. ИБРАГИМОВА

***Мухаметзянова Л.Х.***

Статья посвящена рассмотрению наследия Г. Ибрагимова в фольклористике 20-х гг. XX в. Автор акцентирует внимание на большой роли в теоретическом изучении татарского эпоса классика и теоретика татарской литературы, педагога, общественного деятеля Г. Ибрагимова. Обращая внимание на интересные факты, имеющие отношение к эпосоведению, учёный одним из первых в татарском литературоведении проложил путь к дальнейшим теоретическим исследованиям дастанного эпоса.

The article is devoted to the consideration of the heritage of G. Ibrahimov in folklore studies of the 1920 s. XX century. The author emphasizes the great role in the theoretical study of the Tatar epic classic of Tatar literature, scientist, teacher, public figure G. Ibragimov. Drawing attention to interesting facts related to epic studies, he was one of the first in Tatar literary criticism paved the way for further theoretical studies of the epic.

Жанр дастана в народном творчестве, обладающий солидным объемом, эпичностью, художественным совершенством – область, требующая к себе особого внимания. Народные дастаны это возвышенный жанр, который, начиная с древнейших времен, оказывал влияние на творчество поэтов и прозаиков, стал стимулом для формирования классических литературных канонов и традиций. Этот жанр также тесно связан с философскими и религиозными воззрениями народа, с эволюцией социальных и правовых доктрин.

Содержание ряда дастанов своими корнями восходит к глобальным историческим событиям. Если рассмотреть дифференцированно, в его основе лежит сказочно-мифологическая, историко-героическая и религиозно-мистическая, а порой и эмоционально-любовная интрига, где интересные, поучительные с точки зрения народной массы факты повествуются эпически. Как это свойственно для всех эпических сказаний, дастаны относятся к эпосу в широком смысле этого термина, поэтому в фольклористике и литературоведении термины «дастан» и «эпос» используются как синонимы.

Слово «эпос» по происхождению греческое, означает «слово, повествование, рассказ» [4, с. 513], как термин включает в себя много значений. В энциклопедиях [3, с. 928], [4, с. 514–515] он приводится в широком и узком смыслах. В широком значении термин используется по отношению к литературному виду, основанному на рассказе или повествовании о каком-либо событии или событиях, вбирает в себя вообще все литературные и фольклорные жанры, обладающие этими свойствами. В узком смысле «эпос» – жанр или произведение героического или романического характера, изображающее в фольклоре и литературе народную жизнь в широком эпическом плане.

Первой научной работой в татарской фольклористике, посвященной жанру дастана, считается статья Г. Ибрагимова [1, с. 68–70]. По вопросу татарского дастана в плане отражения литературного менталитета начала XX в. мысли Г. Ибрагимова, посвященные обзору татарского дастанного эпоса, представляют большой интерес. Г. Ибрагимов ведет речь об эталонах мирового эпоса «Илиаде», «Одиссее», «Шахнаме», но не говорит ни слова о наших равноценных им памятниках. А слово «эпос» Г. Ибрагимов оценивает следующим образом: «во-первых, не подходит под нашу орфографию, во-вторых, по языку чужд нашей выразительности» [1, с. 69]. Это подтверждает то, что еще в начале XX в. не было четкого определения жанра дастанного эпоса, в связи с этим обособлять произведения, относящиеся к этому жанру, как народные, тем более рассматривать рукописные дастаны, подвергнутые отдельными авторами фольклорно-литературной переработке, научная общественность была не подготовлена. Это результат того, что на то время фольклорные материалы в должной степени еше не были собраны, классифицированы, а анализ татарского фольклора, в частности, теоретическое исследование жанра дастана, тесно переплетенного с письменным творчеством, находились на начальном этапе. В татарской фольклористике тенденция отчуждения от народного творчества широко распространенных народных вариантов дастанов на сюжеты «Юсуф-Зулейха», «Тахир-Зухра», «Буз егет», «Саид Баттал», «Кахарман Катил», добавляя к ним эпитеты «книжный», «литературный», продолжалась до 70–80-х гг. XX в.

Известно, что в «эпоху российского мусульманства» (определение Г. Ибрагимова [2, с. 338]), т.е. в период, начиная от завоевания Казани и до середины XIX в., читаемые народом и распространяемые в рукописях произведения занимают особое место в жизни татар. Важно то, что большинство этих произведений не являются лишь переводом эпоса других народов, а представляют из себя местные национальные версии на общеизвестный сюжет. Известно, что в эту эпоху татарская литература уже крепко стоит на ногах, уже давно профессионально сформировалась. Тогда у татар были ориентированные на оригинальную литературу, известные широкой общественности своими индивидуальными произведениями поэты [2, с. 338]. Несмотря на это, параллельно с литературными произведениями у татар на протяжении нескольких веков продолжали оставаться актуальными и дастаны, на определенном историческом этапе в народе жила особая потребность в таких произведениях. Это означает, что на долю татарских дастанов выпала не только роль посредника переходного периода из эпического фольклора в литературу, они долгое время функционировали самостоятельно в качестве духовной пищи для народа.

В написанной в 1922 году статье [2, с. 338–358], в которой Г. Ибрагимов историю татарской литературы подразделяет на три периода, такие памятники, как «Юсуф-Зулейха», «Тахир-Зухра», «Буз егет», «Саид Баттал», «Кахарман Катил» и др. называет «дорогими литературными шедеврами, служившими народу духовной пищей» [2, с. 338–339] эпохи древнего кадимистского Востока. Следовательно, в 20-е годы XX в. в литературоведении все же существовал определенный теоретический взгляд, был признан факт наличия в истории литературы памятников, изучаемых сегодня в жанре дастана. Это – попытка теоретического осмысления жанра эпоса. Все памятники, упомянутые автором, испытали влияние отдельных людей, взяли свое начало из письменных источников, в основном, письменно и распространялись. Но в свое время Г. Ибрагимов эти образцы письменного фольклора отделил от «народной литературы». У литературоведов начала XX в. вообще нет обозначения эпического произведения, известного в народе своими многочисленными вариантами, «татарским дастаном». Теоретик литературы Г. Ибрагимов также находится под влиянием эстетических взглядов своего времени, поэтому, говоря о дастанах, сформировавшихся на нашей почве на сюжеты восточных литератур, он не рассматривает их как отдельный жанр.

Причины откладывания проблем изучения татарского дастанного эпического наследия, форм его существования и путей развития в историко-эволюционном плане, а также в сравнительном с фольклором других тюркских народов аспекте, разумеется, кроются не в тесной связи эпического творчества татар, особенно поволжских, с письменностью, не в том, что ученые, выросшие на этом фольклоре, не считают его народным наследием. Отсутствие прогресса в изучении произведений, которых можно было назвать «дастаном», связано с общественно-политическими условиями эпохи.

Несмотря на то, что, начиная с 20-х гг. XX в. и до 40-х гг., как и в литературном процессе тюркских народов, так и в татарском литературоведении и фольклористике по отношению к жанру дастана наметились благоприятные условия, этот период «оттепели» продолжался сравнительно недолго. Известно, что главной причиной задержки в изучении жанра дастана стало решение Центрального Комитета ВКП(б) от 9 августа 1944 г. Оно называется «О состоянии и мерах улучшения массово-политической и идеологической работы Татарской партийной организации». В этом документе татарские историки обвиняются в национализме, идеализации истории Золотой Орды, в его приукрашивании, а литературоведы в популяризации «ханско-феодального» эпоса «Идегей». Это решение ослабило внимание к татарскому народному дастану, сделало невозможным работы в области научного исследования эпического наследия. Позднее, оценивая эту ситуацию, известный фольклорист В.И. Чичеров писал: «В Поволжье, например, после постановлений 1944–1945 гг. «О состоянии идеологической работы в Башкирии и Татарии», в которых дана была справедливая критика идеализации образа Эдиге, собирание и изучение эпоса почти совершенно прекратилось» [6, с. 20]. И, действительно, не секрет, что это решение сыграло свою отрицательную роль в плане научного изучения народного эпоса. Таким образом, дастаны, представляющие собой немалую долю десятивековой культуры, были обречены на ожидание своей очереди среди рукописей на арабской графике, а также и изданных на ней книгах.

Татарский дастан своей темой, сюжетом, мотивами, идеей, художественным исполнением, типологией, образом существования и распространения опирается на общетюркский эпос, основанный на национальных традициях, в то же время и на общетюркскую древнюю и средневековую восточную литературу и фольклор [5, с. 57]. Такого рода эпос у нас формировался на протяжении веков под влиянием письменной культуры и ислама.

Общий взгляд на историю изучения татарских дастанов дает основание утверждать, что в целом в татарской фольклористике было много сделано в деле определения ценности наших дастанов в ряду мировых и тюркских эпических памятников, исследования татарских дастанов на определенном научном уровне, системно-комплексного анализа в сравнительном плане и возвращения их снова народу. И на начальном этапе изучения татарского эпоса несомненно большую роль играл классик татарской литературы, педагог, общественный деятель Г. Ибрагимов. Обращая внимание на интересные факты, имеющие отношение к эпосоведению, он проложил путь к дальнейшим теоретическим изучениям татарского эпоса.

ЛИТЕРАТУРА

1. Ибраһимов Г. Әдәбият кануннары. Казан, 1918. 120 б.
2. Ибраһимов Г. Иҗтимагый, әдәби хәрәкәтләр тарихын тикшерүдә марксизм ысулы // Ибраһимов Г. Әсәрләр. 8 томда. 5 т.: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. Б. 330–358.
3. Краткая литературная энциклопедия. М.: Советская энциклопедия, 1975. 1056 с.
4. Литературный энциклопедический словарь. М.: Советская энциклопедия, 1987. 753 с.
5. Мухаметзянова Л.Х. Татарский эпос: книжные дастаны. Казань, 2014. 380 с.
6. Чичеров В. И. Вопросы изучения эпоса народов СССР // Эпос народов СССР. М., 1958. С. 5–23.

## ИЗОБРАЖЕНИЕ ИСТОРИЧЕСКОГО ВРЕМЕНИ И ПРОСТРАНСТВА В РОМАНЕ Г. ИБРАГИМОВА «НАШИ ДНИ»

***Мухарлямова Г.Н.***

В статье рассматривается проблема исторического времени и пространства в романе Г. Ибрагимова «Наши дни». Конфликт в романе определяют оппозиции прошлое / будущее, старое / новое, темное / светлое, день / ночь. Хронотопические образы дороги, ночи, зари характеризуют состояние страны в переломное для нее время.

The article examines the problem of historic time and space in the novel «Our days» by G. Ibragimov. The conflict in the novel is determined by the following oppositions: past/future, old/new, dark/light, afternoon/night. Chronotopic images of road, night, dawn characterize the state of the country during the turning-points of its history.

Хронотоп эпических литературных произведений определяет историческое время и пространство как фон, характеризующий общую историко-общественную атмосферу и определяющий действия персонажей, их взаимоотношения, а также решающим образом воздействующий на формирование личности героя.

Роман Г. Ибрагимова «Наши дни» повествует о событиях, связанных с революционной деятельностью в стране. В произведении историческое время определяется тяжелыми условиями существования людей, смутой и напряженностью. Так, указывая на политические, социально-экономические обстоятельства в стране, в романе подчеркивается, что положение простого народа с каждым днем все больше ухудшается: «Деревня голодает. Ей нужна земля. Голодает рабочий. Ему нужно повышение заработной платы. Весь трудовой народ придавлен непосильными налогами. Нужно облегчить их. Весь бедный люд, все инородцы угнетены. Им нужна свобода» [3, с. 52]. Закономерно, что данные обстоятельства вызвали у народа бурные волнения, определяясь оппозицией темное/светлое: «Тем временем на просторах России поднимаются бурные волны. Начинается борьба против косности, против темной, душной, прогнившей жизни – за светлые, вольные дни» [3, с. 67]. Это не останавливает народ и уже над «городом, еще вчера погруженным в дрему, сегодня гул и треск бомб, пулеметов, винтовок. Взрывы бомб, брошенных нынче в губернатора, завтра в министра, то и дело потрясают тихие когда-то улицы. Грабежи становятся чем-то обычным… Растерянное правительство кидает свои войска, полицию, жандармерию, чтобы остановить вздыбившиеся волны. Тюрьмы полнятся новыми и новыми заключенными, крестьянские поля, заводские, фабричные улицы покрываются трупами убитых повстанцев, кровь заливает землю. В темные ночи на обнесенных высокой кирпичной стеной тесных площадках возле зловеще вытянувшихся к небу столбов смерти палачи ждут своих жертв» [3, с. 12].

Характерные черты данного исторического времени определяет хронотоп революции. Хронотоп революции, приводя все в движение, способствует скоротечности происходящих событий. Это были дни, которые по определению Г. Ибрагимова, «развертывались с молниеносной быстротой». Писатель смог образно изобразить весь ужас, стихийность происходящего: «Волны вдруг стали неотвратимо близкими, молнии засверкали перед самыми глазами. Искры глухой, страшной борьбы, которая еще так недавно представлялась очень далекой, о которой и не думали, что она когда-нибудь дойдет сюда, вспыхивали уже совсем рядом… Дракон революции, который буйствовал где-то вдали, чей жуткий призрак являлся здесь лишь в воображении, теперь готов ринуться и на них, готов заглотить их…» [3, с. 12]. Образы огромных волн, молний, искр способствуют охарактеризованию революционного времени, как стихийного бедствия. Писатель неслучайно вводит в произведение образ Дракона революции. Дракон – «в мифологии многих народов фантастический образ крылатого (иногда одноголового) огнедышащего змея» [2]. «Выступая в роли чудищ, драконы – автохтонные владыки земли, с которыми приходится бороться героям, завоевателям и созидателям, чтобы захватить или освоить землю. …Битва с драконом символизирует те трудности, которые необходимо преодолеть, чтобы овладеть сокровищами внутреннего знания. Победа над драконом олицетворяет разрешение конфликта между светом и тьмой, разрушение деструктивных сил зла, либо победу над собственной темной природой человека и достижение самообладания» [4].

Дракон пожирает, убивает все живое на земле, на что готов и Дракон революции. Интересен и тот факт, что образ Дракона был использован автором еще раз и в повести «Красные цветы», однако уже в ином значении.

Здесь он применяется по отношению к противникам революции, которые «поднялись из сибирских болот, Балтийского и Черного морей» и наступали «с открытой пастью».

Историческое время изображается писателем с помощью противопоставлений старое/новое и прошлое/настоящее/будущее. В.Е. Хализев, рассматривая категорию времени в художественных произведениях, говорил о соотнесенности прошлого, настоящего и будущего [6, с. 231]. Так, Г. Ибрагимов в своем романе «Наши дни» пишет: «… то было время, когда пред взорами других ярким видением встало грядущее. Борьба разгорается. В ее пламени горят, рушатся гнилые устои старой жизни. А впереди, в далеком мареве, сияя светом свободы, вспыхивают лучи зарождавшейся жизни». Революция олицетворяет, таким образом, движение в будущее. В то же время определение, что новая жизнь кажется в мареве, наталкивает на вопрос: «Верил ли писатель в осуществление этого сам?», ведь, как известно, марево – это «мираж, призрачное видение» [5]. Все это свидетельствует о том, что будущее представляется писателю чем-то отдаленным, недоступным, нереальным, наконец.

Таким образом, «начатая рабочими борьба за повышение заработной платы и сокращение рабочего дня переросла в политическую борьбу против самодержавия», которое постепенно начинает сдавать свои позиции. Но оно, в свою очередь, как определяет главный герой романа «Наши дни» Булат Зариф, «собирает всю свою последнюю мощь и бросается в бой, чтобы задушить революцию» [3, с. 13]. Противостояние двух сторон, определяясь бинарной оппозицией светлое/темное, выявляет характер событий, особенности художественного времени и пространства в литературном произведении. Отношение ко времени становится, таким образом, одним из приемов создания системы образов, в основе которой, как правило, находится прием антитезы.

Начавшиеся небольшие колебания среди народа под влиянием определенных социально-экономических, политических предпосылок переросли в большое массовое волнение народа, исторический ход которого уже не в силах было остановить ничто. Это волнение и вылилось в революцию, которая должна была привести народ, по мнению многих, из темного прошлого в светлое будущее.

В то же время анализ произведений, повествующих о послереволюционном времени показывает, что революция не разрешила всех конфликтов, людям не удалось сразу построить новую счастливую жизнь. Писатели неоднократно подчеркивали, что времена продолжали оставаться тяжелыми, смутными, полными борьбы и различных испытаний. Подтверждение этому мы находим, например, в романе Г. Ибрагимова «Глубокие корни», где писатель, не идеализируя настоящее, раскрывает противоречия новой жизни.

Историческое время и пространство, изображаемое в романе «Наши дни» определяет и хронотоп дороги, в данном случае хронотоп «большой дороги», изображающий главное эпохальное историческое движение, понимаемый как путь, ведущий героев к революции. Дорога в романе, олицетворяя сложный и трудный для всех путь героев к революции, выражается в различных вариациях. В путь, в который вышли герои произведения «для всех единый путь», так как здесь нет разделения ни на русских, ни на евреев, ни на немцев, ни на татар: «Мол, скоро рабочие нашего города объединятся и пойдут с красными флагами к губернатору, станут чего-то требовать

у него. И если тот им откажет, бросят работу, забастуют…» [3, с. 13]. Так начинается их путь, который они пролагают вперед к революции, к манящему их светлому будущему. Вскоре герои понимают, что одними забастовками, митингами многого добиться невозможно. Тогда Булат Зариф – один из главных героев произведения призывает рабочий народ на вооруженное восстание – на один из верных путей, которым, по их мнению, можно прийти к этому будущему.

В то же время, пути героев различаются по тем признакам, из каких идейных соображений они встали на него. Так, Герей Султанов в отличие от Булата Зарифа и других «выбрал себе иной путь на фронте революции, считал ее войной, кровавой, жестокой, непримиримой войной. Как в любой другой войне, так и в этой он видел необходимость крепко вооружиться против врага – против буржуазии, помещиков, их армии, жандармов». Герей Султанов был твердо убежден, что «узловой момент революционной деятельности – вооружение рабочих, организация боевых дружин, воспитание в этих дружинах закаленных бойцов-большевиков. Для этого требовались деньги, много денег – тысячи, миллионы». Добыть их, по его мнению, «можно лишь одним способом: захватывать правительственную почту, банки, поезда, отнимать золото силой, экспроприировать его. И Герей все силы отдавал на защиту в партии своей линии, на выполнение своих планов» [3, с. 45]. Все это еще раз свидетельствует о противоречивости ситуации, возникшей в данное время в стране.

В романе, подчеркивая сложность пути героев, автор водит их по узким глухим переулкам, где «не было фонарей, где тьма стояла кромешная, ноги по щиколотку тонули в слякоти». На это указывает и шаткие, полусгнившие ступеньки на сажень вниз, по которым спускался Хабиб Мансуров в комнату своего друга Даута Урманова и каменный настил у порога, залитый водой. Этим писатель как бы намекает на неосуществление их планов в будущем.

Автор останавливается на подробном жизнеописании его товарища Баязита, который с детства чувствовал себя «птицей, запертой в клетке, из которой не вырваться навек» [3, с. 64]. Будучи сыном ишана, он не любил совершать намаз, не любил класть земные поклоны…», за что его начинают преследовать наставники. Ничто не могло его укротить, и хотя «мозг его вобрал в себя Коран, пусть молящиеся в мечети сидят, отдавшись обаянию его напевного голоса – он, невзирая ни на что, предается грехам… в восьмой день святого рамазана среди бела дня его видят на окраине города с женщиной» [3, с. 66]. Это был очередной ответный удар на желание всех его близких, сделать из него священнослужителя. Узнав об этом, его отец, Джихан ишан приезжает в медресе, «валит его на пол, созывает всех шакирдов, всех хальфэ и при них жестоко в кровь избивает его» [3, с. 66]. Это было последней каплей в море терпения Баязита, после чего он больше не возвращается в медресе. Таким образом, герой разрывает замкнутый круг и вырывается в свободное пространство. Баязит едет в Челябинск, где в звании кари приглашается в почтенные дома и читает суры из Корана. Но его бунтарский характер не дает ему покоя усидеть на одном месте. И он снова сбегает. Писатель в нескольких штрихах описывает жизненный путь героя, подчеркивая тем самым, что до начала революционных волнений герой метался в поисках самого себя. Вскоре «на просторах России поднимаются

бурные волны. Начинается борьба против косности, против темной, душной, прогнившей жизни – за светлые, вольные дни» [3, с. 67]. Все это толкает Баязита в бой, он уже не хочет жить старой жизнью, хочет окончательно ее разгромить, но в то же время не знает «с чего начать, к кому пристать, какими путями вести борьбу», «куда же идти, с кем искать дорогу?» [3, с. 67]. В то время он решил примкнуть к течению фидаистов, так как «он страдал всю жизнь… всю жизнь душа была в тисках», а он хочет вздохнуть свободно. Даут Урманов и Баязит долгое время не могли для себя ясно определить, к какой партии они принадлежат: «В некоторых случаях называли себя революционерами вне партии, в других – национальными социалистами или беспартийными социалистами» [3, с. 69]. В одно время Булат Зариф хотел перетянуть их на свою сторону, однако духовно они были не готовы к этому. Вскоре Баязит был арестован и его «измучив путаными, коварными вопросами, отправили в городскую тюрьму, в отделение для политических» [3, с. 72], где посадили в четвертую одиночную камеру.

Как видно, путь к революции пересекается с жизненным путем героев произведения, так как во многих произведениях, по мнению М. Бахтина, хронотоп дороги соответствует жизненному пути литературных героев [1, с. 48]. Жизненному пути героев в литературных произведениях соответствует их биографическое время, и с течением времени меняются и характеры героев, и их судьбы.

Не остается без внимания тот факт, что Г. Ибрагимов в романе «Наши дни», останавливаясь на жизнеописании многих своих героев, очень мало дает информации о жизненном пути главного героя произведения – Булата Зарифа. Из его прошлой жизни известно, что жил он на окраине города в маленькой хибарке с матерью и младшей сестрой. После стычки с жандармами на цирковой площади, он был вынужден уйти в подполье и менять каждый день место своего ночлега. Булата путали, называя его и социал-демократом – большевиком, и сторонником движения панисламизма, пантюркизма. Однако ясно, что Булат был большевиком, человеком сильной революционной закалки.

Смертельная участь настигает Султана Герея – героя романа Г. Ибрагимова «Наши дни». Он проходит суровую жизненную школу, с раннего детства работает на заводе, постепенно знакомится с представителями социал-демократии, вступает в большевистскую партию. Султан Герей был самым активным участником революционных движений и боролся, как Булат Зариф за перерастание всеобщей стачки в вооруженное восстание. Этот путь привел его к жизненной трагедии: он был схвачен жандармами и казнен. Он – жертва революции ради самых высоких идеалов и полностью уверен, что «казнью Герея враг не спасет себя. Погибнет Герей, но не революция. Революция не может не победить. Революция свершится! А если так – Герей тоже не исчезнет бесследно. В яростных волнах революции, которые сокрушат старый мир, вспыхнут алым светом и капли его крови…» [3, с. 390]. Таким образом, пересечение горизонтальной и вертикальной проекций жизненного пути главных героев, заканчивающихся в большинстве произведений изучаемого периода смертью героя, определяют характер революционной борьбы, в которой происходит формирование революционной личности, готовой ради утопических идеалов пожертвовать собственной жизнью.

Как известно, хронотоп дороги выражается также в различных вариациях, например, в виде тропинок, переулков. Подпольный характер революционного движения не позволяет героям открыто, безопасно и беспрепятственно передвигаться по городу. Они вынуждены перемещаться по темным улочкам, узким тропинкам, расшатанным лестницам, ходить окольными путями, встречаться в переулках и закоулках. У героев романа нет возможности передвигаться по большой, широкой, одобряемой обществом дороге, они по воле судьбы и определенных обстоятельств вынуждены проходить расстояния по неосвещенным переулкам, узким тропинкам. Писатель показывает, что им предстоит многое преодолеть, прежде чем с тропинок они выйдут на большую дорогу.

Автор и сам сравнивает своих героев с путниками, «которые пробиваются к тропе, которая ведет их из дремучего леса, они как бы ощупью искали свою дорогу в сгущавшемся вокруг них мраке» [3, с. 348]. Нередко герои были вынуждены ходить окольными, окружными путями.

Цикличное время «закат – ночь – рассвет» определяет историческое время и пространство, изображаемое в произведениях того периода, а также демонстрирует неустанное движение времени, не только изменение, но и обновление жизни.

В произведениях этого периода главные события, независимо от их характера, происходят преимущественно в ночное время суток, причем в отличии от татарской прозы начала XX века, где в большинстве случаев образ ночи выполняет функцию ирреального мифологического пространства, в прозе 20–30-х годов XX века, напротив, хронотоп ночи носит характер социализированного пространства, в котором герои решают общественные проблемы.

Ночь – это время перед зарей, время, когда задумываются новые планы, намечаются встречи героев, совершаются разного рода преступления, покушения и убийства. Многим героям приходится все дела совершать ночью, чтобы укрыться, остаться нераскрытым. Ночная темень дает возможность все действия и поступки героев оставлять незамеченными. Так, в романе Г. Ибрагимова «Наши дни» все собрания, обсуждения революционных планов проводятся ночью, передвижения героев по городу также происходят преимущественно в ночное время.

В романе говорится, что ночью «было произведено много арестов, получено много новых материалов» [3, с. 82]. Неуловимого Хабиба Мансурова – Беглеца − поймали также ночью, и в час ночи «жандармские агенты привели его в пятый полицейский участок» [3, с. 185]. Еще одного из главных героев романа – Булата Зарифа в первый раз уводят в участок осенней ночью «люди с саблями и винтовками перерыв, перевернув все в доме». Как видим, ночь является удобным временем для проведения обысков.

Характер ночного времени определяет пространство, в котором находятся литературные герои. Так, ночь в тюрьме отличается тем, что она «тяжелая, какой она может быть только в тюрьме, долгая, тянущаяся, точно год темная ночь» [3, с. 385]. Еще один пример: «На окутанную мглой тюрьму, казалось, опустилась полная тишина» [3, с. 391]. Однако многие заключенные не могут уснуть. Арестантов не обмануло предчувствие – этой «черной ночью» казнили Герея Султанова.

Не менее беспокойна ночь и для героев, которые находятся на свободе. Так, герой романа Г. Ибрагимова «Наши дни» Баязит проводит беспокойную ночь, размышляя о своем положении: «В эту ночь, он не смыкает глаз. Обуревавшие его всю жизнь ненависть, протест как бы сплавляются воедино» [3, с. 68]. Утром, после долгих и мучительных раздумий он принимает важное и в то же время страшное решение: «Я дал себе твердое слово поехать в деревню и убить отца!» – говорит он Дауту Урманову. Таким образом, ночь − это и время принятия сложных решений.

Ночь, будучи символом смерти, показывает, что в это время суток происходят убийства, покушения, казни.

Герея Султанова – героя романа Г. Ибрагимова «Наши дни» − казнили ночью в «низком, мрачном помещении», под потолком которого висел фонарь.

Историческое время и пространство, изображаемое в произведении определяется оппозицией день/ночь. Ночь воспринимается героями как прошлое или мрачное настоящее, а день как светлое будущее. В записке Герею Султанову Булат пишет, что «на исходе мрачные часы темной душной ночи… эти черные ночи не вечны… наш день наступит вновь» [3, с. 390]. Таким образом, оппозиция день / ночь в данном случае пересекается с противопоставлением прошлое / будущее.

Оппозиция день/ночь характеризует положение страны в данный период времени, так как главные герои еще не вполне уверены, что настал день, так называемый предвестник новой жизни. Итак, день – это светлая полоса в жизни страны, ночь – темная. Герои произведений этого периода ждут того момента, когда после тяжелой, хмурой, опасной ночи «заалеет заря».

Следует отметить, что хронотоп зари является отличительной чертой произведений татарской прозы 20–30-х годов прошлого столетия. «Образ зари, символизирующий величие «пленительного счастья», во всей полноте раскрыл в татарской литературе свой социальный смысл и поэтическую красоту именно в дни социалистической революции» [7, с. 31], – писал в свое время Г. Халит. Данный хронотоп определяет историческое время и пространство художественной литературы этого периода. Заря воспринимается писателями не только как время рождения нового светового дня, но и, в первую очередь, как время пробуждения новой общественной мысли, новых идеалов в духе того времени. Заря – часто встречающийся образ в романе Г. Ибрагимова «Наши дни». Так, между Булатом, Сахибом и Баязитом происходил следующий разговор:

«– Ты веришь, что завтра взойдет солнце?

– Почему не верить? Верю! – ответил Сахиб с наивной непосредственностью.

Баязита словно кольнули в сердце. “А вот я не верю, нет!” – хотелось крикнуть ему.

– Если веришь в то, что завтра взойдет солнце, верь и в революцию! – сказал Булат Сахибу» [3, с. 350]. Таким образом, заря символизирует время перемен, начало светлого будущего.

Узники тюрьмы не оставляли надежд на рассвет, который принесет им освобождение от тюремных оков. За темной ночью «словно стараясь пробудить бледными своими лучами, засветилась заря. И вот на пыльных стеклах, на ржавой решетке тюремного окошка заиграл свет яркого весеннего солн-

ца…» [3, с. 385]. В то же время как бы указывая на то, что радостные времена в их жизни настанут не так быстро, наступают «снова сумерки. Опять заходит солнце. В последних его лучах вспыхивают, загораются облака. Горит, полыхает огненно-красная, багряная гряда. Горит и, медленно угасая, окутывается черной дымкой. На землю опускается ночь. Мир поглощает тьма» [3, с. 385]. То обстоятельство, что никто из героев не может сказать, когда в этой тьме проступит рассвет, характеризует мучительно долгое течение времени в тюрьме. Но, несмотря на это, они до последнего не теряют надежды на свое освобождение.

Таким образом, противоречия исторического времени, описываемого в произведении Г. Ибрагимова «Наши дни», определяются не только характером времени, обусловленного политическими, социально-экономическими условиями, в которых жили герой в преддверии революции, но и характером восприятия и осознания ими событий, происходящих в стране в этот период.

ЛИТЕРАТУРА

1. Бахтин М.М. Эпос и роман. СПб.: Азбука, 2000. 304 с.

2. Большой энциклопедический словарь / Режим доступа: http: // dic. academic.ru/dic.nsf /enc3p / 123178

3. Ибрагимов Г. Наши дни: Роман / пер. с татарского Р. Фаизовой. М.: Современник, 1983. 398 с.

4. Словарь символов / Режим доступа: http: // dic. academic.ru/dic.nsf /simvol /224

5. Толковый словарь Ушакова / Режим доступа: http: // dic. academic.ru/dic.nsf /ushakov

6. Хализев В.Е. Время и пространство // Теория литературы. М., 1999. С. 247–249.

7. Халит Г. У истоков татарской советской литературы // История татарской советской литературы. М.: Наука, 1965. С. 31–51.

## Г. ИБРАҺИМОВ ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ ТӘРҖЕМӘ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

***Насибуллова Г.Р.***

В данной статье рассматриваются переводы художественных произведений Г. Ибрагимова на русский язык. Дается обзор переводов одного произведения несколькими переводчиками.

This article considers translations of G. Ibragimov's novels and stories into. An overview of translations of one work by several translators is given.

Татар әдәбият тарихында һәм үсешендә Галимҗан Ибраһимовның үз урыны бар. Язучы һәм галимнең киң кырлы мирасы татар әдәбияты үсешенә нык тәэсир ясый. Әдәбият галиме Д.Ф. Заһидуллина аны хаклы рәвештә «XX гасыр башы татар әдәбиятын тудыручы» дип атый [1].

«Г. Ибраһимов үткән юл – татар халкының XX гасыр башларыннан алып утызынчы еллар ахырына кадәр, ягъни илдә революция булып, социализм җиңүенә тикле булган рухи үсеш юлы. Әдипнең тормышы һәм иҗаты халыкның революцион көрәш тарихы, яңа тормыш төзү, социалистик культура формалашуы белән аерылгысыз бәйләнгән. Г. Ибраһимовның культура тарихындагы роле турында сүз барганда, барыннан да элек, аның матур әдәбият өлкәсендә тоткан урыны аеруча зур һәм үзенчәлекле булуын әйтергә

кирәк. Әдипнең иҗат эволюциясе һәм татар әдәбиятында тоткан урыны турында фәнни хезмәтләр язылган, аның иҗаты шактый җентекле тикшерелгән дияргә була. Һәм һаман да тикшерелеп тора, киләчәктә дә шулай булыр. Чөнки зур талантлар, классик язучылар, бай иҗатлар турында һәр чор, һәр буын үз сүзен әйтә, аңарга карата үзенең мөнәсәбәтен билгели. Мондый тарихи шәхесләр рәтенә керү үзе генә дә язучының олылыгын, үлемсезлеген күрсәтә. Г. Ибраһимов – әнә шундый әдипләрдән» [2, б. 17]. Аның әсәрләре һәм катлаулы язмышына багышланган күп санлы мәкаләләр, тарихчылар, фәлсәфәчеләр, политологлар, әдәбият галимнәре тарафыннан күп хезмәтләр язылган. Шулай ук язучының образы әдәби һәм сынлы сәнгать әсәрләрендә мәңгеләштерелгән. Язучының исемен кайтару һәм халыкка җиткерүдә академик Мансур Хәсәновның өлеше зур. Аның татар һәм рус телендәге күпсанлы мәкаләләре, хезмәтләре «Ибраһимов фәне»нә нигез салды. Шулай ук язучының иҗатын өйрәнүгә Г. Сәгъди, Җ. Вәлиди, Г. Нигъмәти, М. Гайнуллин, И. Нуруллин, О. Кадыров, Ф. Мусин, Ф. Галимуллин, Р. Ганиева, Ф. Бәширов, Д. Заһидуллина, Э. Галиева һ.б. әдәбият галимнәре зур өлеш кертә. Әлеге мәкаләдә без язучының әсәрләренең тәрҗемә тарихы һәм үзенчәлекләренә киңрәк тукталырбыз. Билгеле булганча, әдәби әсәрнең башка телгә тәрҗемәсе аерым мөстәкыйль хезмәт була алмый, ул оригинал белән янәшә яшәргә генә хокуклы. Шуңа күрә тәрҗемә әсәрне өйрәнгәндә оригиналны, язучының тулаем иҗатын яхшы белү зарур.

Г. Ибраһимовның әсәрләре рус теленә 1920–1970 елларда тәрҗемә ителә. Беренчеләрдән булып, аның «Табигать балалары» хикәясе 1928 елда рус телендә яңгыраш ала. Әлеге хикәя «Советская страна» әдәби альманахында басылып чыга. 1931 елда басылган «Татар әдәбияты (революциягә кадәр)» җыентыгына «Табигать балалары» һәм «Карт ялчы» хикәяләренең русчага тәрҗемәләре кертелә. Алга таба Г. Ибраһимовның башка әсәрләре дә тәрҗемә ителә. Аларның кайчан һәм кем тарафыннан тәрҗемә ителгәнлекләрен түбәндәге исемлектә күрергә була: 1. «Тирән тамырлар» романы (тәрҗемәче – Г. Шәрипова, 1931); 2. «Казакъ кызы» романы (тәрҗемәче – Г. Шәрипова, 1934); 3. Хикәяләр. (тәрҗемәче Г. Кәримова, 1961); 4. «Безнең көннәр» романы (тәрҗемәче – Р. Фәизова, 1962); 5. «Тирән тамырлар» романы (тәрҗемәче – Р. Фәизова, 1962); 6. «Казакъ кызы» (тәрҗемәче – Р. Фәизова, 1966); 7. «Яшь йөрәкләр» (тәрҗемәче – Р. Фәткуллина, 1980) һ.б.

Г. Ибраһимов кайбер әсәрләренең рус теленә тәрҗемәләре фәнни яктан өйрәнелгән. Мәсәлән, Хәйруллина Гөлназ Сөйләйман кызы «Г. Ибраһимов әсәрләренең рус теленә тәрҗемәләре: поэтика һәм стиль» кандидатлык диссертациясендә язучының «Тирән тамырлар» романының тәрҗемәсен оригинал белән чагыштыра, Р. Фәизова һәм Г. Шәрипова тарафыннан башкарылган тәрҗемәләрне чагыштырма планда өйрәнә, тискәре һәм уңай якларын ачыклый [3, б. 15]. Г. Ибраһимовның әлеге романының ике тәрҗемәсен чагыштырма анализ башкарганда Г.С. Хәйруллина әсәрнең жанр һәм композицион, ритмик-стилистик, интонацион үзенчәлекләренең башка телдә саклanышы һәм бирелешенә игътибар итә.

Г. Шәрипова үз тәрҗемәсендә Г. Ибраһимов хикәяләвенең динамиклыгын һәм җиңеллеген саклап калырга тырыша. Ләкин тәрҗемә процессында бик күп кыскартулар куллана. Тәрҗемәче кайбер аерым төшенчәләрне, гыйбарәләрне кыскарту белән генә чикләнми, ә тулы эпизодларны, хәтта тулаем бүлекне төшереп калдыра. Әлеге югалтулар оригинал текстның композиция

төзелеше үзгәрүгә китерә. Галимә Г.С. Хәйруллина фикеренчә, тәрҗемәченең әлеге адымы аның әсәрнең жанрын дөрес билгеләмәүдә, детектив буларак кабул итүдән килеп чыгарга мөмкин. Тәрҗемәче күп очракта әсәрнең төп сюжет линиясе – үтерүчене эзләүгә бәйле булмаган тасвираламаларны, вакыйгаларны кыскарткан. Күрәсең, Г. Шәрипова романны детектив әсәр буларак кабул иткән, әсәрнең төп мәгънәсен аңламаган. Шулай ук рус вариантында татар халкының үзенә генә хас булган төшенчәләр төшереп калдырылган. Нәтиҗәдә, оригинал әсәрнең милли үзенчәлеге җуелган. Г.С. Хәйруллина, Г. Шәрипова тәрҗемәсен «оригинал белән таныштыручы» дип атый. Галимә әлеге атамасын тәрҗемәченең автор стилен саклап калмавы, ә бары тик әсәр белән рус телле укучыны таныштыруы белән дәлилли.

Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романының Р. Фәизова тарафыннан башкарылган тәрҗемәсе оригинал текстның тулысынча, кыскартылуларсыз бирелүе, тәрҗемәченең автор сүзенә игътибарлы булуы белән аерылып тора. Ләкин тәрҗемәдә күп очракта Р.Фәизова, үзе дә автор хокукларын алып, кайбер күренешләрне дәвам итә. Шулай ук тәрҗемәче әсәрнең стилистик, ритмик-интонацион төзелешен төзәтергә тырышып, автор текстын танып булмаслык дәрәҗәдә үзгәртә.

Р. Фәизова «Тирән тамырлар» романын Г. Шәриповадан соңрак башкара. Галимә Г.С. Хәйруллина фикеренчә, бу вакыт совет әдәби тәрҗемә мәктәбе үсеш алган чор белән туры килә. Шуңа күрә Р. Фәизованың тәрҗемә процессында җибәргән төгәлсезлекләрен шул чор үзенчәлекләре белән, тәрҗемә мәктәбенең төп юнәлеше белән аңлатырга була.

Г. Ибраһимовның романнары белән беррәттән хикәяләре рус теленә тәрҗемә ителә. Мәсәлән, Роза Фаткуллина язучының «Карак мулла», «Табигать балалары» хикәяләрен рус теленә тәрҗемә итә. Г. Ибраһимовның «Карак мулла» хикәясе теле тәрҗемә өчен шактый катлаулы. Анда гарәп-фарсы алынмалары, иске татар әдәби теленең катлаулы синтаксик конструкцияләре, диалекталь сүзләр күп кулланыла. Әлеге кыенлыклар тәрҗемә текстта лексик-семанттик характердагы хаталар китереп чыгара. Галимә Г.С. Хәйруллина әлеге хаталар тәэсирендә һәм күпсанлы кыскартулар нәтиҗәсендә тәрҗемә текстта автор стиле бөтенләй сакланмаган дип саный.

Г. Ибраһимовның «Табигать балалары» хикәясе оригинал текстның мәгънәви үзенчәлекләрен рус телле текстта саклануы белән аерыла. Ләкин бу хикәядә тәрҗемәче күбрәк сүзгә-сүз тәрҗемә итә. Хикәядә язучының гыйбарәләрен калькалаштыру белән беррәттән, җөмләдәге сүзләр төзелешен, татар теленең синтаксик төзелешен үзгәртмичә бирү очрый. Тәрҗемә процессында Г. Ибраһимовның стиле, интонациясе сакланып калмаган.

Шул рәвешле, Г. Ибраһимов әсәрләренең тәрҗемәләрен күзәткәннән соң, без әлеге әсәрләрнең оригиналдан ерак булуын, чор, тәрҗемә фәне үсеше белән бәйле рәвештә тәрҗемәчеләрнең әлеге процессны башкарганда язучының стилен, интонациясен сакламавын, оригинал тексттан ераклашуларын күрдек.

ӘДӘБИЯТ


1. http://www.azatliq.org/a/28368286.html

2. Хәсәнов М. Интернационализмның җанлы традицияләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. Б. 17.

3. Хайруллина Г.С. Переводы произведений Галимджана Ибрагимова на русский язык: поэтика и стиль: автореф. дис. ... канд. филол. наук: 10.01.08 / Литературный ин-т им. А.М. Горького. М., 2001. 15 с.

# XX ГАСЫР АЗАГЫ – XXI ГАСЫР БАШЫНДА БАШКОРТСТАНДА ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ МИРАСЫН ӨЙРӘНҮ, САКЛАУ ҺӘМ ПРОПАГАНДАЛАУНЫҢ АЕРЫМ АСПЕКТЛАРЫ ТУРЫНДА

***Насипов И.С.***

В сообщении проанализированы достижения, рассмотрены некоторые региональные аспекты современных задач в изучении, сохранении и пропаганде наследия Галимджана Ибрагимова в общем контексте научно-исследовательской, литературно-творческой и культурно-просветительской деятельности.

The report analyzes the achievements, considers some regional aspects of contemporary problems in the study, preservation and outreach of Galimdzhan Ibragimov’s heritage in the general context of scientific-research, literary-creative and cultural-educational activities.

Татар халкы тарихи Евразия киңлекләрендә сибелеп яши. Хәзерге Татарстаннан тыш, Россия төбәкләрендә һәм якын-ерак чит илләрдә ул җирле халыкларның һәм дәүләтләрнең икътисади-сәяси һәм иҗтимагый-мәдәни тормышында анык эз калдырган. Алар милләтнең мәшһүр улларының һәм кызларының эзләре: тормышның төрле өлкәләрендә хезмәт куеп, берләре бу төбәкләрдә һәм илләрдә дан казанган шәхесләр, даһи затлар буларак билгеле һәм тарихта калган; икенчеләре исә, тиешле бәһа алмыйча, билгесез яки онытылуга дучар ителгән. Башка халыклар тарафыннан танылган, аларның үз каһарманнары булып киткән татарлар бар, ләкин алар тагын да күберәк булыр иде. Чөнки, иң беренче чиратта, үз милләте таныганның һәм күтәргәннең генә кыйммәте булу зарури. Алар белән берлә милләт үзе дә күтәрелә, башка халыклар тарафыннан танылa вә ихтирам яулый. Шуңа күрә бу юнәлештә безгә максатчан булырга, бай тарихи вә мәдәни мирасыбызга сакчыл карарга, милләт җәүһәрләрен вакытында барлап, халкыбыз күңеленә энҗе бөртекләре итеп тезеп барырга бурычлыбыз.

Галимҗан Ибраһимов – татарның күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, галим һәм язучы, фән һәм мәгариф оештыручысы буларак танылу алган улларының берсе. Соңрак булсын, ләкин вакытлы ихтирам алган шәхес ул. Ләкин бу күпкырлы талант иясенең бай мирасын өйрәнүдә, өйрәнелгәненә заманча яңа караш булдыруда безнең башкарасы эшләребез бихисап.

Әдипнең тормышын, эшчәнлеген һәм милли-мәдәни мирасын барлауда, өйрәнүдә, саклауда һәм халыкка, киң җәмәгатьчелеккә җиткерүдә берникадәр дәрәҗәдә аның якташларының да өлеше бар. Татарның Уфа якларында, Урал буе төбәкләрендә туып танылу алган уллары һәм кызлары арасында Галимҗан Ибраһимов лаеклы урын тота. Шунысы шатлыклы, аның мирасы өчен тарткалаш-талаш та сизелми – ул татарныкы гына. Аны бар даирәләрдә таныйлар, эшчәнлегенә югары бәһа бирәләр, гыйльми казанышларын таныйлар, иҗади сәләтенә һәм әдәби осталыгына сокланалар. Ул үз вакытында ук танылган һәм бүген дә абруйлы тарихи әһел. Мәсәлән, ул күпчелек төрки халыклар әдәбияты үсешенә уңай йогынты ясаган әдип буларак билгеле. Заманында ассызлыкланганча, 1928 елда Давыт Юлтый «Сәсән» журналында, Г. Ибраһимовның башкорт әдәбияты үсешенә йогынтысын билгеләп, болай дигән: «Вакытлар узыр, Октябрьнең ун еллыкларын

тагын уздырырбыз. Яшь башкорт әдәбияты да кайсыдыр баскычында гомумкешелек әдәбияты алдында хисап бирер. Шул чакта Галимҗан да безнең арада булыр» [4, 158].

XX гасырның сиксән бишенче елларына кадәр Галимҗан Ибраһимовның мирасы Башкортстанда филология фәннәре докторы, профессор Ү.И. Гыймадиев тарафыннан фәнни яктан тәфсилле өйрәнелде. Күренекле галим билгеле дәүләт һәм җәмәгыять эшлеклесе, мәшһәр галим һәм язучының тормыш юлын һәм иҗаты үсешен әдип яшәгән чорның иҗтимагый-сәяси шартларына ярашлы һәм Башкортстан белән күпьяклы бәйләнештә яктыртты. Аның күпсанлы хезмәтләрендә, шул исәптән монографияләрендә, Галимҗан Ибраһимовның шәхес булып формалашуына туган якның йогынтысын, әсәрләрендә һәм алардагы хәл-сәхифәләр бирелешендә, образларның сурәтләнешендә Башкортстан җирлегенең һәм табигатенең үзенчәлекле чагылышын, революциягә чаклы чорда «Галия» мәдрәсәсендә эшчәнлеген, төрле чорларда Уфа якларында һәм Урал буенда барган тарихи вакыйгаларга мөнәсәбәте, монда яшәп иҗат итүче башкорт һәм татар әдипләре белән бәйләнеше, бигрәк тә аның башкорт язучылары иҗатына йогынтысы һәм башкорт әдәбияты үсешенә уңай тәэсире мәсьәләләре каралды [3, б. 4].

Соңрак чорда да, әйтик XX гасыр азагы – XXI гасыр башында, Башкортстанда Галимҗан Ибраһимовның күпкырлы эшчәнлеге өйрәнүгә галимнәр, әдипләр һәм журналистлар зур өлеш кертте (Р. Әмиров, Ә. Нигмәтуллин, С. Поварисов, Г. Рамазанов, С. Сафуанов һ.б.). Бу яктан бигрәк тә әдипнең якташы, талантлы журналист һәм республиканың әдәби-мәдәни томышы белгече Фәрит Фаткуллин хезмәте аеруча зур урын алып тора. Аның татар матбугатында дөнья күргән күпсанлы мәкаләләре Галимҗан Ибраһимовның тормыш юлын анык күзалларга мөмкинлек бирә, әдипнең туганнары, замандашлары, якташлары истәлекләре аша байтак кызыклы мәгълүмат – моңача билгесез кыйммәтле сәхифәләр ачыла [11, б. 12]. Башкортстан матбугаты Галимҗан Ибраһимовка бәйле вакыйгаларны һәр чорда даими яктыртып килде. Бу яктан «Кызыл таң»да басылган мәкаләләрне махсус билгеләп узарга кирәк, аларны аерым бер җыентыкка туплап бастыру бик вакытлы һәм зур кыйммәткә ия булыр иде. Соңгы елларда «Кызыл таң» газетасында филология фәннәре докторы Рәмил Исламовның мәкаләләре басылды – алар да бик кызыклы һәм яңалык ача [9, б. 10].

Уфаның элек тә, бүген дә евразиянең мәдәни үзәге булуын билгеләү аша Галимҗан Ибраһимовның тормышка карашын формалаштыруда туган ягының үзенчәлекле ролен күрсәтеп, аның фикерләрендә евразиялек идеяләре чаткыларының чагылышын Л. Гумилевның пассионарлек теориясе контекстында күзаллап, әдәбият галиме, филология фәннәре кандидаты Фаил Фәтхетдинов та бүген бик мавыктыргыч эш алып бара.

Галимҗан Ибраһимов туган ягы элек-электән Стәрлетамак төбәге дип йөртелгән. Аңлашыла ки, булачак әдип үзе дә Стәрлетамак шәһәрендә берсүзсез булган, һәм бер генә тапкыр түгелдер. 1899 елда Гыйрфан мулла уллары Шакирҗан белән Галимҗанны Ырынбурга мәдрәсәгә укырга алып бара. Шәкертләр өйләренә дә кайтып йөргәннәр. Ә юл Стәрлетамак аша уза. Шуңа күрә бүгенге Стәрлетамак шәһәре өчен Галимҗан Ибраһимов бик тә үз кеше. Монда аның туган тиешле нәселләре дә яши. Болар үз чиратында әдипнең эшчәнлеген һәм иҗатын өйрәнүгә шәһәр җәмәгатьчелеген җәлеп итеп тора. Алар бу юнәлештә бик күп мактауга лаек эшләр башкарды.

Стәрлетамак шәһәренең 5 нче санлы гимназиясе озак еллар дәвамында «Ибраһимов укулары» республика фәнни-гамәли конференция уздыра, әдипнең тормышын һәм иҗатын өйрәнүгә зур өлеш кертә. Бу гыйльми форум быел 11 тапкыр оештырылды һәм ул әдипнең иҗади мирасын өйрәнү һәм саклау эшенә укучы яшьләрне һәм яшь галимнәрне тарту максатын куя. Аның эшендә елда, яшьләр белән беррәттән, Башкортстан галимнәре, әдипләре һәм җәмәгать эшлеклеләре генә түгел, Татарстан кунаклары да катнаша. Заманында Ф. Галимуллин, М. Зәкиев, Р. Җамалетдинов, Р. Исламов, Р. Миннуллин, К. Миннуллин, В. Хаков һ.б. катнашкан булса, бу елны Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясенең Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре Н. Насыйбуллина һәм И. Ямалтдинов килделәр. Бу еллар эчендә «Ибраһимов укулары»нда республиканың мәктәпләреннән меңләгән укучылар һәм укытучылар чыгыш ясады, аларның хезмәтләре өч җыентык булып басылып чыкты, интернет челтәрендә урын алды [5, б. 6; 7].

Галимҗан Ибраһимовның исемен мәңгеләштерүгә әдипкә туган тиешле булган эшкуар Марат Сәитов һәм аның энесе Ирек Сәитов зур көч салалар. Алар Авыргазы районы Иске Әпсәләм авылында туып үскәннәр һәм әниләре Мәвсилә Ибрагимова яклап туганлык җепләре Ибраһимовларга бәйле. Аларның матди ярдәме илә Стәрлетамакта һәм Авыргазы районында 1995 еллардан башлап барлык чаралар уза. Солтанморатта музейны яңарту, район үзәге Толбазы авылында Туган якны өйрәнү музейында Г. Ибраһимов почмагын җиһазлау, Үзәк район китапханәсен төзекләндерү һәм китап фондын баету, аларда китап сөючеләр конференцияләрен оештыру, Суфиян Поварисовның «Пәйгамбар таңы» роман-трилогиясен бастырып чыгару һ.б. мөмкин булды.

Марат Сәитов исә Галимҗан Ибраһимовның мирасын төрле архивларда барлау эшен оештыра, әдипнең шәҗәрәсен төзеп бастыра [1, б. 235–248]. Бүгенге көндә туган якны өйрәнүче Мөдәрис Сафин ярдәме белән шәҗәрәне төзәтеп яңарту һәм тулыландыру өстендә зур тикшерү эше башкарыла. Аның аерым нәтиҗәләре дә билгеле, һәм алар киң җәмәгатьчелеккә җиткерү өчен гыйльми әзерләнә, бик күп яңа мәгълүмат дөньяга чыгарылачак дип көтелә. Шуның өстенә, Марат әфәнде Галимҗанның бүгенге көндә билгеле булган туганнарын бер-берсе белән таныштыру, аралаштыру өчен дә көч сала.

Галимҗан Ибраһимовның исемен мәңгеләштерүдә бигрәк тә аның якташылары зур көч салды. Бу хезмәт Авыргазы районы тарихында аерым урын алып тора. Бу тарих сәхифәләрен район татарлары иҗтимагый оешмалары мәгълүматларына таянып ачып карыйк [2].

Әдипнең намуслы исемен аклауны аның авылдашы рәссам Хәләф Рәҗәповның 1952 елда «Кондызлы күл буенда» картинасыннан башланган, дип исәпли якташлары. 1967 елда Солтанморат урта мәктәбендә Галимҗан Ибраһимовның тууына 80 ел тулу көннәрендә беренче музей ачыла. Анда аның кулъязмалары, шәхси киемнәре, архив документлары, фотоматериаллар урын ала. Тууына 100 ел тулуга бәйле чаралар Башкортстанда зурлап уздырыла. Тантаналарда республиканың җитәкчеләре катнаша. Татарстаннан мәртәбәле кунаклар килә. 1987 елда музей өчен аерым агач бина төзелгәч, мәктәп музееннан материаллар анда күчерелә. Бу чорда Ибраһимовларның шәҗәрәсе төзү буенча күп эшләр башкарыла. Кызганыч, музей бинасы янгын хәләкәтендә юкка чыга, экспонатлар да янып бетә.

1997 елда мавзолей тибында йорт-музей салына (проектның авторлары – Рудольф Авсахов һәм Рәфкать Ягафәров), аның урамга карган ягына куелган бюстның авторы – Зөлфәт Басыров.

1996 елда район хакимиятенең махсус карары белән Галимҗан Ибраһимов исемендәге премия булдырылды. Ул әдәбият, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә ирешкән казанышлар өчен бирелә. Беренче лауреат – башкорт шагыйре Рәшит Назаров. Бүгенге көнгә лауреатлар саны – 25. Алар арасында беренче музейны булдыручы, Солтанморат мәктәбе укытучысы Фәүзия Рахматуллина; язучының тормыш юлына багышланган «Пәйгамбар таңы» роман-трилогия авторы Башкортстанның халык язучысы, профессор Суфиян Поварисов; авылдашы шагыйр Салават Рәхмәтулла; Башкортстанның һәм Татарстанның халык җырчысы Идрис Гәзиев кебек үзенчәлекле талант ияләре бар. Премия бердәнбер оешмага – Казан шәһәрендә урнашкан Татарстан Фәннәр Академиясенең әдипнең исемен йөрткән Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына бирелгән.

Шулай ук, 1996 елда аның исеме үзәк район китапханәсенә, балаларның җәйге-савыктыру ял лагеренә, район үзәге Талбазы авылындагы урамга бирелә. Районның әдәби-иҗади көчләрне берләштергән «Зәңгәр чишмә» әдәби берләшмә исемендә дә аның истәлеге мәңгеләштерелгән. Бүгенге көндә бу берләшмә утыздан артык рус, башкорт, татар, чуаш телендә иҗат итүчеләрне туплап, халык һәм яшь-үсмерләр арасында рухи һәм патриотик тәрбия эшен алып бара.

Ел саен март аеның беренче декадасында мәктәпләрдә, китапханәләрдә, мәдәният учакларында, музейларда «Ибраһимов көннәре» игълан ителә. Бу әдәби бәйрәм кысаларында тематик альбомнар, иншалар, яшь рәссамнәр бәйгеләр, Г. Ибраһимов премиясенә лаек булган лауреатлар белән очрашулар уза. Китап укучылар конференцияләре, яңа басмаларга презентацияләр, сәхнәләштерелгән күренешләр, тематик экспозициялар һәм башка чаралар әдипнең тормыш һәм иҗатын өйрәнү, популярлаштыру максатында оештырыла. Соңгы елларда «Галимҗан Ибраһимов – азатлык җырчысы» исеме астында электрон альбомнар булдырылды. Район китапханәсе «Галимҗан Ибраһимовның тирән тамырлары» дип аталган электрон басма төзеде [2].

Авыргазы районы администрациясе Галимҗан Ибраһимовның тууына 130 ел тулуга бәйле чараларныда әдипнең туган авылында Солтанморатта зурлап уздырды [13]. Бәйрәм чараларында республиканың күренекле әдипләре, галимнәре, җәмгыять һәм дәүләт эшлеклеләре, язучының якташлары һәм авылдашлары катнашты. Казаннан Татарстанның халык шагыйре Роберт Миннуллин һәм Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясенең Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры Ким Миннуллин килгән иде. Филология фәннәре докторы, профессор К.М. Миннуллин үзенең чыгышында быел Татарстанда Галимҗан Ибраһимовның тууына 130 ел тулуга бәйле чаралар һәрвакыттагыча дәүләт күләмендә билгеләнәчәк, диде. Ул күренекле әдипнең күпкырлы эшчәнлеген билгеләп, аның бай мирасын өйрәнүдә, саклауда һәм халыкка җиткерүдә галимнәр алдында торган бурычларны атады. Бу яктан аның төрки дөньяга керткән өлешен барлау – татарны дөньяга таныту, дип билгеләде. Һәм чыннан да, бу бик урынлы фикерләр. Башкортстан җәмгатьчелеге моңа үз өлешен кертте һәм килчәктә дә бергәләшеп эшләргә әзер.

ӘДӘБИЯТ

1. Генеалогическое древо Галиджана Ибрагимова // Абсалям: страницы истории. 190-летию села Абсалямово посвящается / авт.-сост. М.Х. Сафин. Уфа: ГУП ИПК МВД РФ по РБ, 2008. 277 с.

2. Башкортстан Республикасы Авыргазы районы татарлары милли-мәдәни автономиясе материаллары / Р.М. Валиев җитәк. төзелде. Толбазы, 2017. Кулъязма.

3. Ғалимьян Ибраһимов. Библиографик күрһәткес (1907–1977 йылдар) / төз. Ф.Ғ. Ғәбсәләмов, Ү.И. Ғимазиев. Фән.ред. Ү.И. Ғимазиев. Өфө, 1979. 250 б.

4. Ғимазиев Ү.И. Талант һәм хезмәт. Ғалимьян Ибраһимов ижады тураһында әзәби-публицистик мәкәләләр. Өфө: Башҡорт. кит. нәшр., 1982. 160 б.

5. Ибрагимовские чтения: Сб. материалов Республиканской научно-практической конференции, посвященной 125-летнему юбилею писателя, ученого, публициста, общественного деятеля Г.Г. Ибрагимову (Россия, Республика Башкортостан, г. Стерлитамак, МАОУ «Гимназия № 5 г. Стерлитамак», 16 марта 2012 г.) / отв.ред. И.С. Насипов, зам.отв.ред. И.С. Мансуров. Стерлиатамак: Стерлитамак. гос. пед.академия им. Зайнаб Биишевой, 2012. 288 с.

6. Ибрагимовские чтения: Сб. материалов Республиканской научно-практической конференции, посвященной писателю, ученому, публицисту, общественному деятелю Г.Г. Ибрагимову (Россия, Республика Башкортостан, г. Стерлитамак, МАОУ «Гимназия № 5 г. Стерлитамак», 15 марта 2013 г.) / отв. ред. И.С. Мансуров, зам. отв. ред. О.Ф. Николаева. Стерлиатамак: СФ БашГУ, 2013. 244 с.

7. Ибрагимовские чтения: Сб. материалов Республиканской научно-практической конференции, посвященной писателю, ученому, публицисту, общественному деятелю Г.Г. Ибрагимову (Россия, Республика Башкортостан, г. Стерлитамак, МАОУ «Гимназия № 5 г. Стерлитамак», 16 марта 2016 г.) / отв.ред. И.С. Мансуров, зам.отв.ред. О.Ф. Николаева. Стерлиатамак: СФ БашГУ, 2016. 256 с.

8. Ибраһимов Г.Г. Милләт. Тел. Әдәбият: Сайланма хезмәтләр / Кереш К.М. Миннуллин. Казан: Мәгариф, 2007. 239 б.

9. Исламов Р. Әдипнең автографлары // Кызыл таң. 2017. 9, 16 февраль.

10. Исламов Р. Әдипнең хатлары // Кызыл таң. 2017. 11 март.

11. Фаткуллин Ф. Данлы ояның лаеклы улы // Тулпар. 2017. № 2. Б. 52–55.

12. Фаткуллин Ф. Милләтебезнең йөзек кашы. Галимҗан Ибраһимовның тууына – 130 ел // Кызыл таң. 2017. 11 март.

13. Фаткуллин Ф. Рәхмәт укырга дип киләбез! // Кызыл таң. 2017. 21 март.

## СУФИЯН ПОВАРИСОВ ТРИЛОГИЯСЕНДӘ ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ШӘХЕСЕ («Пәйгамбәр таңы», «Күкнең җиденче катында», «Оҗмахка бер адым»)

***Насыйбуллина Н.Ш.***

В статье дается анализ трилогии С. Поварисова о классике татарской литературы Галимджане Ибрагимове, жизнь которого трагически оборвалась в годы страшных репрессий 30-х годов. В трилогию вошли романы («Заря пророка», «На седьмом небе», «Трагедия»). В произведениях рядом стоят два понятия – величие и трагедия личности.

The article is focused on S. Povarisov's trilogy about the classic of Tatar literature Galimjan Ibragimov whose life tragically ended up in the years of the terrible repressions of 1930s. The trilogy included novels («Dawn of the Prophet», «At the Seventh Skies», «Tragedy»). Two notions stand in the works – greatness and tragedy of personality.

Башкортстанның халык язучысы, күренекле галим, филология фәннәре докторы, Башкортстан һәм Татарстан Республикаларының атказанган фән

эшлеклесе, Башкортстан Язучылар берлегенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге әдәби премиясе лауреаты Суфиян Шәмсетдин улы Поварисовның бер канаты төрле характердагы, төрле жанрдагы әдәби иҗаты булса, икенче канаты – олы гыйльми эшчәнлеге. Ул берьюлы берничә юнәлешкә – әдәби иҗатка да, тел гыйлеме өлкәсенә дә зур өлеш керткән шәхесләрнең берсе. Г. Ибраһимов әсәрләренең тел үзенчәлекләрен тикшереп «Татар әдәби телен үстерүдә Г. Ибраһимовның эшчәнлеге» дигән темага докторлык диссертациясен яклаганнан соң репрессия корбаны, яңа татар совет әдәбиятына нигез салучы әдипләрнең берсе, талантлы тәнкыйтьче, әдәбият теоретигы, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Г. Ибраһимовка багышлап трилогия-эпопея язды. Башта роман бер-бер артлы «Тулпар», «Казан утлары» журналларында басылды, соңыннан Казанда 1999–2001, 2004–2006 елларда аерым китап булып дөнья күрде.

Трилогия «Пәйгамбәр таңы», «Күкнең җиденче катында», «Оҗмахка бер адым» дип аталган кисәкләрдән тора. Алар барсы да язучы, олуг галим, милләт, халык өчен бөтен барлыгын биргән шәхес турында.

«Пәйгамбәр таңы» романында XIX һәм гарасатлы XX гасырлар кисешкән чорда Башкортстанның хәзерге Авыргазы районы Солтанморат авылында туып, тарихка канлы вакыйгалары, сыйнфый бәрелешләре белән кереп калган фаҗигале елларда шәхес буларак формалашкан Галимҗан Ибраһимовның балачак һәм яшүсмер еллары сурәтләнә.

Әсәр баланың дөньяга килүе, аңа исем кушу вакыйгалары белән башланып китә. Исеме җисеменә туры килсен, эчке дөньясын, эчке холык-фигылен аңлатып торсын, дәвер пәйгамбәре исемен йөретерлек укымышлы, акыллы, галим кеше булсын иде, дип Гыйрфан мулла улына Галимҗан исемен куша. Аның фамилиясе дә Ибраһим Галәйһиссәламнең исеменнән алынган, чөнки нәсел тамыры Ибраһим хәзрәттән килә.

Әдәбият галиме Ф. Галимуллин «Мәдәни җомга»да басылган мәкаләсендә: «Галимҗанның дөньяга килүен сурәтләгән күренешне автор, борынгы дини китаплардагыча тирән мәгънә салып сурәтли. Шул рәвешле, Галимҗанның туган көне пәйгамбәр таңы дип билгеләнә. Димәк, бу – әлеге баланың гадәттән тыш җан иясе буласына ишарә. Автор аны дөньяга китерүчеләрне дә гаять матур итеп, мәхәббәт ияләре буларак сурәтли. Уртак мәхәббәттән, бәхетле ата-анадан туган бала, үзе генә бәхетле булып калмыйча, халык өчен дә сәгадәт китерер дигән тәэсир кала», – дип яза [1, б. 5].

Язучы тарафыннан баланы тәрбияләп үстерүче ата һәм ана образларына әсәрдә зур урын бирелә. Әнисе Хәсәнә абыстай укымышлы, төскә чибәр, сабыр холыклы, түземле, һәрчак акыл белән эш итә, ә этисе Гыйрфан мулла – үзсүзле, кырыс холыклы, кызу канлы, дөреслекне, гаделлекне яклаучы, тирән белемле, авылның абруйлы кешесе. Ананың сабырлыгы һәрвакыт атаның кызулыгын басып килә. Хәсәнә абыстай балаларын кыйнауга каршы, безнең кебек динле кешегә матчада чыбык тоту килешкән эш түгел, сугылган-кагылган балада акрынлап кире сыйфатлар күбәя бара, ди. Баланы укыту, аларга дөрес тәрбия бирү, күзләрен ачу – бөтенесе ана өстендә. Ул балаларына «Кыйссаи Йосыф», сәбах җиле, фәрештәләр, пәйгамбәрләр тарихы турында күп сөйли. Йосыф пәйгамбәрнең кешелеклелек, кечелеклелек сыйфатлары, аның зинданда утырганда да бәндәләргә карата булган миһербанлылык тойгылары белән яшәве, Зөләйханың искиткеч маҗаралы мәхәббәте – барысы да сабый күңеленә яшәүнең бер яктырткыч көче булып

салына, сеңә бара. Гыйрфан мулла да улының пәйгамбәр буласын төшендә күрә, аң-белемле итү өчен бөтен көчен-сәләтен бирә.

Атасының кырыс табигатенә, гаделлегенә, эш сөючәнлегенә күнеккән балалар аның һәр сүзен иман шарты кебек кабул итәргә гадәтләнеп үсәләр. «Ата әйтсә – хак әйтә», «Ата сүзе – иман» дигән төшенчәләргә тугры калалар.

Вәли мулла мәдрәсәсеннән куылгач, Галимҗан әтисенә: «Әткәй! Дөреслекне якларга, иманга тугрылыклы булырга, алдашмаска син безне үзең өйрәттең бит; әнкәй дә шул рухта тәрбияләде», – ди. Романда кешелеклелек, кечелеклелек, кеше бәхете өчен яшәү алгы планга куела. Әсәрнең кыйммәте дә әнә шунда. Гыйрфан мулла белән Хәсәнә абыстай шуларның бөек үрнәген күрсәтеп яшиләр, балалары күңеленә дә шундый орлыкларны салалар. «Дин кануннары буенча икмәкнең кырыктан бер өлешен ятимнәргә, ярлыларга, Актүти кебек карт-корыга бирергә тиешбез. Тәңрем үзе шаһит, мин аны биш тапкырга арттырам», – ди Гыйрфан мулла. Хәсәнә абыстай да авылда кем генә бала тапмасын, аш-су тулы табак-савытын күтәреп йөгерергә ашыга, һәрчак хәер биреп тора, ятим кыз Мәдинә-Акчәчкәгә ярдәм итә. Алар кешеләрне ярлыга, байга аермый, күңел байлыгы, күңел ярлылыгы буенча эш итәләр. Язучы кешеләрне Галимҗан исеменнән дүрт төркемгә бүлдерә: «Югарыга әтисен дә куеп карады ул. Ләкин башлык түгел. Шуңа күрә ил, халык мәнфәгате белән яшәү ягыннан караганда, аны өстән аска табан икенче баскычка бастырырга мөмкиндер. Яхшы, иҗтиһадлы башлыкка ул җанын фида кылырга да әзер тора. Өченче төркемгә Мөбахис мәзин кебек хәйләкәрләр керә. Дүртенчесенә – староста Тәхлис ишеләр. Аларга арба ватылса – утын, үгез үлсә – ит. Ә менә Хөрмәтулла абзый сыманнарны кая куярга? Андыйлар, үзләре кыерсытылган булсалар да, башкаларга яманлык теләми. Димәк ки, олы йөрәкле, киң күңелле, кешелекле булып чыгалар. Алар икенче төркемнең бер күзәнәге...» [3, б. 263].

Галимҗан турында әтисе горурлык белән : «Әнә нинди ул үстерәбез... – кайбер утын авыз кебек Хәрти дими бит. Матур итеп, олыларны кадер-хөрмәт итү йөзеннән, эчке бер җылылык, илаһилык белән «Хөрмәтулла абзый» дип әйтә. Димәк ки, һәр адәми затны кешегә саный. Ул гына да түгел, аның язмышы өчен ут йотып, үрсәләнеп йөри. Югалган сарыкны көне буе эзләп иза чиккәннәр. Дөрес әйтә бит, шайтан алгыры: «Ырынбур качмас әле» – ди. Әйе, Ырынбур качмый да, югалмый да, җир дә упмый аны. Ә кеше югалса? Тап син аны яңадан. Менә бит ничек зур уйлый бу «таш маңгай» Пәйгамбәрләр башы бар анда. Пәйгамбәрләр башы!» [2, б. 110].

Ходай Тәгаләнең пәйгамбәрләре кешелек дөньясын вәхшилектән, кыргыйлыктан йолып калып, халыкны тәрбияләгән, Ходай Тәгалә кушкан якты юлга чыгарган. Аларның бу миссиясе язучыларга тапшырылган, алар пәйгамбәрләр кебек үк, кешелек дөньясын матурлыкка өндәгән, кешеләрдә үзара дус булу, тыныч тормышта яшәү, бер-береңне хөрмәт итү кебек асыл сыйфатлар тәрбияләгән.

Суфиян Поварисов һәр бүлекне үгет-нәсыйхәт, киңәш бирердәй ата-ана кисәтүе, бала озатканда уйланулар, ана фатихасы кебек бик матур шигъри юллар белән башлап китә. Мәсәлән:

«И газизем, аяк бастың киң дөньяга,
Юлдаш булсын зур бәхетләр – атла алга;
Гөлләр сипсен фәрештәләр юлларыңа,
Авыр булса, һич сыкранма – түз барына» [3, б. 34].

Солтанморат, Зәңгәр Чишмә буйларының искиткеч гүзәл табигате кешеләрнең якты күңеле белән бергә үрелеп тасвирлана. «Солтанморат бит ул! Ходай Тәгалә аңа оҗмах бакчасының бер як читен кисеп биргән», – ди язучы. Табигать матурлыгы белән хозурлану кешене олы йөрәкле итә. Әтисенең: «Табигать йөрәге матур кешеләргә генә ачыла», дигән сүзләрен булачак язучы күңел сандыгына мәңгелеккә салып куя.

Роман 1906 елда Галимҗанның туган авылыннан Уфага «Галия» мәдрәсәсенә укырга китүе белән тәмамлана.

Әсәр «Казан утлары»нда басылып чыккач авторга төрле тарафлардан бик күп хатлар килә. Язучы Тәүфикъ Әйди: «...көчегезне «Пәйгамбәр таңы» романының дәвамын язуга багышласагыз, минемчә, отышлырак булыр иде. Ибраһимовның катлаулы тормыш, иҗат дәверен сурәтләү үтә җаваплы һәм кыен эш, аңа теләсә кем тотына алмый. Бездә әнә шундый батырлык таләп иткән иҗатка бирелүдән өркү, тарту-сузу аркасында даһиларыбызның балачагы гына кәгазьгә төшәргә өлгерә. Сезнең башлангыч андый язмышка очрамасын иде», – ди [5, б. 79] .

Язучы героеның образын тулырак ачу максатыннан тагын ике роман иҗат итте. «Күкнең җиденче катында» (1999) дигән икенче өлеше Г. Ибраһимовның 1906–1917 еллардагы гомерен үз эченә ала. Трилогиянең бу кисәгендә автор, Г. Ибраһимовның шәхес булып формалашуын, дөньяны танып-белүен, үзе ышанган, илһамландырган юлга төшүенең тарихы тасвирлана. Аның күзаллаулары, төрле хәлләрдә бихисап кешеләр белән аралашуы, илдәге катлаулы вакыйгаларны бәяләве аша без шул еллар мохитен, мәгълүм шартларда Г. Ибраһимовның тулаем җәмгыятькә мөнәсәбәте, карашлар системасы барлыкка килүен күрәбез [1].

Әсәрдә Г. Ибраһимов – атаклы язучы, тарихчы, әдәбият галиме, публицист, методист, педагог, тел галиме, тәнкыйтьче, революционер, усал, кырыс, үзсүзле, башбирмәс, шул ук вакытта кешелекле, аңлы көрәшче, көчле рухлы шәхес буларак күзаллана. Шул сыйфатларны бирү белән генә тукталып калмыйча, Суфиян Поварисов үзендә пәйгамбәрләр зирәклеге, Галимҗанныкыдай сәләт һәм осталык барлыгын дәлилли. Әсәр авторы тарафыннан, авторның галимлеге белән әдиплеге үзара кушыла. Трилогиянең беренче һәм икенче кисәкләре бу дөньяга зур эшләр башкарырга килгән һәм инде күп яктан максатына ирешеп баручы 30 яшьлек ир затының эш-хәрәкәтләрен, уй-фикерләрен, идея-эстетик карашларын сурәтләүдән гыйбарәт.

Трилогиянең «Оҗмагка бер адым» исемле өченче кисәгендә репрессия корбаны Г. Ибраһимовның шәхес буларак формалашкан һәм «халык дошманы» дигән кара ягылганнан алып, төрмәдә һәлак булуына кадәрге тормыш юлы яктыртыла. Әсәр дәвамында, әсәр героеның катлаулы, шул ук вакытта фаҗигале вакыйгаларга дучар булуының сәбәпләре, Г. Ибраһимовның үткәне – Ленин һәм Сталин белән бергә эшләве, гражданнар сугышы вакытында Колчак тылында разведчик булып йөрүе, кайнар мәхәббәте, якыннарын югалтуы, Ялтада дәваланган җиреннән кулга алынуы, Казан төрмәсенә ябылуы, шул катлаулы вакыйгаларда кичергән хис-тойгылары сурәтләнә. Төрмәдә Г. Ибраһимов үзенең үткәннәрен исенә төшерә. Сталин аңа Үзәк мөселман комиссариаты оештыруны тапшыра, шулай итеп, ул Сталин кул астында эшли башлый. 1918 елны аклар һәм чехларның кара дулкыны Казан, Самара һ.б күп кенә шәһәрләргә ябырылгач, Г. Ибраһимовның җаны түзә алмый, һәм үзенең якташы Көнчыгыш фронты

өчен батальоннар оештыру башлыгы Мәхмүт Шаһиәхмәтов янына килә, үзен берәр батальонга җибәрүен сорый. Аны аклар ягына разведчик итеп җибәрергә булалар. Өстенә ямаулы бишмәт кидереп, башына иске эшләпә элеп, иягенә сакал ябыштырып, җигелгән атка утыртып, кырык тартмачы карт кыяфәтендә Г. Ибраһимовны яшерен юллар белән фронт сызыгына үткәрәләр.

1923 елда Г. Ибраһимов Казан университетына лекция укырга чакырыла. Аның керүен студентлар түземсезлек белән көтәләр, чөнки бу лекторның язмышы, татар дөньясында үзенчәлекле шәхес, милләт йолдызы булып балкуы, Ленин, Сталин янында эшләве, Колчак тылында кылган каһарманлыклары – барысы да аларны кызыксындыра. Лекциядән соң ул медицина факультетында укучы Өммегөлсем исемле кыз белән таныша. Өммегөлсем башка белгечлек буенча укыса да, әдәбият белән бик кызыксына, Галимҗанның лекцияләрен тыңларга килә. Тора-бара бу дустанә мөнәсәбәтләр мәхәббәткә әверелә. Уллары Рөстәм дөньяга килә. Ләкин әти кешегә улын рәхәтләнеп сөяргә насыйп булмый. Г. Ибраһимов туберкулез белән авырый, улын үзенең янына якын җибәрергә курка. Дүрт яшь ярымлык вакытында Рөстәмне йөрәк параличы якты дөньядан алып китә. Бала югалту кайгысын икесе дә бик авыр кичерә. Берникадәр вакыт үткәч, Гөлсем ханым Г. Ибраһимовны ташлап чыгып китә. Әсәрдә Галимҗанның кичерешләре табигать күренеше белән параллель куела. Кинәт көчле гарасат куба, җир тетри башлый, җирнең асты өскә килә. Ул боларны вафаты алдыннан кабат күңеленнән уздыра, иң мөһиме – үзе сайлаган юлның дөресме-түгелме икәненә җавап эзли. Тоткан юлы дөрес булса – оҗмахлы, булмаса – тәмуглы. Бу – әдип язмышының иң фаҗигале сәхифәләре.

Билгеле булганча, 1937 елның 29 сентябрендә Ялтада дәваланган чагында Г. Ибраһимов кулга алына. Кичкә табан Г. Ибраһимов бүлмәсенә ике НКВД кешесе килеп керә. Тентү үткәрүчеләр арасында Г. Ибраһимовның «шәкерте» Мөбарәк тә була. Бу кеше белән без Г. Ибраһимовтан соңгы сорау алганда да очрашабыз. Димәк, остазының үлеменә шаһит булган бу кеше йөзендә автор каһәр төшкән репрессия елларында заманның яман агышына җайланып алган, үз тиресен саклаган, үзеннән мең өлеш өстен торган кешеләр язмышына төкереп караган кешеләрне сурәтли.

Г. Ибраһимовны тормыш иптәше дә ире артыннан ияреп, Казанга китә. Ләкин аны да «халык дошманының хатыны» дип төрмәгә утыртып куялар, бер ай буена җәзалыйлар, ә чыгаргач ул «анасыннан аерылып калган бәбкәдәй, ялгыз башын кая куярга белми, шәһәр урамнарында аптырап йөри».

Төрмәдә сорау алу вакытында Г. Ибраһимовны күп тапкыр «халык дошманы» булуын танып, кул куюын таләп итәләр, ләкин ул кул куймый. Соңгы сорау вакытында ерткыч бүредәй бер тентүче каләм белән аның күзләрен төртеп тишә, моннан соң бик каты кыйныйлар. Бу көнне, 1938 елның 20 гыйнварында Галимҗан Ибраһимов мәңгелеккә күчә.

Суфиян Поварисов репрессия елларында илнең алтын баганасына торырлык ватан каһарманнарының корбан булуы хакында ачынып яза. Совет властен оештыру һәм ныгыту өчен көчен һәм сәламәтлеген кызганмаган, коммунистлар партиясенең һәр карарын тормышка ашыру өчен хәтта фанатикларча хезмәт иткән көрәшче-революционерның шундый хәлгә дучар булуын сурәтли. Аның герое җирдә явызлыкның бетерелүен, гаделлекнең тантана итүен күрергә тели һәм шуңа бөтен җаны-тәне белән омтыла.

С. Поварисов «Пәйгамбәр таңы», «Күкнең җиденче катында», «Оҗмахка бер адым» романнарында бөек әдипнең тормыш һәм иҗат эволюциясен бар нечкәлекләре белән ачып бирүгә ирешә. Таһир Таһиров «Таң – хәйран калдыра» исемле мәкаләсендә: «Поварисовның ялкынлы революционер, әдәбият классигы, академик Галимҗан Ибраһимовны әдәби образга, романнар героена әверелдерергә җөрьәт итүе үзе бер кыюлык булса, шул авыр эшне искиткеч уңышлы башкарып чыгуы – чын-чыннан иҗади батырлык, әдәби каһарманлык. Трилогия – татар-башкорт әдәбиятының гына түгел, бөтен төрки халыклар мәдәниятенең зур казанышы, авторның таң-хәйран калырлык уңышы», – дип яза [8, б. 2].

С. Поварисовка Г. Ибраһимовның замандашлары белән аралашу бәхете тими, аларның инде күбесе фани дөньядан киткән була. Шулай да, галим буларак, ул әлеге зур эшкә бик озаклап һәм җентекләп әзерләнә: һәр очраган мәгълүматны теркәп бара, архивларда эзләнә, төрле фактларны терки, чагыштыра, бер җепкә тезә. Аның иҗатын өйрәнеп, 1974 елда ук Уфада «Г. Ибраһимов стиленең үзенчәлекләре һәм аларны мәктәптә өйрәнү» дигән методик кулланма бастырып чыгара. 1980 елда исә, әдәбият дәресләрендә куллануны максат итеп, «Г. Ибраһимов прозасында образлар системасы» дигән икенче хезмәтен тәкъдим итә. Шул рәвешле, әдипне өйрәнү берничә дистә елга сузыла. Ә инде трилогия Суфиян Поварисовның тарихи темада эшләвенең янә бер уңышлы нәтиҗәсе, халкыбызның бөек улы, күренекле дәүләт эшлеклесе һәм төрки дөньяга танылган галим, Галимҗан Ибраһимовның исемен мәңгеләштерүдә зур адым булып тора.

ӘДӘБИЯТ


1. Галимуллин Ф. Галимҗан Ибраһимовның тууына 125 ел // Кызыл таң. 2012. 28 март.
2. Поварисов С.Ш. Күкнең җиденче катында: роман. Казан: Матбугат йорты, 1999. 279 б.
3. Поварисов С.Ш. Пәйгамбәр таңы: роман. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 285 б.
4. Поварисов С.Ш. Оҗмахка бер адым: романнар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. 464 б.
5. Поварисов С.Ш. Прометей яки Галимҗан Ибраһимов хәяте // Галимҗан Ибраһимов һәм XXI гасыр: Тууына 120 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. Казан, 2007. 332 б.
6. Поварисов С.Ш. Особенности стиля Г. Ибрагимова и изучение их в школе. Уфа: БашГУ, 1974. 200 с.
7. Поварисов С.Ш. Язык и стиль прозы Г. Ибрагимова. Уфа: БашГУ, 1979. 50 с.
8. Таһиров Т. Таң – хәйран калдыра // Кызыл таң. 2001. февраль.


## Г. ИБРАҺИМОВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ КАНАТЛЫ ГЫЙБАРӘЛӘР


***Нәбиуллина Г.Ә.***



В данной статье рассматривается употребление пословиц и авторских афоризмов в творчестве Г. Ибрагимова, выявляются их роль в достижении художественной выразительности.

This article discusses the use of Proverbs and aphorisms of the author in the work G. Ibragimov, revealed their role in achieving expression.


Г. Ибраһимов прозасына хас аһәңлелек, камиллек, нәфислек, лиризм һәм романтик рух, иң беренче чиратта, язучының хикәяләү осталыгына

бәйле. Г. Ибраһимовның теле, әсәрләренең тел-стиль үзенчәлекләре, әдип буларак осталыгы турында фәнни әдәбиятта күп язылды. Безнең максат Г. Ибраһимов әсәрләренең текст буларак оешуында һәм стилистик яктан мөһим роль уйнаган мәкальләрнең кулланылыш үзенчәлекләрен ачарга омтылыш ясаудан гыйбарәт.

Г. Ибраһимов әсәрләрендә мәкальләрнең гаять киң кулланыла. Персонаж сөйләме, пейзаж, портрет, психологизм микротекстлары еш кына акыллы гыйбарәләрдән торган хикәяләү нигезендә туа. Мәкаль-әйтемнәр куллану сөйләмне образлы, бизәкле, тәэсирле итә. Алар еш кына сөйләмгә әзер килеш килеп керәләр яисә лексик-грамматик яктан берникадәр үзгәртелеп кулланылалар, яки сөйләмдә мәкальнең идеясе генә дә файдаланылып, яңа канатлы сүз барлыкка килә. Контекстка җайлаштыру йөзеннән мәкальнең текстына төрле чит сүзләр кушу, аның традицион лексик составын яки грамматик формасын үзгәртеп куллану күренешләрен дә күзәтергә мөмкин.

Мәкальнең текстына гомумиләштерү яки, киресенчә, конкретлаштыру характерындагы сүзләр өстәү контекстта мәгънәнең яңгырашын көчәйтә. Мәсәлән, *Бер тәүлектә булдырырга тырыш!* ***Калган эшкә кар ява башлар, тимерне кызуында сугарга кирәк (****Г. Ибраһимов. «Безнең көннәр»); Шулай, карчык,* ***бер авызың пешкәч, суык суны да өреп кабарга кирәк*** *(Г. Ибраһимов. «Тирән тамырлар»).*

Кайбер очракларда яңа сүзләр исәбенә мәкальләр тагын да киңәйтеп әйтеләләр. Бу рәвешле киңәйтеп әйтелгән мәкальләр контекстуаль стилистик таләпкә тулырак җавап бирәләр. Мәсәлән, *Бу ни эш!.. Чех дип, ул чаклы масаймагыз!..* ***Безнең очта да яңадан бәйрәм булыр әле!*** *(Г. Ибраһимов. «Кызыл чәчәкләр»).*

Мәкальне әйтеп бетермәү яки аның текстындагы берәр сүзне махсус рәвештә төшереп калдыру күзәтелә, Мәсәлән, *Кич кайтыр алдыннан чүмәләгә җыя башлагач, уртанчы ул, хахылдап кычкырып җибәрде, ямьсез сүз катнаштырып:*

*–* ***Мактаулы килен****...– ди – дип, бавы чишелгән көлтәне Гөлбану өстенә шаяртып ыргытты. Һәммәсе кычкырып көлә башладылар. (Г. Ибраһимов. «Татар хатыны ниләр күрми»).*

Мәкаль еш кына теге яки бу риторик фигура формасын алган була. Мәсәлән: – Укыткан *хәлфәләрегез сезгә ни кирәген белмиләрмени?* ***Йомырка тавыкны өйрәтәме?*** *Ахмак булмагыз! (Г. Ибраһимов. «Безнең көннәр»).*

Мәкаль текстының традицион синтаксик формасын үзгәртеп әйтү кайбер очракларда мәкальгә ироник мәгънә бирә: *Тавыкны йомырка өйрәтми* мәкале түбәндәге мисалларда шулай кулланылган:

*Син инде, Зифа апай, аш-су тирәсен миннән яхшырак беләсең.* ***Йомырка тавыкны өйрәтә****, дип ачуланма, тик исеңә төшерер өчен генә әйтәм (Г. Ибраһимов. «Тирән тамырлар»).*

Мәкаль составындагы аерым сүзләр дә үзләренең традицион грамматик формаларын үзгәртергә мөмкиннәр. Мәсәлән, түбәндә мәкальнең грамматик хәбәре үзгәртеп әйтелгән: *Ләкин* ***без капчыкта ята алмады****, бу сөйләшләр Шайҗанның хатыны ... колагына чалынды. Ул, бик тырышса, түзә алмады, теле кычытып, бик зур сер итеп, Миңлезифага гына сөйләде (Г. Ибраһимов. «Татар хатыны ниләр күрми»).*

Мәкаль текстының берәр сүзе, мәкальнең бер буыны яки бер кисәге контексттагы сүз яки фраза белән алмаштырып әйтелә: *Сиңа, Хәдичәттәй*

*апай, шатланып киләләр,* ***фатирың тар булса, күңелең киң синең*** *(Г. Ибраһимов. «Безнең көннәр»).* Бу өзектә *урының тар булса да, күңелең киң булсын* мәкале кулланылган.

Түбәндәге мисалда мәкаль үзенең аңлатмасы белән янәшә кулланылган: *Гыймади карт миңа әйтте: бу эт Фәхриләрнең авызларын капламый булмас, диде. Акчасыз эш чыкмый,* ***майламый таба купмый****, диде (Г. Ибраһимов. «Тирән тамырлар»).*

Г. Ибраһимов халык телендә урын алган мәкальләрдән генә файдаланып калмаган, үзе дә канатлы сүзләр, фәлсәфи эчтәлекле гыйбарәләр иҗат иткән. Язучының төрле әсәрләреннән тупланган канатлы гыйбарәләрдән күренгәнчә, Г. Ибраһимов яшәешнең иҗтимагый-сәяси, әхлакый-этик якларына битараф калмаган. Язучы бигрәк тә хыял һәм чынбарлык, дөньяда кешенең тоткан урыны, гаилә мөнәсәбәтләре, язылган һәм язылмаган кануннар хакында уйлана, идея, максат белән яшәргә өнди. Мәсәлән, *Идеясезлек – бик түбәнлек вә хайванлыктыр; Кем үзендә идея хис кыйлмаса, ул адәм рухлыгына ышансын; Кеше идея аркасында кәмаль вә фазыйләткә ирешә; Идеясыз нә нам, нә ихтирам; Татлы хыял! Өмид! Читтән безем хәятымызны да шулар гына саклыйдыр; Өмидләр атлаган саен кырыла бара, ләкин бетми; Өмидләр һәммәсе җилгә корылган; Кеше үзенә үзе хуҗа, һәрбер эшеннән үзе мәсьүл; Дөньяда һичкем үзеннән башканы кайгыртмый; Кеше ни нәрсә эзләсә, шуны таба; Һәр кешенең даирәсе мәсләге, вәсгате, фикриясе илә мөтәкасиб була; Күзләр адәмнең язмышын сөйли; Адәмнең эчке дөньясы, хәят юлында кичергәннәре аның йөзендә эз калдыра; Адәм башы ниләр күрми, ниләргә күнекми!; Дөньяда адәм кызыгырлык берни дә юк; Дөнья-дөнья инде, ул сине баса, аның кызу эшләре, мәшәкатьләре күңелдәге әйбәт уйларны оныттыра; Дөнья куам дип чулак булып калыр хәл юк; Дөньяда бар икән җүләрләр: алдый белгән, алганын ашарга җүне җитмәгән!; Дөнья – мөэминнең зинданы; Дөньясы шулай корылган инде: адәм туа, үсә, тормышның тулкыннары белән каядыр бармак булып сугыша, көрәшә дә, бервакыт үлә; Ни эшләмәк кирәк, дөньясы шулай корылган инде, адәм туа, үсә, тормышның дулкыннары белән каядыр бармак булып сугыша, көрәшә дә бер вакыт үлә. Бу – тимер канун. Моңардан һичкем котыла алмый; Хатыннар – мөлаем һәм дикъкатле җаннар; Балалар фәкать үз гаиләләрен генә сөяләр.* Мисаллардан аңлашылганча, Г. Ибраһимов тудырган канатлы гыйбарәләр тормыш-яшәешнең төрле ягына караган иҗтимагый-сәяси мәсьәләләр, яшәеш кыйммәтләре, әхлакый төшенчәләргә бәйле проблемаларны иңли. Алар әдипнең дөньяга карашын, яшәеш кыйммәтләренә мөнәсәбәтен, фәлсәфи уйлануларын чагылдыралар. Тормышта дөрес һәм гадел юлны табарга, өмет һәм максат белән яшәргә чакыралар. Белем-тәҗрибәсен, акылын чын күңелдән һәм халык теле белән әйтә алган язучының әлеге афоризмнары беркайчан да актуальлеген югалтмыйлар.

Күренгәнчә, мәкальләр тормышның төрле өлкәләрен чагылдырган үтемле, хикмәтле сүз буларак, Г. Ибраһимов әсәрләрендә киң кулланылалар, сөйләмне сәнгатьле, яңгырашлы һәм ышандырырлык итүдә куәтле чара булып торалар. Икенче яктан, геройларның эчке дөньясын, характерын, хис-кичерешләрен, эш-гамәлләрен тасвирлаганда ярдәмгә килә. Безгә калса, әсәрләре канатлы гыйбарәләргә бай Г. Ибраһимовның афористик җыентыгын эшләү кызыклы булырдыр. Мондый хезмәтләрне әзерләп бастыру

Г. Ибраһимовның зирәклегән, тел һәм иҗат байлыгын, фәлсәфи фикер хәзинәсен барлау һәм туплауда әһәмиятле эш булыр иде.

ӘДӘБИЯТ

1. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. 1 т. 507 б.
2. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. 2 т. 476 б.
3. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. 3 т. 450 б.

## ЭТНОГРАФИК МӘГЪЛҮМАТ ЧЫГАНАГЫ БУЛАРАК Г. ИБРАҺИМОВ МИРАСЫ

***Нурмөхәммәтова Р.С.***

Любое художественное произведение несет на себе отпечатки культуры определенного народа с его сложившимися традициями, устоями, менталитетом. В творчестве Г. Ибрагимова находит ярчайшее проявление специфика материальной и духовной жизни татар, где каждый эпизод, действия героев и описание быта – кладезь этнографической информации. Сведения, полученные из произведений Г. Ибрагимова, являются яркими выразителями этнокультурного своеобразия татарского народа начала XX века.

There is the imprint of culture of a certain people with its established traditions, foundations, mentality in any artwork. In the work of G. Ibragimov we can detect the most specific manifestation of the material and spiritual life of the Tatars finds the brightest manifestation, where every episode, the actions of heroes and the description of everyday life are a storehouse of ethnographic information. The information obtained from the works of G. Ibrahimov is a vivid expression of the ethnocultural originality of the Tatar people of the early 20th century.

Халыкларның килеп чыгышы һәм тарихи үсеше, матди һәм рухи мәдәниятенең үзенчәлекләре, иҗтимагый мөнәсәбәтләр, гаилә, көнкүреш, гореф-гадәтләр, бәйрәмнәр һәм йолалар этнография фәненең төп өйрәнү объектын тәшкил итә [3, б. 4]. Этнослар арасындагы аермалар нәкъ менә шушы өлкәләрдә туплана һәм алар барысы бергә этник үзенчәлекләрне, халыкларның кабатланмас йөзен барлыкка китерәләр.

Халыкның хуҗалык, матди һәм рухи мәдәният, гаилә көнкүреше тарихын өйрәнүдә бөек фикер ияләренең, танылган язучыларның иҗатындагы этнографик күренешләрне тикшерү, туплау әһәмияткә ия. Шундый әдипләребезнең берсе булган Галимҗан Ибраһимов иҗатын әлеге максатларда күзәтү этнография, этнолингвистика һәм лингвокультурология фәннәренә кайбер өстәмә мәгълүматлар, ышанычлы дәлилләр бирә, дигән фикердә, бу хезмәттә язучының XX гасыр башында иҗат ителгән ике әсәре буенча («Кызыл чәчәкләр», 1921; «Алмачуар», 1922) татар халкының тормыш-көнкүрешен чагылдырган күренешләрне, аларны атаган лексик берәмлекләрне барлау максаты куела.

Һәр язучы, үзе яшәгән дәвернең актив күзәтчесе, үз халкының тормыш-көнкүрешендә турыдан-туры катнашучы буларак, әсәрләрендә вакыйгалар барган урынның, вакытның кабатланмас тел сурәтен барлыкка китерә. Ул геройларының яшәү шартларын, матди халәтен һ.б. тасвирлауны үзмаксат итеп куймаса да, мондый күренешләрне сурәтләүдән баш тарта алмый. Бу детальләр чор колоритын, геройның характерын тудыруда әһә-

миятле роль уйныйлар. Ә тел галимнәренә, тарихчыларга шул чор ситуациясен, лексик байлыкны тасвирлау өчен гаять кыйммәтле материал булып торалар.

Мәгълүм булганча, этнография фәнен матди мәдәниятка караган *ашамлыклар, ризык табу белән бәйле хуҗалык алып бару формалары, кораллар, йорт кирәк-яраклары, каралты-кура, кием* һ.б.; рухи мәдәниятне чагылдырган *тел, дин, әхлак, сәнгать, шигърият, язу* һ.б., иҗтимагый төзелеш белән бәйле *гаилә, никах* кебек күренешләр кызыксындыра.

Г. Ибраһимов әсәрләре мондый этнографик мәгълүматларга шактый бай, аларны өйрәнү мәдәният күренешләренең үсеш динамикасын бүгенге көннәргә кадәр күзәтергә мөмкинлек бирә. Бу мәкалә кысаларында XX гасыр башы татар тормышының матди мәдәният белән бәйле кайбер күренешләрен тасвирлау белән чикләнәбез.

Язучының алда атап үтелгән әсәрләреннән XX гасыр башында яшәгән татарларның хуҗалык итү рәвеше, аерым алганда терлекчелек һәм игенчелек турында этрафлы мәгълүмат алырга мөмкин.

Табигый яшәү шартларына бәйле рәвештә, татарлар элек-электән иген игү белән шөгыльләнгән. Тикшерелгән әсәрләрдән XX гасыр башында халкыбызның *тары, солы, борчак, арыш, борай, карабодай* үстергәнен күрәбез (алга таба әсәр исемнәре «Алмачуар» – А, «Кызыл чәчәкләр» КЧ рәвешедә кыскартылып биреләчәк): ***Иген****дә өмет зур түгел* (КЧ); ***Тары****ны йомшакка чәчсәң, чүп басып, харап итә* (А); *Бүлеп-бүлеп* ***солы*** *салабыз* (А); *Басуны әйләндек, арба тутырып яшел печән төядек тә иң еракка –* ***борчак*** *җирләренә килеп чыктык* (КЧ); ***Арыш*** *көлтәсе тападым* (КЧ); *Мин авылга кайтып төшкәндә,* ***солы, борай****ны чәчеп бетергәннәр,* ***тары, карабодай****га яңа чыкканнар гына иде әле* (КЧ) һ.б.

Иген игү, җир эшкәртү өчен *сука, сабан, төрән сабан* кебек кораллар кулланылган: *Шуңа күрә әллә кайчаннан кузгалмый яткан авыр* ***төрән сабан****ны тартып чыгаралар* (А); *Урманга, тауга-ташка,* ***сабан-сука****га җиксәң, ул ничек чаба алачак?* (А) һ.б.

Хуҗалыкта терлекләрдән *ат* (тай, колын, бия, айгыр), *сыер*, кош-кортлардан *тавык, каз* асралган, йортта *эт* тотылган: *Алмачуар* ***тай*** *була, тик* ***колын*** *гына булмый икән* (А); *Усал елтыр күзле бер башкорт һич көтелмәгән җирдән үзенең кара бурлы, матур, зур симез* ***бия****сен безгә бүләк итте* (А); *Кола* ***айгыр*** *да аңардан күп калышмый* (А); *Әткәй коткарам дип йөри торгач, актык* ***ат****ыннан,* ***сыер****ыннан яза* (А); ***Каз*** *бәбкәләрен Өзән елгага илтеп кайт* (А); ***Тавык****лар йомырка салгандыр, ояларны кара* (А); *Боларның* ***эт****ләре бик усал бугай...* (КЧ) һ.б.

Әсәрләрдә ат җигү кирәк-яраклары төркеменә караган бай лексика (*нукта, аркан, дуга, тезген, авызлык, чыбыркы, камчы, арба* һ.б.) чагылыш тапкан: *Кичә шуны ишеткәч, әтидән сорамыйча-нитмичә,* ***нукта*** *тоттым да йөгердем* (А); ***Аркан****ның икенче башына кызыл калын* ***дуга*** *тагылган* (А); *Хәзер безгә аннан бер* ***чыбыркы сабы*** *да алырга ярамый!* (А); *Әткәй бакча буенда* ***арба*** *төзәтеп маташа иде* (А); *Минем Алмачуар, озын* ***тезген*** *белән бәйләнгән хәлдә, улакның бер башыннан икенче башына йөреп тора* (А); *Кулына* ***камчы*** *тотып...* (А); *Алда, яисә артта берәр ат күрсә,* ***авызлык****ны тешләп ала да оча гына* (А); *Әткәй нидер кычкырып калды, мин, аңа карамастан,* ***чыбыркы****ны алдым* (КЧ); *Оялышыбыздан сабаннарны,* ***камыт****ларны ташлап, шыр килеп качтык* (КЧ) һ.б.

Йорт / торак теләсә кайсы халыкның матди мәдәниятендә иң мөһим элементны тәшкил итә. «Аның төзелеш үзенчәлекләре һәм семантик тутырылышы халыкның тарихи һәм мәдәни тәҗрибәсе, гаилә кору үзенчәлекләре, билгеле бер этнос вәкилен чолгап алган реалияләр белән турыдан-туры бәйләнгән» [2, б. 4]. Г. Ибраһимов әсәрләрендә татар халкының шул чордагы йорт-җирен, каралты-курасын, өй эчендәге кирәк-яракларны тасвирлаган урыннар еш очрый: *Башкача да* ***йорт-җир****не байтак төзәтте* (А); *Минем сүзне ишетү белән, урыныннан торды да* ***коймага*** *эленгән нуктаны алды* (А); *Боларга тоташып, бераз читкә таба, урта хәлле кешеләрнең уртача зурлыкта* ***өй****ләре, уртача* ***бина****лар үз дәрәҗәләренә күрә урын алалар* (КЧ); *Тагы бераз китсәгез,* ***йорт****лар кечерәя* (КЧ); *Үзем кебек малайларны, кызларны ияртәм дә* ***күпер капкасы****на чыгам* (КЧ); *Без һәммәсенә* ***капка*** *ачабыз* (КЧ); *Ул арада әнкәй дә, күпергә караган* ***читән****гә килеп, миңа кычкыра* (КЧ); ***Читән өе****безнең* ***ишегалды****на чыгып...* (КЧ); *Намаздан кайтышлый, Заһит хәзрәт бу әйбәт тавышны ишеткән дә бакчаның* ***койма****сыннан карап торган* (КЧ); *Мин китәм, бүген үк китәм дә,* ***алты почмаклы өй****, кечерәк бер* ***келәт*** *алып, шуларны Зариф осталар янына күчерергә җитәрлек акча табып кайтам* (КЧ); ***Ишек, тәрәзә, идән, түшәм*** *– бары да бик бөтен* (КЧ); *Тик, бераз биегрәк булсын өчен,* ***нигез****гә берәр* ***бүрәнә*** *салырга туры киләчәк* (КЧ); *Берничә көннән* ***мич*** *тә өлгерде* (КЧ); ***Чолан****нан көрпә алып чыктым* (КЧ); *Шуннан соң гына ул Гыйрфан байның зур* ***сарай****ларыннан, таш* ***пулат****ларыннан курыкмый башлады* (КЧ); *Заһит хәзрәтләрнең йортына килеп җитсә, бөтенләй югалып кала:* ***зур капка****ларга,* ***яшел түбәле өйләр****гә карый да...* (КЧ) һ.б.

Ризык – халык тормышының иң борынгы матди элементы, ул аның яшәү рәвеше, табигать шартларына бәйле элек-электән формалашып, камилләшеп килгән. «Аш-сулар кешенең тормыш итү, яшәү чыганагы буларак, гаилә-көнкүреш, ел фасыллары, бәйрәмнәр белән бәйле йолаларының төп компонентлары саналалар» [1, б. 3]. Әлбәттә, Г. Ибраһимов сурәтләгән геройлар ризык муллыгы һәм төрлелеге белән бик мактанып булмый торган вакытта яшәгәннәр, әмма әсәрләрдә искә алынган ашамлыклар – чор сурәтен тудыру өчен кыйммәтле дәлилләр. Текстлар буенча төрле катлау кешеләренең ашаган ризыклары аерылуын, көнкүрештә өстенлек иткән һәм бүгенге көнгә үзгәрешсез килеп җиткән кайбер элементларны очратабыз: *Менә мин мичкә ягам да* ***белен*** *пешерәм...* (А); *Әткәйләр киткәндә,* ***катык*** *оеп җитмәгән,* ***икмәк*** *тә пешеп өлгермәгән* (А); *Күземә ак-кара күренмәде, каз йомыркасы зурлыгындагы* ***бәрәңге****ләрне,* ***тоз****лап-тозлап,* ***арыш икмәге*** *белән бөгәргә тотындым* (А); *Бу вакыт теге базарчылар симез* ***ит*** *пешертәләрдер,* ***ак күмәч*** *ашыйлардыр* (КЧ); *Көндездән калган ике* ***бәрәңге****не тозлап ашыйм,* ***сөт****сез,* ***шикәр****сез бер чынаяк* ***чәй*** *эчәм* (КЧ); *Бер көнне шулай* ***кечкенә бәлеш****ләр пешергән дә ике баласына икене тоттырган* (КЧ); *Гайниякәйнең ак кулы безгә зур бер тәлинкә белән әйбәтләп киселгән* ***икмәк****, әрчеп туралган суган, байтак ук салкын* ***ит*** *сузды* (КЧ); *Башкорттан мичкәләп* ***кымыз*** *алдырам...* (КЧ); *Яңа күрше Гайнияләр* ***аш-су*** *белән ярдәм иттеләр* (КЧ); *Мин исән-сау, ди,* ***сохари*** *җибәрегез, ди* (КЧ); *Бу җирләрдә* ***ризык****ларың бетмәгән икән әле...* (КЧ); *Мин әнинең хәлен сорашып бетерергә өлгерә алмадым, яшьләр каяндыр* ***май, йомырка, сөт, икмәк*** *тә табып китерделәр* (КЧ); *– Әбкәем, бик харап сусадым. Бозлы* ***әйрән****ең юкмы?* (КЧ);

***Бал-май*** *үземдә күп була...* (КЧ) һ.б. Гади халык табынында балык һәм аның бик күп төрләре ят ризык булмавы күренә: *Мин бер атуда ике куянны алмак булам: бияне дә сакларга,* ***балык*** *та тотарга* (А); *– Анда каптырырга да әйбәт, менә дигән* ***чуртаннар, алабугалар*** *да эләгә... – диләр* (А); *Арада беләк юанлыгы* ***кызылканатлар*** *бар иде, бик зур бер* ***җәен*** *эләккән иде* (А); ***Алабуга****мы,* ***сазан****мы эләгер* (А); *Арада зур ук* ***чабаклар, алабугалар, кызылканатлар*** *бар* (А) һ.б.

«Матди мәдәният элементлары вакытлар үтү белән зур үзгәрешләр кичерә. Кешенең көндәлек тормышында чагыштырмача тотрыклы өлкә саналган ашау-эчүгә бәйле ихтыяҗлар да заман шукымыннан читтә кала алмый» [5, б. 8]. Әлеге әсәр материалы да татар табынына ят ризык-эчемлекләрнең кулланыла башлавын күрсәтә: *Күбесе безгә ярты* ***конфет****мы,* ***прәннек****ме, каткан* ***клиндер*** *кисәгеме ташлап китә* (КЧ); *Менә сезгә алтын шахтасы янында ясалганнан бер* ***кызылбаш****!* (КЧ); *Аңа* ***аракы*** *дип су эчерәләр* (КЧ) һ.б.

Кием-салымнар – халыкның этник үзенчәлекләренә ишарә итә торган элементлар, аларда халыкның күпгасырлык тәҗрибәсе, хуҗалык төзелеше һәм мәдәни дәрәҗәсе, физик-географик яшәү шартларына җайлашуы, эстетик күзаллаулары матди рәвештә чагыла [4, б. 7]. Бу өлкәгә караган терминнар да әсәрләрдә вакыйгалар барган заманның төп күрсәткечләренә карый: ***Яшел чапан****ны бер як кулбашына салды да, икенче кулын* ***кызыл билбау*** *белән муенына асып, акрын гына кайтып китте* (А); *Акчасы күп, имеш;* ***күкрәкчә*** *ясап, янында йөртә, имеш, дип сөйлиләр аның хакында* (А); *Шулай да җиңдем: минем* ***ак киез эшләпә****гә тутырылган йомыркалар белән шырпыны исләренә төшергәч, малайлар риза булдылар* (А); *Кабартып ясаган* ***ефәк*** *бәйләме кебек үзеннән-үзе дулкынланып торалар* (А); *Өскә* ***кызыл киҗеле күлмәк****нең калынын кидем* (А); ***Түбәтәй*** *төшеп кала, диләр* (А); *Мин аякны чишендем,* ***чалбар****ны салдым да бер кулга камчы белән яшел* ***яулык****ны алдым* (А); *Бер якта аллы-гөлле, кызыллы-яшелле* ***чүпрәк*** *диңгезе үз алдына дулкынланып тора* (А); *Аның башында белен кебек изелгән җыртык* ***кәләпүш****, өстендә мең ямаулы, буй-буй җыртыклы* ***киндер күлмәк****тән башка бер нәрсә дә юк* (КЧ); *Ул ара да булмады, бу эт көтүе эченә сары башлы, су күзле,* ***әйбәт кием****ле, яңа* ***итек****ле нindидер бер малай килеп чыкты* (КЧ); *Кулына бераз киелгән, шулай да бик таза* ***күлмәк****, бер иске* ***чалбар****, бер* ***кәләпүш****, бер* ***камзул*** *тоткан* (КЧ); ***Чабата****чы Әхми баласының көтүче булып китүендә нинди гаҗәп эш бар* (КЧ); *Йөрүе бөтенләй бушка булмаганга охшый: аякта* ***итек****, өстә кара* ***чикмән****, кулда* ***күн бияләй****, башта яңа* ***кырма бүрек*** (КЧ); *Өйдәгеләрен онытмаган: сеңлесе Гайниягә ике тәңкә ярымлык* ***шәл****, атасына бер* ***читек****, әнкәсенә* ***күлмәклек*** *алган* (КЧ); *Гайния* ***зәңгәр яулыгын*** *артка кайтарып салды, ак* ***алъяпкыч*** *белән билне кысып <...> бәйләде* (КЧ) һ.б.

Савыт-саба (*самавар, чынаяк, чокыр, тәлинкә, табак* кебек) һәм йорт кирәк-яраклары (*ашъяулык, чаршау, сөлге, өстәл, капчык, шырпы, сандык*), кораллар да (*кармак, көрәк, сәнәк, чалгы, кайчы, кадак, пычкы, өтергe, ышкы, үлчәү* һ.б.) хуҗалыкта бик кирәкле предметлар: *Яшереп куйган* ***шырпы****ны алдым* (А); *Җебем чыдамады –* ***кармак****ны өзеп алып китте* (А); *Мин,* ***ашъяулык****лар,* ***табак****лы бәрәңгеләр өстеннән атылып,* ***йорт****ка чаптым* (А); *Бер* ***самовар*** *кайнарлык вакыт үтмәгәндер* (А); *Әткәй белән әнкәй* ***чаршау*** *артында пыш-пыш сөйләшәләр* (А); *Уянып китсәм, ишек*

*алдында* ***түшәк****тә ятам* (А); *Яшь киленле йортларга кереп,* ***сөлге*** *җыеп йөриләр* (А); *Мин дә, әнкәйнең* ***сандык*** *төпләрен актарып, бер яшел яулыгын эзләтеп алдым* (А); *Кулында зур таяк, аның башына* ***кызыл башлы сөлге*** *эленгән...* (А); *Икенче кулында* ***зур сөлге*** *– бусы икенче килгәнгә билгеләнгән* (А); *Бик зәһәр берничә* ***корыч кармак*** *алып булыр дип уйлап куйганмын...* (КЧ); *Әткәй, Сафа абзый, Шаһи бабай,* ***көрәк****ләр,* ***сәнәк****ләр алып, Әхмәткә тиресне төяргә булыштылар* (КЧ); *Җирән кашкага ашатырга печән чабып алып кайту өчен* ***чалгы*** *да алдык* (КЧ); *Мич буендагы* ***кайчы****ны алып, Шаһбаз башына бәрә* (КЧ); *Нәрсә ясарга: агачмы, нечкә* ***такта****мы,* ***калай****лармы,* ***када****клармы – һәммәсен Гали ташый* (КЧ); *Фазыйлларның бер асравы күп* ***савыт-саба*** *күтәреп бара икән* (КЧ); *Аннан соң бер* ***чынаяк*** *бик каты чәй бирәләр* (КЧ); *Гыйлаҗи тутырып бер* ***чокыр****ны эчә дә кызмача сөйләнә* (КЧ); *Минем* ***пычкы****ларым,* ***өтерге****ләрем,* ***ышкы****ларым кул тидерү белән үзләре йөреп торырлар...* (КЧ); *Минем* ***үлчәү****ләр ике бүрәнә арасына ялгыш кысылган яфракны да сизәрләр* (КЧ); *Ишекне бикләп,* ***ачкыч****ын кесәсенә салды* (КЧ); *Ике* ***чиләккә*** *тутырып,* ***көянтә*** *белән бөгелә-сыгыла Агыйделгә төшеп керләрен чайкап та менде* (КЧ); ***Өстәл****не җыештыргач; яңа күлмәк белән итегемне* ***капчык****ка салып аркама астым* (КЧ); *авылның уртасына таба, теге* ***балта*** *остасы Зарифлар янына күчәрбез* (КЧ) h.б.

Югарыда искә алынган матди мәдәният элементлары – татар тормыш-көнкүрешенә караган мәгълүматның бер өлеше генә. Әмма аларга нигезләп, билгеле бер заманның этнографик сурәтен ачык күзалларга була, шулар буенча үткән һәм бүгенге көн арасында кайбер охшашлыклар, параллельләр табарга мөмкин. Шул рәвешле чорлар арасындагы бәйләнешне, дәвамчанлыкны өйрәнү өчен әдәби әсәрләр, башка чыганаклар белән бергә, кызыклы һәм ышанычлы материал бирәләр.

ӘДӘБИЯТ


1. Баязитова Ф.С. Аш-су һәм халык традицияләре лексикасы. Казан: «Дом печати», 2007. 480 б.

2. Зиангирова Э.М. Татарская лингвокультурология: функционирование концептов «өй» и «йорт» (на материале произведений М. Магдеева). Казань: Казанский гос. ун-т им. В.И. Ульянова-Ленина, 2007. 217 с.

3. Исхаков Д.М. Татары: популярная этнография (этническая история татарского народа). Казань: Татар. кн. изд-во, 2005. 159 с.

4. Татар теленең этномәдәният сүзлеге: матди мәдәният лексикасы (кием-салым, тукымалар һәм бизәнү әйберләре атамалары) / төзүче авторлар: Р.Р. Җамалетдинов, Ә.Ш. Юсупова, Г.Ф. Җамалетдинова, Р.С. Нурмөхәммәтова, М.Р. Саттарова, И.И. Фазлыева, З.Г. Ханова / Тәрҗемәчеләр: А.Х. Әшрәпова, Л.Р. Мөхәммәтҗанова, Л.Р. Мөхәрләмова, Л.Х. Шәяхмәтова. Казан: Казан ун-ты нәшр., 2016. 288 б.

5. Татар теленең этномәдәният сүзлеге: матди мәдәният лексикасы (ризык, һәм савыт-саба атамалары) / төзүче авторлар: Р.Р. Җамалетдинов, Ә.Ш. Юсупова, Г.Ф. Җамалетдинова, Р.С. Нурмөхәммәтова, М.Р. Саттарова, Г.Н. Хөснуллина / Тәрҗемәчеләр: А.Х. Әшрәпова, Л.Р. Мөхәммәтҗанова, Л.Р. Мөхәрләмова, Л.Х. Шәяхмәтова. Казан: Казан ун-ты нәшр., 2015. 280 б.


ЧЫГАНАКЛАР


1. Ибраһимов Г. Алмачуар: хикәя. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. 47 б.

2. Ибраһимов Г. Кызыл чәчәкләр. Электрон ресурс: http://kitap.net.ru/red.php

## ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ҺӘМ КЫРЫМ

***Османов Д.И.***

В статье исследуются некоторые малоизвестные факты жизни и деятельности Г. Ибрагимова в период его пребывания в Крыму в 1927–1937 гг., в частности его эпизодические встречи с крымскотатарскими писателями, сведения из крымской прессы того периода, связанные с Г. Ибрагимовым, а также мероприятия по увековечению памяти писателя в г. Ялте на современном этапе.

The article explores some little-known facts of the life and activities of G. Ibragimov during his stay in the Crimea in 1927–1937, in particular, his occasional encounters with the Crimean Tatar writers, data from the Crimean press of the period associated with G. Ibragimov, and activities to perpetuate the memory of the writer in Yalta at the present stage.

2017 ел, язучы һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның тууына 130 ел тулу белән бергә, аның Кырымга, Ялтага, килеп урнашуына 90 ел үтүгә дә туры килә. 1927 елда Ялтага дәваланырга килгән язучы, монда 9 ел (1927–1936) Халтурин урамының 5 нче йортында торганнан соң, Ялта шәһәр хакимияте аңа Боткин урамының (1936) 23 нче йортыннан ике бүлмәле фатир бирә. Авыру булуына карамастан, Г. Ибраһимов иҗатын дәвам итәргә тырыша, аның папкасында тәмамланмый калган әсәрләр шул хакта сөйли.

Кырымда әдип белән кырымтатар язучылары да элемтәдә тора. «Ени дюнья» («Яңа Дөнья») кырымтатар газетасында хәбәр ителгәнчә, 1928 елда Акмәчеттә Г. Ибраһимовның тууына 40 ел тулуга багышланган кичә уздырыла, аны шунда чыкыралар, ләкин ул, авыру сәбәпле, бу кичәдә катнаша алмый, дип яза кырымтатар галиме И. Керимов [1, с. 36].

1933 елда аның янына Ялтага кырымтатар шагыйре Зиядин Джавтобели һәм Кәрим Җаманкълы киләләр. Язучылар Кырымның әдәби тормышы хакында сөйләшәләр [2, с. 323–324]. 1936 елда Ялтага Казаннан килгән язучылар Шәриф Камал, Кәрим Тинчурин, Галимҗан Нигъмәти Галимҗан Ибраһимов белән даими очрашып торалар, шундый очрашуларның берсендә кырымтатар язучысы Кәрим Җаманаклы да катнаша. Бу очрашулар Галимҗан Ибраһимовның 50 еллык юбилеен Казанда уздыру планнары белән бәйле була. «Г. Ибраһимов кунакларына кырымтатар һәм татар язучыларының очрашулары хакында мәкаләләр басылган «Илери» («Алга») кырымтатар журналын, әзербәйҗан, украин, кырымтатар язучыларының тәрҗемә ителгән аерым әсәрләре басылып килгән «Безнең юл» (1929 ел) журналын күрсәтеп, кырымтатар язучысы һәм драматургы Гумер Ипчинең иҗатын аеруча югары бәяләде», – дип яза К. Җаманаклы [3, б. 8].

1915–1916 елларда Галимҗан Ибраһимов,Уфада «Галия» мәдрәсәсендә татар теле, әдәбияты дәресләрен алып барганда, яшь Гумер Ипчи һәм башка кырымтатар шәкертләре анда укыйлар. Бу хакта Кәрим Җаманаклы Ташкентта кырымтатар телендәге «Ленин байрагъы» газетасының 1962 елның 18 март санында «Алимджан Ибраимов»исемле мәкаләсендә язып чыга.

«Бу шәкертләр арасында өлкән язучыбыз Умер Ипчи (Алкедай), намлы татар шагыйре Шәехзадә Бабич, башкорт шагыйре Сәйфи Кудаш та бар иде», – дип хәбәр ителә мәкаләдә. Гомумән, мәкаләдә Галимҗан Ибраһимовның тормыш юлы, иҗаты турында сүз бара һәм аның 1928 елда «Тирән тамырлар» романын Ялтада тәмамлавы турында әйтелә [4, б. 4].

1936 елда Казаннан килгән язучылар белән Ялтада булган очрашуларда Казанда тел, әдәбият һәм тарих гыйльми институтын оештыру кирәклеге, Казанның бу мәсьәләдә милли республикалардан артта калганлыгы хакында да сүз куертыла.

«Кырымтатарларының тел, әдәбият институтын һәм башка республикалардагы институтларны телгә алдылар, алар тарафыннан әзерләнеп чыгарылган гыйльми хезмәтләр турында үзләренең фикерләрен әйттеләр. Галимҗан ага Симферополь тел, әдәбият гыйльми тикшеренү институты галиме Якуп Кемаль тарафыннан 1930 елда әзерләп чыгарылган «Нехдж-ульфарадис» («Тюрко-татарская рукопись XIV в.») әсәренең әдәбиятыбызны өйрәнү юлында зур әһәмияткә ия булуын ассызыклый» [5, б. 326]. Тора-бара Г. Ибраһимов Кырымны үзенең яңа әдәби Ватаны дип атый.

«Мин Кырымны бик артык яраттым»...

Г. Ибраһимов Ялтада язучылар белән очрашканда, Кырым тормышы белән бәйле әсәр язарга хыялланганын да белдерә. Бу хакта ул Мәҗит Гафури, Мөхтәр Ибраһимовка үзенең хатларында язганы турында кырымтатар язучысы Кәрим Җаманаклыга әйтә.

Кырымда Г. Ибраһимовның шәхси тормышында да үзгәрешләр килеп чыга. Аның янында үзе белән Кырымга килгән җәмәгате, әдипнең бердәнбер улы Рөстәмнең (1926–1931) әнисе – Гөлсем Мөхәммәдова яши [6, с. 243]. Кызганычка каршы бу бала 4 яшендә вафат була. Бу юлларның авторына, Галимҗан Ибраһимовның Башкортстаннан килгән туганы Марат Ибраһимов белән бергә, 2007 елда Кырымның СБУ (элеккеге КГБ) хезмәтеннән Г. Ибраһимов турында мәгълүматлар эзләп барганда, мондый мәгълүматнең юклыгы хәбәр ителде. Ә менә Кырым ЗАГСының архивында Рөстәмнең вафаты хакында мәгълүмат сакланганы билгеле булды, ләкин ни өчендер бу хакта мәгълүмат М. Ибраһимовның китабында чагылдырылмый. Г. Ибраһимовтан аерылган соң, Гөлсем Мөхәммәдова (1904–1988) кырымтатар шагыйре Абдуреим Шәех-заде Алтангъа (1898–1976) кияүгә чыга. Кырым татарларын 1944 нче елда туган җирләреннән сөргәндә, әлеге гаилә Сәмәрканга җибәрелә. Аларның Сөмбел исемле кызлары туа. Соңгында Гөлсем ханым кызы белән Казанга күченеп кайта һәм гомеренең ахыргы көннәренә кадәр биредә яши. Г. Ибраһимов исә, 1935 елның 7 нче июнендә Фәтхуллина Хәдичә белән гаилә төзи.

Кырымда, Г. Ибраһимовка карата кызыксыну узган гасырның 1996–1997 елларында, кабат уянып китә. Кырымга сөргенләктән кайта башлаган кырым татарларының ярымутрауда еллар буе хөкем сөргән мөхиткә тәэсирләре нәтиҗәсез калмый. Һәрхәлдә ярымутрауда яшәгән татарларның да милли җанлануы, аларның төрле шәһәрләрдә милли-мәдәни үзәкләре пәйда булуы шушы чорга туры килә.

1997 елда Кырымның җөмһүрият мәдәният фонды янында оешкан милли җәмгыятьләр ассоциациясе Галимҗан Ибраһимов исемендәге премия булдыра. Бу премия белән Кырымда яшәүче Идел буе татарларының мәдәниятенә өлеш керткән Марат Сәфәров (1998, «Идел» үзәге рәисе), Фоат Мортазин (1999, язучы, галим), Рифкат Хәйбуллин (2000, журналист) бүләкләнә.

Ялтадагы «Равенство» (рәисе С. Невретдинов) милли азчылыклар шурасы, «Акчура» (рәисләре Р. Акчурин, Рәисә Алексеева) татар үзәге исә, Ялтаның Халтурин урамында Галимҗан Ибраһимов яшәгән йортка истәлек тактасы урнаштыру башлангычы белән 2000 елда шәһәр хакимиятләренә

мөрәҗәгать белән чыга [7]. Берничә елга сузылган ике арада язышу нәтиҗәсендә, Ялта шәһәр хакимияте 2007 нче елның 25 нче октябрендә Галимҗан Ибраһимов яшәгән Халтурин урамындагы 5 йортка аның хөрмәтенә истәлек тактасы урнаштыру карарын чыгара [8]. Татарстанда ясалган, Кырымга китерелгән бу такта 2008 елның апрелендә тантаналы рәвештә язучы яшәгән йортка урнаштырыла. Чарада Казаннан Галимҗан Ибраһимов исемендә тел, әдәбият, сәнгать институтының директоры, галим Ким Миннуллин, Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының директор урынбасары, галим Фәрит Солтанов, Бөтендөнья татар конгрессының вәкилләре Рөстәм Гайнетдинов, Рамис Сафин, Татарстанның халык артисткасы, җырчы Гөлзада Сафиуллина, «Акчура» Ялта татар үзәге, «Идел» җөмһүрият татар үзәге вәкилләре катнаша.

Шуны да әйтергә кирәк: бүгенге көндә Ялтаның бер китапханәсендә һәм музеенда да Г. Ибраһимовка багышланган бер генә экспозиция дә юк. Ялтаның «Акчура» үзәгенең инде күптән Халтурин урамындагы 5 нче йортны үзәккә бирелүен таләп иткән мөрәҗәгатьләре һаман да җавапсыз кала бирә. Бу мәсьәлә уңаеннан Татарстанның рәсми даирәләре үз сүзен әйтергә тиешләрдер.

«Ялтага килгәндә мин үлем хәлендә идем. Кулдан каләм төшкән, көч беткән иде. Аның табигате, шифалы һавасы, мине аякка бастырды. Мин Кырымны бик артык яраттым. Кырым минем өчен дөньяның иң матур, иң мәгънәле, иң тирән хисләр уяткан яңа әдәби Ватаным булды», дип яза Галимҗан Ибраһимов. Аның «Тирән тамырлар», Безнең көннәр» романнарының нәкъ менә Ялтада тәмам булулары мәгълүм.

ӘДӘБИЯТ


1. Керимов И.А. Крымскотатарская довоенная пресса о Галимджане Ибрагимове // Наследие Г. Ибрагимова и тюркский мир: Материалы международной научно-практической конференции, посвященной 125-летию со дня рождения Г. Ибрагимова. Казань, 2012. С. 36–37.
2. Җаманаклы К. Әдипләр һәм галимнәр дөньясында. Г. Ибраһимов турында истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1966. Б. 323–324.
3. Галлямова Д.Г. Керим Решидов Джаманакълы: имя в Отечественной истории Крым – Казань – Елабуга. Казань: Издательский дом «Логос». 2016. 8 с.
4. Ленин байрагъы // Ташкент, 1962. 18 март. 4 б.
5. Җаманаклы К. Г. Ибраһимов турында истәлекләр // Әдипләр һәм галимнәр дөньясында. Казан: Татар. кит. нәшр., 1966. 326 б.
6. Ибрагимов М.Х. Галимджан Ибрагимов. Казань: Татар. кн. изд-во. 2012. 243 с.
7. «Равенство» милли азчылыклар шурасы, «Акчура» үзәге мөрәҗәгате. 08.06.2000. № 16/4.
8. Ялта шәһәр хакимияте карары. 25.10.2007. № 2119.


## Г. ИБРАҺИМОВ ХИКӘЯЛӘРЕНДӘ ӘХЛАК ПРОБЛЕМАСЫ


***Рәхмәтуллина А.А.***



В рассказах Г. Ибрагимова поднимаются вопросы добра и зла, совести, человеческого достоинства, справедливости. Герои рассказа «Любовь – счастье» («Сөю – сәгадәт») несут с собой свет надежды и веры, любви и сочувствия, нежности и понимания – каким должен быть человек. В рассказе «Мулла-вор» («Карак мулла») безнравственность и жестокость главного героя Тимери переходят в преступление. Потеря совести, пренебрежение народными

традициями, отсутствие уважения к людям – все это приводит к тому, что люди превращаются в преступников.

In his stories G. Ibrahimov raises the questions of good and evil, conscience, human dignity and justice. The heroes of the story «Love is happiness» carry (или bring) a light of hope and faith, love and sympathy, tenderness and understanding – what a person should be like. In the story «Mullah-the-Thief» («Karak Mullah») immorality and cruelty of the main character Timeri turn into a crime. Loss of conscience, disregard for national traditions, lack of respect for people – all these lead to the fact that people turn into criminals.

Хәзерге вакытта Россия мәгариф өлкәсенең, җәмгыять һәм дәүләтнең мөһим максатларның һәм иң зур бурычларның берсе югары әхлаклы, җаваплы, иҗади, инициативалы, компетентлы гражданнар тәрбияләү [3, б. 12]. Әхлакый сыйфатлар тәрбияләүнең бер чарасы – матур әдәбият. Әдәби әсәрләрнең яшь буынга әхлак тәрбиясе бирүдә әһәмияте гаять зур. Кешедә гуманизм сыйфатлары тәрбияләү, югары әхлак идеалын тудыру татар әдәбиятында әле борынгы чордан ук төп темаларның берсе саналган [3, б. 39]. Кешелекнең төп әхлакый сыйфатлары – намус, гаделлек, җирдә дөрес итеп яшәү, ата-ананы хөрмәт итү кебек төшенчәләр мәңгелек, һәр халык өчен уртак. Кеше булу һәркем үзендә әхлакый сыйфатлар тәрбияләргә, җәмгыятьтә кабул ителгән әхлак нормаларына туры килгән яшәү рәвеше сайларга, халыкның гореф-гадәтләрен хөрмәт итәргә тиеш [1, б. 8]. Татар телендә әдәбият сүзе әдәп сүзе белән бер тамырдан. Бу сүзнең бер мәгънәсе яхшы тәрбия һәм әхлакны аңлата, әдәбият югары әхлакый кыйммәтләргә нигезләнгән кешелеклелек – гуманизм идеяләрен яклый. Кешелекнең төп яшәү кагыйдәләре яхшылык белән яманлыкны аеруга юнәлтелгән. Кеше яхшылыкны үз кыйбласының төп юнәлеше итәргә омтыла. Татар халкының әхлак нормалары ислам кануннары белән дә аваздаш булып, бу кануннар белән дә ныгытыла. Балага кече яшьтән ата-ананы хөрмәт итәргә, туганнарга, гомумән кешеләргә шәфкатьле булырга, көчсезләрне кыерсытмаска, ярдәмчел булырга, саран һәм хөсетле булмаска, гайбәт сөйләмәскә, үчле, явыз булмаска кирәк дигән фикер сеңдерелә.

Г. Ибраһимов иҗатында да гуманизм идеяләре, гомумкешелек проблемалары һәр әсәрендә күтәрелә. Әдип татар халкының әхлакый сыйфатларын, бөтен кешелек өчен хас сыйфатларны, тәрбия мәсьәләсен күтәрә. Халыкның гасырлар дәвамында формалашкан гореф-гадәтләрендә чагылган әдәп-әхлак кануннарын барлый, халыкның рухи кыйммәтләренә дан җырлый.

Г. Ибраһимовның «Табигать балалары» хикәясендә гади кеше һәм аның рухи матурлыгы олылана, аның хезмәтенә һәм мәхәббәтенә дан җырлана. Бу әсәрдә авыл кешесенең ярдәмчеллеген, ихласлыгын, өлкән яшьтәгеләргә ихтирамын һәм мәрхәмәтен күрсәткән өмә эпизоды бар. Төп герой Хафизның күршесе ялгыз Бәдри карчык. Көз җитә башлагач, ул үзенең тарысын өмә белән урдырырга тели. Көз – крестьян өчен эш вакыты, һәр кешенең үз мәшәкатьләре дә күп вакыт. Авыл кешесенең ярдәмчесез карт-карчыкларга мөнәсәбәте Хафиз аша әйттерелә: «*Андый ятим карчыкларга бармый килештереп булмый инде*» [2, б. 183]. Татар халкы һәрвакыт өлкән яшьтәгеләргә игьтибарлы булган, аларны рәнҗетмәскә тырышкан. Өлкәннәргә, бигрәк тә ата-анага мөнәсәбәт Хафизның әнисе белән мөнәсәбәте аша да

ачыла. Ул өйләнүе белән әнисен дә сөендерергә тели: «*Әнкәйнең картаюы да бар, ул күңеленнән рәнҗидер, минем кебекләр түр башында килен хезмәте күреп утыра, мин әле һаман утын кертеп, идән юып йөрим ди торгандыр*» [2, б. 186]. Шул ук вакытта геройның туганнары турында да уйлаганы күренә. Татар халкының әдәп-әхлак сыйфатларын үлчи торган гыйбарәләрнең – «*Кешедән яхшы түгел*», «*Кеше нәрсә әйтер*» Хафиз өчен дә кагыйдә булып тора. «*Агай-энеләремнән дә яхшы түгел, яшем егермеләрне үтеп, һаман өйләнмәгәч, алар минем өчен кызарып, гарьләнеп йөриләр бугай*» [2, б. 186]. Хикәядә татар халкының эстетик идеалы да гәүдәләнә. Кызлар тыйнак, сабыр, эшкә уңган, чиста-пөхтә, бераз оялчан, төскә биткә чибәр булырга тиеш. Шул ук вакытта аның кешеләр белән мөгалләмәсе, үз-үзен тотышы да игътибар үзәгендә. «*Шаһи картның алма кебек кызы бар, эшкә дисәң авылда бер. Үзе шундый сылу, үзе зифа*» [2, б. 181], «*Бибиәсма хәйран уңган бит... Кыз кеше инде, аңар бар да ак булсын, бар да пакь булсын, бар да ялтырап торсын...Чәйгә утырсаң исең китәр: ашъяулыгы нинди... самовары алтын кебек, чынаяк-саба дисеңме, – бар да уңган кыз кулы шул*» [2, б. 187]. Халыкның өйләнергә яше җиткән егетләр өчен дә идеал образы бар. Бу – эшчән, бер эштән дә курыкмаган, йорт-җире җитеш, тәвәккәл, батыр, сау-сәламәт, буйлы, көчле егет. Хафиз шул таләпләргә туры килә. Әнисе белән генә яшәвенә карамастан, ул үз тырышлыгы белән йорт-җирен җитешле итә, тырышып мал тота, бер эштән дә курыкмый: «*Мин егерме бер яшьтәмен. Өч атым, ике сыерым, ун баш сарыгым бар. Үткән көзне өйне дә сипләттем, алты почмаклы ясаттым. Шуңар дип боярдан урман алган идем, кыш буе утынын ягып рәхәтләндек, аның өстәвенә, ваграк булса да, кырык җиде бүрәнәсе калды. Насыйп булса, тагы бер-ике имән багана алып, киләсе көзгә капканы яңадан эшләтергә, кечерәк булса да, келәт салдырырга исәплим. Аннан соң тик мунча кала – заманы белән анысы да булыр әле, Алла боерса!*» [2, б. 180]. «*Мин инде әдәм алдында хур булырлык егет түгел, мактанудан булмасын, Ходайга шөкер дип әйтәм. Буем, төсем яхшы, бар җирем таза-сау*» [2, б. 181].

Татар халкы вакытында гаилә корып, балалар үстергән кешеләрне хөрмәт итә. Әсәр Хафизның өйләнеп, үрнәк булырлык гаилә коруы белән тәмамлана. Геройларның, бигрәк тә Хафизның, мәхәббәт өчен көрәшүләрендә, аларның рухи ныклыгында, шәхес буларак камиллегендә әсәрнең идея-әхлакый проблематикасы чагыла.

Әхлак нормаларын бозу кешеләргә бәла-казалар, тирән борчулар китерә. Әдәпнең «Карак мулла» хикәясендә әхлаксызлык, бозыклык үрнәге булган Тимри образы тасвирлана. Тимринең бөтен нәселе – ата-бабалары үзләренең явызлыклары белән тирә-юньгә фаш булган кешеләр. Г. Ибраһимов бу нәселне түбәндәгечә сурәтли: «*Аларның бер бабасы, юлчылар төшергән булып, үзенә кунарга килгән зур байларны талый торган иде. Үзе үлгәч, коесын тазартканнар икән, әллә ничә адәм башы, адәм гәүдәсе чыккан*» [2, б. 95]. «*Караклык белән даны чыккан бу нәсел, мал урлау берлән генә түгел, болай усаллык, батырлык һәм бик аз нәрсә өчен дә дөнья җимереп үч алучанлык, куәтлелек һәм зур гәүдәлелек берлән дә атаклылар иде*» [2, б. 95]. Автор, әлеге нәселгә шул рәвешле характеристика биреп, әсәр башында ук бу геройдан бернинди яхшылык көтәргә ярамавын хәбәр итә. Тимери мәдрәсәдә белем ала. Шул вакытта ук ул үзенең явыз асылын тыя алмый. Кешеләрдәге курку һәм битарафлык хисен файдаланып, явыз-

лык эшләвен биредә дә дәвам итә. Караклыгы фаш ителеп мәдрәсәдән куылганнан соң да, Тимери ике төрле дөньяда яшәвен дәвам итә. Ул, бер яктан, авылның мөэзине, мулласы вазифаларын башкара, икенче яктан, караклар дөньясы белән дә арасын өзми. Авыл халкының бу вакыйгалардан хәбәре булса да, битараф кала бирә. «*Халык эчтән көлә, бер мөнәсәбәтсезлек сизенәләр, ләкин тыштан һәркем: «Бер минем өчен генә түгел, илгә ярагач, бер миңа ни калган!» дип дәшмиләр, аның мөэзин булу мәсьәләсе чыккач, бар да ирексез тамга салганнар иде*» [2, б. 100]. Явызлыкның үсеп китүендә кешеләр, бу очракта авыл халкы үзләре дә гаепле. Бөтен кеше үз өстенә җаваплылык алудан кача. Тимеринең кырын эшләре әледән-әле кеше теленә керә. Тирә-яктагы явызлыкларның башында Тимери тору бер кешедә дә шикләнү уятмый. Тимеринең үзенә дә ике тормышта параллель яшәү кыен була башлый, ул «мулла» битлеген ташлап, үзенең асылына кайта. Тимери кылган җинаятьләр артканнан арта барып, ул вәхшилекнең соң чигенә җитә – кеше җаны кыела. Бары шуннан соң гына, бар халык җыелып аның өстеннән «усалның монда яшәмәвен ил халкы тели» дип язып, аны илдән куалар. Г. Ибраһимовның бу әсәрендә әхлаксызлыкның җинаятькә бара торган юл булуы күрсәтелә.

Тормышның нигезендә әхлаклылык ята. Әхлак – иман кешенең яшәеш чорындагы тәртип билгесен күрсәтә, аның барлык күркәм сыйфатларын берләштереп тора. Г. Ибраһимов әсәрләрендә тәрбия кылуның ата-бабаларыбыздан килгән гореф-гадәтләр, дини һәм дөньяви йолалар, хезмәт, гаилә һәм милли традицияләребез, җәмгыять тормышында урнашкан әдәп, әхлакый кыйммәтләр, ислам диненә салынган әхлакый һәм гуманистик идеяләр, шәригать кануннарына нигезләнгән булуы күренә.

ӘДӘБИЯТ


1. Әдәбият белеме сүзлеге / төзүче редактор А.Г. Әхмәдуллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. 238 б.
2. Ибраһимов Г. Сайланма әсәрләр. 1 том. Казан: Таткнигоиздат, 1957. 528 б.
3. Концепция духовно-нравственного развития и воспитания личности гражданина России в сфере общего образования: проект / А.Я. Данилюк, А.М. Кондаков, В.А. Тишков. М.: Просвещение, 2009. 24 с.


# КОНЦЕПТ *ХАТЫН-КЫЗ* (ЖЕНЩИНА) КАК ФРАГМЕНТ ИНДИВИДУАЛЬНО-АВТОРСКОЙ КАРТИНЫ МИРА Г. ИБРАГИМОВА


***Сагдеева Ф.К.***



Предметом рассмотрения в данной статье является смысловое содержание концепта *хатын-кыз* (женщина), воссоздаваемое на основе лексической экспликации в художественной прозе Г. Ибрагимова. Основным фактором, повлиявшим на выбор объекта исследования, является то, что в художественных текстах этого писателя широко представлен материал для выявления указанного концепта как фрагмента индивидуально-авторской картины мира.

The subject of this article is the semantic maintenance of a concept hatyn-kyz (woman), recreated on the basis of a lexical explication in G. Ibragimov's works of fiction. The main factor that influenced the choice of the object of research is that in

the literary texts of this writer the material, for revealing this concept as a fragment of the individual author's picture of the world, is widely presented.

Известно, что в качестве выявления содержания концепта может служить художественная речь, построенная на основе концептуальных авторских ассоциативных полей, с точки зрения структуры представляющих собой сеть отношений между ключевым словом и его употреблениями, актуализирующими те или иные компоненты исходного слова. Писатели способны обогатить содержание концепта своими ндивидуальными приращениями как содержательного, так и прагматического характера. В художественном тексте, являющемся результатом речемыслительной деятельности, автор вербализует свою концептуальную картину мира. Исходя из этого, на основе когнитивного анализа художественного текста возможна реконструкция модели концептуальной картины мира автора или выявление фрагментов ее содержания – концептов.

Обращение к художественной речи позволяет обогатить не только информативную, но и прагматическую составляющую концепта, актуализованную автором в образно-эстетической форме. Художественный текст представляет индивидуально-авторское видение содержания концепта, которое дополняется многочисленными смыслами, вносимыми читателями в процессе восприятия и интерпретации текста. Ассоциации, возникающие в процессе чтения художественного текста, способствуют постижению художественного текста, постижению художественного мира автора, его эстетической позиции, системы образов.

Анализ толкований лексемы *хатын-кыз* позволяет выявить основу ее семантики, состоящую из категориально – лексической семы 'лицо' + семы, конкретизирующей 'лицо' в аспекте половой принадлежности – ' женский пол', 'противоположное по полу мужчине'. Неопределенность семантического компонента ' противоположное по полу мужчине' дает большие возможности для осуществления дальнейшей конкретизации этого понятия на уровне вторичных значений.

Женщины в художественной прозе Г. Ибрагимова представлены разноаспектно, они различаются по национальности, социальному положению, возрасту. В индивидуально-авторской картине мира образ женщины в основном имеет положительную оценку. При этом женственность ассоциируется с любовью, умом, красотой, решительностью, терпением, выносливостью.

В словах *кыз бала, кыз, хатын, карчык, хатын-кыз* воплощается один из центральных образов художественных произведений Г. Ибрагимова. В процессе форимрования в художественном тексте его содержание постепенно обогащается все новыми концептуальными смыслами, включающими всю коммуникативную и эстетически значимую информацию о предмете, которая лежит в основе концепта.

В смысловой структуре реального фрагмента концепта *хатын-кыз* представлены следующие семантические аспекты парадигматической актуализации:

пол: *ир, жегет, ир жегет, карт;*

возраст: *кыз бала, кыз, өлкән хатын (в значении взрослая женщина*) *карчык;*

родственные отношения: *кыз (в значении дочь), килен, яшь килен, зур килен, килендәш, хатын (в значении жена), каенана каен сеңел, кодагый, җинги, балдыз, якын кардәше, апа, әби;*

семейное положение: *кәләш, хатын (в значении жена);*

социальная характеристика: *байбичә, бай хатыны, хуҗа хатын, ялчы хатын, данабикә, ярлы хатын, фәкыйрь карчык, пешекче хатын, асрау хатын;*

национальная и территориальная отнесенность: *татар хатыны, казакъ кызы, башкорт карчыгы, марҗа, Караюрга хатыннары, Карамалы кызы и др.*

Как показывает материал, парадигматические актуализации концепта в художественном тексте выражают, как ядерные аспекты смысла – такие, как пол, возраст, семейное положение, так и околоядерные – социальная характеристика, национальная и территориальная отнесенность.

В художественной речи на фоне субстантивов специфическими признаками выделяются лексемы, названные нами вокативами по их примарной функции – ласковые обращения к девушке, женщине: *карагым, колынчагым, җаным, иркә таем, чырагым* и др. Например: *Колынчагым, куйсаңчы юкны, мал, бәхет эчендә усәсең, ил эчендә якты йолдыздай сылулыгың бар, тагы җитмәгәнең нәрсә?* [2, с. 355].

Следует заметить, вокативы называют лицо присутствующее. Денотативная специфика заключается в том, что они называют лицо как некоторую социально-ориентированную коммуникативную модель. Именуя лицо по присущей ему коммуникативной роли адресата, вокативы не предицируют индивидуализированной информации, а лишь те признаки, которые востребованы в конкретных условиях коммуникации.

Объективация концепта *хатын-кыз* (женщина) в тексте художественных произведений Г. Ибрагимова вокативами, т.е словами категории адресатности, отражают индивидуально-авторскую картину мира писателя.

В данном случае семантическая структура вокативов близка к прототипической, поэтому с этой точки зрения они скорее всего являются стилистическими синонимами лексемы – *син* (местоимением), чем именами существительными.

Разветвленность парадигматических ассоциаций позволяет выделить текстовые парадигмы, воплощающие отшношение автора к героиням, формирующим ценностную картину художественного мира автора.

Анализ парадигматического контекста дает возможность установить некоторые смысловые компоненты в структуре околоядерных парадигмантов, позволяющих на основе их сопоставлений ярче представить образ героинь – женщин, описываемых Г. Ибрагимовым: девочка – беспомощная, доверчивая; девушка – молодая, красивая, избранница мужчины, неопытная в отношениях с мужчиной, потенциональная невеста, предчувствующая счастье; невеста – красивая, чистая душой, телом и помыслами.

Синтагматический контекст располагает большими возможностями в прояснении потенциальных смыслов лексемы. Значимыми в этом плане являются слова признаковой лексемы, функционально-ориентированные на характеризацию образов, создание эмоционально-оценочного дискурса в художественной речи. Признаковая лексема служит основным средством воплощения внешней, портретной характеристики и внутреннего мира женских образов персонажей.

В синтагматическом авторском контексте описываются как традиционные харакеристики девушки, так и индивидуально-авторские. Для создания портретной характеристики Г. Ибрагимовым используются отдельные слова признаковой лексики. Самыми употребительными при описании внешности являются слова, связанные с понятием *матур – матур, мөлаем, ягымлы, сылу* и др. Например: *Матур җиңгәләрнең йорты янәшә, ике арада кечкенә ишек кебек кенә капка да ба*р [1, с. 228]; *... гаҗиб мөләем бер ханым; әлеге минем исememне язып алган ягымлы, матур хатын* [1, с. 180]; *Кызларның сылулары, җегетләрнең асыллары кара-каршы килгән икән* ... [2, с. 357].

Для создания портретной характеристики писатель наряду с отдельными словами признаковой лексики использует целые синтагмы, перифразы, включающие эпитеты, элементы сравнения, метафору, позволяющие образно представить портрет героини: «*Әнә фирештә кебек ак киемле, ачык йөзле кызлар... Болар арасындагы теге, зур кара күзле кыз... Бу бит адәм түгелдер фирештәдер, фирештәнең дә иң олысы, аллага иң якын булганыдыр...*

*Аның ак алсу йөзе... зифа буе... тәнен йомшак кычаклап-урап алган ак киеме... Бөтен дөньяга сөеп, иркәләп карый торган зур, матур кара күзе... шат кына елмаюы, матур елмаеп, сөеп, иркәләп карап, матур тавышы белән ниндидер матур әйберләр турында сөйләве...*» [1, с. 180]. В данном случае актуализируется признак *привлекательность.* Для выражения физической привлекательности женщины используются следующие *телесные* признаки: *лицо, глаза, фигура* и др.

Эстетически отрицательный признак *непривлекательность* актуализируется такими языковыми единицами, как *ямьсез, карчыкның ачулы йөзе, тәхкыйрь белән тулган тавышы* и др.

Анализируемый материал показывает, у Г. Ибрагимова портрет женщины не отождествляется с простым описанием внешности, ее лица, фигуры, одежды. В портрет включается описание внешнего и внутреннего состояния героини, ее действий и взаимоотношений с другими персонажами, манеры говорить и образ мышления, а также описание характера. Например, *Айбала фәкыйрь, ямьсез, ләкин ваемсыз, һәрвакыт шат күңелле, дәртле йөрәкле бер хатын иде* [2, с. 354].

Внутренний мир образа реальной жещины в художественной речи автора представлен следующими актуальными смыслами:

влюбленность и мечтательность: *Кызның йөзе ачылды. Күзләрендә мәхәббәт нуры ялтырады, тулы карасу-кызгылт иреннәрдә елмаю уйнады... Гуя уз эчендә уйнаган шатлыкка, зиһенендәге матур хыялга карап, акрын: – Сизгерлегең бар, ау, җиңгәм!.. – дип, акрын гына көлде, саф энҗедәй тезелгән вак тешләре ялтырап калды* [2, с. 355];

нежность и преданность: *Иркә таем, – диде, – кичә Калтай белән булган эш өчен акылсыз сердәшеңне кичергән булсаң, төшеңне сөйлә, йөрәгеңне ач!*

способность сопереживать: *Карагым, сиңа ни булды? Сулган гөлгә охшап калгынсың гуй!.. – дип, иркәле кызгану белән йөзеннән үпте, икесенең дә зиһеннәре икенче якка китте.*

*Киленчәк ихлас күңелдән борчылды, кызның мендәрен каплап, тулкынлап яткан кара җефәк чәчләрен уйнатып, ярым кочаклады* [2, с. 354, 355];

умение шутить*: Ишектән керүгә, эле һаман юрганнар эчендә иренеп яткан дусын шаяртып шелтәләде* [2, с. 354];

дружба между женщинами: *Болар бик күптәнге дуслар, сердәшләр иде*;

способность испытывать радость и волнение: *Карчыкның күзләренә нур кереп китте, күңеленә дулкын йөгерде, гомерендә күрмәгән жылы мамык шәлне, балалар кебек шатланып, шунда ук ябынып карады*;

способность испытывать страх: *Карчыкның җаны бугазына килде «Үлем шулдыр, бетәмдер, болар газраилдер», дип уйлады. Калтырап, бетеп, иреннәрен ике якка аерды* [3, с. 255]*; йөрәгем шуннан куркып калды* ; *бу куркыныч кызның уз башын да күптән хафалый иде* ;

беспокойство, растерянность: *Кызның матур, кара туткыллы йөзенә тынычсызлык чыкты, күзләре берничә минут, бөтенләй эчке уйга туктал-ган кебек, бер җиргә каттылар. Озын керфекләре салындылар* [2, с. 419]; *Мәрхәбә бөтенләй каушап калды, үги каенанасы Фәтхиянең болай теләр-теләмәс каршы алуын күргәч, аның бу борчылуы тагы да артты* [3, с. 245];

злость: *Каеана, тешен кысып, ачулы куз ташлады*... [3, с. 323] и др.

У Г. Ибрагмова мужчина по отношению к женщине может испытывать двойственное чувство, о чем свидетельствует сочетание контрастных признаков, воплощенных в конкретных образе. Например: *Их, мин ул кыз белән акылымнан язам бугай... Матур бер җылан өчен дин алмаштырып, әткәй-әнкәйне, Гайниямне ташлап йөрер хәлем юк!* [3, с. 41].

Таким образом, описываемые Г. Ибрагимовым женщины обладают разной внешностью и наделены разными внутренними качествами. У этих женщин разные судьбы и разные отношения в браке с мужчиной. Одни из них счастливы, другие проходят тяжелые жизненные испытания: *татар хатыны ниләр күрми*, что, естественно, отразилось и на содержании концепта *хатын-кыз* как одном из ключевых компонентов смысловой семантической структуры художественных произведений писателя.

ЛИТЕРАТУРА

1. Галимҗан Ибраһимов. Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. 1 т. : хикәяләр (1907–1929). 510 б.
2. Галимҗан Ибраһимов. Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. 2 т. 478 б.
3. Галимҗан Ибраһимов. Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. 3 т. 455 б.

## ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ӘСӘРЛӘРЕН РУС ТЕЛЕНӘ ТӘРҖЕМӘ ИТҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

***Саттарова М.Р., Мохитова Г.М.***

Перевод, будучи творческим и древним видом человеческой деятельности, является актуальным направлением современного языкознания. Настоящая статья посвящается анализу некоторых особенностей перевода произведений Г. Ибрагимова на русский язык на примере рассказа «Яз башы (Начало весны)». Степень творческого мастерства переводчика позволяет читателю ознакомиться с авторским стилем, спецификой национального менталитета и окунуться в атмосферу эпохи.

The translation, being a creative and ancient human activity, is the interesting direction of modern linguistics. The present article is devoted to the analysis of some features of the translation of the story «Yaz Basha (Beginning of Spring)» written by G. Ibragimov into Russian. Degree of creative skill of the translator is allowed to

the reader to get acquainted with author's style, specifics of national mentality and will plunge into the atmosphere of that time.

Галимҗан Ибраһимов татар халкының дөньяга танылган шәхесләреннән берсе. Әдәби әсәрләренең эчтәлеге, теле, күтәрелгән мәсьәләләрнең киңкырлы һәм тирәнлеге белән танылган авторның иҗаты, иҗтимагый эшчәнлеге шактый җентекле өйрәнелгән. Мәсәлән, Б.Э. Хәкимов Г. Ибраһимовның тел белеме өлкәсендәге эшчәнлеген, З.Г. Сәлахова Г. Ибраһимов иҗатында натурализм гәүдәләнешен тасвирлаган. Г.С. Хәйруллина әдипнең «Тирән тамырлар», «Карак мулла», «Табигать балалары» әсәрләренең рус теленә тәрҗемәләрендә чагылыш тапкан поэтик һәм стиль үзенчәлекләрне өйрәнгән. Шул рәвешле, бу шәхес, автор, җәмәгать эшлеклесе тикшеренүчеләрнең игътибарын төрле яклап җәлеп иткәнлеге ачыклана. Әлеге мәкаләдә «Яз башы» хикәясе мисалында Г. Ибраһимов әсәрләренең рус теленә тәрҗемәләренә хас кайбер үзенчәлекләр анализланды.

Тәрҗемә эшчәнлеге бик борынгы заманнардан килә торган күренеш булуга карамастан, әлеге юнәлешнең теоретик нигезе чагыштырмача соңрак формалаша. Егерменче гасыр дәвамында төрле сәбәпләр белән бәйле илебез тел белемендә тенденцияләр үзгәрешен беләбез. Теоретик карашлар, нигезләр үсеше гамәли яктан тәрҗемә эшчәнлегенә дә тәэсир итми калмаган. Г. Ибраһимов XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында актив иҗат иткән автор. Аның әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итү XX гасырның 20–70 нче елларында аеруча актив башкарылган. Г.С. Хәйруллина хезмәтендә автор хезмәтләренең рус теленә тәрҗемәләре хронологик тәртиптә түбәндәгечә китерелә. «Тирән тамырлар (Глубокие корни)» романының Г. Шәрипова башкарган тәрҗемәсе 1931 елда; шул ук автор тәрҗемәсендә «Казакъ кызы (Дочь степи)» романының тәрҗемәсе 1934 елда; «Татар хатыны ниләр күрми (Татарка)» романы 1935 елда басыла. Г. Кәримова тәрҗемәсендә «Алмачуар (Чубарый)» хикәяләр җыентыгы 1961 елда басылып чыга. Р. Фәизова тәрҗемәсендә «Безнең көннәр (Наши дни)» һәм «Тирән тамырлар (Глубокие корни)» романнары 1962 һәм 1964 елларда дөнья күрә. «Яшь йөрәкләр (Молодые сердца)» җыентыгы Р. Фаткуллина тәрҗемәсендә 1980 елда басылган [3, б. 56]. Бу әсәрләр төрле елларда кабат басылып чыгуы авторның популярлыгын раслый.

Билгеле булганча, тәрҗемә – иҗади процесс. Бер телдә белдерелгән фикерне икенче телгә күчерү, ягъни тәрҗемә итү, билгеле бер телдә мәгънәсе буенча икенче телдәгегә туры килерлек чаралар табуга нигезләнгән. Икенче төрле әйткәндә, тәрҗемә ул – ике тел белән эш итү, ике тел арасында тәңгәллекләр табу дигән сүз. Мондый тәңгәллекләрнең вариантлары чиксез күп төрле. Сайлап алган вариантның никадәр уңышлы булуы тәрҗемәченең осталыгына, тырышлыгына һ.б. бәйләнгән [4, б. 142].

Тәрҗемә теориясенең мәсьәләләрен тикшерү аерым тәрҗемә үрнәкләрен анализлау аша башкарыла. Әдипнең мирасы бай һәм әсәрләренең тәрҗемәләре бер генә булмауны истә тотып, әлеге мәкаләдә Г. Ибраһимовның «Яз башы» хикәясенең тәрҗемәсендә чагылыш тапкан лексик-семантик үзенчәлекләрне анализлыйк.

1910 елда язылган әлеге әсәр Г. Кәримова тарафыннан XX гасыр уртасында тәрҗемә ителгән. Тәрҗемәдә лексик-семантик үзенчәлекләр, сурәтләү чараларынын бирелеше төрле. Билгеле булганча, тәрҗемә оригинал телгә

мөмкин кадәр якын торырга тиеш. Шул сәбәпле, лексик-семантик үзенчәлекләр термины астында тәрҗемәдә рус телендәге лексик берәмлекләрнең, фразеологизмнарның һ.б.ның мәгънәви төсмерен саклау күздә тотыла.

Әсәрнең милли колоритын, авторның индивидуаль стиль үзенчәлекләрен саклау – әдәби әсәрләрне тәрҗемә итүгә куелган иң төп таләпләрнең берсе. Р.А. Юсупов тәрҗемә тоериясе нигезләрен яктыртуган багышланган фәнни хезмәтендә матур әдәбият әсәрләрен тәрҗемә итүгә куелган төп таләпләр, аның мөһим принциплары күрсәтә: «Оригиналга мәгънәсе, эчтәлеге, формасы һәм стиль үзенчәлекләре буенча тиң тәрҗемә аңа эстетик яктан да туры килә. Чөнки матур әдәбият әсәрнең эчтәлек һәм форма бердәмлеге укучыда билгеле бер эмоцияләр, кичерешләр тудыра, аңа тәэсир итә, икенче төрле әйткәндә, ул билгеле бер эстетик әһәмияткә ия була. Ә инде эчтәлек һәм форма бердәмлеге икенче телгә тулы кыйммәтле килеш күчерелә икән, тәрҗемә оригиналга эстетик яктан да тиң була, һәм шулай булырга тиеш тә. Бу сыйфат тәрҗемәнең төп принципларыннан берсен тәшкил итә» [4, б. 78].

Тәрҗемәче әнә шул сыйфатларны сакларга, автор күрсәтергә теләгән моментларга зыян китермәскә тиеш. Нигездә, Г. Кәримова бу максатка ирешкән. Ләкин тәрҗемәне өйрәнгәндә кайбер җитешсезлекләр дә ачыкланды. Мәсәлән, әсәрнең беренче җөмләсендә үк лексик аңлашылмаучанлык килеп чыга: *Мин унбер яшьләрдә булганмындыр, яңа гына укудан кайткан идем. – Мне, наверное, было лет одиннадцать, когда я вернулся с учения.* Оригинал текстта, беренче булып сөйләүченең ничә яшьтә булуы искәртелә, аннан инде темага кереп китәр өчен аның нәрсә белән шөгыльләнүе билгеләнә. Ә рус телендәге тексттан чыгып, учение – хәрби уку йортыннан – кайткан 11 яшьлек егет турында сүз бара дип аңлап була. Бу җөмләне башкача тәрҗемә итсәк, аңлаешлырак булыр иде: *Мне было лет одиннадцать, я только вернулся с учебы.*

Әсәрдәге кайбер берәмлекләрне тәрҗемә иткәндә тәрҗемәче автор стиленнән читкә киткән. Мәсәлән, «*тиз генә*» берәмлеген «*бережно*» дип тәрҗемә итеп булмый. *Мин моны тиз генә эләктердем дә, **зур көрәштә җиңгән батырның алган бүләге** сынлы тотып, әнигә китердем. – Я бережно взял листок, словно это была **награда герою за доблесть**, и отдал маме.*

Биредә тәрҗемәче милли стилдән читкә тайпылган, текстны руслаштырган, әлеге җөмләне башкача тәрҗемә итеп, милли колоритны, автор стилен саклап калсак әйбәтрәк булыр иде: *Я быстренько схватил листок, будто это **награда, выигранная батыром в борьбе** и принес его маме.* Тагын бер мисал: *Ну, таптың, малай! Китәбез, **валлаһи**, китәбез! – дип кычкырып җибәрдем. – Вот молодец, какое хорошее дело вспомнил! Давайте пойдем, ребята, **непременно** пойдем!*

Билгеле булганча, тәрҗемә процессында фразеологизмнарны уңышлы тәрҗемә итү дә мөһим. Бу әлеге тел берәмлекләренең функциональ мөмкинлеге, стилистик максатка хезмәт итүе белән аңлатыла. Гомумән, фразеологизмнар сурәтләү чарасы буларак та файдаланала ала. Халык тәҗрибәсен чагылдырган тел берәмлекләре буларак, алар билгеле бер күренешне тасвирлауны җиңеләйтә. Аларның әһәмияте дә шунда: фразеологизмнар берничә җөмлә белән генә әйтеп була торган фикерне җиткерү сәләтенә ия. Гомумән, әдәбиятта фразеологик берәмлекләр сурәтләү чаралары арасында

мөһим урын алып торалар, чөнки аларга сурәт тудыру, гомумиләштерү, эмоциональлек, экспрессивлык, стилистик яктан бизәү һәм образлылык функцияләре йөкләнгән, һәм әлеге үзенчәлек тәрҗемә процессында да билгеле бер таләпләр куя. Г.Х. Әхәтов фразеологик әйтелмәләрне бер телдән икенче телгә тәрҗемә итүнең дүрт төп юлын тәкъдим итә [2, б. 36].

1. Калькалаштырып тәрҗемә итү яки мәгънәләре белән тәңгәл килгән фразеологик тезмәләрне файдалану: *баш вату – ломать голову* һ.б. Калькалаштырып тәрҗемә итү юлы татарчадан русчага, русчадан татарчага тәрҗемә иткәндә зур әһәмияткә ия. Моның төп сәбәбе – татарлар яши торган җирдә билингвизм булуы татар яки рус фразеологизмнарының ике халык арасындада интернациональ фразеологизмнар хәленә китерүдер. Бу күренеш Р. Аюпова тарафыннан өйрәнелгән [1, б. 267].

2. Ярымкалька юлы белән тәрҗемә итү: *Күздән югалу – скрыться с глаз, күз алу – отрывать глаз, борын төбендә – под носом* һ.б.

3. Тәрҗемә итүче телдән параллель фразеологик әйтелмәләр эзләү: *Син безнең бөтен өметебезне кисмәкче, ике кулсыз итмәкче буласыңмыни – Хочешь свести на нет всю нашу работу* һ.б.

4. Аңлатып бирү юлы белән тәрҗемә итү: *тел-теш тидерерлек түгел – нельзя обижаться, тел бистәсе – болтушка, күз сөртеп алу – поглядывать.*

Анализлана торган әсәрдә фразеологизмнарны тәрҗемә итүнең түбәндәге төрләре билгеләнде:

Тәрҗемә итүче телдән параллель фразеологик әйтелмәләр эзләү. Мәсәлән: *Э, алаймыни?.. **Күзегез кызамыни**?.. Сезгә ул да юк бит әле! – дидем. – Ах, так? **Завидки берут**! Вам-то и такая не попадается!*

Аңлатып бирү юлы белән тәрҗемә итү: *Ни эшләгән, ни булганны белмим**... йөрәгем ярыла**, җаным чыга... –* ***Сердце остановилось от страха****, ноги подкосились.* Биредә автор аңлатып бирү юлы ярдәмендә фразеологзмның төп мәгънәсен ачып бирә, димәк, әлеге эквивалент уңышлы.

Бер тел фразиологизмнарының сәнгатьлелек сыйфатларын бердәй мәгънәле икенче тел әйтелмәсенә күчерү – иҗади эш, һәм моның төрле алымнары бар. Г. Каримова әлеге алымнарны дөрес кулланган.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, «Яз башы» әсәре рус теленә уңышлы тәрҗемә ителгән. Тәрҗемә эшчәнлеге автор иҗатын яхшы белүне таләп итә. Әлеге нисбәттән әсәрдә гарәп-фарсы алынмалары кулланылуны, диалекталь төшенчәләр булу-булмауны, шул чор татар теленең үзенчәлекле синтаксик конструкцияләре очрауны истә тоту мөһим. Тәрҗемә тексты аңлаешлы, җиңел укылуга карамастан, төшереп калдырулар, автор стиленнән, милли колориттан тайпылулар булу әлеге әсәр тәрҗемәсен камилләштерү мөмкинлеген раслый.

ӘДӘБИЯТ

1. Аюпова Р.А. Влияние регионального билингвизма на процесс перевода ФЕ с иностранного языка и на фразеологический фонд двух взаимодествующих языков // Сопоставительная филология и полилингвизм. Материалы Всероссийской научно-практической конференции (Казань, 29–31 октября 2002 года). Казань: РИЦ «Школа», 2002. С. 266–268.

2. Әхәтов Г.Х. Татар теленең лексикасы (Педагогия институтлары һәм колледжлары студентлары өчен кулланма). Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. 92 б.

3. Хайруллина Г.С. Переводы произведений Галимджана Ибрагимова на русский язык: поэтика и стиль: дис. ... канд. филол. наук. М., 2001. 148 с.

4. Юсупов Р.А. Тәрҗемә һәм сөйләм культурасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. 237 б.

# Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ «ЗӘКИ ШӘКЕРТНЕҢ МӘДРӘСӘДӘН КУЫЛУЫ» ХИКӘЯСЕНДӘ НАТУРАЛИСТИК АЛЫМНАРНЫҢ ГӘҮДӘЛӘНҮ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

***Сәлахова З.Г.***

В рассказе «Изгнание шакирда Заки из медресе» подробно исследованы эстетические особенности, виды и функции натурализма. Прибегая к натуралистической образности, Галимджан Ибрагимов уделяет большое внимание отражению отталкивающе безобразных явлений окружающей среды и быта шакирдов. Натуралистический стиль в «Изгнании шакирда Заки из медресе» ярко проявился в изображении образов шакирдов как людей «социального дна»: они нищенствуют, живут впроголодь, попрошайничают, ходят гурьбой за подаяниями…

Художественный метод рассказа «Изгнание шакирда Заки из медресе» характеризуется эстетической раздвоенностью. Во-первых, его уверенно можно определить как натурализм, основанный на фотографизме с элементами физиологизма; во-вторых, как просветительский реализм, в пользу последнего говорит изображение образа Заки в единстве с окружающей средой, бытовой конкретикой и идеалами джадидизма.

Aesthetic features, types and functions of naturalism in the story «The expulsion of the Shakird Zaki from the madrassah» were studied in detail.By resorting to naturalistic imagery, Galimdzhan Ibragimov pays much attention to repulsing the ugly phenomena of the environment and the life of the shakirds.The naturalistic style in «The Exile of the Shakird Zaki from the Madrassah» was vividly manifested in the image of the Shakirdas as people of the «social bottom»: they are begging, they live half-starving, beg, beg for alms ...

The artistic method of the story «The expulsion of Shakirda Zaki from the madrassah» is characterized by aesthetic bifurcation. Firstly, it can confidently be defined as naturalism, based on photographicism with elements of physiology; Secondly, as enlightening realism, in favor of the latter, the image of Zaki's image in unity with the environment, everyday specifics and ideals of Jadidism speaks.

Галимҗан Ибраһимов «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» әсәрен 1907 нче елда яза. Әлеге хикәядә Габдрахман Сәгъди реализм күрә, ә И. Нуруллин белән Р. Бикмөхәммәтов натуралистик алымнар табалар, М. Хәсәнов та әсәрдә натуралистик элементларның күзгә ташлануын инкяр итми.

Без дә И. Нуруллин һәм Р. Бикмөхәммәтов белән килешкән хәлдә, әлеге хикәядә тормыш, көнкүрешне фотография ысулы белән биргән натуралистик тасвирларның мул булуын күрсәтергә тырышырбыз.

Галимнәр Г. Ибраһимовның Октябрь инкыйлабына кадәрге иҗатын романтизм белән бәйләп өйрәнәләр. Әмма «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясе романтизм ысулы белән язылмаган. Язучы анда мәдрәсә тормышын фотография ысулы белән натуралистларча гәүдәләндерүче реалист буларак чыгыш ясый.

Хикәядә шул чордагы иске тип мәдрәсә һәм анда белем алучы шәкертләр тормышы тасвирланган. Төп герой итеп шәкерт Зәки алынган. Намуслы, нечкә күңелле Зәкинең, мәдрәсәдәге уку тәртипләренә ризасызлык белдереп, бу уку йортын ташлап чыгарлык, рухи азатлыкка омтылган шәхес дәрәҗәсенә үсеп җитүе ышандырырлык итеп күрсәтелгән.

Г. Ибраһимов хикәядә кешенең яшәеше буйсынган көнкүрештәге закончалыкларны ачарга омтыла, моның өчен игътибарын кешене чолгап алган тирәлеккә юнәлтә. Ул «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы»нда әйләнә-тирәлекне ямьсезлек категориясе аша сурәтли. Биредә әлеге төшенчә чынбарлыкның тискәре күренешләрен бөтен тулылыгында укучыларга җиткерү максатыннан файдаланыла.

Ләкин алда языլачак әсәрләрендә исә язучы матурлык эстетикасына өстенлек бирәчәк һәм еш кына матурлык белән ямьсезлекне романтикларча капма-каршы куеп сурәтләячәк. Бу күпмедер дәрәҗәдә әдипнең тормышка фәлсәфи күзлектән каравына да бәйле. Фәлсәфә галиме Яхъя Абдуллин язганча: «Г. Ибраһимовның чынбарлыкны диалектик рәвештә күзаллавының бик мөһим бер чагылышы – аның күренешләрне каршылыклы итеп каравы. Аның фикеренчә, табигатьтә дә, иҗтимагый тормышта да нәфислек һәм шөкәтсезлек бер-беренә бәйләнгәннәр… Шушы каршылыклы тенденцияләрнең көрәше һәм шул ук вакытта бердәмлеге тормышның нигезендә ята» [1, б. 136].

«Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясендә әдип натуралистик алым һәм ысуллар куллану аша, Зәки яшәгән мәдрәсә тормышын объектив чагылдырып, башкалар өчен «кызыксыз», «шыксыз» дип исәпләнгән материалның да эстетик мөмкинлекләрен күрсәтә. Ул үзенең хикәясендә чынбарлыкны ничек бар, шулай алып, әдәби чаралар белән бизәмичә генә, укучыга тәкъдим итә. Мисалга әсәрдән бер өзек китереп үтик: «Бу өй башка өйләргә караганда, карсак, буялмаган, шкатурлары кубып беткән стенасына күмер вә акбур берлән әллә ниләр язып, чобарлап бетерелгән, тәрәзәләре бик кара, каюсы ватылган, каюсыннан иске сөлгеләр салынып тора; капкасы бик начар гына вә капка төбендә һәртөрле чүпләр өелеп ята» [4, б. 4]. Әлеге өзектә мәһабәт йорт күрергә хыялланып килгән Зәкинең шундый манзарага тап булуы геройның хыяллары белән реаль тормыш арасындагы каршылыкка ишарә ясый.

Мәдрәсәнең эчке күренеше дә тышкы ягы белән тәңгәл килә. Г. Ибраһимов мәдрәсәнең эчке манзарасын сурәтләгәндә, андагы күренешләрне тәнкыйть күзлеге аша үткәреп сайлап тормыйча, фотографик төгәллек белән сурәтли. Күңел биздергеч, ямьсез якларны да, ваемсыз гына копировка аркылы төшереп алган шикелле, җайлап кына әсәр тукымасына кертә бара. Әдип күбрәк кеше характерына түгел, тирәлеккә игътибар итә. Мәдрәсәнең күңел кайтаргыч, җирәнгеч эчке күренеше бөтен ямьсез төсләре, барлык яман исләре белән әсәрдә чагыла. Әдипнең түбәндәге тасвиры шул фикерне расласа кирәк: «Зәки мәхдүм кергән өйнең мәнзарасы менә шул рәвешле иде: ишек төбендә һәртөрле чүпләр вә нәҗес нәрсәләр өелгән, бер сулы таз; ул тазның тирәсендә төкерү вә какырудан хасил булган шакшы күл вә аяк киемнәре вә һәртөрле комганнар бар. Өйнең түшәме, стенасы вә идәне бик кара, тузанлы, чүпле; тәрәзә төпләре сулы, черегән вә бик каралган; өйнең берничә җирендә кечкенә-кечкенә тишек киезләр вә пычак берлән әллә ниләр язылган ямьсез өстәлләр бар; вә өстәл астында икмәк, чынаяк, чәйнек, күлмәк ыштан, тагын әллә ниләр бар; өстәл янында кап-кара тышлы мендәрләр вә каешланып беткән киемнәр вә һәр махсус киез өстендә ике-өч кешеләр бар. Бу кешеләрнең бәгъзесе намаз укый, бәгъзесе ашый, эчә, бәгъзесе йоклый, бәгъзеләре язу яза, бәгъзеләре пыялага эре эре идеп шәмаил яза, бәгъзесе Коръәннән күчереп тәрилкәгә сары нәрсә берлән язып утыра.

Бер почмакта берничә сукыр коръән укый; вә икенче почмакта аксак-туксак адәмнәр читек тегеп утыралар» [4, б. 4].

Тормышта, бәлкем, кеше бу ваклыкларга шул кадәр игътибар да итмидер, ә әдип исә бер генә детальне дә күз уңыннан төшереп калдырмаска тырышып, чынбарлыктагы төгәллекне мөмкин кадәр әсәр эчендә сакларга омтылган. Шуңадыр Г. Сәгъди әдипне: «…беренче адымыннан ук сәнгатьчә тасвирчы» [10, б. 2], – дип бәяли.

Чыннан да, әдип беренче хикәясендә үк яшәешне җентекләп тасвирлавы белән аерылып тора. Ул әдәби сурәтләүнең натуралистик ысулларын куллану аша, Зәки яшәгән мәдрәсә тормышын объектив чагылдырып, башкалар өчен «кызыксыз» материалның да эстетик мөмкинлекләрен күрсәтә. Г. Ибраһимов «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясендә мәдрәсә чынбарлыгын күңел кайтаргыч, тупас, шакшы яклары белән алып, укучыга тәкъдим итә.

Чынбарлыкны болай тәфсилләп язу натуралист язучылар өчен мөһим бер сыйфат булуын әдәбиятчы галим В.А. Миловидов: «…не менее важным гарантом достоверности изображения действительности в натуралистическом романе был документализм, фактография, стремление предельно объективно воссоздать мельчайшие подробности бытия» [7, с. 19], – дип билгеләп үтә.

Гомумән алганда, әдип мәдрәсәнең эчке һәм тышкы күренешләрен, андагы интерьерны бирү, предметларны күзаллау өчен натуралистик тасвирлардан уңышлы гына файдаланган дип нәтиҗә ясый алабыз. Моның шулай икәнлеген хикәядән мисал өчен китерелгән өзекләр дә раслый.

Әсәрдә шәкертләрнең әхлаксызлыгы, бозыклыгы да натуралистик тасвирлар аша ачылган. Зәкинең мәдрәсәдә үткәргән беренче көне түбәндәгечә сурәтләнә. «Озак та үтмәде, берсе карлы бозлы салкын вә пычрак суны Зәкинең йөзенә җиң эчендән коеп та җибәрде. Бичара Зәкинең өсте-башы һәммәсе пычранды, суланды. Кызганыч Зәки, башын киссәләр дә, кулындан һични килми, сабырдан башка бер чарасы юк, калтырап, туңып бер сәгать кадәр тавышсыз гына елап, утырды» [4, б. 9].

Бу очракта натуралистик тасвирның вазифасы беркадәр үзгә. Ул Зәкинең эчке кичерешләрен ачуга, әсәрдәге психологик башлангычны арттыруга хезмәт итә. Алга таба геройның уңай идеалы белән реаль тормыш арасындагы каршылык көнкүреш фаҗигасе рәвешен ала. Мәдрәсәдәге укыту-тәрбия эшенең бик тә түбән булуы Зәки шәкертнең уй-хыяллары аркасында тормышка ашмый. Соңрак та идеал белән чынбарлык арасындагы каршылык тирәнәйгәннән-тирәнәя. Моның өчен автор укучыга аз таныш булган мәдрәсә тормышыннан киң белешмә бирә, үз героеның тормыш шартларын акрын-акрын анализлап та бара. Зәкинең мәдрәсәдә кичергән һәр көнен бер-бер артлы укучы күз алдыннан үткәрә. Бу тасвирлауларда без әдипнең натурализмга бирелеп киткән урыннарын еш очратабыз. Менә бер мисал: «Бу хәлдән истифадә итмәк булып, иптәшләре идәннең баз капкачын ачып шул турыга гына пычрак сулар, нәҗесләр белән тулган таз (ләгән) куйдылар. Бичара Зәки, тирләп, пешеп куып йөргәндә, ачык базга тугры килеп, чалт идеп нәҗес ләгәнгә килеп төште. Баз яхшы тирән генә иде. Әгъзасы да агыртды, ләгәндә булган нәҗескә һәммә киемнәре дә буялды» [4, б. 10]. Әдип биредә мәдрәсәдәге шәкертләр тормышын бөтен ваклыкларына кадәр җентекләп сурәтләүгә зур игътибар биреп, андагы әдәпсез, шыксыз, пычрак тормышның кеше физиологиясенә, акылына һәм җанына күңел кайтаргыч йогынтысын да ача.

Г. Ибраһимовның тормышны түкми-чәчми тасвирлаучы оста каләм иясе булуына галим Роберт Бикмөхәммәтов та игътибар итми калмый. Ул үзенең бер хезмәтендә: «Внимание к точности, глубине, действенности описания, заметное уже в «Изгнании…» [2, с. 82], – дип яза.

Г. Ибраһимов әсәр үзәгенә иске тип татар мәдрәсәләренең шәкертләргә заман таләбенчә төпле белем бирә алмау, аларны рухи яктан гарипләндерү проблемасын куя. Аларның кадими мәдрәсәләрдә нигезле белем ала алмыйча, михнәт-газап чигүләрен, дөньядан артта калуларын натуралистик детальләр аша тасвирлый. Болар барысы да яшь гомерен наданлыкка корбан иткән, тупаслык, кыргыйлык баскычлары аша үткән Зәки образы аша гәүдәләндерелә.

Әлеге хикәясендә Г. Ибраһимов Зәкинең кеше буларак холкы ничегрәк формалашуга аерым игътибар бирә. Ул герой яшәгән тирәлекнең аның характерында нинди эз калдырганын күрсәтә. Әйләнә-тирәлек дигәндә әдип беренче чиратта көнкүрешне күз алдында тота. Әлеге көнкүрешне бөтен ваклыклары һәм төсләре белән сурәтләп, Зәки шәкертнең тормышка мөнәсәбәте формалашудагы әһәмиятен ассызыклап бара. Моның өчен шәкертләр яшәгән тормыштан аерым бер көнне тасвирлап үтә. Хикәядә шәхес эреп юкка чыга, ул «толпа», «масса» белән бергә кушыла һәм бу гавам образы бернинди хыял, фантазияләр белән баетылмыйча, натуралистик детальләр белән бирелә.

Зәкинең эчке халәтен ачып бирү, шуның белән бергә җәмгыятьнең кеше шәхесенә тәэсир итеп, аны ничек үзгәртүен күрсәтү өчен дә язучы натуралистик ысул белән язылган юлларны тәкъдим итә. Фикеребезне исбатлар өчен түбәндәге өзеккә мөрәҗәгать итик: «…Зәки дә моназарә өчен соң дәрәҗәдә тырышды. Белсә дә, белмәсә дә, өстәл сугып, акыруга өйрәнә башлады. Шәкертләр арасында иң мактаулы вә яхшы эш – белсә дә, белмәсә дә, хата булса да тугры булса да, үзенең алга алган сүзене ташламау, хатасыны игътираф итмәү улдыгындан, безнең Зәки дә үзенең сүзене бирмәскә, әллә нинди ялган, хата булса да, шул сүз өчен кычкырышырга вә тукталып калмаска бик иҗтиһад итә, тавышы беткәнчә кычкырыша вә сүгешә иде» [4, б. 25]. Өзектән күренгәнчә, авторның Зәки холкындагы аерым үзенчәлекләр турындагы бәяне, ягъни аның надан мөназарачы булып китүе натурализмга тартым бәяләмәләр рәвешендә гәүдәләнә. «Татар совет әдәбияты тарихы»нда да моңа охшаш фикер белән очрашабыз. «Сәнгатьчә эшләнеше ягыннан «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» җитлеккән әсәр булудан ерак иде әле. Аның хикәяләү стилендәге примитивлыклар, натурализмга якын сурәтләр язучының беренче тәҗрибәсе икәнлеген әйтеп торалар» [11, б. 244].

Чыннан да, хикәядәге сурәтләрнең натурализмга якын булуы белән без дә килешәбез. Алай гына да түгел, кайбер урыннарда натуралистик тасвирлар аеруча ачык күзгә ташлана. Г. Ибраһимов әсәрне документаль төгәллек белән дәлилле итеп бирергә омтыла. Әсәрнең сюжеты нигезенә, эчтәлеккә реаль хәлләр салынуы шуны расласа кирәк. Әдип үзе белгән вакыйгаларны, башкаларны аз кызыксындырган хәлләрне, сайлап тормыйча гына, әсәр тукымасына кертеп җибәргән.

Әсәрдә мәдрәсәнең тышкы һәм эчке күренеше, анда укучы һәм көн күреп ятучы шәкертләрнең өс-башларының да пычрак икәнлеге натуралистларча кара буяулар белән тасвирлана. Натуралист язучыларга хас

билгеләрнең берсе В.Е. Красовский фикеренчә: «…натуралисты… использовали человека прежде всего как материал для своей «социометрии», подчиняли его изображение бытописи и нравоописанию» [6, с. 78].

Хикәядә күп урын мәдрәсәдәге укыту тәртипләре, шәкертләрнең тормыш-көнкүреше, аларның гадәтләрен сурәтләүгә бирелә. Аларның яшәеше шул дәрәҗәдә чикләнгән ки, бөтен гомерләре мәдрәсә белән бәйле рәвештә үтә. Бары тик гаед көннәрендә генә шәкертләр мәдрәсәдән читкә сибеләләр. Мондый көннәрендә дә алар байлар ишек төбендә хәер теләнеп үткәрәләр. Шәкертләрнең бу рәвешле түбәнсенүләре турында да Г. Ибраһимов натуралистларча тасвирлап бирә.

Әсәрдә натурализмның көчле булуын әдәбият белгече И. Нуруллин да билгеләп үтә. Ул болай ди: «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы»… Г. Ибраһимовның башлангыч чор иҗатын тәшкил итә дисәк, хата булмас. Бу чорда исә, …рационализм һәм натурализм тенденциясе шактый көчле әле» [8, б. 244].

Әлбәттә, И. Нуруллин хаклы. Чөнки Г. Ибраһимов әлеге хикәясендә натуралистик тасвирларга бик еш мөрәҗәгать итә. Искечә укытыла торган кадими мәдрәсәләрдә белем туплау урынына, шәкертләрнең начар гадәтләрне өйрәнүгә нинди юллар белән килүләрен җентекләп сурәтләп, укучыга җиткезә. Милләтнең алдан бара торган кешеләре, халыкка караңгы төндә юл күрсәтергә тиешле укымышлы затларының ни өчен мәдрәсә караңгылыгында адашып калуларын бик тәфтишләп язып үтә. Моның өчен гади бер татар мәдрәсәсен алып, анда тиешле белем ала алмыйча, михнәт-газап чигеп яшәүче шәкертләр тормышын төрле күренешләр аша тасвирлап бирә. Әдип кадими мәдрәсәдәге шәкертләрнең милләткә хезмәт итәсе урынга, күп очракта җан асрау, үзләренең тамакларын туйдырыр өчен генә яшәүләрен натуралистик төгәллек белән тасвирлый. Бу бик аяныч вакыйгаларны һәм күңелсез хәлләрне тормышта күзәтелергә мөмкин булганча язып, укучы хөкеменә чыгара.

Г. Ибраһимов мәдрәсә тормышының караңгы, ямьсез якларын әлеге хикәясендә тәнкыйтьләп чыга. Яшь буынга нигезле тәрбия бирү, уку-укыту эшен көйләү, дөньяви фәннәрне чит итмәү кебек мөһим мәсьәләләр күтәрелгән бу әсәр, татар милләтенең киләчәген кайгыртуы белән дә үзенчәлекле. Әдип үгет-нәсыйхәт тә бирми, мораль дә укымый. Чөнки ул «Татар шагыйрьләре»ндә: «…Тукаев…башына ни килде – вәгазьме, шелтәме, – “яхшы булыңыз, җәмәгать!” дигән төсле, әйтә дә сала» [5, б. 131], – дип үгет-нәсыйхәтчелеккә үзенең тискәре карашын белдергән иде. Шуңа да ул чынбарлыкны натуралистик детальләр аша шундый төгәл дөреслек белән чагылдыру үзе үк инде укучыга тәэсир итү көченә ия дип саный. Р. Гайнанов әдипнең сигез томлыгының беренче томына язган «Искәрмәләр һәм аңлатмалар»ында болай ди: «Әсәрдәге реализм (дөресрәге, натурализм), чынбарлыктагы вакыйгаларның әйдәве шулкадәр көчле була ки, Вәли мулланың уң кулы булган хәлфә исемен автор башта Мөбарәкҗан дип алып, ахырга таба чын үз исеме белән атарга мәҗбүр була» [3, б. 505].

Әлеге юллар үзләре үк Г. Ибраһимовның хикәя өчен материалны турыдан-туры тормышның үзеннән алуы турында сөйли. Ә алынган вакыйгаларны әдип әллә ни катлаулы әдәби алымнарга мөрәҗәгать итмичә, тормышта ничек бар, шулай әсәргә күчереп куя. Үзәк герой Зәки дә тормыш агымына буйсындырып сурәтләнә. Соңрак мәдрәсәдәге кадими-схоластик

кагыйдәләр Зәкине канәгатьләндерә алмыйлар һәм ул, андагы укытуның камил булмавына ризасызлык белдереп, бу уку йортын ташлап чыга. Билгеле, язучы кайчандыр үзе Вәли мулла мәдрәсәсен ташлап чыкканда кичергән хис-тойгыларны Зәки шәкерт образы аша сурәтли. Шуңа күрә әсәрдә күпмедер дәрәҗәдә автобиографизм элементлары бар дип тә әйтә алабыз.

Димәк, Г. Ибраһимов хикәяне «тормыш диктовкасы астында» яза, мәдрәсәдәге шәкертләр яшәешен чагылдыруга бик тәфсилләп туктала. Шәкертләрнең көндәлек эшләре, укулары, мәчеткә һ.б. урыннарга йөрүләре гаҗәеп дәрәҗәдә җентекләп бирелә. Шәкертләр тормышын мөмкин кадәр тулы сурәтләргә тырышуын Р. Бикмөхәммәтов: «С протокольной добросовестностью описывается обстановка медресе… Перед читателем проходят картины похорон бая, учебных занятий, молитв в мечети, шакирдских потасовок. Автор стремится быть объективным наблюдателем, возможно шире показать жизнь медресе» [2, с. 82], – дип билгеләп үтә.

Чыннан да, әдип мәдрәсә тормышын бик тәфтишләп, энәсеннән җебенә кадәр үткәреп тасвирлый. Безнең күзалдыбыздан бер-бер артлы мәдрәсәдәге төрле вакыйгалар картинасы уза. Язучы бу күренешләрне үзенең каләмен натурализм буяуына манып ясый. Шулай итеп, тормыш дөреслеге реалист язучылардагыча әдәби әсәр тукымасына үтеп кереп, чынбарлыктагы вакыйгалар төгәл детальләр белән чагылдырыла.

Хикәядә кулланылган натуралистик детальләр, бер яктан, эчке интерьерны бирү, ягъни кадими мәдрәсәләрнең шыксызлыгын күрсәтү өчен файдаланылса, икенче яктан, иске тип мәдрәсәләрдә укучы шәкертләрнең әхлаксызлыгын сурәтләү өчен хезмәт итә. Әсәрдә мәдрәсәдәге тәртип, укыту системасы, андагы яшәү рәвешен чагылдыру өчен дә натуралистик алым файдаланылган. Димәк, әсәрдәге натуралистик тасвирлар кадими мәдрәсәләрнең чын йөзен күрсәтүгә ярдәм итә.

Шулай итеп, Г. Ибраһимов «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясендә шул чор татар мәдрәсәләренең көнкүрешен түкми-чәчми сурәтләп, әдәбиятка үзенчәлекле реализм алып килә. Әлбәттә, кулланылган натуралистик тасвирларның барысы да реализмга хезмәт итә. Галим Р.М. Самарин билгеләп үткәнчә: «…натурализм… содержал в себе также и реалистические тенденции – особенно в тех случаях, когда перед литературой возникали задачи изображения новых общественных явлений, требовавших для своего воплощения в художественных образах и новых средств» [9, с. 295].

«Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясен карап чыкканнан соң әдип хикәядә көнкүрешне, яшәү рәвешен фотография ысулы белән тасвирлаган, ягъни этнографизмга басым ясаган натуралистик алымга өстенлек бирә дигән нәтиҗәгә киләбез.

## ӘДӘБИЯТ


1. Абдуллин Я. Милләт язмышы. Казан: Фән, 1999. 313 б.

2. Бикмухаметов Р. Галимджан Ибрагимов // Вместе с народом. М.: Советский писатель, 1959. С. 338.

3. Гайнанов Р.Р. Искәрмәләр һәм аңлатмалар // Ибраһимов Галимҗан. Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. 18 б.

4. Ибраһимов Г. Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы. Казан: Өмид, 1912. 50 б.

5. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. 5 т. 615 б.

6. Красовский В.Е. О принципах изображения действительности и человека в прозе русских натуралистов конца XIX века // Время и творческая индивидуальность писателя. Ярославль, 1990. С. 68–79.

7. Миловидов В. Натурализм: метод, поэтика, стиль: (Пробл. сравнит. литературоведения): Учеб. пособие по спецкурсу. Тверь: ТГУ, 1993. С. 19.
8. Нуруллин И. XX йөз башы татар әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1966. 427 б.
9. Самарин Р.М. Проблема натурализма в литературе США и развитие американского романа на рубеже XIX–XX веков // Проблемы истории литературы США. М.: Наука, 1964. С. 287–346.
10. Сәгъди Г. Егерме еллык әдәби хезмәтнең беренче адымында // Кызыл Татарстан. 1927. 20 ноябрь.
11. Татар совет әдәбияты тарихы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1966. 244 б.

# Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ «АЛМАЧУАР» ӘСӘРЕНДӘ СӨЙЛӘМ ЭШЧӘНЛЕГЕН БЕЛДЕРГӘН ФИГЫЛЬЛӘРНЕҢ ФУНКЦИОНАЛЬ-СЕМАНТИК КЫРЫ

***Сәлахова Р.Р.***

Язык произведений писателей всегда привлекал и продолжает привлекать внимание языковедов. Глаголы речи, как нам представляется, играют весомую роль в структуре образных связей в художественном тексте рассказа Г. Ибрагимова «Алмачуар». Это обусловлено их лексико-семантической вариативностью.

The language of the works of writers always attracted and continues to attract the attention of linguists. The verbs of speech, we believe, play an important role in the structure of shape relations in a literary text of the story of G. Ibragimov «Amatuar». This is due to their lexical and semantic variability.

Лексик-семантик вариантлылык дигән термин татар тел белемендә фигыль сүз төркемен өйрәнүчеләр тарафыннан соңгы ике дистә елда кулланыла башлады. Д. Гапделганиеваның «Татар фигыленең лексик системасында күпмәгънәлелек һәм омонимлык» дигән хезмәтендә лексик-семантик вариантлылык лексик-семантик ысул белән сүз-фигыль ясалышына таба күчеш этабы дип аңлатыла [2, б. 12].

Р.К. Иштанова тарафыннан язылган хезмәттә татар фигыленә хас булган семантик төркемнәр(эш, хәрәкәт, танып белү, тәртип-низам, процесс, яңгыраш лексик-семантик вариантлары) барлана [5, б. 19].

Кешеләрнең үзара аңлашу, аралашу процессының төп күрсәткече булып сөйләм эшчәнлеген белдергән фигыльләр тора. Бу төр фигыльләр туры сөйләмнең төп компоненты буларак кулланылалар, аларның лексик-семантик вариантлары кыек сөйләмдә дә күпләп күзәтелә. Әлеге фигыльләрнең семантик кыры гаять үзенчәлекле, күптөрле булуга карамастан, тел белемендә аларның функциональ-семантик кырын җентекләп өйрәнгән хезмәтләр юк дәрәҗәсендә. Функциональ-семантик кыр дигәндә, һәр аерым фигыльнең аерым вариант-парадигмаларда ничек реальләшә алуы күздә тотыла.

Сөйләм эшчәнлеген белдергән фигыльләрнең функциональ-семантик кыры түбәндәгеләрдән гыйбарәт: төп фигыльләр, сөйләмнең характеры һәм эчтәлегенә бәйле фигыльләр, хәбәр итү фигыльләре, сөйләшүне, ягъни сөйләм вакытында контактка керүне белдерә торган фигыльләр, сөйләү эчтәлегендә боеру (каузация) мәгънәсе булган фигыльләр, бәяләү фигыльләре, эмоциональ мөнәсәбәт белдерә торган торган,сөйләмнең төрлечә яңгыравы-

на ишарә иткән фигыльләр, дип фигыле белән килгән һәм дәшмәүне белдерә торган фигыльләр [1, б. 203].

Телдә нинди генә лексик берәмлекне алсак та, аның лексик-семантик һәм грамматик үзенчәлекләре тулысынча билгеле бер контекст эчендә генә ачыла. Төрле чорларга караган әдәби әсәрләр теләсә-нинди тел күренешен өйрәнү барышында кыйммәтле чыганак ролен үтиләр. Татар телендә сөйләм эшчәнлеген белдергән фигыльләрне барлап, аларның мәгънәви үзенчәлекләрен, лексик-семантик төркемчәләрен билгеләү өчен татар халкының классик язучысы Галимҗан Ибраһимовның «Алмачуар» исемле хикәясенә мөрәҗәгать итүебез шуның белән аңлатыла. Күренекле әдипнең әлеге хикәясендә төп герой Закирның колынга булган мөнәсәбәте сурәтләнелә. Алмачуарны ярату хисе белән яшәгән Закирның рухи халәте тәэсирле итеп бирелгән. Аның Алмачуар белән һәр аралашуы авыл баласының табигатьне бөтен матурлыгы белән сөюен, шул җирлектә формалашуын күрсәтә. Әсәр аз күләмле булуына карамастан, сөйләм эшчәнлеген белдергән фигыльләрнең һәр лексик-семантик төркемчәсенә мисаллар күпләп күзәтелә. Алар нигездә туры сөйләмнең төп компоненты булып торалар. Мәсәлән: *Ул Алмачуарны миннән көнләшә булса кирәк. Кайчан гына **сүз чыкмасын**, мине **тиргәргә, каһәрләргә** тотына.Әле дә әткәй ни барын **сөйләп бетермәде**, әнкәй, миңа каршы кызып, **ачуланып китте**:*

*Фу, илаһым, – **ди**, – нинди бәла-каза килгән, дип торам... Бер тай өчен адәм шул чаклы **акырыр** икән, **ди*** [3, б. 279].

Югарыда китерелгән кыска гына өзектә дә сөйләм эшчәнлегенең төрле лексик-семантик төркемчәләренә караган фигыльләрне күрергә мөмкин. Мәсәлән, ***сөйләү*** фигыле – сөйләргә, үзеңнең уй-фикерләреңне сүз белән җиткерү, сөйләм куллану (туры сөйләм вакытында дип сөйли кебек вариант кулланыла). Вакытлыча сузылган сөйләм процессына акцент ясала. Мондый төр фигыльләр, гадәттә, хәбәрнең эчтәлеген актуальләштерә.

***Дию*** – әйтергә (туры сөйләм вакытында, башка кеше сөйләмен җиткергәндә сөйләм эшчәнлеген белдергән төп фигыльләр кулланыла: *дип әйтү, дип сөйләү*. Сөйләм актының эчтәлек өлешенә басым ясала.

***Әйтү*** – әйтергә, сүз ярдәмендә фикерләреңне белдерү, телдән хәбәр бирү (туры һәм кыек сөйләм вакытында). Аерым бер сөйләм актына акцент ясала.

***Тиргәү, каһәрләү, ачулану*** – хисләрне белдерә торган мәгънәдәш фигыльләр төркеме. Кемгә дә булса ачуланып һәм аның намусына тиярлек итеп төрле сүзләр әйтү [7, б. 103].

***Сүз чыгу*** – сөйләм эшчәнлеген белдергән фразеологизм. Мәгънәсе: нәрсә турында булса да сүз башлау [4, б. 97].

***Акыру*** – аваз ияртеменнән ясалган яңгыраш фигыле, бик көчле кычкыруны белдерә [6, б. 47].

Шулай итеп, фигыльләрнең семантик төркемчәләрен билгеләгәндә, аларның тематикалары, синтагматик үзенчәлекләре һәм лексик мәгънәнең структурасын исәпкә алу мөһим. Гаимҗан Ибраһимовның «Алмачуар» әсәрендә сөйләм эшчәнлеген белдергән фигыльләрнең түбәндәге төркемчәләрен аерып чыгарырга мөмкин:

**Эмоциональ мөнәсәбәтне белдерә торган фигыльләр:** Бу төр фигыльләр сөйләм аша белдерелә торган эмоцияләр белән бәйле: *зарлану, зар салу, сукрану, ялыну, үтенү, ялвару, гозерләнү, мыгырдау, мыжгылдау,*

*тиргәү, әрләү, орышу, сүгү, битәрләү, табалау, ачулану, шелтәләү*. Әсәрдән мисал: *Әнкәй һаман сүз уңае сыен күз яшьләрен сөртә-сөртә:*

*– Картым, ачуланмасаң, балаларны кунакка чакырыр идем, – дип* ***ялына*** *торган иде* [3, б. 264]*; Әнкәй елаган өчен мине һаман* ***орыша****:*

*– Бу чаклы тиле булырсың икән, – ди, – тумаган тай өчен шулай елыйлармыни?, – ди.Әнкәй моның өчен һаман сукрана: – Ике атың бар өстеннән, нәрсә шул хәерче кебек лырт-лырт белән йөрисең? – ди* [3, б. 278].

**Этикет кагыйдәләре белән бәйле фигыльләр**: *сәламләү, сәлам бирү, исәнләшү, хушлашу, саубуллашу, рәхмәт әйтү*. Әсәрдән мисал: *Ул арада Сафа бабай, әйткәй, күршеләр, килеп, мине ат башыннан кочаклап алдылар, һәммәсе мактый, һәммәсе* ***рәхмәт укый*** [3, б. 287]. *Башкалар да* ***рәхмәт укыйлар****, яңадан чүгәләп дога кылалар* [3, б. 264].

**Сөйләмнең төрлечә яңгыравына ишарә иткән фигыльләр:** ***Шауламагыз****, бирәсе әйберем әллә кайчан әзерләнгән. Тик тизрәк тусын гына!* [3, б. 267]; *Мәйдан* ***гөж килә*** [3, б. 262]; *Әткәй белән әнкәй чаршау артында* ***пыш-пыш киләләр***[3, с. 276]. *Халык* ***шау-шу килә****, мәйдан кайный!* [3, б. 262].

**Хәбәрләшү, аралашуны белдергән фигыльләр:** *әйтү, сөйләү, дию, хәбәр итү, хәбәр бирү, сөйләшү, серләшү, җавап бирү.*Әсәрдән мисал: *Башка сүз* ***әйтмәделәр****, тик Сафа бабай гына: – Башта бик каулама, аерманың бу ягына чыккач, кызганма, нык сук! Тарткалап баруны ярата торган мал түгел бу! – дип, кат-кат* ***әйтеп калды*** [3, б. 284]. *Әткәй белән әнкәй чаршау артында пыш-пыш* ***сөйләшәләр*** [3, б. 276]; *Моңа* ***җавап кайтарырга****сүзем булмый, телем киселә: үземне җиксеннәр, аңа риза, тик минем Алмачуарыма гына тимәсеннәр* [3, б. 281].

**Дәшмәүне белдергән фигыльләр**: *дәшмәү, өнсез калу, ләм-мим әйтмәү, эндәшмәү* һ.б. Әсәрдән мисал: ***Дәшми-тынмый*** *тагы бик озак карап торды да: – Шулай шулай! Яңлышмыйм. Бу да нәкъ агалары кебек... – диде* [3, б. 278]; *Мин аңа* ***сүз дәшәргә*** *курыктым, әллә тирләгәнгә, әллә ачуланганга, аның йөзе кара көйгән иде* [3, б. 262].

Кайбер очракларда сөйләм эшчәнлеген фигыльләрнең гиперонимнары булып гомумирәк семантикага ия булган фигыльләр тора. Бу очракта сөйләм эшчәнлеген белдергән фигыль сөйләм белән бәйле булмаган шәхси очракны яки гамәлләр төрлелеген чагылдыра: *кабатлау,тәкрарлау, тәкърар кылу, тәкърар итү, кат-кат әйтү, мөрәҗәгать итү*. «Алмачуар» хикәясендә моңа мисал итеп түбәндәге җөмләне китерергә мөмкин: – *Башка бик каулама, аерманың бөу ягына чыккач, кызганма, нык сук! Берүк тезгененңне иркен куй! Тарткалап баруны ярата торган мал түгел бу! – дип,* ***кат-кат әйтеп*** *калды* [3, б. 284].

Сөйләм эшчәнлеген белдергән күпчелек фигыльләр сөйләм аша бәя бирү белән бәйләнгән. Уңай бәяне аңлата торган фигыльләргә *мактау, мәдхия кылу, мәдхия җырлау, хуплау, хуп күрү* һ.б. керә. Мәсәлән, *Сафа бабай тагы,* ***теләкләр теләп****, колынны* ***мактады*** *да минем колагымнан шаярып тартты* [3, б. *275*]. *Шулай итик дип сөйләп биргәч, әти карышмады, киресенчә,* ***хуплады****: – Их, балам, көенечкә генә булмаса ярар иде синең бу кылануларың, – диде һәм мин әйткәнчә эшләде* [3, б. 278].

**Тискәре бәя**не *хурлау, яманлау, тәнкыйтьләү, тәнкыйть итү, шелтәләү, шелтә белдерү, битәрләү* кебек фигыльләр тапшыра.

*Әнкәй елаган өчен мине һаман* ***орыша****: – Бу чаклы тиле булырсың икән, – ди, – тумаган тай өчен шулай елыйлармыни?, – ди* [3, б. 266]. *Әнкәй*

*моның өчен һаман* ***сукрана*** *:– Ике атың бар өстеннән, нәрсә шул хәерче кебек лырт-лырт бер белән йөрисең? – ди* [3, б. 266].

Әсәрдә төп герой Закирның әти-әнисенә булган мөнәсәбәте, әти-әнисенең Закирга буган мөнәсәбәтләрен автор тәкъдим иткән сөйләм фигыльләре аша да чамалап була. Закирның әнисе сөйләмен күбрәк *орышу, ачулану, сукрану, тиргәү* кебек фигыльләр белән бирелсә, әтисе белән улы арасындагы сөйләшүләрдә мондый төр фигыльләр бер дә күзәтелми. Алдагы ике баласыннан игелек күрмәгән ата кеше Закирга зур өметләр баглый, ул аның белән һәрчак ипләп сөйләшә. Моның шулай булуын әсәрдән алынган түбәндәге юллар да дәлилли: *Әткәй* ***ачуланмый****, ике өлкән баласының хәсрәтеннән соң бөтен йөрәген миңа баглаган булса кирәк, ул мине ярата, сүземне тыңлый, һәрчак иркәли* [3, б. 266]. *Гаҗәп яратам мин әйткәйне! Ул әз генә дә* ***ачуланмый****, минем сүзне ишетү белән, урыныннан торды да коймага эленгән нуктаны алды* [3, б. 272].

Закирның әнисе сөйләмендә кулланылган фигыльләр ананың бераз кырысрак булуын характерлыйлар, әмма ике баласы белән «авызы пешкән» ана төпчеге Закирның тормышта үз юлын таба алырлык көчле рухлы булып үсүен тели.

Әйтелеш үзенчәлекләрен чагылдырган фигыльләр дә байтак әлеге әсәрдә. Мондый төр фигыльләргә мисал итеп, *кычкыру, акыру, бакыру* кебек әйтелешнең динамикасын күрсәткән фигыльләрне китерергә мөмкин. Г. Ибраһимов мондый төр фигыльләрне әсәрдәге вакыйгаларның иң кызган вакыты – ат чабышын сурәтләгәндә кулланган. Чабыш башында кычкыру фигыленең беренчесе ат чабышын башлап җибәрүче Садыйк абзыйның сөйләмендә күзәтелсә: *– Берәү, икәү, өчәү! Һайди, туганнар! – дип* ***кычкырып та*** *җибәрде. Ул «һайди»ның «һ» сен әйтеп бетә алмагандыр, атлар, әйтерсең, канатланып чаптылар* [3, б. 285]. Икенчесе исә, әсәрнең кульминацион ноктасы – чабышның ахырында, атларның мәйданга якынлашкан мәлен зур дулкынлану һәм түземсезлек белән көтеп торучы халык тарафыннан кулланыла: *– Һайди, Алмачуар! Һайди, күк бия! Һайди, Алмачуар! Һайди, күк бия!.. Ике яклап безне каулыйлар ...* ***Кычкыралар****, сугалар,* ***шаулашалар****. Шау-шу, тавыш, тапталыш! Әйтерсең, мәхшәр көне*! [3, б. 287].

Татар телендә сөйләм эшчәнлеген белдергән фразеологик берәмлекләрнең дә саны күп. Мондый фразеологизмнарның фразеосемантик кыры «*сөйләү – эндәшмәү*», «*мактау*» – *тиргәү*», «*бәхәсләшү*» кебек мәгънәләрне белдергән фразеологизмнар: *телдән төште, тел тегермәне, сүз кату, тел ачылу, авызын томалау, авыз ачу, сүз үрчемәү, су кабу, тел тешләү, ярып салу, тел бармау, телен туктата алмау, телгә килү һ.б.* «Алмачуар» хикәясендә дә шактый күзәтелделәр алар. Мәсәлән: *Ике өлкән баласын хәтергә төшерү һәрвакыт безнең әткәйнең йөрәгенә авыр була, мондый чакта, ничектер, аның тавышы үзгәрә*, ***сүзләре башкачарак чыга*** [3, б. 275]; *Хәзер авылда Алмачуарга* ***тел тидер****гән кеше юк, һәркем аңа: – Күз тимәсен, сөбханалла! Бигрәк асыл сөяк нәрсә икән! Яхшы нәселдән шул!.. дип кенә карыйлар* [3, б. 275]*; Шулай булганга, әткәй дә Алмачуарны юк-барга җигәргә дип,* ***тел кузгатмый*** [3, б. 278]*; Моңа җавап кайтарарга сүзем булмый,* ***телем киселә****: үземне җиксеннәр, аңа риза, тик минем Алмачуарыма гына тимәсеннәр* [3, б. 281]. *Әмма әткәй үз* ***сүзеннән кайтмый*** [3, б. 265].

Мисаллардан күренгәнчә, сөйләм эшчәнленлеген белдергән барлык фигыльләр дә сөйләм яңгырашының үзенчәлекләрен, сөйләм эчтәлеген төрле

аспектларда тапшыралар. Әйтелешнең физиологик үзенчәлеген белдергән фигыльләр әсәрдә сирәк күзәтелде. Гадәттә мондый фигыльләр төркеме үз эченә *шышылдау, тотлыгу* кебек фигыльләрне ала. *Башыма нидер сукты,* ***телем тотлыкты****, сүз әйтә алмый катып калдым* [3, б. 276].

Шулай итеп, Г. Ибраһимовның «Алмачуар» хикәясендә сөйләм эшчәнлеген белдергән фигыльләрнең семантик кырын билгеләргә тырыштык. Танылган әдип, тел белгече сөйләм эшчәнлеген белдергән фигыльләр аша әсәрдәге геройларының, персонажларның холкын, рухи дөньясын осталарча сурәтләп биргән.


ӘДӘБИЯТ

1. Ганиев. Ф.А. Функциональная грамматика татарского языка. Казань, 2015. 272 с.

2. Гаптелганиева Д.М. Многозначность и омонимия и омонимия в системе татарской глагольной лексики: автореф. дис. …канд. филол. наук. Казань, 1999. 31 с.

3. Ибраһимов Г. Сайланма әсәрләр. Казан: Татарстан Республикасы «Хәтер» нәшр. (ТаРИХ), 2002. 543 б.

4. Исәнбәт Н.С. Татар теленең фразеологик сүзлеге. Ике томда. Казан. Татар. кит. нәшр., 1990. 2 том. 365 б.

5. Иштанова Р.К. Глаголы татарского языка в семантическом аспекте: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2000. 25 с.

6. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 1 т. 476 б.

7. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. 3 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. 3 т. 832 б.


## Г. ИБРАҺИМОВ ИҖАТЫНДА МӘХӘББӘТ МОТИВЫ


***Сәмитова С.Г. (Казан)***



Г. Ибрагимов в своих произведениях показывает истинное место любви в человеческой жизни, отношениях между людьми, находя свои, присущие ему приемы, и, выражая в своих произведениях, как правило, личные взгляды на это явление человеческого бытия. Его герои совершают подвиги и идут на преступление; это чувство, способное свернуть горы, изменить ход истории; чувство, дающее счастье и вдохновение и заставляющее страдать; чувство, без которого жизнь не имеет смысла.

In his works, G. Ibragimov shows the true place of love in human life, the relationships between people, finding his own original ways, and expressing, as a rule, his personal views on this phenomenon of human existence. His heroes perform feats and go to crime; feeling of love is able to turn mountains, change the course of history; It is a feeling that gives happiness and inspiration and makes you suffer; it is a feeling without which life does not make sense.


Классик әдәбият кешенең рухи халәтен, эчке дөньясын ачуга юнәлтелгән. Классик сүзе латин телендәге **classicus** – үрнәк сүзеннән алынган. Ул кеше тормышын төрле вакыйгалар, иҗтимагый шартлар, кешеләр арасындагы дуслык, төрле мөнәсәбәтләр, рухи бәйләнешләр аша сурәтли. Классик әдәбиятта мәхәббәт мотивына да зур урын бирелә. Классик әдәбият, кагыйдә буларак, бәхетсез мөнәсәбәтләргә дан җырлый. Бәхетле мәхәббәткә мисаллар аз. Чын мәхәббәт шәхесне барлыкка китерә, рухи яктан үсәргә, камиллеккә омтылырга мөмкинлек бирә. Әмма традиция буенча, әдәбиятта мәхәббәт геройлардан «мәҗнүн» ясый. Романтик геройлар шәхес буларак

яшәүдән туктый, инерция буенча яши, мәхәббәте, яки яраткан кешесе үлгәч алар да физик яки рухи яктан һәлак була. Мәхәббәтне бу рәвешле сурәтләү рус әдәбиятында И.С. Тургеневта, И.А. Бунинда очрый. Бәхетле мәхәббәтнең рус әдәбиятындагы классик үрнәге булып Л.Н. Толстойның «Сугыш һәм солых» роман-эпопеясе санала. Татар әдәбиятында бәхетсез мәхәббәт фольклордан ук килә, борынгы әдәбиятта үстерелә. Татар халкының яраткан дастаннарында мәхәббәт ике гашыйкның һәлакәте белән тәмамлана. Шулай да, татар әдәбиятында да бәхетле мәхәббәтнең матур үрнәкләре дә бар. Бәхетле мәхәббәтнең иң күркәм үрнәге – Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре.

Г. Ибраһимов иҗатында да мәхәббәт мотивы төрле конфликтлар, мәхәббәтне төрлечә кабул иткән төрле социаль катлауларга караган геройлар аша төрле яктан ачыла.

Г. Ибраһимовның «Сөю – сәгадәт» хикәясендә мәхәббәт чиста, самими, көч буларак бәян ителә, автор рухи мәхәббәткә дан җырлый. Әсәрдә мәхәббәт платон фәлсәфәсе аша кешегә яшәргә көч бирә торган, рухи яктан камилләштерә торган табигый хис буларак тасвирлана. Хикәянең башыннан азагына кадәр мәхәббәтнең кешегә илаһият тарафыннан бирелүе, гашыйк булуның илаһи вакыйга булуы сурәтләнә. Хикәядә рухи мәхәббәт семантик яктан беренче чиратта матурлык, сер аша ачыла: «*табигатьнең яңа күрке, матурлыгы*» [1, б. 126], «*дөнья вә табигатьнең тирән вә нечкә серләре*» [1,б.126], «*яңа латәфәт, яңа матурлык*» [1, б. 127], «*хәятым әллә ничә дәрәҗәдә матурланды*» [1, б. 127], «*Һәммә нәрсәнең төсе матурга таба үзгәрде*» [1, б. 127].

Г. Ибраһимов мәхәббәт хисен культ рәвешендә илаһилаштырылган «Х» образы аша, лирик геройның мәхәббәт объекты аша ача. Әдип бу кызны җир кешесе түгел, фәрештә буларак тасвирлый: «*Менә шул чакта язмыш, хәятымны артыграк бизәү өчен булса кирәк, минем гомер юлыма «Х» атлы **бер фәрештәне** чыгарып куйды*» [1, б. 126], «*Боларның (кызларның) галәме миңа бөтенләй ят һәм вә башка бер җирдә булмаган сер, латәфәт вә илиһият белән тулы тоела, шулар белән бәрабәр мин, йөрәгемдә куәтле бер ялкын хис кылсам да, аның бер җирендә аерым бер бушлык бар кеби сизә, ләкин ничек тутырырга белми идем*» [1, б. 126], «*Иптәшләрем аны «ямьсез дә түгел, ләкин син әйткәнчә, «**хур кызына биргесез**» дә түгел, тик гади бер кыз!» диләр*» [1, б. 127], «*Бөтен адәмнәрнең, минем кеби, аның гольвияте каршында сәҗдә итмәве – мине чынлап гаҗәпләндерә.*

***Минемчә, ул – илаһи***» [1, б. 127].

Әлеге хикәядә хатын-кызны изгеләштерүе, фәрештәләргә тиңләве очраклы түгел, нәкъ хатын-кыз ир кешегә, үзенә гашыйк булган егеткә мәхәббәт аша Аллага якынлашырга мөмкинлек бирә. Г. Ибраһимов бу хикәясендә мәхәббәтнең Алла тарафыннан аерым шәхесләргә генә бирелүен күрсәтә, мәхәббәтнең югарыдан бүләк булуын исбатлый. Герой мәхәббәтне кичереп, үзе дә илаһиятне аңларлык, кабул итәрлек дәрәҗәдә рухи яктан баый. Текстта капма-каршы илаһият/җир дөньясы семантик оппозицияләре тасвирлана. Мәхәббәтнең мифопоэтик тональносте аның бу дөньяга карамавын раслый. Җир дөньясына үтеп кергән мәхәббәт геройларның пространствосын да башка дөньяга һәм вакытка күчерә. Геройлар «*шәһәрнең һәртөрле чәчәкләр белән бизәлгән әгъла бакчасы эчендә, шат, матур вә ачык адәмнәр арасында музыканың бер куаныч вә бер моңлы көйләрен*

*тыңлап йөри*» [1, б. 131]. Бу бакча ике дөньяны бүлеп торган чик рәвешендә бирелә. Геройлар чикне үтеп, мәхәббәт яши торган икенче дөньяга кичәләр. Әсәрдәге икенче дөнья – табигать уртасындагы елга. «*Елганың бер ягы – зур һәм карт урманлы биек таулар, икенчесе- яшел үләннәр, ал-гөл чәчәкләр белән түшәлгән зур, киң тугай; бара торган суыбыз яхшы ук киң генә; аның өсте тымызык, тигез, шома. Кояш батып бара. Шуның тәэсиреннән күзге кебек ялтыраган су асты саргылт алтынга әйләнеп, күңелне әллә кая, күккә, мәхәббәт галәменә ашыра, җанга аерым бер рәхәтлек, латиф бер тәэсир кылә*» [1, б. 132].

Хикәя мәхәббәтнең бер мизгелен генә тасвирлый. Автор «Х»ның ярәшүле икәнен әйтү белән чикләнә. Чөнки платон хисләре җир тормышына күчәргә тиеш түгел. Бу әсәрнең идеясе белән туры килми. Бу әсәрдә мәхәббәт кешелек дөньясының иң зур кыйммәте буларак ачыла.

«Сөю – сәгадәт» хикәясендә сурәтләнгән рухи мәхәббәт мотивы алга таба «Яшь йөрәкләр» романында үстерелә. Романның сюжетында Зыя һәм Мәрьямнең бер-берсенә мәхәббәте ята. Романдагы бөтен вакыйгалар шушы геройлар һәм аларның хисләре тирәсендә төзелә. Романтик геройларның тормыш белән конфликты, мәхәббәте, эчке кичерешләре әсәрнең төп өлешен алып тора. Илаһи мәхәббәтнең җир тормышы белән экзистенциаль конфликты, мәхәббәт һәм үлемнең мистик бәйләнеше, җир тормышында, бу дөньяда мәхәббәтнең трагизм булуы Зыя белән Мәрьямнең мәхәббәте, эчке кичерешләре, психологик халәтләре аша гәүдәләнә. Роман Мәрьямнең төше белән башланып китә. Бу төш Зыяның солдатка каралу вакыйгалары, Мәрьям нинди тойгылар астында булганын бирү белән романдагы вакыйгалардан да хәбәр бирә. Дүртенче бүлекнең кереше дә Зыя солдатка киткәч, һәм Мәрьям башка кешегә кияүгә бирелгәч, аның эчке кичерешләрен күрсәтә. Бөтен роман эмоциональ лирик буяуга буялып бирелгән. Бу романда да геройларның эмоциональ халәте табигатьтән алынган параллельләр белән көчәйтелә. Сюжетның кульминацион моментлары табигать тасвирланмалары белән ассызыклана, бу да мәхәббәтнең чынбарлыктан ерак булуын, илаһи башлангычын ассызыклый. Әдип табигать белән мәхәббәтне тиң күренешләр буларак тасвирлый.

Әдип Зыяны тәртипле, әмма нечкә күңелле, йомшак табигатьле итеп сурәтли: «*...назик хәтерле, бик аз нәрсәләргә дә кәефе китә. Ләкин бу кәеф китүчелек, эчке вә самими бер үпкәдән гыйбарәт булып, һичбер тәкъдирдә дөнья җимереп, үч алырлык мәртәбәдә дошманлыкка җитә алмый... Халык та аңа яхшы күз белән карый... Аны һәр җирдә нәмүнә (нәмүнә – үрнәк) булырлык бер егет кебек тоталар»* [1, б. 272], Тик анда бер җитешсезлек «*нурлы хәятында кара тап*» булып торган бер сыйфат булса, ул да аның «*тумышыннан ук ибтила мәртәбәсендә (ибтила мәртәбәсендә – авыру дәрәҗәсендә.) музыкага бәйләнеше*!*»* [1, б. 273], Зыя үз бәхете өчен көрәшергә сәләтле түгел. Ул үзе укыган мәдрәсәне яратмый, андагы шартлардан канәгать түгел, беренче мөмкинлек булу белән мәдрәсәне ташлап чыга. Ләкин ата-анасының рәнҗүеннән куркып, аларны борчымас өчен, яңадан шундый ук башка мәдрәсәгә барып керә. Зыя авыру дәрәҗәсендә музыка сөя, өендә гитарада уйный, ләкин атасы гитарасын ватып ташлагач, каршы сүз дә дәшә алмый. Зыя Мәрьямне сөя, өйләнү турында да хыяллана, ләкин өйләнергә теләвен кешегә белдерә алмый. Шул рәвешле Зыя бәхет турында бары хыялланырга гына сәләтле, реаль тормышта яшәргә, хәтта көрәш

кирәк булмаган, җиңел генә хәл ителергә тиешле мәсьәләләрдә дә бернинди адым ясарга сәләтле түгел. Герой газаплы эзләнүләрендә ялгыз, ул реаль дөньяны кабул итмичә, хис һәм үзе уйлап чыгарган хыял дөньясында яши. Аның хыял дөньясына бары бер генә кеше – үзе кебек үк хыялый Мәрьям генә үтеп керә.

Мәрьям авыл кызы булса да, шәһәр традицияләренә нигезләнеп тәрбияләнә. Әнисе Фатыйма бикә «*Мәрьямне гимназиягә бирергә иҗтиһат кылган*» [1, б. 312], була. Бу теләге барып чыкмагач ул аны кызлар мәктәбенә бирә. Болай да реаль тормыштан аерылган тәрбия алган хыялга бай Мәрьям төрек романнары «дөнья»сында, тагын да гайре табигый дөньяда яши башлый. Үзен шул романнардагы героинялар белән чагыштыра. Шулай да, Мәрьям Зыяга караганда тормышка җайлаша алырлык сыйфатларга да ия. Әмма дөрес булмаган тәрбия, бер фикердән кайта алмау, тормышка яраклаша белмәү аны да бәхетсез итә.

Реаль тормыштан, хуҗалыктан аерылган, бары хыял һәм өмет дөньясында яшәгән геройлар – Зыя, Мәрьямнәр үләргә тиешләр. Геройларның җирдән аерылган мәхәббәт фаҗигасе конфликтның башта ук җирдә илаһи мәхәббәт була алмый дигән фәлсәфи, экзистенциаль аспектын ача. Автор романтик геройларның илаһи мәхәббәтен гадәти тормыш шартларында, җир мәхәббәте, гади ир белән хатын мәхәббәте рәвешендә үстерүдән дә курка, шул рәвешле геройлар аерылышырга, яки үләргә тиеш була. Романтик геройлар бер-берсенә түгел, мәхәббәт хисенә табыналар. Автор бу әсәрләрендә кеше психологиясенең иң яшерен якларын күрсәтергә омтыла, табигать гүзәллеге белән янәшә тасвирланган мәхәббәт культына дан җырлый.

«Табигать балалары» хикәясендә Г. Ибраһимов авыл яшьләренең мәхәббәтен, аларның чиста хисләрен, мөнәсәбәтләрен тасвирлый. Алда карап узган әсәр геройларыннан аермалы буларак, Хафиз белән Бибиәсма гади игенче балалары, авыл тормышы эчендә кайнап үскән яшьләр. Аларның мәхәббәте дә җир кешеләре, авыл яшьләре мәхәббәте, алар бер-берсен яраталар, яшеренеп кенә очрашалар, тизрәк башлы-күзле булу турында хыялланалар. Автор Бибиәсманың матурлыгын да җир кызы матурлыгы рәвешендә сурәтли. «*Әсма, диләр! Бибиәсма. Диләр, карчыклар, иркәм, дип аның аркасыннан кагалар, имеш күргән егетләр аның йөзенә, зифа буена, аяк атлавына хәйран булып сөйлиләр*» [1, б. 183]. Әсәрдә кешеләрнең бөтен яктан бәхетле, канәгать, риза булуы сизелә. Әдип бу хикәясендә кешенең табигый һәм табигать җимеше булуы, аның асылы, рухи сыйфатлары кебек мәсьәләләр аша Жан-Жак Руссо карашларын уздыра. Руссо кешеләрнең әхлакый, рухи һәм физик сыйфатларын югары бәяли. «Табигать балалары» хикәясендә хезмәт кешесенең рухи сәламәтлеге, бай эчке дөньясы, чиста хисләре, физик сәламәтлеге һәм көче бөтен күркәмлеге белән ачыла. Әсәрдә үзәк урында «Яшь йөрәкләр»нең нәкъ киресе булган гади кешенең мәхәббәт һәм хезмәт романтикасы үзәккә куела.

Бәхетле мөнәсәбәтләр әдипнең «Казакъ кызы» повестендә үстерелә. Бу әсәрдә йолаларга баш бирергә теләмәгән, үзе бәхете өчен көрәшергә әзер Карлыгач белән ирек сөючән, бунтарь рухлы Арсланбайның саф мәхәббәте тасвирлана. Бу әсәрдә дә мәхәббәт «Табигать балалары» хикәясенә аваздаш. Бу әсәрләрдә кешеләрнең мәхәббәте, аларның җирдә дә бәхеткә омтылуы, бәхетләре өчен көрәше тасвирлана.

Әлеге карап үткән әсәрләрдә мәхәббәт берничә аспектта ачыла. Автор беренче ике әсәрендә илаһи мәхәббәтне күрсәтсә, соңгы ике әсәрендә исә гади җир кешеләренең хисләрен гәүдәләндерә.

ӘДӘБИЯТ


1. Ибраһимов Г. Сайланма әсәрләр. 1 том. Казан: Таткнигоиздат, Матур әдәбият редакциясе, 1957. 527 б.

2. Нигъмәти Г. Сайланма әсәрләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1958. 278 б.

3. Нуруллин И.З. XX йөз башы татар әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. Б. 159–176.


## Г. ИБРАҺИМОВ ИҖАТЫНДА ФРАЗЕОЛОГИК БЕРӘМЛЕКЛӘРНЕҢ СТИЛИСТИК ӘҺӘМИЯТЕ


***Сибгаева Ф.Р.***



Богатейшие возможности стилистического использования фразеологических средств языка в художественной литературе, делают ее сильнейшим выразительным средством языка.
В данной статье рассматриваются фразеологические единицы и их ститистическая особенность в творчестве Г. Ибрагимова. Основная особенность фразеологизмов в творчестве Г. Ибрагимова в том, что значение фразеологизма не равно сумме значений образующих его слов. Они исторически изменчивы, могут вступать в синонимические и антонимические отношения, могут быть многозначными.

The richest possibilities of the stylistic use of phraseological tools of language in literature, making her the strongest expressive means of the language.
This article considers phraseological units and their statistical feature in the work of G. Ibragimova. The main feature of phraseological units in the works of G. Ibragimov that the meaning of the idiom is not equal to the sum of the values of its constituent words. They are historically changeable, can join synonym and antonymy relations, can be multivalued.


Татар әдәбияты, тел белеме өлкәсендә Галимҗан Ибраһимов бай һәм кабатланмас мирас калдырган шәхесләрнең берсе. Әлеге бөек шәхес тарафыннан фразеологик берәмлекләрне оста файдалану, образларны, вакыйгаларны сиземлерәк итеп сурәтләү, аларга үзенчәлекле төс кертү, әсәр телен халыкчан, гади, аһәңле итүдә зур роль уйный [2, б. 18]. Тәкъдим ителгән мәкаләнең актуальлеген Г. Ибраһимов иҗатында кулланылган фразеологик берәмлекләрнең стилистик функцияләрен анализлау билгели.

Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» әсәрендә кискен көрәш вакыйгаларына, тормышның фаҗигале, киеренке күренешләренә бәйле рәвештә персонажларның авыр физик һәм рухи халәтен сурәтләүгә зур урын бирелә. Моның өчен автор тойгыга бай, күңелгә көчле тәэсир итә торган фразеологизмнарның синонимик рәтен уңышлы файдалана: *йөрәк яну, йөрәк кысылу, күз алды караңгылану, җан чыга язу, тимер кыршау кысу, тын куырылу* һ.б.

Ике сыйныф вәкиле арасындагы каршылыклы мөнәсәбәтләр җирлегендә туган дошманлык һәм нәфрәт хисләрен дә язучы бай фразеологик чаралар белән сурәтли. Мәсәлән, «ярсу», «ачулану» мәгънәсен белдергән фра-

зеологик берәмлекләр романда егермеләп тапкыр кулланыла: *гайрәт чәчү, буран күтәрү, күзләрне кан басу, үзен-үзе белмәү* һ.б.

Теңкәгә тию [1, б. 136], йөрәккә тию [1, б. 204]; башны әйләндерү [1, б. 33], йөрәкне кайнату [1, б. 200] кебек синоним фразеологизмнарның мәгънәви һәм стилистик төсмерләрен Г. Ибраһимов кешенең билгеле бер халәтен күрсәтү өчен куллана. Белем һәм культура дәрәҗәсенә карап, геройларның үз сөйләме өчен хас булган берәмлекне оста куллана: *Минзифа әбинең теңкәсенә тиеп бетте бит шул кәһәр төшкере!* [1, б. 136]. *Бик җаныбызга тиде бит!* [1, б. 243] *Менә шулар аның йөрәген кайнаталар* [1, б. 200].

«Уйлану», «тынгысызлану» мәгънәсен белдерү өчен автор түбәндәге фразеологик берәмлекләрне сайлап ала: *шөбһәгә төшү* [1, б. 85], *күңелгә шик керү* [1, б. 97], *шик йөрәкне тырнау* [1, б. 39], *мине уй кыру* [1, б. 82], *мидә утлы кадак әйләнү* [1, б. 27] һ.б.: *Минем йөрәгемне авыр бер шик тырный да тырный, тырный да тырный!* [1, б. 39].

«Борчылу», «кайгыру» төшенчәләре түбәдәге фразеологик берәмлекләр белән бирелә: борчуга төшү [1, б. 176], җан әрнү [1, б. 144], йөзне кайгы болыты каплау [1, б. 138], йөрәк телгәләнү [1, б. 300], йөрәк яну [1, б. 141], йөрәк кысылу [1, б. 183], йөрәк әрнү [1, б. 288], хәсрәт-сөрем каплау [1, б. 175] һ.б.: *Моңа җаным бик әрнеде* [1, б. 144]. *Бая үзе каты чәкәләшеп алган Шәяхмәтнең бу талашка җаны бик әрнеде* [1, б. 132].

Мисаллардан күренгәнчә, «кайгыру» мәгънәсен белдергән фразеологизмнарда «җан», «йөрәк» һәм «ут» компонентлары актив кулланыла. Кайгы-хәсрәтнең ачысы ут кызуы белән чагыштырыла һәм фразеологик берәмлекләрдә яну, көю сүзләре белән бирелә. Мәсәлән: кайгы уты эчендә яну [1, б. 237], кара көю [1, б. 174].

Г. Ибраһимов фразеологик берәмлекләрдә «йөз» компонентын үзенчәлекле куллана: йөз кибеп кату [1, б. 220], йөз тимерләнеп кату [1, б. 358], йөзне кайгы болыты каплау [1, б. 138] һ.б. Бу берәмлекләрдә кайгының йөрәкне авырттырып, җанны әрнетеп кенә калмыйча, кешенең тышкы кыяфәтендә дә чагылыш табуын ассызыклый: *Йөзләрен караңгы кайгы болыты каплады* [1, б. 138].

Фразеологик әйтелмә составында кулланылган караңгы эпитеты мәгънәне тагын да көчәйтеп җибәрә. Әсәрдә кайгы болыты фразеологизмының синонимы – кайгы сөреме [1, б. 138] дә очрый һәм «кайгы-хәсрәт килү» мәгънәсен аңлатып килә.

Үлем образы әсәрнең башыннан ахырына кадәр озата бара, шуңа күрә Г. Ибраһимов үлемне фразеологик берәмлекләрнең синонимлыгы аша җиткерә: җан чыгу [1, б. 320], кул-аяк кору [1, б. 357], күздән җан чыгу [1, б. 251], язмыш өзелү [1, б. 321], кадалып китү [1, б. 125], башны ашау [1, б. 55] һ.б.

«Тирән тамырлар» романында составына эт, кан, утлы, кара һ.б. шундый эпитетлар һәм метафоралар кергән фразеологик берәмлекләр еш очрый: кара кан [1, б. 73], эт мужиклар [1, б. 118], кара үлем [1, б. 239], канлы күз яше [1, б. 74], кара уй [1, б. 251] һ.б.

Ак һәм кара антоним мәгънәле лексик берәмлекләр кергән фразеологизмнар актан караны аеру, нәрсәнең яхшыга, нәрсәнең начарга алып баруын билгеләү өчен автор куллануны кирәк тапкан: *Шулай маташа торгач, ул ак белән караны аерырлык булган иде* [1, б. 204].

Язучы тимер предметларның атамалары катнашкан берәмлекләрне дә оста куллана: *тозак очы китереп кысу* [1, б. 56], *утлы тимер кыршау кысу* [1, б. 240], *йөз тимерләнеп кату* [1, б. 358], һ.б.

«Тирән тамырлар» әсәрендә акыл белән бәйләнешле фразеологик берәмлекләр еш очрый: *акыл бирү* [1, б. 219], *акыл сату, баш уйлату фразеологизмнары* «*өйрәтү*», «*киңәш бирү*» мәгънәләрен белдерә.

Әсәрдә *баш* компонентлы берәмлекләр дә уңышлы кулланыла. Баш ашау [1, б. 201] фразеологизмы «һәлак итү, оятка калдыру, хур итү» мәгънәсен дә белдерә һәм җир тишегенә керердәй булу [1, б. 207], хурлыктан ертылу [1, б. 201] кебек берәмлекләренең синонимы да булып килә: *Ул гына минем башымны ашады, күз яшем аңа төшәр, – дип,үлгән анасын каргый* [1, б. 201]*; Ул башын, йөрәген кая куярга, бу мәсхәрәдән дөньяның кайсы тишегенә кереп качарга белми...бәргәләнеп елый иде* [1, б. 207].

Баш вату [1, б. 312] – «бик нык уйлану, борчылу», баш югалту [1, б. 211] – «уйламыйча эш итү», баш әйләнү [1, б. 233] – «нәрсә беләндер артык мавыгу; төрле хисләргә бирелеп, үз-үзеңне оныту; аптырау; үз-үзеңне ялгыш бәяләү, масаю», башта томан булу [1, б. 219] – «нишләргә кирәклекне төгәл белмәү», баш китү [1, б. 379] – «хәтерсезләнү», баш күккә тию [1, б. 228] «шатлану, куану» төшенчәләрен ачыклап киләләр: *Җиһанша уллары дигәндә тирә-як кызларының дәртле йөрәкләре яна, башлары әйләнә иде* [1, б. 228]. *Ул әйтә, башым әйләнде инде монда,ди* [1, б. 123]*; Башындагы томан бөтенләй таралды* [1, б. 219]*; Җамалиның башы күккә тиде. Куанычыннан кая басарга белмәде* [1, б. 228].

«Кеше турында яманлап сөйләү, начар хәбәр тарату» мәгънәсе гайбәт чәчү [1, б. 201], гайбәт йөрү [1, б. 166], гайбәт чәйнәү [1, б. 214], җыен тузга язмаганны сөйләү [1, б. 174], хәбәр кузгалу [1, б. 152] һ.б. шундый фразеологик берәмлекләр белән бирелә.

«Тирән тамырлар» әсәрендә сүз компоненты булган фразеологизмнар актив һәм тел-стиль үзенчәлекләренә, мәгънә төсмерләренә карап уңышлы файдаланылганнар: *сүз ялгау* [1, б. 169], *сүз тегермәнен әйләндереп җибәрү,* [1, б. 167], *сүзгә тагылу* [1, б. 144] *һ.б. берәмлекләр әңгәмәнең башлануын белдерәләр. Сүз кызу* [1, б. 143] *исә әңгәмә барышында кызып-кызып сөйләшүне аңлата. Сүз очлау* [1, б. 146], *сүзне өзү* [1, б. 151], *сүз киселү* [1, б. 237] *әңгәмәнең тәмамлануын ачыклый. Сүз төбе* [1, б. 381] *әйтергә теләгән фикерне, сүзгә кереп китү* [1, б. 173] ачуланышуны белдерә.

Персонажларның портретларын сурәтләгәндә дә Г. Ибраһимов халык фразеологизмыннан оста файдалана – *аяклы тарих* [1, б. 174] фразеологизмы белән күп күргән, тормышның ачысын-төчесен татыган, белемле кешене тасвирлый: *Аяклы тарих – Җиһанша бабай тагын үзенең йөрәгенә, миенә кан белән, газап белән язылган вакыйгаларга кереп китте* [1, б. 174].

Ерткыч күз [1, б. 183] фразеологизмы усал итеп караучы кешене, кыыршы тел [1, б. 186] ямьсез сөйләүчене, нык каешланган каты кул [1, б. 177] авыр хезмәттә күп эшләгән кешене, талаш баш [1, б. 216] ызгышырга, талашырга ярата торган кеше, усал тел [1, б. 166] усал кешене, утлы тел [1, б. 166] начар сүз әйтеп, рәнҗетүче кешене, яман тел [1, б. 143] начар сүзле кешене сурәтләргә ярдәм итә, шуның белән геройларның эчке дөньясын, тышкы кыяфәтләрен, холык үзенчәлекләрен ачык күзалларга ярдәм итә.

«Тирән тамырлар» әсәрендә кулланылган фразеологик берәмлекләрне лексик-семантик үзенчәлекләреннән һәм стилистик функцияләреннән чыгып, берничә төркемгә бүлеп карарга мөмкин:

1. Персонажларның характеристикасы сыйфатында кулланылучы фразеологизмнар: 1) персонажларның портретларын сурәтләүче фразеологизмнар: ачулы күз, ерткыч күз, җимерелгән баш, йөзе изелү, йөз тимерләнеп кату, кырыкка ярылырдай булып ашыккан йөз, нык каешланган каты кул, кытыршы тел, талаш баш, усал тел, утлы тел, яман тел, каткан колак, су күз һ.б.; 2) персонажларның акыл, белем дәрәҗәсен күрсәтүче фразеологизмнар: акылдан шашу, акылдан язу, акылы башына сыймас булу, ми яктырып китү һ.б.; 3) персонажларның психик халәтен сурәләүче фразеологизмнар: баш китү, баш югалту, баш әйләнү, аяклы тарих, башта томан булу, баш китү, тәҗрибәсез кул, тилергән күз, таш маңгай, ми әйләнү һ.б.; 4) персонажларның рухи дөньяларын, хис-тойгыларын күрсәтүче фразеологизмнар: агарынып кату, ач күздән зәһәр ут чыгару, ачудан кара көю, борынны салындыру, чыгырыннан чыгу, җан әрнү, җир тишегенә керердәй булу, йөрәк телгәләнү, йөрәк яну, йөрәк кысылу, йөрәкне курку алу, йөрәккә барып бәрелү, кайгы уты эчендә яну, кара көю, күңелне кытыклау, күңелдә шик булу, күңел күге, өметсезлеккә чуму, өмет сүнү, тойгы уяну, хәйран калу; 5) персонажларның сөйләмен характерлаучы фразеологизмнар: кисеп әйтү, котырган тавыш, кытыршы тел, лыгырдап тору, буш бугаз, гайбәт чәчү, гайбәт чәйнәү, кабартып сөйләү, кычкырыш ялкыны кабыну, сүз ялгау, сүз кызу, сүз очлау, сүз төбе, сүз киселү, сүз тегермәнен әйләндереп җибәрү, сүзгә кереп китү, сүзгә тагылу, сүздән кайтмау, сүзне өзү, тел киселү, җыен тузга язмаганны сөйләү; 6) персонажларның характерын сурәтләү чарасы буларак кулланылган фразеологизмнар: яман тел, буш бугаз, кытыршы тел, салкын караш, сакаллы сабый, талаш баш һ.б.

2. Эш-гамәлләрне, вакыйгаларны характерлаучы фразеологизмнар: 1) эш-гамәлнең үтәлү рәвешен белдерүче фразеологизмнар: карап кату, катып тору, катып уйга талу, кәеф ачу, сүз ялгау, агарынып кату, җан чыгу, йокы очу, йөз агару, кәеф ачу,көнне төнгә ялгау, теш кайрап йөрү, төймәдән дөя ясау,текәлеп карау, хәлдән таю, бер атуда ике куянны алу, гөж килү, мөлдерәтеп карау; 2) эш-гамәлнең үтәлү вакытын сурәтләүче фразеологизмнар: алда күз күрер, яшьлек канат ярганда, биш былтыр, итәккә ут капкач, таң атмас борын, ярты төн аугач һ.б.

3. Иҗтимагый күренешләрне сурәтли торган фразеологик берәмлекләр: аяклы тарих, язмыш дулкыны, тормыш дулкыны, язмыш сынавы, тормыш төбе, тормыш газабы һ. б.

Күргәнебезчә, Г. Ибраһимов «Тирән тамырлар» романында тел-стиль ягыннан матур яңгырашлы булган, кыска гына эпизод-диалог аркылы тирән мәгънә аңлаткан фразеологизмнардан оста файдаланган. Бу сыйфат исә язучы-рәссамның отышлы ягы. Фразеологик берәмлекләр авторга геройның портретын тасвирлауда, эчке дөньясын ачуда, вакыйга-күренешләрне чагылдыруда ярдәм итә.

ӘДӘБИЯТ

1. Ибраһимов Г. Сайланма әсәрләр. III том. Казан: Тарих, 2002. 540 б.

2. Курбатов Х. Сүз сәнгате. Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы. Казан: Мәгариф, 2002. 322 б.

# ПРОИЗВЕДЕНИЯ Г. ИБРАГИМОВА КАК ОБЪЕКТ ЛЕКСИКОЛОГИЧЕСКИХ ИЗЫСКАНИЙ (на примере названий одежды)

***Тагирова Ф.И., Сабитова И.И.***

В статье на примере одной тематической группы лексики – названий одежды – анализируется потенциал художественных текстов Г. Ибрагимова в качестве предмета и источника лексикологических исследований. Раскрываются некоторые семантические, функциональные и иные особенности данной группы лексики.

The article gives a detailed analysis of the value of G. Ibrahimov's literary texts as an object and source of lexicological research on the example of one thematic lexical set – the names of clothes. Some semantic, functional and other peculiarities of this lexical set are revealed.

Творчество Г. Ибрагимова всегда привлекало научный интерес исследователей – как литературоведов, так и лингвистов. Даже ощущается некоторое оживление подобного интереса. Исследования, посвященные жизни, творчеству, общественной деятельности писателя, весьма многочисленны и разноплановы. Однако говорить о том, что они всеобъемлющи, было бы неверно. Особенно это относится к лингвистическому аспекту ибрагимоведения. Если сделать обзор работ по исследованию особенностей языка писателя, обнаружится, что большинство из них представляют собой статьи, посвященные лексическим особенностям языка отдельных произведений, тематическим и лексико-семантическим группам (Ф.Г. Гарипова [2, с. 204]; Ф.С. Баязитова [3, с. 218; 4, с. 181]; Г.Р. Мөгътәсимова [3, с. 225]; М.Р. Саттарова [3, с. 222]; Р.С. Нурмөхәммәтова [3, с. 226; Г. Хөснуллина [3, с. 229]), средствам актуализации концептов (А.А. Ногманова [3, с. 239]; Ф.И. Тагирова [3, с. 242]; Ф.К. Сагдеева [4, с. 207]) и др. Некоторые работы освещают синтаксические и грамматические особенности текстов Г. Ибрагимов ([Л.Р. Мирсиапова [4, с. 222]; Г.Ә. Нәбиуллина [3, с. 231]; И.И. Сабитова [3, с. 232]; Р.Ф. Фаттахова [4, с. 191]) и. т.д. Однако эти исследования в целом не складываются в одну систему, так как осуществлены по разным методикам, по сути являются разноаспектными и разрозненными. Исключение здесь составляет разве что монографическая работа Ф.М. Газизовой [1]. Обилие подобных работ далеко не означает, что тексты произведений писателя, его язык исследованы достаточно исчерпывающе. Все исследователи солидарны только в одном: произведения Г. Ибрагимов по сей день дают неоценимый материал для изысканий в самых различных аспектах. Поэтому есть основания говорить, что в аспекте лексикологии язык Г. Ибрагимов требует более последовательного и системного изучения.

Язык писателя представляет собой весь массив средств общенародного языка, которые писатель использует в своих произведениях. Язык Г. Ибрагимова в этом плане является чрезвычайно богатым, разноплановым, колоритным. Так, его произведения насыщены этнографизмами, диалектизмами, бытовой лексикой, архаизмами, заимствованной лексикой, топонимами и т.д. и т.п. В вышеперечисленных статьях некоторые из этих лексических пластов рассматривались. В данной работе мы рассматриваем использо-

ванные автором названия одежды. Эта область лексики в татарском языкознании являлась предметом исследований ряда специалистов, главным образом, диалектологов. Так, следует упомянуть работы Р.К. Рахимовой [11], Д.Б. Рамазановой [9, с. 43–53; 10, с. 121–126], Л.Ф. Тухбиевой [12, с. 50–57] и др.

Для произведений Г. Ибрагимов характерны точные, детальные описания места действия – ландшафта, пейзажа, момента действия – времени года, погоды и т.п. С такой же точностью, даже скрупулезностью он описывает действующих лиц – их лица, внешность, создавая полный физический и психологический портрет. Одним из средств достижения такой живости и правдивости в отражении действительности отчасти являются названия одежды. Рассмотрим эту лексику с нескольких ракурсов.

В количественном отношении лексика одежды во всех произведениях Г. Ибрагимов представлена очень широко. Всего нами было выбрано из текстов несколько десятков разных названий. Для иллюстрации обилия и разнообразия данной лексики приведем несколько примеров из разных произведений: *Ул (Нурый), чалма, җилән, читек, кәвеш киеп, бушаган арада мәчеткә дә йөри башлады.* (Диңгездә) [5]. *Аларның ире, хатыны, бае, ярлысы гомумән үзләре чәчеп үстергән пәҗи вә җитеннәрдән үз куллары белән эшләгән киндер вә алачадан күлмәк кияләр; тун, чикмән, шарф, бияләй вә оекларның һәрберен дә үзләренең сарыкларның йон вә тиресеннән үзләре хәзерлиләр иде.* (Йөз ел элек) [5]. *Кыш ул, кая гына барса да, якасы әллә кайдан ук мөмтаз сыйфат илә күренеп торырлык, зур бүре толып, зуррак җирдә булса, кызыл якалы төлке тамак толып кия.* (Яшь йөрәкләр) [5] и т.п.

С тематической точки зрения можно выделить названия следующих групп:

1) Легкая одежда: *җилән, чапан, камзул, казаки, бишмәт, күлмәк, халат, бохара бикасабы* и т.п. Например: *Ләкин ишеккә дә җитә алмады, тар билле, күкрәкләре укалы бәрхет бишмәт, башына түбәсе укалы, чите каракүлле озынча бүрек кигән Карлыгач-Сылу кызулап килеп керде ---.* [6]

2) Теплая верхняя одежда: *чикмән, тужурка, тун, билле тун, толып, доха* и т.п. Например: *Алардан уртагарак җөббәле, чалмалы, җиләнле, кечкенә кара бүрекле, тужуркалы, кайсы чапанлы динчеләр тезелгәннәр* [6].

3) Головные уборы: *кәләпүш, чалма, рус картузы, камалы бүрек, мескен бүрек, кырма бүрек, колаклы бүрек, озын йонлы чиркас бүреге, фуражка, эшләпә, калфак, кепка, яулык, колакчын* и т.п.

4) Обувь: *оек, чабата, читек, пима, галош, ботинка, кәвеш, штиблет, башмак, ката* и т.п. Например: *Кечкенә аякларына Казан эше булган кызгылт төсле тар, нечкә матур итек, өстенә зәңгәрсу кара күлмәк киде ---.* [6]

С генетической точки зрения представлена не только общетюркская и собственно татарская, но и заимствованная лексика:

1) Арабизмы: *фәс, җөббә* и т.п. *Өстенә җөббә, аягына штиблет, башына каракүл бүрек кигән, җитү чәчле шома Казан шәкерте Зәки Гайфи тәкәллеф белән генә атлап барды ---.* [6]

2) Фарсизмы: *шәл, кәләпүш* и т.п. *Өйдәгеләрен онытмаган: сеңлесе Гайниягә ике тәңкә ярымлык шәл, атасына бер читек, әнкәсенә күлмәклек алган* [6].

3) Русизмы: *платье* и т.п.

4) Европеизмы:

а) заимствования из французского языка: *галош, жакет, пальто, вуаль, ботинка, манжет, шинель, костюм, тужурка, кепка, юбка, фуражка, камзул* и т.п. *Ирнең башында кепка. Өстендә кара пальто.* (Безнең көннәр) [6]. *Фәхри --- эшләпәгә тоташтырып, куе кара вуаль белән битен каплаган Гәүһәр туташның янына ук килде.* (Безнең көннәр) [6].

б) из немецкого языка: *галстук, шарф, штиблет, картуз* и т.п. *Пәкри --- башына рус картузын киде дә --- өенә китте*. (Йөз ел элек). [5]

в) из шведского: *кофта* и т.п.

5) Заимствования из других языков: *урамал, көпе* и т.п.

В произведениях Г. Ибрагимов широко представлены единицы, которые с точки зрения активности употребления в настоящее время уже перешли в пассивный пласт татарского языка и являются архаизмами. Необходимо подчеркнуть, что большинство из них представляют собой историзмы, то есть слова и сочетания, означающие изчезнувшие реалии: *мескен бүрек, чабата, бишмәт, җилән* и т.п., например: *Кичә көтмәгәнрәк вакытта Гыйлаҗи кайтып төште дә безне җыйды. Йөрүе бөтенләй бушка булмаганга охшый: аякта итек, өстә кара чикмән, кулда күн бияләй, башта яңа кырма бүрек* [6].

Автор использовал в текстах произведений большое количество этнографизмов, в частности названий одежды, на наш взгляд, не случайно, а весьма целенаправленно и продуманно. Это оправдано и с точки зрения создания местного, деревенского или национального колорита, и как средство оживления, конкретизации, приближения персонажа к действительности.

Выбор характера лексики в каждом случае, естественно, обусловлен тематикой конкретного произведения. Так, роман «Казакъ кызы» насыщен заимствованиями из казахского языка, этнографизмами и экзотизмами. Например: *Өстендә буй-буй сырып тегелгән яңа көпе, башында бәрхет тышлы, кызыл төлке эчле, чите камалы очлы бүрек, билендә кара алтын белән бизәлгән көмеш кәмәр, кулында камчы.* Или: *Кирәгә буйлап көпеле, колакчынлы казакълар, күзе яшьле, ак урамаллы хатыннар утыралар* [6]. А в романе «Безнең көннәр» преобладают западные заимствования. Например: *(Чибәр кызның) өстендә <u>кара йон юбка</u>, <u>кызыл ефәк кофта</u>. Аягында <u>биек үкчәле кечкенә сары ботинка</u>. Аз гына хәл ала да, шунда бер кадакка эленгән <u>жакеты</u> белән <u>эшләпәсен</u> алып, чыгарга киенә башлый* [7]. Причем их употребление продиктовано соображениями не только стиля или тематики, но и семантики. Так, лексемы *күлмәк* и *платье* употреблены в этом произведении параллельно, но для обозначения разных понятий. Слово *платье* означает не просто платье, а платье европейского кроя, в отличие от вида национальной одежды, означаемой словом *күлмәк.* Например, сравним: *Аның аяк очы башында --- пальто, берничә <u>платье</u>, шәл эленеп тора.* и *Кызның куштан итәкле, килешле зәңгәр <u>күлмәге</u> --- аны аеруча чибәр күрсәтеп тора. Коңгырт чәч өстендә --- ак энҗеле калфак --- соклангыч күренә* [7].

Преобладание лексики того или иного характера связано и с этапами творчества. В то же время язык писателя тесно связан с языковым контекстом эпохи. Так, период активного использования западных и русских заимствований у Г. Ибрагимова совпадает с таким периодом у других авторов начала XX века, да и всей татарской литературы вообще.

Таким же образом можно было бы продолжить анализ языка писателя на предмет использования лексических средств, связанных с литератур-

но-художественной традицией, требованиями направлений романтизма или соцреализма и т.д.

В целом, на наш взгляд, по сей день не реализован в достаточной мере потенциал текстов Г. Ибрагимова применительно к лексикологическим исследованиям. Подобные исследования важны для характеристики языка Г. Ибрагимова как писателя, его идиостиля, так как лексический состав является частью индивидуального стиля. Кроме того, богатый лексический материал его произведений может служить основой семантических, этимологических и других изысканий.

ЛИТЕРАТУРА

1. Газизова Ф.М. Язык и стиль прозы Галимджана Ибрагимова: автореф. дис... канд. филол. наук. Уфа, 1975. 33 с.

2. Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман: Г. Ибраһимовның тууына 115 ел тулуга багышланган фәнни конференция материаллары. Казан: Фикер, 2003. 272 б.

3. Г. Ибраһимов мирасы һәм төрки дөнья: Г. Ибраһимовның тууына 125 ел тулуга багышланган Халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары (17 апрель, 2012 ел). Казан, 2012. 265 б.

4. Галимҗан Ибраһимов һәм XXI гасыр: Г. Ибраһимовның тууына 120 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. Казан, 2007. 332 б.

5. Ибраһимов Г. Сайланма әсәрләр: 3 томда. Казан: Таткнигоиздат, 1957. 1 т. 526 б.

6. Ибраһимов Г. Сайланма әсәрләр: 3 томда. Казан: Таткнигоиздат, 1956. 2 т. 594 б.

7. Ибраһимов Г. Сайланма әсәрләр: 3 томда. Казан: Таткнигоиздат, 1956. 3 т. 611 б.

8. Рамазанова Д.Б. Понятие «одежда» в татарских говорах // Татар теле һәм этносы тарихы мәсьәләләре. Казан: ТӘһСИ, 2000. 176 б.

9. Рамазанова Д.Б. Некоторые наблюдения над семантикой слова итәк в татарских говорах // Проблемы лексикологии и лексикографии татарского языка. Выпуск 2. Казань: ТӘһСИ, 1995. 146 б.

10. Рахимова Р.К. Профессиональная лексика, относящаяся к ткачеству, одежде, обуви и головным уборам (на материале Заказанья ТАССР): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1975. 32 с.

11. Тухбиева Л.Ф. История изучения названий одежды и головных уборов в тюркологии и татарском языкознании // Проблемы лексикологии и лексикографии татарского языка. Выпуск 6. Казань: Фикер, 2003. 158 б.

## МӘКТӘПТӘ ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫҢ ТОРМЫШЫН ҺӘМ ИҖАТЫН ӨЙРӘНҮ

***Тимашева А.А.***

В статье рассмотрены некоторые особенности изучения творчества писателя Галимджана Ибраһимова по современным школьным программам татарской литературы. Обращено внимание на возможности использования материалов литературного краеведения.

This article considers some features of Galimdzhan Ibragimov’s works on modern school programs of Tatar literature. It is also paid attention to the possibilities of using materials of literary local studies.

Әдәбиятның чишмәсе, агачының тамыры, ачып җибәргән җирлеге – ул халык иҗаты. Әдәбиятка нигез салучылар, аны үстереп, көннән-көн баетып, тулыландырып, яңа үсеш-үзгәреш кертүчеләр дә шактый күп. Мәсәлән, татар драматургиясенең түрендә Галиәскәр Камал исеме тора. Татар поэзиясенең көче, биеклеге Габдулла Тукай иҗаты белән билгеләнә. Татар

прозасында исә аерым бер урынны зур талант иясе, барлык тугандаш халыклар тарафыннан остаз дип танылган – Галимҗан Ибраһимов алып тора.

Галимҗан Ибраһимов кебек зур талант ияләре безне һәрвакыт сокландыра, без алар белән горурланабыз, аларга дан җырлыйбыз һәм әдәбиятка керткән өлешләренә сөенеп, рәхмәт сүзләребезне бүгенге көндә дә белдерәбез. Ул ике гасыр әдәбиятлары арасына салават күпере салган кебек, ике чорда да гаять актив иҗат иткән, әдәбиятның алгы сафында барган әдип һәм журналист; әдәбият теориясен һәм тәнкыйтен үстерүгә күп хезмәт куйган кеше; тел, әдәбият, тарих фәннәре өлкәсендә эшләгән галим һәм укытучы. Үз чорының иң белемле фикер иясе, таланты безнең көн язучыларын һәм укучыларын рухландыра торган каләм иясе [2].

Мондый даһи шәхесләребезнең иҗаты яшь буынны тәрбияләүдә бик әһәмиятле урын били. Шуңа күрә андый әдипләрнең иҗатын мәктәптә тиешле дәрәҗәдә өйрәнүгә аеруча зур игътибар бирелә. Язучы белән танышу мәктәптә югары сыйныфларның беренче баскычында, ул да булса 5 нче сыйныфта, әдәбият дәресләрендә башлана. Бу сыйныфта Г. Ибраһимовның кыскача гына тормыш юлына һәм иҗатына күз салу, өстәмә мәгълүмат белән эшләү карала. Балачак хәтирәләре белән бәйле, укучыларда уңай психологик халәт тудыра торган, үз тормышын сурәтләгән «Алмачуар» хикәясе укырга тәкъдим ителә [1]. Укыту программасында 5 нче сыйныфта өйрәнү өчен бик аз вакыт бирелә. Әлбәттә, бу сәгатьләр эчендә язучының эшчәнлеген тулысынча яктырту өчен бик аз, шуңа күрә укучыларга үзаллы күп укырга һәм кызыксынырга туры килә.

Галимҗан Ибраһимовның эшчәнлеген һәр сыйныфта карарга булыр иде, ләкин программа, стандартлар буенча һәр сыйныфта бер чор үтелергә тиеш дип бирелгән. Шәхеснең иҗат эшчәнлеге XIX һәм XX гасырлар эченә керә, шуңа бәйле 6 нчы сыйныфта булган белемнәрне тулыландырып, яңа, күләме буенча зуррак булган әсәрләр белән танышу күз уңында тотыла. Ул да булса дуслык темасын тулы итеп яктырткан «Кызыл чәчәкләр»повесте.

Программа буенча 7–9 сыйныфларда Г. Ибраһимов белән танышу каралмый [3]. Гомумән, әдәбиятны чорларга бүлеп укытуда укучыларның яшь үзенчәлекләре, психологик хәләтләре, кабул итергә әзерлекләре, мөмкинчелекләре күз уңында тотыла. Урта сыйныфларда мәхәббәт, табигать, дуслык һ.б. темаларга караган, ә югары сыйныфта кабул итергә авыррак булган әсәрләр укыла. 10 сыйныф тулысынча борынгы әдәбиятны өйрәнүгә бирелә, шуңа күрә Г. Ибраһимов әсәрләрен өйрәнү бу чорга керми. 11 сыйныфта берничә дәрес эчендә «Казакъ кызы»романы белән танышу күзаллана.

Г. Ибраһимовның барлык әсәрләре белән мәктәп программасы эчендә генә карап бетерү мөмкин түгел, шуңа күрә күп әсәрләре укучының үзаллы танышуына кала.

Гасырлар алышынып, тормыш үзгәреп торуга карамастан, Г. Ибраһимов кебек бөек кешеләрнең эшләре, әдәбиятка яки башка өлкәгә керткән өлешләре югалмый, онытылмый. Еллар үтүе укучыларның фикер йөртү сәләтләренең үзгәрүенә, мәгълүматлар артуына, яңа фикерләр формалашуына китерә, күп очракларда фактларга бәйле бәхәсләр барлыкка килә. Материалны үзләштерүнең нигезендә чор үзенчәлекләре ята, шуңа бәйле генә нинди дә булса язучы белән танышу аңлы рәвештә үтә. Мәсәлән, бүгенге көндә укучыга Г. Ибраһимов яшәгән вакытны аңлату һәм асылына төшү бик авыр, шуңа күрә төрле видео, аудиоязмалар чыгаралар, яңа метод, алымнар

кертелә, техник чаралар белән эш карала. Билгеле бер әсәрнең төп каһарманын бүгенге тормыш күзлегеннән чыгып караганда, аны уңай герой дип билгеләргә мөмкин, чөнки әсәр белән танышканнан соң бер фикерне генә мәңгелеккә бәйләп куеп булмый, минемчә, ул чор таләбе. Моңа карамастан, мин Б. Майлин сүзләре белән тулысынча килешәм: «Галимҗан – сүз остасы; аның сүзе укучыны тылсымлый; китаплары җанлы чынбарлыкның киң панорамасын гәүдәләндерә».

Әдипнең иҗатын Башкортстан мәктәпләре җирлегендә өйрәнү өчен үз мөмкинлекләре бар. Республикада аның туган ягы – Авыргазы районы Солтанморат авылында әдипнең Музей-йорты урнашкан. Ул әдипкә, татар халкының мәдәни һәм тормыш-көнкүреше белән бәйле бай материаллар, экспонатлар белән җиһазландырылган. Аны барып күрү, махсус танышу мөмкинлеге бар. Шулай ук әдипнең әсәрләрендә урын алган бай табигать күренешләрен, җирлекне, укытучы осталыгына таянып сайланган алымнар ярдәмендә, дәресләрдә бөтенләй башка яңгыраш аша биреп була. Суфиян Поварисовның «Пәйгамбәр таңы» трилогиясен класстан тыш уку дәресләрендә һәм сыйныфтан тыш чаралар аша уку программаларында каралган әдипнең әсәрләре белән бәйләп үзләштерү бигрәк тә уңышлы нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. Шулай ук, яңа белем стандартлары таләп иткәнчә, проект эшчәнлегендә бү үзенчәлекләр бигрәк тә үтемле темалар буларак файдаланыла ала. Алдынгы карашлы, заманча эш итүче укытучылар бу яктан бай тәҗрибә туплаганнар. Аларны файдаланырга һәм киңрәк таратырга кирәк.

Г. Ибраһимовның белемгә омтылуы, хезмәт юлын иртә башлавы хәзер дә укучыларга үрнәк булып тора. Әсәрләрендә күтәрелгән мәңгелек темалар, проблемалар үз актуальлекләрен югалтмыйлар.

Бүгенге көндә Г. Ибраһимовның иҗаты Г. Тукай, Г. Камал, Һ. Такташ, Х. Туфан һәм башка бөек әдипләр исеме белән беррәттән тора, чөнки бу язучылар әдәбиятны өскә күтәргән, таныткан остазлар һәм зур хөрмәткә лаек кешеләр.

ӘДӘБИЯТ

1. Ганиева Ф.Ә. Әдәбият: Татар урта гомуми белем мәкт. 6 нчы с-фы өчен дәреслек-хрестоматия / Ф.Ә. Ганиева, И.Г. Гыйлаҗев, Ф.Ф. Исламов. Казан: Мәгариф, 2000. 240 б.: рәс. б-н.

2. Җәләлиева М.Ш. Әдәбият: Татар урта гомуми белем мәкт. 5 нче с-фы өчен дәреслек-хрестоматия / М.Ш. Җәләлиева, Г.М. Әдһәмова, Д.Ш. Сибагатуллина. Тулыл. 3 нче басма. Казан: Мәгариф, 2000. 255 б.: рәс. б-н.

3. Гыймадиева Н.С, Билалова Ә.Г. Әдәбият дәреслекләре буйлап. (V–VIII сыйныф укучылары өчен ярдәмлек). Казан: Яңалиф, 2006. 124 б.

## И. НУРУЛЛИН КҮЗАЛЛАВЫНДА Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ ИНКЫЙЛАБКАЧА ПРОЗАСЫ

***Тимерова Л.М.***

В статье рассматриваются идейно-тематическое, философско-эстетическое развитие и изменения в творчестве Г. Ибрагимова до октябрьской революции 1917 года в представлении И. Нуруллина.

The article discusses the idea of the thematic, philosophical and aesthetic development and changes in the work of G. Ibragimov, before the October revolution of 1917 in performance I. Nurullin.

И. Нуруллин тәнкыйтендә XX гасыр башы прозасын анализлау зур урын тота. Г. Ибраһимов иҗатын да ул шуның эчендә, аның мөһим өлеше буларак бәяли. Галимнең «XX йөз башы әдәбияты» дип исемләнгән монографиясендә Г. Ибраһимов прозасын яктыртуга аерым бүлекчә багышланган. Әлеге хезмәттә И. Нуруллин язучының әдәби тәҗрибә туплау юлын һәм кузаллауларының фәлсәфи-эстетик яссылыктагы үзгәрешләрен күрсәткән.

Галим, Г. Ибраһимовның иҗат мәйданына килүе 1907 елны – «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясе белән башлануы хакында яза. Бу язмада тәнкыйтьче әле яшь язучының, тәҗрибәсезлегеннән тыш, XIX гасыр һәм 1905 елгы революция еллары, татар әдәбиятын иҗат принциплары да бик нык сиздерә иде, дип әйтә. Ул Г. Ибраһимов прозасының җитешсезлекләрен һәм уңай якларын күрсәтә һәм бу фикерләр әдәбият белемендә әлегәчә искермәгән. Галим Г. Ибраһимовның җитешсезлекләре дип түбәндәге сыйфатларны атый: конкрет вакыйганы алмау, сюжеты булмау, образларның берьяклылыгы, автор сөйләменә артык зур урын бирелү, исеме аталган бер генә персонаж катнашу.

Аныңча, бу әсәрдә Г. Ибраһимов иллюстратив тасвир белән чикләнә. И. Нуруллин, кайсы гына язучы иҗатын анализларга алынса да, аны чор әдәбияты җирлегендә бәяли. Г. Ибраһимов прозасын анализлаганда, «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясенә хас сыйфатларны М. Гафури, З. Һади, Ш. Мөхәммәдев кебек авторлар прозасында да барлыгын әйтә, аталган әдипләрнең иҗатын натурализмга хас тәфсиллек берләштергәнлекне ача.

И. Нуруллин Г. Ибраһимов каләменең сизелерлек тизлек белән камилләшүе турында сүз алып бара. Аның 1909 елда иҗат ителгән «Татар хатыны ниләр күрми» повестен үк беренче хикәядән соң алга таба атланган зур адым дип саный: «Биредә, төп персонажлардан тыш, исемгә генә түгел, бәлки шактый ачык характерга ия булган күп кенә бүтән персонажлар бар, һәм алар бер сюжетка оешалар. Авылның гореф-гадәтләре, геройларның тышкы кыяфәтләре һәм эчке халәтләре өметле каләм белән шактый оста сурәтләнгән» [1, б. 242].

Телгә алынган хикәягә бәя биргәндә дә галим аны үз чорының танылган әсәрләре янәшәсенә куя. Аерым алганда ул анда Закир Һади кулланган композицион алымнар өстенлек иткәнне исбатлый. Мәсәлән, З. Һади кебек үк, Г. Ибраһимов герое турында «аның балачагыннан башлап сөйләшергә керешә» [1, б. 242] ди.

И. Нуруллин Г. Ибраһимов прозасының, образлар кору, композиция үзенчәлекләреннән тыш, фикерләү типлары турында да сүз йөртә. Ул аның башлангыч чор әсәрләрендә публицистика еш очравын әйтә. Алда аталган әсәр янәшәсенә «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә»не дә (1909) өсти.

Г. Ибраһимов әдипнең теләсә кайсы әсәренә фәнни-тәнкыйди караш белән якын килә. Әйтик, «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә»дә шулай ук кечкенә конфликт бар, әмма конкрет вакыйга юк, дип белдерә, ул бары тик бәхәстә генә чагылыш таба, дип әйтә.

И. Нуруллин Г. Ибраһимов иҗатын төгәл һәм дәлилле рәвештә этапларга бүлә һәм беренче чор иҗатына рационализм, натурализм хас иде, дип белдерә. Галим, «Татар хатыны ниләр күрми» повесте белән, Г. Ибраһимов иҗатында соңрак көч алачак сыйфатлар яралды дип саный. Әдипнең инде конкрет тормыш вакыйгаларына нигезләнүен, шактый реалистик язуын әмма романтизм чаткылары калуын әйтә. Шул ук вакытта И. Нуруллин

Гөлбану һәм башка кайбер характерларда натурализм билгеләре саклануны да күрә.

И. Нуруллин, «Яз башы», «Диңгездә», «Йөз ел элек», «Карак мулла» һ.б. хикәяләре белән, Г. Ибраһимов иҗатында романтизм принциплары өстенлек иткән чор башланды дигән крашта тора. Ул: «Әдәбият һәм сәнгатьнең асылы, иҗтимагый роле, чынбарлыкка мөнәсәбәте мәсьәләләрен дөрес, материалистик аңлауга кадәр Г. Ибраһимов катлаулы һәм каршылыклы юл үтте», [1, б. 245] – дип әйтә.

Билгеле булганча, татар әдәбияты тарихында XX гасыр башында «Саф сәнгать»кә бәйле бәхәсләр барган. И. Нуруллин Г. Ибраһимовның 1909–1910 еллардагы эшчәнегеген «сәнгать сәнгать өчен» теориясенә мөнәсәбәт, сәнгатькә бәйле карашларындагы үзгәрешләр белән бәйли: «Г. Ибраһимов 1909–10 елларда әдәбияттагы, аеруча поэзиядәге үгет-нәсихәтчелеккә, риторика һәм рационализмга каршы ярсулы көрәш башланган иде. Тора-бара, артык мавыгып китеп, һәм рус эстетик фикерендәге чайкалулар тәэсирендә булса кирәк, «сәнгать сәнгать өчен» теориясенә таба авышты. Һәм бу гаҗәп тә түгел. Дидактик сәнгать өчен төп нәрсә – фикер. Художестволы форма шуңа иллюстрация хезмәтен генә үти. Әнә шул сәнгатьне тәнкыйть итәм дип чама тойгысын югалтып җибәрсәң, су белән бергә баланы да тагарактан түгеп ташлавың, ягъни форманы беренче урынга куеп, эчтәлекнең ролен кечерәйтеп күрсәтүең мөмкин. Бу исә «саф сәнгать»кә таба тайпылу дигән сүз. Чөнки бу теория өчен нәкъ менә төп нәрсә – саф форма, ә бу формага нинди эчтәлек салынган – әһәмияте юк» [1, б. 245].

И. Нуруллин Г. Ибраһимовның «саф сәнгать»кә шаукымына бирелеп алуын күрсәткән хезмәтләре арасында иң характерлысы сыйфатында «татар шагыйрьләре» исемле очеркларен атый. Галим Г. Ибраһимовның татарның иң зур шагыйрьләренә бәясен поэзиянең үзе аңлавындагы максат-бурычларына илтеп тоташтыра: «аныңча, поэзия тормышта табылырга мөмкин булган матурлыкны тагын да бизирәк төшеп, укучыга күрсәтеп бирергә тиеш. Поэзиянең игътибарын җәлеп итәрлек ике нәрсә бар: берсе – мәхәббәт, икенчесе – табигать» [1, б. 246].

И. Нуруллин, аның унберенче елда язылган хикәяләренә таянып, әлеге карашларның үз прозасына да йогынтысы булуын дәлилли. И. Нуруллин 1912–14 елларда аның иҗаты инде башка төр үзгәрешләр кичерде, бу елларда әдип прозасында реализм көчәя барды, дип белдерә. Монографиядә Г. Ибраһимов даими эзләнгән, әдәби-эстетик карашларында туктаусыз үгәреш кичергән әдип сыйфатында ачыла. Ул аның әдәбият һәм сәнгатьнең иҗтимагый роле турында соңрак кайгырта башлавын, әмма инде бу мәсьәләнең үтә мөһимлеген аңлавын әйтә. Икенче яктан галим игътибарны ул кулланган иҗат принципларына юнәлтә: «Бу процесс катлаулы юл белән барды. Реализм принципларының өстенлек алуы белән бергә, романтизмның аерым алымнары һәм чаралары Г. Ибраһимов әсәрләренең тукымасына сеңеп, реализмын баеттылар, чынбарлыкны гәүдәләндерү мөмкинлекләрен арттырдылар» [1, б. 258].

И. Нуруллин Г. Ибраһимовның революциягә кадәрге иҗатында «Безнең көннәр» романы аерым урын тота дип саный. Ул бу әсәрнең әһәмиятле ягын пролетариат позициясенә басарга өлгермәгән Г. Ибраһимовның 1905 елгы революциянең, татар иҗтимагый хәрәкәтенең үзенчәлекле якларын ачып бирүендә күрә. Икенче яктан әсәрнең тормышчанлыгы, илдәге

сәяси хәлләрне объектив тасвирлавы һәм алардан тиешле нәтиҗә чыгаруы Г. Ибраһимовның идея-эстетик яктан зур адым ясаганлыгын күрсәтә дигән нәтиҗәгә килә. Бу хезмәттә И. Нуруллинның торгынлык еллары фәне кысаларында, үз заманына хас фикер йөрткәнлеге күренә, чөнки татар сүз сәнгате XX гасыр башы чорын пролетариат әдәбиятына һәм социалистик реализмга таба бару юлы социалистик реализмга әзерләнү этабы буларак күзаллый. Галим карашынча, «Безнең көннәр» романы социалистик реализм белән язылмаган, «без аны критик реализмның гүзәл үрнәге, югары баскычы татар критик реализмын социалистик реализмга китереп ялгаган әсәр... итеп карарга тиешбез» [1, б. 263].

Кыскасы, И. Нуруллин язучының октябрьгә кадәрге иҗаты татар әдәби хәрәкәтенең характерлы тенденцияләрен чагылдыра, революцион күтәрелеш еллары милли сүз сәнгатебезне шактый ачык күзалларга булыша. Күргәнебезчә, ул Г. Ибраһимов иҗатына беренче чиратта методлар яссылыгыннан якын килә.

ӘДӘБИЯТ

1. Нуруллин И. XX йөз башы татар әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1966. 328 б.

## «МИН ХӘЯТЕ МОТЛАК КЕШЕСЕ...»
## (ТР милли музее фондларында Г. Ибраһимовның Ә. Хәсәнигә язган хатлары)

***Төхвәтова Г.Ф.***

В статье рассматриваются письма Г. Ибрагимова к издателю Ахматгараю Хасани, хранящиеся в фондах Национального музея РТ. Одно из писем вводится в научный оборот впервые.

The article considers the letters of G. Ibragimov to the publisher Akhmatgaray Khasany that are stored in the collections of the National Museum of the Republic of Tatarstan. One of the letters is introduced into scientific circulation for the first time.

Эпистоляр жанрдагы язмалар чорның иҗтимагый, әдәби процессларын тирәнрәк аңларга ярдәм итә, җәмгыять һәм шәхес арасындагы мөнәсәбәтләрне ачыклый һәм теге яки бу язучының биографиясе, иҗат юлы хакында кызыклы мәгълүмат чыганагы булып тора. Язучы, тел галиме, илебездәге иҗтимагый тормышның, үзгәрешләрнең уртасында кайнаган Галимҗан Ибраһимовның (1887–1938) фәнни нигезләнгән биографиясен тулыландыруда хатлар зур роль уйный.

Әдипнең кулъязмалары үзе исән вакытта ук игътибар үзәгенә куела, алар «Безнең юл», «Кызыл Татарстан», «Коммуна» газета-журналларында дөнья күрә башлый [5, б. 14]. Г. Ибраһимовның шәхси язмаларын барлау һәм бастырып чыгаруда Г. Мөхәммәдова, А. Шамов, Ф. Ибраһимова, Р. Хәйретдинов, М. Әхмәтҗанов, Н. Юзиев, М. Хәсәнов һ.б. күп көч куя. Бу өлкәдә аеруча А. Шамов һәм Ф. Ибраһимова хезмәтләрен билгеләп үтәргә кирәк. Г. Ибраһимовның тууына 75 ел тулган вакытта төзелгән комиссиянең председателе буларак Афзал Шамов, әдипнең кулъязмалары, рәсемнәре, документлары белән берлектә, хатларын туплый һәм нәшер итә. Ф. Ибраһимованың

«Язучы биографиясенә яңа чыганаклар» хезмәтендә һәм аның тарафыннан әзерләнгән Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең тугызынчы томында язучының төрле оешмаларга, төрле кешеләргә язган шәхси язмалары урын алган.

Татарстан Республикасы Милли музее фондларында Г. Ибраһимовның тәрҗемәче Гайшә Шәриповага, Хөсни Кәримгә һ.б. язган хатлары сакланып калган. Алар арасында күренекле татар матбагачысы, нашир, публицист, тәрҗемәче, драматург һәм җәмәгать эшлеклесе Әхмәтгәрәй Хәсәнигә (1883–1933) юлланганнары да бар.

Г. Ибраһимовның Ә. Хәсәнигә 1913 елның 8 сентябрендә язылган хаты [9] музейга 3179 номерлы акт белән 1962 елның 30 сентябрендә Зәйнәп Хәсәни тапшыра. Язма бүгенге көнгә кадәр беркайда да нәшер ителмәгән, беренче тапкыр фәнни әйләнешкә кертелә. Ул 22×17,6 см размерлы авыш сызыклы дәфтәр битенең ике ягына язылган.

Хат Г. Ибраһимовның туган авылы Солтанмораттан җибәрелгән. Язучы авылда июнь урталарыннан сентябрь урталарына кадәр яши [4, б. 363]. Хатта үзенең тиздән Казанда булачагын хәбәр итә, һәм чыннан да сигез көннән соң, ягъни 1913 елның 16 сентябрендә, Г. Ибраһимов Казанга килеп җитә. Бу турында «Йолдыз» газетасының 19 сентябрь санында мәгълүмат басылган [6].

Хат Ә. Хәсәнинең Галимҗан Ибраһимовны «Аң» журналына эшкә чакыруына җавап буларак язылган: «Мөхтәрәм Әхмәтгәрәй әфәнде! Мәктүбегезне алдым. «Аң» кебек куәт вә тәрәкъкыйне чындан арзу [омтылыш. – *Г.Т.*] иттегез. Бер журналның портфелен тәкъдим итүегезгә, шундый мөһим вакыйгада мине хатлавыгызга рәхмәт» [9]. Биредә язучының тәкъдим хакындагы уйланулары күренә.

«Беләсез, мин хәяте мотлак [ирекле тормыш. – *Г.Т.*] кешесе. Шуның өчен дә күпләрнең тәгаҗҗебенә [гаҗәпләнүенә. – *Г.Т.*] каршы, моңарчы Вакыт вә Йолдызлар кебек зур вә карт гәзитәләрнең дәгъвәтен [чакыруын. – *Г.Т.*] иҗабәт итми [кабул итми. – *Г.Т.*] килә идем. Ләкин сезнең дәгъвәтегезне алгач, кырт кисеп рәд [кире кагу. – *Г.Т.*] җавабы бирәсем килмәде» [9], – дип яза Г. Ибраһимов.

Г. Ибраһимовны журналга «Аң» исеменнән рәсми рәвештә иң элек Фатих Әмирхан чакыра [11, б. 69]. Ә. Хәсәни дә язучыны берничә тапкыр хат язып чакырган булса кирәк. Чөнки язучы 1913 елның 3 гыйнварында Киевтан Хәнәфи Кайбышевка юллаган хатында «Монда килгәч, Гәрәй, үзе хат язып, яңадан «Аң»га язышуны үтенде» [11, б. 69], – дип белдерә.

Г. Ибраһимов 1913 елның 18 октябреннән 1914 елның 13 февраленә кадәр «Аң»ның җаваплы секретаре вазифаларын башкара. Ул журналның фәнни-иҗтимагый һәм әдәби сыйфатын күтәрергә тырыша. Бу максаттан редакция тирәсенә сәләтле, белемле яшьләрне туплый башлый [4, б. 364]. Г. Ибраһимов «Аң»да эшләвенең максатын 1913 елның 26 октябрендә Хөсни Кәримгә язган хатында түбәндәгечә аңлата: «Аң»ның секретарьлеген алдым. Буны, бәлки, ишеткәнсеңдер дә. Яшь фикер, яшь куәт «Аң» тирәсендә җыелсын иде. Чын мәгънәсе илә әдәби вә мәдәни бер мәҗмуга шәкеленә керсен иде, дим» [12, б. 78]. «Аң»ның сәнгатьне пропагандалаудагы казанышлары да анда секретарь булып Г. Ибраһимов эшләгән чорга туры килә [7, б. 192].

«Татарларны туплау, аларны оештыру һәм милли фирка төзү максатыннан» [10, б. 15] Г. Ибраһимов, журналдагы эшен калдырып, Киевка китәргә мәҗбүр була. Ләкин журнал белән бәйләнеш өзелми, «Аң» битләрендә язучының төрле елларда әдәби, фәнни мәкаләләре басылып килә. Мәсәлән,

«Татар имласында яңа агымнар» (1915), «Татар сарыфлары» (1915), «Телләре башка булса да, күңелләре бер» (1916) һ.б.

Ф. Ибраһимова фикеренчә, «Аң» редакциясе 1914 елның языннан башлап Г. Ибраһимовка журналда басылган һәм басылачак әсәрләре өчен ай саен билгеле бер күләмдә гонорар җибәреп торган дигән фикердә тора. Казан губерна жандарм идарәсе архивында «Г. Ибраһимов «Аң»нан китсә дә, журналның хезмәткәре булып исәпләнә», – дигән сүзләр бар [4, б. 370].

Г. Ибраһимов белән Ә. Хәсәнинең алга таба да аралашып торуын Г. Ибраһимовның 1915 елның 6 мартында Солтанмораттан Ә. Хәсәнигә язган хаты да дәлилли. Әлеге хатның төп нөсхәсе музей фондларында саклана.

Хат беренче тапкыр Афзал Шамов тарафыннан «Совет әдәбияты» журналының 1962 елның 3 нче санында бастырыла. Әлеге хат тексты тирән эчтәлекле искәрмәләр һәм аңлатмалар белән баетылып 2000 елда нәшер ителгән Г. Ибраһимовның 9 томлык әсәрләренең 9 нчы томына да кертелә. Анда төп нөсхәсенең саклану урыны итеп А. Шамовның шәхси архивы күрсәтелә. Әмма музей документларын өйрәнү әлеге шәхси язманың язмышы башкача булуын күрсәтә.

Хат, Ә. Хәсәни архивындагы башка предметлар белән берлектә, музейга 1956 елның 24 октябрендә Ә. Хәсәнинең хатыны Хәсәнова Зәйнәп Ногман кызы тарафыннан тәкъдим ителә. Шул ук елның 12 декабрендә сатып алу комиссиясе тарафыннан тикшерелеп, 15 декабрьдә татар артисты Г. Кариевның автографы белән фотографиясе, татар мәдәнияты тарихына караган фотографияләр һәм документлар сатып алыну турында 967 номерлы акт төзелә. Актны музей фондларын җитәкләгән Ф.Г. Гасимов төзи. Экспонатларның саны 21+6 дип күрсәтелә. Алар музейның экспонатлар кабул итү дәфтәренә 1957 елның 27 февралендә КППи – 119759 номеры белән «Коллекция фото, программ и других материалов, связанных с историей татарского театра» буларак теркәлгән.

Описьта Габдулла Кариев, Кәрим Тинчурин, Фатих Әмирхан, Мортаза Имәнский, Әхмәт Урманчиев, «Сәйяр» труппасы белән бәйле фотолар, Габдулла Тукайны соңгы юлга озату вакытында төшерелгән фотосурәтләр, Г. Кариев иҗатына багышланган монография, әдәби кичәләр һәм спектакль программалары, Г. Кариев хаты һ.б. тапшырылуы хәбәр ителә. Шунда ук Г. Ибраһимовның нашир Ә. Хәсәнигә язган хатының төп нөсхәдә булуы искәртелә.

Хатта Г. Ибраһимов «Аң» журналында секретарь булып эшләгәндә төзегән «Альбом» («Сәнаигы нәфисә мәҗмугасы») һәм Беренче Бөтендөнья сугышы елларында дошман кулы астында калган, мохтаҗлыктан җәфа чиккән Карс өлкәсендәге төрки халыклар файдасына спектакль кую турында сүз бара, «Гасыр» нәшриятында хикәяләр нәшер итү үзенчәлекләре аңлатыла. Язучы «Аң» журналында басылган хикәяләр хакында үзенең фикерен җиткерә, аларның әдәби кыйммәте турында уйлана. Г. Ибраһимов Җамалетдин Вәлидовнең «Аң»ның 1915 елгы 3, 4, 6, 7 нче саннарында басылган мәкаләсен түбәндәгечә бәяли: «Аң» ны күрдем. Җәләйнең мәкаләсенә «Әдәби хәрәкәт» исеме биргәнсең икән. «Язгы чәчәкләр» дигәннән бусы мәгънәлерәк булыр» [2, б. 90]. «Сәгыйть Рәмиев «Аң»га үзенең «Яңа шигырь һәм әүвәлгеләре» дигән яңа басылган шигырь мәҗмугасын җибәрәм диде. Син аны яратасың бугай. Шул хакта «Аң»да берәр нәрсә язылса, яки һич

булмаса, аның мәҗмугасыннан берәр кыйтга кертелсә, күңелле булыр иде» [2, б. 90], – дип яза Г. Ибраһимов шагыйрь С. Рәмиев хакында.

Хатта Г. Ибраһимовның шәхси тормышына, туганнарына караган мәгълүматлар да бар, аерым алганда агасы Шакирҗан Ибраһимов телгә алына. Шулай ук язучы үзенең авылда тору вакыты, Уфага китәчәге турында яза. Әдипнең Казан турындагы уйланулары кызыклы: «Казанда чакта аннан китәсе килә. Китсәң, сагына башлыйсың. Ялкауланмый бер хат яз әле. «Гасыр» вә «Аң» әһеленә, гомумән, сәлам» [2, б. 90].

Гомумән, төрле фондларда сакланып калган Г. Ибраһимов белән бәйле документлар, кулъязмалар, хатлар тикшерелеп, киң җәмәгатьчелеккә җиткерелергә тиеш. Чөнки еллар узуга карамастан, алар актуальлекләрен югалтмый, язучының тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнүдә яңа мәгълүматлар ачалар.

ӘДӘБИЯТ

1. Әхмәтгәрәй Хәсәни: Фәнни-популяр җыентык / Д.Ф. Заһидуллина, А.Д. Батталова, Л.Н. Йөзмөхәммәтова. Казан: Җыен, 2011. 408 б.

2. Әхмәтгәрәй Хәсәнигә // Ибраһимов Г. Әсәрләр. 9 томда. Казан, 2000. 9 т.: Хатлар һәм документлар / төз. Ф. Ибраһимова. Б. 89–90.

3. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 9 томда. Казан, 2000. 9 т.: хатлар һәм документлар / төз. Ф. Ибраһимова. 464 б.

4. Искәрмәләр һәм аңлатмалар // Ибраһимов Г. Әсәрләр: Казан, 2000. 9 томда. 9 т.: Хатлар һәм документлар / төз. Ф. Ибраһимова. Б. 338-456.

5. Исламов Р. Әдипнең хатлары // Мәдәни җомга. 2017. 17 март.

6. Йолдыз. 1913. 19 сентябрь.

7. Мәһдиев М. Без бишенче елны бер көнне // Әхмәтгәрәй Хәсәни: Фәнни-популяр җыентык. Казан: Җыен, 2011. Б. 185–194.

8. НМ РТ КППи-119759/18

9. НМ РТ КППи-121400

10. Таһиров И.Р. Галимҗан Ибраһимов – җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе // Г. Ибраһимов мирасы һәм төрки дөнья: Г. Ибраһимовның тууына 125 ел тулуга багышланган Халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары (17 апрель, 2012 ел). Казан, 2012. Б. 14–16.

11. Хәнәфи Кайбышевка // Ибраһимов Г. Әсәрләр. 9 томда. Казан, 2000. 9 т.: Хатлар һәм документлар / төз. Ф. Ибраһимова. Б. 69 .

12. Хөсни Кәримгә // Ибраһимов Г. Әсәрләр. 9 томда. 9 т.: Хатлар һәм документлар / төз. Ф. Ибраһимова. Казан, 2000. Б. 78–80.

## ИНСЦЕНИЗАЦИЯ ПРОИЗВЕДЕНИЯ «СУДЬБА ТАТАРКИ» Г. ИБРАГИМОВА

***Фардеева Д.Р.***

В статье дается анализ сценического варианта произведения «Судьба татарки» Г. Ибрагимова. Спектакль «Судьба татарки» является ярким образцом театрального прочтения литературного первоисточника. Появление инсценировки Х. Салимжанова стало началом полноценного существования произведения Г. Ибрагимова на сцене татарского театра.

The article analyzes the scenic version of the work «The Destiny of the Tatar woman» by G. Ibragimov. The performance«The Destiny of the Tatar woman» is a vivid example of the theatrical interpretation of the original literary source. The dramatization of Ibragimov’s workby Kh. Salimzhanov gave rise to its full-fledged existence on the stage of the Tatar theatre.

Г. Ибрагимов сыграл значительную роль в становлении татарской прозы и эстетической мысли начала XX века. Он принадлежит к той плеяде писателей, которая была выдвинута на литературное поприще революцией 1905–1907 годов. Г. Ибрагимов, вовлеченный в круг таких выдающихся талантов родного слова, как Г. Исхаки, Ф. Амирхан, Г. Камал и Г. Кулахметов, под их непосредственным влиянием вскоре определил свое творческое направление и художественный облик, и оставил в национальной литературе неизгладимый след. Как точно отметил литературовед Г. Халит: «Ибрагимов поднял плодородные пласты татарского литературного языка, насытил его живыми, полнокровными элементами народной речи. Он упорным трудом добился пластичности, яркости и свободного течения повествования» [1, с. 19].

Начало творческого пути Г. Ибрагимова было ознаменовано выходом в свет в 1909 году повести «Судьба татарки», в которой была поднята тема свободы женщины, актуальная для того времени. Как известно, до начала XX века для татарского общества было характерно неравенство полов в общественной и семейной жизни, жестко регламентированное общественной моралью и религиозными предписаниями.

В произведении Г. Ибрагимова тема женского неравноправия, ненормальности положения татарской женщины в дореволюционном обществе является основной. Как точно отмечает Г.С. Кашшаф: «…Произведение Галимджана Ибрагимова «Судьба татарки» – одно из сильнейших реалистических произведений. Автор, сосредоточив эпические события в одном фокусе, смог показать на примере судьбы одного человека целый ряд подобных нелегких судеб, на примере одной группы персонажей смог представить перед нашими глазами историческое движение народа» [2, с. 128].

В нашей статье мы рассматриваем сценическую версию произведения «Судьба татарки» Г. Ибрагимова, основываясь на видеозаписи спектакля, поставленного в 1960 году и на инсценировке Х.Ю. Салимжанова. Инсценировщик, прекрасно понимая законы сцены, удачно перевел это прозаическое произведение на язык драмы. Х.Ю. Салимжанов сохранил идейно-тематическую направленность повести, драматизм реальных жизненных ситуаций, этнографические картины, позволяющие показать все тонкости быта татарской деревни начала XX века. Вместе с тем, он сумел внести свой авторский взгляд, создав полнокровный спектакль. В центре произведения тяжелая участь семнадцатилетней девушки Гульбану, судьба которой олицетворяет судьбы всех татарских женщин того времени.

Гульбану – героиня светлая, трагическая. Ее образ олицетворяет нравственную чистоту, душевную красоту татарской женщины, ее стремление к воле, ее способность не только терпеть, но и отстаивать свои права, свое человеческое достоинство. Гульбану – истинный национальный характер, ее речь отличается высокой поэтичностью, образностью, эмоциональностью.

Главная героиня спектакля (актрисы Г.Ф. Булатова, Р.К. Хайрутдинова) начинает и завершает его. Действие начинается монологом Гульбану. При открытии занавеса зрители видят комнату в опрятном деревенском доме, разделенную печкой на две половины. На стенах шамаилы – изречения из священных писаний с видами Мекки и Медины. Позади видны двери в кухню и на улицу. При открытии занавеса издали доносится хоровое пение на мотив старинной татарской песни «Каляу Гайша». Песня удаляется, смолкает. Оформление сцены передает достаточно яркое представление об обста-

новке, в которой воспитывалась и росла главная героиня, о ее окружении. Следует особо отметить интересное оформление первого действия режиссером П. Исанбетом. С правой стороны сцены между домом и забором остается пустое пространство. Зрители видят, как отец Гульбану Нури (актер Г. Зиятдинов) раскрывает здесь свои тайны. Здесь Гульбану делится секретами со своей тетушкой Мафтухой (актрисы Г.В. Ибрагимова, М.Г. Миннибаева), глубоко переживает вместе с матерью.

Гульбану с первых минут действия производит на зрителя приятное впечатление. Она одета по-деревенски, очень опрятно. Это стройная, красивая девушка, лицо которой излучает свет юности и затаенной внутренней радости. Гульбану садится на нары и поправляет подушки. Эта молодая девушка любит и любима. Чаша ее радости льется через край. Зрители чувствуют мелодичность и напевность речи Гульбану. В режиссерском плане ей сопутствует татарская народная песня, помогающая актрисе войти в роль, создать нужную сценическую атмосферу, а именно татарскую деревню начала XX века. И для понимания образа Гульбану такое начало имеет огромное значение.

Жизнь Гульбану в этой сцене – это песня безоблачной молодости, песня чистой любви. Но вот она узнает, что отец сосватал ее за богатого и не известного ей жениха. Бесконечное горе охватывает девушку. Она тихонько плачет на груди у матери. В это время на сцене гаснет свет, и лишь прожектор освещает упрямое лицо Нури (актер Г. Зиятдинов), его злобный взгляд и бороду. В этот момент решается судьба молодой татарской девушки, и уже здесь зритель ощущает трагическую предопределенность судьбы Гульбану. Злые высказывания Нури звучат как ответ на горестный разговор матери и дочери за домом. В этой сцене проявляются черты трагедийного характера главной героини. Помощи ждать неоткуда: мать бессильна перед черствым и жестоким отцом. Такое решение данной сцены выбрано очень удачно, так как оно способствует более полному раскрытию характеров персонажей.

Артист Г. Зиятдинов создал образ властного, жадного крестьянина, который под видом устройства судьбы своей дочери фактически продал ее. Он радостно рассуждает, что триста рублей – это целое состояние. Черствый, угрюмый, расчетливый крестьянин Нури – Зиятдинов вызывал у зрителей неприязнь, отталкивающее к себе чувство. Его жена Фатхия говорит о нем, что бог создал его с каменным сердцем. Актер Г. Зиятдинов правдиво воссоздал жадную психологию главы патриархальной семьи, в которой дочь – товар, невестка – раба. Эта недобрая традиция наложила глубокий отпечаток на образ Нури. В семье Нури – тиран, он никогда не советуется с женой, а принимает решения сам. Жена не смеет возражать мужу. В образе Нури с исключительной реалистической силой раскрыты социально-моральные устои татарской патриархальной крестьянской семьи, дикие домостроевские нравы, косность и грубость. Он беспощадно выгоняет из дома своего старшего сына Шайхула за то, что тот осмелился просить у него благословения на брак с дочерью сельского батрака.

Еще одна судьба татарской женщины в спектакле – судьба Фатхии, ее исполняли две актрисы: Ф.Х. Камалова и Г.Н. Нигматуллина. Как и любая мать, Фатхия горячо любит свою дочь и желает ей счастья, сочувственно относится к ее желаниям и стремлениям. Фатхия глубоко переживает за дочь, но она не может противостоять своему мужу и ограничивается тревожными

мыслями, не способная сделать ничего больше. Эта женщина – жертва патриархальных порядков, она превращена в рабыню мужа-деспота и давно смирилась со своим положением. В образе Фатхии ясно вырисовываются отсталость и забитость татарских женщин тех времен. Когда Гульбану узнает о том, что отец сосватал ее за Закира, она умоляет мать не выдавать ее за него. Фатхия отвечает, что ничего не может поделать, видимо судьба такая, против нее мы бессильны.

Несчастливое замужество было частым явлением в жизни татарской женщины в дореволюционную эпоху. Беспощадный обычай выдавать дочь замуж за совершенно незнакомого человека воспринимался как непреложный закон.

Для главной героини существует лишь один выход из этой ситуации – изменить жизнь самостоятельно. Г. Ибрагимов не сообщает открыто об этом в своей повести, а хочет, чтобы читатели догадались сами. К такому же заключению приходят и зрители спектакля. Таким образом, судьба персонажа становится социальным событием.

Во втором акте сочувствие к Гульбану еще более возрастает, трагизм ситуации усугубляет звон веселых бубенчиков свадебного кортежа. Режиссер П. Исанбет сумел насытить весь акт атмосферой напряжения, драматической динамикой. При этом изобразительные средства весьма скупы. Так, создавая обстановку пышной свадьбы Закира и Гульбану, режиссер совершенно не строит массовых сцен, использует традиционный занавес татарской избы, закрывающий одну половину другой. Невидимые зрителю гости с шумом врываются и проходят в гостиную. Просто и выразительно [3, с. 3].

В первом действии Гульбану – юная, светлая, глубоко верящая в счастливое будущее девушка. Во втором же акте перед зрителями предстает безрадостная молодая женщина, избавившаяся от иллюзий, которыми были ее мечты. То, о чем героиня мечтала – о создании счастливой семьи со своим возлюбленным, – вдруг разрушилось. Зрители осознают, что ее жизнь исковеркана. Каждая сцена давала возможность актрисам Г.Ф. Булатовой и Р.К. Хайрутдиновой выразить определенное состояние героини: в них раскрывался характер Гульбану, ее душевное состояние, ее страдания. Она осознает, что катится в бездну. Поведение Гульбану подчеркивают ее обреченность, безысходность, трагичность положения.

Рождение мертвых детей как результат побоев – очередной удар, очередное испытание для Гульбану. Она выдерживает удар одна и сильно меняется. В этой сцене Гульбану уже находится на краю пропасти, потеряв всякий интерес к жизни. Ее походка становится тяжелой, медленной, глаза теряют блеск, тускнеют. Однако героиня еще способна бороться дальше: она обращается за помощью к духовному представителю, но ее надежды не оправдываются.

В дальнейшем каждая сцена спектакля подготавливала трагический конец. Финальное действие происходит на берегу реки. Издалека видна деревня. В середине панорамы высокая мечеть. В глубине сцены крутой обрыв. Вдалеке виднеется лес, на середине дощатые мостки. Глубокая ночь, лишь проступает свет луны. Сквозь пелену полумрака возникает фигура Гульбану. На сцене глубокая тишина. Гульбану в черном рваном платье, платок сполз на плечи, волосы растрепаны.

Примечателен здесь длинный трагический монолог Гульбану, рассказывающей о душевном страдании героини. Молодая женщина представляет перед собой лес, луга своей родной деревни Кара-Юрга, говорит о том, как она по ним соскучилась, как хотела бы видеть их. Она с горечью рассказывает о том, что родилась под несчастливой звездой, ее жизнь безвременно угасла. В этом монологе заключается главный вопрос спектакля. Во время монолога Гульбану тихо слышится звук скрипки (татарская народная мелодия «Каляу Гайша»). Слова и движения молодой женщины совершаются в такт с музыкой. Гульбану бросается в реку, река на заднем плане сцены. Свет резко гаснет. Постепенно светает. Пробуждается жизнь. Издалека доносится хор. Несколько мужчин осторожно несут тело Гульбану на середину сцены. Последняя сцена сыграна очень волнующе, трепетно.

Монолог главной героини является важным элементом «диалектики души» Гульбану, благодаря которому инсценировщик воссоздал на сцене глубокий, психологически сложный образ героини Г. Ибрагимова. Х. Салимжанов не исключил из действия ни один из этапов жизни главной героини, стремясь последовательно, логически обоснованно показать судьбу дореволюционной татарской женщины. Цельность, решительность характера Гульбану выражается в том, что она отказалась покорно подчиниться распорядкам патриархального общества и предпочла мучительной жизни в рабстве смерть. Но ее шаг стал проявлением не слабости, а душевной силы и смелости, горячей ненависти к гнету и деспотизму.

Роль Гульбану исполняли две актрисы – Г.Ф. Булатова и Р.К. Хайрутдинова. Говоря о разнице исполнения роли этими двумя актрисами, критик Г.С. Кашшаф отмечал, что, «наблюдая за игрой Хайрутдиновой, мы видим перед собой молодую девушку, которую в дальнейшем ждут муки и страдания. Булатова же изображает женщину, которая уже довольно настрадалась. Она не схожа с Гульбану Ибрагимова» [2, с. 133]. Следовательно, актриса Р.К. Хайрутдинова создает образ, идеально совпадающий с общим представлением о героине Г. Ибрагимова. Это именно та татарская девушка Гульбану, которая сошла со страниц повести «Судьба татарки».

При постановке спектакля «Судьба татарки» (1960)[1] режиссер П.Н. Исанбет учел все нюансы дореволюционного быта. Перед театральным художником А.И. Тумашевым была поставлена следующая задача: в декорациях должна чувствоваться жизнь татарской деревни начала двадцатого века, с которой художник превосходно справился. Декорации были удивительными, реалистично показывалась прошлая жизнь татарской деревни. Глубокую идею режиссерского замысла ясно ощутил и композитор З.В. Хабибуллин. Его музыка насыщает звуковую палитру спектакля, олицетворяя трагическую судьбу дореволюционной татарской женщины.

В своем произведении Г. Ибрагимов обобщил крупный материал, характерный для дореволюционной действительности. Следует отметить, что в повести и спектакле «Судьба татарки» не только отчетливо изображена тяжелая участь татарских женщин в дореволюционную эпоху, но и поставлена в обширной исторической перспективе проблема женского освобождения, обоснована неизбежность исторического прогресса народа. Минувшее время рассматривается на новом идейно-эстетическом уровне. На примере

---

[1] Видеозапись из архива ТГАТ им. Г. Камала.

судьбы конкретной героини в повести и спектакле остро разоблачается патриархальное общество и религиозное мышление, убедительно звучит моральный приговор социальным и семейным отношениям прошлого.

В заключении можно сказать, что Х.Ю. Салимжанов создал инсценировку, в которой произведение Г. Ибрагимова не подверглось коренной трансформации, но при всем том спектакль звучал современно и животрепещуще. Спектакль «Судьба татарки», поставленный на сцене П. Исанбетом, стал серьезной победой театра и шел на сцене десять лет. Долгая жизнь его в театре говорит о верности выбранного пути не только в режиссерском решении, актерском исполнении, но и в сценической трансформации произведения «Судьба татарки». Можно смело сказать, что работа над сценизацией повести «Судьба татарки» Г. Ибрагимова явилась для театра значимым этапом его деятельности, когда режиссура, сценография, актеры, автор инсценировки оказались приобщенными к широкому кругу художественных задач, решение которых требовало смелости мысли и слаженной работы. Непрерывные аншлаги и положительные отзывы критики говорят о том, что зрители испытали подлинное эстетическое наслаждение от общения с героями повести Г. Ибрагимова.

ЛИТЕРАТУРА

1. Ибрагимов Г. Избранное / перевод с татарского Г. Шариповой; вступ. статья Г. Халита. Казань: Татар. кн. из-во, 1957. 416 с.
2. Кашшаф Г.С. Татар хатыныниләр күрми // Совет әдәбияты. 1960. № 5. Б. 128–133.
3. Кумысников Х.Л. Заметки о трех спектаклях // Советская Татария. 1960. 12 июля.

## МӘКТӘПТӘ Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ «АЛМАЧУАР» ӘСӘРЕН КЕШЕ ҺӘМ ТАБИГАТЬ БЕРЛЕГЕ ЯССЫЛЫГЫНДА ӨЙРӘНҮ

***Фәйзуллина З.М.***

В статье расскрывается особенности изучения в школе произведения Г. Ибрагимова «Алмачуар». Рассматриваются свойственные автору особенности описания природы и человека.

The article reveals the close features is the works of G. Ibragimov «Almachuar». The author discusses the characteristic features of the description of man and nature.

Бүгенге катлаулы, ыгы-зыгылы тормышта балаларга табигать белән бердәй булырга, аңа сакчыл карап, һәркайда һәм һәркайчан табигый бәйлыкларны сакларга, шул байлыкка кадерле мирас итеп карау хисләрен тәрбияләү әһәмиятле. Кешеләрне, туган төбәкне, туган җиреңне якын күрү, ярату – бөек һәм мәртәбәле хисләр. Якыннарыңа, туганнарыңа, дусларыңа, туган җиреңә һәрвакыт тугрылыклы булу кебек хисләрне балалар аңына борын-борынгыдан ук сеңдерергә тырышканнар. Шул хисләргә ялганып игелеклелек, кешелеклелек, гуманлылык кебек сыйфатлар үзеннән-үзе ялганып килә. Кешеләрдә, балаларда шул сыйфатларны тәрбияләү – әдәбиятның иң зур бурычын тәшкил итә. Әдәби әсәрләрнең әһәмияте дә шунда. Шуннан соң үзеннән-үзе әлеге хисләрне укучыга җиткерү, аңлату бурычы алга килеп баса. Пейзаж, табигать сурәтләнеше шул максатка хезмәт итә. Даһи әдипләребез иҗаты әлеге катлаулы мәсьәләне чишәргә булыша. Г. Ибраһимов

гасырдан артык еллар дәвамында ничәмә-ничә буынны тәрбияләп килгән «Алмачуар» әсәре белән генә дә таныла алган булыр иде.

Туган як, туган җирне яратуны мәңгелек темалар рәтенә кертеп карый галимнәр. Кайсы гына әдипне алма, аның иҗатында әлеге темага мөрәҗәгать иткән әсәрләрне табарга була. Кешелекнең аерылгысыз булган, гомер дәвамында бергә яшәп, шул бергәлек булган очракта гына кешелеклелек үз асылында булыр.

Г. Ибраһимовның һәр әсәрендә дә табигать һәм кеше бердәмлегенә тап булабыз. Әйтик, «Алмачуар» хикәясен мәктәптә өйрәнгәндә укучыларның игътибарын шуңа юнәлтү әһәмиятле. Төп каһарманның уй-фикерләре, борчу-шатлыклары табигать күренешләре бердәйлегендә бирелә. Туган авылының матур табигатен, авылдашларын, якыннарын, табигатьнең бер кисәге булган колынны – Алмачуарны якын итә, ярата Закир. Яшүсмер малай образы аша автор идеалы гәүдәләнеш ала. Ягъни укучы балаларга тәрбия бирү максатыннан, идеал яшүсмер образы тудырыла.

Шуның белән берлектә укучыларга пейзаж турында мәгълүмат бирү, аны тудыру осталыгы хакында сүз алып бару җиңелләшә. Г. Ибраһимовның һәр әсәрендә пейзажның матур үрнәкләрен табарга була. Әдипнең «Алмачуар» хикәясендә төп каһарман – Закирга бәйле рәвештә геройның туган ягы, туган авылы табигате искиткеч табигый, матур, чынбарлыктагыча тасвирланган. «Яратам мин үзебезнең авылны, бигрәк тә яратам авылның төньягын каплаган зур тауларны! Аңардан да бигрәк яратам шул таулар өстендә мең еллар буенча шаулап утырган зур карт урманны!» [1, б. 218–242].

Әдип «Алмачуар» хикәясе тукымасына табигать күренешләрен кертеп, әсәрнең композицион бөтенлеген, образларның тулылыгын, кешеләрнең психологияләрен төгәл ачу өчен җирлек булдыра.

Хикәядә төп геройның – Закирның күңел матурлыгы белән янәшә табигать гүзәллеге дә параллель бирелә. Автор таулар, болыннар матурлыгын, елгаларның мәгърурлыгын вакыйгалар агышында бик урынлы гына әсәргә кертеп җибәрә: «Беләм, бик беләм: таулар, болыннар буйлап килеп, безнең авылның буеннан аккан бу елга Өршәккә, Өршәк Димгә, Дим Агыйделгә коя. Агыйдел кая барадыр – анысын бер Алла белә» [1, б. 242].

Табигать матурлыгы, серлелеге, аның кодрәте һәрвакыт кешелек, халкыбызның милли бәйрәмнәре, кешеләрнең яшәү, тормыш алып бару рәвеше белән тыгыз бәйләнештә бирелә: «Безнең авылның кояш батыш ягында зур киң бер сырт бар. Сабан туен һәрвакыт шунда ясыйлар». Яки икенче бер мисал: «Без авылдан чыкканда, көн матур, җил юк иде. Болында безне кошлар сайрап каршы алдылар» [1, б. 218–242]. Геройларның хис-кичерешләрен, күңел ярсуларының тирәнлеген, ихласлыгын психологик планда бирү өчен дә табигать күренешләре ярдәм иткән бирелә.

Табигатьнең сихри, әкияти булуы матур итеп, балалар күзлегеннән карагандыгы сыман әкияти итеп тасвирлана: «Тик бик күп дөнья гизгән Сафа бабай гына кайвакыт сөйләп куя: көз көне кошлар китә торган якта, ди, Әчтерхан дигән бер зур шәһәр – борынгы ханнар шәһәре бар, ди, шуның аръягында, ди, гаҗәп зур бер диңгез бар, ди. Агыйдел, ди, бик күп авыллар, шәһәрләр, таулар, кара урманнар эченнән агып, айлар, еллар буенча бара-бара да, ди, әнә шул олуг диңгезгә барып коя... ди, сез моннан бер йомычка салып җибәрсәгез, ди, ул, ди, Өршәкләр, Димнәр, Агыйделләр буйлап агар-агар да әнә шул ерак диңгезгә барып төшәр, ди... Их, күрәсе иде ул

диңгезләрне!» [1, б. 218–242]. Игътибар итсәк, шунда ук малайның өлкәннәргә ихтирам, ышаныч белән каравы да сизелә. Шул рәвешле туган илнең табигатенең серлелеге, сихрилеге чиксезлеге авылдашларның, өлкәннәрнең сурәтләвендәгечә, үсмер күзаллавындагыча аңлашыла. Солтанмораттан һәм күрше авыллардан еракка китеп карамаган малай күңелендә бөтен илебез, үзе күзаллаган табигать бөтенлегенә мәхәббәт яши.

Г. Ибраһимов «Алмачуар» хикәясендә кеше һәм табигать образларын бербөтен итеп бирә. Колын – Алмачуар образы – туган җир, туган авыл, туган нигезнең җыелма образы, кеше күңелендә яшерелгән иң изге хисләрнең чагылышлары җыелмасы, бер бөтен буларак күз алдына килеп баса. «Тирә-якта асыллыгы, сылулыгы белән генә түгел, тавышы, җиңел, җитез, килешле һам акыллы уйнавы белән минем Алмачуарга тиңдәш булырлык бер колын күренми дә, ишетелми дә.» [1, б. 218–242]. Шул рәвешле авторның төп идеясе ачып салына. Кеше өчен туган җире, туган нигезе, үзенең туган авылы – бар җирдән кадерле, үз. Аңа тиңдәш булырлык бүтән җир беркайда «күренми дә, ишетелми дә».

Автор, үзе дә авыл баласы буларак, табигать күренешләренә битараф кала алмаган, бу аның «Алмачуар» хикәясендә яхшы күренә. Г. Ибраһимовның биографиясенә мөрәҗәгать итсәк, әлеге хикәясендә үзенең тормыш юлы чагылышын да күрәбез. Автор Башкортстан Республикасында туган [2, б. 572]. Әсәрдә дә башкортстан якларының матур табигате тасвир ителә. Закир образында да бәлки авторның үз тормышы, хис-кичерешләре, чагылыш тапкандыр дияр өчен җирлек бар.

Гомумән, Г. Ибраһимовның һәрбер әсәре пейзаж байлыгы, табигать матурлыгын тасвирлау осталыгы белән һәр укучы күңеленә үтеп керә торган югарылыкта иҗат ителгән. Әсәр һәм өлкән, һәм кече яшьтәге укучылар өчен әһәмиятле: кешенең күңел төпкелендә яткан матурлык, ярату хисләрен уятып, сискәндереп җибәреп, балаларда исә шул хисләрне тәрбияләүгә хезмәт итә. Нәтиҗә ясап, шуны әйтә алабыз, Г. Ибраһимовның «Алмачуар» әсәре укучыларда кешелеклелек, миһербанлылык, гуманлылык, игелеклелек кебек яхшы сыйфатлар тәрбияләү белән бергә, аларда табигатькә якынлык, мәхәббәт, туган җирне кадерләү кебек хисләрне дә булдыруга нигез булып тора. Шуның белән бергә, татар әдәбиятының олпат классигы – Г. Ибраһимовның әсәрләре кыйммәте еллар үткән саен арта гына бара.

ӘДӘБИЯТ

1. Ибраһимов Г. Сайланма әсәрләр. Казан: ТаРИХ, 2002. Б. 218–242.

2. Әдипләребез: библиографик белешмәлек: 2 томда / төз. Р.Н. Даутов, Р.Ф. Рахмани. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 1 т. 751 б.

## Г. ИБРАҺИМОВ ПУБЛИЦИСТИКАСЫНДА «ГАЛИЯ» МӘДРӘСӘСЕ ТЕМАСЫ ЯКТЫРТЫЛЫШЫ

***Фәйзуллина Ф.Г.***

В статье рассматривается публицистика Г. Ибрагимова, отражающая тему медресе «Галия», где он учился и работал. Показано влияние медресе «Галия» на формирование свободомыслящего публициста, страстного защитника новых идей.

The article discusses the publicism of G. Ibragimova, reflecting the theme of the madrasah «Galiya», where he studied and worked. The influence of madrasah «Galiya» in the formation of a passionate publicist.

Татар мәдәниятенең кайсы гына тармагын алып карасаң да, Галимҗан Ибраһимовның исеме яңгырамаган өлкәне табуы авыр. Аның исеме татар мәдәнияте тарихында әһәмиятле урын били. Ул зур әдәби һәм гыйльми мирас калдырган әдип һәм галим генә түгел, киң эрудицияле эшлекле дә. Заманының көндәлек вакыйгаларына матбугат битләрендә үзенең карашын, мөнәсәбәтен белдереп барып, Г. Ибраһимов ялкынлы публицист буларак та таныла. Һәм татар совет матбугатын оештыручыларның берсенә әверелә.

Г. Ибраһимов 1906–1909 елларда белем алган Уфадагы «Галия» мәдрәсәсе аның рухи-фикри офыгы киңәюгә уңай йогынты ясый. Шушы чорда Г. Ибраһимов, «Әлислах» газетасының фактик мөхәррире Фатих Әмирхан чакыруы буенча, газетаның Уфадагы үзхәбәрчесе булып китә. 1907 елда «Әлислах» газетасында ул Оренбургтагы Вәли мулла мәдрәсәсендә үз башыннан кичкән вакыйгаларга нигезләнеп язылган үзенең беренче әдәби әсәре – «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» повестен бастыра. Нәкъ шушы чорда шул ук газетада аның беренче публицистик мәкаләләре дә күренә башлый. Бу вакытта татар мәдрәсәләренең заман таләпләренә җавап бирерлек дәрәҗәдә булмавы эзләнүчән табигатьле яшь Ибраһимовның тәнкыйть утына эләгә. Яшь публицист газета укучыларны мәдрәсә хәбәрләре белән даими таныштырып килә. Шул рәвешле ул мәдрәсәләрдәге иске тәртипләргә каршы көрәшкә күтәрелә. Г. Ибраһимовны беренче чиратта, әлбәттә, «Галия» мәдрәсәсенең язмышы борчый.

«Әлислах» газетасының 1907 елгы 17 декабрь санында аның «Әлислах» мөхбире» имзасы белән беренче тапкыр «Галия» мәдрәсәсе турында сөйләнгән «Уфа мәдрәсәләре» исемле мәкаләсе дөнья күрә. Г. Ибраһимов Уфа шәһәрендә барысы өч мәдрәсә барлыгын искәртеп, аларга аерым-аерым тукталып китә. «Госмания», «Хәсәния» мәдрәсәләре белән таныштырганнан соң, «боларның кайсысына гына керсәң дә, дәресләрнең начарлыгыннан, мөгаллимнәрнең укыта белмәвеннән, низам-тәртип юклыгыннан кайгырып чыгарлыктыр» [1] дигән нәтиҗәгә килә. Өченче мәдрәсә – «Галия» хакында Г. Ибраһимовның фикере нигездә шул ук булса да, әлеге мәдрәсә белән якыннан таныш булганлыктанмы, ул андагы тәртипләрнең киләчәктә үзгәрәчәгенә өметләр баглый. «Мәдрәсәи «Галия»нең дә бәхак гали *(бик югары)* улып-улмадыгыны читтән торып та белергә мөмкин. Бу да әллә кайда бара алмый инде. Шулай булса да, Уфа байлары, «Галия» мөгаллимнәре җиддиятьлә *(җитдилек, тырышучанлык белән)* хәрәкәт итсәләр, истикъбале *(киләчәге)* өмидледер...» [1], – дип яза.

Г. Ибраһимов әлеге мәкаләдә, «Галия» мәдрәсәсендә уку-укыту тәртипләрен аңлатуга күчкәнче, татар милләтенең әле ул заманда һәръяклап камил бер мәдрәсә төзерлек дәрәҗәгә җитмәвен ассызыклап үтә. «Галия» мәдрәсәсендә «диния вә гарәбият» башка татар мәдрәсәләреннән алда булса да, газета игъланнарында, мәдрәсә программаларында күрсәтелгән, шәкертләр укырга өметләнеп килгән фәннәрнең бөтенләй укытылмавына борчыла. Булачак педагог шул заманда матбугат битләрендә «мәктәп, мәдрәсә һәм шәкертләр әхвалене ислях»ны яктырткан мәкаләләр белән даими танышып бара. Ул аларда күтәрелгән «татар мәдрәсәләреннән эш чыгу ихтималы юк. Хөкүмәт мәктәпләренә керергә кирәк» дигән фикерне яклый.

Аларга кушылып, «Рус мәктәбенә керү» – хәзерге татар шәкерте моны гәзитә мөхәррирләреннән башка да белә» [5], – ди. Шунысы игътибарга лаек, Г. Ибраһимов әлеге фикернең дөреслегенә ышанса да, шәкертләрне сукырларча турыдан-туры рус мәктәпләренә керергә өндәми. Моның мөмкин түгеллеген яхшы аңлый. «Ничек итеп матди вә мәгънәви җәһәттән хәзерләп, яшьләрне русча укытырга? Русчага керәсе килгән яшьләрне ничек теләкләренә ирештерергә? Аларга кайдан акча табарга? Ничек хәзерләргә?» кебек сорауларга җавап эзләп, ул матбугаттан ярдәм сорый. Шул ук вакытта, ислях мәсьәләсенә килгәндә, татар тормышында диннең ни дәрәҗәдә көчле хөкем сөрүен, иң бөек рольне уйнаганын истән чыгармаска чакыра. «Татарның күңелендә дин, ахирәтдән башка нәрсә юк. Татар дөнья тереклегенә, дөньяда мәсгудияткә *(рәхәтлеккә)* гөнаһ вә нәфрәт күзе белән карый. Хәят, мәгыйшәт *(тормыш)*, истикъбал, сәгадәт кеби нәрсәләр татар кашында чүп дә түгел. Татар боларны кирәксенми. Болар өчен кайгырмый, тырышмый. Аларны бер кирәкле нәрсә, дип тә белми» [5], – ди. Шунлыктан халыкны үзе ышанган нәрсәсе – дин исеменнән яңалыкка чакыру кирәклеген алга сөрә. «Татарларны иске мәгыйшәттән биздереп, яңага чыгаруда иң җиңел юл – «шул динемез яңа тормышка каршы түгел, бәлки аңарга чакыра» фикерене кабул иттермәк һәм дин галимнәрене шул яңа рухта тәрбия итмәк»нең нәтиҗәсе булуда аның шиге юк. Г. Ибраһимов динне кире какмый, ә аны яңача аңлау тиешлекне ассызыклый. Татарны искелектән чыгару өчен, халыкны «дин яңалыкка куша, дип ышандыру кирәк» [5], ди.

Г. Ибраһимов «Галия» мәдрәсәсе белән бәйле хәлләрне матбугатта яктыртып бара. «Уфа, мәдрәсәи «Галия»дә тентү» мәкаләсендә 1909 елның 15 гыйнварында мәдрәсәдә булган вакыйга сурәтләнгән. Биредә Г. Ибраһимов хөкүмәтнең шикләнүе нәтиҗәсендә полициянең мәдрәсәгә килүенә сәбәп эзли. Ул мәдрәсә турындагы фикерләрдән хәбәрдар. Чөнки «Галия» төзелгәннән бирле һәр тарафыннан һөҗүмгә очрап тора: искеләр аны, дин бетерә, дип сүгәләр. Кайбер хәзрәтләр үзенең шәкертләре «Галия»гә китеп, мәдрәсәләре буш калганга аны дошман күрәләр. Тройски ишанының «Галия» шәкертләре динсез. Аларны меллалыкка ала күрмәңез!» дигән хат таратулары турында, Бөре өязенең бер ахуны, кырык мелладан имза алып, «Галия» исламияткә зарарлы. Аны яптыр!» дип, мөфтигә гариза биргәнлеге турындагы хәбәрләр белән беррәттән, «Аларда ливальвир *(револьвер)*, бомба бар, имеш», дигәннәре дә күпвакыт ишетелеп тора. Г. Ибраһимов: «Хөкүмәттә бу мәдрәсәнең шәкертенең андагы тәрбиянең нидән гыйбарәт икәнене аңламый, никадәрле мактасалар да, һаман да «надан татарныкы» икәнлегене белми, анда әллә ни бардыр, әллә нинди тәрбия бирәләрдер, дип уйлый. Аның шәкертләре һаман шул черегән татар шәкерте икәнене төшенми, урынсызга шикләнәдер» [2] – дип, хөкүмәтнең бу адымына гаҗәпләнә. Мәкаләнең эчтәлегенә караганда, «Галия»дә дүрт сәгать ярым дәвам иткән шактый җитди тентү оештырыла. Мөгаллимнәрне канцеляриягә җыеп, аларны саклау өчен ике штыклы солдат куела. Шәкертләрне класс бүлмәсеннән азлап-азлап кына ятак бүлмәләренә чакырып, күлмәк-ыштаннан башка һәммә киемне дә салдырып, читекләренә, чолгауларынача тентиләр. Шәкертләрдән тыш, дәрес тыңларга дип, авылдан килгән меллалар да биредә токтынга эләгә. Мәдрәсәдә кунучыларны тентеп беткәч, укучыларның адреслары буенча йөреп чыгалар. Тентү барышында шактый гына нәрсәләр алына. Нәтиҗәдә, мәдрәсәгә кара ягарлык нәрсәләр табылмый. Тентү тыныч

кына узса да, үзе дә «Галия»шәкерте буларак, Г. Ибраһимов әлеге вакыйганың ахыры нәрсә белән бетәчәгенә борчыла.

1915–1917 еллар аралыгында Г. Ибраһимов Уфадагы үзе укыган «Галия» мәдрәсәсендә укытучы булып эшли. Бу чорда әдипнең иҗтимагый карашлары тагы да ачыклана төшә. Г. Ибраһимов «Галия» мәдрәсәсе тирәсендә барган вакыйгаларга битараф кала алмый. Ә мондый вакыйгаларның иң тетрәндергәне – һәйәте хариҗиянең *(тышкы эшләр комиссиясе)* «Тормыш» журналында (1915, 31 нче сан) игълан иткән «бүгеннән башлап Галия»гә асла *(һич)* акча бирмәскә» дигән карары. Әлеге вакыйгага мөнәсәбәт белдерүчеләрдән беренче Муса Бигиев була. Бу карарга каршы чыгып, ул: «Русия мөселманнарының иң караңгы почмакларына кадәр ун сәнә тоташ яктыртып килгән бер мәдрәсәне инде һәр җәһәтлә тәэмин итү, косурлары *(кимчелекләре)* вар исә, тәкмил итү *(җитештерү, бетерү)* тиеш бер вакытта... акча бирмәскә карарыны игълан итү, әлбәттә, тиеш түгел иде» [3], – дип, үзенең канәгатьсезлеген белдерә. Г. Ибраһимов, М. Бигиев фикерен куәтләп, үз тарафыннан Зыя Камалине яклап, «Мәдрәсәи «Галия» вакыйгасы хакында берничә сүз» исемле язмасын бастыра. Ул «Галия» мәдрәсәсендә узган шәкертлек елларына, инде мөгаллим күзлегеннән чыгып, анализ ясый.

Г. Ибраһимов мәдрәсәдә укуын: «Яшь күңел күпне эсти, башка мәдрәсәләр күңелнең ул теләкләрен бирмәгән. Әүвәлге остазыңнан бәддогалар алып, ата-анаңның ризалыгыннан аерылып, зур өмидләр илә бу яңа мәдрәсәнең дә берәр ел укыганнан соң никадәрле нәрсә бирә алуы ачык беленгәч, без идарәгә һәм Зыя әл-Камалинең үзенә каршы шундый бер хәрәкәт башладык ки, мин анда идарәнең кайбер әгъзалары кашында «Мәдрәсәи Галия»не юк итәргә, шәкертләрне бер мәдрәсәдән таралырга димләүчеләрнең берсе булып танылдым. Ничә мәртәбә мәдрәсәдән куыла башладым. Ахыргы елымда эш шуңа җитте ки, яңадан барсам, мине һәм минем берничә иптәшемне мәдрәсәгә кабул кылмаячаклары ачык сурәттә мәгълүм иде» [4], – дип искә ала. Г. Ибраһимов биредә укуының соңгы ике елы баштан аяк мәдрәсәнең эчке һәм тышкы идарәләре, бигрәк тә Зыя Камали белән көрәштә үтүен яшерми. Һәм шул ук вакытта: «Мин төрле мәдрәсәдә, төрле мөдәррисләрнең дәресендә булдым. Ләкин Зыя әл-Камали кадәрле шәкертнең гакылына хөррият биргән бер мөдәррискә очрамадым. Аның кадәрле шәкертнең фикердә истикъляльн *(бәйсезлеген)* уйгатырга тырышучы бер остаз күрмәдем» [4], – ди. Күңелендә сакланып калган шәкертлек елларындагы хатирәләре нигезендә Г. Ибраһимов Зыя Камалинең мөгаллимлек хезмәтен тәкъдир итә. «Татардан ни нәрсә чыксын!» дип, үз халкына кул селкеп йөргән Уфа мирзаларын җыеп, аларга исламияттән, исламның мәдәният һәм гыйлемгә мөнәсәбәтеннән дәресләр бирергә көч тапкан Зыя Камалинең тырышлыгын югары бәяли. Татар дөньясында фикерле һәм зыялы йөзләрчә имам, мөгаллимнәр чыгарып торган «Галия» мәдрәсәсенең тууы һәм кыска гына вакыт эчендә алдынгы уку йорты булып танылуы бары Зыя Камали аркасында гына икәнлекне укучыларга җиткерергә тели. Ул мәдрәсәне салуда матди ярдәм күрсәткән Уфа байларын да кире какмый, әмма төп идея башлангычының Зыя Камалидә булуын онытмаска чакыра.

Г. Ибраһимов үзендә тәрбияләнгән иске фанатизм туңлыкларыннан котылуда Шиһаб хәзрәттән кала, икенче йогынты ясаган кешенең дә Зыя Камали булуын исеннән чыгармый. Бу ике затка үзен мәңге бурычлы дип саный.

Зыя Камали, гомумән алганда «Галия» мәдрәсәсе, Г. Ибраһимовның фикеренә бәйсезлек бирү юлында зур роль уйныйлар. Чөнки, мөгаллим Зыя Камалинең төп максаты шәкертләрне фикерләрен курыкмыйча әйтә белергә өйрәтү була. «Галия» мәдрәсәсендә укыганда ныклап беркетелгән әлеге сыйфат Г. Ибраһимовның ялкынлы публицист булып формалашуына төп этәргеч булгандыр дисәк, ялгыш булмас.


ӘДӘБИЯТ

1. «Әлислах» мөхбире. Уфа мәдрәсәләре // Әлислах. 1907. 17 декабрь.
2. Гыйрфанзадә. Уфа, мәдрәсәи «Галия»дә тентү // Әлислах. 1909. 26 февраль.
3. Җарулла Муса. Соң көннәрдә начар хәлләр // Вакыт. 1915. 16 октябрь.
4. Ибраһимов Галимҗан. Мәдрәсәи «Галия» вакыйгасы хакында берничә сүз (Муса әфәнденең «Вакыт»та басылган мәкаләсен укыгач язылды) // Аң. 1915. № 20. Б. 354–359.
5. Ибраһимов Галимҗан. Шәкертләр һәм уку // Әлислах. 1908. 8, 15, 23 сентябрь.


## ТАТАР ТЕЛЕН УКЫТУНЫҢ ЯҢА ЮЛЛАРЫН ЭЗЛӘҮ


***Фәтхуллова К.С.***



В статье рассматриваются вопросы повышения качества и результативности обучения татарскому языку в общеобразовательных школах на основе системно-деятельностного подхода.

Theи article deal swith improving the quality and effectiveness of the Tatar language teaching in secondary schools on the basis of system-activity approach.


Тел үзендә кешелек тарихын саклый. Шуңа күрә дә һәр халык туган телен саклап калу, үстерү, укыту, дөньяда таныту һәм тарату турында кайгырта. Иң мөһиме – туган телне буыннан-буынга тапшыру, яшь буынга ана телендә сыйфатлы белем бирү. Галимҗан Ибраһимов сүзләре белән әйтсәк, «телнең эчендә халыкның рухы, моңы, уй һәм тойгысы яшерелгән. Бу – бер хәзинә. Ана телен яхшы белү кешегә әдәбиятның ишеген ача, гомергә аның рухын сугарачак чишмәгә юл күрсәтә». Татар җәмәгатьчелеге арасында Галимҗан Ибраһимов – галим методист, дидакт буларак та танылу алган мәшһүр шәхесләребезнең берсе. Шул чорда ук ул укучыларда мөстәкыйль фикерләү, танып белү активлыгын үстерүне төп бурычлардан санаган һәм үз фикерләрен методик хезмәтләрендә яклап чыккан, бу сыйфатларны үстерү алымнарын өйрәнгән, телдән һәм язма сөйләмне үстерүнең әһәмиятлелеген ассызыклаган [1]. Галимнең әлеге фикерләре бүгенге көндә дә үзенең гыйльми һәм гамәли актуальлеген, методик кыйммәтен югалтмый. Хәзерге вакытта татар телен укыту методикасы нәкъ шушы проблемаларны хәл итүгә төп игътибарны юнәлтә.

Татар телен укытуда төп юнәлеш итеп системалы-эшчәнлекле юнәлеш билгеләнгән. Аның гомуми эчтәлеге түбәндәгеләрдән гыйбарәт: 1) танып белүнең актив формаларыннан файдалану (модельләштерү, чагыштыру, системалаштыру, гомумиләштерү, анализлау, күзәтү ясау); 2) рефлексия (гомуми яки индивидуаль) өчен шартлар булдыру (куелган максаттан чыгып, эшчәнлекнең нәтиҗәләренә үзбәя бирә белү) [2, б. 48]. Эшчәнлекле дәрес – нәтиҗәгә ирешүгә юнәлтелгән эшләр системасы ул. Дәреснең төп эчтәлеге укучыларда универсаль уку гамәлләре системасын формалаштырудан гыйбарәт. УУГ – танып белү күнекмәләре һәм уку мотивациясе булдыруга

хезмәт итә торган гомуми гамәлләр. Алар укучыларга уку эшчәнлеген оештыруны һәм төп компетенцияләргә ия булуны тәэмин итәргә тиеш. Татар теленнән белем бирүнең төп нәтиҗәләре метапредмет (танып белү; коммуникатив; регулятив УУГ); шәхескә бәйле; предмет нәтиҗәләрен үз эченә ала. Системалы-эшчәнлекле юнәлеш укытучыдан түбәндәге осталыкларга ия булуны таләп итә:

– «укытучы-укучы» системасы белән идарә итү технологияләрен белү (максат-бурычларны билгеләү, белем бирү процессын оештыру һәм нәтиҗәләрне бәяләү);

– яңа педагогик технологияләрдән файдалана белү (проектлар технологиясе, мультимедиа технологиясе, уен технологиясе);

– укучыларга мөстәкыйль белем алу өчен шартлар булдыру (укытучы – ярдәмче, тьютор, юл күрсәтүче), укучылар белән хезмәттәшлек итү;

– импровизациягә сәләтле булу (дәрес барышында аңа үзгәрешләр кертү).

Заманча дәресне планлаштырганда, татар теле укытучысы түбәндәгеләргә таянып эш итә: педагогик процессның төп объекты итеп укучыны билгеләү; белем бирү эчтәлеген, эш төрләре һәм алымнарны үзгәртү; дәрестә өйрәнелә торган материалның эчтәлеген шәхескә юнәлтү; укучы эшчәнлегенең эчке мотивларын булдыру; иҗади характердагы биремнәргә өстенлек бирү; дәрестә укытучы шәхесенең укучыларга тәрбияви тәэсир итүен истә тотып эшләү; дәреснең һәр этабында кире бәйләнеш булдыру; уку эшчәнлегенең нәтиҗәләрен бәяләү.

Татарстан Республикасында гомуми белем бирү системасының төп бурычы – иҗади фикерләүче, инициативалы, иҗтимагый тормышта актив катнашучы, белемле, ике дәүләт һәм чит телләрдә дә иркен сөйләшеп аралашучы полилингваль шәхес тәрбияләү. Шушы бурычны уңышлы хәл итү өчен, укучыларда аралашу осталыгы (коммуникатив компетенция) булдыру таләп ителә. Лингвометодикада аның берничә төрен аерып күрсәтәләр: сөйләм компетенциясе; тел компетенциясе; этномәдәни компетенция; компенсатор компетенция. Татар теле дәресләрендә укучылар әлеге осталыкларга ия булсыннар һәм телне шәхесара һәм мәдәниятара аралашу чарасы буларак үзләштерсеннәр өчен, аерым бер биремнәрдән файдалану мөһим. Осталыкның һәр төренә аңлатма биреп һәм аңа бәйле эш төрләрен карап үтик. Сөйләм компетенциясе – коммуникатив максатка ирешү өчен, телдән (диалогик һәм монологик) һәм язма сөйләм оештыра алу осталыгы ул. Сөйләмнең беренче формасы – диалогик сөйләмгә өйрәтүне укытучы, яңа таләпләрдән чыгып, методик яктан дөрес оештыра белергә тиеш. Сыйныфтан сыйныфка укучыларда әлеге күнекмәләрне булдыру эшен системалы рәвештә алып бару сорала: бирелгән ситуация буенча әңгәмә кору; сөйләшүне башлап һәм кирәк очракта җанландырып җибәрү; үзеңне кызыксындырган сорауларны бирү һәм аларга җавап алу. Укытучы, укучыларның диалогик сөйләмен бәяләгәндә, билгеле бер критерийларга таянып эш итә: аралашу максатына ирешүе; репликаларның лексик-грамматик яктан дөрес булуы; этикет үрнәкләрен урынлы куллануы; актив һәм итагатьле әңгәмәдәш булуы. Монологик сөйләмгә өйрәтү түбәндәгеләрне үз эченә ала: ситуатив бирем белән танышу; биремдә күрсәтелгән сорауларны яктыртып сөйләү; темага бәйле өстәмә сорауларга киңәйтелгән җаваплар бирү. Укучыларның монологик сөйләмен бәяләү критерийлары: коммуникатив максатка ирешүе; теманы тулысынча ачып бирүе; бәйләнешле сөйләмне лексик-грамматик яктан дөрес оештыруы.

Укучыларда телдән һәм язма сөйләм осталыгы булдыру өчен, дәреслекләрдә түбәндәге күнегүләр тәкъдим ителә: *Җөмләләрне укыгыз һәм сораулар куегыз; Диалогны тулыландырыгыз; Ситуациягә бәйле репликаны әйтегез; Телләр өйрәнү турында сөйләгез. Сөйләмегездә түбәндәге мәгълүматлар да булсын: мәктәптә телләр өйрәнү; татар теле дәресләре; телләр белүнең файдасы; Дустыгызның сорауларына җавап биреп, аңа хат языгыз* һ.б. Иҗади эшләүче укытучы, шундый биремнәрне тагын да төрләндереп, укучыларның яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләрен исәпкә алып эш итә. Моның өчен ул өстәмә чыганаклардан, уку әсбапларыннан файдалана ала.

Тел компетенциясе – аралашу барышында тел берәмлекләрен дөрес куллана белү осталыгы ул, ягъни икенче телдә лингвистик кодка ия булу. Укучылар әлеге осталыкка ия булсыннар өчен, махсус биремнәрне куллану зарур: *Кирәкле сүзләрне куеп, текстны укыгыз; Сүзләрне кирәкле формада куеп, текстны языгыз; Сүзләрдән җөмләләр төзеп әйтегез; Текстны укыгыз һәм туры килгән сүзне билгеләгез; Беренче җөмләнең эчтәлегенә туры китереп, икенче җөмләне язып бетерегез һ.б.* Мисаллардан күренгәнчә, мондый төр күнегүләр укучыларның лексик-грамматик күнекмәләрен үстерүгә юнәлтелгән.

Этномәдәни компетенция – икенче телдә сөйләшүче халыкның милли-мәдәни үзенчәлекләрен, сөйләм этикетын исәпкә алып, аралашу оештыра алу осталыгы ул. Татар теле дәресләрендә укытучы, белем бирү белән генә чикләнмичә, укучыларга әхлакый тәрбия бирә, аларны төркемдә аралашу барышында итагатьле әңгәмәдәш булырга өйрәтә. Моның өчен шундый күнегүләрдән файдаланырга мөмкин: *Итагатьле сүзләрне (сөйләм гыйбарәләрен) кулланып, әңгәмә корыгыз; Милли бәйрәмнәр турында сөйләшү үткәрегез; «Шәһәребезнең бер һәйкәле» темасына презентация әзерләгез; Кыска диалогларны тыңлагыз. Вакыйгаларның кайда баруын билгеләгез; Ике дусның сөйләшүен тыңлагыз. Туры килгән җавапны билгеләгез* һ.б. Алар ярдәмендә укучылар татар халкының күренекле шәхесләре, татар мәдәнияте, сәнгате турында мәгълүмат алалар.

Компенсатор компетенция – икенче телдә аралашу барышында тел «кытлыгын» җиңеп чыгу осталыгы ул. Татар телен өйрәнгәндә, мондый күнекмәләргә ия булу шактый әһәмиятле, шуңа күрә укытучы дәресләрдә әлеге күнегүләрне актив кулланырга тиеш дип саныйбыз: *Контексттан чыгып, сүзләрнең мәгънәсенә төшенегез; Сүзнең мәгънәсен тамырыннан һәм кушымчаларыннан чыгып билгеләгез; Җөмләне кыскартып, фикерегезне белдерегез; Сөйләшү барышында әңгәмәдәшегездән ярдәм сорагыз; Бер үк фикерне төрле тел бәремлекләре белән белдерегез* һ.б.

Санап чыккан – эш төрләре укучыларның бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү һәм лексик-грамматик белемнәрен тирәнәйтүгә, көндәлек тормыш, уку һәм кызыксынулар турында хәбәр итәргә һәм фикер алышырга өйрәтүгә хезмәт итә. Алар ярдәмендә укучы үз эшчәнлеген нәтиҗәле оештырырга өйрәнә: аралашуда катнаша ала (төркемдә, парлап, индивидуаль эшли ала); мисаллар китерә һәм дәлилли; күзәтүләр ясый һәм гомумиләштерә; үзләштергән мәгълүматны сөйләмдә куллана; мәгълүматны чагыштыра һәм анализлый; үзтикшерү белән шөгыльләнә; дөрес җавапны сайлый, хаталарын төзәтә; нәтиҗәләр ясый һәм үзбәя бирә.

Бүгенге көн татар теле укытучысының дәрестәге эшчәнлеген түбәндәгеләргә кайтып кала: уңай психологик халәт булдырып, аралашу оештыра; уку проблемасын укучылардан әйттерә; проблеманы хәл итәргә ярдәм итә; эзләнү, мәгълүматны эшкәртү һәм гомумиләштерү эшчәнлеген оештыра; биремнәрне формалаштыра; актив эш төрләрен тәкъдим итә; укучыларны актив эшләргә этәрә; җавапларга ачыклык кертә; комментарийлар бирә; коммуникатив күнекмәләрне ныгыта; укучыларның эшчәнлеген хуплый һәм уңай бәяли.

Гомумиләштереп әйткәндә, бүгенге көндә татар телен яңача укыту системасы эшчәнлекле дәрескә билгеле бер таләпләр куя: максатча оештыру; дәрес этаплары арасында бәйләнеш булдыру; төркемдә һәм парлап эшләү алымнарын куллану (коллектив эшчәнлек оештыру); мөстәкыйль эшчәнлеккә һәм аның нәтиҗәләренә төп игътибарны юнәлтү; мультимедиа чараларын киң куллану; яңа мәгълүматның гамәли әһәмиятенә басым ясау; үзтикшерү һәм үзбәя бирү өчен, укучыларда җаваплылык үстерү; һәр эшчәнлекне уңай бәяләү.

Соңгы елларда татар теленнән үрнәк эш программалары һәм укыту-методик комплектлар яңартыла; уку-укыту ярдәмлекләре һәм мультимедиа әсбаплар төзеп бастырыла, электрон дәреслекләр һәм онлайн- курслар эшләнә һәм укыту практикасында киң кулланыла. Шушы өлкәдәге алдынгы тәҗрибә белән уртаклашу һәм аны тарату эше дә игътибардан читтә калмый. Димәк, бай тарихка ия булган татар лингвометодикасы заман таләпләреннән чыгып үсеш ала, үзгәрә һәм камилләшә дип әйтә алабыз.


ӘДӘБИЯТ

1. Ибраһимов Г. Татар телен ничек укытырга. Казан, 1916.

2. Фәтхуллова К.С. Заманча дәрес – сыйфатлы белем нигезе // Мәгариф, 2016. № 8. Б. 48–51.

3. Хуторский А.В. Системно-деятельностный подход в обучении. М.: Эйдос, 2012.

4. Современный урок в условиях федерального государственного образовательного стандарта [Электронный ресурс]: учебно-методическое пособие / авт. и научн. ред. Т.В. Машарова; авт. А.А. Пивоваров и др. Киров: Тип. Старая Вятка, 2015. 108 с.


## Г. ИБРАҺИМОВ ИДИОСТИЛЕНДӘ КУШАМАТЛАР


***Хаҗиева-Демирбаш Г.С.***



В статье на материале произведений Г. Ибрагимова анализируется состав и эмоционально-экспрессивные функции прозвищ. В результате анализа их значений в аспекте интертекстуальности установлен ряд историко-культурных коннотаций, позволяющих раскрыть тему и идею, идиостиль автора.

Abstract. In the article, the composition and emotionally expressive functions of nicknames are analyzed on the basis of the works of G. Ibrahimov. As a result of the analysis of their meanings in the aspect of intertextuality, a number of historical and cultural connotations have been established, allowing to reveal the subject and idea, the idiostyle of the author.


Образ тудыруда сүзнең эчке матурлыгын һәм экспрессив-мәгънәви көчен барлавы язучыны төрледән-төрле яңа стилистик мөмкинлекләргә мөрәҗәгать итәргә, сүзнең кыйммәтен аңлап, индивидуальлелеккә, омтылырга

этәрә, идиостилен формалаштыра. Г. Ибраһимов иҗаты халыкчанлык белән сугарылган милли әдәби тел үсеше чорына туры килә [18, б. 55]. Шуңа күрә аның теле бүгенге чор татар язучылары өчен генә түгел, ә төрки халыклар өчен дә халыкчанлыгы белән үрнәк булып тора. Язучының идиостилендә халыкчанлык сыйфатлары кушаматларны үзенчәлекле куллану белән бергә үрелеп килә. Реаль һәм әдәби чынбарлыкны яктырткан исемнәр материалы әсәрнең структурасында мөһим әдәби чара ролен үтәү белән беррәттән, образлар структурасының, язучы сурәтләгән дөнья картинасының бер фрагментын чагылдырган аерым бер системасын тәшкил итәләр. Фәнни әдәбиятта әлеге катламга караган лексиканың күпкырлы экспрессив үзенчәлекләренә, автор уйланмасы гәүдәләндерү мөмкинлекләренә игътибар ителә. Бүгенге тел белемендә кушаматларның милли-мәдәни [21], социомәдәни [23], функциональ-семантик [16], этнопоэтик [22] үзенчәлекләрен өйрәнүгә өстенлек бирелә. Татар антропонимикасында кушамат категориясе Г.Ф. Саттаров [19], С.И. Гасимова [8] хезмәтләрендә җентекле итеп тикшерелә. Төрки тел белемендә кушамат мәсьәләсе башкортларда – Г.А. Амиргалина [7], кумыкларда – Р.А. Мусаева [17], каракалпакларда – Ю.Н. Хожалепесова [20], азәрбайҗаннарда – А. Курбанов [15], М.Н. Чобанов [1], кыргызларда – Ш. Жапаров [10], казакларда – Т.Җ. Жанузаков [2], төрек тел белемендә Ю. Кенан Караҗан [3], Мехмет Семих [5] тарафыннан яктыртыла. Шулай да аерым бер язучының идиостилендәге кулланылган кушаматларны аерым алып, аларның әдәби әсәрнең идея-эстетик кыйммәтләрен, эчтәлеген, ассоциатив бәйләнешләрен, мотивацияләрен, яшерен мәгънәләрен ачу мөмкинлекләрен өйрәнгән хезмәтләр юк.

Г. Ибраһимов XX гасыр башы милли антропонимикон үсеше тенденцияләрен билгеләгән реаль җирлек материаларыннан файдаланып, әсәр тукымасына кертеп җибәрә. Шуңа күрә Г. Ибраһимов әсәрләрендәге һәрбер антропонимик берәмлек авторның сәнгати югарылыгын, реаль чынбарлыкка карата булган фикерләрен, принципларын, мөнәсәбәтен чагылдырырга мөмкинлек бирә. Г. Ибраһимов милли антропонимиконыбызга хас исемнәрне сайлап, әсәр тукымасына кертеп җибәрә һәм әлеге исемнәр мәгънәнең семантик-стилистик йөкләмәсен тагы да арттыралар, образга хас әдәби-хисси тәэсирне тирәнәйтәләр. Әдәби әсәрдә кулланылган кушаматлар референт бәяләмәсен чагылдырган коннотатив мәгънәгә ия булып, персонажның аерым сыйфатларына игътибарны арттыралар. Әдип әсәрләрендә кулланылышка кертелгән һәрбер кушамат референт турында аерым этномәдәни мәгълүматны чагылдырып, бирелү-кушылу мотивлары исә, контекст нигезендә ачыла.

Г. Ибраһимов әсәрләрендә персонажларның эш-хәрәкәтләре, төс-кыяфәте, сөйләшү манерасы, мәсләк үзенчәлекләре нигезендә тагылган кушаматалар билгеләнә: *Аны һәммәсе кимсетәләр, яратмыйлар, җәберлиләр, теләгәнчә мыскыллыйлар, исеме белән дәшмичә башы зурлыктан* ***«Тубал»*** *дип кенә йөртәләр* («Уты сүнгән җәһәннәм»). Биредә кулланылган тубал сүзе денотатның зур башлы булуын гына сыйфатлап калмый, ә хикәядә Тубалның аң-белемгә, гыйлемгә омтылучан булуы ассызыклау өчен файдаланыла. Персонажның кушаматы «тубал булу», ягъни артык күп уйлаудан яки шау-шудан баш авыраю дигән мәгънәгә дә барып тоташа.

Повестьтә кулланылган Әрем тел кушаматы татар телендәге әрем тел әйтеменең семантикасына туры килеп, «усал, төртмәле сүзләр әйтүчән

кеше» дигәнне аңлата: *Безгә кодагый булачак, Гөлбануга кайнана булачак Сабираны беләм. Аны исеме белән атамыйлар, әрем-тел дип,* ***Әрем-тел*** *Сабира дип йөртәләр* («Татар хатыныниләр күрми»).

Әсәрдә башка кешеләрдән аеру максатында, квалификатив принцип нигезендә, теге яки бу сүзнең семантик тулылыгына басым ясаган кушаматлар персонажның тышкы кыяфәтенең үзенчәлекләрен сыйфатлыйлар: *Тирә-якта аларның авыллары Бикъярны: «****Көяз****», – дип, «****Бикъяр көязләре****» дип дип мыскыллап сөйлиләр* («Татар хатыны ниләр күрми»). *Базарда юк кына нәрсә өчен теге* ***Сыераяк*** *Хәмди белән әрләшеп китте* («Татар хатыны ниләр күрми»). ***Тиле Әхмәт*** *үз ирке белән диярлек килеп биреләде* («Тирән тамырлар»). *Буйга зурлыгы өчен аны* ***Озын Хафиз*** *дип йөртәләр* («Алмачуар»). *Күршенең* ***калын Низами*** *дигән берәү калага бара икән* («Тирән тамырлар»). *Аның артыннан* ***Назлы килен*** *Гыйззелбанат, Төхфәтнең хатыны* ***Усал тел килен*** *Мәрфуга, аларга ияреп бергә үскән кызлар* («Татар хатыны ниләр күрми»). Г. Ибраһимовның идиостилендә кулланылган квалитативлар иркәләү-кечерәйтү төсмерләренең киң спектрдагы мәгънәләрен бирәләр, үз чиратында әлеге коннотатив мәгънәләр персонажга каратагына түгел, ә сөйләм субъектына карата да мөнәсәбәт чагылдыралар. Кешенең төс-кыяфәтен, хәрәкәтләрен, тормышка карашын характерлый торган кушаматлар арасында нигездә тискәре семантикага ия сүзләр урын алган.

Г. Ибраһимов хикәяләрендә мәсләк белән бәйләнелешле кушаматларның семантикасын ачуга да аерым игътибар бирә. «Тирән тамырлар»әсәрендә Кочегар кушаматының кушу-бирелү сәбәпләрен персонаж тарафыннан болай дип аңлатыла: «*Мең тугыз йөз уникенче елның язында, теге Амур – Лена буендагы алтын приискаларында эшчеләрне аттырдылар бит. Шуңа протест итеп, безнең завод өч көн эшләмәде. Мине Василий Петровичны, тагы унбер эшчене – котыртучылар дип, кулга алдылар, урыннан кудылар, мин күп.., күп заман эшсез ач йөрдем. Күп өстерәлгәч, Алафузовка кочегар итеп алдылар. Минем кушамат менә шуннан чыга. Болай үзем мин химик* («Тирән тамырлар») [13, 143]. Әдип шул ук повестьта пешекче Миңзифа әбинең кушамат тагылу тарихын да әдәби алым буларак файдалана: «*Миңзифа әбине* ***Пешекче әби*** *дип йөртәләр. Ул татар милли ашларын хәзерләүдә заманында бөтен каланың беренче остасы булды»* («Тирән тамырлар») [13, б. 148].

Г. Ибрһимов әсәрләрендә персонажның яшәү урынына мөнәсәбәтле дә кушаматлар тагылуын билгеләргә мөмкин: ***Түбән оч Вәли*** *дигән бер фәкыйрь күп еллар инде Уралда эшли иде* («Татар хатыны ниләр күрми»). *Гадәт буенча, кияү өндәүчеләрдән* ***Чокыр Хәбипнең*** *йортына төште* («Татар хатыны ниләр күрми»). ***Пионер Самат, Октябрь баласы Азат*** («Тирән тамырлар»).

Г. Ибраһимов хикәяләрендә персонажның төрле гадәтләрен сурәтләп кушылган кушаматлар да билгеләнәләр. Тәмәке салып тарта торган махсус трубканы кулланырга яраткан Шәвәли картның кушаматы – Челем була. *Атасы белән талашкан көнне ул Нурыйда күп еллар ялчы булып торган* ***Челем бабай*** *– Шәвәли (Шаһвәли) картны очратты* («Татар хатыны ниләр күрми»).

Г. Ибраһимов хикәяләрендә нәселдән килә торган кушаматларга да игътибар бирә. Әлеге төр кушаматларны куллану авторга нәсел җебен барлауда оста әдәби алым буларак файдаланыла: *Бара торгач, «ала»сы төшеп*

*югала, «саескан» исеме «малайга кушамат булып ябышып кала. Зурайгач, бай крестьян булгач та төшми. Сөләйманнан нәсел буенча Нурыйларга күчә. Кимсетеп әйткәндә: **«Саескан»** дип, **«Саескан»** дип, **«Саескан Нурый»** дип, «**Саескан Нурый Фәтхиясе**», «Саескан Нурый балалары» дип йөртәләр* («Татар хатыны ниләр күрми») [12, б. 67]. ***Кәҗә Солтан!*** («Татар хатыны ниләр күрми»). *Сабираның атасы Солтан заманында сунарчы булган, диләр. Бервакыт үзенең бер дус адәмендә әче балны эчеп, кызыбрак чыккан да зур мөгезле ак кәҗәне болан дип, поши дип, аты белән куып киткән, диләр. Авылдагы дошман байлары, җәй, кыш мәптекккә ятучы бер аксак хәлфәгә тутырган тавык, илле тиен акча биреп, зур бәет чыгарттылар. Бу бәетне, өйдән өйгә кереп, садака җыеп йөрүче бер сукыр хәерчегә ятлаттылыр. Халыкка бик кызык тоелды. Бер тиен акча, ике йомырка биргән һәркемгә сукыр хәерче Солтан турындагы бәетне укып чыга торган булды. Шуннан солтанга – **Кәҗә Салтан** дип ат куштылар* («Татар хатыны ниләр күрми») [12, б. 67].

Г. Ибраһимов идиостилендә тулы исемнәрне кыскарту, иркәләү-кечерәйтү аша барлыкка килгән кушаматлар да билгеләнәләр: *Кич, атка куна китәр алдыннан тәрәзә аркылы күрше малай **Апушка** сызгырып җибәрде* («Татар хатыны ниләр күрми»). *Атам көтүче иде: озын буйлы, киң маңгайлы карт. Исеме – **Әптерәш*** («Көтүчеләр»).

Димәк, әсәр тукымасына үтеп кереп, этномәдәни текст вазыйфасын үти торган кушаматлар әдип иҗат иткән чорга хас үзенчәлекләрне, образлар системасын барлыкка китерүдә, персонажларның үзара мөнәсәбәтләрен интерпретацияләүдә зур роль уйнавын ассызыкларга кирәк. Г. Ибраһимов иҗатында кулланылган һәрбер кушамат образны күзаллауда, төшенчәләрне сурәтләүдә үзәк лейтмотив булып тора. Әдип тарафыннан әсәр тукымасына кертелгән кушаматлар әсәрнең әдәби-эстетик концепциясен тормышка ашыруның бер чарасы булып, аның темасын һәм тирән мәгънәви идеясен ачарга ярдәм итәләр.

ӘДӘБИЯТ

1. Azerbaycan kişi adları. / M.N. Çobanov; haz. Cengiz Alyılmaz. Erzurum: Atatürk Üniversitesi Türkiyat Araştırmaları Enstitüsü, 1993. 88 s.

2. Kazak Türklerinde kişi adları / T.J. Januzaqov, K.S. Esbayeva; aktaran Nurettin Aksu. Ankara: Türk Dil Kurumu, 2003 102 s.

3. Takma adlar / Y. Kenan Karacanlar. İstanbul: Tüm Yayınlar, 1977. 143 s.

4. Tanzimattan bugüne Türk yazı hayatında takma adlar indeksi / Naile Binark, Saide Arslanbek. Ankara: Türk Kütüphaneciler Derneği, 1971. 34 s.

5. Türk edebiyatında mahlaslar, takma adlar, tapşırmalar ve lakaplar / Mehmet Semih. İstanbul: Anahtar Kitaplar Yayınevi, 1993. 84 s.

6. Абдуллина Г.Р. Сайфуллина В.Р. О башкирских прозвищах // Актуальные проблемы филологии: история, современность и перспективы: Материалы Всероссийской научной-практической конференции. Нефтекамск, 2013. С. 11–14.

7. Амиргалина Г.А. Современные башкирские прозвища, связанные с внешним видом человека // Фундаментальные исследования. 2015. № 2–3. URL: http: // cyberleninka.ru / article/n/ covremennye-bashkirskie-prozvischa-svyazannye-s-vneshnim-vidom-cheloveka (дата обращения: 01.09.2016).

8. Гасимова С.И. Историко-лингвистический анализ татарских прозвищ: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2006. 25 с.

9. Дранникова Н.В. Локально-групповые прозвища в традиционной культуре: функциональность, жанровая система, этнопоэтика: автореф. ... дис. канд. филол. наук. Архангельск, 2005. 25 с.

10. Жапаров Ш. Адам аттары – эл байлыгы. Бишкек: Текник ББ, 2009.

11. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 9 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. 1 т. 511 б.

12. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 9 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. 2 т. 477 б.
13. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 9 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. 3 т. 456 б.
14. Карташева И.Ю. Прозвища как явление русского устного народного творчества: автореф. дис. ... канд. филол. н. Челябинск, 1985. 25 с.
15. Курбанов А. Основы Азербайджанской ономалогии. Баку: Нурлан, 2004. 2 т. 504 с.
16. Лангнер А.Н. Функционально-семантические и словообразовательные особенности прозвищ: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Белгород, 2010. 25 с.
17. Мусаева Р.А. Кумыкская антропонимика: прозвища и имена: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Махачкала, 2008. 22 с.
18. Поварисов С.Ш. Г. Ибраһимов и татарский литературный язык. Уфа: РИЦ БашГУ, 2009. 400 с.
19. Саттаров Г.Ф. Татар антропонимикасы. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1990. 276 б.
20. Хожалепесова Ю.Н. Прозвища в системе каракалпакской антропонимии: автореф. дис. ... канд. филол. наук, 1996. 26 с.
21. Цепкова А.В. Национально-культурная специфика прозвищ: автореф. ... дис. канд. филол. наук. Новосибирск, 2011. 26 с.
22. Шостка Е.С. Прозвища Тамбовской области: языковой и социокультурный аспект: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Тамбов, 2009. 25 с.
23. Шпар Т.В. Прозвищные антропонимические номинации в социолингвистическом аспекте: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Уфа, 2012. 26 с.

## Г. ИБРАҺИМОВ ХЕЗМӘТЛӘРЕНДӘ «ИНТЕЛЛИГЕНЦИЯ ҺӘМ ИНКЫЙЛАБ» ТЕМАСЫ

***Харрасова Р.Ф.***

В статье говорится о том, что молодой общественный деятель Г. Ибрагимов придерживался взглядов либерального народничества, отводя интеллигенции роль просветителя масс. В дальнейшем он, как и марксисты, в своих трудах указал на двойственность, промежуточность положения интеллигенции между пролетариатом и буржуазией. После 1917 года писатель усердно борется за решение проблемы использования старой, а также формирования новой народной интеллигенции из рабочих и крестьян.

The article tells that the young public figure G. Ibragimov adhered to the views of liberal populism, assigning the intelligentsia the role of the educator of the heaps of people. Later in his works he pointed out, like Marxists, the duality and intermediate position of the intelligentsia between the proletariat and the bourgeoisie. After 1917 the writer worked hard to solve the problem of using the old and formation of a new intelligentsia of workers and peasants.

Белгәнебезчә, татар интеллигенциясенең күпчелеге руханилар катлавыннан формалашкан, чөнки нәкъ менә алар – бер үк вакытта халыкка белем бирүчеләр, мәгърифәт-мәдәният нуры өләшүчеләр һәм еш кына, икенче һөнәрләр үзләштереп, чит хезмәтләр башкарып, руханилык вазифаларын ташлап, әлеге катламга тулаем күчүчеләр, зыялыларны сан ягыннан ишәйтүчеләр. Әлбәттә, динчеләргә дә гасыр дәвамында башка социаль төркемдәгеләр килеп кушылган, ул үз эчендә бик чуар булган һәм төрле дәрәҗәгә, күзаллауларга ия кешеләрдән торган. Татар зыялыларының бер өлешен, әйтик, хәерчеләнгән морзалар, юрист, табиб һәм башка һөнәрләрне үзләштергән морза балалары, белем алып, социаль баскычта югарырак күтәрелгән һөнәрчеләр һәм башкалар тәшкил иткән. Бигрәк тә XIX–XX гасыр чикләрендә социаль барышта күзгә ташланырлык үзгәрешләр күзәтелгән,

һәм инде интеллигенцияне аерым социаль төркем, теге яки бу катлау эчендәге яисә катлаулар арасындагы катлам-прослойка сыйфатында күрсәтерлек җирлек булган.

Зыялыларның карашлары формалашуда бөтен Көнчыгышка таралган төрле тип схоластик мәдрәсәләрнең яисә яңа мәктәпләрнең, җәдидчелек хәрәкәтенең, кайберләренекенә европа белеменең, югары катлаулар белән аралашуның, шулар эченә керүнең, аларга хезмәт итүнең, рус интеллигенциясенең, бигрәк тә ул тудырган әдәбиятның тәэсире зур. Шушындый чуар составлы татар зыялыларының берише инкыйлабның алгы рәтләрендә хәрәкәт иткән һәм хакимият өчен көрәштә әкренләп пролетариат әйдәманына әверелгән.

XX гасыр башында интеллигенциясенең асылы, кемнәрдән оешуы, җәмгыятьтәге урыны турында бәхәсләр тынмый. Берәүләр аны аерым сыйныф сыйфатында карый; икенчеләр социаль төркем саный, әмма кайсы иҗтимагый катлауга кертергә белми; өченчеләр җәмгыятьнең гомумкешелек идеалларын яклаган элитасы дип исәпли; дүртенчеләр ул төрле класслардан оеша, бердәм социаль төркем формалаштыра алмый, чөнки үз эчендә бик аерыла, дип белдерә. Иң киң таралган карашларда исә: а) зыялылар буржуазия һәм пролетариатның бер өлешен тәшкил итә, кыйбласына һәм күзаллауларына нисбәтле, я анысына, я монысына хезмәт куя; б) вак буржуазия элементы булып тора.

1917 елга кадәр үк татар җәмәгать эшлеклеләре, әдипләре дә иҗтимагый-сәяси көрәштә буржуазиянең һәм пролетариатның, башка катлауларның, социаль төркемнәрнең роле, аңа кайсы тарафтан кушылулары турында уйланган, чөнки түнтәрелешкә хәзерләнү этабында төрле партияләр арасында бәхәсләр барган, вакыты белән көрәш аеруча кискенләшкән. Соңыннан – 1925 елда Г. Ибраһимов белдергәнчә, шушы чорда төрле – иҗтимагый-социаль төркемнәрнең күпчелеге төп нигез агымнарга – татар эшчеләре, татар буржуазиясе, вак буржуа социализм группалары хәрәкәтләренә берләшә һәм шулардан «либерал татар буржуазия зыялысы өчен бөтен программа сәяси азатлык һәм демократизм белән чикләнсә, революционер социал-демократия байрагын күтәргән пролетариат тарафыннан моның өстенә төп максуд итеп социализм өчен көрәш алынадыр» [4, б. 272]. Китерелгән өзектән күренгәнчә, әдип соңгы ике агымны берләштерә, шуларга мөнәсәбәттә зыялы дигәндә, либерал-буржуаз катлауның белемле, мәдәни катламын, русча әйткәндә, прослойкасын күздә тота.

Г. Ибраһимов татар интеллигенциясе темасын, әлбәттә, беренче чиратта, әдәбият һәм сәнгатькә кагылышлы мәкаләләрендә яктырта. Аның 1910 елда дөнья күргән язмаларыннан татар зыялыларының ничек барлыкка килүе, нинди шартларда сан ягыннан артуы һәм гасыр башында милләт, аның әдәбияты, театры, рәсем сәнгатенең алгарышы юлындагы гамәлләре хакында укырга мөмкин. Шулардан «Рәссамлык» дип аталганында ул зыялыларны, мәсәлән, «мөхтәссис кыйсем» («белгеч өлеш») төшенчәсе белән белдереп уза, бер урында «Зыялы сыйныфлар үз халкының мәгыйшәтеннән алынган моң ләүхәләр белән кабинетын зиннәтләүгә, әлбәттә, сөеп карар», дип яза [2, б. 16–17]. Күрәбез ки, «зыялы сыйныфлар» дигәндә, мәдәни, югары сәнгать әсәренә зәвыгы булган, белемле катламнар турында бара.

Г. Ибраһимов инкыйлабка килү чорында интеллигенциягә мөнәсәбәттә бигрәк тә В.Г. Белинский карашларын яклый, «халыкчылар» тарафдары

була. Ул да, аның кебек, зыялыларга, шуның бер өлешен тәшкил иткән әдәбиятчыларга мөгаллимлек вазифасы – халыкны белемле һәм тәрбияле итү, сүз сәнгатен яңа баскычка күтәрү бурычы йөкли. Бу, аерым алганда, аның «Рус мөхәррирләреннән мәшһүр интикадчы В.Г. Белинский җәнаблары хакында» (1910) язмасында чагылыш таба.

Егерменче гасырның беренче унъеллыгында язылган мәкаләләре белән, Г. Ибраһимов «түбәннән күтәрелгән», «халык язучылары»ның иҗатын пропагандалау эшенә керешә. Шуның ачык мисалы – «Каһарман шагыйрь» (1914) язмасыдыр. Ул анда атаклы шагыйрь, рәссам, һәйкәлтараш Шевченконы хөррият каһарманы дип атый. Шушы чорда язган кайбер мәкаләләрендә Г. Ибраһимов белемле, һөнәрле татарларны милли рухны милли зәвык, милли тойгылар белән баету эшенә өнди; милләт уянсын өчен, аның төрле юнәлештәге сәнгатьләрен үстерергә кирәк, дигән караш уздыра. Әдип кайвакыт теге яки бу әдип иҗатында тасвирланган яңа тип зыялы геройлар турында сүз алып бара. Әйтик, ««Шәрекъ клубы»нда татарча театр»да (1915), «Ф. Сәйфи-Камалов пьесасындагы Мөхәммәт исемле укытучы геройның монологыннан өзекләр китереп, милләтнең төрле сыйныфлардан торганлыгы турында сөйли, геройның үзен идеалист халыкчы вазифасын башкарган зыялы рәвешендә күрә.

1917 елдан соң идарәчелекне үз кулларына алган большевиклар эшчеләрдән һәм крестьяннардан яңа тип интеллигенция формалаштыруны һәм төрле өлкәләрдә эшләгән иске белгечләрне үзләре күрергә теләгәнчә тәрбияләүне, пролетариат диктатурасы, лидерларының сәясәте белән килешмәүчеләрне әкренләп тарафдарларына әйләндерүне илдә социализм төзү стратегиясенең бер юнәлеше итеп ала. Шушы чорда инкыйлаби көрәшләрнең мәшһәрендә кайнаган Г. Ибраһимовны да кемнең кем белән булуы һәм зыялыларның кемгә хезмәт итүе мәсьәләсе бик нык борчый. Тарихи барышны яктырткан язмаларының күбесендә ул әлеге проблеманы читләп үтми, һәрвакыт без – алар, кем өчен, ни өчен кебек гыйбарәләр, сораулар тирәсендә сүз алып бара.

Г. Ибраһимов «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре» язмасында милләтебездәге иҗтимагый катлаулар турында махсус фикер йөртә һәм аларның калыплашу юллары турында да сөйли; халыкны капма-каршы сыйныфларга, иҗтимагый катлауларга, шуның тармакларына матди хәл, хакимияткә якынлык, һөнәр нигезендә бүлә; һәрберсенең эчендәге каршылыкларны билгеләп узарга тырыша һәм хәтта бер үк исем астында берләшкән катлауларның да русларныкыннан аермалы хәлдә икәнлеген исбатлап бирә [4, б. 248–268]. Г. Ибраһимовның татар интеллигенциясенең инкыйлаб хәрәкәтендәге роле турындагы карашлары әлеге хезмәтнең күп кенә бүлекчәләрендә ачыла, әмма «зыялылар катламы» гыйбарәсе автор тарафыннан кулланылмый. Моның төп сәбәбе интеллигенция төшенчәсенең озак гасырлар фикер йөртү эшчәнлеге белән шөгыльләнүчене белдерүендә, инсанның килеп чыгышын аңлатмавында, зыялы катлам һәр иҗтимагый катлауда була дип санауда дип уйларга кирәк. Әлеге төшенчә социаль мәгънәдә XIX гасырның икенче яртысында кулланыла башлый, бездә исә, гомумән, ике гасыр чигендә генә бигрәк тә маркистик әдәбият тәэсирендә активлаша. Асылда аның эчтәлеге артык үзгәрми: ул тәнкыйди карашлы, тирән белемгә ия, аны һәм эш тәҗрибәсен системага салган, дөнья мәдәнияты казанышларын башкаларга ирештерүче, иҗади, югары әхлакка,

специфик психологик сыйфатларга ия кешеләр төркеме дип күзаллана. Г. Ибраһимов та, зыялылар катламы турында сүз йөрткәндә, күбрәк аларны һөнәрләре аша атый. Шушы ук хезмәттә ул булачак зыялыларның алмашы булган алдынгы шәкертләр һәм аларның оешкан сәяси-иҗтимагый хәрәкәте турында да махсус сүз алып бара. Шулай да әдипнең тарих фәненә караган хезмәтләрендә төп игътибар зур сыйнфый көрәшне ачуга һәм зур агымнарның, инкыйлаби көрәштә мөһим иҗтимагый катлауларның, һәрберсендә төп фигураларны күрсәтүгә, киңбилгеле шәхесләрнең теге яки бу агымдагы урынын, тарафын билгеләүгә юнәлтелгән.

Г. Ибраһимовның интеллигенцияне, аның инкыйлаб чорындагы ролен яктыртуында кискен үзгәрешләр инкыйлабтан соң башлана. Ул бигрәк тә егерменче елларда танылган зыялыларыбызны Яңа ил төзүгә, Яңа әдәбиятка хезмәт иттерү һәм гади халыктан яңа тип зыялылар калыплаштыру турында уйлана. 1920 елда «Габдулла Кариев иптәш рухына» дип язылган мәкаләсендә Г. Ибраһимов болай белдерә: «Үзенең шөһрәте белән татар дөньясын яңгыраткан Габдулла Кариев түбәннән, тормышның төбеннән, ярлы, караңгы авыл эченнән күтәрелде». Алга таба шушы мотивны әдип һәм прозасында, һәм публицистикасында, һәм фәнни хезмәтләрендә еш ассызыклый.

Г. Ибраһимов егерменче елларда зыялыларны инкыйлабка хезмәт иттерүдә марксистларның, бигрәк тә В.И. Ленин карашларының тарафдары була. Ул интеллигенциянең бер өлеше аңлы рәвештә маркистик позицияләргә басты, ә бер өлеше урталыкта, өченчеләре дошман сыйныфларга хезмәт итә дип саный һәм урталыктагыларны большевикларга хезмәт иттерү өчен көрәш башлый. Әдип иҗтимагый көрәшкә катнашкан танылган татар зыялылары хакында еш кына ирония белән яза, аларның теге яки бу хәрәкәтләр эчендәге гамәлләрен, позицияләрен тәнкыйть утына ала, кайчандыр көрәштәшләре булган аерым затларга антипатиясе сизелеп тора. Бу хәтта аның нәфис иҗатына да үтеп керә. «Яңа кешеләр» (1920) драмасында советка каршы позициядә торган матди хәле яхшы милләтче татар зыялысы Әхтәм Банаев сыйнфый алышта инкыйлабчылар тарафдары булган гади кыз мөгаллимә Камәргә каршы куела. «Милли идарәче» Әхнәф, кызылларның җиңгәнлеген күргәч кенә, үзе әйтмешли, «Чехның, Колчакның йөзе ачылгач», «фикерләремездә тирән үзгәреш – зур перелом булды» дип белдерә, мескенләнә, чарасызлана, ахыр чиктә большевиклар, гавам алдында тезләнә – каләме белән бары тик советка гына хезмәт итәргә ант-вәгъдә бирә.

Г. Ибраһимов «фикерләре төзәлгән»нәр янәшәсенә эшче-крәстияннан үсеп чыккан каләм ияләрен дә китереп кушу, һәрдаим халыкка, каләмдәшләренә Яңа заман кыйммәтләрен аңлату эшен аеруча актив алып бара. «Кызыл каләмгә юл ачылсын!» (1920) язмасында әдип «Искене җимереп, яңа азат тормыш төзүдә кызыл штык, чүкеч һәм урак белән бер дәрәҗәдә хезмәт йөкләтелгән кызыл каләм үз өстендәге бурычны үти алсын өчен, эшче-крәстиянның авыр канлы көрәшендә үткен корал булган кызыл каләмгә киң юл ачылсын өчен, һич нәрсәне яшермәскә, авыруны бөтен куркынычы белән ачып бирергә мәҗбүрбез», – дип яза [2, б. 237].

Г. Ибраһимов «Дүртенче елга кергәндә» (1920) мәкаләсендә татар интеллигенциясе каршында кыйбла сайлау мәсьәләсен кабыргасы белән куя: «Ике сыйныф бар. Аларның көрәше дәвам итә. Әдипләр, шагыйрьләр, артистлар, журналистлар, философлар, галимнәр үзләрен алдамасыннар, бу ике сыйныфның кайсы белән баруларына җавап бирсеннәр – халык үзе дә,

һичнәрсәдән курыкмыйча, боларны шул үлчәүләргә салырга тиешле» [2, б. 243]. Ә инде «Өч җавап» (1922) хезмәтендә Г. Ибраһимов әдипләрнең әдәби пәрдә астына яшерелгән яисә ачыктан-ачык фикере, тасвирлаганы халыкка тәэсир иткәнлектән, «шагыйрьнең, әдипнең кемгә, нинди әмәлгә, кайсы сыйныфка хезмәте мәсьәләсе килеп чыга. Шигырьнең, әдәбиятның хезмәт, тәрбия мәсьәләсе сүз белән агитациядә, вәгазьдә, фәлсәфәдә, коры фикер сатуында түгел, бәлки адәмнәрнең рухында нинди эз калдырачак күренешләр, вакыйгалар бирүендәдер» – дип белдерә [2, б. 312].

Чынлыкта да, Октябрь инкыйлабын русларда да, татарларда да гыйлемгә, сәнгатькә хезмәт итүчеләрнең барысы да сөенеп каршы алды дип булмый. Аларның беришесе чит илгә күчеп китә, икенчеләре битарафлык күрсәтә, көтү позициясенә баса, өченчеләре хәтта каршы көрәшкә күтәрелә. Иске зыялыларның, бигрәк тә каләмдәшләренең инкыйлаби хәрәкәткә кушылуында Г. Ибраһимов язмаларының роле, әйткәннәренең ышандыргыч көче бик зур була.

Үзе дә каләм иясе булган Г. Ибраһимов, интеллигенция һәм инкыйлаб мөнәсәбәтләре турында сүз йөрткәндә, күбрәк әдипләргә, аларның язганнарына, инкыйлаб чорында торкан мәсләкләренә туктала. Бу чорда нәкъ менә басма сүзнең халыкның үзаңын үстерүдәге, күзаллауларын формалаштырудагы роле шулкадәр зур була ки, большевиклар, беренче чиратта, нәфис әдәбиятны һәм вакытлы матбугатны көчле контрольгә ала, әдип-зыялылар эшчәнлеге белән идарә итүгә керешә.

Г. Ибраһимов татар интеллигенциясенең милләт алгарышындагы гамәлләрен тасвирлаудан бервакытта да туктамый. Ул «Татар әдәбияты хакында тагын бер әсәр» (1923) һәм башка язмаларында тарихыбыздагы иҗтимагый чорларны инкыйлабка килү баскычлары рәвешендә дә күзаллата һәм һәрберсендә иҗтимагый мәйданда билгеле шәхесләр торкан урыннарны билгели. Әдип «Аңларга тырышыгыз, туганнар!», «Пролетариат әдәбияты турында» (1923) кебек мәкаләләрендә марксист әдипләрнең һәрдаим пролетариатка ничек һәм нинди эчтәлектәге әсәрләре белән хезмәт итәргә тиешлеге, әдәбияттагы сыйныфчылык турында сүз йөртә.

Г. Ибраһимов «Кара маяклар, яки ак әдәбиятлар» дип исемләнгән күләмле хезмәтендә гомерләре буе татар милләтенең алгарышын кайгырткан атаклы шәхесләребезгә, бары тик пролетариатка гына хезмәт итү-итмәү, инкыйлабны кабул итү-итмәү кебек позицияләрдән чыгып, кара мөһер суга: аларны төрек-татар, ислам контрлары һәм «кара әдәбият тудыручылар» дип бәяли. Ул, инкыйлабка төрле юллар белән килүче М. Бигиев, Исхаков, Әмин бәк һәм башка татар зыялылары инде бер кыйблага җыелды, дип белдерә. Ахыр чиктә язучы каләме шуңа барып җитә ки, ««Хәрби шуралар» һәм буның тирәсендә оешкан барлык тәти «милли» егетләр, ак офицерлар, боларның иярченнәре – Европадагы хәзерге фашизмның икенче исемдә, икенче төстәгеләре генә иде»,– дип котычкыч нәтиҗә ясый. Ә бит, белгәнебезчә, алар арасында милләт хәдиме булган зыялыларыбыз да бар. Г. Ибраһимов хезмәтенең ахырында үзе күзаллаган һәм эчендә интеллигенция вәкилләре дә булган фашистик көчләрнең солтангалиевчеләр аркылы басмачылар белән бәйләнулары, партия эченә кадәр кул сузулары турында сүз алып бара.

Кыскасы, Г. Ибраһимов, бер яктан, инкыйлабка хәзерләнү дәверендә татар интеллигенциясенең игелекле эшләрен, бигрәк тә заман әдәбиятын

формалаштырудагы һәм үстерүдәге ролен уңай бәяли, икенче яктан, инде ул дәвер зыялыларының чоры үтте, пролетариат диктатурасын яклаган, советка хезмәт иткән яңа буыннарны тәрбияләргә, каршы көчләрне большевиклар ягына аударырга кирәк, дигән караштa тора, бу идеяләрне тормышка ашыруда үзе дә бик күп реаль эшләр башкара. Ахыр чиктә Г. Ибраһимов сыйныфлар алышында марксистик күзалламаган, гомуммилләт яшәеше, татарның барлык катлауларының да алга китешен кайгырткан зыялыларыбызга каршы рәхимсез көрәш юлына баса.

ӘДӘБИЯТ

1. Ибраһимов Г. Яңа кешеләр // Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр. 1975. 3 т. Б. 387–447.

2. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. 5 т. 588 б.

3. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр, 1986. 6 т. 598 б.

4. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр, 1984. 7 т. 510 б.

## «БЕЗНЕҢ КӨННӘР» РОМАНЫНДА ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫҢ СҮЗ ЯСАУ ҺӘМ КАЛЬКАЛАШТЫРУ ТӘҖРИБӘСЕ

***Хәбибов Л.Г.***

Классик татарской литературы Г. Ибрагимов в своих произведениях и многочисленных статьях показал трепетное отношение к родному языку, глубокое освоение этого языка и мастерское владение им. Для точного выражения понятий и своих мыслей он в некоторых случаях образовывал слова и словоформы, калькировал слова и выражения из русского языка. В этом процессе наряду с удачным опытом словотворчества у писателя обнаруживаются менее удачно образованные слова и выражения.

The classic of the Tatar literature G. Ibragimov in his works and numerous articles showed a trembling attitude to the native language, the profound mastering of this language and masterful possession of it. For the precise expression of concepts and his thoughts, in some cases he formed words and word forms, and he traced words and expressions from the Russian language. In this process, along with a successful experience of word-making, the writer finds less well-formed words and expressions.

Татар әдәбиятының классик язучысы Г. Ибраһимов әсәрләрендә күтәргән проблемаларның киңлеге һәм тирәнлеге белән әдәбиятыбыз үсешендә аерым урын биләп тора. Романтик рухта язылган беренче чор иҗатына караган әсәрләреннән ул тиз арада халык язмышын, аны борчыган проблемаларны кыю күтәреп чыккан әсәрләр иҗат итүгә күтәрелә алды. Ул аларны реаль картиналарда югары сәнгати осталыкта тасвирлап та күрсәтте.

Язучы иҗатының халыкчан булуын югарыда әйтелгәннәрдән тыш аның әсәрләренең теле дә билгели. Г. Ибраһимов – гомумхалык татар телен киң һәм тирән үзләштергән каләм иясе. Гомумхалык татар теленә нигезләнеп, XIX йөзнең соңгы чирегендә формалаша башлаган милли әдәби телебезнең XX гасыр башында һәм аның алдагы унъеллыкларында ныклы үсеш алуына үзеннән шактый өлеш керткән әдип ул.

Г. Ибраһимов әдәби телнең грамматик төзелешен телче-галим һәм методист буларак та өйрәнүгә һәм телебезнең нечкәлекләрен, морфологик һәм

синтаксик күренешләрен «Галия» мәдрәсәсе шәкертләренә җиткерү эшендә күп көч салды. Әдип татар әдәби теленең төзелешен телнең үз хасияте нигезендә тасвирлап һәм аңлатып бирергә омтылды. Бу җәһәттән без аның «Татар сарфы (морфологиясе)» һәм «Татар нәһүе (синтаксисы)» (1911 ел) грамматика буенча язган хезмәтләрен күрсәтергә тиешбез. Әйтергә кирәк, бу хезмәтләр күп тапкыр бастырылып, дәреслек буларак берничә дистә ел белем бирү системасында кулланылдылар.

Язучының «Безнең көннәр» әсәре – тарихи-революцион роман. Аның бу әсәрендә Казанда татар интеллигенциясе вәкилләренең рус профессиональ революционерлары белән бәйләнештә самодержавиегә каршы көрәштә катнашулары һәм бу көрәшкә әзерләнүләре киң рәвештә, җанлы картиналарда һәм образларда тасвирлап бирелгән.

XX йөз башындагы иҗтимагый-сәяси һәм икътисадый тормышның интенсив үсеше, шул нигездә татар дөньясында да барган үзгәрешләр яңа мөнәсәбәтләр, яңа төшенчәләр дә барлыкка китерде. Язучы иҗатында алар реалистик рәвештә объектив чагылыш таптылар.

Г. Ибраһимов бу романда сүзләрнең мәгънә белдерү егәрлеген һәм мөмкинлекләрен нечкә тоеп, алар белән сак эш итә. Тормышта барлыкка килгән яңа төшенчәләрне белдерү максатында язучы яңа сүз иҗат итәргә яки ул төшенчәләрне белдергән чит тел сүзләрен структур яктан калькалаштырырга омтыла.

Хәзерге татар теленең бай лексикасын киң тармаклы сүзләр системасы һәм аларның мәгънәләре тәшкил итә [2]. Галимнәр фикеренчә, анда төрле структураларга һәм стильләргә караган йөзләрчә мең сүзләр исәпләнә. Агглютинатив төзелешле татар телендә сүзләр һәм аларның төрле формалары ясалуы беренче чиратта телнең үз сүз ясаучы чаралары нигезендә бара. Күренекле татар дериватологы Ф.А. Ганиев билгеләвенчә, «лексика үсешенең бу юлы бик борынгыдан килә» [2, б. 8].

Г. Ибраһимов «Безнең көннәр» әсәрендә татар теленә хас сүз ясаучы грамматик чаралар ярдәмендә яңа сүзләр һәм сүзнең төрле формаларын ясауда үзенчәлекле эшчәнлек күрсәтте. Моннан тыш әдип рус телендә барлыкка килгән төшенчәләрнең калькаларын татарчалап бирү тәҗрибәсен дә ясап карады.

Хәзер шуларның кайберләренә тукталабыз.

1. Исемнәр ясалышы.

Язучы кайбер исемнәрне ясаганда, кушымчалау, сүзләрне кушу ысуллары белән эш итә.

*-чы/-че* кушымчасы ярдәмендә түбәндәге сүзләр ясалган: *динче, коткычы, текстильче, картачы.* Мәсәлән: *Управляющий елмаеп Гәүһәргә карады, көлде:*

*– Монда юк-бар к о т к ы ч ы л а р керә. Шуңа күрә каравыл куйдык, әйдә утырыгыз миңа, – диде* [1, б. 313]. *Зариф Булатов килеп керде. Аның килүе һәммәсе өчен дә көтелмәгән бер әйбер булганга, исерек к а р т а ч ы л а р компаниясе бер минут гаҗәпсенеп карадылар да, аватүнә, Булатны сырып алдылар* [1, б. 372]. Күрүебезчә, Г. Ибраһимов бу җөмләләрдә әдәби телдәге *коткы таратучылар* һәм *карта уйнаучылар* тезмә характердагы исемнәр урынына кушымчалау юлы белән ясалган *коткычылар, картачылар* сүзләрен кулланган. Бу мисаллардагы *картачылар* ясалма сүзен, безнең карашка, уңышлы дип әйтеп булмас иде.

Беренчедән, әлеге ясалма сүз *карта уйнаучылар* тезмә сүзеннән мәгънә белдерү ягыннан таррак, икенчедән, *картачы* сүзе «географик карталарны әзерләүче һәм алар белән эш итүче белгеч (зат)» мәгънәсен белдерү өчен кулайрак.

-*лык/-лек* кушымчасы белән түбәндәге сүзләр ясалган: *кунаклык, куллык.* Мәсәлән: *Яңа надзиратель Безобразов беренче адымында ук каты к у л л ы к күрсәтте* [1, б. 120]. *Нигъмәт хатыннар ягына, Сәхип к у н а к л ы к я г ы н а кереп, исәнләшеп, сәлам биреп чыктылар да юынырга тотындылар* [1, б. 352]. Гомумхалык телендә *каты куллылык күрсәтү* фраземасында *куллылык* сүзе шул формада ясалган: башта нисби сыйфат, аннары ясагыч кушымча ярдәмендә исем ясалган. Язучы кыскалыкка омтылу теләге беләнме логик-грамматик яктан дөрес ясалган сүзне үзенчә кулланып караган. Безнең уебызча, Г. Ибраһимов икенче җөмләдә кулланган *кунаклык ягы* сүзен дә бик үк уңышлы дип әйтә алмыйбыз. Язучы бу тезмә сүзне рус телендәге *гостиная* сүзеннән ирекле тәрҗемә буларак ясап караган булырга тиеш. Әмма бу рус сүзен *кунаклар бүлмәсе* яки *кунаклар кабул итү бүлмәсе* дип алырга кирәк ләбаса.

-*челек* кушымчасы белән түбәндәге сүзләр ясалган: *көнләшүчелек, булучылык.* Мәсәлән: *Нина башта ук берничә тапкыр бу кыз турында сүз кузгатырга уйлап караган иде, ләкин, к ө н л ә ш ү ч е л е к күренер дип, телен тешләгән иде* [*1,* б. 378]. *Сез (Тангатаров) хәзерге тормышны корал көче белән җимерүче оешмаларда актив әгъза б у л у ч ы л ы к белән гаепләнәсез* [1, б. 421]. Әдип тарафыннан кулланылган *көнләшүчелек* ясалма сүзе дә артык ясалма буларак кабул ителә. Ә бит әдәби һәм гомумхалык телендә бу сүз белдергән мәгънәне *көнләшүчәнлек, көнчелек* сүзләре тулысы белән белдерә алалар.

2. Сыйфатлар ясалышы.

Г. Ибраһимов сыйфатлар ясалышында да үзенә уңай булганрак формалар эзләде, телебезнең синонимик мөмкинлеген киңәйтергә омтылды.

*-чыл/-чел* кушымчасы ярдәмендә ясалган сүзләр: *намазчыл*. Мәсәлән: *Әмма Гәүһәр кискен кеше иде. Беренче адымнан ук үзенчә ачык юл сызды. Аның анасы бик динле, иске фикерле, н а м а з ч ы л карчык иде* [1, б. 309]/

Бу кушымча исемнәргә, сыйфатларга һәм саннарга кушыла. Исем нигезгә кушылып, ясаучы нигез тәгъбир иткән нәрсәне яратучы дигән мәгънәне белдерә.

*-чан/-чән* кушымчасы белән берничә сүз ясалган: *яшеренүчән, аңлаучан, гафучан, сынаучан, сөючән, йөрүчән.* Бу кушымча исем фигыльләргә ялганып, ясаучы нигез тәгъбир иткән эш-хәрәкәткә яки процесска дучар булучан дигән мәгънәне белдерә. Мәсәлән: *Ул (Гәүһәр) табигате белән бик артык я ш е р е н ү ч ә н кыз иде* [1, б. 312]. *Бу кыз (Саҗидә) бик тиз а ң л а у ч а н булып чыкты* [1, б. 321]. *Үзен (полковник Герасимов)* «*ата*» *кебек – йомшак күңелле, г а ф у ч а н* «*ата*» *кебек тотты* [1, б. 345]. *Барысы да сезнең җимешләр, – дип, Герасимов үзенең ачулы, с ы н а у ч а н күзләрен тоткынга кадады* [1, б. 350].

*-ык/-ек* кушымчасы белән ясалган сүзләр: *сүнек.* Мәсәлән: *Карчык җыерчыклар белән капланып, кара саргылтланып кипкән йөзе, салынкы кашлар астына әллә кая төпкә, тирәнгә яшеренгән с ү н е к күзләре белән Булатка күтәрелеп карады да: – Син Зариф дигәннәре буласыңмы? Минем улымны нигә астылар?! – дип җылап җибәрде* (б. 380). Бу кушымча ярдәмендә

ясалган сыйфат *сүнгән* сыйфат фигыленә караганда карчыкның күзенең статик халәт-билгесен дөресрәк чагылдыра.

3. Фигыльләр ясалышы.

Г. Ибраһимов эш-хәрәкәт, торышны белдергән төшенчәләрне атау максатында фигыль сүз төркеменә караган сүзләр дә ясап карады. Аларның кайберләре шактый уңышлы булды, ә кайберләре артык ясалмалылык үрнәге генә булдылар.

*-ла/-лә,-лый* кушымчалары белән ясалган сүзләр: *конвертлау, якынлау.* Мәсәлән: *Башка сүз таба алмады, иртә торгач, бу хатны к о н в е р т л а д ы да кесәсенә тыкты* [1, б. 87]. *Аяклар һаман я к ы н л ы й л а р. Инде күбәйделәр* [1, б. 429]. Язучының *конвертлау* фигылен куллануын бу сүз белдергән төшенчәне перифрастик төзелмә аркылы белдерү мөмкинлегенә альтернатива эзләве белән аңлатып була. Чагыштыр: *конвертлады – конверт эченә салды* яки *пичәтләде – пичәт куйды.* Бу ике фигыль формасы да гомумхалык телендә кулланыла алалар һәм әдәби тел берәмлекләре булырга хаклылар. Язучы *якынлыйлар* фигыль формасын язма сөйләмдә кулланган. Билгеле, ул *якынлашалар* фигыленә мәгънәдәш булып тора. Безнең карашка, *якынлыйлар* формасы да хәрәкәтне хәзерге планда объектив чагылдыра ала.

*-лан/-лән* кушымчасы белән ясалган сүзләр: *оялчанлану, кызулану, дуслану.* Мәсәлән: *Ул (Хәбип) икәнен белгәч, башта кайдан башларга сүз тапмый калдылар, Хәбипнең сорауларына да тартынып, о я л ч а н л а н ы п, кыска, кыюсыз җаваплар бирделәр* [1, б. 222]. *Хәбип белән Разия электән үк якын дуслар. Качкынның бунтарь характеры кызга ошый, ул Мансуровның теленнән дә бераз курка. Шуңа күрә дә ныграк д у с л а н ы р г а тели иде* [1, б. 298]. Беренче җөмләдәге *оялчанланып* хәл фигыле формасы ясалма сыйфатка сүз ясагыч *-лан* аффиксы ялганып ясалган (оял-*чан*). Барлыкка килгән бу хәл фигыль формасы артык ясалма буларак кабул ителә. Безнең карашка, фигыль нигезенә *-ып* кушымчасы ялганып ясалган хәл фигыль формасы оялу халәтен дөресрәк, адекват рәвештә белдерә һәм гомумхалык телендә актив кулланыла да. Икенче җөмләдәге *дусланырга* ясалма фигыле язучы куллануында сәеррәк булуы белән игътибарны җәлеп итә. Дуслык мөнәсәбәте ике яки аннан күп сандагы затлар арасында урнаша һәм ул контаминацияләнгән фигыль ясагыч *-лаш* кушымчасы белән белдерелә: *дус-лаш-ырга.* Бу кушымчаның *-ш* компоненты фигыльнең уртаклык юнәлешен формалаштыра да инде. Шуңа күрә *-лан* кушымчасы белән фигыль һәм аның уртаклык юнәлеш формасын ясау отышлы түгел дияргә генә кала.

*-ай* кушымчасы белән ясалган сүзләр: *мулая*. Мәсәлән: *Җәй кәсеп итеп, бераз акча таба торган булгач, бигрәк дәрәҗә зураю, мантыйкхан (укучы) булу сәбәпле керәчәк хосуллар (керем, садакалар) да м у л а я башлаган иде* [1, б. 232]. Ф.Ә. Ганиев раславынча, *-ай/-әй* кушымчасы хәзерге вакытта сүз ясамый торган типка карый [2, б. 140, 144]. Бу кушымча сыйфатларга, сирәк кенә рәвешләргә, исемнәргә, ияртемнәргә ялганып, фигыльләр ясауда катнаша. Югарыдагы мисалда бу кушымча, *мул* сыйфат нигезенә ялганып, ясаучы нигездә күрсәтелгән билге алуны һәм аның ишәюен белдерә: *мул-ай-а* (орфограф. *мулая*). Гомумхалык телендә *мулая* фигыле белдергән төшенчә перифрастик фигыль формасы белән белдерелә һәм ул керем, садакаларның арта бару процессын динамикада төгәлрәк бирә ала (*мул була башлаган иде*).

Теге яки бу сүзне бер телдән икенче телгә кисәкләп, ягъни морфемалап тәрҗемә иткәндә, бер бөтен сүз барлыкка килә. Мондый юл белән сүзләр ясауны калькалаштыру дип атыйлар. Калькалаштырганда, чит сүзнең төзелеше һәм мотивировкасы кабул ителә [3, б. 79–80]. Мәсәлән: *водоросль – суүсем, земной шар – җир шары, ледокол – бозваткыч* һ. б.

Г. Ибраһимов «Безнең көннәр» романында рус телендәге сүзләрнең шактый уңышлы калькаларын да ясап карады. Мәсәлән:

*өй хатыннары* – домохозяйка: *Водопровод та тукталачак икән дип, өй хатыннарының котларын очыра* [1, б. 8];

*көл савыты* – пепельница: *Графин белән су куелган, аның янында бер стакан, көл савыты* [1, б. 90–91];

*идән асты* – подполье: *Менә ничә ел инде ул (Гәрәй Солтан) идән астында яши* [1, б. 296]. Безнең карашка, язучының бу сүзьясалыш калькасы уңышлы түгел, чөнки *идән астында яши* сүзтезмәсе татар телендә логик-грамматик яктан *качып-посып, яшеренеп яши* сүзтезмәсе аркылы белдерелә, шуңа күрә мондый кальканың кирәге юк дәрәҗәсендә.

Язучы ярымкалькалар да кулланган: *тимер дружиналар* – железные дружины. Мәсәлән: *Кичә хәбәр бар иде: эшчеләр тимер дружиналар төзегән имеш, демонстрациягә, җыелышларга коралланып чыгалар имеш, диделәр* [1, б. 16]. Әсәрдә шулай ук түбәндәге тулы һәм ярымкалькалар кулланылганнар: *кунаклык ягы* – гостиная, *ятак бүлмәләр* – спальни, *контрхәрәкәт* – контрдействие, *күзәтчелек* – наблюдение, *саклы*к – осторожность, *көнлекче* – подёнщик һ. б.

Шулай итеп, Г. Ибраһимов «Безнең көннәр» романында төшенчәләрне тулы һәм төгәл белдерү максатында сүзләр һәм аларның формаларын, рус телендәге сүзләрнең калькаларын ясап карый. Әйтергә кирәк, аларның шактый өлеше логик-грамматик яктан дөрес һәм уңышлы төзелгән. Шуның белән бергә язучы ясаган сүз һәм сүз формаларының кайберләре артык ясалма килеп чыккан, алар тәҗрибә үрнәге булып кына саналырга тиеш.

ӘДӘБИЯТ


1. Галимҗан Ибраһимов. Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. 4 т. 465 б.

2. Ганиев Ф.Ә. Хәзерге татар әдәби телендә сүзьясалышы. Казан: Мәгариф, 2009. 271 б.

3. Сафиуллина Ф. С., Зәкиев М. З. Хәзерге татар әдәби теле: Югары һәм урта уку йортлары өчен дәреслек. Тулыл. 2 нче басма. Казан: Мәгариф, 2002. 407 б.


## ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫҢ «ЯШЬ ЙӨРӘКЛӘР» РОМАНЫНДА КҮТӘРЕЛГӘН ЧОР ПРОБЛЕМАЛАРЫ


***Хәйруллина Ә.С., Даутов Г.Ф.***



Изучение творчества классика татарской литературы Г. Ибрагимова до сих пор остается актуальным. В статье рассматривается его роман «Молодые сердца». В нем поднимается национальная тема, присущая истории начала XX века.

The study of creativity of the classic of Tatar literature G. Ibragimov is still relevant. The article discusses his novel «Young hearts». It raised a national issue inherent to the history of the early twentieth century.

XX йөз башы татар әдәбият кайнап аккан язгы ташу кебек гаять интенсив үсеш кичерә. Әдипләр, тасвирлау һәм сурәтләү чаралары, тема яңалыгы эзләп Шәрыкъ әдәбиятына да, рус мәдәниятенә дә мөрәҗәгать итәләр. Кечкенә кеше, аның күңел дөньясына мөрәҗәгать итү көчәя, М. Гафури, Ш. Камал кебек каләм әһелләре игътибарларын гади кеше кабул ителешендәге дөнья сурәтен үзәккә куеп иҗат итә башлыйлар. Бу уңайдан Г. Ибраһимов иҗаты аерым урын алып тора.

Шуны искәртеп үтик: XX йөз башында һәр татар әдибе язучылык эшчәнлеген мәгърифәтче буларак башлаган. Г. Ибраһимов та бу кагыйдәдән читтә калмый. Аның 1907 елда язылган «Зәки шәкернең мәдрәсәдән куылуы» хикәясе тулысынча ул вакытта иң актуаль булган уку-укыту, аның ысуллары, проблемасына, мәктәп-мәдрәсәләребезнең заманнан артта калган булуын тәнкыйтьләүгә багышланган. Ләкин талантлы әдип мәгърифәтчелек кысаларында гына чикләнеп кала алмый, ул күп укый, эзләнә һәм шуның нәтиҗәсе буларак 1911–1912 елларда, аның әдәби кыйммәте ягыннан бер дәрәҗә югары торган, романтик рухтагы «Йөз ел элек» (1911), «Карак мулла» (1912) әсәрләре дөнья күрә. Язучының бу чор тормышы турында И. Нуруллин болай дип күрсәтә: «Мәгълүм булганча, Г. Ибраһимов 1909–1910 елларда әдәбияттагы, аеруча поэзиядәге үгет-нәсихәтчелеккә, риторика һәм рационализмга каршы ярсулы көрәш башлаган иде. Мавыгып китеп, үзе дә сизмәстән, беркадәр «сәнгать – сәнгать өчен» теориясенә якын фикерләр әйтүен инкяр итеп булмый [2, б. 161]. Ләкин бу мавыгулар тиз уза һәм әдип әдәбият мәйданына чын әдәби шедеврын – «Яшь йөрәкләр» романын чыгара. «Яшь йөрәкләр» – диелә «Татар әдәбияты тарихы»ның III томында, Ибраһимов татар әдәбиятында психологик роман жанрын башлап җибәрде» [3, б. 343].

Әдип үзе дә, бу әсәренең эзләнүләр, газаплы уйланулар юлы, шул юлда ялгышулар нәтиҗәсе буларак яралганлыгын искәртә: «Егерменче гасырның башларынача без борынгыча яшәдек. Хәзер татар уянды. Яшәү юлында яңалыклар эзли башлады. Безнең хәятнең хәзерге көннәре – искелек җимерелеп, яңалык мәйдан ала башлаган бер дәвер. Бу дәвердә картраклар борынгы уйны, борынгы хәлләрне сакларга, яшьләр аны ватарга, җимерергә, яңа рәвешчә яшәргә тырышалар. Ике арада көрәш бара, бу көрәш 1905 елдан соң аеруча куәт алды.

«Яшь йөрәкләр» – бер роман. Анда шул искелек белән яңалыкның көрәшү дәверендәге хәлләр төрле каһарманнар аркылы тасвир ителгәннәр» [1, б. 75].

Әйе, романда искелек белән яңалык көрәше дә, аталар һәм балалар каршылыгы да бар. Күргәнебезчә, язучы үзе дә моны таный. Ләкин бу сүзләрнең 1918 нче елда, большевикларның «Кто не с нами, тот против нас» дигән принципны тормышка ашырып, бөтен яшәешне сыйныфлар каршылыгы теориясе аркылы аңлатып, дөньяны бик гади, аклы-каралы, дөресрәге, аклы-кызыллы, бай-ярлы призмасы аша гына кабул итеп яши башлаган вакытлар дип әйтелгәнен истә тотыйк. Шуңа күрә, Г. Ибраһимовның үз әсәрен дә шулай гадиләштереп, искелек-яңалык көрәшенә генә кайтарып калдырып аңлатуын, чор вәзгыятенә иярү дип кабул итәргә кирәктер.

Чынлыкта исә «Яшь йөрәкләр» күпкә катлаулырак, тирәнрәк һам тормышның үзе кебек гади схемаларга гына сыеп бетми торган, мәңге актуаль булып, һәр чор укучысын борчыган мәсьәләләрне күтәрүче әсәр.

Романны укый башлауга игътибарны җәлеп иткән нәрсә – образларның тормышчанлыгы. Икенчесе – әдипнең тәфсилләп, ямен һәм тәмен белеп, иренмичә, хәтта ки, сокланып, яратып татар тормышын, татар яшәешен сурәтләве. Мәсәлән, солдат хезмәтенә алынучы егетләрнең хәрби оешмага каралырга бару күренешен алыйк. Монда төрле төбәктән, төрле милләт вәкилләре җыелган. Язучы аларның һәрберсен диярлек сурәтләп үтә: «Русларның бик гади кыяфәттә булулары да, Зыяның диккатен алды. Чынлап та, буларның никрутлары да һичбер күвәзлек (көязлек) күрсәтми: авылында, гади вакытта ничек булса, монда да шулай: шул фуражка, шул кара чикмән, шул күн итек яисә ыштыр белән зур чабата». Чуаш белән мукшы халкына да урын бирелгән, болар: «Баштанаяк кара сарык йонына уралган, кысык күзле, үлек йөзле, кыска буйлы вә бөтен тирә-ягына, булса да ярый, булмаса да ярый – безгә барыбер, дип йөргәндәй вә, шуның илә бәрабәр, бөтен торышлары исә кемнәндер куркып иелгән…, бичара шикелле тоелган бу басынкы бәндәләргә карасаң, тагы башка бер халык күргәнеңне сизәсең». Төгәл характеристика, ачык картина, һәр халыкка хас сыйфатлар ике-өч җөмләгә сыйдырылган. Ә менә татар никрутларын тасвирлаганда, әдип сүзләрне дә, эпитетларны да кызганмый, әдәби сүз куәтенә тулы ирек бирә. Болай башлап китә ул алар турындагы сүзне: «Иң әүвәл күзгә чалына татар никрутлары» [1, б. 132]. Егетләр хәтәр, …. «Һичбере гади киемдә түгел», ул шәп икәнлеген үзе дә белә, шуңа күрә, «… кырык тиенлек бәйләм бүрекне маңгайга кырын салганнар». Дөрес, «такыр баш өши, колак ут кеби яна, ләкин аңа илтифат итми, чөнки күвәз». Кайчандыр дөнья тоткан, бар кыйтгаларны үзе белән санлашырга мәҗбүр иткән, әллә ничә империя төзегән халык вәкилләре икәнлеге күренеп тора, никрут егетләребез, дөрес, тарихтан хәбәрдар түгел, ләкин кан, Дәрдемәнд әйткән сөт (сөт калыр / Ватан китәр!) калган. Генетик хәтер әле дәүләтчелекне, башка халыклар белән билгә таянып сөйләшкәнне, Идел-Йортның имин чагын, җаннарның гаярьлеген хәтерли. Без ким түгел җирдә һичкемнән!, шуңа күрә егетебез, «…яшерен тарткан махоркасы урынына, каралырга килгәч, егермесе биш тиенлек папирос алган. Шуны, һичкемнән шикләнмичә, ике бармак арасына кыстыра да, төтен вә барлык тартуын «гаспадаларча» чыгарырга тырышып, бик һавалы вә эре кыйлана; аның бөтен торышы дөньяга югарыдан карап:

– Күрәмсез? Мин – кем? – дип тора» [1, б. 133].

Төп геройларның берсе Зыя, гади фигура түгел. Ул – колонизациядәге халыкның фаҗигасен күрсәтүче образ. Зыя – искиткеч сәләткә ия. Ул музыка белән яши, яхшы музыка ишетер өчен хәтта фахешханәгә бара, атасының тыюына карамастан төрле коралларда уйнарга өйрәнә, хәтта, яшереп кенә өйләренә дә алып кайта. Үз милли дәүләте, үз хөкүмәте карамагындагы консерваториясе, милли музыка мәктәбе булса, Зыя әллә нинди биеклекләргә ирешер, дөньякүләм танылган музыкант булып, татар милләтенә хезмәт итәр, аны бар галәмгә яңгыратыр һәм танытыр иде. Ләкин, аһ, дәрига! андый мөмкинлек юк, татар, әйдәп баручы укымышлы катламы, морзалары, юк ителгән, игенчеләр даирәсенә әйләндерелгән булганга, егетебезнең сәләтен тормышка ашыру мөмкинлеге юк, ул бетәргә, үләргә, юкка чыгарга дучар ителгән. Искиткеч сәләт, сирәк очрый торган талант, кулланылыш даирәсе булмаганлыктан, ишетелмичә кала. Һәм бик күп андыйлар. Г. Исхакыйның «Мулла бабай» романында да китапка гашыйк, җир дөньясыннан аерылган, шуңа күрә бик фәкыйрь тормышта яшәүче хәзрәт образы бирелә…

Татар әдәбиятында морзаларга мөнәсәбәт бик әйбәт түгел. Г. Исхакыйның «Көз» повесте, М. Галәүнең «Мөһәҗирләр»ендәге улын дәүләти вазифа алыр өчен чукынырга өндәгән Гәрәй морзаны искә төшерү дә җитә. Әдипләребез морзаларны байлыкларын саклап калу өчен диннәрен алыштырган, димәк, милләткә хыянәт иткән тарихи сыйныф буларак кабул иткән, ахрысы. Ләкин «Яшь йөрәкләр»дәге Гәрәй морза, Зыяның сөйгәне Мәрьямнең әтисе, данлы вә шанлы вакытлардагы олпатлыкны, ханнарга хас затлылыкны саклап калган кеше буларак тәкъдим ителә: «Ул гомерендә дәүләт хезмәтләреннән һичберен алмады, ил тарафыннан сайланып куелган урыннарны да рәд кыйлды, шулай булса да, тирә-якның зур эшләре Гәрәй морзага киңәштән, аның ишарәсеннән башка эшләнми иде. Ул үзен малдан, акчадан югары тота – шуңа күрә бик юмарт та. Халык юмартлыкка мисал урынында «Гәрәй морза кебек һиммәтле» дип сөйлиләр» [1, б. 95].

Гомумимәштереп шуны әйтергә мөмкин: романдагы һәр образ зур тарихи-иҗтимагый гәүдәләнешкә ия. Сабир, Чеховның «Чия бакчасы»нда тасвирланган буржуазиянең сәяси-иҗтимагый мәйданга килү процессын күрсәтүче булса, Мәрьям, шул вакыттагы татар хатын-кызларының олы тормыштан читтә, үз дөньялары белән яшәүләрен, шуңа күрә, практик тормышка әзер булмауларын ача. Димәк, безгә әле «Яшь йөрәкләр» романын яңадан укып, бөтен тирәнлегендә ачарга кирәк.


ӘДӘБИЯТ

1. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. 2 т. 476 б.
2. Нуруллин И. XX йөз башы татар әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. 285 б.
3. Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. 3 т. / том. ред. Халитов Г.М., Гыйззәтуллин Н.Г., Әхмәдуллин А.Г. һ.б. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 598 б.


## ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ҺӘМ КЕДРА МИТРЕЙ ИҖАТЛАРЫ ЧАГЫШТЫРМА ПЛАНДА


***Хәкимова В.Х.***



В работе впервые показано творчество Галимджана Ибрагимова и удмуртского писателя Кедра Митрея в сопоставительном плане.

For the first time shown creativity and Galimdzhan Ibragimov Udmurt writer Cedar Mitrea in comparative terms.


Төрки һәм угро-фин халыкларының тарихи бергәлеге, керешеп – аралашып яшәүләре аларның телләренә, халык авыз иҗатларына һәм әдәбиятларына да сизелерлек йогынты ясаган. Ләкин бүгенге көнгә кадәр татар һәм удмурт халыклары әдәбиятларын аларның күренекле язучылары иҗатлары нигезендә чагыштырма планда фәнни югарылыкта анализлап язылган аерым хезмәтләр юк дәрәҗәсендә.

Шул максат белән язылган бу мәкаләбездә татар әдәбияты классигы, энциклопедист – галим, күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, Хезмәт Герое Галимҗан Ибраһимов (1887–1938) һәм удмурт әдәбиятына нигез салучыларның берсе Кедра Митрей (бу аның тәхәллүсе, тулы исеме – Дмитрий Корепанов (1892–1949) иҗатларын татар һәм удмурт әдәбиятлары

контекстында чагыштырма планда өйрәнеп, типологик охшаш һәм үзенчәлекле якларын билгеләргә, әсәрләрендә күтәрелгән гыйлемлелек мәсьәләләрен яктыртырга булдык.

Моның өчен XIX йөз ахыры XX йөзнең беренче яртысына кадәрге вакыт аралыгын алдык. Бу чор татар әдәбияты тарихы үсешендә реализмга таба борылыш, яңа чор башлану булып бәяләнә. Бу үзгәрештә Г. Ибраһимов та мөһим роль уйный, ул әдәбиятыбызга яңа сулыш өрә. Беренче әсәрләрендә үк мәгърифәт мәсьәләләре күтәрелә, татар җәмгыятенең кайбер якларын тәнкыйть утына тота.

XX йөз, гомумән, татар һәм удмурт халыклары өчен аеруча катлаулы чор. Аның үзенчәлеге тарихи вакыйгалар белән бәйле. Гасыр башында булган инкыйлаблар, үзгәртеп корулар милләтләр язмышына да көчле йогынты ясый. Шуңа күрә бу чорда әдәбиятта дөнья сурәте тулысынча үзгәрә, кешенең гаделлекне, мәрхәмәтлелекне, кешелекне яклавы киң чагыла. Милләт язмышы, аның рухи кыйммәтләре алгы планга чыга.

Кедра Митрей – удмурт әдәбиятында, сәнгатендә, тарихында аерым бер урын алып торган олуг шәхес. Классик әдипнең иҗади эзләнүләре удмурт халкы рухи байлыгының аерылгысыз өлешен тәшкил итә.

Нәкъ менә Г. Ибраһимов һәм Кедра Митрейны алуыбыз сәбәпләрен түбәндәгечә дәлилләргә мөмкин булыр иде:

а) Г. Ибраһимов һәм Кедра Митрейның яшь аермасы аз, алар бер эпохада яшәгәннәр;

б) биографияләрендә һәм һәртөрле эшчәнлекләрендә шулкадәр зур охшашлык, бер шәхес турында сүз бара, диярсең;

в) икесенең дә дөньяви күзаллауларында һәм шуның чагылышы буларак иҗатларында типологик охшашлыклар зур;

г) икесенең дә гомер юллары драматик тәмамлана, икесе дә репрессия корбаннары.

Максатка ирешү юлында түбәндәге бурычлар билгеләнде һәм тормышка ашырылды:

1. Г. Ибраһимов һәм Кедра Митрей иҗатларын өйрәнеп, алар турындагы фәнни әдәбиятка күзәтү ясадык;

2. Чордаш әдипләрнең бер үк жанрдагы, тематик яктан охшаш әсәрләрен сайлап алып, иҗади эзләнүләрендәге уртаклыкларны ачыкларга тырыштык;

3. Язучыларның биографияләре һәм аларның иҗатлары, иҗтимагый вакыйгалар белән бәйләнешен торгызырга омтылдык;

4. XX йөз башы әдәбиятларында өстенлек алган ике юнәлеш – революцион-романтик һәм тәнкыйди реализм юнәлешләре бу ике язучының да тоткан кыйбласы икәнлеген билгеләдек.

Г. Ибраһимов һәм Кедра Митрей иҗатлары татар һәм удмурт әдәбиятлары белгечләре тарафыннан җентекләп өйрәнелә. Әмма чагыштырма метод безгә икенче күзлектән карарга ярдәм итә. Моңа кадәр билгеле булмаган детальләрне ачыкларга, охшаш моментларны билгеләргә булыша.

Бу ике язучының иҗатларының якынлыгы тагын географик фактор белән дә аңлатыла ала: биредә Идел – Кама регионы турында гына сүз бармый, ә ике язучының да милли үзаңнары һәм шәхес буларак Казанда формалашуларын ассызыклап билгеләп үтү кирәктер. Икесенең дә иҗатлары биредә чәчәк ата, гаделсезлекләргә каршы көрәш, диннең үзен түгел, ә дини

догмаларны кабул итмәү, акыл, гыйлем һәм мәхәббәт культларына өстенлек бирүләре ачыклана.

Бу ике язучы арасындагы охшашлык аларның иҗатларындагы жанрлар системасында аеруча киң чагылыш таба (автобиографик хикәя, повесть, роман, тарихи драма һ.б.). Лирик текстлар Г. Ибраһимовта да, Кедра Митрейда да юк, әмма лирика эпик һәм драматик әсәрләре тукымасында тупланган. Алар икесе дә фольклор традицияләрен уңышлы файдаланалар.

Г. Ибраһимов һәм Кедра Митрей әдәбиятта милли рамкалар кысасында гына калмыйча, рус һәм европа әдәбиятлары классиклары казанышларына да йөз тоталар, аларның иҗатларын тирәнтен беләләр, үз иҗатларында уртак фикерләрне чагылдыралар.

Г. Ибраһимовның да, Кедра Митреййның да сәнгатьле күзаллаулары реализм һәм милли романтизм синтезына нигезләнә, шуңа бәйле рәвештә аларның типологик һәм индивидуаль язу үзенчәлекләре ачыклана. Халыкның күп гасырлык тормыш тәҗрибәсе, аның фәлсәфәсе, әхлак нормалары һәм морале, дин чагылышы – үзләрнең тамырлары белән тирән тарихка барып тоташучы бу реаль кыйммәтләр һәр ике авторга да үз әсәрләрен иҗат итүдә чыганаклар булганнар. Ләкин бу ике язучының максатлары төрле: аларның икесе өчен дә әсәрләрендә үз милләте язмышы, үз халкы тарихы өстенлек алу хас. Г. Ибраһимов һәм Кедра Митрей бер-берсеннән нәкъ шуның белән аерылып торалар.

Кыска гына чыгышымда мин үзләреннән бай мирас калдырган бу ике язучы, әдәбият галиме, тәнкыйтьче һәм тел белгечләренең иҗатларын тулысынча анализлауны максат итеп куймадым. Ә Г. Ибраһимов һәм Кедра Митрейның автобиографик әсәрләре «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы», «Авыру гасыр балалары» хикәяләренә тукталмакчы булдым.

Автобиографик жанрның дөньяга чыгуы өчен гасыр башы уңайлы тарихи җирлек әзерли. Татар әдәбияты белемендә беренчеләрдән булып системалы рәвештә бу жанр хасиятләрен өйрәнүче һәм фәнни яктан нигезләүче Казан Федераль университеты доценты Г.Р. Гайнуллинаны билгеләп үтәргә кирәк. Автор Көнчыгыш һәм Көнбатыш традицияләренең йогынтысында татар мемуаристикасының синтентик эволюциясен ача, 1960–1970 елларда иҗат ителгән автобиографик әсәрләрне комплекслы тикшерә. Язучының иҗат лабораториясен «автор – лирик герой» бәйләнешендә өйрәнеп, галимә татар автобиографик әсәрләренең тибын, поэтикасын, төп идея – тематик, стилистик үзенчәлекләрен билгели.

Удмурт әдәбият белемендә XIX йөз ахыры XX йөз башларында автобиографик жанрның беренче адымнары ясала дип исәпләнә. Ул удмурт әдәбиятына нигез салыну белән дә бәйле. Моңа кадәр легендалар, мифлар, җыр иҗаты тәшкил иткән башлангыч шулай итеп әдәби автобиография элементлары булган жанр белән керешеп итә.

Шул заманда яшәп иҗат иткән татар әдәбияты классигы Г. Ибраһимов һәм удмурт язучысы Кедра Митрей автобиографик жанрга ихтыяҗны сизеп, үзләренең әсәрләрен язалар. Г. Ибраһимовның «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы», Кедра Митрейның «Авыру гасыр балалары» әсәрләре язучыларның үз тормышларыннан алынган. Без беләбез: иске тәртипләр белән килешмәве аркасында Галимҗан шәкертне башта Оренбург мәдрәсәсеннән, аннан соң Уфадагы «Галия» мәдрәсәсеннән куалар. Ә Кедра Митрей шундый ук язмышка Казандагы семинариядән куылгач дучар була.

Бу ике язучының да башлангыч чор иҗатларында ук гыйлем алу, гыйлемлелек мәсьәләләре күтәрелә. Дини уку йортларында укучы шәкертләрнең гайре табигый хәлдә яшәве, аларга тиешле белем бирелмәве, белемнәре җитәрлек булмаган укытучыларның яшь буынның вакытын юкка әрәм итүе әсәрләрдә куе буяулар белән тасвирлана. Бу хикәяләрдә кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр, тормыш гаделсезлекләрнә каршы чыгу, иректе шәхес идеясе беренче планга куела. Идеаллары җимерелгән автор – герой аша җәмгыятькә бәя бирелә. Әмма Г. Ибраһимов та, Кедра Митрей да үзләренең иҗатларында үз халыклары күңелендә тирән урнашкан дин фәлсәфәсе белән бәйле рухи-әхлакый кыйммәтләрне һәрвакыт зурлап тасвирлыйлар. Ә бу хикәяләрендәге геройларның уйларын, тойгыларын ачып салу, аларны төрле хәлләрдә сурәтләү авторларга шәхесләрнең рухи якларын ачарга ярдәм итә. Әдәби геройларның рухи дөньясында халыкка хас әхлакый сыйфатлар чагылыш таба. «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы», «Авыру гасыр балалары» хикәяләре авторлары берьюлы һәм объект, һәм субъект ролен үтиләр. Шул сәбәпле үткәннең һәм бүгенгенең вакыт катламнары янәшә тора. Автобиографик әсәр язучыларны берләштерүче уртак сыйфат – хакыйкатьне ачыктан-ачык әйтеп бирү максаты була. Халык язмышы проблемасы төп урынны били, Акыл, Гыйлем культы сизелә. Һәр икесе дә борынгы тамырларны, борынгы мәдәниятне зурлыйлар. Һәр ике язучының да әсәрләрендә төп геройлар – иҗтимагый тирәлек белән килешмәүче шәхесләр. Әмма геройлар социаль тәртипләрне үзгәртеп кору юлларын реаль тормышның үзеннән эзләмиләр, ә романтик идеалны аңа каршы куялар. Ике әсәрдә дә зыялыларның халыкка аң – белем таратудагы роле – төп проблема. Бу әсәрләрдә авторларны темалар охшашлыгы гына түгел, аларны тормышка ашыручы принциплар да якынайта. Социаль проблематика улкадәр өстә ялтырап ятмаса да, «кечкенә кеше», аның рухы, фикерләве белән яшәешнең болай дәвам итүе мөмкин булмаганы, җәмгыятьтә зур үзгәрешләр көтелгәне аңлашыла. Һәм «кечкенә кеше» бөтен кешелек белән кушылып китә, үзенең уйлары, эше-хәрәкәте белән мәңгелек проблемаларны хәл итүдә катнаша.

XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар һәм удмурт әдәбиятлары үсешен тулырак күзаллау өчен Г. Ибраһимов һәм Кедра Митрей иҗатларын, аларның әдәби мирасларын чагыштырма өйрәнү, әсәрләрендәге проблематика һәм сәнгати үзенчәлекләрен ачыклау зарур. Чор арты чор узса да, бу язучылар күтәргән идеяләр, милли үзенчәлек символына әйләнгән рухи бөтенлек, яңалык һәм яңарыш хәрәкәтен бик күп әдипләр хуплап каршы алдылар, үзләренең әсәрләрен иҗат иттеләр. Г. Ибраһимов һәм Кедра Митрейның үткен каләмнәре тудырган милли үзенчәлекләр, әсәрләрендәге кеше һәм аның иҗтимагый шартларда гәүдәләнеше, шәхес иреге, тирәлек һәм аңа мөнәсәбәт һ.б. күп кенә күтәрелгән мәсьәләләр башка язучыларга да уңдырышлы җирлек хезмәтен үтәде. Иҗатлары татар һәм удмурт әдәбиятларының дөнья әдәбияты контекстына кушылуына нигез булып торды. Үз халыклары әдәбиятларында беренче башлап йөрүче, җәмгыять тормышында лидерлар булган бу ике язучының әсәрләре дистә еллар дәвамында күпмилләтле Россия әдәбиятыннан алып ташланган, читләштерелгән иде. Ә бу ак тапны тутыру заман фәнни тикшеренүчесенең бурычы, ул яңа рецептив теорияләр белән коралланган булырга тиеш.

ӘДӘБИЯТ

1. Взаимосвязи и взаимодействие литератур мира: Библиогр. указ. (1961-1965). Ч. 1–2. М., 1968; Библиогр. указ. (1966- 1970). Ч. 1–2. М., 1973; Библиогр. указ. (1981-1985). Ч. 2 / сост. И.Н. Исаева. М., 1988. 194 с.

2. Бахтин М. М. Автор и герой в эстетической деятельности (эстетика словесного творчества). М.: Искусство, 1986. 444 с.

3. Ибрагимов Г. Сочинения в восьми томах. I том. Рассказы (1907–1929). Казань: Татар. кн. изд-во, 1974. 509 с.

4. Кедра Митрей. Дитя больного века. Отрывки из повести Избранное / предисл. А. Ермолаева. Ижевск: Удмуртия, 1965. С. 140–200.

5. Опаленный подвиг батыра. Жизнь и творчество Кедра Митрея. Воспоминания, статьи, письма, посвящения и произведения Кедра Митрея / сост. З.А. Богомолова. Ижевск: Удмуртия, 2003. 352 с.

# Г. ИБРАҺИМОВ ХИКӘЯЛӘРЕНДӘ ХРОНОТОП ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

***Хәлиуллина А.Г.***

Статья посвящена исследованию проблемы художественного хронотопа в рассказах Г. Ибрагимова. На основе изучения рассказов делается вывод, что категории пространства и времени позволяют писателю четко выделить основные сюжетные узлы произведения. Описываемые в рассказах события развиваются в нескольких пространственно-временных планах, а сам хронотоп характеризуется многомерностью.

The article is devoted to the study of the problem of the artistic chronotope in the stories of G. Ibrahimov. Based on the study of stories, it is concluded that the categories of space and time allow the writer to clearly identify the main plot of the work. The events described in the stories develop in several space-time plans, and the chronotope itself is characterized by multidimensionality.

Әдәби материал нигезендә урын һәм вакыт берелешен ачыклау әсәрдәге вакыйгалар эзлеклелеген, аның корылышын өйрәнүгә генә торып калмый, идея-эчтәлеген тагын да тирәнрәк аңлауга, язучының эстетик бәясен тоюга хезмәт итә. Әдәби әсәрдә чагылдырылган бербөтен урын һәм вакыт хакындагы күзаллау хронотоп буларак билгеләнә [1, б. 214]. Хронотоп теориясенең нигезләре М.М. Бахтин тарафыннан эшкәртелә. Урын һәм вакыт берелеше әсәрдә сурәтләнгән вакыйгаларны конкретлаштыра төшә, чор картинасын, вакыйгалар барган урынны төгәлләү мөмкинлеген булдыра. Системалы оештырылган урын һәм вакыт әдәби әсәрнең «эчке сурәтләнгән дөньясын» (Д.С. Лихачев) күзалларга ярдәм итә. Хронотоп урын һәм вакыт бәйләнешен, кушылу үзенчәлеген бирүдән тыш, М.М. Бахтин билгеләвенчә, аларның образлы чагылышын да өйрәнә.

Әдәби урын һәм вакыт берелеше Г. Ибраһимовның хикәяләрендә дә кызыклы күзәтүләр ясарга мөмкинлек бирә. Белүебезчә, Казан шәһәрендә яшәгән беренче чорда (1909–1912) язучы иҗатында күренекле урын тоткан бер төркем романтик эчтәлекле хикәяләр языла («Яз башы», «Диңгездә», «Йөз ел элек», «Сөю – сәгадәт», «Уты сүнгән җәһәннәм» һ.б.). Табигать күренешләрен сурәтләүдәге осталык, геройларның күңел кичерешләрен бирүдәге психологик нечкәлек, вакыйгаларны корудагы маһирлык, телсурәт чараларының муллыгы – язучы каләменә хас төп сыйфатлар.

Әсәрдәге әдәби урын һәм вакытны билгеләү максатыннан Г. Ибраһимовның 1911 елда иҗат ителгән «Диңгездә», «Йөз ел элек», «Сөю – сәгадәт», «Уты сүнгән җәһәннәм» хикәяләре игътибар үзәгенә алынды. Әлеге әсәрләрдә үзәк геройның күңел дөньясына, аның кичерешләренә, уй-фикерләренә зур урын бирелә. Һәр хикәя үзәгенә алынган вакыйга геройның тормышка карашлары, үзенә һәм башкаларга карата бәяләмә кебек кабул ителә. Кешенең табигать баласы булуына, табигыйлек кануннары буенча яшәргә тиешлегенә басым ясавы Г. Ибраһимов иҗатында руссочыл карашларның чагылышын да ачык күрсәтә [6]. Табигать һәм җәмгыять, мәдәни шәһәр һәм авыл каршылыгы Ж.-Ж. Руссодан башлангыч алган романтик традицияләр белән көчәйтелеп, тагын да калкурак итеп бирелә.

Нигездә бу төркем әсәрләрдә әдәби вакыт һәм урын ике катламга: тышкы (объектив) һәм эчке (субъектив) катламнарга бүленә. Хикәядә әйдәп баручы перцептуаль хронотоп вакыйгаларны үткән, бүгенге һәм киләчәк арасында урнаштыра, геройның «тышкы» һәм «эчке» тәҗрибәләренең синтезы рәвешендә тәкъдим ителә. Шуны да аерым билгеләргә кирәк, алда телгә алынган хикәяләрдә тарихи вакыттан бигрәк («Йөз ел элек» хикәясендә тарихи вакыт ачык билгеләнелә), психологик вакыт алгы планга чыга, вакыйгалар вакыт киңлегеннән бигрәк аның чиклелегенә нигезләнә. Әдәби вакытны кору, вакытның вакыйгаларны әйдәп баруы әсәрләрдәге динамиканы көчәйтә. Мәсәлән, «Диңгездә» хикәясендәге кабатланып килүче «Без һаман барабыз» җөмләсе реаль вакыйгалар белән хикәяләү герой сөйләгәннәрне бер ноктада кисештерә.

Хикәяләрдә геройларның хәтирәләренә алып кереп киткән юллар әсәрдә бирелгән пространствоның төп компонентларын алдан ук билгеләп тә куя шикелле. «*Мин өебезнең бакчага караган тәрәзәсе аркылы зур күл артына батып барган олуг кояшка карап хыялга батам*» («Сөю – сәгадәт»). Яки «*Өйдә һичбер тавыш-тын юк. Мин һаман шул урында, шул хәлдә ялгызмын; тик хыялым гына каршымда*» («Уты сүнгән җәһәннәм»). «*Карыйсың да үзеңне, дөньяңны онытасың, хыялың гүя сине икенче дөньяларга, матурлык, изгелек белән, шигърият белән тулган яңа илаһи галәмнәргә алып китә. Йөрәгеңне ташка әйләндергән авыр газаплар, башны чуалткан зур, кечек борчулар кодрәт белән алынып ташланалар, тирән мәсгудият эченә чумасың*» («Диңгездә»). Хыял, билгеле булуынча, алга әйдәү көченә ия, чөнки ул киләчәк компоненты буларак карала. Хыялда туган вакыйга һәм күренешләр алга төбәлгән булулары белән янәшә хәтирәләр рәвешендә үткәнгә дә әйләнеп кайту сыйфатына ия. Тик Г. Ибраһимовның «Уты сүнгән җәһәннәм» хикәясендә хыял тормышка ашмаслык яшен кискән пыскып баручы ут булып кала. Садыйкның хыяллары һәм Гыйльманның ирешелгәннәре арасында вакыт аралыгы гына түгел, белем, тәҗрибә, абруй һәм, ниһаять, җәмгыятьтә тоткан урын мәсьәләсе дә калка.

«Сөю – сәгадәт» хикәясендә борчулы һәм авыр хыял дөньясына чумган Риза исемле герой «Х. туташ»ка бәйле хәтирәләрен тергезә. «*Үзем дә, шуңар тәмам бирелеп, иске хатирә дәфтәрен актарган адәм кеби, артта калган күренешләрне актара башлыйм!*» Хикәяләүченең хәтирәләре катламында геройның тормышында булган вакыйгалар вакытның төрле юнәлештәге агышына корылган. *«Күз алдыма хәзергедән, үткән вә киләчәктән, буталып, кисәкләнеп, чуалчык күренешләр килә. Мин шунлар эчендә хыялымны байтак әварә кыйлып талдыргач, мием авырып, рухым куәтен азайткач,*

*табигый юл буенча, үткән гомернең төрле күренешләре хыялымда гәүдәләнеп күренә башлый»* («Сөю – сәгадәт»). Сәгадәтле тормыш мизгелләре үкенү хисләре аша тергезелә. Яшьлекне, «хур кызына биргесез» булып кабул ителгән гади бер туташны сагыну, беренче саф, самими хисләргә сусау геройны бүгенгедән үткәнгә алып кайта.

Чикләнгән вакыт аралыгында хикәяләүче геройның күңел хисләре динамикасы гына түгел, ә фикер үзгәреше дә ачык күренә. Мәсәлән, «Сөю – сәгадәт» хикәясендә «*Кигән кием ничек туза, яшь гомер шулай уза*» дигән җыр юлларын герой хәзерге вакыт ноктасында башкачарак аңлый башлый. «*Шул җырның чын мәгънәсе менә хәзер беленде*». Вертикаль сызыкта яшь гомернең узуы «*май ахырында бөтен тирә-ягына ямь вә хәят биреп утырган чагы белән көз көне актык яфракларын коярга әзерләнгән*» агач һәм хикәяләүче герой арасындагы уртаклыкта да ачык чагыла.

Шундый ук үзгәреш «Уты сүнгән җәһәннәм» хикәясендә дә ачык күренә. Хыялга бирелеп тыныч кына яшәп яткан геройны Гыйльман Каһиров белән булган очрашу үзгәртә. Авылда үз тормышыннан канәгать булып, балалар үстереп яткан Садыйк өчен әлеге ноктадан башлап вакыйгалар иҗтимагый-тарихи яссылыктан психологик катламга күчә. Хәер, герой үзе дә бер иптәшеннән «…син әхваль һәм хиссият колы» дигән сүзләрне ишеткәне бар. Кайчандыр бөтен яктан Садыйктан түбән Тубал – Гыйльманның үзгәргән булуы, аның белемле, бай кешегә әверелүе – Садыйкның тормышка ашмаган хыялларын кузгата, надан мулла сыйфатында йөрүче Садыйк күңелендә авыр хисләр тудыра. Язучы геройның әлеге кичерешләрен тәфсилләп тасвирларга алына, югары хыяллар белән тормыш төпкелен капма-каршы куя. Гыйльман уңышының сере – зур ихтыяр көче, тырышлык нәтиҗәсендә икәнен дә, үзенең бу юнәлештә җибәргән хатасын да аңлаган Садыйк үзендә тормышын үзгәртә алырлык көч таймый. Яшен яктысыннан курыккан Садыйк тормышына Гыйльман нәкъ менә караңгыда ялтырап киткән яшен булып килеп керү вакыйгаларның вертикаль проекциясен сызып, икегә бүлеп үтү кебек кабул ителә. «*Минем уем нәкъ шул йиргә җиткән чагында куәтле бер яшен яшьни, бөтен дөньяны гаҗиб бер яктылык ала; вә шул яктылыкның караңгылык белән аралашып киткән актык секундында хыялымда өзгеч бер күренеш ялтырап китә: гүя мин гарештән, нурдан егылып, ниһаясез караңгы төнгә, түбәнгә, коточкыч астка киткәнмен дә, шуны аңлап, кабаттан өскә чыгарга талпынам, ләкин куәт юк, канат кисек булганга, кире йөзтүбән, әүвәлгедән дә төпкәрәк китәм, имеш…*». Язучы Садыйкның яшәешен «уты сүнгән җәһәннәм» дип атап, С. Рәмиевнең реакция елларында язылган шигыре белән мәдәни бәйләнешкә кереп, сурәтләнгән вакыйгалар чиген тагын да киңәйтә төшә. Хикәяләүче геройның «*шагыйремезнең, заманында ятлап та, әллә качан оныткан бер шигыре*»н зиһенендә тергезүе, «таңы ерак» төн өчен ачынган шагыйрь белән шигъри юллар аша бәйләнешкә кереп «алда хәят юк» дип өзгәләнү күңел, киләчәк проекциясен аска, түбәнгә батыра.

«Диңгездә» хикәясенең үзәк герое да тетрәнгән рухына гармония табарга тели. Бу гармония бары тик табигатькә якынлыкта, табигатьнең аерылгысыз бер өлеше булып яшәүдә фаразлана. Көймә ярга туктагач, «корымлы завод морҗалары акырган» чынлыкка атлап чыгарга, ачык пространстводан ябык мохиткә күчәргә мәҗбүр булган кешеләргә иярү үзәк геройга шатлык алып килми. Әмма «бөек яшәү белән яшисе килә» дип хыяллан-

ган геройның киләчәгенә караганда, төнге диңгез өермәсеннән исән калган юлчылар өчен җир тормышы ышанычлырак һәм тотрыклырак күренә.

Фәрраш Нури сөйләгән балык сыртына ясалган утрау, корбан сораучы балык турындагы легендалар да тарихи һәм психологик вакыт аралыгында уңышлы китерелгән. Хикәядә Габдулла Хаҗины кәфенгә төреп, терелэй килеш балыкларга ашарга бирү турыдан-туры Юныс пәйгамбәр кыйсмәтенә ишарә ясаса, укучы аңында Дәрдмәнднең «Кораб» (1908) шигырендәге «Кайсы юллар, / Нинди упкын / Тарта безне җан сорап?!» шигъри юллары милләт язмышы өчен борчылучы геройны күз алдына бастыра.

Тормыш кануннарын чагылдыручы реаль урын буларак «Сөю – сәгадәт» хикәясендә төнге тынлыгын «заводларның вакыт-вакыт мәгънәсез акыруы» бозган шәһәр билгеләнгән. Әсәрдә кызның «икенче адәмгә билгеләнгән булуы», өзек-өзек штрихлар белән генә сурәтләгән өй эче (бүлмә, «яхут бүлмә», зал, чәй өстәле, мич һ.б.) шул чордагы татар тормышы белән тарихи-мәдәни ассоциацияләр тудыра. Билгеле булуынча, өй – XX йөз башы татар әдәбиятында тормышта күнегелгән тәртипләр, көнитеш, гаиләдәге зәвык һәм культура күрсәткече булып тора [2, б. 87]. Тормыш тәртибен ачыклаучы әлеге ябык пространство Г. Ибраһимовның «Сөю – сәгадәт» хикәясендә романтик рухта, шактый якты буяуларда тәкъдим ителә. Кеше кичерешләренең нечкәлекләрен бирү максатында язылган әсәр тормыш ваклыкларыннан өстен, иҗтимагый кануннардан азат итеп оештырыла. Өй эчендә геройларның хәрәкәт-гамәлләре пространство һәм кабул ителгән тәртипләр белән чикләнсә дә, мәхәббәтне яшәүнең мәгънәсе дип тәкъдим ителгән хикәядә алар җимерелә. «*Сәгать төнге өч иде. Өйдәге һәммә кеше йоклап беткән. Тик мин дә ул гына. Мин үз бүлмәмдә, ул залында…*». Х. туташның һәр көн кич «пичнең душнигын ачу мәсьәләсе белән бүлмә»гә килеп керүе бәҗраны хасил итүче гадәти-көнкүреш вакыт рәвешен ала. Саналган гамәлләрнең даимилеге вакыт агышын туктата, тарихи барыштан читкә алып китә.

«Уты сүнгән җәһәннәм» хикәясендәге вакыйгалар авыл җирлегендә бара һәм бирелдәге «зур, караңгы өйнең аулак бүлмәсендә ялгыз»ы утыручы Садыйкны хыял дөньясыннан чынбарлыкка алып чыга, үткәндәге танышы белән очраштыра. Бу өй эченә геройның «тәмсез караңгылыктагы» тормышы да, бала елавы да, хатынының сукрануы да сыйган. Якты киләчәк турындагы өметнең киселүе «каберең өстенә яңлыш язулы бер соры таш!» ноктасында туктала. Герой уйларындагы тарихи вакыт шуның белән тәгәлләнә. Әсәрдәге вакыйгалар вакыты «авырып, ватылып» хатыны янына барып егылу белән тәмамлана.

Вакыт һәм урынның образлы чагылышы буларак хикәяләрдә тәрәзә, ишек хронотопларын билгеләргә кирәк. Ишек хронотобы тупса хронотобына туры килә һәм геройның нинди дә булса чикне атлап чыгу алдында торуын билгели. «Сөю – сәгадәт» хикәясендә яшьләрнең бер-берсенә мәхәббәтен генә түгел, ә пространстводагы күчеш-үзгәреш траекториясенең мәгънә тирәнлекләрен ачарга ярдәм итүче гомумиләштерелгән ишек образы геройларны ачык пространствога алып чыга. «*Язмыш безгә артык рәхимле имеш ки, безгә гали сәгадәтнең ишекләре тәмам ачык иде. Без аның белән бу ишектән кереп, үзебезнең рухларыбыз теләгән һәрбер эшләр белән хәятыбызны илаһи бер рәвешкә сала идек*».

«Уты сүнгән җәһәннәм» хикәясендәге ишек аны ачарга һәм ябарга, үз уңаеңа уйнатырга җайлаштырылган тотка образы аша конкретлаша. «*Тот-*

*касын тотып ишекне уңга да, сулга да борган кебек, үзем теләгән якка борырга уйлаган хәят куәтле дулкыны илә элеп алган да, диңгезгә ташланган бер җомычка рәвешендә уйнатып йөртеп, ниһаять, шунда мулла ясаган*». Язмышының үз кулында булачагына инанган, әмма йомычка сыйфатында бәргәләнеп йөреп, «шыбырдап торган яңгырны тыңлый торгач…» философ булып киткән Садыйк тормыш тоткасын үз кулыннан ычкындырган.

Гомумән, ишек, тәрәзә хронотоплары ябык һәм ачык пространстволарны тоташтыра, эчке һәм тышкы дөньяны аеручы чик булып тора. Тәрәзә, үз чиратында, кешенең дөньяга карашлары киңлеген, тирә-якны кабул итү үзенчәлеген чагылдырып килсә, ишек – геройларның үзара мөнәсәбәтләрендә башка баскычка күчешне: «Сөю – сәгадәт»тә көндәлек-гадәти проблемаларны калдырып, бары тик мәхәббәт хакына гына яшәүне тормыш фәлсәфәсе итеп тану мизгелен гәүдәләндерә, «Уты сүнгән җәһәннәм»дә үзе теләгән ишекне ачып керә алмау кебек аңлашыла башлый. Шул ук әсәрдә автор-хикәяләүче тәрәзә образына да аерым мәгънә сала. «*Бүлмәмнең карт агачлар белән тулган зур бакчага караган бердәнбер тәрәзәсе бар. Мин шуның яңагына артым белән терәлеп, күзләремне тышның куе һәм шомлы караңгылыгына юнәлдергәнем хәлдә, төннең тынлыгына күмелеп тик кенә утырам*». Тәрәзә, бу очракта, хәзерге вакыт картиналарын чагылдыручы аралык булудан бигрәк, үткән һәм киләчәкне күз алдына бастырырга сәләтле хәтер һәм хыял көзгесе. Хикәя башында тынлыктан тәм табып утыручы герой халәтен ахырда тәрәзә каршындагы күренеш чарасызлык ноктасына китереп тери. «Тәрәзәм каршындагы караңгы бакчада яфраклар шыбырдый, каравылчы да кара төнне ярып никтер шакылдарга тотынды». Шул ук тәрәзә аша яшен чаткысы ялтырап китә, герой халәтен психологик киеренлеккә җиткерә.

«Диңгездә» хикәсендә, исеменнән үк аңлашылуынча, вакыйгалар диңгез белән бәйле сурәтләнелә. Язучы диңгезнең тыныч вакытын да, җилдавыллы, яшенле, ярсыган чагын да күрсәтә. Диңгез, табигатьнең үзе кебек үк, тормышның көтелмәгән агышын гәүдәләндерә. Давылда калган җилкәннең язмышы милләт язмышы белән ассоциацияләшә.

Ә «Сөю – сәгадәт» хикәясендә вакыйгалар «*шәһәрнең һәртөрле чәчәкләр белән бизәнгән әгъла бакчасы*»ннан «*зур һәм карт урманлы биек таулар*» һәм «*яшел үләннәр, ал-гөл чәчәкләр белән түшәлгән зур, киң тугай*» уртасыннан аккан елгага күчә. «*Шунда төштек тә, уңай бер кимәгә икәү генә утырып, кояш баешына таба карап акрын гына киттек…*» Әсәрдә көймә, «Диңгездә» хикәясеннән аермалы буларак, бәхетле мизгелне гомумиләштерүче ябык пространство моделе буларак тәкъдим ителә. Сөю ялкынында янучы яшьләрнең аерым микродөньясын булдыру көченә ия итеп сурәтләнгән «кимә», тормыш агымында тыныч кына агучы гаилә моделе белән тиңләшә. Табигатьтәге тынлык тулган айның «*хыялый, мөэссир, ләкин бик мөлаем, гүзәл, шигъри һәм серри төс*»е белән тулыландырыла, сандугач-былбыл сайравы, яшьләрнең бәхет-сәгадәттән туган күңел ярсуы белән алышына. Герой күңелендәге хисләр көчәйгән, киеренкеләнгән саен пространстводагы күчеш тә тизләнә, хронтопның эчке мөмкинлеге тагын да киңәя. Бүлек ахырында хикәяләүче «*Шунда пәрдә төшә*» дип искәртә һәм әсәрдәге вакыйгалар чиген икегә бүлә, үткән һәм бүгенгене «караңгы пәрдә» белән аерып куя.

«Сөю – сәгадәт» хикәясенең соңгы бүлеге үткәннәргә тагын бер кат бәя бирә, табигатьнең «шагыйрь вә сентименталист итеп» яратылган бәндәсен

хисләр дулкынында йөздерә. Әмма үткәндәге тыныч кына агучы елга урынына күл пәйда була. Хикәяләүченең күңелендә тергезелгән хәтирәләрне «ярым сары төстәге күл» һәм «сары алтын төсенә әйләнгән зур күл» бөҗрасы каймалап ала. Бер урында торучы сары күл таулы елга агымына каршы куела. Үткәндә ярсыткан шашкын хисләр күл кебек тынып калса да, шагыйрьнең хәтирәләрен җуя алмаганлыгы ачык тоемалана.

Г. Ибраһимов хикәяләрендә вертикаль проекциянең үзәген кояш тәшкил итә. Күп кенә хикәяләрендә язучы башыннан ахырына кадәр «*кояшка карап хыялга бата*», «*хәятын шул кояшка охшата*». Кояш образы белән бергә бакый/фани дөнья оппозициясе кертелә. Кеше гомеренең чикләнгәнлеге дә кояш бату белән чагыштырыла, Мәңгелек бөҗрасының уртасында торуы аны «олуг кояш» итә, әлеге фикер экзистенциализм фәлсәфәсе кануннары яссылыгында шәрехләнә. «*Ә бәхетле кояш алай түгел: ул чыга, күтәрелә, бата, югала, әмма мәңгегә түгел, – таңда янә чыкмак, дәхи дә ерак күкнең иң гали ноктасына ирешеп, табигатькә үзенең олуглыгын белдермәк, куәт вә матурлыгы белән адәмне үзенә табындырмак өчен генә бата. Ул – туктаусыз; бәлки, мәңге дә шулай әйләнер*» («Сөю – сәгадәт»).

«Диңгездә» хикәясендә кояш әле баюга, әле таң атуга бара. «*Кояш түбәнәя, күк йөзе ачык, һава саф, бөтен дөньяны кичкә каршы гына була торган бер рәхәт тынлык чолгый*» дип башланган хикәядәге вакыйгаларны «тынлык/давыл» оппозициясе ачыклый башлый. Давыл – диңгез өстендә дулаган дулкыннар торышы гына түгел, күңелендә мең сорау, мең газап яшеренгән үзәк герой халәте дә. Тагын бер үзенчәлек – Г. Ибраһимовның хикәяләрендәге вакыйгалар төн белән бәйле: җилкән төнлә давылга эләгә, Садыйкның киләчәге төн кебек караңгы, хәтта мулла да төнгелеккә бурлыкка чыга һ.б.

Гомумән, шуны да аерым билгеләп китәргә кирәк, Г. Ибраһимовның унынчы еллардагы сәнгатьчә фикерләү үзенчәлеге хикәяләрендә ачык тоемлана. «Саф сәнгать» теориясенең чагылышы булган әсәрләрнең күбесе өчен ачык пространство (диңгез, печәнлек, ялан-кырлар һ.б.) булу хас. Хикәяләрдә шулай ук кояш, җил, давыл, яшен, диңгез кебек романтик әдәбиятка хас символлар кулланылу әдәби урын һәм вакытны тулыландыра, күпкатлы итә. Язучының табигать, пейзаж символикасына мөрәҗәгать итүе фәлсәфи мәгънәгә ия. Хикәядәге әдәби урынның киңлеккә омтылышы, әдәби вакытның субъективлыгы хикәяләүченең фәлсәфи уйлануларына гомумиләштерүләр ясарга мөмкинлек бирә.

Шулай итеп, Г. Ибраһимов хикәяләрендә урын һәм вакыт катлаулы бәйләнешкә керә, әсәр үзәгенә салынган фаҗигалелекне көчәйтә, язучының эстетик бәясен чагылдыра.

ӘДӘБИЯТ

1. Бахтин М. Формы времени и хронотопа в романе // Вопросы литературы и эстетики. М., 1975.

2. Әдәбият белеме. Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. Казан: Мәгариф, 2007. 321 б.

3. Заһидуллина Д., Әминева В., Ибраһимов М. Әдәби әсәр: Өйрәнәбез һәм анализ ясыйбыз: Урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма. Казан: Мәгариф, 2007. 112 б.

4. Заһидуллина Д., Ибраһимов М., Әминева В. Әдәби әсәргә анализ ясау: Урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма. Казан: Мәгариф, 2005. 111 б.

5. Ибраһимов Г. Хикәяләр, повесть, роман. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. Б. 51.

6. Мингазова Р. А. Руссоистские традиции в творчестве Галимджана Ибрагимова: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2009. 26 с.

# Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ «АЛМАЧУАР» ХИКӘЯСЕНДӘ ЭМОТИВ ЛЕКСИКА

***Хәлиуллина Н.У., Шакирҗанова А.Р.***

В статье исследуется лексико-семантическое поле эмотивных языковых единиц на материале рассказа Г. Ибрагимова «Алмачуар». Душевные переживания героя имеют большое значение в раскрытии идеи произведения, поэтому лексическое поле эмотивов представлено большим количеством единиц.

The present article seeks to reveal the essence of the lexical-semantic field of affective linguistic units on the story «Almaguer» by G. Ibragimov. Emotional stress of the character has a great importance in developing the ideas of the work. Consequently the lexical field of emotives is represented by a number of units.

Тел гыйлемендә эмотив лексика катламына хис-кичерешләрне, кешенең кәефенең, тойгыларның, аларның төрле чагылышын атаучы берәмлекләр системасы кертелә. Эмоцияләр кеше яшәешенең әһәмиятле өлкәсенә карыйлар һәм әйләнә-тирәне танып белүнең һәм аны чагылдыруның әйдәп баручы формасын тәшкил итәләр. Эмоцияләр интеллект белән берлектә шәхеснең үзәген барлыкка китерәләр. Америка психологы К. Изард билгеләвенчә, «безнең һәрберебездә «эчке үзәк – мин-минлек» яши, ул, гадәттә үзгәрешсез кала һәм үзенең табигате буенча эмоциональ була». Бу фикер телчеләр өчен аеруча әһәмиятле, чөнки һәр кешенең хис-тойгылар дөньясының төзелеше (мәсәлән, теге яки бу эчке кичерешнең еш кабатлануы) аның кыйммәтләр дөньясын, ә соңгысы, үз чиратында, стереотиплар һәм мотивацияләр белән берлектә тел йөретүченең иң югары дәрәҗәсен – прагматиконны билгелиләр [2].

Галимнәр күрсәтүенчә, төрле ситуацияләр белән бәйле рәвештә якынча 70 төрле тойгы ачыклана. Психолингвистика фәнендә, лексиконны тикшерү нигезендә, төрле милләт кешеләре өчен прототип эмоцияләр аерыла. Шатлык, кайгы, курку, гаҗәпләнү, ачу кебек фундаменталь эмоцияләр сөйләшүче аңында типик саналалар, телдә структуралашалар, ягъни кечкенә система тәшкил итәләр.

Хис-тойгылар, психик кичерешләр сыйфаты, ешлыгы, дәвамлылыгы, тирәнлеге, генетик чыгышы, катлаулылыгы һәм башка билгеләре буенча бер-берсеннән аерылалар. Хис-тойгыларны классификацияләүдәге авырлыклар аларның «эчке» һәм «тышкы» нигезләренең төгәл генә аерып алырлык дәлилләр җитешмәүдән дә тора [2].

Кешегә хас универсаль күренеш буларак, эмоцияләр тел берәмлекләре аркылы төрлечә чагылыш табалар. Әдәби әсәрләр телендә эмотив берәмлекләр, бер яклап, геройның характерын ачу, хәл-вакыйга турында тулы күзаллау булдыру, икенче яклап, язучының, лирик геройның дөньяга карашын, тирә-юньгә мөнәсәбәтен билгеләүдә зур роль уйныйлар.

Әсәр көрәш, бәрелеш, авырлык һәм бәрәкәт, этлек һәм яхшылык, хәсрәт-хафа һәм җиңел аяк белән килү кебек бер хис-тойгының капма-каршысы белән алмашынып торуы мотивлары белән буйдан-буйга сугарылган. Ләкин алар бербөтенне барлыкка китерү факторлары гына булып торалар. Дөнья ике яклы, һәрнәрсә ике кырлы. Кеше, бу очракта, баланың күңеле – каршылыклардан төзелгән бербөтен. Әсәрнең лексик катламын идеографик яссылыкта тикшереп караганда да, әлеге фикернең автор тарафыннан бик

оста үстерелешен күрергә була. *Алмачуар* – ат төсе буларак, кара түгел, күк дип тә булмый. Анасы кебек саф бурлы да түгел – ничектер, күгелҗем ак чәчәк төсе кебегрәк булып ялтырп тора (274 б.)

Хикәядә шатлык – кайгы дихатомиясе төп урынны алып тора. Шуңа күрә елмаю, шатлану, көлү һәм елау, катып калу, мөлдерәмә яшьләр тулу кебек эмотив берәмлекләрнең кулланылыш ешлыгы күзәтелә: шатлык (6), елмаю (6), көлү (3) – кайгы (4), елау (21).

Автор эмоцияләрне катып калган күренеш буларак түгел, ә динамикада сурәтли. Мәсәлән, *еларга җитешеп, әткәйгә бардым, түзә алмый елап җибәрдем; адәм шул чаклы акырыр икән, мин аның саен ярсыдым, аның саен елый бирдем, шулай елый-елый барып, эштән чыгып ... йоклап калганмын; мыек астыннан елмаю, ярым елмаю* һ.б.

Хис-кичерешләрнең градациядә бирелешен күрсәтүче эмотив фигыльләргә тукталыйк:

*– Я, куй шул сукрануыңны, – ди, – нигә, ди, баланы юкка* ***елатырга****, – ди.*

*Чыннан да, берәр авыр йөккә, ерак җиргә җигә башласалар, мин әткәйгә барып сыенам, иркәләнәм, ул минем* ***күзләремдә мөлдерәп төшәргә-ташарга торган күз яшьләремне*** *күрә дә, мыек астыннан көлеп, башымнан сыйпый:*

*– Я син, Закир, юкка елап барма... Ярар, җикмәбез, – ди.*

*– Мин* ***кая сикерергә урын тапмыйм****. Көн буена* ***аягым кая басканны белмим*** (266 б.).

***Шатлыгым йөрәгемнән тулып таша****. Җире, күге, бөтен дөньясы минем* ***шатлыгымнан*** *һәммәсе* ***бииләр*** *кебек тоела* [1, б. 280].

Әсәрдән күренүенчә, хис-тойгылырның тупланган урыны – йөрәк, күңел: *Әмма менә сез җиңүче башкортның йөрәгендә аннан соң ниләр булганы – сезнең төшегезгә дә кермәгәндер. Бу вакыт күңелемә шик килде. Шулай да үземне тыя алмадым...* [1, б. 263]. *Елый алмадым, йөрәгем таш булып катты*. [1, б. 288.). *Ике өлкән баласын хәтергә төшерү һәрвакыт безнең әткәйнең йөрәгенә авыр була...* [1, б. 275].

Күзләр шулай ук эмоцияләрне чагылдыручы урын: *Фәхри малае күзләрен елтырата-елтырата сөйли башлый... Боларны ишеткәч, башкаларның да күзләре кыза...* [1, б. 268].

Эмоцияләрнең тышкы чагылышын белдерүче фигыльләр бер семантик төркем тәшкил итәләр: *чаптым, атылдым, акырам*, *ташландым, чинап, дулау, авызларын ачып тору, тавышы үзгәрә, башыма нидер сукты, телем тотлыкты, катып калдым, йөрәгем суга, тәнем калтырый, күкрәгем кысып-кысып ала*.

Ат образы аша кеше кичерешләрен сурәтләү хикәядә зур урын ала. Авторның, безнең уебызча, җиткерергә теләгән бер фикере – табигать белән кеше, рух белән материя берлеге. *... Бу арада әллә ничек үзгәреп тора: юккабарга* ***ачулана****, якын барсаң өстеңә йомылып килә.*

*Әле дә бардым. Элекке кебек тоттыру кая, пырых-пырых итеп, үз алдына холыксызланып,* ***кызып тора*** [1, б. 267].

Г. Ибраһимовның «Алмачуар» хикәясендәге эмотив лексик-семантик кыр түбәндәге берәмлекләрдән төзелә: елау (21), курку (10), ачулану (8), аптырау (7), елмаю (6), шатлык (6), шаяру (6), шомлану (5), хәйран булу (5), кайгыру (4), карап кату (4), кызып тору (4), көлү (3), газап чигү (3), тыелу (3), кызгану (2), хәсрәт (2), холыксызлану, хафа, әсәрләнү, көенеч, ярсу,

шелтә, тынычсызлану, сабырсызлык, күзләрен елтырату, таш булып кату, йөзе кара көю, күңелгә шик килү, үзеңне тыя алмау, шелтәләп карау, күз яшьләрен сөртә-сөртә, күзләрдән мөлдерәп төшәргә торган күз яшьләре, күзләрен елтырата-елтырата, күзләре кыза, күзгә ак-кара күренмәү, күңел тынычланмау, күзгә йокы кермәү, йөрәк түзмәү, баскан җирендә тора алмау, күзләре уйнап, ялкынланып тору, күңелгә шөбһә килү, күз алды караңгылану, мөлдерәп карау, күңел төшмәү.

Шулай итеп, автор укучыны кичерешләр эчендә, эмоцияләр дулкынында тота. Нәтиҗәдә, эмотив лексик һәм тотрыклы сүзтезмәләрнең ешлыгы күзәтелә.

ӘДӘБИЯТ


1. Ибраһимов Галимҗан. Сайланма әсәрләр. Казан: «Хәтер» нәшр., (ТаРИХ), 2002. 542 б.

2. Калимуллина Л.А. Семантическое поле эмотивности в русском языке: диахронический аспект (с привлечением материала славянских языков). Уфа: РИО БашГУ, 2006.


## ҒӘЛИМЙӘН ИБРАҺИМОВТЫҢ «АЛМАСЫУАР» ХИКӘЙӘҺЕ ТРАДИЦИЯЛАРЫНЫҢ БАШҠОРТ ХАЛЫҠ ИЖАДЫ МЕНӘН АУАЗДАШЛЫҒЫ ХАҠЫНДА


***Хөббитдинова Н.Ә.***



Статья «О созвучности традиций рассказа «Алмачуар» Г. Ибрагимова с башкирским народным творчеством» посвящена рассмотрению некоторых случаев созвучности, сходства поэтических, эпических особенностей башкирского фольклора в рассказе известного татарского писателя. В частности, автором было установлено художественно-эстетическое своеобразие фольклорного мотива «запрет – нарушение запрета – наказание» как сюжетообразующего мотива, характерного также и башкирской сказке и эпосу. В описании внешнего вида главного героя рассказа скакуна Алмачуар были выявлены некоторые параллели с крылатым конем Акбузат из одноименного башкирского народного эпоса.

The article «On the harmony of traditions of the G. Ibragimov's story «Almachuar» with the Bashkir folk art» is devoted to the consideration of some cases of consonance, similarity of poetic, epic features of Bashkir folklore in the story of the famous Tatar writer. In particular, the author established the artistic and aesthetic originality of the folklore motif «prohibition – violation of the prohibition – punishment» as a plot-forming motif, which is also characteristic of the Bashkir fairy tale and epic. In describing the appearance of the main character of the story of the mount Almachuar, some parallels were found with the winged horse Akbuzat from the eponymous Bashkir folk epic.


Билдәле булыуынса, сығышы менән Башҡортостан ере менән, артабанғы ғүмере һәм торомош юлы иһә Татарстан менән бәйле булған күренекле ғалим, мәғрифәтсе һәм әҙип Ғәлимйән Ибраһимовтың «Алмасыуар» тигән хикәйәһе башҡа әҫәрҙәре араһында киң билдәлеләренән һанала. Уны башҡорт уҡыусылары ла яратып һәм кинәнеп уҡый. Һуңғылар өсөн әҫәр унда һүрәтләнгән хәл-вҡиғаларҙы үҫешергә ярҙам иткән ҡайһы бер художестволы деталдәрҙең, күренештәрҙең башҡорт фольклоры традициялары менән ауаздаш булыуы менән яҡындыр.

Башҡорт менән татар халҡы күрше-күлән булып тормош һөргәнлектән, әлбиттә, әҙәбиәттә лә уртаҡ халыҡ ижады алимдары менән һүрәтләү сараларының сағылыуына ғәжәпләнерлек түгелдер. Ошо яғы менән ҡараласаҡ әҫәр ҙә мөһим мәғәнәгә эйә.

«Алмасыуар» әҫәрендә хәл-ваҡиға Башҡортостандың күркәм Өршәк йылғаһы буйында урынлашҡан татар ауылында үҫешә. Һүрәтләнгән гүзәл тәбиғәтле ер менән саф күңелле әҫәр геройҙары гармонияла йәшәп, көнкүреш мәшәҡәттәре менән шөғөлләнә. Ошо һил генә ағым менән барған тормошто, айырып әйткәндә, Хафиз тигән бер кешенең ғаиләһендәге хәлдәр хикәйә сюжеты үҫешенә этәргес көс биреп ебәрә.

Ул хәлдәр иһә Әлемғол исемле башҡорт байының «тота килеп» Хафизға быуаҙ бейәһен бүләк итеүенән башланып китә. Һәм әҫәрҙең сюжеты ошо күренештән аҙаҡ һуңғыһының ғаиләһендәге килеп тыуған яңылыҡтарға бәйләнеп үҫешә лә инде. Тик шулай ҙа был сюжет яралыуының сәбәбе лә юҡ түгел. Сәбәбенең төбөндә, халыҡсан яҙыусының ижадына хас булғанса, фольклорҙың ятыуы көн кеүек асыҡ. Мәҫәлән, халыҡ ижадының сәсәм жанрҙарына ҡарған әҫәрҙәрендә «тыйыу – тыйыуҙы боҙоу – яза» («запрет – нарушение запрета – наказание») тигән сюжетты булдырыусан (сюжетообразующий) мотивтың булыуы билдәле. Был мотив әҫәрҙең конфликтын тыуҙырыуҙа мөһим роль үтәп килә. Ул, академик Ә.М. Сөләймәнов әйткәнсә, «сюжеттың кинәт етеҙ старт алыуына этәреш биреүсе механизм, детонатор хеҙмәтен үтәй» [3, 396-сы б.]. Шул мотивҡа башҡорт халыҡ ижадында, мәҫәлән, «Әрмәнде тун» (АТ 402: Әрмәнде ҡыҙ – Батша ҡыҙы+АТ 400: Юғалған ҡатынды эҙләү) тибындағы йәки «Һыу ҡыҙы», «Ҡотлобикә менән Ҡотлояр» (АТ 425+4001) ише һәм башҡа тылсымлы әкиәттәр сюжеты ҡоролған: герой мотлаҡ тыйыуҙы боҙа һәм язаһын да ала. Тыйыуҙы боҙоу, һөҙөмтәлә, язаһын алыу тылсымлы әкиәттәрәренә, ғөмүмән, хас күренеш булыуын ғалим Ә.Ғ. Яхин да таный [4, 65-се б.].

Ә.Сөләймәнов дауам итеп, «...Һәр тыйыу – үҙенә күрә аманат. Әммә фольклор әҫәре был хаҡта ҡабат-ҡабат хәтергә төшөрөүҙе артыҡ һанай». Ә бына әҙәбиәт инде, тип дауам итә ул, «ғәҙәттә, аңлатма биреүҙе, асыҡлыҡ индереүҙе кәрәк тип таба», тигәйне [3, 396-сы б.].

Ысынлап та, мәҡәләлә ҡаралған Ғ. Ибраһимовтың «Алмасыуар» хикәйәһенә лә был әҙәбиәт законсылығы хас, әлбиттә: әкиәт булһа, харамлашыу күренеше (йәғни әхлаҡ яғынан да дин йәһәтенән дә тыйылған ҡылыҡ) һабан туй мәлендә генә һүрәтләнер ине лә, Әлемғолдоң шул арҡала алған язаһы – сире һәм тәүбәгә килеүе һүрәтләнер ине. Әммә әҙәби фекер үҙенекен итә: бөтә халыҡ алдында Әлемғолдоң үҙе рәнйеткән Хафиздың өйө алдына бейәһен килтереп, доға-фәләнен уҡытып, фатихаһын алыу ҡыланышына ҡат-ҡат тип әйтерлек «асыҡлыҡ индерәлә». Тик ошо тәүбәгә килеүҙең төп сәбәбе булып, йәғни сюжеттың үҫешә башлауына этәргес көс биреүсе ролен әкиәттән билдәле булған әлеге «тыйыу – тыйыуҙы боҙоу – яза» мотивы тора ла инде. Икенсе төрлө әйткәндә, һабан туйында аяҡ алып харамлашыу арҡаһында, Әлемғол ныҡ итеп ауырып китә һәм, тәүбәгә килеп, «...Бу авыру Хафизга каршы хәйлә эшләп, аны рәнҗетүдән килгәндер, терелсәм, бурлы биямне аңа дога кылдырырмын дип нәзер әйткән идем», ти. Йәғни иман йәһәтенән дә, саф кешелеклелек, әхләҡ яғынан да тыйылғанды боҙоуы уның башына әлеге яза кеүек төшә. Шунан нәҙер һүҙ әйтелә лә инде. Әҙәби әҫәрҙә иһә ул ана шул яғы менән мөһим художестволы функция үтәп килә, йәғ-

ни киләсәктә ошо мотив һөҙөмтәһендә сюжет артабан әүҙем үҫешә башлай: алып килгән бейәнән тыуған ҡолонсаҡ Алмасыуар ҡушаматын алып, төп лирик герой Закир тормошона килеп инә лә инде.

Ат, йылҡы малы татар һәм башҡорт яҙмышында әйтеп бөткөһөҙҙур урын алып тороуы хаҡында фольклор материалдарында байтаҡ һаҡланған. Йылҡы малының төҫ-башы, тышҡы матурлығы менән һоҡланыу һүрәте Ғ. Ибраһимовтың ҡаралған әҫәрендә шулайыраҡ бирелгән:«...Колын чыннан гаҗәеп бер нәрсә иде: аның ботлары ничектер җиңел атлыйлар. Бәкәлләре озын, шундый нечкә озын ки, мондыйлар тик чабышкы атларда гына була, диләр. Әле яңа гына кибеп килә торган койрыгы белән ялы, әз генә, кыска гына булсалар да, озаклап үреп, кабартып ясаган ефәк бәйләме кебек үзеннән-үзе дулкынланып торалар. Түм-түгәрәк сырты өстеннән, нәкъ арка үзәк турыннан, бармак калынлыгы кара тасма кебек булып, койрыктан ялга җиткәнче, кара ефәк йон сузылган. Озынча, акыллы башның киң маңгаендагы озын яра кашка – бу колынны мең миллион иптәшләре арасыннан бөтенләй аерып, матурлыгы белән ялгыз дип күрсәтәләр. Бөтен гәүдәсе, әйтерсең, ходайның үз кулы белән, фирештәләрнең ярдәме белән тигезләп, матур итеп, коелып ясалган. Шундый... сылу, шундый асыл сөяк булып яратылганнар. Төсе хакында аптырап калдым. Кара түгел, күк дип тә булмый. Анасы кебек саф бурлы да түгел – ничектер, күгелҗем ак чәчәк төсе кебегрәк булып ялтырап тора» [1].

Күреүебеҙсә, ҡолонсаҡтың төҫ-башы һәм аҡыллы булыуы ябай нәҫелдән түгеллеген, йәғни сабыштарҙа ҡатнаша торған тай икәнлеге хаҡында белгертелә. Уның бындай сифаттарға эйә булыуы әкиәт йәки эпостағы атты – Толпарҙы йәки Аҡбуҙатты хәтерләтә кеүек:

...Ҡолағын беҙҙәй ҡаҙаған,  
Ялын ҡыҙҙай тараған;  
Башкүнәктәй танаулы,  
Һарымһаҡтай аҙаулы;  
Ҡарсыға түш, тар бөйөр,  
Еңел, текә тояҡлы;  
Ҡуян күҙле, баҡыр күҙ,  
Ҡыҫыр йылан тамаҡлы;  
Урайы ҡуш, яңағы ас,  
Муйындары бер ҡолас.  
Ҡыйғыр, бөркөт ҡабаҡлы...  
Алғыр бүре күҙендәй,  
Күҙ бәбәген сылатыр... –

тип һүрәтләнә, мәҫәлән, төп геройҙың тоғро юлдашы Аҡбуҙат шул исем менән аталған башҡорт халыҡ эпосында [2, 92-се б.]. Асылда Алмасыуар ҙа ошо үҡ тасуирлауҙарға һәм ысын толпар сифаттарына эйә булған йылҡы малы сурәтендә күҙаллана.

Шулай итеп, Ғ.Ибраһимовтың «Алмасыуар» хикәйәһенә татар фольклоры традициялары менән бергә башҡорт халыҡ ижадының да поэтик элементтарын күҙәтергә мөмкин. Улар әҫәрҙе художестволы биҙәп кенә ҡалмайынса (әле генә ат миҫалында ҡаралғанса) уның сюжеты үҫешенә лә хәл иткес этәргес көс биргән. Шуның менән художестволы-эстетик, тематик функция үтәп, әҫәрҙе ысын халыҡсан ижад емеше кимәленә күтәрергә булышлыҡ иткән.

ӘҘӘБИӘТ

1. Алмачуар. Г. Ибрагимов. Рассказ [Электронный ресурс]: http:// kitaphane. tatarstan.ru

2. Башҡорт халыҡ ижады: Эпос / төҙ. Ә. Сөләймәнов, инеш мәҡ. авт. М. Сәғитов, һүҙ арты мәҡ. авт. Ә. Сөләймәнов менән Р. Рәжәпов. Өфө: Китап, 1998. 448 б.

3. Сөләймәнов Ә.М. Ҡисса һәм дастандарыбыҙ // БХИ: Эпос: Кисса һәм дастандар / Сост. Н.Т. Зарипов, А.М. Сулейманов, Г.Б. Хусаинов и т.д. Уфа: Китап, 2002. Б. 380–443.

4. Яхин А.Г. Система татарского фольклора. Казань: Таткнигоиздат, 1984. 200 с.

## Г. ИБРАҺИМОВ ИҖАТЫНДА ТАТАР ФОЛЬКЛОРЫ

***Хөсәинова А.Җ.***

В этой статье рассматриваются фольклорные мотивы и образы, используемые Г. Ибрагимовым в своих произведениях. Раскрывются особеннности использования и интерпритации данных мотивов, роль татарского фольклора в творчестве писателя – классика татарской литературы.

This article discusses the folklore motifs and images used by G. Ibragimov in his literary works, describes features of the use and interpretation of these motifs, the role of the Tatar folklore in the creative work of the writer.

Галимҗан Ибраһимов, татар әдәбияты классигы, ялкынлы трибун, киң эрудицияле галим татар фольклористикасына зур өлеш керткән шәхесләрнең берсе булды. Мәжит Гафури Г. Ибраһимов турында бик зирәк фикер әйтеп калдырган: «Кем ул Галимҗан? Ул әдип кенә түгел. Телче, тарихчы гына да тугел. Ул бер татар, казакъ өчен генәме? Юк. Үзбәк, азәрбайҗаннар, тагы әллә кемнәр арасында гына шөһрәт түгел ул. Бөтен Шәрыкның кояшы ул. Менә кем ул Галимҗан!» [3, б. 36]. Чынлап та, Г. Ибраһимов үзенең әсәрләре, романнары язган сүз осталыгы, төрле халыкларның тормышкөнкүрешләрен күрсәтү осталыгы белән байтак халыкларның арасында «үзебезнеке» дип сөйләрлек ихтирам яулаган.

Г. Ибраһимовның әдәбият белеме өлкәсендә язылган һәм башка хезмәтләрендә дә фольклорга караган күп кыйммәтле фикерләр табырга мөмкин. Ул фольклорны язучы өчен бетмәслек байлык итеп күргән; халыкның колоритын, тормыш-көнкүрешен ачыклар өчен мөһим урын алып торганын билгеләгән. «Фольлор халыкның психологиясен аңларга ярдәм итә. Аңарда – тарих, халыкның уй-фикерләре, хис-тойгылары. Ул (фольклор) халык җаны көзгесе» [7, б. 55].

Галимҗан Ибраһимов иҗатында фольклор мотивлар аның «Яз башы» исемле хикәясендә зур урын алалар. Хикәя Сабир исемле шәкерт-малай исеменнән алып барыла. 1910 елда Казанда «Мәгариф» нәшрияте басмасында китап булып чыккан. Исеме астында җәяләр эчендә «Бер шәкерттән хикәят» дигән сүзләр бар. 1912 елда икенче басмасында Казанда «Шәрык» нәшрияты чыгарган. 1921 елда «Балалар күңеле» һәм «Күчмә уку китаплары» сериясендә басылган (нашире – «Мәгариф», Казан). Аннары Г. Ибраһимов әсәрләре «Җыелмасы»ның 1929 елда чыккан 2 нче томына һәм «Сайланма әсәрләр»е 3 томлыгының 1957 елда басылган 1 нче томына кергән, әсәр шулай ук киң халык өчен рәсемнәр белән зур тиражларда аерым рәвештә берничә тапкыр басылып чыккан [2, б. 457]. 1910 елгы текстка таянып эш ителде.

Сюжетның нигезендә, Г. Ибраһимовның барлык хикәяләрендә, романнарындагы кебек, Башкортостанның табигате, революциягә тиклем авылның тормыш-көнкүреше сурәтләнә. Табигать үзе Г. Ибраһимовның булачак хезмәтләренә нигез салган кебек тоела. Автор табигатьнең әдәбиятка йогынтысы турасында үзенең «Альбом турында берничә сүз» исемле мәкаләсендә яза.

Хикәянең төп герое әкиятләрдәге куркыныч җәнлекләр белән бәрелешкә килә. Г. Ибраһимов үзенең әдәби иҗатында да туган ягында кечкенәдән ишетеп үскән халык авыз иҗаты әсәрләрен – әкиятләрне, халык җырларын, легенда-риваятьләрне, сөйләкләрне, мәкаль-әйтемнәрне мул файдалана, шул рәвешле, хикәя-романнарын җирле колорит, кабатланмас моң белән баета. Төп герой – Сабирның әйләнә-тирә табигать белән танышкандагы кичерешләрен ачыклар өчен, әсәр тукымасына аждаһа турындагы мифологик хикәятне дә алып керә.

Хикәянең кульминациясе дә әлеге персонаж хакындагы халык ышануларының бала күңеленә тәэсир нәтиҗәсендә барлыкка килә: көчле давыл, яшенле яңгардан куркудан Сабирның күзенә аждаһа күренә һәм малай аңын югалта. Г. Ибраһимов еланның йөз ел яшәп, аждаһага әверелүен, аннары Каф тауларында мең ел гомер кичергәч, юхага әйләнеп, гүзәл кыз кыяфәтендә кешеләрнең канын суырып йөрүе турындагы мифологик хикәят аша борынгы ышануларның бала күңеленә нинди зур зыян ясый алганлыгын оста күрсәтә.

А.Х. Садекова билгеләгәнчә, «аждаһа – явыз, изүче, җимерүче көч, ә юха мәкер һәм хыянәтне чагылдырып килә. Алар кешенең фантазиясе тарафыннан тудырылганнар һәм кеше аларны һәрвакыт җиңеп чыккан. Сабирның явыз көчләр тылсымыннан котылып, терелеп, якты кояш дөньясына, дусларына балачак уеннарына кире әйләнеп кайтуы татар әкиятләренең оптимистик тәмамланышы бәлән туры килә. Ягъни «әкият мотивлары башка – профессиональ нәфис әдәбият дәрәҗәсендә осталарча гәүдәләнеш ала» [9, б. 24].

Шуны да әйтик, аждаһа турындагы ышанулар, әдипнең туган ягында, Башкортостанның Авыргазы районы татарлары арасында әлегә кадәр киң таралган. Ул гына да түгел, әлеге районның Мостафа авылында якындагы Баеш һәм Галим күлләреннән «аждаһа күтәрелүе» дип фаразланган сәер табигать күренешен күзәткән кешеләр бүгенге көндә дә исән. «Аждаһа күтәрелүе»нең соңгы очрагы, аларның сүзләренә караганда, 1965–1970 елларга туры килә. Бу аномаль күренеш хакында вакытлы матбугатта, аерым алганда, Башкортостанда татар телендә нәшер ителүче «Тулпар» журналында күләмле язма да дөнья күрде. Димәк, аждаһага бәйле мифологик карашларның Г. Ибраһимов иҗатының чишмә башында язылган хикәягә килеп керүе һич тә очраклы түгел. Ул язучының җирле фольклорга, мифологиягә яшьтән үк игътибарлы булуын, талантының халык авыз иҗатына нигезләнеп үсеш алуын дәлилләп тора.

Бу әсәрдә Г. Ибраһимов үзе туып үскән ягындагы фольклорны кулланган. Аның аша ул халыкның авыз иҗатын байлыгын, матурлыгын һәм онытылмаганын күрсәтә. Бик күп әкият элементы кулланылган.

1922 елда иҗат ителгән *«Алмачуар»* хикәясе татарлар белән башкортлар арасындагы җанлы мөнәсәбәтләрне күрсәтүгә багышланды.

Бу мөнәсәбәт халыкның тормыш-көнкүреше, этнографик картиналары күренешләрендә ачыла, гомумкешелек бәһаләре алгы планга чыгарыла.

Әдип реализм принципларының яңадан-яңа мөмкинлекләрен эзләү белән бергә элеккедән дәвам итеп килгән иҗат үзенчәлекләрен камилләштерүдән дә баш тартмады. «Алмачуар» хикәясе моның ачык мисалы булды. Романтик рух белән өртелгән көчле, гадәттән тыш характерга ия геройларның дәвамы буларак туган образ – гади крестьян малае Закирның сәламәт рухы һәм бай табигате әле дә булса әдәбият сөючеләрне соклandyрудан туктамый. Моның сәбәбе исә Г. Ибраһимовның иҗат методына хәрәкәттәге, үсештәге төшенчә буларак мөнәсәбәтеннән, бу өлкәдә катып калган кануннар булмыйча, яңалык һәм новаторлыкның узган белән тыгыз бәйләнештә генә җитди ачыш һәм уңай нәтиҗәләргә аңлап эш итүеннән килә иде.

Әсәрнең сюжет уртасында ат образы. Әйтергә кирәк, ат образы татар фольклорының бар жанрларында да зур урын алып тора. Татарларда бүгенге көндә дә ат турында 600 дән дә артыграк мәкаль яши.

Әкиятләрдә ат – ул әдәби персонажның тугры һәм еш кына тылсымлы ярдәмчесе. Борынгы вакыттан ук ат образы җырларда да очрый.

Бу атка гашыйк булган егет аның турыда болай ди:

*«Колын чыннан гаҗәеп бер нәрсә иде!*

*Аның ботлары ничектер җиңел атлыйлар, Бәкәлләре озын/ шундый нечкә-озын ки, мондыйлар тик чабышкы атларда гына була, диләр. Әле яңа гына кибеп килә торган койрыгы белән ялы, аз гене, кыска тына булсалар да, озаклап үреп, кабартып ясаган җефәк бәйләме кебек, үзеннән-үзе дулкынланып торалар. Түм-түгәрәк сырты өстеннән, нәкъ арка үзәк турыннан, бармак калынлыгы кара тасма кебек булып койрыктан ялга җиткәнче кара җефәк җон сузылган. Озынча, акыллы башның киң маңгаендагы озын кашка бу колынны мең-миллион иптәшләре арасыннан бөтенләй аерып, матурлыгы белән ялгыз итеп күрсәтәләр. Бөтен гәүдәсе әйтерсең Ходайның үз кулы белән, фәрештәләрнең ярдәме белән тигезләп, матур итеп, коелып ясалган. Шундый сылу, шундый асыл сөяк булып яратылганнар»* [6, б. 72].

Бу цитата атның бөтен тышкы кәяфәте тасвирлана. Галимнәр бу турыда болай диләр: эпослы халыкларда атны мактау характерлы һәм үзенчәлекле жанр булып тора. Г. Ибраһимовның әсәрендә атны тасвирлау яңа төс алган – ул бала күзләре белән каралган, тирән психологизм белән баетылган.

Татар халкының иҗтимагый аңында Ат – үзебезне үзебез халык, милләт буларак танырга ярдәм итә торган иң мөһим категорияләрнең берсе. Без электроника заманында да «аттан артык эшлибез», «ат кебек тартабыз», «ат кебек чәчәбез»...

Г. Ибраһимовның «Алмачуар» әсәрендә гүзәллеге белән трагик, трагиклыгы белән гүзәл ат язмышы кызыксынуны көчәйтә генә.

Әдип колын портретын язганда чын анималист рәссамнарча эш итә һәм бик тәэсирле, тотсаң җылылыгы, юешлеге сизелерлек, реалистик портрет тудыра. Әгәр бу портрет булмаса, әсәр, ахыр чиктә, үзенең хиссиятен шактый югалтыр иде, чөнки Алмачуарның һәлакәте безне бу чаклы тетрәтә алмас иде. Үтә кадерле, гүзәл нәрсәне югалту Һәрвакыт мәңгелек үкенечкә әйләнә.

Чынлап та, Г. Ибраһимов ат портретын иҗат иткәндә нинди әдәби традицияләргә таянды икән? Моны ачыклар өчен татар халык әкиятләренә, җырларына, дастаннарга, табышмакларга мөрәҗәгать итергә кирәк. Йөзләгән әкиятләр арасында барлыгы өч кенә әкият турыдан-туры атка багышланган: «Корчаңгы бай», «Ак байтал», «Тай», һәм алардагы иң җентекле

сурәт – «ап-ак; кечкенә; кап-кара; тау кебек зур; корчаңгы». Шуларда да әтрафлырак, тулырак сурәт очрамады.

Дастаннарыбызга килгәндә дә хәл шулайрак. «Ак Күбәк» дастанында Ур колак исемле ат сурәте бар:

*Урколагым кылыклы,*
*Кыйгач камыш колаклы,*
*Утраучы беләкле,*
*Ут урманча йөрәкле...* [5, б. 70]

Әлбәттә, бу портрет түгел, ә эскиз гына.

Алдагыларны җыйнап, һәм «Алмачуар» әсәренең киңәйтелгән метафора булуын да истә тотып, Галимҗан Ибраһимовны татар әдәбиятында анамалистик портрет жанрына нигез салучы дип бәяләп була. Әдипнең бу традициясе бүген дә гамәлдә, үсештә. Ат – татар аңының һәм яшәү рәвешенең иң күркәм өлеше. Әмма, ни сәбәптәндер, Ат татар халык иҗатында сурәтләү объектына әйләнмәгән. Татар ат сурәте төшерергә яратмаган, атка карап сокланмаган, үзен шушы бөек ләззәттән ни өчендер мәхрүм иткән. Ни өчен? Бу четерекле сорауга фәнебез, әлбәттә, әтрафлы җавап бирер. Ә Татарстан халык шагыйре Ренат Харис мондый версия яза*: татар атны шулкадәр көчле яраткан һәм кадерләгән ки, сокланып, аңа* ***күз тидерүдән*** *курыккан.* Бүген дә әле «Балага алай сокланып карама – күз тидересең!» дигән сүзләрне бик еш ишетергә туры килә [8, б. 72].

Г. Ибраһимов үзенең «Алмачуар» хикәясендә сабан туендагы ат чабышының чын мәгънәсендә драматик мизгелләрен аеруча калку итеп тасвирлый.

Сабантуй – халык бәйрәме. Ул элек яз көне кар беткәч тә, чәчүгә чыкканчы үткәрелгән. Моны, кагыйдә буларак, авыл картлары киңәшеп хәл кылганнар һәм бәйрәмне үткәрү көне турында базар көнне игълан иткәннәр. Шуның белән бергә, бер төбәктәге авыллар ярышларны төрле көнне үткәрергә омтылганнар. Бу башка авыл кешеләре дә күршеләренең бәйрәмендә катнаша алсын өчен эшләнгән. Ләкин сабан туй ул шул авыл халкының үз бәйрәме исәпләнгән һәм башка авыллардан кунак чакыру гадәте булмаган. Катнашасы килгән күршеләр чакырмыйча гына, мәйданга үзләре килгәннәр һәм бәйгеләр беткәч, гадәттә өйләренә кайтып киткәннәр. Дөрес, бу авылдагы туган-тумачасы һәм таныш-белешләренең ашка чакыруы да мөмкин булган. Ләкин, тулаем алганда, сабан туй кунак чакыру, кунакка йөрешү вакыты булган. Әйе, ул – олы бәйрәм, һәм аңа хәзерлек алдан ук башланган. Хатын-кызлар өй җыештырганнар, бөтен нәрсәне чистартканнар. Ирләр исә ишегалдын, урам тирәләрен себергәннәр, чүп-чарларны җыештырганнар һ.б. [1, б. 15].

Элек-электән Сабан туйларында авыр әйберләр, ягъни ташлар күтәрүдә ярышканнар. Ярышларның бу төре татар халык әкияте «Алпамша»да менә ничек сурәтләнгән: «Алпамша ташны тотып алып, берсен икенчесенә китереп бәреп яра да, ике ташны кулына киеп, ярылган ике ташны култык астына кыстыра да тауга менеп китә». Авыр әйберләр ыргыту буенча «Ак бүре» әкиятендә сурәтләнгән ярышлар булуы да ихтимал: «Диюнең һөнәре шул иде, буш вакытларда шул шарны (биш йөз пот авырлыгында) алып атып, менә шул биек тауның башына очыртып җибәреп, шар төшкән чагында яңадан бер кулы белән тотып алып, һавага ыргытып җибәрә иде».

Бүгенге көндә дә Сабан туе халкыбызның иң олы бәйрәмнәреннән берсе. Ул чәчү беткәч, июнь аеның беренче атналарында авылларда һәм район үзәкләрендә, аннары ай урталарында республикабызның зур шәһәрләрендә уздырыла. Хәзерге сабан туйларын үткәрү – элекке вакыттагы җыеннар уздыру вакытына туры килә. Июнь ахырында җөмһүриятебезнең башкаласында зур республика Сабан туе була. Сабантуй бәйрәмен үткәрү датасын хакимият тарафыннан билгеләнә [1, б. 22].

Алмачуарның һәлак булуы хакында: Галимҗан Ибраһимов бу мәсьәләдә үзен ветеринария белгече дәрәҗәсендә компетентлы булуын күрсәтә. Сабантуй алдыннан Алмачуарны дөрес ашаталар, дөрес тәрбиялиләр, ләкин яраулау, ягъни тренировка, стадиясендә Алмачуарны елдагыча була торган дистанциягә – җиде-сигез чакрымга әзерлиләр, ә бәйге көтмәгәндә, унбиш чакрымнан булып чыга. Гомерендә беренче тапкыр ярышка чыккан, холкы белән албирмәс, азартлы Алмачуар, бәйге башланганчы ук инде, һәлакәтле, халыкча әйткәндә – янып үлүгә-хөкем ителгән була. Бу – беренчедән, ә икенчедән – автор да, халык та бу гүзәл затка, артык сокланып карап, күз тидергән булулары да ихтимал. Әлбәттә, күз тиюне реаль нәрсә дип кабул итсәк.

Шулай итеп, Г. Ибраһимов иҗатында фольклор мотивлар зур роль уйныйлар. Алар, үзенә күрә, халыктан калган зур әдәби мирас буларак авторга ярдәм итеп, халыкның яшәешен, колоритын, рухын, тормыш-көнкүрешен ачыклап, укычуга әсәрләрне аңлау юлында әһәмияте бик зур булып кала. Әйтергә кирәк, Г. Ибраһимовның әдәби иҗаты гаять үзенчәлекле һәм бай. Ул мирас вакытлар үткән саен үзенең яңа сыйфатлары белән ачыла бара.

ӘДӘБИЯТ


1. Баязитова Ф.С. Г. Ибраһимов әсәрләрендә этнографизмнар. Казан: 2007. 87 б.
2. Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман: Тууна 115 ел тулуга багышланган фәнни конференция материаллары. Казан: Фикер, 2003. 270 б.
3. Гимазиев Ү. Талант һәм хезмәт: Галимьян Ибраһимов ижады тураһында әдәби- публицистик мәкәләләр. Уфа: Башкорт. кит. нәшр., 1982. 160 б.
4. Гыйльман Г. Әдәби мирас. 4 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. 189 б.
5. Госман Х. Борынгы төрки һәм татар әдәбиятының чыганаклары. Казан: КДУ, 1981. 515 б.
6. Ибраһимов Г. Мәкаләләр, истәлек-хәтирәләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. 544 б.
7. Ибраһимов Г. Сайланма әсәрләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. 464 б.
8. Мөхәммәтҗанов Р.М. Г. Ибраһимов фольклоризмы һәм татар совет прозасы // Әдипнең 100 еллыгына багышланган фәнни конференция тезислары. Уфа, 1987. Б. 23–28.
9. Садекова А.Х. Фольклор в эстетике Галимджана Ибрагимова. Казань: ИЯЛИ, 1995. 103 б.


## ЯРДӘМ ЮЛЫНДА


***Хөснетдинова Г.А.***



В статье рассматривается история создания литературных сборников, изданных в помощь голодающим Поволжья в 1921–22 годах XX века. Они были составлены и изданы татарскими писателями и издателями под руководством Г. Ибрагимова. Дается краткая информация о произведениях и авторах, включенных в сборники, и анализируются данные на сборники рецензии.

This article deals with the history of literary anthologies, published for famine relief in the Volga region in 1921–22 years of XX century. They have been compiled and

published by the Tatar writers and publishers under the leadership of G. Ibragimov. Brief information about the works and authors included in the compilations and analyses them.

1921–1922 еллар ачлыгы Татарстанда 1921 елның көзендә башлана. 1921 елның ахырында ачларга ярдәм оештыру комиссиясе төзелә (Татпомгол). Бу комиссия 1922 елның августына чаклы Беларустан һәм РСФСР өлкәләреннән азык-төлек, чәчүлек орлыгы кайтара. Ачлык афәте кичермәгән төбәкләргә меңләгән кешеләр озатыла. Авыл һәм шәһәрләрдә ачка интегүчеләрне дәүләт һәм җәмәгатьчелек ярдәмендә ашату пунктлары оештырыла.

Бу эштән Татарстан язучылары да читтә калмый. Алар иҗатлары белән ачлыктан интеккән халыкка каләмнәреннән килгән кадәр ярдәм итү өчен «Әдәби ярдәм мәҗмугасы» исемле җыентык оештырып бастыру эшенә керешәләр. Эшнең башында әдәби иҗаты һәм сәяси эшчәнлеге белән танылган язучы, җәмәгать эшлеклесе Г. Ибраһимов тора.

Вакытлы матбугат битләрендә китерелгән мәгълүматка караганда «Әдәби ярдәм мәҗмугасы»ның беренче китабы 1922 елның гыйнвар айларында басылган булса кирәк. Моңа дәлил итеп, «Татарстан хәбәрләре» газетасының 25 гыйнвар санында басылган белдерү-хәбәрләрне күрсәтергә була. Берничә санда басылган бу хәбәрләрдә «Мөһим әдәби әсәр. Бөтен килере ачларга багышланган «Әдәби ярдәм мәҗмугасы» (альманах) басылып тәмам булды. Мәҗмуга Галимҗан Ибраһимов редакциясендә чыга. 130 бит, хакы 40 мең сум» [8], дип язылган һәм шуңа өстәп күпләп алдыру өчен адреслар да күрсәтелгән.

Казанда 2 нче номерлы Дәүләт басмаханәсендә ачлар файдасына багышланган бу мәҗмуга 10000 тираж белән дөнья күрә. «Ярдәм» мәҗмугасын башкарып чыгару комиссиясенең рәисе Галимҗан Ибраһимов китапка язган аңлатма-керешендә «мәҗмуганың ачлыктан һәлак булып барган эшче-крәстиян кардәшләрне коткару юлында кулдан килгән кадәрле ярдәмгә тырышуларының җимеше булып чыгуын» [3, б. 2] яза. Һәммә язучыларның әсәрләрен мәҗмуга өчен буш бирүләре, хәреф җыючыларның, үзләренең ярым ач хәлдә яшәүләренә карамастан, мәҗмуганың күбрәк өлешен «җомга өмәсе» ясап җыюлары, Дәүләт нәшриятенең кәгазь белән «Полиграф» шөгъбәсе матбага көче белән ярдәм итүләре өчен мәҗмуганы башкару комиссиясе әгъзалар Фәтхи Бурнаш һәм Бирюков исеменнән рәхмәт белдерә һәм башка аркадашларыннан бу мәҗмуганың тизлектә таралуына ярдәм итүләрен үтенә.

«Әдәби ярдәм» мәҗмугасының беренче китабы Фәтхи Бурнашның «Ил көтә ...» исемле шигыре белән ачыла. Аннан соң Галимҗан Ибраһимовның Шәехзадә Бабич иҗатына багышланган «Вакытсыз һәлак булды» исемле тәнкыйть мәкаләсе, шагыйрьнең кайбер шигырь үрнәкләре китерелә. Шулай ук китапта Мәҗит Гафуриның «Соңгы минутта», Фатих Әмирханның «Беренче ашкыну» (басылмаган озын хикәясеннән бер кисәк), Фәтхи Бурнашның «Шәмсия» (басылмаган пьесадан бер кисәк), Кәрим Әмиринең «Ачлык көннәрендә», Гали Рәхимнең «Идел» хикәясеннән өзек, Г. Газизнең «Күмгән иде», Фатих Сәйфи-Казанлының «Крушниклар», Сәгыйть Сүнчәләйнең шигырьләре, Садри Җәлалның «Барыбер...» исеме белән басылган әсәрләре дә урын алган. Китапның болай итеп төзелү сәбәбен Г. Ибраһимов

«мәҗмуганың чыгуын ашыктыру өчен, әсәрләрнең урыннары кулга килеп керү тәртибе буенча куелды» [3, б. 2], дип аңлата. Чыннан да китапта бер язучыга да, аның әсәренә дә өстенлек бирелмәгән. Җыентыкка эшче-крәстиян тормышын язучы Г. Ибраһимов, Ф. Сәйфи-Казанлы әсәрләре белән бергә буржуаз әдәбияты вәкилләре дип исәпләнгән язучыларның әсәрләре дә кертелгән.

Тормыш авырлыкларыннан, ачлыктан алҗыган халык арасында мәҗмуга тиз арада таралган булса кирәк. «Татарстан хәбәрләре» газетасында «Ачлык белән көрәш» исеме белән басылган белдерү-мәкаләдә китерелгән мәгълүматка караганда «Әдәби ярдәм мәҗмугасы»ның беренче китабыннан ач балалар өчен 10 миллиард сум ярдәм китерелә [2].

Язучылар арасында башланган әлеге изге эшнең уңышларын исәпкә алып, Галимҗан Ибраһимов «Әдәби ярдәм мәҗмугасы»ның икенче китабын оештыру эшенә керешә. «Татарстан хәбәрләр» газетасының 1922 ел 10 февраль санында ул «Әдипләр, шагыйрьләр, наширлар, басмаханәчеләр дикъкатенә» исемле мөрәҗәгатен бастыра. Мөрәҗәгатьтә мәҗмуганың 10–12 табак зурлыгында ун мең булып басылачагы, бөтен килере ач балаларга багышлануы, һичкемгә хезмәте өчен бер нәрсә түләнмәячәге хакында белдерә. Ул ачлыктан һәлак булып барган эшче-крәстиән балаларына кулдан килгән кадәрле ярдәм итүне үзенең бурычы дип белгән язучылардан кулъязмаларын ашыгыч рәвештә тапшыруларын сорый.

Ә кәгазь һәм басу якларын тәэмин итү өчен Казандагы наширләрдән, басмаханәчеләрдән мәҗмуга өчен кәгазь һәм басу белән кемнең, ничек ярдәм итә алуын билгеләү хакында киңәш өчен җыелуларын үтенә [7].

Озак та үтми мәҗмуганың беренчесе артыннан ук матбугат мәйданына мәҗмуганың икенче китабы тәкъдим ителә.Ул әдипләр, шагыйрьләр, нашир һәм матбагачыларның бер коллектив буларак хезмәт-ярдәмнәре белән «Татарстан матбагасы» нәшриятендә басыла. Бу хакта «Татарстан» газетасының 1922 ел 20 июнь санында белдерү дә урнаштырыла.

Мәҗмуганың керешендә Г. Ибраһимов «икенче китапны да һичбер тиен чыгышсыз нәшер итеп, ач балалар файдасына саф килер хәлендә багышларга ирешә алдык» [4, б. 2] дип, шатланып яза.

«Әдәби ярдәм мәҗмугасы»ның беренчесе тәҗрибә сыман булса, икенчесе төплерәк рәвештә, мәгънә һәм зурлык ягыннан да тулырак, күркәмрәк булып чыга.

Мәҗмуга, Садри Җәлал тәнкыйтен истә тотып булса кирәк, Г. Тукайның 1911 елда язган «Көзге җилләр» шигыре белән ачыла. Аннан соң Г. Ибраһимов, Ф. Сәйфи-Казанлы, Ш. Госманов, Г. Рәхим, Ф. Әмирхан, Г. Газиз әсәрләре, Ш. Бабич, М. Гафури, М. Укмаси, Н. Думави, Сәмави, Әмири, З. Бәширова, М. Ярмөхәммәдләрнең шигырьләре урнаштырылган.

Китаплар басылып, сатуга чыгу белән «Татарстан хәбәрләре» газетасы битләрендә Садри Җәлал һәм Сәлах Атнагуловларның тәнкыйть мәкаләләре басыла.

«Ярдәм» мәҗмугасы» исеме белән беренче китап хакында язган мәкаләсендә тәнкыйтьче Садри Җәлал мәҗмуганы «әдәби яктан караганда шактый ук тулы һәм матур чыккан, чеп-чи тенденциозный нәрсәләр бөтенләй юк диярлек» [6], дип бәяли һәм  китапка кертелгән һәр язучыга, аның әсәренә кыскача анализ бирә. Мәсәлән, Г. Ибраһимовның Шәехзадә Бабич хакында язган мәкаләсен «...самими җәмәгать эшчеләребезне тәкъдир итүдә, Тукай

ише затларыбызның сәяси, иҗтимагый һәм әдәби эшләренә кыйммәт бирүдә үрнәк булып тотылыр», Ф. Бурнаш, Ш. Бабич, Ф. Сәйфи-Казанлы, М. Гали, Г. Газизләрнең әсәрләрен «хәзерге яңа карашлы яңа кешеләр тарафыннан да яратып укылырлык әдәби әсәрләр» дип мактаса, Ф. Әмирхан әсәрен «“Арцыбашев” агымы белән сугарылган» [6] дип, тәнкыйть итә.

Г. Рәхимнең «Идел» хикәясенә тәнкыйтьче аерым туктала. Ул «әлегә кадәр язган нәрсәләренә караганда бу иптәштә яхшы гына бер әдәби зәвык, көчле матур тел-өслүб булса, хәзер язган нәрсәләрендә артык бер төчелек һәм реальный тормыштан ераклык сизелүен» [6] ассызыклый. Язучының буржуаз, мещан сыйныфыннан булуына басым ясап, «...тиреслектә яшәүчеләр башка чылбырлар белән богауланганнар, алар башка җырлар, башка моңнар көйлиләр...» [6] дип, анализын тәмамлый.

Сәлах Атнагуловның «Татарстан» газетасының 1922 ел 2 июнь санында «Ярдәм мәҗмугалары» исеме белән басылган мәкалә-рецензиясе аерым игътибарга лаек.

Тәнкыйтьче фикеренчә, мәҗмугадагы әсәрләр тел, эчтәлек, мәгънә, сәнгать-матурлык ягыннан татар әдәбиятында ярылып яткан өч зур сыйнфый агым, тармак барлыгын күрсәтәләр. Беренче буржуаз агым тармагына ул – «Тәгъзия», «Ил көтә», «Сандугач ник соры булган?», «Барыбер...»ларне, икенче крәстиян әдәбияты агымына «Алмачуар», «Яңгырсыз елларда», «Язгы җил»ләрне, өченче эшче халык тормышы агымына «Крушниклар», «Эшче кызы – Нина», «Язмышка каршы», «Зимагур»ларны кертә.

Моңа өстәп Ф. Әмирханның «Тәгъзия»се белән М. Максудның «Язмышы», Г. Рәхимнең «Сандугач ник соры булган?» парчасы белән М. Галинең «Чукынган мәхзүм белән урыс зиярәтенә күмелгән хаҗи» парчаларының «бер-берсенә капма-каршы агымнарны күрсәтеп торуларын» [1] билгели.

Шунда ук ул «бу каршылыкларны сәяси агымнар каршылыгы рәвешендә йөртмәвен» искәртә һәм бары «татар әдәбиятында «Крушниклар», «Эшче кызы – Нина» кебек парчаларның мәйданга ташланганлыкларын сиздереп үтмәкче булуын» [1] белдерә.

Сүзен йомгаклап, мәҗмугаларның һәркемне кәнагатьләндерерлек әдәби әсәрләрне бергә җыйнаган, кулга тотарлык күркәм, әдәбият шүрлегендә күзгә бәрелерлек калын булып чыгуларын яза. Аларның китапханәләрдә генә түгел, мәктәпләрдә дә әдәби кулланма вазыйфасын үтәрлек әсәрләрдән санала алуларын билгеләп, китапларга үзенең уңай бәясен бирә.

Мәҗмуганың беренче китабы хакында язган С. Җәлал икенче китапка да, вакытлы матбугат битләрендә, үз мөнәсәбәтен белдереп рецензия бастыра. Ул С. Атнагулов фикерләренең хаталы булуларын ассызыклап, һәрбер әсәрнең башына «бусы шәп нәрсә, ә менә бусы – мәгънәсез әйбер», дип, ярлык ябыштырып куюны ташларга кирәклекне, «әсәрләр үзләре өчен һәрвакыт үзләре генә сөйләргә тиеш»лекне [5] икърар итә.

Мәҗмугалар хакында сүзне йомгаклап, аларның бер яктан ачларга ярдәм итү юлында билгеле бер нәтиҗә бирүләреннән тыш, якын киләчәктә туарга тиешле яңа әдәби журналларның беренче нигез ташлары да булаларын әйтеп үтәргә кирәк.

ӘДӘБИЯТ


1. Атнагулов С. «Ярдәм мәҗмугалары» // Татарстан. 1922. 2 июнь.
2. Ачлык белән көрәш // Татарстан хәбәрләре. 1922. 14 февраль.

3. Әдәби ярдәм мәҗмугасы. I китап. Казан. [1922]. 130 б.
4. Әдәби ярдәм мәҗмугасы. II китап. Казан. 1922. 240 б.
5. Җәлал Садри. Матбугат дөньясында // Татарстан. 1922. 15 август.
6. Җәлал Садри. «Ярдәм» мәҗмугасы // Татарстан хәбәрләре. 1922. 6 февраль.
7. Ибраһимов Г. Әдипләр, шагыйрьләр, наширләр, басмаханәчеләр дикъкатенә // Татарстан хәбәрләре. 1922. 10 февраль.
8. Мөһим әдәби әсәр // Татарстан хәбәрләре. 1922. 25 гыйнвар.

## УКЫРГА-ЯЗАРГА ӨЙРӘТҮНЕҢ ЯҢА ЮЛЛАРЫН ЭЗЛӘҮ ЧОРЫ

***Шәкүрова М.М.***

Статья посвящена исследованию научного наследия методики преподавания татарского языка в конце XIX – начале XX в. Нами были проанализированы грамматики, лингвометодические пособия, учебники по татарскому языку Г. Ибрагимова, Г. Сагди, М. Курбангалиева и др. В этот период основное внимание сосредоточено на изучении языка, на целях и задачах, методах и формах обучения татарскому языку. Первым научным трудом по методике татарского языка в татарской школе, не потерявшим своего значения в татароязычной аудитории, является работа великого татарского писателя Галимджана Ибрагимова «Татар телен ничек укытырга?» («Как преподавать татарский язык?»), опубликованная в 1916 г. Эта работа состоит из введения и шести глав, в которых заложены основы методики преподавания татарского языка в основном в начальных классах.

The article is devoted to the study of the scientific legacy of the methodology of teaching the Tatar language in the late XIX – early XX century. The first scientific work on the methodology of the Tatar language in the Tatar school, which did not lose its significance and in a foreign language audience, is the work of the great Tatar writer Galimdzhan Ibragimov «How to teach the Tatar language?», Published in 1916. This work consists of the introduction of six chapters, Which laid the foundations of the methodology of teaching the Tatar language mainly in primary classes.

XX гасыр башларында рус мәктәпләре белән берлектә махсус татар мәктәпләре өчен дә дәреслек хезмәтен башкарган әлифбалар, үз-үзеңә өйрәткечләр, грамматика китаплары, методик кулланмалар күпләп чыга башлый (Г. Ибраһимов, А. Максудов, С. Рахманкулов, Ш. Рәхмәтуллин, М. Юнусов, Г. Сәгъди, М. Корбангалиев һ.б.). Бу чорда башлангыч мәктәпләрдә татар телендә укырга-язарга өйрәтүне җиңеләйтү, җәдит мәктәпләре өчен татарча дөньяви әлифбалар төзү турында бәхәс бара. Татар тел белемен үстерүдә, укыту методикасын камилләштерүдә, грамматик төшенчәләрнең терминнарын булдыруда бер төркем тел-әдәбият белгечләре киң эш җәелдереп җибәрәләр: Г. Ибраһимов, В. Богородицкий, Г. Алпаров, Җ. Вәлиди, Г. Шәрәф, Г. Сәгъди, М. Корбангалиев, Г. Нугайбәк, Н. Хәким, Р. Газизов, Х. Бәдигъ, Г. Рәхим, Ф. Сәйфи, соңрак Л. Җәләй, В. Хангилдин, М. Фазлуллин.

1899 елда Уфада язу һәм тел мәсьәләләренә багышланган конференция үткәрелә. XX йөз башында татар әдәби теленең фонетик-орфографик нормалары турында бәхәсләр тагы да көчәеп китә, алфавитны алмаштыру

турында да сүзләр кузгатыла (С. Рәмиев, Г. Ибраһимов, Г. Алпаров, М. Корбангалиев, Г. Нугайбәк һ.б.).

1905 елда булган инкыйлаб җилләре нәтиҗәсендә Россия империясенең төрле төбәкләрендә (Казан, Уфа, Оренбург, Мәскәү, Петербург һ.б.) татар телендә газета-журналлар чыга башлый («Тәрбияи әтфаль» («Балалар тәрбиясе». Мәскәү), «Тәрбия» (Казан), «Мәктәп» (Казан), «Мөгаллим» (Оренбург) журналлары һ.б.). 1913–14 елларда чыккан «Мәктәп» журналы түбәндәге мәсьәләләрне яктырта: уку-укыту һәм тәрбиягә караган хәбәрләр; мәктәп фәннәре һәм аларның программалары; хатын-кыз мәгарифе; чит илләрдә мәгариф; әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләре, тел белеме; фәнни, тарихи һәм икътисади мәкаләләр; мәктәп-мәдрәсә тарихлары һ.б. [8, 5] Татар зыялыларыннан Г. Баттал, Һ. Атласи, Һ. Максуди, Г. Алпаров, Г. Ибраһимов, Н. Думавый, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан. Г. Мостафа һ.б. мәгариф мәсьәләләренә караган мәкаләләрен атап үтәсе килә.

Әлеге чорда шәкертләр уку-укыту программасына, надан хәлфә һәм ишаннарга ризасызлык белдерәләр, мәдрәсәләрне ташлап китәләр, фәннәрне киңрәк өйрәнүне таләп итәләр. Г. Тукай кадими укыту системасын тәнкыйтьли, бердәм, мәгърифәтле булырга чакыра («Туган тел», «Дустларга бер сүз», «Шәкерт, яки бер очрашу», «И каләм», «Беренче мәртәбә мәктәпкә бару», «Әлифба» һ.б.). Шагыйрь «Исемдә калганнар» дигән автобиографик әсәрендә Кырлай авылында башта бер ел кызлар белән бергә абыстайга дини китаплардан «Иман шарты»н өйрәнергә йөрүе, аннары икенче елны мәдрәсәгә баруы турында болай дип яза: «Мин мәдрәсәдә, «Һәфтияк» иҗеген вә сүрәсен бик тиз белгәч, «Бәдәвам», «Кисекбаш»ларга кердем. Үземнең сабагымны тиз белеп, миңа күп вакыт тик торырга туры килгәнгә, миңа өйрәтергә үземнән наданрак балаларны да бирә башладылар» [10, б. 21]. Г. Тукайның укыту-тәрбия өлкәсендәге карашлары, методик уйланулары барлыкка килә («Яңа кыйраәт» (1909), «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» (1910) һ.б.) [2, б. 37–44].

Татар теленнән беренче программалар XX гасыр башларында чыга: «Ибтидаи-рөшди мәктәпләр өчен» (1907), «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе программасы (1913) һ.б. «Мәдрәсәи Мөхәммәдия» программасында иң күп сәгатьләр рус телен өйрәнүгә бирелгән (һәр елны атнага 6 сәгать исәбеннән), 26 уку предметын өйрәнәләр, шул исәптән татар телен («төрки тел» исеме белән) һәм әдәбиятын да. Р. Әмирханов яңача укыта торган «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен октябрь борылышына кадәр булган бердәнбер татар университеты дип саный [1, б. 36–37]. 1882–1918 елларда әлеге уку йортында татар халкының атаклы уллары – азатлык өчен көрәшүчеләр, язучылар, шагыйрьләр, галимнәр белем ала: Х. Ямашев, С. Габбасов, Г. Камал, Ф. Әмирхан, М. Гафури, Ф. Бурнаш, К. Тинчурин, Г. Нугайбәк, Г. Шәрәф, Х. Бәдигый, А. Рәхим, Г. Гобәйдуллин һ.б.

XX гасыр башларында телне әдәбият белән бәйләп укыту, нәхү (синтаксис), сарыф (морфология) һәм имла (орфография) кагыйдәләрен билгеле бер тәртиптә өйрәтү, фәнни анализ ясау, дәреслекләр төзү, тыныш билгеләренең вазифалары белән таныштыру кебек мәсьәләләр игътибар үзәгендә тора. Татар телендә бер-бер артлы мәктәп дәреслекләре чыга башлый (Х. Максуди. «Төрки сарыфы», «Төрки нәхүе», 1910; Г. Ибраһимов. «Татар сарыфы», «Татар нәхүе», 1911; Г. Нугайбәк. «Төрлек»; Җ. Вәлиди. «Татар теленең имла

һәм сарыф вә нәхү кагыйдәләре», 1915; Г. Сәгъди. «Үз телебезчә мөкәммәл сарыф-нәхү», 1915 һ.б.).

Г. Сәгъди «Үз телебезчә мөкәммәл сарыф-нәхү» дигән дәреслегенең кереш сүзендә «Һәр мөгаллим галим була алса да, һәрбер галим мөгаллим вә педагог була алмыйдыр» дип искәртеп, дәреслек төзүнең гаять дәрәҗәдә катлаулы эш икәнлеген, зур тәҗрибә соравын әйтеп уза» [9, б. 4]. Бу дәреслек өч бүлектән, 36 дәрес үрнәгеннән гыйбарәт. Автор синтаксис һәм морфологияне бер яссылыкта карый. Мәсәлән, Г. Сәгъди 16 нчы дәрестә төшем тәмамлыгы (туры тәмамлык. – *М.Ш.*) турында мәгълүмат биргәндә, башта кушымталарны (кушымчаларны. – *М.Ш.*) тикшерә. Мисалларда бирелгән фигыльләр аша сорау куеп (мәсәлән, тоям (нәрсәне?), ишеттем (нәрсәне?) һ.б.), «төшем тәмамлыгының ахырына кушыла торган «-ны» кушымчасы кайсы бердә әйтелми дә калу» очрагын ассызыклап үтә: *Китап укыдым. Сыер саудым. Базардан күлмәклек алдым. Өй бураттым. Ат җиктем. Хат яздым.* Әле XX гасыр башларында, ягъни татар телендә тыныш билгеләрен куюга багышланган хезмәтләр чыга башлаган бер дәвердә Г. Сәгъди 10 төрле тыныш билгесен тикшерә, аларны кулланып, мисаллар белән ныгыта һәм кагыйдә рәвешенә китерә. Ул пунктуацияне синтаксик һәм интонацион принципларга салып аңлата [11, б. 36].

1915 елда Г. Ибраһимов сарыф-нәхү китапларының күпләп чыгуын бик хуплап каршы ала, аларның юнәлешен билгели, бу фәннәрнең бер рәвешкә кергәнлеген ассызыклый. Сарыф-нәхү китаплары, автор фикеренчә, «һәммәсе төп итеп татар телен, татар әдәбиятын ала, һәр сүзен вә һәр кагыйдәсен татар теленнән вә татар әдәбиятыннан алынган мисаллар белән ныгыта бара» [3].

Галимҗан Ибраһимов – татар телен укыту методикасына үзеннән зур өлеш керткән галим, укытучы-методист, язучы. Ул орфография, грамматика мәсьәләләре белән кызыксына, татар телен укыту методикасын эшли («Татар теле һәм татарча язу хакында бер сүз» (1910), «Татар нәхүе» (1911), «Татар сарыфы» (1911), «Татар имласы. Мәктәпләр өчен дәреслек» (1914), «Татар телен ничек укытырга. Телебезнең методикасы турында бер тәҗрибә» (1916) һ.б.). Ул 1910 елдан алып укытучы булып эшли башлый, дәреслекләр яза.

Г. Ибраһимовның «Татар сарыфы» дигән хезмәте мәктәп-мәдрәсәләр өчен кулланма рәвешендә язылган. Китапның теле гади, аңлаешлы, гамәли максатларны күздә тотып язылган. Мисалларны халык авыз иҗаты әсәрләреннән һәм Г. Тукай, Дәрдемәнд, Ф. Кәрими, Г. Исхакый һ.б. ала. Мәсәлән:

Шаулый диңгез, – җил өрәдер,
Җилкәнен киргән караб,
Төн вә көндез – ул йөзәдер:
Юл бара, ят ил карап. (Дәрдемәнд)

Бу шигырьдә «*диңгез*» сүзе олугъ суны, «*җил*» кузгалган һаваны аңлата. *Җилкән, караб, төн, көндез, юл, ил* дигән сүзләр дә һәрбере билгеле бер әйберне белдерәләр. Ягъни боларның һәрбере бер-бер нәрсәгә ат була. Шул рәвешчә: бер нәрсәнең атын (исмен) белдерә торган сүзләр «исем» дип атала. Югарыда саналган сүзләрнең һәрбере исемгә керә [4, б. 24]. Г. Ибраһимовта да «Исем» сүз төркемен өйрәткәндә, Дәрдемәндгә мөрәҗәгать итүен күрдек. Дәрдемәнд шигырьләренең шул дәрәҗәдә популяр булуына, укучы тарафыннан җылы кабул ителгәненә тагын бер кат ышанасың. Алга таба

М.Х. Корбангалиев, Р.С. Газизов, Х. Бәдигый, М. Фазлуллин һ.б. дәреслекләрендә дә Дәрдемәнд шигырьләреннән өзекләр еш очрый. Китап укучыларга аңлаешлы, гади телдә язылган.

Татарча уку-язуга өйрәтү методикасын үстерүдә Г. Ибраһимовның 1916 елда язган «Татар телен ничек укытырга? (Телебезнең методикасы хакында бер тәҗрибә)» исемле хезмәтенең гыйльми һәм гамәли әһәмияте зур була. Ул әлеге хезмәтенең кереш өлешендә мәктәп-мәдрәсәләрдә татар телен укытыргамы-юкмы дигән бәхәскә чик куя, ана телендә уку-язуга өйрәтүнең ысулларын күрсәтә, әһәмиятен билгели, төгәл бурычлар куя: «ана телен укытуда мәдәни халыклар тарафыннан гамәлгә куелган ысул вә нәзариятларны үз телемезнең хосусиятләренә һәм хәзерге иң төп хаҗәтләремезгә яраклаштырып эшләүдән гыйбарәт» [5, б. 135]. Г. Ибраһимовның «Татар телен ничек укытырга?» дигән лингводидактик хезмәтендә ысулы саутия белән әлифба укыту юллары өч чорга бүлеп карала: башлангыч дәресләр, әзерлек дәресләре, әлифба өйрәтү дәресләре. Автор грамотага өйрәтүнең бер системасын булдыра, уку-язуга өйрәтү методикасын яхшы белеп эш итә. Г. Ибраһимов дәресләрнең һәр төренә җентекләп туктала, бигрәк тә әлифба укыта башлау дәресләре, дөрес язарга өйрәтү турында тулы мәгълүмат бирә.

Г. Ибраһимовның уку-язуга өйрәтү мәсьәләсе М.Х. Корбангалиевнең «Дөрес язарга өйрәтү тәмринаты» дигән мәкаләсендә дә чагылыш таба. 1914 елда «Мәктәп» журналында басылып чыккан әлеге мәкаләдә автор төп ике ысулны билгеләп үтә:

1) имла (диктовка),

2) күчереп яздыру.

«Әлеге ике ысул бер-берсеннән аерылгысыз кулланылганда гына укучыларның дөрес язуына ирешергә мөмкин» – ди М.Х. Корбангалиев [6, б. 116]. Методист «өйрәтү имласы укырга-язарга өйрәтүнең әүвәлге дәресләреннән башланып, урта мәктәпне тәмамланганчы дәвам итәргә тиеш» дип саный. Кабатлау имласы өйрәтү имласы дәресеннән соң үткәрелә һәм «алга таба яңа кагыйдәләр өйрәтергә кирәкме, я шул өйрәткәннәрен кабатлатуны дәвам итәргәме?» дигән сорауларны ачыкларга ярдәм итә.

М.Х. Корбангалиевнең «Дөрес язарга өйрәтү тәмринаты» дигән мәкаләсендә дөрес язарга өйрәтү өчен, укучыларны шул кагыйдәдән файдалана белергә, аңа туры китереп, мисаллар табарга өйрәтергә кирәклеге ассызыклана. Биредә автор өйрәтү имласының бүгенге көндә дә киң кулланылышта булган дәрес планын тәкъдим итә. Күренекле методист, Г. Ибраһимов фикерләрен дәвам итеп, «Ана теле методикасы» (1918, 1920) дигән хезмәтендә башлангыч сыйныфларда уку-язуга өйрәтүнең ысулларын өч өлешкә бүлә, һәрберсенә җентекләп туктала. Мәсәлән, 1) хәрефләрне җыеп укыту ысулының (*тәркип ысуллары)* төп гамәле – «сүзнең өлешләреннән бөтен сүзгә күчү, ягъни укыту хәрефләрдән яки авазлардан башланып, иҗекләргә вә сүзләргә күчүе; 2) *тәхлил ысуллары* – укыту бөтен сүздән яки җөмләдән башланып, аларның өлешләренә, ягъни иҗекләргә, авазларга яки хәрефләргә күчү; 3) *тәхлил-тәркип ысуллары.* Болары белән укытканда, тәркип, тәхлил ысуллары бер-берсе белән төрле рәвештә бәгланып баралар» [7, б. 40]. Уку-язуга өйрәтү эшен җиңелләштерү максатыннан, М.Х. Корбангалиев рәсемнәр, шигырь-хикәяләр, уеннар, шакмаклар һ.б. файдаланырга кирәклекне хуплый, дәреслекләрдә аларны иркен куллана. Рәсемле әлифбаларның тарихын тасвирлап бирә: уйный-уйный укырга өйрәтүнең

тамырлары Германиядән кергән; алты тигез өлешкә бүленгән, һәрбер ягына берәр хәреф ябыштырылган шакмакларны XVII гасырда инглиз педагогы Локк тәкъдим иткән булган.

Гомумән алганда, XX гасыр башларында күтәрелгән проблемалар – укырга, сөйләргә, язарга өйрәтү методикасы – бүген дә актуаль. Дөрес язарга өйрәтү эше мәктәпләрдә иң авыр мәсьәләләрдән санала [12]. Бер төркем методистлар тел дәресләрен төрләндерергә, төрле алымнардан, уеннардан (бала белән ата-ана яки укучы белән укытучы үзләренең рольләрен алмашалар) файдаланалар, шулай ук Я.А. Коменский, Д. Локк, Ж.Ж. Руссо, К.Д. Ушинский кебек атаклы педагогларның фикерләренә дә нигезләнәләр. Әлеге чорда басылып чыккан дәреслекләр, методик кулланмаларны тикшереп чыкканнан соң, шуны әйтәсе килә: Г. Ибраһимов, Г. Сәгъди, М. Корбангалиев – чын мәгънәсендә үз эшен белеп, яратып башкаручы методистлар, тәҗрибәле укытучылар. Аларның методик кулланмалары, мәктәп дәреслекләре бүген дә үрнәк булып торырлык.

ӘДӘБИЯТ

1. Амирханов Р. У. Некоторые особенности развития народного образования у татар в дооктябрьский период // Народное просвещение у татар в дооктябрьский период. Казань, 1992. С. 36–37.

2. Заһидуллина Д. Ф. Урта мәктәптә татар телен укыту методикасы: Метод. кулланма / Д. Ф. Заһидуллина. Казан: Мәгариф, 2000. 483 б.

3. Ибраһимов Г. Татар сарыфлары // Аң. 1915. № 21–22.

4. Ибраһимов Г. Татар сарыфы / төз. Б. Э. Хәкимов һ.б. Казан, 2003. 118 б.

5. Ибраһимов Ф. И. Белем Әлифбадан башлана. Казан: Мәгариф, 1994. 256 б.

6. Корбангалиев М. Дөрес язарга өйрәтү тәмринаты // Мәктәп. 1914. № 5–6. Б. 116–118.

7. Корбангалиев М. Х. Ана теле методикасы. Казан: «Корылтай», 1920. 245 б.

8. Мәрдәнов Р. Ф. XX йөз башы татар тәгълим-тәрбия журналларының библиографик күрсәткече / Төз. Р. Ф. Мәрданов. Казан: «Милли китап» нәшр., 1997. 78 б.

9. Сәгъди Г. Үз телебезчә мөкәммәл сарыф-нәхү: Ирләр һәм кызлар мәктәбенең ибтидаи соңгы, рөшди беренче сыйныф шәкертләре өчен дәреслек. Казан: Умидъ, 1915.

10. Тукай Г. Әсәрләр: 5 томда / төз. Р. Гайнанов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 415 б.

11. Шакурова М. М. Становление и развитие методики преподавания татарского языка в иноязычной аудитории // Научный Татарстан. 2010. № 2. С. 36–47.

12. Шакурова М.М. Татарско-русское двуязычие: проблемы обучения языкам // Филологические науки. Вопросы теории и практики Philological Sciences. Lssues of Theory and Practice.Тамбов: Грамота, 2016. № 10. Ч. 2 С. 211–214.

## ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫҢ АНА ТЕЛЕН УКЫТУ ЭЧТӘЛЕГЕНӘ БӘЙЛЕ МЕТОДИК КАРАШЛАРЫ

***Юсупов А.Ф.***

Статья посвящена изучению методического наследия Г. Ибрагимова, в частности, исследованию формирования и развития методических взглядов ученого; анализу социально-культурных и языковых факторов, оказавших влияние на формирование методической концепции ученого. В ходе исследования описывается также сфера научных интересов Г. Ибрагимова относительно к содержанию процесса обучения к родному языку, что в начале XX века являлось сложным и противоречивым вопросом.

The article is devoted to the study of the methodological heritage of G. Ibrahimov, in particular, to the study of the formation and development of the methodological

views of the scientist; Analysis of socio-cultural and linguistic factors that influenced the formation of the methodological concept of the scientist. In the course of the research, G. Ibrahimov's sphere of scientific interests is also described in relation to the content of the learning process to the native language, which at the beginning of the 20th century was a complex and controversial issue.

Уку-укыту барышының эчтәлеге – яшь буынга нәрсә укытырга, кешелек дөньясы туплаган белемнәрдән кайсыларын сайларга дигән сорауга җавап ул. «Уку-укыту барышының эчтәлеге дип өйрәнү өчен сайлап алынган белем һәм күнекмәләр системасын атыйлар» [4, б. 316–317]. Уку-укыту барышының башка якларына бәйле буларак, эчтәлек катлаулы һәм каршылыклы рәвештә формалаша, аңа куелган максатлар, иҗтимагый һәм фәнни уңышлар, социаль һәм шәхси мәнфәгатьләр, педагогик мөмкинлекләр һ.б. тәэсир ясамый калмый.

Билгеле булганча, XX йөз башына кадәр татар мәктәп-мәдрәсәләрендә уку-укыту барышының эчтәлеге тулысынча дини өйрәтмәләргә бәйле була. Укыту системасы традицион рәвештә алып барыла, Коръән, хәдис, тәфсир кебек дини фәннәргә басым ясала. Телләрдән гарәп теле өйрәтү мөһим дип санала, урта гасырлар схоластикасында төп тикшеренү методы булган формаль логика (мантыйк) тирәнтен өйрәнелә. Мәктәп-мәдрәсәләрдә уку-укыту эше шушы рәвешле гасырлар буена бернинди үзгәреш кичермичә алып барыла. Әмма XX йөз башында мондый педагогик барыш татар җәмәгатьчелеген канәгатьләндерми башлый, аны яңарту теләге белән чыгыш ясаучылар барлыкка килә. Г. Ибраһимов та шундый шәхесләр рәтендә була.

Мәктәпнең төп максатын шәхесне җәмгыятьтә яшәүгә, үз-үзеңнераслауга, ягъни тормышка әзерләү дип белдереп, Г. Ибраһимов уку-укыту эшенең эчтәлеген дә гамәли як белән бәйләп аңлата. Аның фикеренчә, мәктәп-мәдрәсәләрдә укучыларга дөньяви тормыш, җәмгыять тормышында актив катнашу, шәхес буларак җәмгыятьтә үз урынын табу өчен кирәк булган белем һәм күнекмәләргә басым ясалырга тиеш. Бу исә яңа мәктәптә уку-укыту барышының эчтәлеген дөньяви фәннәр тәшкил итәргә тиеш дигән фикергә алып килә. Дөньяви фәннәрнең үзәген, аның фикеренчә, тел һәм әдәбият тәшкил итәргә тиеш.

Бу очракта ана телен предмет буларак кына өйрәнү күздә тотылмый, ә барлык башка фәннәрнең дә ана телендә үзләштерелүе мөһим дип санала. Бер яктан ул яшь буынны милли рухта тәрбияләүне күздә тота, икенче яктан мәктәптә барлык фәннәрне дә өйрәнү коралы итеп билгеләнә. Г. Ибраһимов үз ана телендә алынган белем генә төпле була ала дип саный. Бу сыйфатны ул милли мәктәптә уку-укыту эшенең төп һәм нәтиҗәле шарты итеп билгели: «Алдымызда торган бөек үзгәрешләрдә мәктәпнең, тәгълим-тәрбиянең бик зур роль уйнаячагы, мәктәп нинди генә нигезгә төзелсә дә, анда тел-әдәбият дәресләренең беренче урынны тотарга тиешлеге үзеннән-үзе билгеле бер мәсьәләдер. Мәдәни халыкларның мәктәпләрендә үк әһәмият бирелеп, укытылуы лазем вә фарыз дәрәҗәсендә тотылган фәннәрнең иң беренчесе «Тел вә әдәбияты миллия»дер. Тел вә әдәбиятның мәктәптә рәсми дәресләр эчендә тоткан урыны мәдәни халыклар тарафыннан күптән тәгаен кыйлынган. Ачык, табигый вә уңайлы рәвештә билгеләнеп беткән инде» [2, б. 233]. Бу мәсьәләдә Г. Ибраһимов башка халыкларның мәгърифәтчелек тәҗрибәсенә таянырга чакыра.

Г. Ибраһимовның ана телен һәм әдәбиятын укыту өлкәсендәге карашлары, гомумән үзенчәлекле. Аның методик карашлары бу яктан синкретик характерда дип әйтергә дә мөмкин булыр иде. Аның методик, педагогик эчтәлекле хезмәтләрендә тел һәм әдәбиятны укыту кушылып китә, дөресрәге, ул телне һәм әдәбиятны бер фән итеп укыту фикерен алга сөрә, телне әдәбиятның башлангычы, ә әдәбиятны телнең катлаулы формасы итеп карый, шуңа бәйле үз методик концепциясен тәкъдим итә. Аның фикеренчә, «мәгълүм ки, әдәбият әсәрләрдән, әсәрләр җөмләләрдән, җөмләләр сүзләрдән, сүзләр тавышлардан ясала. Димәк, тел вә әдәбиятның иң кечкенә кисәге, иң саф вә иң җиңел мәртәбәсе – сүзне ясый торган тавышлардыр. Шуңа күрә дә тел вә әдәбияте тәгълимиянең (әдәбият гыйлеменең) бисмилласы балага сүзләрне тәшкил итә торган тавышларның кагыйдәдә ничек сурәтләнүеннән, ягъни имлядан (әлифбадан) башлана» [2, б. 70].

Д.Ф. Заһидуллина Г. Ибраһимовның әдәбиятны укытуга бәйле карашларын өйрәнеп, шундый нәтиҗәгә килә: Г. Ибраһимов рус галимнәренең хезмәтләрен файдалана, укытучыларының берсе итеп ул Овсянико-Куликовскийны санавын әйтә. Казан университеты профессоры Д.Н. Овсянико-Куликовский да әдәбиятны, телдән барлыкка килеп, тел кебек үк 3 өлештән төзелгән дип саный: тышкы сүз формасы, эчке форма (образлылык) һәм эчтәлек яки идея. Әсәрнең идеясе субъектив, язучының шәхси карашын һәм тәэсир-кичерешләрен чагылдыра. Шуңа күрә әсәрнең эчке һәм тышкы формасы аерым кыйммәткә, әһәмияткә ия диеп белдерә. Тышкы сүз формасы – аваз һәм хәрефләр, тавышлар, сүзләр һәм җөмләләр. Шулай итеп, төгәл структура саклана: аваз – сүз – җөмлә. Алга таба күп җөмләләрдән төзелгән текстлар – әдәби әсәрләр тикшерелә башлый. Шул ноктада тел дәресләре әдәбият дәресләренә күчә [1, б. 54–59].

Мәктәптә ана телен укыту мәсьәләләренә багышлап, Г. Ибраһимов 1916 елда «Татар телен ничек укытырга?» исемле методик хезмәтен бастырып чыгара. Әлеге хезмәттә башлангыч мәктәптә татар телен укыту белән бәйле мәсьәләләр тикшерелә. Китапның кереш сүзендә автор мәктәпләрдә татар теле укытуның әһәмиятен гыйльми, милли һәм гамәли яктан нигезли.

Г. Ибраһимовның бу яктан да карашлары кызыклы, ул тел һәм фикерләүне аерылгысыз саный, ягъни телне фикерләүнең тышкы формасы дип карый. Шул сәбәпле, ана телен җентекләп өйрәнү кешедә фикерләү сәләтен үстерүгә нигез булдыра дип саный: «Адәмнең уйлавы аның теле белән бик нык багъланган. Рух һәм тел галимләре «кешедә уйлау куәтенең үсүе, уйларның ачык вә бөтен рәвеш алуы – аның теленең кинәюе, сүз вә лөгатьләренең бай булуы белән бик нык багълы» икәнен, «тел – уйлауның коралы, уйның калыбы» идекен икърар итәләр.

…Гомумән, адәм сүзсез уйлый алмый. Рухымыздагы бер мәгънә үзенә уйгын бер сүз белән тәгъбир ителгәнгәчә ничектер томанлы, таркау бер хәлдә була. Сүз шул таркау нәрсәне кысып китереп, бер калыпка сала, аңа сабит (тотрыклы) вә билгеле бер рәвеш бирә.

Димәк, безнең уйлавымызда телнең хезмәте бар.

Татар телен укытуның гыйльми әһәмиятләрендән берсе менә шул ноктадандыр: ана теле дәресләре шәкертләрне сүз вә җөмләгә баета, шуның белән уйлаулары өчен гомер барынча кирәк була торган коралларның берсен алар кулына биргән була» [3, б. 153–154].

Г. Ибраһимов фикеренчә, укучыларны фәнни рәвештә уйларга өйрәтү өчен ана теле бик уңайлы материал булып тора. Мәктәп белем һәм күнекмәләр бирү белән генә чикләнеп калырга тиеш түгел, ул укучының зиһенен ачу, аны фәнни, логик уйларга өйрәтүне дә алга сөрергә бурычлы.

Моннан тыш, һәр мәсьәләгә практик күзлектән карауучы кеше буларак, ул ана теле дәресләрендә балага алга таба тормышта кирәк булачак белем һәм күнекмәләр дә бирелергә тиеш дип саный. Мәктәптән соң да бала «китап аркылы үзенең рухын тәрбияләү, гакылын эшләтү, мәгълүматын арттыруда дәвам итсен!» [3, б. 157] дип уйлый.

Г. Ибраһимовның мәктәптә ана теле укыту хакындагы фикерләре бүген дә бик актуаль яңгырый, чөнки татар мәктәпләрендә уку-укыту эчтәлеген билгеләү мәсьәләсе әле дә бәхәсле һәм үзгәрүчән өлкәләрнең берсе булып кала бирә. Аның хезмәтләре мәктәпне милли нигездә кору барышында файдалы методик күрсәтмәләр табарга да мөмкинлек бирә.

ӘДӘБИЯТ

1. Заһидуллина Д.Ф. Г. Ибраһимов: әдәбиятны ничек укытырга? // Татарстан. 1996. № 7. Б. 54–59.

2. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. 5 т.: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). 615 б.

3. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 8 т.: төрки һәм татар теле белеме буенча хезмәтләр (1910–1930).431 б.

4. Подласый И.П. Педагогика: учеб. пособие для студентов высш. пед. учеб. заведений / И.П. Подласый. М.: Просвещение: Гуманит. издат. центр «ВЛАДОС», 1996. 631 с.

## РЕЧЕВЫЕ СТЕРЕОТИПЫ В ПРОИЗВЕДЕНИЯХ Г. ИБРАГИМОВА

***Юсупова А.Ш., Галимова Г.Н.***

В статье рассматриваются вопросы изучения речевого стереотипа в произведениях Г. Ибрагимова как средства межкультурной коммуникации. Подчеркивается необходимость изучения речевого стереотипа, который является одним из показателей межличностных отношений в языке, важным компонентом культуры и неотъемлемой частью общей системы этического поведения в обществе.

The article discusses the study of speech stereotype in the works of G. Ibragimov as a means of intercultural communication. Emphasizes the necessity of studying speech steriotip, which is one of the indicators of interpersonal relations in the language, an important component of culture and an integral part of the General system of ethical behavior in society.

Для современной лингвистики характерно изучение языка применительно к человеку, его сознанию, мышлению и практической деятельности. В этой связи возрастает научный интерес к национально-культурному аспекту исследования языка, к исследованию единиц языка и речи, отражающих явления, типичные для той или иной лингвокультуры. Развитие антропоцентрического подхода в лингвистике послужило новым источником познания системы общения, языковой ментальности, стереотипов общения и поведения, а также способствовало возникновению и развитию новых междисциплинарных научных направлений, таких как психолингвистика, социолингвистика, этнолингвистика, лингвокультурология, лингвострановедение.

Межкультурная коммуникация определяется не только социальными факторами, но и стереотипно-поведенческими условиями культур коммуникантов. Так, например, параллельно с усвоением языка происходит получение знаний о культуре и формирование способности понимать ментальность носителей другого языка. Гармоничная межкультурная коммуникация требует понимания стереотипов поведения, содержащихся в национальных традициях и их восприятии.

Исследование языка в лингвокультурологическом аспекте имеет непосредственное отношение к проблеме «язык и культура». Этот «особый аспект рассмотрения языка вне рамок его структуры связан с пониманием языка как системы, передающей в целом некоторую культуру, системы, в которой закодировано восприятие мира» [5, с. 63].

Речевой стереотип определяется как готовая речевая формула, быстро и экономно передающая общезначимое и общепонятное содержание в типичных ситуациях общения, выбирая которую автор формирует положительное, нейтральное или отрицательное отношение у читателей к речевому событию. К основным функциям речевых стереотипов относятся: неосознаваемая индивидом передача мыслей в процессе общения, обобщенное отражение повторяющихся явлений действительности, экономия речевых усилий с целью защиты нашего сознания от лишней работы по созданию новых речевых единиц, регулирование поведения участников общения.

Проведенный анализ существующих подходов к изучению природы речевых стереотипов позволяет сделать следующий вывод: понятие «речевой стереотип» объединяет разные по своей значимости для коммуникантов речевые единицы на основе их информативности и воспроизводимости в речи в готовом виде. Попытки разграничить их по стилистико-смысловому эффекту при восприятии читателями или по их значимости для коммуникантов привели к выделению понятий «клише», «стандарт», «штамп». Встречающиеся в лингвистике и в других науках понятия «стереотип», «трафарет», «шаблон», выводятся одно из другого и определяют, на наш взгляд, одно и то же явление, как прочно сложившийся, привычный образец чего-нибудь, не заключающий в себе ничего оригинального, творческого. В лингвистической литературе наряду с термином «стереотипы общения» также используются следующие наименования: «устойчивые формулы общения», «клише», «речевые штампы» и др [2, с. 5].

Так, в работах Н.И. Формановской стереотипы общения рассматриваются как единицы устного речевого этикета, к которым автор относит микросистему национально-специфичных вербальных единиц, «принятых и предписанных обществом для установления контакта с коммуникантами, поддержания общения в желательной тональности», соответственно правилам речевого поведения [7, с. 72–73].

По мнению С.М. Эрвин-Трипп, речевые стереотипы включают в себя «слова приветствия, благодарности, извинения – т.е. случаи, когда возможность альтернативных вариантов резко ограничена, и, следовательно, предсказуема» [8, с. 347].

В плане синтаксиса готовой речевой формулой может стать любая содержательно-смысловая единица языка (речи) – слово, словосочетание, предложение, лозунг, поговорка, фразеологизм, крылатое выражение и т.д. Можно заключить, что общезначимость информации требует стандартиза-

ции ее формы в регулярно повторяющихся, частотных ситуациях и ведет к образованию лингвистических единиц, которые воспроизводятся в речи в готовом виде, а не создаются вновь.

С точки зрения прагмалингвистики речевые стереотипы обладают прагмалингвистической значимостью, так как с их помощью выражаются различные оценочные отношения внутри данной социальной группы, но не всегда, а только в типичных ситуациях. И в этих условиях речевой стереотип обладает способностью осуществлять типизированное воздействие на личность, апеллируя к ее эмоционально-оценочному содержанию.

В настоящей работе на конкретном материале произведений татарского писателя Галимджана Ибрагимова рассматриваются речевые стереотипы общения, исследуется их тесная связь с культурой и языковым сознанием татар.

Галимджан Ибрагимов – один из ярких представителей советской национальной литературы. Даже емкое слово «писатель» не раскрывает полностью многогранную личность Ибрагимова, его роль в духовной истории татарского народа. Художник, воплотивший в своих произведениях основополагающие принципы социалистического реализма, критик и теоретик литературы, выдающийся ученый, государственный и общественный деятель, он был пионером новой национальной культуры.

Галимджан Ибрагимов внес огромный вклад в развитие татарской литературы. Еще в 1910 году вышел первый сборник его рассказов «Яз башы». Огромную популярность получили его повести «Татар хатыны нилəр күрми», «Карт ялчы», «Табигать балалары» другие рассказы. Творчество Ибрагимова оказало влияние на развитие художественной прозы всех тюркоязычных народов.

Появление стереотипных высказываний обусловлено прагматикой языка. Так, например, в процессе общения неоднократное повторение однотипных речевых ситуаций привело к образованию стереотипных коммуникативных единиц, которые обычно используются в подобных ситуациях. Стереотипные высказывания хранятся в виде готовых фраз (заготовок) в памяти человека и обычно всплывают в определенной конкретной ситуации. В произведениях Г. Ибрагимова неоднократно встречаются примеры подобным стереотипам: *«Хəерле сəгатьтə!»* [4, с. 226] – пожелание доброго в каких-либо начинаниях; *«Ахыры хəерлегə булсын!»* [4, с. 227] – проявление сомнения в продолжительности явления, которое принесло радость, счастье; *«Фатиха бирегез!»* [4, с. 176] – прошение благословления у старших при новых начинаниях и др.

В основе мировидения и миропонимания каждого народа лежит своя система предметных значений, социальных стереотипов, когнитивных схем. Именно определенная системность сознания, или образа мира, влияет на поведение представителей того или иного сообщества и определяется ею [6, с. 72]. Даже слова приветствия, либо прощания у разных народов будут разные. У Г. Ибрагимова использованы следующие традиционные выражения: *«Исəнме»* (жив ли?) [4, с. 21], *«Сау бул»* (будь здоров) [4, с. 16].

Стереотипы рассматриваются и как элементы, выполняющие в общении функцию «культурного кода», знание, которого дает возможность субъекту идентифицировать себя с определенной лингвокультурной общностью. Соответственно, принадлежность к конкретной культуре определяется наличием базового стереотипного ядра знаний. Так же существуют

устойчивые формулы общения, которые определяют религиозную принадлежность лица, использующего данные клише. Рассмотрим примеры из рассказов Г. Ибрагимова: *«Әссәламегаләйкем»* [4, с. 21] – слово приветствия, *«Аллага шөкер»* [4, с. 23] – хвала богу и др.

Бесспорным является и тот факт, что мы живем в мире стереотипов, навязанных нам культурой, поэтому совокупность ментальных стереотипов этноса известна каждому его представителю. Например, *«Җиңел аягы белән килгән булсын! Бәрәкәт китерсен!»* [4, с. 175] – говорится когда кто-то впервые приходит (заселяется) в дом; *«Сөенчегә нәрсә бирәсең?»* [4, с. 178] – просьба о вознаграждении за радостную весть; *«Каберең якын булмасын»* [4, с. 75] – нежелание иметь чего-либо общего с человеком, по отношению к которому сказано данное выражение; *«Күз тимәсен!»* [4, с. 185] – пожелание сбережения от сглаза, *«Йир йотсын, юк, кояштыр, юк…»* [4, с. 45] – клятвенные слова и др. Подобные стереотипы используются носителями языка в стандартных ситуациях общения. Ментальный стереотип – это некоторый фрагмент концептуальной картины мира, ментальная «картинка», устойчивое культурно-национальное представление о предмете, явлении или ситуации.

Закрепленные в национальном менталитете стереотипы поведения определяют специфику и своеобразие этикета данного народа. В настоящий момент нерешенным остается вопрос о специфике и типологии речевых стереотипов общения в разных лингвокультурах. В этом плане особый интерес представляет исследование этнокультурного аспекта речевых стереотипов общения татар, поскольку такие стереотипы ранее в науке не изучались.

ЛИТЕРАТУРА


1. Абаев В.И. Язык и мышление. М.: Наука, 1948. 365 с.

2. Бухаева Р.В. Этнокультурные стереотипы речевого общения (на материале бурятского языка): автореф. дис. ... д-ра филол. наук: 10.02.19. Улан-Удэ, 2015. 56 с.

3. Замалетдинов Р.Р. Татарская культура в языковом отражении / Р.Р. Замалетдинов. М.: ВЛАДОС; Казань: Магариф, 2004. 239 с.

4. Ибраһимов Г.Г. Хикәяләр, повесть, роман. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. 463 б.

5. Колшанский Г.В. Проблемы коммуникативной лингвистики // Вопросы языкознания. 1979. № 6. С. 51–63.

6. Уфимцева Н.В. Этнические и культурные стереотипы: кросскультурное исследование // РАН ИАН. Сер. Литература и язык. Т. 54. № 3. 1995. С. 52–73.

7. Формановская, Н.М. Коммуникативно-прагматические аспекты единиц общения / Н.М. Формановская. М.: Ин-т рус.яз. им. А.С. Пушкина, 1998. 291 с.

8. Эрвин-Трипп С.М. Язык. Тема. Слушатель: анализ взаимодействия // Новое в лингвистике. Вып. 7: Социолингвистика. М., 1975. С. 336–362.


# Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ «ТАТАР ШАГЫЙРЬЛӘРЕ» ХЕЗМӘТЕНДӘ Г. ТУКАЙ ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ СТИЛЕ ҺӘМ ПОЭТИКАСЫ МӘСЬӘЛӘСЕ


***Юсупова Н.М.***



Статья посвящена изучению труда Г. Ибрагимова «Татар шагыйрьләре», где на материале творчества С. Рамиева, Дардменда, Г. Тукая исследуется проблема поэтики, стиля татарской поэзии начала XX века. В книге, поднимающей проблемы поэта и поэзии, народности и национального своеобразия в художественной литературе, разрабатывая критерии эстетичности, определяя функ-

ции литературы, категории красоты, Г. Ибрагимов особое внимание уделяет особенностям стиля, поэтики в творчестве Тукая. На основе трансформации системы образов, стиля выявляется своеобразие его лирики, определяются национальные традиции и новшества.

The article is devoted to the study of the work of G. Ibragimov «Tatar stepper», where the material of S. Ramiev, Dardmend, G. Tukaya's creativity studies the problem of imagery, style of Tatar poetry of the beginning of the 20th century. In the book, raising the problems of the poet and poetry, national character and national identity in fiction, developing criteria for aesthetics, defining the functions of literature, the category of beauty, G. Ibrahimov pays special attention to the peculiarities of style, imagery in the work of Tukay. On the basis of the transformation of the system of images and style, the peculiarity of his lyrics is revealed, national traditions and innovations are determined.

Татар сүз сәнгате тарихында үзенчәлекле урынны биләгән XX йөз башында татар әдәбиятының идея эчтәлеге яңара; ул гыйлем, мәгърифәт, тәрбия һәм әхлак мәсьәләләреннән иҗтимагый, сәяси, аеруча милли проблемаларга йөз белән борыла, әдәби тәнкыйть формалаша, үсеш-үзгәрешләр кичереп, нәзарият кызу темплар белән үсеш ала. Шушы чорда әдәбият, әдәби тәнкыйть өлкәләрендә күзаллауларны, фикерләрне үзгәрткән, карашларны киңәйткән, татар мәдәнияте, сәнгате, тәнкыйте тарихында олы мирас калдырачак шәхесләр мәйданга чыга. Шундыйлардан Г. Ибраһимов – XX йөз әдәбият мәйданында тирән эз калдырган әдип, күп тәнкыйть мәкаләләре белән чыгышлар ясаган тәнкыйтьче, «милли әдәбият нәзариясенең нигезләрен эзләү юнәлешендә рухиятчеләр мәктәбенә нигез салучы»ларның берсе [6, б. 202].

«Татар шагыйрьләре» басылып чыгуга әдәби җәмәгатьчелекнең игътибар үзәгенә алына: «Татар шагыйрьләре» циклыннан шагыйрь һәм шагыйрьлек сәләте, шигъриятнең торышы, поэзиянең сурәтләү объекты мәсьәләләрен эченә алган берничә мәкалә – Җ. Вәлидинең «Татар шагыйрьләре» [1], Н. Хәлфинның «1913 елда татар шагыйрьләре» [10], Ф. Сәйфи-Казанлының «С. Сүнчәләй шигырьләре» [8] – әдәби мәйданга чыга.

Тәнкыйтьче-галим XX йөз башы татар әдәби тәнкыйтендә «Татар шагыйрьләре» хезмәте белән бәхәсләр, фикер төрлелеге уята. Ул китап тулысы белән 1913 нче елда дөнья күрә һәм Тукайны вакытсыз югалту кайгысын кичергән көннәрдә очраклы рәвештә Казан каласына килеп җитә [2, б. 25].

Романтик әдәбият һәм тәнкыйтьнең үрнәге булган «Татар шагыйрьләре» хезмәтендә Г. Ибраһимов өч шагыйрь – С. Рәмиев, Дәрдемәнд, Г. Тукай иҗатларын тикшерү объекты итеп ала. Монда шигырь һәм шагыйрь, назыйм һәм нәзым, матур әдәбиятның миллилеге, халыкчанлыгы, лирик әсәрләргә хас төп үзенчәлекләр, аның сурәтләү объекты, тел-өслүб, матурлык эстетик категориясе кебек әдәби, нәзари проблемалар күтәрелә.

Хезмәтнең иң күләмле өченче бүлеге Тукай поэзиясен өйрәнү объекты итеп ала. Г. Ибраһимов үз алдына «Тукай шагыйрьме, түгелме» соравын куя һәм нәтиҗәдә Тукайның шагыйрьлеген шик астына ала, шагыйрь иҗатына каршылыклы, тискәре бәя бирә. Мондый кискенлекнең сәбәбен үз чордашларыннан Н. Думави Галимҗан Ибраһимовның «Тукайны гареб шагыйрьләренә карап, гареб аңы белән үлчәү»дә [5, б. 158] күрә. Автор реалист Тукай иҗатын романтик иҗат принциплары, романтик эстетика

ноктасыннан чыгып өйрәнә [9, б. 125]. Шуңа да шагыйрьнең романтик эстетика таләпләренә җавап бирүче «Туган авыл», «Милли моңнар», «Җәйге таң хатирәсе» кебек шигырьләренә югары бәя бирә, «Тукаевтан күтәргә читен булган мәртәбәдә гүзәл әсәрләр» буларак билгели. Г. Ибраһимов Тукай поэзиясенең лирик ягына уңай мөнәсәбәтен белдерсә дә, иҗтимагый асылын кабул итә алмый, шагыйрьнең чын мәгънәсендә милли, халыкчан әсәрләре тәнкыйтькә дучар була [3, б. 185].

Тукай шигырьләренең поэтикасы, стиле мәсьәләсе дә тәнкыйтьченең игътибары үзәгендә тора. Гомумән, әдәби әсәрнең стиле XX гасыр башы әдәби тәнкыйтендә әдәби әсәрне бәяләүдә үзенчәлекле сыйфат буларак билгеләнә.

Д. Заһидуллина күрсәткәнчә, ул чорда стиль төшенчәсе «бик борынгы заманнардан килгән, татар нәзари фикеренә гарәп-төрек чыганаклары, Герберт Спенсерның «Стиль фәлсәфәсе» кебек китаплар аша үтеп кергән фикерләр» [6, б. 235] тәэсирендә формалаша, стильгә билгеле бер кагыйдәләрне, таләпләрне куя. Г. Сәгъди, Г. Баттал, Г. Ибраһимов өлешчә шушы өйрәтүгә таяналар. Г. Баттал әдәби әсәр тел-стилен система, бөтен итеп күзалларга мөмкинлек бирүче нәзария тәкъдим итә. Ул стильне өслүб, өслүбне язу рәвеше дип атый, моннан тыш тел чараларын, җөмләләрне тоташтыру үзенчәлеген дә шуңа кертеп карый [6, б. 150]. Г. Ибраһимов стильгә төп шартлар итеп дөреслек, сафлык, ачыклыкны күрсәтә, шуның белән бергә бүгенге әдәбият белемендәгечә үк, аның кагыйдәсен дә бирә. Ул нәзым, вәзен мәсьәләләрен дә стиль төшенчәсенә кертеп карый [6, б. 235]. Әдәби әсәрнең мәүзугъ, мөндәриҗә, план һәм тел-өслүб берлеге, гармониясе булуын күрсәтеп, автор аларның барысында – идеягә – төп уйга буйсындыра [6, б. 232].

Г. Ибраһимов Тукайның иҗатын бәяләүдә стиль, поэтика мәсьәләләрен алга чыгара һәм анализын шагыйрь әсәрләренең «тышкы ягын» бәяләүдән башлый. «Тышкы як»ны тәнкыйтьче «тел, ифадә һәм өслүб» буларак күздә тота. Гомумән, Тукай иҗатына багышланган мәкаләләрдә хезмәтләрдә тел-өслүб мәсьәләсе аеруча зур урын алып тора» [4, б. 39]. Г. Ибраһимов шагыйрь әсәрләренең стиле белән янәшәдә эчтәлеген – «эчке ягын» да янәшә анализлап бара: «...аның фикер вә тойгыларда үзгәреш кичергән бу дәверләре белән тел вә өслүб җәһәтеннән төзелүе янәшә рәвештәрәк баралар; аның эчке вә тышкы тәкямел кулга-кул бирешкәнгә охшаш бер хәлдә кузгалалар» [7, б. 127].

Тәнкыйтьче бу җәһәттән шагыйрь иҗатында, стиленә аваздаш төстә, өч дәверне аерып чыгара: «динчелек»,«Мөхәммәдия» чоры, «күчү дәвере», «татарлык» яки «миллилек» дәверләре.«Бөтен дөнья мөселманы өчен кайгырып, шул хакта фикер вә фәлсәфә саткан чорда аның тел вә өслүбе «Мөхәммәдия» дип атадыкымыз мәртәбәдә иде. Аның шигырь күзе татарга төшә башлау илә, теле дә бераз адәм рәтенә керде, аз булса да татарчага якынлап, теге «күчү дәвере» килде. Ниһаять, аңлап, нәзарияләп, миллият юлына бирелгәннән соң, аның инде тәмам татарчалашуы башлана. Һәм ул инде алган мәүзугъсы, тоткан өслүбе, язган теле – гомумән эчке вә тышкы хәлләре белән татарлыкны аңкыта» [7, б. 127], – дип, ул Тукайның стиль үсешен аерып куя.

«Мөхәммәдия» чорына Г. Ибраһимов стиль төзексезлеге ноктасыннан тискәре бәя бирә: «Бездә һичбер шагыйрь Тукай чаклы начар – буталчык тел белән башламады. Күрәсез, югарыдагы ун юл нәзымның лөгате нинди

дә, өслүб вә шивәсе нинди! Монда татар сүзе унга бер генә булып, калганы гарәптән, госманлылардан, сарттан, белмәм, тагы әллә кемнәрдән алынган. Тәркиб вә өслүбе кемчә һәм кемгә тәкълид икәнен бер ходай үзе белсен! Тукаев еллар буена шул телен, шул өслүбен ташлый алмый» [7, б. 112]. Шундый шигырьләре рәтенә тәнкыйтьче Г. Тукайның башлангыч чор иҗатыннан «И, каләм!», «Ифтиракъ соңында», «Шагыйрь вә Һатиф», «Гыйшык бу, йа», «Мөридләр каберстаныннан бер аваз», «Пушкинә», «Дәрдемәнд дәгелмием?», «Япунияи мөселман идәчәк голяма нәрсәдә?», «Бөрадәранә нәсихәт», «Хур кызына», «Милләтә», «Сүеглемең*** кабер ташында», «Шәкерт, яхуд тәсадеф», «Кем ул?», «Мөхәммәдия»дән», «Сөальләр» шигырьләрен кертеп карый. Бу чор иҗатына хас тискәре сыйфатлардан мәгънәләрне белдерүдә томанлык, дини терминнарның күп кулланылуы, ярымдөньяви, дини, әхлакый китаплар стиленә, шигырь формаларына таяну сыйфатлары аерып куела.

Бу чорның «Мөхәммәдия» дәвере дип аталуы кызыклы. Г. Ибраһимов аны үзе болай нигезли: «Ул дәвер язганнарында бик аз гына «Тәрҗеман» да бар, бик аз гына госманлы әдәбияты да күренә, ләкин иң көчлесе «Мөхәммәдия»дер. Аның вәзеннәренең байтагы «Мөхәммәдия»дәгечә улдыгы күренә... Шуның өчен Тукаевның бу язуларын тудырган заманны «Мөхәммәдия» дәвере» дип атау бер дә хаксыз булмас иде» [7, б. 117]. Шунда ук ул «Йосыф китабы», «Кисекбаш» китаплары йогынтысын да билгеләп куя. Билгеле булганча, бу чорга мөнәсәбәтле әсәрләр иҗат ителгән вакытта Тукай Җаекта яши, мәдрәсәдә белем алуы әсәрләрендә дини китапларның йогынтысын нигезләп куя да.

Алга таба тәнкыйтьче стиль камилләшүендә «татарлык» дәверен – өченче чорны аерып чыгара, аңа үз мөнәсәбәтен күрсәтә. Т. Гыйлаҗев фикеренчә, шагыйрьнең татарчылык дәверенә керүе 1907 нче еллардан соңгы чорга туры килә [4, б. 41].

«Татарлык» дәверенә хас төп сыйфатлар итеп Г. Ибраһимов Тукай стиленең садәлеген, «Тукай каләменнән көтәр дәрәҗәдә авыр булган» матурлыгын, халыкчанлыгын күрсәтеп, хиссилек, хис-кичереш сызыгының, пейзаж күренешләренең бирелешенә мөнәсәбәттә тасвирый стильнең формалашуын төгәлләштерә, мондый әсәрләрне иҗатының Казан чоры белән бәйләп куя. Мәсәлән, «Күз», «Ләззәт вә тәм нәрсәдә» һ.б. шигырьләрендә образлылыкның җитәрлек булмавы өслүбтә дә чатаклыклар китереп чыгара дигән фикерне ассызыклый. «Теләнче», «Эштән чыгарылган татар кызына» шигырьләре дә халык ишетергә теләгәнне генә биргән, ләкин тел-стиль ягыннан «азмы-күпме шигъри өслүбтә» язылган шигъри әсәрләр итеп бәяләнә.

Г. Ибраһимов Г. Тукайның тел-өслүб ягыннан камил әсәрләре итеп «Милли моңнар», «Су анасы», «Таз малай», «Җәйге таң хатирәсе» һ.б. шигырьләрен күрсәтә, аларны камил үрнәкләр дип бәяли. Аларга карата «моның мәүзугъсы, исеме генә түгел, теле, өслүбе вә бөтен торышы – халык хыялының, халык телендәге рухның үзе, нәкъ үзедер» дигән фикердә тора.

Күзәтүләрдән күренгәнчә, Г. Ибраһимовның «Татар шагыйрьләре» хезмәтендә Тукай иҗатындагы поэтика һәм стиль күренеше шактый эзлекле өйрәнелә. Г. Ибраһимов Тукай шигырьләренең образлылыгына, сүзләр бәйләнешенә, тел-сурәтләү чараларына, стиль сыйфатларына игътибар итә. Шул үрнәктә Г. Ибраһимов язучы стиле, чор стиле, стиль төрләре (мәсәлән, тасвирый стильне аерып билгели) күренешләрен ачыклый, фәнни нигезгә утырта.

ӘДӘБИЯТ

1. Вәлиди Җ. Татар шагыйрьләре // Вакыт. 1913. 25 апрель; 24 июль; 25 июль; 26 июль.

2. Гыйлаҗев Т. Әдәби мирас: тарих һәм заман. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 206 б.

3. Гыйлаҗев Т. Г. Ибраһимовның эстетикасында Г. Тукай иҗаты // Фән һәм мәктәп. 1998. № 7–8. Б. 183–186.

4. Гыйлаҗев Т. XX гасыр башы татар әдәби тәнкыйтендә Габдулла Тукай шигърияте-нең тел-өслүб мәсьәләсе // Әдәби мирас: тарих һәм заман. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. Б. 39–44.

5. Думави Н. Шәрыктан Гаребкә мөнәсәбәте илә // Аң. 1916. № 9. Б. 157–161.

6. Заһидуллина Д. Әдәбият кануннары һәм заман. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. 271 б.

7. Ибраһимов Г. Татар шагыйрьләре // Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. 5 т. Б. 74–157

8. Сәйфи-Казанлы Ф. Сәгыйть Сүнчәләй шигырьләре // Аң. 1913. № 21. Б. 8–14.

9. Хасанов М. Писатель, ученый, революционер. М.: Наука, 1987. 225 с.

10. Хәлфин Н. 1913 нче елда татар шагыйрьләре // Аң. 1914. № 1. Б. 11–12.

## Г. ИБРАҺИМОВ «МӨСЕЛМАН ИТТИФАКЫ» ПАРТИЯСЕ ХАКЫНДА

***Яхин Ф.З.***

Исследуя историю революционного движения татар, в 1925 году Г. Ибрагимов выпустил отдельную монографию. В третьей главе было раскрыто тактическое и политическое своеобразие партии татарской буржуазии «Союз мусульман». В нашей статье изучаются оценки Г. Ибрагимова данной партии, определяется, что он относил ее деятельность к революционно-демократическому движению.

Exploring the revolutionary movement of Tatars, G. Ibragimov has published the individual monograph in 1925. Tactical and political specificity of the Tatar bourgeoisie's party «The union of Muslim» have been disclosed by him in a chapter 3. In out article the evaluation by G.Ibragimov are studied for that party, and is defined, that he has been belonging its activities to the revolutionary-democratic movement.

Әдипнең татар тарихын тикшерүдә һәм аңлатуда ике хезмәтенә совет чорында аерым соклану белән бәя бирә иделәр. Аның беренчесе – «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре (1905)» булып, икенчесе – «Урал» һәм «уралчы»лар» дип атала.

«Татарлар арасында революция хәрәкәтләре (1905)» ВКП (б)ның Татарстан Өлкә Комитеты һәм Татарстан Башкарма Комитеты бүлекләре һәм комиссияләре карарлары белән Татарстан дәүләт нәшрияты тарафыннан Казанда 1925 елда аерым китап булып басылып чыга [3, б. 502]. «1926 елда русча басмасы да дөнья күрә. Китап турында 1926 елгы «Правда», «Известия» газеталарында, «Новый Восток» журналы битләрендә һәм башка газета-журналларда уңай рецензияләр була» [3, б. 502]. «Урал» һәм «уралчы»лар» исә «1927 елда Казанда аерым китап булып басылып чыга. Титул биткә «Урал» гәзитәсенең 20 еллык бәйрәмен үткәрү комиссиясе карамагында басыла» дигән искәрмә бирелгән» [3, б. 509]. Г. Ибраһимовның бу хезмәтләренә Х.Х. Хәсәнов, К.Ф. Фасеев, Ф.И. Агзамов, Р.И. Нафигов һәм башка галимнәр

югары бәя бирделәр [7, с. 3–138], М.К. Мөхәррәмов, С.Х. Алишев – әдипнең, тарихчы буларак, «марксист-тарихчыларының беренчеләреннән» булуына аерым игътибар иттеләр [3, б. 490]. Бу мәсьәлә белән М.Х. Хәсәнов аерым кызыксынды, Г. Ибраһимовның тормыш һәм иҗат юлын җентекле тикшереп фәнни монография язды һәм аны бөек язучы, революционер тарихчы буларак бәяләде [6, б. 224–227]. Ул фәнни тикшеренүләрендә галимнәр һәммәсе дә Г. Ибраһимовның марксистик-ленинчыл юлда булуын расладылар. Әмма шул заманга хас социологик принципны файдалануы белән бергә, илдәге сәяси вазгыятькә Г. Ибраһимовның бар тулылыгы белән бирелгәнлеген, коммунистик дәүләт системасының теләкләренә җавап бирүче хезмәтләр язуын, татар халкына һәм аның тарихына советларга кирәкчә мөнәсәбәт тудыруга омтылуларын аңласалар да, карашларының чикләнгәнлеге хакында фикер да йөрттеләр, аның милли хисләргә иярүләрен тоемлап, шушындый хаталану очракларына да игътибар иттеләр. Әмма бу хезмәтләре Г. Ибраһимовның, миллилеккә бирелүдән бигрәк, татар халкын бөек рус милләтенең сателлиты, иярчене, хезмәтчесе буларак аңлатып һәм сөйләп бирергә омтылышларыннан гыйбарәт иде. Ул тарихи-объективлык юлын сайлавын расларга тырышты, шул ук вакытта марксистик-ленинчыл социологиягә тулысынча буйсынып эш итүен дә күрсәтте.

Г. Ибраһимовның иҗат чоры гаҗәеп катлаулы дәвер иде. Бер яктан – солтангалиевчелек каты эзәрлекләнде, икенче яктан – илдәге сәяси вазгыять шактый буталчык иде, өченчедән – булып узган иҗтимагый-сәяси тетрәнүләр дәверен яхшы хәтерләгән халыкта шул үткәнгә карата ачык бер социологик караш тудыру галимнәрдән таләп ителде. Шушы соңгысын Г. Ибраһимов әдәбиятта да, фәндә башкарып чыга алды. Ясалма тарихлар бары тик югарыдан кушу белән генә һәм аларга ярарга тырышудан туа. Әгәр дә әдип шушы юлга басса, андый хезмәтләре белән хәтта үзенең әдәби әсәрләрен инкарь итәр иде. Социологик тарихлар ул елларда объективлык, партиялелек, марксизм-ленинизм исеменнән, татар милләтен тәмам кечерәйтүдән гыйбарәт хәлдә иҗат ителә башлыйлар. Без хәзер ул хакта ачыктан-ачык, турыдан-туры сөйләшә алырга тиешбез. Темабызның актуальлеге дә шуңардан гыйбарәт.

Г. Ибраһимов, шул чорның тарихчылары кебек, 1905–07 елгы Халык күтәрелешен татар милли азатлык хәрәкәтенә бәйле, аның үзенчәлекле күрсәткече буларак тикшерә, иҗтимагый үсешнең асылы буларак бәяли алмады. Менә шул сәбәпле татар буржуазиясе динчелектә гаепләнде. Югыйсә татарда дингә сыену милли кысуларга каршы протест рәвешен алган иде инде. Бездәге дини хәрәкәтләр эчтәлекләре белән милли-азатлык хәрәкәтләре дә иделәр. Менә шуның өчен дә, аңлашылып тора, 1905–07 елгы Халык күтәрелеше моңа кадәр барган милли-азатлык хәрәкәтләреннән бер этабының, әмма беренче этабының түгел, махсус тикшерүгә лаеклы нәтиҗәсе иде, шул ук вакытта ул яңа чорны да башлап җибәрде. Аның либерализм дәвере булуы аңлашылып тора. Икенчедән, 1905–07 елгы Халык күтәрелеше милли-азатлык һәм революцион хәрәкәтләрнең һичшиксез җиңү белән тәмамланачагына ышаныч тудырды. Өченчедән, 1905–07 елгы Халык күтәрелеше татар милли революцион көчләренең мәдәни яктан алдынгы һәм халыкларны әйдәп барырлык дәрәҗәдә өстенлекле булуын да күрсәтте. Бу яктан татар халкы белән, мәсәлән, поляклар арасында аермалар юк дәрәҗәсендә иде. Әмма алдагы хәрәкәтләрдә бөтен авырлыклар

татар халкына төшәсен, Россия уртасындагы саналган, әмма мәмләкәтнең һәммә өлкәләрендә диярлек үз җирләрендә яшәүче татар халкына милләтне географик җирлек белән бәйләп карау хата икәнлеген, бары тик мәдәни мохтарият кысаларында күзаллауның дөрес һәм табигый булуын төшенүгә юл ачты, шул хакыйкатьләрне ачык күрсәтеп бирде. Моны аңлау алдынгы көчләрнең югары фикерле булулары хакында сөйли иде. Әмма Г. Ибраһимов башкача уйлый, башка төрле нәтиҗәләр чыгара. Сәбәбе, әлбәттә, бик гади. Ул иҗтимагый үсеш, иҗтимагый аң белән сыйнфый үсеш һәм аңны бер ноктада карый, шуның нәтиҗәсендә тарихи карашлар системасын тудыра. Бу аның марксистик-ленинчыл социологик принципларның нигезләрен төгәл үзләштерүеннән килә. Г. Ибраһимов гомумән дә европа һәм рус акыл ияләренә, авторитетларына ияргә яшьли өйрәнә. Аның бу үзенчәлеге «Татар шагыйрьләре» (1913–1914) хезмәтендә аеруча ачык чагыла. Татар дөньясын «мәдрәсә исе килүче» буларак бәяләп, европоцентристик идеалларны ул үзенә байрак итә һәм халыкны да шул идеалларга ияргә чакыра. Татар милли буржуазиясенең формалашуын һәм югары катламы тарихын, үзенчәлекләрен тикшергәндә Г. Ибраһимов аның Россия империясенә хезмәт итүенә төп басымны ясый, әмма империя ягында торганына карагада, «турыдан-туры татар җәмәгать эшләрен үзенә кәсеп итеп алган» [3, б. 355] булуына бар игътибарны юнәлтә. Бу үзенчәлеге әдипнең тарихи хәрәкәтләрне милли кысаларда карарга кирәклеген ачык күзалламавыннан килә. Әгәр дә аның аңында марксистик-ленинчыл тенденциоз карашлар бөтен тулылыгы белән аңына урнашып җиткән булса, ул татар буржуазиясенең калган ике катламын да шул ук бәя кысаларында карамый калмас иде. Әмма алар аны кызыксындырмыйлар, чөнки социологик тарих өчен ул катламнарның роле юклыгын әдип инде ачык күрә. Бу ике катламның берсен ул «самодержавиягә багланган» [3, б. 355] алпавытлар-мирзалар буларак атый, икенчесен «иске тип чиновник булып каткан» [3, б. 355] төркемгә кертә, «болар бюрократия лагерында калдыралар» [3, б. 355] дип белдерә. Татар милли-азатлык хәрәкәте һәм аның тирән тамырлары да Г. Ибраһимов фикерләмәләреннән шулай ук читкә чыгарыла. Патша фәрманнарына буйсынмау, җирдән-байлыктан милли мәнфәгатьләрне өстен куйган татарның югары катламы оештырган аң уяту, дини реформалар уздыру кебек катлаулы фикер үсеше хәрәкәтләре, аларның халык эченә китүләре һәм бу процессларның бездә көчле булуына төпләп игътибар тиешле дәрәҗәдә бирелми. Бөтен мәсьәләләр сыйнфый мәнфәгать таләбенчә алга куела. Чөнки боларны факт буларак искә алу һәм кузгату гына да социологик теориянең асылын какшатыр иде.

Татар буржуазиясе XX гасыр башына кадәр үк, XIX йөзнең урталарына үз идеологиясен булдырып, җәдитчелек кысаларында аны алга таба үстерде. 1883 елда «Тәрҗеман» газетасы чыгарыла башлый. Милли хәрәкәтнең сүз ирене алу юнәлешендә бу беренче бөек җиңүләреннән берсе иде. Чөнки татар милли буржуазиясе 1906 елгы Конституцион ирекләргә кадәр үк, төрле китап нәшриятлары һәм типографияләре булдырып, милли җәмәгатьчелеккә хезмәттә шактый мактаулы уңышларга ирешә алды. Шундыйларның тагын да берсе – чын мәгънәсендә милли мәктәпне тудыру, аны ныгыту, саклап калу һәм үстерүдән гыйбарәт иде. Г. Ибраһимов та, аңардан соң да социология кысаларында үстерелгән тарих гыйлеме бу милли казанышларга озак еллар бәя бирә алудан мәхрүм калды. «Китап дөньясына сәяхәт» хезмәтен-

дә галим Ә.Г. Кәримуллин 1612 елдан татар милли басма китабының яшәү тарихын ачыклап [4, б. 14], патша цензурасы заманнарында аның шактый көчле басым һәм каршылыкларга дучар булганлыгын, әмма халыкка аңбелем тарату юлында хезмәт итүен ачык аңлатып бирә алды, ә 1905–07 еллардагы Халык күтәрелешеннән соң да, конституцион ирекләр бирелүгә карамастан, Россия шартларында шактый авырлыклар белән яшәвен язды [4, б. 206]. Г. Ибраһимов исә «татар буржуазиясенең Беренче революциягә кергәндә әйтерлек әзерлеге дә, ачык яки яшерен организациясе дә, партиясе дә булмады» [3, б. 355] дип язды, Габдерәшит Ибраһимовның (1857–1944) «милли кыңгырау» аталуының тарихын да ачмады, аны бары тик «татар буржуа-алпавыт дөньясының тарихи кыңгырагы» [3, б. 357] дип, кимсетеп, Россия Эчке эшләр министрлыгының агенты рәвешендәрәк кенә телгә алды, татар идеологларыннан һәм бөек галимнәреннән берсе Муса Бигиев (1873–1949) та аның өчен «Мөселман иттифакы» партиясенең «җанлы протоколы» [3, б. 357] гына иде. Әгәр дә ул аларның тарихи-мәдәни эшчәнлекләрен ача башласа, сайлап алган методына һәм стиленә хилафлык киләчәк иде, әлбәттә. Ничек тә татар милли буржуаз көчләрнең дәрәҗәсен төшерү омтылышлары аның тенденциозлыгын көчәйтте генә. Андый урыннарда ул тарихчы булудан пропагандист роленә күчә. Менә шуңа күрә дә татар пролетар оешмаларының нәкъ башка телдә сөйләшүче эшчеләр кебек үк эшләрне оештырып алып бару, «социал-демократия байрагы астында берләшү, тик агитация, пропаганда чараларында гына татар өчен аерым методлар куллану» [3, б. 356] сыйфатлары аны сокландырды. Дөрес, ул яктан татарның сокландыргыч эшләре бар иде. Большевистик басма китаплар, брошюралар, листовкаларның XX йөз башында масса төсен алуы И. Абдуллинга, «Большевистик көрәшчән сүз» исеме астында аларны махсус туплап, өйрәнеп, бәяләп, аларны 1987 елда аерым китап буларак бастырып чыгарырга мөмкинлек бирде [1, б. 31–33], беренче татар пролетар язучы Г. Коләхмәтов XX йөз башында «Уалган мол» хикәясен язды, «Ике фикер», «Яшь гомер» большевистик драмаларын иҗат итте [2, б. 36–37]. Бу фактлар татарларда 1917 елга кадәр сыйнфый аңның шактый югары булганлыгы хакында сөйли, бәхәс юк. Бу исә татар буржуазиясенең милли-азатлык идеалларына хезмәт итәргә чакыруларының сәбәпләрен дә ачык күрсәтә. Әмма изелгән милләттә сыйнфый көрәш башлану өчен, марксистик-ленинчыл тәгълимат аңлатуынча, милли-азатлык хәрәкәтенең уңышка ирешүе шарт [5, с. 270–271]. Г. Ибраһимов моны танымый, хәтта искә дә алмый. Бу түгелме аның тенденциозлыгы күрсәткече?

Милләтенең дәрәҗәсен төшерү, аны мескен, тормыш өчен яраксыз итеп тасвир итү өчен Г. Ибраһимовка аның авангард рус халкыннан башка, үз мөстәкыйльлегендә, беркем дә түгеллеге уйдырмасын уйлап чыгарырга, моның өчен берничә мисал да китерергә кирәк була. Материалны ул «Мөселман иттифакы» документлары арасыннан барлый, төп матбугат чаралары булган «Казан мөхбире» газетасын актара. Турыдан-туры дәлил ролен үтәрлек мисалларга очрамагач, арадан кайбер вакыйгаларны көлкегә алудан гайре чарасы калмый. Шул рәвешле «Иттифак»ның Икенче съезды барышы вакыйгалары аерым һәм максатлы мыскыллана [3, б. 365–366]. «Конституцион-демократия партиясе» белән кушылуны да, шушы кадетларның 1906 елгы съездда докладчыларыннан татарны һәм Чыңгыз ханны искә алып сөйләгәннәрендә Йосыф Акчураның француз телендә керткән

кисәтүләрен дә ул «иркәләнү» буларак атый [3, б. 376–377]. Съезд рәисе князь Василий Александрович Долгоруков (1868–1918), ягъни 1907 елдан башлап Николай патшаның адъютанты, аннары генерал-майор, сарайдагы үзара исеме – «гофмаршал Валя», үзе махсус, турыдан-туры килеп тә, ахырдан да «Иттифак» вәкилләре һәм, шәхсән, Йосыф Акчура каршында берничә тапкыр гафу үтенүләре дә Г. Ибраһимов каләме өчен Россиядә татар мәртәбәсе күрсәткечләре түгел [3, б. 377]. Шунысы гаҗәп, русның алдынгы карашлы акыл ияләреннән, олы алпавытларыннан берсе Федор Измайлович Родичев (1854–1933) «Россиядәге җәмәгать белән җир биләү ысулын тәнкыйть кылып сөйләгәндә, «бу борынгы татар урдалары заманыннан калган начар бер мирас» дигән мәгънәдә» [3, б. 377] чыгыш ясый. Моны Г. Ибраһимов аерым игътибарга ала, әмма көлке бер ситуация буларак мисалга китерә. Мондый урыннар аның акылының «төрттерү», «чыгымлап кую» үзенчәлегеннән килә. Әмма андый хисләргә бу тарихи хезмәтләрендә ул бик сирәк бирелү җаен карый. Татар милли-буржуаз хәрәкәтенең көчен, аның Россиядә алдынгы урыннарга менүен, яңа заманның яңа эшләре өчен әзер булуын, әйдәп баручы көчкә әверелүен, сәяси яктан җитлеккәнлеген Г. Ибраһимов күрми кала алмый, анысы. Әмма аларга дөрес бәяне ул шушы язмаларыннан читтә куя. Әмма, Дәүләт думасы депутатлары хакында сүз кузгатканда, «монда татар милли буржуазиясенең атаклы юлбашчыларыннан төпле сәясәтче Йосыф Акчуриннар, оренбурглы төпле сәясәтче Фатих Кәримиләр кебек фамилияләр юк» [3, б. 382] дип белдермичә узмый. Димәк, татарның акыл ияләреннән, төпле кешеләреннән Россия патша хөкүмәтенең коты алынып торган, андыйлар булса, аларны дәүләт һәм халык бәхете өчен эшләрдән мөмкин кадәр читләштерергә тырышкан. Мондый сәясәтнең ил өчен зыянлы булуын Г. Ибраһимов искәртми кала алмаган. Бу урыннарда аның шәхси хисләре дә уйнап алган. Әмма, шушындый ачышлары булуга да карамастан, аның тарихи хезмәтләре социологик һәм рус большевикларының тенденциозлыгы кысаларына куып кертелгән марксистик-ленинчыл дип аталган карашларга буйсындырылып язылганнар. Бу яктан безнең әдибебез татарда алда баручылардан берсе иде. Аның талантлы, әдип буларак тасвирлы күзаллаулары, оста каләме халык эчендә коммунистик тенденциоз идеологиянең җәелүенә уңышлы хезмәт итте.

ӘДӘБИЯТ


1. Большевистик сугышчан сүз / төзүчесе һәм кереш сүз, искәрмәләр авторы – Абдуллин И.А. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 279 б.

2. Гыйззәт Б. Татар пролетариат әдәбиятына нигез салучы // Гафур Коләхметов: Революционер-язучының 100 еллыгына багышланган мәкаләләр җыентыгы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. Б. 26–37.

3. Ибрагимов Г. Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 7 т.: Тарихи хезмәтләр (1911–1927) / томны төзүче, текст, искәрмә һәм аңлатмаларны әзерләүче С.Х. Алишев. 539 б.

4. Кәримуллин Ә.Г. Китап дөньясына сәяхәт: Татар басма сүзенең сәхифәләреннән. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 208 б.

5. Философский словарь / под редакцией Розенталя М.М. Изд. 3-е. М.: Политиздат, 1972. 496 с.

6. Хасанов М.Х. Писатель, ученый, революционер: Страницы жизни и творчества Галимджана Ибрагимова. М.: Наука, 1987. 318 с.

7. Хусаин Ямашев / составитель Х.Х. Хасанов. Казань: Татар. кн. изд-во, 1972. 136 с.

# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫҢ «ЯЗ БАШЫ» ҺӘМ «ДИҢГЕЗДӘ» ХИКӘЯЛӘРЕНДӘ АЖДАҺА ОБРАЗЫ

***Яхшисарова Г.Р.***

В статье рассматривается образ «Аждаха» в произведениях Г. Ибрагимова «Начало весны» («Яз башы») и «На море» («Диңгездә»).

The article discusses the mythical character «Dragon» in the works of G. Ibragimov «Beginning of spring» and «On the sea».

Кагыйдә буларак, язучылар үзләренең иҗатында фольклорга еш мөрәҗәгать итәләр. Г. Ибраһимов иҗатында да фольклордан алынган сюжетлар, мотивлар, образлар шактый. Галимнең «Әдәбият кануннары» дигән теоретик хезмәтендә халык иҗатына аерым бүлек багышланган. Анда татар фольклористикасына караган мөһим мәгълүматлар табарга мөмкин [5, б. 16]. Ул татар халык иҗатын бәет, җыр, әкият, мәкаль, табышмак, такмак, такмаза дигән жанрларга бүлә. Язучы җеннәр, албастылар, шүрәле һәм Су анасы әкиятләре, изге Гали әсәрләре, үги ана, үги кыз һәм таз егет турындагы әкиятләр, мәкаль һәм табышмакларны искә ала. Әсәрләренең эчтәлеген баету, сурәтләргә теләгән образларын тагын да тулырак һәм сәнгатьчә итеп бирү өчен, халыкның күп гасырлык тормыш тәҗрибәсе нигезендә туган үткен сүзләренә мөрәҗәгать итә.

А. Садекованың «Фольклор в эстетике Г. Ибрагимова» дигән хезмәтендә төрки-татар эпик традицияләренең Г. Ибраһимов иҗатында сәнгати яктан чагылыш табуын тикшерүгә юнәлтелгән. Анда галим Г. Ибраһимов әсәрләрендә милли характер һәм милли рухның гәүдәләнүен, әсәрләрнең мажаралык белән сугарылганын күрсәткән [5, б. 16].

Татар әдәбиятында мифологик образларга мөрәҗәгать иткән язучылар күп. Мәсәлән, Г. Тукайның «Су анасы», ««Шүрәле», «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш», Г. Афзалның «Мусалар токымы», Н. Фәттахның «Сызгыра торган уклар», Х. Камаловның «Хиросима төне».

Г. Ибраһимов та үзенең иҗатында татар фольклорына һәм мифларга еш мөрәҗәгать итә. Аның «Яз башы» (1910) хикәясе халык иҗатына нигезләнгән. Аннары бу мотивны «Диңгездә» (1911) хикәясендә дә күрәбез. Бу ике әсәрдә язучы тылсымлы әкиятләрдәге аждаһа образына мөрәҗәгать итә.

«Яз башы» хикәясендә Салихның туган авылында иптәшләре белән үткәргән бер көне, балыкка бару вакыйгасы тасвирлана. Табигать кочагында ял итәргә, балык тотарга барган геройларның бәхетле көне куркыныч аждаһа турындагы ышану белән караңгылана, әсәргә әкиятләргә хас фантастик элементлар килеп керә. Хикәядә халыкның «аждаһа» образы турындагы ышануы түбәндәгечә күрсәтелә: «*Көн үтеп кояш баткач, җил-давыл күтәрелеп һаваны кара болыт каплый. Малайлар куркудан өйгә кайтырга җыена. Ә өйгә кайту юлы камышлык аша үтә. Анда риваятьләр буенча куркыныч аждаһа яши»* [2, б. 52]. Шул рәвешле, язучы татар халкының мифологик ышануына мөрәҗәгать итә.

Халыкта еланның йөз ел яшәгәч аждаһага әйләнүе турында ышану бар. Ә аждаһа турында дөньяда мең ел яши, ләкин ул татарлар торган җирдә булмый дип ышаналар. Каюм Насыйри аждаһага мондый аңлатма бирә:

«*Аны болыт күтәреп ала да диңгез атавына илтеп ташлый. Татарларның фикеренчә, аҗдаһаны болыт алган вакытта, ул һавада койрыкларын болгый, бик каты селкенә. Атауда мең ел яшәгәч, аҗдаһа юха кызга әйләнә*» [4, б. 183].

Белүебезчә, аждаһа – тылсымлы әкият героеның дошманы. Ул әкиятләрдә берничә башлы итеп сурәтләнә. Аждаһа гадәттә диңгездә яисә су (елга) буенда яши һәм кешеләргә су бирми. Әкиятләрдә аждаһаның күңелен күрү өчен аңа кызларны корбан итәләр. Чират патша кызына җиткәндә, әкият герое аждаһа белән сугышып, аны җиңә һәм кызларны афәттән коткарып кала. Кагыйдә буларак, егет үзе коткарган патша кызына өйләнә.

Л.Ш. Җамалетдинов аждаһа образын тикшереп бу образның үсешендә ике этап аерып күрсәтә. Бик борынгы заманда ул, тотем буларак, кешеләргә яхшылык эшләүче итеп уйланылса һәм хөрмәт ителсә [1, б. 44], соңга таба кешенең дошманына әверелә. Бу икенче этапта, тотемизм кире кагылгач, еланның кешене йотуы ерткычлык акты итеп санала башлаган, һәм, нәтиҗәдә, әкиятләрдә елан белән сугышу турындагы сюжетлар барлыкка килгән [1, б. 44].

Хикәядә Г. Ибраһимов аждаһаны түбәндәгечә күрсәтә: *«Ул камышлы һәм кеше керә алмый торган күтерлекләрдә була, ди. Аны минем бабам күргән: буе унбиш колач, калынлыгы ат чикле, ди. Шундый батыр, ди, сулышы-теше белән зур үгезләрне ерактан суырып аладыр, ди. Ул шул камышта ята бирә, ди. Әгәр дә тирә-якка зыяны булмаса, ята да ята, ди. Зыян итә башласа, маллар, адәмнәр, хайваннар алса, болыт килеп, җил-давыл белән күтәреп китә, ди.*

*Шуннан алып китә, китә, китә икән дә, ди, җиде диңгезне, җитмеш дәрьяны чыгып, Каф тауларына алып барып, гел еланнар, аҗдаһалар гына кайнап, ыжгырып ята торган бер төпсез мәмерҗәгә ташлыйдыр, ди. Моннан күтәргән чакта аждаһа каршы торырга тели икән, ди. Фирештә аны тимер чылбырлар белән авызлыклаган булганга, ай-ваена карамыйча, тарта бирә, аждаһа тирә-яктагы зур агачларга, ташларга урала икән, ди. Ләкин фирештә аны калдырмый, шунлыктан карт агачлар тамырлары белән өзелеп чыгалар, ташлар күчәләр, ди»* [2, б. 54].

Әзербайҗан, татар һәм башкорт мифларында аждаһа су белән, күктәге болытлар белән туры китерелә. Күп очракта, азәрбайҗан һәм башкорт күзаллавында ул күлдә очрый. Татарлар күзаллавы буенча аждаһа диңгез утраучыгында яши [3, с. 50].

Кайвакыт аждаһаның кыланышлары коточкыч рәвеш ала. Казакъ халкының бер табышмагында «аждаһа» («айдаһар») болай сурәтләнә:

> «*Бер Айдаһар Җир йөзен ашап бара,*
> *Барлык сөякләрне авызына җыеп бара.*
> *Авызына Айдаһарның төшкән җаннар,*
> *Ярамам инде эшкә дип калалар*» [7, б. 46].

Г. Ибраһимовның «Диңгездә» әсәрендә дә мифик зат турында бара. Авторның хикәягә керткән тасвирламадан без аждаһага охшаш, корбан сорый торган әкияти мифологик образны күзаллыйбыз. Мәсәлән, *«...Иртә торып, корабның өстенә менсәләр, бик зур бер утрауның агып барганын күрәләр – бу гаҗәп тә, куркыныч та була. Утрауның өстендә кечкенә-кечкенә таулар, ташлар, зуррак агачлар да бар...». «...бу агып барган утрау*

*гади түгел, ул ничә мең еллар яшәгән артык зур балыкларның аркасындагы чәнечкеләренә төрле нәрсә җыела-җыела, күп заманнар үткәч булган “ясалма утрау” икән». «Башта тау-тау булып дулкыннар күренә. Тагы ныклабрак күз салсалар, ниндидер бернәрсәнең, диңгезне икегә ярып, як-ягында дөнья кадәрле дулкыннар ясап, кояш чыгышы ягына таба йөзеп барганын күрәләр...»* [2, б. 68].

Бу мисаллардагы образ татар халык тылсымлы әкиятләрендәге нәкъ шул аждаһа образына охшаш. Ул да диңгезчеләрдән корбан сорый.

Әсәрнең үзәгенә алынган вакыйга – герой белән мифик затлар арасындагы көрәш җәмгыятьтәге явызлык белән яхшылык арасындагы көрәш. Аждаһа – явызлык символы. Аның җиңелүе кешелекнең явызлыкның җиңелүенә ышанычын гәүдәләндерә. Бу хикәяләрдә ачык чагылган сюжет кору, табигать күренешләрен сурәтләү осталыгы, кеше образларының, әсәр каһарманнарының рухи дөньясын, күңел кичерешләрен биредәге психологик нечкәлек, тел, язу стилендәге тасвири чараларның муллыгы Г. Ибраһимовны ул вакыттагы татар прозаикларының иң алгы сафында баручы әдип итеп таныта.

ӘДӘБИЯТ

1. Җамалетдинов Л.Ш. Татар әкиятләрен барлау юлында / төз. И.И. Ямалтдинов. Казан: ТӘһСИ, 2015. 264 б.

2. Ибраһимов Г. Сайланма әсәрләр. Казан, 1957. 1 т. 527 б.

3. Мифы народов мира. Энциклопедия: в 2-х т. / гл. ред. С.А. Токарев. М.: Сов.энциклопедия, 1991. Т. 1. А–К. 671 с.

4. Насыйри К. Сайланма әсәрләр. Казан, 1953. 418 б.

5. Садекова А.Х. Фольклор в эстетике Галимджана Ибрагимова // Галимҗан Ибраһимовның иҗат дөньясында. Казан, 2012. С. 9–103.

6. Татар халык әкиятләре: Әкиятләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 480 б.

7. Урманче Ф.И. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда / Фатих Урманче. Казан: Мәгариф, 2008. 1 т. 303 б.

## СВЕДЕНИЯ ОБ АВТОРАХ

**Абдуллина Диллария Маратовна,** кандидат филологических наук, ведущий научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия*.

**Абзалина Рамзия Асраровна,** старший научный сотрудник Национального музея Республики Татарстана. *Казань, Россия.*

**Алеева Анися Ханифовна,** кандидат филологических наук, старший научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия*.

**Алишина Ханиса Чавдатовна,** доктор филологических наук, профессор, директор центра тюркологии Тюменского государственного университета. *Тюмень, Россия.*

**Аминева Венера Рудалевна,** доктор филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия*.

**Ахмадгалиева Гузалия Габдрауфовна,** кандидат филологических наук, доцент Елабужского института Казанского (Приволжского) федерального университета. *Елабуга, Россия.*

**Ахметова Миляуша Ансаровна,** научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия*.

**Баширова Илида Басыровна,** доктор филологических наук, главный научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия*.

**Булатова Миннира Рахимовна,** кандидат филологических наук, научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия*.

**Вафина Альмира Мухаматназиповна,** учитель высшей категории МБОУ «Школа № 62» Авиастроительного района г. Казани. *Россия*.

**Габидуллина Фарида Имамутдиновна,** кандидат филологических наук, доцент Елабужского института Казанского (Приволжского) федерального университета. *Елабуга, Россия.*

**Гайнуллина Гульфия Расилевна,** кандидат филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия*.

**Гайнутдинов Айдар Марсилевич,** кандидат филологических наук, старший научный сотрудник Института истории им. Ш. Марджани АН РТ.

**Галимзянова Эльмера Махмутовна**, кандидат филологических наук, старший научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия*.

**Галимова Гульшат Наилевна,** аспирант Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия*.

**Галимуллин Фоат Галимуллович,** доктор филологических наук, профессор Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия*.

**Галиуллин Радик Рамилевич,** кандидат филологических наук, доцент, зав. кафедрой татарского языка и литературы, методик их преподавания Набережночелнинского педагогического университета. *Набережные Челны, Россия.*

**Галлямов Филус Гатипович,** доктор филологических наук, профессор Елабужского института Казанского (Приволжского) федерального университета. *Елабуга, Россия.*

**Ганиева-Гиниятуллина Айгуль Фирдинатовна,** кандидат филологических наук, старший научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия*.

**Гарипова Лейля Шамилевна,** кандидат филологических наук, старший научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия*.

**Гаязов Альфис Суфиянович,** доктор педагогических наук, профессор, президент Академии наук Республики Башкортостан. *Уфа, Россия*.

**Гильманов Дамир Шарифзянович,** кандидат филологических наук, заместитель директора по национальному образованию и воспитанию МБОУ «Школа № 31» Ново-Савиновского района г. Казани. *Россия.*

**Даутов Гумар Фильгизович,** кандидат филологических наук, доцент Елабужского института Казанского (Приволжского) федерального университета. *Елабуга, Россия.*

**Денмухаметова Эльвира Николаевна,** кандидат филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия*.

**Жундибаева Арай Канапияновна,** доктор философских наук, доцент Государственного университета имени Шакарима. *Семей, Казахстан.*

**Загидуллина Дания Фатиховна,** доктор филологических наук, профессор, вице-президент Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия*.

**Закирзянов Альфат Магсумзянович,** доктор филологических наук, доцент, зав. кафедрой татарской литературы Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия*.

**Закирова Ильсеяр Гамиловна,** доктор филологических наук, главный научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия*.

**Закирова Лилия Ривгатовна,** кандидат филологических наук, учитель русского языка и литературы МБОУ «Черемшанский лицей». *Россия*.

**Замалиева Луиза Фирдусовна,** кандидат филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия*.

**Зарипова-Четин Чулпан Афраимовна,** кандидат филологических наук, доцент, зав. кафедрой русского языка и литературы Кавказского университета. *Карс, Турция.*

**Ибрагимов Арсений Оскарович,** ученик 7 класса МАОУ гимназии № 115 Советского района г.Уфы Республики Башкортостан. *Уфа, Россия*.

**Ибрагимов Марат Хакович,** председатель правления МОО «Общество защиты прав потребителей». *Уфа, Россия*.

**Ибрагимов Марсель Ильдарович,** кандидат филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия*.

**Идрисов Рауф Рифгатович,** кандидат филологических наук, доцент Башкирского государственного университета. *Уфа, Россия.*

**Каюмова Гелюса Фаридовна,** кандидат филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия*.

**Кириллова Зоя Николаевна,** кандидат филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия*.

**Куртсеитов Рефик Джаферович,** кандидат социологических наук, доцент, заведующий кафедрой социально-гуманитарных дисциплин Крымского инженерно-педагогического университета. *Симферополь, Россия.*

**Мингазова Ляйля Ихсановна,** доктор филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия*.

**Мингазова Резиля Абузаровна,** кандидат филологических наук, преподаватель Набережночелнинского педагогического колледжа. *Набережные Челны, Россия.*

**Миннуллин Ким Мугаллимович,** докто филологических наук, профессор, член-корреспондент АН РТ, директор Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия*.

**Миннуллина Фатыма Халиулловна,** кандидат филологических наук, старший научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия*.

**Миргалимов Ильдар Флусович,** заместитель руководителя Республиканского агентства по печати и массовым коммуникациям «Татмедиа». *Казань, Россия*.

**Мотигуллина Альфия Рухулловна,** кандидат филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия.*

**Мугтасимова Гульназ Ринатовна** кандидат филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия.*

**Мукимова Насима Анваровна,** кандидат филологических наук, доцент Башкирского государственного университета.

**Мулюков Урал Абдуллович,** судья Верховного Суда Республики Башкортостан. *Уфа, Россия*.

**Мухаметзянова Лилия Хатиповна,** доктор филологических наук, доцент, ведущий научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия*.

**Мухаметшин Фанис Мухаметгалиевич,** кандидат филологических наук, учитель высшей квалификационной категорий общеобразовательной школы-интерната «Лицей имени Н.И. Лобачевского» Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия*.

**Мухарлямова Гульназ Нурфатовна,** кандидат филологических наук, старший научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия*.

**Мухитова Галия Масгудовна,** студент 4 курса Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия.*

**Набиуллина Гузель Амировна,** кандидат филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия.*

**Насибуллина Нурида Шайдулловна,** кандидат филологических наук, старший научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия*.

**Насибуллова Гузель Ришатовна,** кандидат филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия*.

**Насипов Ильшат Сахиятуллович,** доктор филологических наук, доцент, зав. кафедрой татарского языка и литературы Башкирского государственного педагогического университета им. М. Акмуллы. *Уфа, Россия.*

**Нурмухаметова Раушания Сагдатзяновна,** кандидат филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия*.

**Османов Длявер Ибраимович,** главный редактор журнала «Йылдыз», секретарь Союза крымско-татарских писателей. *Симферополь, Россия.*

**Рахматуллина Асия Альфритовна,** директор МБУДО «Городской центр творческого развития и гуманитарного образования для одаренных детей» г. Казани. *Россия*.

**Сабитова Ильгамия Исламутдиновна,** кандидат филологических наук, старший научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия*.

**Сагдеева Фаузия Кабировна,** кандидат филологических наук, старший научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия*.

**Салахова Рузиля Рашитовна,** кандидат филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия*.

**Саляхова Зухра Габделахатовна,** кандидат филологических наук, учитель МБОУ «Гимназия № 10» Авиастроительного района г. Казани. *Россия*.

**Самитова Савия Гималтыновна,** кандидат филологических наук, доцент Института социальных и гуманитарных знаний. *Казань, Россия*.

**Саттарова Мадина Рашидовна,** кандидат филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия*.

**Сибгаева Фируза Рамзеловна,** кандидат филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия*.

**Тагирова Фяридя Инсановна,** кандидат филологических наук, ведущий научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия*.

**Тимашева Алина Александровна,** студентка 3 курса Башкирского государственного педагогического университета им. М. Акмуллы. *Уфа, Россия.*

**Тимерова Ландыш Муллануровна,** аспирант Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань*, *Россия*.

**Тухватова Гузель Фардиновна,** кандидат филологических наук, зав. Литературным музеем Г. Тукая. *Казань, Россия*.

**Файзуллина Зиля Магсумовна,** учитель татарского языка и литературы МБОУ «СОШ № 32» Кировского района г. Казани. *Россия*.

**Файзуллина Фания Галимулловна,** старший научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия*.

**Фардеева Динара Радиевна,** кандидат филологических наук, научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия*.

**Фатхтдинов Фаил Камилович,** кандидат филологических наук, доцент, директор – главный редактор издательства «Кызыл таң». *Уфа, Россия*.

**Фатхуллова Кадрия Сунгатовна,** кандидат педагогических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия*.

**Хабибов Лутфулла Гайфуллович,** кандидат филологических наук, доцент, профессор Института развития образования Республики Башкортостан. *Уфа, Россия*.

**Хазиева-Демирбаш Гузалия Сайфулловна,** кандидат филологических наук, старший научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия*.

**Хайруллина Альфира Салихзяновна,** кандидат филологических наук, старший преподаватель Елабужского института Казанского (Приволжского) федерального университета. *Елабуга, Россия.*

**Хакимова Василя Харисовна,** преподаватель Удмуртского республиканского социально-педагогического колледжа. *Ижевск, Россия.*

**Халиуллина Альбина Габитовна,** кандидат филологических наук, доцент Башкирского государственного педагогического университета им. М. Акмуллы. *Уфа, Россия*.

**Халиуллина Нурия Усмановна,** кандидат филологических наук, доцент Башкирского государственного педагогического университета им. М. Акмуллы. *Уфа, Россия*.

**Харрасова Рифа Фатхрахмановна,** кандидат филологических наук, доцент, старший научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия*.

**Хуббитдинова Нэркэс Ахметовна,** доктор филологических наук, ведущий научный сотрудник Института истории, языка и литературы Уфимского научного центра Российской Академии наук. *Уфа, Россия*.

**Хусаинова Алина Ямилевна,** кандидат филологических наук, старший преподаватель Башкирского государственного педагогического университета им. М. Акмуллы. *Уфа, Россия*.

**Хуснутдинова Гульназ Азатовна,** кандидат филологических наук, старший научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия*.

**Шакирзянова Алия Расиховна,** студентка Башкирского государственного педагогического университета им. М. Акмуллы. *Уфа, Россия*.

**Шакурова Муслима Магесумовна,** кандидат филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия*.

**Юсупов Айрат Фаикович,** кандидат филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия*.

**Юсупова Альфия Шавкетовна,** доктор филологических наук, профессор, директор Высшей школы татаристики и тюркологии им. Габдуллы Тукая Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия*.

**Юсупова Нурфия Марсовна,** кандидат филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия*.

**Яхин Фарит Закизянович,** доктор филологических наук, профессор, зав. отделом текстологии Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия*.

**Яхшисарова Гульнара Рашитовна,** аспирант Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия*.

СОДЕРЖАНИЕ

Приветствие президента Академии наук Республики Татарстан М.Х. Салахова . . . . . 3

Приветствие президента Тюркской академии Дархана Кыдырали . . . . . 5

Приветствие президента Академии наук Республики Башкортостан А.С. Гаязова . . . . . 7

*Заһидуллина Д.Ф.* Галимҗан Ибраһимов идеаллары: «Мин хәят эзләдем, хәятта мәгънә эзләдем...» . . . . . 9

*Ибрагимов М.И.* Вопросы национальной идентичности в статьях Г. Ибрагимова 1910–1920-х гг. . . . . . 16

*Миңнуллин К.М.* Татарларда фәнни-тикшеренү үзәкләре (институтлары) оештыру идеясе һәм Галимҗан Ибраһимов . . . . . 21

*Бәширова И.Б.* Төрки-татар әдәби тел нәзарияте: Галимҗан Ибраһимов иҗаты . . . . . 26

*Галимуллин Ф.Г.* «Безнең юл» журналы һәм Галимҗан Ибраһимов . . . 34

*Мулюков У.А.* Формирование правосознания в произведениях Г. Ибрагимова (на примере романа «Глубокие корни») . . . . . 40

*Фәтхтдинов Ф.К.* Галимҗан Ибраһимовның тормышка карашын формалаштыруда туган ягының үзенчәлекле роле . . . . . 47

*Абдуллина Д.М., Мөхәрләмова Г.Н.* Мәктәптә Г. Ибраһимов иҗатын өйрәнү юллары . . . . . 51

*Абзалина Р.А.* Хөсни Кәрим – татар язучысы, журналист, җәмәгать эшлеклесе . . . . . 57

*Алеева Ә.Х.* Г. Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» әсәрендә хатын-кыз азатлыгы һәм социаль аспектлар . . . . . 59

*Алишина Х.Ч.* Непрочитанные страницы биографии Галимджана Ибрагимова . . . . . 63

*Аминева В.Р.* Творчество Г. Ибрагимова в межлитературном контексте . . . . . 67

*Ахметова М.А.* Особенности изображения деревни в повести «Адәмнәр» («Люди») Г. Ибрагимова . . . . . 76

*Булатова М.Р.* Г. Ибраһимов әсәрләрендә иске язма тел һәм җирле сөйләш үзенчәлекләренә күзәтүләр . . . . . 80

*Вафина А.М.* Г. Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» әсәрендә хатын-кыз язмышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . 85
*Габидуллина Ф.И., Җундибаева А.К.* Флүн Мусин хезмәтләрендә Г. Ибраһимов . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 88
*Гайнетдинов А.М.* Галимҗан Ибраһимовның бөек остазы . . . . . . . 95
*Гайнуллина Г.Р.* Ә. Еники һәм Г. Бәширов тәнкыйтендә Г. Ибраһимов шәхесенә караш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 100
*Галимҗанова Э.М.* Галимҗан Ибраһимов һәм вакытлы матбугат . . . 103
*Галиуллин Р.Р.* Социалистик релизмның детектив формага йогынтысы (Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романы мисалында) . . . . . . 106
*Галләмов Ф.Г.* Г. Ибраһимов әсәрләрендә гомумиләштерүче сүзле тиңдәш кисәкләрнең кулланылу үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . 112
*Ганиева-Гыйниятуллина А.Ф.* «Яшь йөрәкләр» романының фәлсәфи-психологик үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 118
*Гаязов А.С.* Образ малой родины в творчестве Галимджана Ибрагимова (на примере рассказа «Чубарый») . . . . . . . . . . . . 122
*Гыйльманов Д.Ш.* Үз ялкынында дөрләп янган әдип . . . . . . . . . . 126
*Даутов Г.Ф., Әхмәдгалиева Г.Г.* Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» романында татар милли мәгариф системасының бирелеше . . . . . . 128
*Денмөхәммәтова Э.Н.* Татар телендә гарәби чыгышлы фигыльләр һәм аларның Г. Ибраһимов әсәрләрендә кулланылышы . . . . . . . . 132
*Җамалиева Л.Ф.* Г. Ибраһимов хезмәтләрендә татар фольклоры мәсьәләләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 137
*Заһидуллина Д.Ф.* «Казан утлары» журналы тарихына кайбер мәгълүматлар һәм Галимҗан Ибраһимов эшчәнлеге . . . . . . . . . . 142
*Закирҗанов Ә.М.* Г. Ибраһимов һәм татар әдәбияты Яңарышы . . . . 146
*Закирова И.Г.* Сабан туе бәйрәменең Г. Ибраһимов иҗатында чагылышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 149
*Закирова Л.Р., Габидуллина Ф.И.* Г. Ибраһимов әсәрләрендә өстәлмәләр һәм аларның лексик-семантик үзенчәлекләре . . . . . . . 153
*Зарипова-Четин Ч.А.* Традиции и культурные ценности тюркских народов в произведениях Г. Ибрагимова . . . . . . . . . . . . . . . 156
*Ибрагимов А.О., Ибрагимов М.Х.* «Галимджан Ибрагимов – глазами молодых» десять лет и вся жизнь… . . . . . . . . . . . . . 161
*Идрисов Р.Р.* Галимҗан Ибраһимов һәм Әмирхан Еники . . . . . . . . 164
*Каюмова Г.Ф.* Г. Ибраһимовның «Көтүчеләр» хикәясендә Вахитның романтик эзләнүләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 167
*Кириллова З.Н.* Г. Ибраһимов иҗатында ияртүче теркәгечләр . . . . . 170

*Куртсеитов Р.Д.* Литературная и общественная деятельность Галимджана Ибрагимова сквозь призму современности . . . . . . . 175
*Минһаҗева Л.И.* Галимҗан Ибраһимов: шәхесе һәм традицияләр хакында уйланулар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 179
*Минһаҗева Р.Ә.* Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романында ике мәхәббәт моделе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 182
*Миңнуллина Ф.Х., Гарипова Л.Ш.* Г. Ибраһимов иҗатында шәхес фаҗигасе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 187
*Миргалимов И.Ф.* Концепт *пространство* в прозе Г. Ибрагимова . . . . 193
*Мотыйгуллина Ә.Р.* С. Поварисовның тарихи-биографик трилогиясендә Галимҗан Ибраһимов образы . . . . . . . . . . . . 196
*Мөгътәсимова Г.Р.* Г. Ибраһимов әсәрләренең русчага тәрҗемәләрендә реалияләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 202
*Мөкимова Н.Ә.* Рус телле мәктәпләрдә Г. Ибраһимов иҗатын өйрәнүнең кайбер аспектлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 205
*Мөхәммәтшин Ф.М.* Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романының кайбер үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 208
*Мухаметзянова Л.Х.* Начальный этап изучения татарского эпоса: деятельность Г. Ибрагимова . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 211
*Мухарлямова Г.Н.* Изображение исторического времени и пространства в романе Г. Ибрагимова «Наши дни» . . . . . . . . . 214
*Насибуллова Г.Р.* Г. Ибраһимов әсәрләренең тәрҗемә мәсьәләләре . . . 221
*Насипов И.С.* XX гасыр азагы – XXI гасыр башында Башкортстанда Галимҗан Ибраһимов мирасын өйрәнү, саклау һәм пропагандалауның аерым аспектлары турында . . . . . . . . . . 224
*Насыйбуллина Н.Ш.* Суфиян Поварисов трилогиясендә Галимҗан Ибраһимов шәхесе («Пәйгамбәр таңы», «Күкнең җиденче катында», «Оҗмахка бер адым») . . . . . . . . . . . . . . . . . 228
*Нәбиуллина Г.Ә.* Г. Ибраһимов әсәрләрендә канатлы гыйбарәләр . . . . 233
*Нурмөхәммәтова Р.С.* Этнографик мәгълүмат чыганагы буларак Г. Ибраһимов мирасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 236
*Османов Д.И.* Галимҗан Ибраһимов һәм Кырым . . . . . . . . . . . 241
*Рәхмәтуллина А.А.* Г. Ибраһимов хикәяләрендә әхлак проблемасы . . . 243
*Сагдеева Ф.К.* Концепт *хатын-кыз (женщина)* как фрагмент индивидуально-авторской картины мира Г. Ибрагимова . . . . . . . . 246
*Саттарова М.Р., Мохитова Г.М.* Галимҗан Ибраһимов әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итү үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . . . . . . . 250
*Сәлахова З.Г.* Г. Ибраһимовның «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясендә натуралистик алымнарның гәүдәләнү үзенчәлеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 254

*Сәлахова Р.Р.* Г. Ибраһимовның «Алмачуар» әсәрендә сөйләм эшчәнлеген белдергән фигыльләрнең функциональ-семантик кыры . 260

*Сәмитова С.Г.* Г. Ибраһимов иҗатында мәхәббәт мотивы . . . . . . . . 264

*Сибгаева Ф.Р.* Г. Ибраһимов иҗатында фразеологик берәмлекләрнең стилистик әһәмияте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 268

*Тагирова Ф.И., Сабитова И.И.* Произведения Г. Ибрагимова как объект лексикологических изысканий (на примере названий одежды) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 272

*Тимашева А.А.* Мәктәптә Галимҗан Ибраһимовның тормышын һәм иҗатын өйрәнү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 275

*Тимерова Л.М.* И. Нуруллин күзаллавында Г. Ибраһимовның инкыйлабкача прозасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 277

*Төхвәтова Г.Ф.* «Мин хәяте мотлак кешесе...» (ТР милли музее фондларында Г. Ибраһимовның Ә. Хәсәнигә язган хатлары) . . . . . . 280

*Фардеева Д.Р.* Инсценизация произведения «Судьба татарки» Г. Ибрагимова . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 283

*Фәйзуллина З.М.* Мәктәптә Г. Ибраһимовның «Алмачуар» әсәрен кеше һәм табигать берлеге яссылыгында өйрәнү . . . . . . . . . . . . 288

*Фәйзуллина Ф.Г.* Г. Ибраһимов публицистикасында «Галия» мәдрәсәсе темасы яктыртылышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 290

*Фәтхуллова К.С.* Татар телен укытуның яңа юлларын эзләү . . . . . . 294

*Хаҗиева-Демирбаш Г.С.* Г. Ибраһимов идиостилендә кушаматлар . . . 297

*Харрасова Р.Ф.* Г. Ибраһимов хезмәтләрендә «интеллигенция һәм инкыйлаб» темасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 301

*Хәбибов Л.Г.* «Безнең көннәр» романында Галимҗан Ибраһимовның сүз ясау һәм калькалаштыру тәҗрибәсе . . . . . . . . 306

*Хәйруллина Ә.С., Даутов Г.Ф.* Галимҗан Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романында күтәрелгән чор проблемалары . . . . . . 310

*Хәкимова В.Х.* Галимҗан Ибраһимов һәм Кедра Митрей иҗатлары чагыштырма планда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 313

*Хәлиуллина А.Г.* Г. Ибраһимов хикәяләрендә хронотоп үзенчәлеге . . . 317

*Хәлиуллина Н.У., Шакирҗанова А.Р.* Г. Ибраһимовның «Алмачуар» хикәясендә эмотив лексика . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 323

*Хөббитдинова Н.Ә.* Ғәлимйән Ибраһимовтың «Алмасыуар» хикәйәһе традицияларының башҡорт халыҡ ижады менән ауаздашлығы хаҡында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 325

*Хөсәинова А.Җ.* Г. Ибраһимов иҗатында татар фольклоры . . . . . . . 328

*Хөснетдинова Г.А.* Ярдәм юлында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 332

*Шәкүрова М.М.* Укырга-язарга өйрәтүнең яңа юлларын эзләү чоры . . . 336

*Юсупов А.Ф.* Галимҗан Ибраһимовның ана телен укыту эчтәлегенә бәйле методик карашлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 340

*Юсупова А.Ш., Галимова Г.Н.* Речевые стереотипы в произведениях Г. Ибрагимова . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 343

*Юсупова Н.М.* Г. Ибраһимовның «Татар шагыйрьләре» хезмәтендә Г. Тукай әсәрләренең стиле һәм поэтикасы мәсьәләсе . . . . . . . . . . 346

*Яхин Ф.З.* Г. Ибраһимов «Мөселман иттифакы» партиясе хакында . . . 350

*Яхшисарова Г.Р.* Галимҗан Ибраһимовның «Яз башы» һәм «Диңгездә» хикәяләрендә аждаһа образы . . . . . . . . . . . . . 355

Сведения об авторах . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 358

**МӘДӘНИЯТЛӘР ТӨРЛЕЛЕГЕ КОНТЕКСТЫНДА
ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ МИРАСЫ**

**Халыкара конференция материаллары
2017 елның 25 апреле, Казан шәһәре**

**ГАЛИМДЖАН ИБРАГИМОВ
В КОНТЕКСТЕ МНОГООБРАЗИЯ КУЛЬТУР**

**Материалы международной конференции
25 апреля 2017 года, город Казань**

Материалы публикуются в авторской редакции

Компьютерная верстка *Н.Т. Абдуллиной*

Подписано в печать: 24.04.2017 г.
Формат 70×108 1/16. Гарнитура «Таймс». Бумага офсетная, печать офсетная
Усл.-печ. л. 32,2. Уч-изд. л. 28,5. Тираж 500

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. Лобачевского, 2/31

Отпечатано ООО «Фолиант»
420111, Казань, ул. Профсоюзная, 17В